Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты

Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова
Академии наук Республики Татарстан

Казан • Казань
2024

**Духовное наследие**
Поиски и открытия
*Выпуск 23*

**Габдрахман Сагди**

# ИЗБРАННЫЕ СОЧИНЕНИЯ

Том 2

**Рухи мирас**

Эзләнүләр һәм табышлар

*23 нче чыгарылыш*

**Габдрахман Сәгъди**

# САЙЛАНМА ӘСӘРЛӘР

2 нче том

УДК 94 (093)
ББК 63.2
С 93

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты*
*Гыйльми советы карары нигезендә нәшер ителә*

Проект «Татар халкының милли үзенчәлеген саклау»
ТР Дәүләт программасы кысаларында ТР Фәннәр академиясе
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының
Язма мирас үзәге тарафыннан гамәлгә ашырыла

**Редколлегия:**
***И.Г. Гомәров*** *(проект җитәкчесе),*
***Д.Ф. Заһидуллина, А.М. Ахунов***

**Фәнни редактор**
*филология фәннәре кандидаты* ***И.Г. Гомәров***

**Рецензентлар:**
*филология фәннәре кандидаты,*
*Язма мирас үзәге әйдәп баручы хезмәткәре* ***Л.Ш. Гарипова,***
*текстология бүлеге фәнни хезмәткәре* ***Г.М. Ханнанова***

**С 93** **Сәгъди Г. Сайланма әсәрләр.** Т. 2 / Г. Сәгъди; төз., текст. иск. һәм аңл. әзерл.: Л.Р. Надыршина, И.Г. Гомәров; кереш сүз авт. Л.Р. Надыршина. – Казан: ТӘһСИ, 2024. – 352 б. («Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар = Духовное наследие: поиски и открытия» сериясе. 23 нче чыгарылыш).
ISBN 978-5-93091-496-2

Җыентык татар халкы рухи мирасының нигезен тәшкил итүче әсәрләрне өйрәнү, аз билгеле язма чыганакларны бастырып чыгару, татар текстларын өйрәнү барышындагы яңа табышлар белән укучыларны таныштыру традициясен дәвам итә.

Чираттагы чыгарылыш тел һәм әдәбият галиме, мәгариф эшлеклесе, педагог Габдрахман Сәгъдинең (1889–1956) «Татар әдәбияты тарихы» хезмәтен үз эченә ала. Әлеге хезмәт гамәлдәге хәрефләр белән кыскартуларсыз беренче тапкыр басыла.

Басма белгечләр, татар тарихы һәм мәдәнияте белән кызыксынучы киң катлау укучылар игътибарына тәкъдим ителә.

ISBN 978-5-93091- 496-2 (2 т.)
SBN 978-5-93091-495-5

© ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге
Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2024

# КЕРЕШ

«Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар» сериясенең әлеге чыгарылышында урын алган «Татар әдәбияты тарихы» – Габдрахман Сәгъдинең татар сүз сәнгате өлкәсендәге күпьеллык фәнни эзләнүләренең нәтиҗәсе. Сүз башында галим үзе аңлатып үткәнчә, хезмәт өчтомлык итеп уйланылган булган: аның беренче кисәге борынгы төрки-татар чыганакларыннан башлап XIX йөзгә кадәрле әдәби үсешне тасвирларга тиеш булса, укучы хөкеменә тәкъдим ителгән бу китапта инде XIX гасырның икенче яртысыннан алып XX гасыр башына кадәрге милли әдәбиятка тәфсилле, киң колачлы күзәтү ясала. Шул ук вакытта әдәби барышны эзлекле бер система итеп карауның әһәмиятен яхшы аңлаган Г. Сәгъди беренче чорга да кыскача иҗтимагый-тарихи һәм әдәби күзәтү биреп үтә: үзе тасвирларга алынган дәвер әдәбиятының үсеш алшартларын билгеләп чыга. Бу мәгълүматлар, һичшиксез, хезмәтне тулыландыра, татар сүз сәнгатендә озак гасырлар дәвамында өстенлек итә килгән төп тенденцияләрне күзалларга мөмкинлек бирә.

XX йөз башы татар яңарышының үзәгендә кайнаган шәхес һәм тирән фикерле, эрудицияле галим буларак, Г. Сәгъди әдәбият тарихын иҗтимагый тарих, мәдәният-сәнгать үсеше белән тыгыз бәйләнештә карый. Күпсанлы чыганакларга таянып, ул XIX гасырдагы реформачылык хәрәкәте, милли тел формалаштыру юнәлешендәге эшчәнлек, һәртөрле фәннәр үсеше, әдәбиятның европалашуга йөз белән борылуы, әдәби төрләр һәм жанрларның киңәя баруы – гомумән, татар әдәбиятын «алтын» дәверенә китереп җиткергән әһәмиятле юнәлешләрне тасвирлап бирә, XX йөз башында да милли әдәбият үсешенең иҗтимагый-сәяси вазгыять һәм мәдәни үзгәрешләр белән турыдан-туры бәйлелеген дәлилли, укучыны әдәбият үсешенең милли аң үсешеннән аерылгысыз булуы турындагы фикергә этәрә.

Хезмәттә әнә шундый киң колачлы күзәтүләр аерым әдипләрнең тормыш һәм иҗат биографиясен, киңкырлы эшчәнлеген яктырткан, аерым әсәрләренә анализ биргән монографик бүлекчәләр белән аралашып килә. Каюм Насыйри, Ризаэддин Фәхреддин, Галиәсгар Камал, Гаяз Исхакый, Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури, Дәрдмәнд, Галимҗан Ибраһимов, Фатих Әмирхан, Сәгыйть Сүнчәләй, Шәриф

Камал, Нәкый Исәнбәт, Шәехзадә Бабич һ. б. шәхесләр хакындагы язмалар аерым әдипнең иҗат портреты гына булып калмыйча, татар әдәбияты үсешенең төп юнәлешләрен, сүз сәнгатенә сыйфат үзгәреше алып килгән күренешләрне барларга мөмкинлек бирә. Шунысы игътибарга лаек: теоретик әзерлекле, рус һәм Европа әдәбият белеме фәне казанышлары белән яхшы таныш галим буларак, Г. Сәгъди үзе игътибар үзәгенә куйган каләм ияләренең иҗатын югары фәнни кимәлдә анализлап бирүгә ирешә, бу тикшеренүләр бүгенге көндә дә актуальлеген саклыйлар.

Гомумән, Г. Сәгъдинең әлеге китабы, үзеннән элгәреге Г. Рәхим һәм Г. Газизнең «Татар әдәбияты тарихы» белән беррәттән, һичшиксез, татар сүз сәнгате тарихын фәнни өйрәнүгә нигез салган, аның хәзерге галимнәр өчен терәк булырдай концепциясен булдырган олы һәм фудаменталь хезмәтләрнең берсе буларак бәяләнергә тиешле.

1926 елда гарәп язуында Казанда дөнья күргән «Татар әдәбияты тарихы»ның бер өлеше, филология фәннәре кандидаты Чулпан Малик кызы Куракова тарафыннан кирилл хәрефләренә күчерелеп, 2008 елда «Шәхесләребез» сериясеннән Г. Сәгъдигә багышланган фәнни-биографик җыентыкта урын алган иде, һәм ул текст шушы китапны эшләгәндә дә файдаланылды. «Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар» сериясенең әлеге чыгарылышында исә Г. Сәгъдинең «Татар әдәбияты тарихы» хезмәте, гамәлдәге графикага кыскартуларсыз күчерелеп, фәнни аңлатмалар һәм шәрехләүләр белән тулыландырылып, фәнни даирәгә тулы рәвештә тәкъдим ителә. Китап әдәбият белгечләренә генә түгел, гомумән, татар тарихы, татар теле һәм мәдәнияте, этнографиясе белән кызыксынучыларга да кыйммәтле чыганак булыр дип ышанабыз.

*Ләйсән Надыршина,*
*филология фәннәре докторы*

# БЕРНИЧӘ СҮЗ

Алдыгызга куелган шушы китап – мөхәррир тарафыннан татар әдәбияты тарихыннан бөтен бер кулланма рәвешендә язылырга уйланган өч бүлек китапның икенчесе. Моның беренчесе татар әдәбиятының XIX йөзнең соңгы ярымынача булган беренче дәвер турында язылачак. Өченчесе исә Октябрь белән башланган өченче дәвергә, ягъни Октябрь революциясеннән хәзергәчә булган әдәбиятка багышланачак. Шуның белән бөтен бер татар әдәбияты тарихын марксизм нигезендә мәгълүм бер системга куешуда бер кешенең кулыннан килә алган хезмәт үтәлгән булыр дип өмет ителә.

Татар әдәбияты тарихын язуга керешкәндәге планыбыз башта ук менә шулай иде. Бу икенче китап, әнә шушы план буенча, иң ашыктырып чыгарылырга тиешлесе булды. Чөнки бу китапта төп мәүзуг[1] ителгән икенче дәвер турында укучыларыбыз өчен дә, укытучыларыбыз өчен дә бер кулланма яисә бер дәреслек мәйданда юк. Кыскасы, төгәл бер әдәбият тарихы рәвешендә тәртипкә салынып тикшерелү һәм шул юл белән төзелү мәгънәсе белән бу дәвер бездә әле эшләнмәгән, кул тигерелмәгән; шуның өстенә мәктәпләребездә дә бу – иң нык тикшерелеп үтәргә тиеш булган бер дәвер.

Шуның өчен, артык зур мәсьүлиятле[2] бер хезмәт булуына карамастан, бу дәвер турындагы шушы китапны башкаларыннан элек чыгару мөхәррир тарафыннан да, Гыйльми Үзәк тарафыннан да тиеш табылды.

Беренче һәм өченче дәвер турында бераз соңлап чыкканда да зарар күп булмаячак кебек күренде. Чөнки беренче дәвер турында Г. Рәхим, Г. Гобәйдуллиннарның әдәбият тарихлары әзме-күпме материал бирү хезмәтен үтәп тора алачаклар. Әмма өченче дәвер – Октябрьдән соңгы дәвер әдәбияты исә әле ул укучыларга бик якын, байтак ягы белән аларга мәгълүм дә. Алар турында гәзит-журналлардагы тәнкыйтьләр, тикшерүләр дә алар өчен ярдәмгә җитешеп тора алалар.

Шуның белән бергә, бу икенче китапта да беренче дәверне бөтенләй игътибарсыз да калдырмадык, калдыра алмадык. Чөнки, бердән, укучылар алдына икенче дәвер өчен әдәби-фикри бер хәзерлек адымы ясап үтүгә, һәрхәлдә, хаҗәт бар; икенчедән, әдәби-иҗтимагый үсү тарихыбызның баш – караңгы ягын икенче дәвердән

[1] Мәүзуг – тема.
[2] Мәсьүлиятле – җаваплы.

бөтенләй аерып, өзеп, бәйләнешсез итеп калдырырга да ярамады. Шуның өчен китапта әүвәл ул дәвер турында да, икенче дәвергә хәзерлек баскычы һәм бер башлангыч рәвешендә, кыска гына булса да, шул ук марксизм сызыгында торып, бераз тукталып үтәргә мәҗбүр булдык. Моны беренче дәвернең конспекты һәм дә бик кыскалык белән язылган мәтене[1] рәвешендә генә аңларга кирәк булыр.

Китап – күпьеллык тәҗрибә нәтиҗәсе. Аның материаллары күптәннән хәзерләнеп, язылып килде. Ләкин шуңа китапның соңгы мәртәбә төзелеп тәмамлануында Татар Коммунистлар университетында мөхәррир тарафыннан укытылган әдәбият дәресләренең ысул һәм материаллары зур тәэсир ясаганын кушарга кирәк.

Китапта мөхәррирнең иң кызу, иң нык омтылган бер ноктасы бу дәвер әдәбиятының үсү, киңәю, юнәлү нокталарын марксизм сызыгында дөрес билгеләргә тырышу, шул ук сызыкта торып, аның багланышларын, буыннарын дөрес һәм ачык билгеләп, мәгълүм бер системга куешу булды.

Әнә шушы максудның бер кешенең кулыннан килә торган өлешенең күбрәге үтәлгән булса, мөхәррир шуның белән үзен бәхетле саный.

Шуның белән бергә, шул максудка ирешү юлыннан мөхәрриргә башкаларның ярдәм һәм булышлыклары да тимәде түгел. Рабфакларда, бигрәк тә Татар Коммунистлар университетында эшләү мөхәрриргә бу турыда зур ярдәм итте.

Китап бер әдәбият тарихы булып язылды. Әдәбият тарихы исә иҗтимагый-әдәби хадисәләрнең[2] һәм шулар турындагы төрле тәнкыйть вә тикшерүләрнең бер нәтиҗәсе, гомуми бер якүне[3] булып төзелергә тиеш, шуның өчен тарихчы үз тикшерүе белән бергә ул әдәби хадисәләр турында башкаларның иҗаби[4] һәм сәлби[5] бөтен фикерләре белән дә нык хисаплашып, аларны да нык тәхлил итеп[6] барырга тиеш, һәм ул шуңа мәҗбүр.

Шунлыктан китапны язуда башкаларның хаклы фикерләрен дә күрсәтә, әйтә бару юлы тотылды, мәнбәгъләр[7] дә ачык күрсәтелә барылды.

---

[1] Мәтене – *биредә:* төп эчтәлеге.
[2] Хадисәләрнең – күренешләрнең.
[3] Якүне – йомгагы.
[4] Иҗаби – уңай, уңышлы.
[5] Сәлби – кире, инкяр ителгән.
[6] Тәхлил итеп – анализлап.
[7] Мәнбәгъләр – чыганаклар.

Бер халыкның әдәбият тарихын тәмам тулы итеп, җиренә җиткереп язу өчен, ул халыкның иҗтимагый тарихы нык, төгәл тикшерелгән, эшләнгән, шул турыда бөтен иҗтимагый дәверләребезне эченә алырлык мәнбәгъләр, материаллар хәзерләнгән булу кирәк. Бездә исә әле иҗтимагый тарихыбыз өчен материаллар аз. Әле ул турыда булган тикшерүләр дә төгәл бер хезмәт булып тәмамланмаганнар. Әнә шул яктан әдәбият тарихчысы өчен күп читенлекләр туа. Бу читенлекләрдән бу китапны язучы да котыла алмады.

Ахырда шуны әйтергә кирәк: китап – ялгыз шигырь әдәбияты, матур әдәбият тарихы гына түгел, гомумән әдәбият тарихы. Бер халыкның әдәбият тарихы булгач, шулай булырга тиеш тә. Шигырь әдәбиятының тарихын гына алу ул бөтен бер нәрсәнең тик бер тармагын гына тикшерү шикелле ярым-йорты бер эш булып калыр иде. Шуның өчен китапта шигырь булсын, белем һәм җәмәгатьчелек әдәбияты булсын – барысы бергә уртак алынып тикшерелде. Бөтен иҗтимагый, әдәби хадисәләр бергә багланып барылды. Урта, югары мәктәпләрдә мөхәррирнең әдәбиятны шушы метод белән укытып килү тәҗрибәләре дә бу юлның күп файдалы, кызыклы, хәятлы бер юл икәнен күрсәттеләр. Ахырда матбугатка да шул юл белән чыгуны теләдек. Бу бабтагы[1] бу беренче тәҗрибә, беренче адым күпме уңышлы булыр – анысын тәнкыйть күрсәтер. Хаталары булса, тагы тәнкыйть төзәтер. Шуңа нык ышанып калабыз.

Китапка борынгы дәвер әдәбиятыннан һәм икенче дәвернең классик әдипләренең тел-өслүб һәм тасвирларыннан мәсьәләне ачык сурәтләндерү өчен кирәкле булган байтак мисаллар да кертелгән иде. Ләкин китапның күләме артык зураеп, ул күләмдә бастырганда китап алучылар өчен артык кыйбат төшү өстенә, бу хәл Дәүләт нәшриятын да кәгазь ягыннан уңайсыз хәлгә куячак булганга, Дәүләт нәшриятының соравы буенча, китапны яңадан кыскартырга, һәм шулай итеп кирәкле мисалларны төшереп калдырып, тик шуларның укылырга тиешле икәнен урыннарында әйтеп үтәргә мәҗбүр булдык. Мисаллардан башка тагын байтак мәгълүматлар да кыскартылды. Имкян[2] булганда, киләчәк басмаларда болар тутырылачактыр.

*Габдрахман Сәгъди*

*1926 ел, август, Казан*

[1] Бабтагы – *биредә:* юнәлештәге.

[2] Имкян – мөмкинлек.

# [БЕРЕНЧЕ ДӘВЕР]

## [I]
## КЕРЕШ
### Әдәби дәверләр турында берничә сүз

Татарның XVI йөздән соңгы көнкүреш тарихы һәм иҗтимагый-әдәби хәрәкәтләре үзләренең төп сыйнфый-икътисади нигезләре белән зур өч дәвергә[1] аерылалар:

1) XIX йөзнең соңгы ярымынача булган бер дәвер. Бу дәвер, мәшһүр тәгъбире буенча[2], борынгы дәвер – «кадим Шәрык» дәвере дип атала. Моны икенче төрле итеп, икътисади мәгънәсе белән әйткәндә, феодаллык, алпавытлык нигезендә, шуның коллыгында яшәү дәвере дия алабыз.

2) XIX йөзнең ярымыннан Октябрь революциясенәчә (1917 елгача) булган бер дәвер. Бу инде – татарның феодаллыктан капиталистлыкка, буржуалыкка омтылу, шуңа әйләнү дәвере; бу дәвер «җәдитлек» – яңару, яурупалашу һәм татар буржуазиясенең дини-милли хәрәкәте дәвере булып үсте.

3) Октябрьдән соңгы дәвер. Октябрь революциясе белән ишеге ачылган бу дәвер – буржуалыкны, буржуа капиталистлыгын җимереп, хосусый милекне бетерү; яңа икътисади нигездә, советчылык юлында социализм – коммунизм тормышын төзергә керешү дәвере.

Икенче дәвергә нинди иҗтимагый-әдәби хәзерлекләр белән килеп кердек?

## [II]
## БЕРЕНЧЕ ДӘВЕРГӘ КЫСКАЧА ГОМУМИ БЕР КАРАШ
### (Икенче дәверләргә хәзерлек урынында)

*Беренче дәвергә кыскача бер характеристика – Беренче дәвердә татарның икътисади-иҗтимагый тормышы һәм сыйнфый бүленүләр – Татарда сәүдә капиталы һәм купецлык – Татар бужуазлана – Беренче дәвердә идеология – Татарда язу теле һәм язма дини әдәбият – Әдәби-*

[1] Әдәбиятыбызның тарихын болай өч дәвергә бүлү татар әдәбиятын тикшерүдә марксизм методын татбикъ итүче Галимҗан Ибраһимовның бүлүе буенча эшләнде. *(Авт. иск.)*

[2] Мәшһүр тәгъбире буенча – гомум кабул ителгән, һәркемгә билгеле булган.

*ятта өметсезлек һәм шуның өчен икътисади-иҗтимагый зәмин*[1] *– Татарның тәрбия һәм идеология урыны, идеология вәкилләре – Мәхкәмәи шәргыя һәм татар идеологлары – Тәсаувыф лирикасы – Дини-нәсери әдәбият – Дини реформа чаткысы һәм акылга ирек сорауда беренче адым – Фикри хәрәкәттә Курсавиның эшләре – Сыйнфый лирика – Гыйшык дастаннары – Кыска сүз*

**Беренче дәвергә кыскача бер характеристика.** Гомуми хәлләрнең барышы ягыннан карап, бу беренче дәверне, кыскачарак итеп әйткәндә, болай характерландыра алабыз. Бу дәвер Русиядәге крестьяннарның җиргә беркетелгән, биләмә колчылыкның («крепостное право»ның) мәйданга чыккан (XVI–XVIII йөзләрдә), Русиядә шәһәр хуҗалыгы башланып, натураль хуҗалыктан акча хуҗалыгына күчелгән, сәүдә капитализмы башланган (XVIII йөздә) һәм дә шушы нигездәге Русия патшалыгының татар халкын икътисади яктан да, иҗтимагый вә мәдәни яктан да аерым рәвештә изү сәясәте йөртелү өстенә, татар халкының үзенең эчендә дә феодалчылык, алпавытлык дәвам иткән, шулай ук татарда да сәүдә капитализмы үсә башлаган бер дәвердән гыйбарәт.

**Беренче дәвердә татар халкының икътисади-иҗтимагый тормышы.** Казан ханлыгы заманында да татарның икътисади, сәяси тормышы төп яктан феодализм нигезендә һәм сәүдә капитализмы сызыгында иде. Татар халкы, Мәскәү патшалыгының колонизация хәрәкәте астында мәхкүм[2] бер халык булып калганнан соң да, күп вакытларгача, башка бер сыйфаттарак булса да, бу хәленнән аерылмады. Татар массасы өстеннән Казан ханлыгы дәверендә хаким булган дөнья һәм дин феодалларының (хан, бәйләр, мирзалар, сәид, хуҗа, руханиларның) хакимлеге Мәскәүнең көнчыгышка таба колонизация сәясәте файдасына һаман дәвам иттерелде.

Тарихи барыш түбәндәгечә булды: Казан Мәскәү патшалыгы кулына кергәннән соң һәм XVI йөздәге төрле кузгалышларда дөньяви, дини ике канаттан гыйбарәт булган татар феодаллары (бәйләр, морзалар, сәидләр, руханилар) күп кырыла. Исән калганнары да, җир-суларыннан аерылып, илләреннән сөреләләр; үзләре күчеп китеп яисә күчерелеп, Русия империясенең төрле почмакларына сибелә, сүтелә, таратылалар.

[1] Зәмин – нигез.
[2] Мәхкүм – *биредә:* басылган.

Шундый сәяси, икътисади кысынкылыклар сәбәпле, татар бәйләре, мирзалары XVI йөздән үк инде Мәскәү хөкүмәтенә ялчы яисә «йомышлы татар» булып һәм тылмачлык итеп яшәргә мәҗбүр булалар. Шулай итеп, рус феодаллары, рус аристократиясе үз кул астында мәхкүм булып калган татар феодалларыннан, татар аристократиясеннән татар-башкорт илләренең колонизациясен төгәлләү эшендә һәм бөтен Шәрык сәясәте юлында ныклап файдалану юлын тоталар. Татар феодаллары, татар мирзаларының Шәрык сәясәтендә, колонизация хәрәкәтендә күрсәтәчәк хезмәтләрен, арадашлыкларын[1] уйлап, шуннан тагын да яхшырак файдалану өчен, Икенче Екатерина заманында татар феодалларына мөнәсәбәтне яхшырта төшү планы да алга алына. Нәтиҗәдә, Екатеринаның 1787 елдагы фәрманы буенча, татар феодал-алпавытларының, татар мирзаларының хокуклары киңәйтелеп, алар рус сыйныфташлары, ягъни рус алпавытлары белән хокукта байтак тигезләндереләләр[2]. 1788 елда исә, татарлар өчен шул ук Екатеринаның («Әби патша») сәяси хәйләсе буенча Мәхкәмәи шәргыя (Духовное собрание) дә ачылган булып[3], татар рухани феодаллары да татар дөньяви феодаллары булган мирзалар кул астында хөкүмәткә бәгланалар. Шул рәвешчә, бу ике канат татар феодаллары һаман татар халкы өстендәге әүвәлге хакимиятләрен яңа бер сәясәткә корал булу юлында дәвам иттерәләр.

Татарның Шәрык сәясәтендә васита ителүе һәм аның үзенең икътисади тормышының да инде бер ягы белән ныклап Урта Азия сәүдәсенә бәйлануы татарны тормыш рәвешләрендә, киемсалымда, гореф-гадәттә, тәрбиядә, бөтен идеологиядә Шәрыкка – кадим Шәрыкка бәйләп алып бара (моны түбәндә тагын ачыграк аңларбыз).

**Татарда сыйнфый бүленүләр.** Бара торгач, XVIII йөзнең ахырларында йомышлы татарларның, мирзаларның үз араларында төрле икътисади баскычлар туа. Бер яктан – Еникиев, Алкин һәм элек Качим[4], Владимир губернасында, аннан соң Башкортстанда зур җир

---

[1] Васитачылыкларын – арадашлыкларын.

[2] Биредә төгәлсезлек киткән: Екатерина II нең татар морзаларын рус дворяннары белән хокукый яктан тигезләштерегән фәрманы 1784 елда чыга.

[3] Оренбург губернасында ачылганлыгы өчен (элек Уфа да шуның эчендә була) «Оренбург Духовное собраниесе» дип аталып йөртелгән. Мәрҗани башта моны Оренбургта ачылып, соңыннан Уфага күчерелде дисә дә, Риза казый, Мәхкәмәи шәргыянең архивында табылган документларга карап, башта ук Уфада ачылганын яза. *(Авт. иск.)*

[4] Касыйм губернасы турында сүз бара.

иясе булган крепостник Тәфкилев[1] кебек алпавытлар, бай түрәләр; икенче яктан да Сәгыйть Хәлфин[2] шикелле вак чиновниклар, тылмачлар; Мөхәммәджан мөфти (беренче мөфти)[3] кебек алпавытлык һәм дөньяви феодаллык өстенә дини феодаллыкны бергә җыйнаган эре чиновниклар татар руханиларын үз тирәсенә туплый. Шулай итеп, татар руханиларын һәм алар аркылы бөтен татар массасын хөкүмәткә нык баглый башлаган татар хакимнәре мәйданга чыга яисә чыгарылалар. Өченчедән, шулар каршысында «чабаталы мирза»лар, ягъни крестьяннар дәрәҗәсендә үз кул көче белән көн күрә башлаучы ярлылар груһы[4] мәйданга килә. Дүртенчедән, шул ук татар йомышлылары эченнән сәүдәгәрләр тармагы аерылып үсә башлый. Аларның купецлар сословиесенә чыгулары, купецлыкка язылулары көчәйгәннән-көчәя бара. Бу хәл янә шул ук XVIII йөздә күп рус дворяннарының купецлыкка чыгулары белән бергәрәк бара. Татар мирзаларыннан җитешә башлаган бу сәүдә капиталы ияләренә ясаклы, ягъни хокукый яктан ирекле булган крестьяннардан – дәүләт крестьяннары арасындагы кулаклардан чыккан сәүдәгәрләр дә килеп кушылалар.

Шулай итеп, татар сәүдә капиталы груһы төзелә бара. Безгә тарихтан мәгълүм: XVIII йөздә татар халкының күпчелеге ясаклы крестьяннар булалар. «Типтәр, мишәр» дип аталган бу крестьяннар да Казан ханлыгы тирәсеннән Башкортстан, Оренбург, Әстерхан губерналарына һәм башка якларга качу яисә җирләреннән көчләп куылу рәвешендә күчеп утыралар. Бу хәл XVII–XVIII йөзләрдә дәвам итә.

---

[1] Котлуг Мөхәммәд Мәмәш улы Тәфкилев (1674–1766) – татар морзасы, XVIII гасырның беренче яртысында рус патшаларының Көнчыгыш сәясәтенә зур өлеш керткән дәүләт эшлеклесе, дипломат. Халык телендә фамилиясенең «Тәфтилев» дип үзгәртелгән варианты да кулланылган (борынгы «Тәфтиләү» җырының да исеме шушы үзгәртелгән варианттан ясалган), текстта шушы вариант та очрый.

[2] Сәгыйть Хәсән улы Хәлфин (1732–1785) – 1750 елларның икенче яртысыннан Казан адмиралтействосында тылмач. 1769–1785 елларда Казан гимназиясендә татар теле укыта. Казан бистәләренең йомышлы татарларыннан Яңа кануннар эшләү комиссиясе (1767–1769) депутаты була. Руслар өчен беренче «Татар әлифбасы» («Азбука татарского языка с обстоятельным описанием букв и складов, сочинённая Казанских гимназий учителем и Адмиралтейской конторы переводчиком Сагитом Хальфиным, и татарских в Казани слобод муллами в оных гимназиях рассмотренная и одобренная») авторы, әлифба 1778 елда Мәскәүдә басыла һәм илле елдан артык киң кулланыла. Татар грамматикасы дәреслеген һәм фундаменталь рус-татар сүзлеген төзи.

[3] Мөхәммәтҗан Хөсәенов (1756–1824) – Россиянең беренче мөфтие. 1788 елда Екатерина II фәрманы белән Уфада Диния нәзарәте оештырылгач, аның мөфтие итеп билгеләнә һәм вафатына кадәр шушы вазифаны башкара.

[4] Груһы – төркеме, катлавы.

XVIII йөздә татар крестьяны үзе инде бай, урта, ярлы рәвешендә өч төркемгә бүленгән була.

Әдәби-иҗтимагый беренче дәверебездә, менә шулай итеп, татар массасы өстеннән татар феодаллары (алпавытлар, руханилар, мөфтиләр), сәүдәгәрләре, купецлары, вак татар чиновниклары – тылмачлары, авыл байлары, кулаклар икътисади-иҗтимагый эшләрдә хаким булып киләләр. Хөкүмәт белән татар массасы уртасында һәм бөтен Шәрык дипломатиясендә васиталык итүчеләр мирзалар, тылмачлар булган шикелле, Шәрык сәүдәсендә васиталык күрсәтүчеләр дә татар сәүдәгәрләре, купецлар булалар. Шулай ук крестьянны Мәскәү хөкүмәтенә – «Ак патша»га дин юлы белән бәйләп торучылар да мөфти кул астындагы указлы муллалар булалар.

Шулар өстенә XVIII йөзнең беренче ярымында Казан йомышлы татарлары арасында фарсыча укый-яза белә торган кешеләр дә байтак була[1]. Хәтта XVII йөзнең ахырларыннан ук татар теле Иран белән Мәскәү патшалыгы арасындагы эшләрдә рәсми бер дипломатия теле булып әйләнә. Фарсыча язулар татарлар тарафыннан русчаның рәсми кәгазьләр теленә тәрҗемә ителә торган була. (Бу хәлләр сәбәпле, фарсы теленең татар теленә тәэсире һәм татарлар өчен фарсы теленең ул вакытта татарның икътисади тормышына бәгланып килгәнен дә истә тотарга кирәк). Татарның чыгтай теле белән якынлыгы һәм чыгтай теленең татарга тәэсире көчәя бару да шундый ук сәбәпләрдән булганлыгы табигый. Татар руханилары янә татар сәүдәгәрләре аркылы шундый икътисади, иҗтимагый сәбәпләр белән Урта Азия – Бохара тәрбиясенә, фарсы теле һәм чыгтай әдәбияты тәэсиренә нык багланалар.

**Татарда сәүдә капиталы һәм купецлык.** XVIII йөзнең ахырларында Мәскәү сәүдә капиталы рәтенннән татарның үзенең сәүдә капиталы да яхшы ук кызу үсә башлый. Кыскасы, XVIII йөз татар сәүдә капиталы өчен иң яхшы һәм уңайлы бер заман була[2]. Бу йөзнең ахырларында, Бохара белән эш итүдән тыш, хәтта Кытай белән

[1] 1729 елда Кавказда генерал Долгоруковның Казан йомышлы татарларыннан фарсыча яза, укый белә торган ун кеше җибәрелүне соравы, «Верховный тайный совет»ның «фарсы телендәге хатларны тәрҗемә һәм тылмачлык кылу өчен Иранга Казан татарларыннан янә ун кеше җибәрергә һәм аларны тизлек белән озатырга», дигән карары, шулай ук 1723 елда Казан бистәсе татарларыннан Иранга – хәзерге Азәрбайҗанга 23 татар тылмачы җибәрелү вакыйгалары шуны куәтли (бу турыда Г. Гобәйдуллинның «Татарларда сыйныфлар» дигән китабына каралсын. 24 бит). *(Авт. иск.)*

[2] «Татарларда сыйныфлар тарихы». Г. Гобәйдуллин. *(Авт. иск.)*

эш итүче – аннан чәй китерүче татар сәүдәгәрләре дә күбәя башлый. Бу йөздә татарларда кредит белән эш күрүләр дә башлана. Кредит бирүчеләрнең күбесе дә Казан татарлары була. Татарларда, бигрәк тә бу йөздә, ростовщиклык – рибачылык белән файдалану да бара. Татарның иң кызу сәүдә мәйданнары Казан, Башкортстан һәм Оренбург тирәләре була. Чынында татар сәүдә капиталының җәелеп эш итә торган мәркәзе Казан белән Оренбург булып чыга. Шуның өчен бу ике мәркәз бер-берсе белән һәрвакыт багланып бара. Оренбург сәүдә мәркәзе аркылы татар Урта Азия белән нык баглана. Татар сәүдә капиталының башланып үсеп китүе өчен Урта Азия капкасы булган Оренбург һәм Каргалы (Сәгыйть бистәсе) тирәләре уңышлы, хәрәкәтле бер урын булып чыга. Мәскәү патшалыгы хөкүмәтенең сәясәте, колонизация планы шуңа киң юл ача.

Эшнең, бу юлдагы хәрәкәтләрнең барышы түбәндәгечә: XVIII йөзнең урталарына таба рус сәүдә капиталы һәм аның колонизация сәясәте үзенең киңәюе, үсүе өчен Шәрыкны иң уңышлы бер мәйдан итеп ала. Җәнүбкә[1] һәм шәркый җәнүбигә[2] таба үзенең үсеп барган озын тамырларын нык җибәрә башлый. Шәфкатьсез бер рәвештә башкорт, казакъ ихтиляллары[3] да бастырылып, казакълар һәм, гомумән, Урта Азия белән Башкортстан арасы төрле крепостьлар белән аерылып куела. Эчке Русиядәге төрле шәһәрләрдән бу якларга күчеп утырулар, хәрби авыллар төзелү кебек хәрәкәтләр башлана. Җаек (Урал), Сакмар, Тубыл сулары буенда вә шушы сызыкларда крепостьлар, курганнар күбәя, төрле шәһәрләр салыну эшләре кыздырыла. Ор суы буенда Орск (әүвәлдә Оренбург дип аталган, хәзердә Орск шәһәре); казачилар оясы Җаек (хәзерге Уральск шәһәре) крепостьлары корыла. Соңыннан болар Шәрык сәүдәсе өчен әһәмиятле шәһәр булып китәләр.

Бу мәсьәләләрдә чиксез оста сәясәтле вә хәйләкәр Оренбург губернаторы һәм аның ышанычлы урынбасары Котлуг Мөхәммәд мирза Тәфкилевләрнең кызулатулары белән 1735 ел, 19 апрельдә хәзерге Оренбург шәһәренең нигезе салына. Шул ук елда Троицк крепосте салынып, соңыннан ул хәзерге Троицк шәһәре булып китә. 1744 елда инде Оренбург шәһәре зур губерна, ягъни Оренбург

[1] Җәнүбкә – көньякка.
[2] Шәркый җәнүбигә – көньяк-көнчыгышка.
[3] Ихтиляллары – бунтлары, баш күтәрүләре.

губернасы шәһәре булып әверелә. (Уфа шәһәре дә башта шул губернада санала.)

Бу якларга, шушы яңа шәһәрләргә күчеп утыручыларга[1] күп льготалар ясала, хөкүмәт тарафыннан күп ярдәмнәр күрсәтелә. Бигрәк тә бу якларга күбрәк сәүдәгәрләр агылалар[2].

Эчке Русиядә крепостнойлыкның шәфкатьсез кысынкылыгы сәбәпле аннан качып китүче крестьяннарның янә бер сыена торган җирләре шушы Оренбург тирәләре була. Алар урманлык, сазлык җирләргә күчүдән башка бигрәк сахрага – башкортлар, казакълар арасына качалар. Алар бигрәк тә Җаек (Урал) һәм Ыргыз[3] суы буйларына җыелалар.

Оренбург шәһәре корылудан бер ел соң Казан татарлары тарафыннан Сәгыйть бистәсе, ягъни хәзерге Каргалы касабәсе[4] төзелеп, рус сәүдә капиталы Шәрык сәүдәсендә үзе өчен васита була торган файдалы сәүдәгәрләргә шунда җыйналуга юл ача.

Шулай итеп, рус сәүдә капиталы үзенең Урта Азиягә, хәтта Көньяк Азиягә, Һиндстанга таба хәрәкәте һәм шул якларны икътисади, сәяси яктан үзенә каратуы өчен Оренбург шәһәрен һәм аның тирәсен иң муафыйк[5] бер мәркәз итеп билгели. Чөнки Мәскәү патшалыгы тарафыннан Оренбург шәһәре Шәрык сәүдәсенең капкасы һәм Шәрык сәясәтенең ачкычы дип табыла.

1752 елда Оренбургта ярминкә дә ачылып, Урта Азия белән сәүдәләр кыза; аннан потлап-потлап алтын-көмешләр Мәскәүгә таба ага башлый[6]. Һиндстан планнары эшләнә, шул турыда Сенатка да проектлар артынча проектлар барып тора. Сәяси тәрбиядә Пётр

---

[1] Ләкин Сенатның боерыгы буенча бу тирәләргә һәм шушы яңа шәһәрләргә бик ышанычлы кешеләрне, акчалы һәм файдалы сәүдәгәрләрне генә күчерәләр. *(Авт. иск.)*

[2] 1747 елда, яңа корылуыннан дүрт ел соң, инде Оренбург шәһәрендә 337 йорт, 4 чиркәү, хөкүмәт номерлары, аптека, магазиннар, кибетләр дә булып өлгерә. (Җиде елдан соң исә Оренбургта 2886 йорт була.) *(Авт. иск.)*

[3] Ыргыз – Казакъстандагы елга.

[4] Касабәсе – бистәсе.

[5] Муафыйк – яраклы.

[6] Тик 1752 елда гына Урта Азия һәм казакълар белән сәүдә итүдә Оренбург һәм Троицк крепосте аркылы Русиягә алардан өч йөз пот көмеш, алты пот алтын кергән була. Речковның хәбәренчә, 1748дән 1755 елгача, димәк, җиде ел эчендә Азиядән Русиягә барысы илле пот алтын, дүрт мең биш йөз потлар чамасы көмеш кергән була. Бу хисап әле тик канцелярия хисабы гына булып, чынында моннан күп артык кертелгәнен әйтәләр (Витявскийның «И. Неплюев и Оренбургский Край в прежнем его составе до 1758 г.» дигән тарихи монографиясенең 3 нче җилде, 16–815 битләр.) *(Авт. иск.)*

Великий[1] шәкерте булып, сәясәттә һәм Мәскәүнең колонизация хәрәкәтләрендә кискен акыллы, хәйләкәр, оста тактикалы булган Оренбург губернаторы Неплюев һәм Шәрыкны Мәскәү кул астына алырга тырышуда аның уң канаты булган Котлуг Мөхәммәд мирза[2] Тәфкилевләрнең тырышлыгы белән бу турыда хәрәкәтләр кызганнан-кыза бара, Пётр Великийның Шәрыкка таба ябырылу сәясәте һәм Һиндстан планнары ике Әби патша (Елизавета[3] белән Икенче Екатерина[4]) заманнарында нык гамәлгә куела башлый. Башкортлар, казакълар тәмам Русиягә буйсындырылып, сахрада кәрван юллары да беркадәре тынычландырыла. Шәрык белән сәүдә һәм дипломатия мөнәсәбәтләрендә, гомумән, татарлар (хосусән, Оренбург һәм Каргалы татарлары) иң яхшы бер васита һәм тылмач булалар. Хөкүмәт каршында шундый эшләре аркасында Шәрык сәүдәсеннән үзләренә дә алар күп табыш ясыйлар.

Кыскасы, Каргалы (Сәгыйть бистәсе) Казан татарларының тәмам бер сәүдә колонияләренә әверелә. XVIII йөзнең ахырларында инде (1792 дә) Сәгыйть бистәсе халкының саны 2674 кә җитеп, шулар эченнән 1810 ысы купец була.

Оренбург тирәләрендә бик күп урыннарда, аның өязләрендә күп кенә крестьяннар, бигрәк тә татарлар һәм аларга башка – рус булмаган халыклар, авылларда «күн, сабын, май кайната торган заводлар, әмма бәгъзе урыннарда исә мамык һәм полотно фабрикалары ачып, шунда эшләгән материяләрен кытат[5] итеп буйыйлар»; «бу крестьян вә татарларның күбесе зур капитал ияләре» булалар. «Шул ук вакытта үзләре әллә никадәр приказчиклар асрыйлар. Күбрәге татарлардан булган бу купец вәкилләре, Оренбург губернасының төрле өязләренә

[1] Пётр I (1672–1725) – Романовлар династиясеннән Россия патшасы (1682 елдан) һәм илнең беренче императоры (1721 елдан).

[2] «Чын аты Котлуг Мөхәммәд Мамишев, русча исеме Алексей Иванович Тәфкилев булган. Бу мирза Пётрның Иран сәфәрендә «секретный эшләрдә» тылмач булып торган» («Татарларда сыйныфлар» – Г. Гобәйдуллин). *(Авт. иск.)*

[3] Елизавета Петровна (1709–1762) – Романовлар династиясеннән Россия императоры (1741–1761), Петр I һәм Екатерина I нең төпчек кызлары.

[4] Икенче Екатерина (Екатерина II Алексеевна, 1729–1796) – Россия императоры (1762 елдан). Екатерина II вакытында Россия империясендәге татар халкы тормышында уңай үзгәрешләр була: диннәр тигезлеге игълан ителә (Изге синодның 1773 елдагы 17 июнь Указы), Уфада Диния нәзарәте оештырыла (1788), татар морзалары хокукый яктан рус дворяннары белән тигезләштерелә (1784), татарларга сәнәгать-җитештерүгә һәм сәүдә итүгә рөхсәт бирелә һ. б. Татар халкында Екатерина II не «Әби патша» дип йөртү гадәте дә бар.

[5] Кытат – тыгыз ефәк тукыма.

вә шәһәрләренә барып, төрле маллар белән сәүдә кылалар. Өязләрдә сыер һәм сарык тиреләре, кайнаткан һәм кайнамаган май, балавыз, бал җыялар. Шуның өстенә бу крестьян һәм татарлар Яурупа малларын алалар. Кармазин һәм ярымкармазин, Голландия сукнолары вә башка төрле сукнолар һәм йон материаллар, буяу һәм канцелярный орлык[1] вә башка нәрсәләр. Бу нәрсәләрне алар зур акчалар тотып алалар да төрле шәһәрләргә илтәләр, бигрәк тә Оренбург вә Троицк ярмаркаларына. Үзләренең зур капиталистлары аркасында Гостиный һәм Меновой дворларда да Азия халыклары кергәндә беренче очрый торган яхшы кибетләрне ишгаль кылалар[2]. Әүвәле заманда бу кибетләр җирле һәм читтән килгән рус сәүдәгәрләре кулында иде. Хәзер инде рус купецлары бу беренче лавкаларны ала алмыйлар[3].

Оренбург рус купецы авызыннан сөйләнгән менә бу юллар 1767 еллар тирәсендәге татар сәүдәсенең хәлен тасвир итә.

Бу, бердән, татарның Шәрык сәүдә капкасы авызында татар сәүдә капиталының ни дәрәҗәдә көчәя барганын күрсәтсә; икенчедән, моннан без татар сәүдә капиталының мануфактурага таба башланган адымнарын да күрәбез.

Татарлар Казан һәм аның тирәләрендә сәүдә белән дә, сәнәгать белән дә шөгыльләнәләр. Казанда аларның күп заводлары була. Өязләрдән җыелган, эшләнмәгән чималларны җыеп кайтып, шуларны үз заводларында эшләтеп, башка шәһәрләргә илтәләр, шуларны күпләп башка купецларга да саталар. Шулай ук шушы завод малларын ярмаркаларга илтеп саткач, аннан шуның бәрабәренә чит җир маллары – Яурупа товары алып килеп, авылларда шуларны тагы сырьега алыштыра торган булганнар.

**Татар буржуазлана.** XIX йөзнең башларында инде, шул юл белән хәрәкәт итә торгач, татар сәүдәгәре буржуазлана башлый. Бу бигрәк тә XVIII йөзнең икенче ярымында, ягъни татар сәүдәгәре өчен базар киңәйгәч, башкорт кузгалышлары да басылгач, кыргызказакълар Русиягә кушылгач, Оренбург, Троицк, Петропавел крепостьлары салынгач башлана. Шуннан соң ул «бөтен Русиянең сәүдә сәясәте хакында да уйлый» башлый.

[1] Канцелярный орлык – хәзер кармин дип аталган буяу (русча бу буяуның әүвәлге атамасы «канцелярное семя» булган).

[2] Ишгаль кылалар – билиләр.

[3] «Татарларда сыйныфлар» – Газиз Гобәйдуллин. 53 бит. *(Авт. иск.)*

Татар сәүдәгәрләре, югарыда әйтелеп үтелгәнчә, Башкортстанга да барып сәүдә кылалар. Шулай итеп, татар өчен ике зур сәүдә урыны була: 1) Казанда, Русиянең үзәгендә; 2) Урта Азиядә, казакъ-кыргыз, башкортлар арасында.

**Беренче дәвердә идеология.** Бу дәвердә татар тормышының әнә шундый икътисади, сәяси, иҗтимагый вә мәдәни шартлары аны кадим Шәрык идеологиясенә нык баглап, шул идеологиянең телдә гәүдәләнү формаларын да нәкъ Шәрык методына суктыра. Икътисади, иҗтимагый хәлләре аны тәмам Шәрык калыбына салуга мәҗбүр итә. Чөнки, югарыда ачык күрелгәнчә, татарның икътисади бавы бер яктан сахра халкы, Урта Азия – Бохара белән бәйләнеп бара. Казан татары Русиядәге шушы икътисади, сәяси хәлләр теләве белән Урта Азия, Себер һәм Кавказ якларына күчә яисә күчерелә тора[1]. Шәрык сәясәтендә, дипломатия эшләрендә, сәүдә йомышларында татар мирзалары, алпавытлары, купецлары васита ителәләр. Икенче яктан, шуның белән татар сәүдә капиталына да туу, үсү, киңәю адымнары ясалган була.

Шул сәбәпле, татарга идеология орлыгы, мәдәният йогынтысы, әхлак, фәлсәфә, әдәбият та шул яктан килә торды. Әдәбияттагы идеология, мөндәриҗә[2] шикелле, аны сурәтләндерүче әдәби форма, тел, өслүб ягыннан да бу дәвердәге татар әдәбияты Шәрык, Урта Азия сызыгында нык торды. Үзен рус-Яурупа тәэсиреннән күп заманнаргача читтә тотып килде.

Шуның өчен бездә бу дәвердә баш-аягы белән Шәрык, Урта Азия тибындагы дини, хыялый кыйссалар (хикәя түгел), дастаннар (поэма) һәм суфилык – дәрвишлек рухындагы тезмәләрдән гыйбарәт әдәбият мәйданга килде.

**Татарда язу теле һәм язма дини әдәбият.** Татарда язу теле XV гасырда ук башланган булса да, аерым китап рәвешендәге язма әдәбият XVI–XVII йөздә күренә башлый. XVIII йөздә инде татар әдәбияты әкренләп үсү юлын ала. Мәүла Колый кебек шагыйрьләрнең һәм Мәскәү хөкүмәте тарафыннан Урта Азиягә, соңра Һиндстанга җибәрелгән сәүдә һәйятенең[3] бер әгъзасы булган татар мөхәррире

[1] 1727 елда биш мең татар, мукшы, чуаш крестьяны Казан губернасыннан Кавказга хезмәткә көчләп күчерелделәр («Татарларда сыйныфлар». Г. Гобәйдуллин). *(Авт. иск.)*

[2] Мөндәриҗә – эчтәлек.

[3] Һәйәтенең – төркеменең.

Исмәгыйль «Сәяхәт»е[1], Дәүләтша ахундның шәкерте Шаһ Әхмәд мулланың «Морад әл-гарифин»[2] тәрҗемәсе (басылуы өчен 1809 елда рөхсәт бирелгән) кебек әсәрләр шуларның үрнәкләре иде.

XIX йөзнең беренче ярымы эчендә Ясәви[3] мәктәбе тибында һәм шуның тәэсире белән, турысы, шуңа ияреп, шулай ук Суфи Аллаяр[4] тәэсире астында тәсаувыф лирикасы туа. Беренче лирик шагыйрьләр дә руханилар, муллалар булалар.

**Әдәбиятта өметсезлек һәм шуның өчен икътисади-иҗтимагый зәмин[5].** Мәскәү патшалыгының ул вакытларда йөрткән гомуми сәясәте[6] һәм шул сәясәтнең теләге буенча татарның мәдәни вә иҗтимагый яктан аерым рәвештә нык изелүе татар гаммәсе[7] арасында башка бер төрле әдәбиятның тууына зәмин бирми. Шуның белән бергә, татар гаммәсендә иҗтимагыйлык, җәмәгатьчелек, җәмәгать файдасы өчен кайгыру һәм шул юлда оешып эшләүчелек психологиясе дә нык сүндерелгән була. Крестьянның һәммәсе инде диннән, дини хорафаттан, дини ялганнардан, дини моңнардан үзенә юаныч эзли башлый. Һәркем үзенең шәхси мәнфәгате, ялгыз үзенең хосусый, ялгыз, шәхси көнкүреше белән генә мәшгуль булу юлын тота. Бу дөнья гомерен, дөнья тормышын «кяфер йорты»нда ничек кенә булса да үткәреп, икенче дөньяга әзерләнү, чын бәхетне, рәхәтне, яхшы тормышны шул алдагы мәүһүм[8], хыялый дөньядан көтү психологиясе көчәя. Татарның бөтен матди тормышы, икътисади шәраите[9] аны шуңа хәзерли.

[1] Сүз XVIII йөзгә караган «Исмәгыйль агай сәяхәтнамәсе» турында бара (авторы билгесез).

[2] «Морад әл-гарифин» («Укымышлыларның максаты») – суфи шагыйрь Суфи Аллаһияр (1616/1630–1713/1723) иҗат иткән әсәр.

[3] Әхмәд Ясәви (Кол Хуҗа Әхмәд, 1093–1166) – Урта Азия суфи шагыйре, ясәвийә тарикатен нигезләүче. Ясәви Яссы һәм Бохара галимнәреннән, шул исәптән танылган дин галиме Йосыф Хәмәдәнидән (1140 елда вафат) белем ала. «Диване хикмәт» (1878) мистик, рухани эчтәлекле шигырьләр җыентыгы авторы.

[4] Суфи Аллаһияр (1616–1713 яки 1723) – суфи шагыйрь. Төрки һәм фарсы телләрендә яЗган. Төп әсәрләре: «Сөбат әл-гаҗизин» («Гаҗизләргә терәк», 1802), «Морад әл-гарифин» («Укымышлыларның максаты», 1858), «Мәсләк әл-мөттәкыйн» («Тәкъвалар юлы», 1899), «Мәхзән әл-мотыйгыйн» («Күндәмнәрнең хәзинәсе»). Нигездә, суфичылык рухында, илаһи гыйшыкка мәдхияләр җырлау максаты белән язылган бу әсәрләрдә социаль мотивлар, шәхес иреге, рухи азатлык идеяләре дә яңгыраш таба.

[5] Зәмин – нигез.

[6] Чыганакта: сәясәтен.

[7] Гаммәсе – массасы.

[8] Мәүһүм – хыялый.

[9] Шәраите – шартлары.

Кыскасы, Русиядәге башка крестьяннар белән беррәттән уртак коллык сызыгында изелү өстенә, икенче яктан, Русия дворянлык патшалыгы, Мәскәү сәүдә капитализмы тарафыннан тик татарның татар һәм мөселман булганлыгы өчен генә аерым бер рәвештә икътисади, мәдәни изелүе татар гаммәсендә дини рухның, дини фанатизмның һәм дә алар арасында суфилык, ишанлыкның нык тамыр җәюенә зәмин хәзерли, аны дөнья тормышыннан тәмам өметсезләндерә, тәкъдиргә нык буйсындыра. Ул, инде бөтенләй өметсезлеккә төшеп, һәрнәрсәне тәкъдиргә, язмышка бәйли башлый. «Йөз еллар буенча туктаусыз дәвам кылган бу җәбер сәясәте татарның җанына, канына шул дәрәҗәдә сеңгән иде ки, «язмыш шулдыр», «тәкъдир шулайдыр», «котылырга чара юктыр» дигән кебек кара өметсезлекләр татар күпчелегенең башын каплаган иде»[1].

Менә шушы зәмин өстендә татарның үз эчендәге дөньяви феодаллары белән рухани феодалларының нык хакимияте өчен киң юл ачыла. Татар мирзалары һәм рус сәүдә капиталының Урта Азиядә нык эш итүендә васита булучы бөтен татар сәүдәгәрләре белән татарның ахирәт феодаллары (муллалар, хәзрәтләр, мәзиннәр, ишаннар) татар гаммәсе өстеннән хуҗа булып алалар. Шулар аркылы татарга борынгы кадим Шәрык идеологиясе урынлашып өлгерә. Тәрбия, уку-укыту эшләре борынгы, шәүкәтле[2] Урта Азиячә – ислам йортынча куела.

**Татарның тәрбия һәм идеология урыны, идеология вәкилләре.** Бу идеологиянең баш вәкилләре, юлбашчылары да Бохара (бигрәк тә Бохара), Дагстан, Һиндстан «җимешләре» булалар.

Бу турыда эшләү түбәндәгечә бара: XVIII йөзнең соңгы ярымыннан игътибарән[3] Урта Азия сәүдәсендә васита булучы татар сәүдәгәрләре, татар байларының димләве, ярдәме белән Урта Азиягә – Бохарага тәхсилгә[4] бару агымы нык көч алып китә. Рус, шулай ук татар сәүдә капитализмы татар дөньясына шундый юл ача. XVIII йөзнең соңгы ярымыннан XX йөзнең бышынача, 150 ел эчендә татар дөньясы үзенең рухи хәятын, гыйлемен, тәрбиясен, мәдәни язмышын Бохара мәдрәсәләренә, Бохара ысулларына, Урта Азия хорафатларына бәйли, шул нигезгә утырта. Шул дәвердә Бохарага,

[1] Галимҗан Ибраһимов – «Татарлар арасында революция хәрәкәтләре». – 7 бит. *(Авт. иск.)*

[2] Шәүкәтле – көчле, куәтле.

[3] Игътибарән – башлап.

[4] Тәхсилгә – укырга, гыйлем алырга.

Харәземгә барып гыйлем алып кайтучылар күбәя. Гыйлем эстәүчеләрнең ул якларда иң кайнаган вакытлары да шул чаклар була. XIX йөздә Русиядә зур мәдрәсәләр тотучы зур дини галимнәр, мөдәррисләрнең күбесе Бохарада җитешәләр. Шушы мөддәт[1] эчендә тик тарихка (Риза[2] һәм Мәрҗани[3] тарихларына) кергән «зур мәшһүр» адәмнәрдән Бохарадан барысы 66 дини галим җитешеп, Русиягә кайталар[4]. Бу «кәттә», «бохари» галимнәр кулында һәм татар байлары идарәсендә Русиянең һәр почмагында, авылларында, шәһәрләрендә мәдрәсәләр ачылып, мулла-мәзиннәр, суфилар, мөридләр җитештерелә башлый. Казан, Каргалы, Эстәрлетамак, Чистай, Тайсуган, Кышкар, Мәчкәрә, Сасна, Курса, Бубый мәдрәсәләре һәм башкалар шундый мәдрәсәләрдән булалар.

**Мәхкәмәи шәргыя һәм татар идеологлары.** Шулвакыт, XVIII йөзнең ахырларыннан башлап, II Екатеринаның, ягъни Әби патшаның 1788 ел 22 сентябрьдәге фәрманы буенча Уфада Мәхкәмәи шәргыя (Духовное собрание) ачыла. Менә бу сәясәт инде татар мирзалары, татар дворяннары, татар сәүдәгәрләре белән бергә татар руханиларының татар гаммәсе өстеннән дини тәгассеб белән тагын да каты хөкем сөрүе өчен киң рәвештә рәсми юл ача[5]. Шуның белән бергә бу эш татарның руханила-

[1] Мөддәт – вакыт, ара.

[2] Ризаэддин Фәхреддин (1859–1936) – мәгърифәтче галим, тарихчы, дин белгече һәм җәмәгать эшлеклесе. Идел буе Болгар дәүләте заманыннан XX йөз башына кадәр яшәгән күренекле шәхесләр турындагы материалны үз эченә алган «Асар» биобиблиографик хезмәте авторы.

[3] Шиһабетдин Мәрҗани (1818–1889) – дин галиме, тарихчы, мәгърифәтче. Мәшһүр мөселман эшлеклеләренең тормышын тасвирлаган «Вафийәт әл-әсляф вә тәхийәт әл-әхляф» («Элгәреләр һәм аларның киләчәк буынга сәламнәре»; кулъязмада) исемле алты томлы җыентык авторы. Ш. Мәрҗани Идел һәм Урал буе мөселман халыклары арасында җәдитчелек идеяләре үсешенә зур йогынты ясый.

[4] XVIII йөзнең соңгы ярымыннан XX йөзнең башына кадәре Бохарага барып укучылар һәм шулар эченнән Русиягә кайтып мулла булучыларның саннары – тик Риза казыйның «Асар»ында күрсәтелгәннәре генә 55 кеше (болар эчендә Кабил һәм Дагстанга да барганнары бар). Шулар өстенә тик Һиндстанга, Кабилгә генә барганнары – 4, Дагстанга барганнары 7 булып, барысы 66 кеше була. Болар инде тик иң «кәттә»ләре генә, әмма алардан тагын Бохарада тәхсил итеп кайтучыларның тарихка керми калганнары аз түгелдер. *(Авт. иск.)*

[5] Шуның өстенә тагын шул ук Екатеринаның шул ук сәясәт белән 1782 елда (Мәхкәмәи шәргыя ачылудан 6 ел элек) Уфа, Тобол губерналарында хөкүмәт ярдәме белән зур мәчетләр (җәмигъ) салдыруга боерыгы булып үтә. 1883 елда бу боерык тагын тәкрарлана (беренче боерык – Уфа һәм Сембер губерналарын идарә итүче генерал-поручик Иван Варфоломеевич Якобийга, икенчесе янә шул ук губерналарны идарә итүче генерал-поручик Аким Иванович Апухтинга бирелә), шулай итеп, шушы боерык буенча Петропавел, Троицк, Верхнеурал һәм Оренбург шәһәрләрендә дүрт мәчет са-

ры белән сәүдәгәр, мирзаларын якынлаштыруга, аларның бер кулдан, бер юлдан хәрәкәт итүләренә дә зур сәбәп була. Мәхкәмәи шәргыянең башына мөфти итеп[1] Мәскәү патшалыгының

лына. Оренбургта Меновойдагы мәчет имамына хөкүмәттән елга 150 сум жалование бирелеп, ике мәзиннең һәрберсенә елга 20 сумнан бирелә. Ике биш вакытлы имам һәм бер мөдәррис янә елга һәрберсе 60шар сумнан жалование алалар. Хөкүмәт тарафыннан иң беренче мәртәбә бу мәчеткә мөдәррис итеп 1789 елда 17 сентябрьдә генерал-губернатор тарафыннан типтәр Хаҗи Мөхәммәд Заһид углы билгеләнә (Бәләбәй өязе Күпәк авылыныкы), имам Думай авылы Әбуязид Уразман углы. Мәзин дә Сәгыйть бистәсеннән (Каргалыдан). 1890 елда исә бу Меновой мәчетенә (сәүдә мәчетенә!) Бөгелмә өязе Баулы авылы мишәре Мөслим Мансур улы билгеләнә. (Бу турыда озын мәгълүмат «Асар»ның 8 нче җөзьэндә, 207 нче маддәдә, 448 биттә бар). Менә бу мәгълүмат та безгә Екатеринаның, шулай ук рус сәүдә капитализмы сәясәтенең һәм шул сәясәт өчен дин һәм муллаларның ничек корал ителгәнен ачып бирә. *(Авт. иск.)*

[1] Мәхкәмәи шәргыянең башында кемнәр утырганын һәм бик күп заманнаргача татар халкының идеология юлбашчылары булган татар руханиларының Мәскәү патшалыгы сәясәтенә, сәүдә капитализмының колонизация хәрәкәтенә кемнәр юлбашчылыгы астында эшләндерелә башлаганлыкларын яхшы аңлау өчен, бу урында мөфтиләрнең кыскача тәрҗемәи хәлләрен язып үтик. Екатерина боерыгы белән куелган беренче мөфти – Мөхәммәтҗан Хөсәен углы (1758–1824) булып, Екатеринаның бу садыйк кешесе иң элек Сәгыйть бистәсе (Каргалы) һәм Оренбург тирәләрендә укып, Мөхәммәдгали Дагстанидан гыйлем ала. Соңыннан, бәгъзеләрнең фикеренчә, хөкүмәт вәкиле булып Бохара вә Кабилгә (Һиндстанга) сәяхәт итә. Шушы сәфәрендә ул фарсы теле дә өйрәнеп кайта. Аннан соң үзенең доносчанлыгы аркылы Русия дәүләтенең зур кешеләре белән танышып ала да, казакъ һәм башкорт халкын һәм башкаларны Мәскәү дәүләтенә буйсындыру юлында хезмәткә алына. Шул ук мөфтинең киңәш вә таләбе белән Мәхкәмәи шәргыя ачылып, үзе шуңа беренче мөфти була. Башка казыйларны, бөтенләй үзенең хезмәтчесе итә, хәтта аларны үзенең хосусый йомышларын үтәүдә дә куллый *(куллана)* бирә. Үзе теләгән бер кешесен казый итә. Муллаларга ат сатып, күп байлык казана. Балалары да Петербургта «Чит диннәрне карамакта булган мәхкәмә»дә хезмәттә булалар. Үзе сәүдәгәр кавеменнән була. 5 нче ревизиядә Уфа өязе Солтанай авылыннан хисаплана. Әүвәл «Иностранная коллегия»дә хисап ителә, соңра Оренбургта офицерлык хезмәтендә була. 1785 елда «Сәрхәд комиссиясе»ндә кыргызлар өчен ахун булып, 1789 ел, 22 сентябрьдә Мәхкәмәи шәргыя башына менеп утыра, мөфти була (бу мөфти вакытында әле Уфада мәчет булмый). Мөфти булудан элек, кыргызларның Русиягә буйсынулары турында зур хезмәтләре булып үтә. Кавказ якларына барып, Русия әсирләрен азат иттертә. Кабарти халкының Русия кул астына кергәнлекләре өчен алардан ант ала. Әстерханнан көнчыгыштагы төрекмәннәр арасында йөреп, анда Русия нөфүзен *(авторитетын)* ныгыта; шушы хезмәтләре өчен Русия дәүләтеннән бүләкләр ала. Императрица Екатерина, император Павел Пётр улыннан үзенә бриллиант белән бизәкләнгән медаль һәм Оренбург шәһәрендә хөкүмәт исәбеннән салынган бер йорт, моннан башка тагын төрле вакытта күп акча һәм киемнәр бирелә. Мөфти булганнан соң, шәһәр урамнарында дүртәр ат җиктереп йөри. Үзе үлгәндә, меңнәрчә алтыны, исәпсез күп хайваннары, йортлары, Уфа башкортларыннын юк бәһагә алган әллә ничә урында җирләре кала. Уфадан алтмыш чакрым урындагы Атҗитәр дигән авылда гына 2284 дисәтинә җире була. Фатыйма дигән бер кызын да казакъ һәм Бүкәй илханнарыннан Җиһангир ханга бирә. Бу да бер сәяси максат белән эшләнә.

Аның бу кызы аркылы Казакъстаннан Эстәрлетамак вә Эстәрлебашта булган мәдрәсәләргә шәкертләр җибәртелеп укыттырыла һәм аның ук тәэсире белән Җиһангир хан казакълар арасына мәчетләр салдыра, һәр ыруга имамнар куйдырта

башлый. Шулай итеп, казакъларның Русиягә баглануларын, буйсынуларын да дин юлы белән ныгыталар.

Бу беренче мөфти үзе хатларын, боерык һәм фәтваларын фарсы телендә яза. Муллаларга указлы булу мәҗбүрилеге дә шушы беренче мөфти заманында чыгарылып, указсыз кешеләр мулла итеп сайлаттырылмас булалар.

Менә татар-башкортларның баш мәхкәмәсе булган дини бер мәхкәмәнең беренче юлбашчысы, беренче мөфтисе шундый сыйфаттагы бер мирза, бер алпавыт иде. Моннан мәсьәләнең бөтен эч йөзе ачылса кирәк.

(Бу мөфти турында мәгълүмат «Асар»ның дүртенче җөзьендә 181–200 битләрдә», «Мөстәфад әл-әхбар»нең икенче кыйсемендә 287–297 битләрдә).

Бу мөфти татар байлары, шулар эченнән бигрәк Казан байларыннан Исмәгыйль Апанаев улы Йосыф Апанаевлар белән дә дус була, хат алышып тора.

Беренче мөфти үлгәннән соң, аның урынына утырган икенче мөфти (Габдессәлам мөфти) дә, бер яктан, Мәскәү патшалыгы сәясәтенең ялчысы булса, икенче яктан, татар сәүдә капиталының кешеләре, бигрәк тә Казан купецларыннын Гобәйдулла Йосыф, Хәсән Апанаев, Исхак Аппаков, читекче Мостафалар белән бик якыннан дус булып, һаман хат алышып тора. Икенче мөфтилеккә казанлылар тарафыннан башка кешенең кандидатлыгы куелган булса да, Оренбург губернаторы: «Монда безнең хозурымызда күп вакыттан бирле дәүләткә яхшы хезмәт итеп, истикамәте *(намуслылыгы)* вә лиякате *(лаеклылыгы)* мәгълүм улган ахунд бар, безнең нәзармездә *(фикеребездә)* ул лаек, әгәр мөфти булырга Бохара бармак вә анда тәхсил гыйлем итмәк шарт булса, хәзинә мәсарыфы берлә (хөкүмәт хисабыннан дигән сүз) бер-ике сәнә *(ел)* мөддәте йөртеп кайтармак мөмкин», – дип таләп итүе буенча, асылда Бөгелмә өязе Габдеррахман авылының кешесе булып та, Каргалыда укыган һәм Оренбургта ахунд, имам булып торган Габсәлам дигән руханины куялар. Уфада беренче мәчет шушы мөфтинең димләве буенча, Казан сәүдәгәре мирза Мөэмин бай Таһир улы тарафыннан салына. Аннан элек Уфада мәчет булмый. Мәчет 1830 елда ачыла (моның турында шул ук «Мөстәфад әл-әхбәр»нең икенче бүлегендә 298–310 [битендә] мәгълүмат бар), «бу мөфтигә 1806 да 16 августта, Русия дәүләте өчен иткән хезмәтләренә бүләк итеп, елына бер йөз илле сум жалуния тәгаен ителгән» («Асар», 7 нче бүлек, 344 бит), шуның өстенә 1814 елда алтын медаль дә алып, әүвәлге жалуниясенә 80 сум өстәлә. 1817 елда хәзинәгә җан бәрабәренә түләнәчәк түләүләрдән азат кылына. Шул ук ел вазифасы 300 сумга җиткерелә. 1820 дә, Оренбург генерал-губернаторы Эссенның үтенүенчә, 1820 сум бүләк ала. Кыргыз урдасын тикшерү өчен төзелгән җәмгыятьтә әгъза булып уңышлы эшләгән өчен, 1823 елда дәүләт тарафыннан биш йөз сумлык алтын сәгать бирелә. Ахырда император Беренче Александр указы белән 1825 тә 30 сентябрьдә икенче мөфти булып билгеләнелә. Үзенә йорт алу өчен хөкүмәттән 1826 елда дүрт мең сум акча бирелә. Менә бу хәл янә ул вакытта Мәскәү хөкүмәтенең тоткан сәясәтенең эч йөзен ныграк ача. Бу мөфти дә фарсыча белгән. Өченче мөфти исә – мишәрләрдән Габделвахид дигән мулла булып, элек Петербургта байларга хезмәт кылган һәм үзе шунда сәүдә иткән бер кеше. Элек байларга указсыз имам була. Соңыннан шундагы байлардан «кул вә тамга» алып, приговор белән указлы имам булып, берничә еллар Петербургта хөкүмәт кешеләренә үзен яхшы күрсәтә ала. Нәтиҗәсендә, өченче мөфтилек урыны шуңар бирелә. Бу мөфти дә даимән байлар файдасын карап, алар теләгәнчә эш итә. Моның заманында байларның күбесе Коръән бастырып файда итә башлый. Бу мөфти үзе бик надан бер кеше була.

Дүртенче мөфти – Русия гаскәре белән килеп, Оренбург шәһәрен салышучы, Урта Азия халыкларын Мәскәүгә баглашучы мәшһүр Котлуг Мөхәммәд мирзаның нәселе. Бу мөфтинең әтисенең әтисе – Котлуг Мөхәммәд мирза улы. Котлуг Мөхәммәд мирзаның исә күп җире, сулары, урманнары була. Котлуг Мөхәммәд һәм аның нәселе турында

садыйк[1] вәкиле булган татар дворяны, татар сәүдәгәре утыртыла. Ул күп хәрәкәтендә татар байлары, татар сәүдәгәрләре белән якын мөнәсәбәттә булып бара. Әнә шушы мөфти кулы белән имзаланган «указ» аркылы татар руханилары тәмамән хөкүмәт сәясәтенең хадиме[2] ителәләр.

Моңа тагын шуны кушарга кирәк: югарыда татар руханилары белән татар байларының бер-берсе белән якынлашканлыкларын әйтеп үткән идек. Менә моңар тагын табигый бер сәбәп булды. Ул

Мәрҗани: «Русия дәүләтенә күп хезмәтләр итеп, генерал-майор рәтбәсен алган вә саир *(башка)* әһле бәйте һәр каюсы дәхи *(тагын)* шул дәүләттә хезмәт итеп, күптән-күп җир вә сулар вә урманлара малик улып вә ничә карья (*авыл)* әһалисе *(халкы),* мисләә, Тирсә вә Килем нам *(исемле)* карьяләр, коллары иде вә билҗөмлә *(барлык)* Русия мәхкүмендә *(хакимлеге астында)* әһле исламнан әле әльан *(хәзерге көндә дә)* боларча дәүләт иясе булдыгы мәгълүм дәгел», – ди. Менә бу сүзләргә аеруча дикъкать ителсен.

Бу дүртенче мөфти Сәлимгәрәй булып, әүвәл Русия гаскәрендә хезмәт итә. Аннан соң хаҗга китә, Истанбулга бара. Соңра кайтып, Габделвахид мөфти урынына дүртенче мөфти булып билгеләнә. Мәхкәмәи шәргыянең яңа бинасы ачылганда, ул мөфтилеккә аяк баса. Мөфти булгач, Казан һәм Тифлис якларына сәяхәт итә (моны Мәрҗани хөкүмәт тарафыннан булса кирәк, дип уйлый). Үзе гыйлемсез, куркак бер мөфти була. Үз хисабыннан Уфада икенче мәчетне салдыра, шуңа муафыйк имамны үзе куя. Таш мәчет янында бер мәктәп торгыза, үзе үлгәндә, 20 мең сум вәкыф *(җәмәгать файдасына тотар өчен мал)* калдыра.

Моның турында Мәрҗани: «Әһлел-гыйлемнән улмай, ибтидаи мәнсабы ифтаи ихраз идән бу улыб фәтхе баб кылды. Зур хатасы фикъһ вә әхкяме шәригатьтән бернәрсә белмәй мәнсабы ифтага рәгъбәт вә сигаят илә аны ихраз итмәкедер. Бу әмре хакыйкатә вә фил-мәгънә бу мәмләкәттә мәнсабы мәзкүрнең билкөллия бетмәкеннән гыйбарәт вә газыйм җинаять улды. Гәрчә сәләфендә улан мөфтиләр һәр чәнд җаһил исәләр дә, билкөллия гари дәгел вә әһле гыйлем гонванына дәхил иделәр», – ди. *(«Галимнәрдән булмыйча, башлыча мөфтилек вазифасына ирешкән бу кеше булды. Зур хатасы – фикъһтан һәм шәригать хөкемнәреннән бернәрсә белмичә, үз теләгенә ияреп, хәйлә ысуллары белән мөфтилек вазифасына ирешүедер. Аның бу эше, хакыйкатьтә, бу мәмләкәттә әлеге вазифа дәрәҗәсенең тулы мәгънәсе белән бөтенләй төшүдән гыйбарәт зур бер җинаяте булды. Аннан алда булган мөфтиләр, никадәр җаһил булсалар да, шыр надан булмаганнар һәм гыйлем әһелләре дип аталырга хаклары бар иде».)*

Аннан соң утырган бишенче мөфти дә – Мирза Мөхәммәдьяр дигән кеше. Моның бер карт бабасы Русия дәүләтендә хөкүмәт хезмәтендә торып, аерымлыклар алган шикелле, әтисе һәм үзе дә башкортларга кантон булып торган. Соңра мөфтилеккә куелган.

Гәбдессәлам мөфтинең язган бер хатында: «Көлл *(бөтен)* голәма вә фазләнең *(зыялыларның)* рәисе мөфти улдыгы шәһәрдә мәсҗед юклыгы гаҗәп, бәлки әгҗабел-гаҗәбдер *(гаҗәпнең гаҗәбе),* гарьлекдер. Вә һәм бу шәһәргә һәран *(һәрвакыт)* вә һәрвакыт голәма вә фазлә, хәвас *(аксөякләр)* вә гавам *(халык массасы),* аяндә вә рәвандәләрнең *(килеп китүчеләрнең)* күп улмакы вә йорт илә торучы купец вә мещан, мирза вә солдат, ягъни гаскәрия җәмәгате чук улмактан гаять тә зарур вә хаҗәт күрәмез» («Асар», 353 бит, 4 нче җөзьэ), – диюенә күрә, ул вакытта, бердән, Уфада һич мәчет булмаган, икенчедән, инде XIX йөзнең беренче чиреге эчендә Уфада купец вә мещаннар һәм мирзалар күп булган була (бу хат үзе 1827 елда язылган). *(Авт. иск.)*

[1] Садыйк – тугры.

[2] Хадиме – хезмәтчесе.

да байтак татар муллаларының төп нәселләре сәүдәгәр һәм мирзалар буыныннан чыгуы иде. Шуның белән бергә татар руханилары үзләренең сыйнфый-икътисади мәнфәгатьләре ягыннан байларга якынаюны, алар белән берләшеп хәрәкәт итүне бай кызларына өйләнү белән дә тәэмин иттеләр.

Кыскасы, мөфтиеннән алып та мулла, мәзиннәренә кадәре бөтен руханилар, байлар һәм мирзалар белән нык багланган, бер икътисади-иҗтимагый мәнфәгать юлында берләшеп алганнар иде. Мәчет, мәдрәсәләрне салдыручылар, аларга имам, мәзин китереп куючылар, шулай ук мәчетен, мәдрәсәсен, мулла, мәзинен идарә итүчеләр, бер дә булмаганда, шул турыда зур тәэсир күрсәтүчеләр, һич шөбһәсез, татар байлары булды. Хәтта байларның руханиларны үз дигәннәренчә йөртүләре турында Каюм Насыйриның 1883 елгы календаренда түбәндәге тарихи факт бар. Казан байларыннан Бикбау хаҗи турында ул әйтә: «Бикбау хаҗи килмәй торып, мәчеттә мәзин камәт төшермәс иде», – ди.

Менә бу хәл – татар сәүдә капиталының руханиларны ничек үзенә йөгендергәнен ачып бирә торган бик кечкенә, ләкин әһәмиятле фактларыннан берседер. Шулай итеп, «икътисад һәм администрация чаралары белән зәгыйфьләнгән татар халкының самодержавиегә буйсынучылык тойгыларын тирәнәйтү, көчәйтү өчен, рус бюрократиясенә татарның үз эченнән таяныч булырлык бер катлау, бер груһ адәмнәр» җитештерелә. Бу груһның Мәхкәмәи шәргыя аркылы җитештерелгән шушы руханилар тармагы, шул рәвешчә, «үзләренең указлары, метрикалары, мәчеттә патшага догалары, бигрәк тә өсләрендә торган Духовное собраниеләре, мөфтиләре белән самодержавиегә нык укмашкан» булалар.

Шуның белән бергә, «бу катлауның икенче тармагы, татар алпавыт мирзалары һәм болардан чыккан эреле-ваклы чиновниклар, гаскәри офицерлар, генераллар кебек рус-Яурупа мәгърифәте белән дә коралланган бер тармак булып, хөкүмәт сәясәтендә руханиларга җитәкчелек итәләр. Кыскасы, шул рәвешчә, үз эченнән чыгып, ике канау аркылы царизм белән багланган югары ике груһ (руслашкан чиновник һәм руханилар) Татарстанның рус тарафыннан колонизация ителүен фикри, рухи тәрбия белән киңәйтә» (Галимҗан Ибраһимов «Татарлар арасында революция хәрәкәтләре», 7 нче бит).

Бигрәк тә бу юлда Мәхкәмәи шәргыя аркылы җитештерелгән һәм, шулай итеп, татар чиновникларына нык бағланган указлы татар руханиларының – вакытында татар дөньясында зур роль уйнаган шушы дини гаскәрләрнең саннарына бераз күз ташлау бу турыда мәсьәләне тагын да яхшырак ачып бирәчәк. 1804 елдан 1898 елгача, тик 94 ел эчендә генә, Мәхкәмәи шәргыядә мулла, мәзинлеккә имтихан тотучылар барысы 17 984 кеше булу бу хәлнең эч йөзен безгә тәмам ачып сала. 1896 елда исә Мәхкәмәи шәргыя карамагында тик ахуннар гына 152 кеше була. Болары инде – указлы муллалар белән Мәхкәмәи шәргыяне һәм аның мөфтиен турыдан-туры баглаучы уртадагы эре буыннар иде. (Бу турыда Ризаның «Тәнзыймәт»енә[1] каралсын.) Бу мәхкәмә башына утыручы мөфти, казыйларның да һәммәсе диярлек я турыдан-туры, я икенче берәүләр аркылы Бохара тәрбиясе алган, шулай итеп, кадим Шәрык идеологиясе белән нык сугарылган адәмнәр иде. Болар татарга Урта Азия гадәтләре белән бергә фарсы телен, чыгтай әдәбияты тәэсирен дә «китап теле» итеп китереп керттеләр. Хәтта мөфтиләрнең боерык вә муллаларга хатлары да күбрәк фарсы телендә булды.

XIX йөзнең башларындагы татар муллалары турында Мәрҗанинең түбәндәге сүзләре мәсьәләне тагын да нык ача: «Бу мәмләкәт галимнәре бик садә[2] һәм тәкәллефсез[3] булганнар, Бохарадан укып кайткан кеше бик аз булган. Мондый кешеләрнең сүзләрендә, кием һәм хәрәкәтләрендә ят булучылык сизелеп, сөйләшүләре дә бозык булса да, телләренә фарсы һәм гарәп сүзләре катыштырып, халыкның исен китергәннәр. Моңа тагын шуны кушарга кирәк: болар (Бохарадан килүчеләр) тегеләргә караганда мәртәбә игътибарлары, сүзләренең үтеме чиксез өстен булганга, белгәннәр – белгәненчә, белмәгәннәр белмәгәннәренчә алардан куркуларыннан аларга баш салганнар, аларны игътираф итәргә[4] мәҗбүр булганнар. Ул гасырларда хәтта безнең әтиләребез кебек кешеләр, Бохарадан укып кайтканга кадәр, «Бохарадан укып кайттым» дигән мулланы адәм

[1] Сүз Ризаэддин Фәхреддин тарафыннан төзелгән «Тәнзыймәт» (1898) китабы турында бара. Китапка «Җәмгыяте шәргыяте Оренбургия тарафыннан мөхтәлиф *(төрле)* вакытларда тәхте нәзарәтендән улан имамларның нәшер улынмыш фәрманлар җәмигъ иделмеш вә беркадәр икенче мәгълүматлар һәм дәрҗ иделмеш рисаләдер. Имам вә мөәзин вә яки имам вә мөәзин улачак шәкерләр өчен тәртип иделмештер», дип аңлатма бирелгән.

[2] Садә – гади.

[3] Тәкәллефсез – табигый.

[4] Игътираф итәргә – танырга.

нәүгыннән[1] өстен, бәлки фәрештәләр шикелле күргәннәр» («Мөстәфад әл-әхбар», икенче китап, 269 бит. Мәрҗани сүзләре хәзерге татар теленә салынып алындылар).

**Тәсаувыф лирикасы.** Менә шушы хәлләр, шундый икътисади, сәяси, иҗтимагый зәмин татар дөньясында XVIII йөздә һәм XIX йөзнең беренче яртыларында татар дөньясы өчен дини әдәбиятка, дини шигырьгә, үгет, вәгазь тезмәләренә, тәсаувыф лирикасына мәйдан ачты. Шуны кабул итүгә, ми вә йөрәкләрдә шуны урынлаштыруга психологик бер хәзерлек ясалган булды.

Бигрәк тә татар руханилары, мәдрәсә шәкертләре, суфилар өчен шул рухта ничек тә булса бертөрле үз әдәбиятлары кирәк иде. Татар байлары кулында корал яисә шулар тәэсире астында булган рухани хаким сыйныф үз шагыйрьләре аркылы үз телләрендә, үзләренә бер татар әдәбияты сорый башлаган иделәр.

XIX йөзнең беренче ярымы әнә шушы әдәбиятны һәм тәсаувыф лирикасын үстерә башлады. Габдеррәхим Имәни[2] (1815–[18]16 да вафат), Таҗетдин Ялчыгол улы[3] (1837 дә вафат), Әбелмәних[4] (1862 дә вафат), Шәмсетдин Суфи[5] (1865 тә вафат), Һибәтулла

[1] Нәүгыннан – затыннан.

[2] Габдеррәхим бине Госман әл-Болгари Утыз Имәни (1754–1834) – шагыйрь, фикер иясе, дин белгече. Татар һәм гарәп телләрендә яза. Поэмалар, шигырьләр, дини трактатлар, фәлсәфә мәсьәләләренә караган гыйльми хезмәтләр, Газәли, Гаттар, Җами, Руми, Аллаһияр китапларына шәрехләүләр авторы. Утыз Имәнинең мәгърифәтчел идеяләре аның замандашлары һәм соңгырак чор фикер ияләренең дөньяга карашларына тәэсир итәләр. Аның хезмәтләре татар иҗтимагый-сәяси һәм эстетик фикеренең яңа, җәдиди юнәлеше формалашуга этәргеч була.

[3] Таҗетдин Ялчыгол (1763–1838) – татарлар арасында абызлар (абызагайлар) хәрәкәте җитәкчеләренең берсе, тарихчы, язучы, педагог. Фәнни трактатлар язу белән шөгыльләнә, дин гыйлемен укыта, җәй көннәрендә күрше авылларга барып, авыруларны дәвалый. Ялчыголның иң күләмле әсәре – «Рисалә-и Газизә» (1795). Әлеге әсәр Аллаһияр Суфиның «Сөбәт әл-гаҗизин» (XVIII йөз ахыры) китабына язылган шәрехтән гыйбарәт. Әсәр татарлар арасында киң тарала, мәктәп һәм мәдрәсәләрдә дәреслек итеп файдаланыла. Ялчыголның «Сидрат әл-мөнтаһа», «Тәварихы Болгария» һ. б. әсәрләрендә тарих, әдәбият, халык медицинасы, мөселман хокукы, тәрбия мәсьәләләре карала.

[4] Әбелмәних Каргалый (Габдессәлам Әбелмәних Әбелфәез углы, 1782–1833 елдан соң) – шагыйрь, дин һәм җәмәгать эшлеклесе. Суфичылык әдәбияты вәкиле. Ул мөнәҗәт, сәяхәтнамә, фәлсәфә-мәхәббәт лирикасы жанрларында иҗат итә. Аскет дәрвишләр, суфи-шәехләр тормышына багышланган күпсанлы шигырьләр авторы.

[5] Шәмсетдин Зәки (Гобәйдуллин Шәмсетдин Ярмөхәммәт углы, Шәмсетдин Суфи, 1821–1865) – суфи шагыйрь. Шигъри мирасының төп өлешен газәл, мәдхия, робагый, фәрд һәм башка жанрларда язылган лирик әсәрләр тәшкил итә. Шагыйрь иҗаты дини-суфи идеяләр, тормыш мәгънәсе турында уйланулар белән сугарылган. Аның шигъриятендә югары әхлак идеаллары раслана, суфиларча яшәү рәвеше мактала.

ишан[1] (1867 дә вафат) кебек әдип вә шагыйрьләр татарда шушы әдәбиятның үз вәкилләре булдылар. Бу әдәбият – шөбһәсез, Урта Азия, кыпчак вә чыгтай тәэсире астында булган руханилар әдәбияты иде.

**Дини-нәсери әдәбият.** XIX йөзнең башларында татарда дини-нәсери әдәбият та баш күтәрде. Васыятьнамәләрендә үзенең әдиплеген күрсәтүче Гаделша мулланың (Эстәрлебаш авылының мулласы булган, 1813 ел тирәләрендә вафат) углы Дәүләтша ахунның «Рисаләи нәҗатия»се һәм Габденнасыйр Курсавиның төркичә «Һәфтияк тәфсире» кебек китаплар шундый әсәрләрдән иде. Соңыннан бу юлда Җамалетдин Бикташевның (1865 ел вафат) «Фәзаил әш-шөһүр»[2] кебек әсәрләре язылып һәм соңыннан басылып, халык арасына күп таралды.

**Дини реформа чаткысы һәм акылга ирек сорауда беренче адым.** XIX йөзнең башларында татарда дини реформа чаткысы да күренеп алды. Татар дөньясында акылга ирек сорауның беренче адымы башланды. Гәрчә моның белән татар дөньясында дәвамлы, гомуми көчле бер хәрәкәт кузгатылып китә алмаса да, һәрхәлдә, бу хәрәкәт үзенең күтәргән шау-шуы белән татар дөньясында, әлбәттә, тәэсирсез калмады. Бердән, бу хәрәкәт татар руханилары арасында дини-фикри бер аерылыш ясый алды. Икенчедән, бу дини реформа чаткысы үзеннән илле еллар соң кузгалган Мәрҗанилар хәрәкәте өчен беренче нигез ташы булды.

Бу беренче реформа чаткысы һәм акылга ирек сорауның шушы беренче кузгалышы Бохара мәдрәсәләрендә укып, андагы дини галимнәр арасында дини яңалык җәнҗаллары кузгаткан, ахырда үзе Бохара әмире һәм галимнәре тарафыннан «зиндикъ»[3], «денсез», «дәһри»[4] дип үлемгә хөкем ителгән татар дини галиме

[1] Һибәтулла Сәетбаттал улы Салихов (Һибәтулла Салихбаттал, Һибәтулла Каргалый, Һибәтулла ишан, 1794–1867) – шагыйрь, дин эшлеклесе. Каргалы мәдрәсәсендә белем ала; 1842 елдан шунда ук мөдәррис, бистә мәчетенең имам хатыйбы була. Үзе исән чакта ике шигъри җыентыгы дөнья күрә: «Төхфәт әл-әүляд» («Балаларга бүләк»), «Мәҗмәгъ әл-әдәб» («Әдәпкә өйрәтү җыентыгы», 1856). Беренче китапта гарәп теле фонетикасы бирелә. Икенчесе дини-әдәп нәсыйхәтләреннән гыйбарәт. Күптөрле жанрларда иҗат итә: мәдхия, мәрсия, газәл, мәсәл, шигъри хикәят һ. б.

[2] «Фәзаил әш-шөһүр» – дини-әхлакый рухта язылган, дини хорафатлар белән сугарылган китап. Татарлар арасында иң күп таралган басмаларның берсе була, кадими уку йортларында «Иман шарты»ннан соң балаларга беренче дәрес китабы итеп укытыла.

[3] Зиндикъ – динсез.

[4] Дәһри – атеист.

Габденнасыйр әл-Курсави (37 яшендә 1813 ел тирәләрендә вафат) аркылы күтәрелде[1]. Бу кузгалыш, реформа чаткысы үз вакытында татар дөньясында зур гына бер шау-шу күтәреп алды. Татар руханилары һәм байлары арасында күп тарафдарлары һәм дошманнары туды. Күп әсәрләрен гарәп телендә язган бу көчле татар буржуа галиме[2] үзенең әсәрләрендә ачыктан-ачык акылга ирек таләп итеп чыкты. Татар дөньясында иҗтиһад[3] ишеге ачты[4], тәкълидкә[5] каршы күтәрелде. Дини бидгатьләргә[6], дини хорафатларга, әүвәлге галимнәрнең китапларына гына ияреп баруга каршы күтәрелеп чыгып, татар рухани галимнәре арасында нык көрәш башлады. Тәкълид

---

[1] Курсави һиҗри белән 1190 елда туып, 1227 елда вафат. Казан тирәсендә Курса авылында тора. Башта Малмыж өязе Мәчкәрә авылында укый. Соңра Бохарага барып укырга тотына. Ваба авыруы сәбәпле Истанбулда вафат була. Бохарада бер остазы – күп татар дини галимнәренең остазы булган төрекмән шәехе Ниязкол белән Шаһнияз дигән бер кеше. Курсави, Бохарадан кайткач, үзенең якын байлары аркасында Мәчкәрәдә мәдрәсә ача (гомумән, Курсави, аңлырак татар байлары белән бик якын мөнәсәбәттә булып, аларның яклавы астында эш итә).

[2] «Дамелла Габденнасыйрга Казан вә Мәчкәрә вә гайре байларының күбесе кариб *(якын, кардәш)* вә мөнәсәбәт иясе булып, мөхлис *(дус)* улдыкларыннан, аның әкъвале (*сүзләре*) вә тәсанифләрене *(китапларын)* тәрвиҗдә *(таратуда)* чалышып *(хезмәт куеп),* бу хосуста сәгый *(тырышлык)* вә бәзел *(юмартлык)* микнәт кыйлганнар *(көч куйганнар)*» (Мәрҗанинең «Мөстәфад әл-әхбар»е. Икенче бүлем, 297 бит). *(Авт. иск.)*

[3] Иҗтиһад – тырышлык белән эзләнү, акыл белән хакыйкатьне эзләү.

[4] «Мулла Габденнасыйр әл-Курсави – Казан губернасы Курса илендә имам вә мөдәррис вә һәм зиядә *(бик зур)* мөхаккыйк *(хакыйкатьне эзләүче)* вә мөдәкъкыйк *(тикшеренүче)* голәмаи заман *(үз заманының галимнәреннән),* хәтта мөҗтәһид *(дин китаплары буенча яңа хөкемнәр чыгаручы)* дәрәҗәсендә «Курса Габденнасыйр мулла» дип мәшһүр адәм иде. Һәр хөкемне Кәламулладан *(Коръәннән)* иҗтиһад кылыр иде вә әйтер иде: замане иҗтиһад мөнкарыйз түгел *(иҗтиһад заманы бетмәгән),* һәркем мөбтәляэн биһи *(зарурияткә очраган һәркем)* үзе иҗтиһад кылсын, мөҗәррәд тәкълид *(элгәреләр сүзенә генә иярү)* мәзмүм *(начар)*», – дияр иде». «Бохарада күп голәма белән моназара (*бәхәс*) кылышып, күп адәмнәрне илзам кылганнан соң *(бәхәстә җиңеп, җавапсыз калдырганнан соң),* әмиргә мәгълүм булып, әмир Габденнасыйр мулланы сәясәт *(җәза бирү)* мәйданына китереп, кател кылырга *(һәлак итәргә)* хөкем иткәч, дустлары вә шәрикләре бу сүзеңдән кайт, вә илля *(югыйсә)* башың китәр, дип димләгәнләрдер, як-ягында ничә җәлладлар ялангач кылыч белән торганда, Габденнасыйр мулла: «Бу сүземдән кайттым», – дигәч, әмир кателдән хәлас кылгандыр *(үлем җәзасыннан азат иткән)*». Габденнасыйр мулла Курсавиның виладәте *(тууы)* тәкърибән *(чама белән)* 1765 еллардадыр, хаҗ сәфәрендә Истанбулда тагун *(чума авыруы)* белән вафат булгандыр 1813 елда («Каюм Насыйри календаре», 1877 ел, 43 бит). *(Авт. иск.)*

[5] Тәкълид – башкаларга иярү.

[6] Бидгатьләргә – яңа гадәтләргә.

богавын өзү юлында фикри сугыш ачты. XIX йөзнең соңгы яртысы эчендә татар дөньясында Яурупа гыйлем дөньясының тәэсире белән очрашкан Мәрҗаниләр соңыннан шул Курсави юлын, аның фикерләрен, фәлсәфи нәзарияләрен[1] киңәйтүчеләр, шуңа якынрак бер юлда ачыграк бер шәкел бирүчеләр булдылар. Аннан соң янә Риза вә Мусалар[2] Яурупа методы беләнрәк шуны буржуа рухында тагын да киңәйтте, тагын да тармакландырып алып киттеләр.

**Фикри хәрәкәттә Курсавиның эшләре.** Курсави үзенең гарәпчә язган «әл-Иршад ли-л-гибад»[3] исемендәге әсәрендә үзенең диндә тоткан юлы «иҗтиһад» (үз акылың белән тикшереп, эзләп, табып, шул үз тапканың белән эш кылу) һәм тәкълид турысындагы фикере ничек булганын тәмам ачып сала. Үзе чыннан тәнкыйди бер әсәр. Ул моның белән, гәрчә гарәп телендә булса да, татарда беренче мәртәбә тәнкыйть юлын ача. Аның тәнкыйте дә – каты, ачы, әлбәттә, әдәби тәнкыйть түгел, дини, фәлсәфи бер тәнкыйть[4].

Курсавиның бер игътибар ителә торган ягы тагы шул: ул мәдрәсәләр салуга, китаплар язу эшләренә керешергә өнди. Тәкълидчеләрне тәнкыйть кылуны да важиб[5] эшләрдән

[1] Нәзарияләрен – теорияләрен, фикерләрен.

[2] Муса Бигиев (1873/1875–1949) – дин галиме, публицист, җәмәгать һәм дин эшлеклесе. Гомерен исламның нигез кыйммәтләрен кайтаруга багышлый һәм яшәешне шуларга нигезләнеп кору принциплары белән яши. Аның дин гыйлеменә кагылышлы идеяләре һәм дини-фәлсәфи фикерләре бөтен мөселман дөньясына тарала.

[3] «Әл-Иршад ли-л-гибад» – «Аллаһ коллары өчен нәсыйхәт».

[4] Ул әлеге әсәрендә үзенең тәнкыйть иткән кешеләрен болай дип сыйфатлый: «Шуны белергә кирәк: безнең гасырыбыздагы һәм үткән гасырдагы адәмнәр эчендә шундыйлар бар – алар, гыйлемнән өлешләре булмаган хәлдә, үзләрен гыйлем кешеләре катарына *(сафына, рәтенә)* куялар. Менә боларның тудырган сүзләрен хикәя кылу һәм сүзләренең бозыклыгын ачып бирү өчен, аерым битләр *(сәхифәләр)* ачсам, бик яхшы булган булыр иде; нәтиҗәдә, нык бер фикер, дөрес бер мәзһәб күрелер һәм, шулай итеп, наданлыктан, наданнардан йөз дүндерү, наданлыкны үтерү, шулай ук аларның исемнәрен үк югалту өчен бик яхшы хәрәкәт ителгән булыр иде. Ләкин эшнең соңы начар булып чыгудан, наданнарның шундый начар нәтиҗәле эшләрне күреп горурлануларыннан һәм аларның яңлыш булган бер игътикадка *(ышануга),* галимнәр каршында ташланган сүзләргә ышанырга ашыгуларыннан куркып, бу юлны тотмадым. Хосусән, гыйлем әһеленең киеме белән киенеп тә, караңгылык ишекләренә ябышып ятучы кешеләрдән курыктым. Шуның өчен тик аларның сүзләренең бозыклыгын гына ачып бирүне (ягъни аларның сүзләрен күчермәстән), сүзләрен рәд итә (*кире кага*) баруны гына халык өчен муафыйграк һәм нәтиҗәдә яхшырак була дип таптым», – ди (1 бит). Менә бу сүзләреннән Курсавиның акыл ирегенн буып, фикер хәрәкәтенә каршы торучы мөтәгассыйб *(фанатик)* татар муллаларына каршы нинди сызыкта торып көрәш башлаганын бераз аңлап булса кирәк. *(Авт. иск.)*

[5] Важиб – тиешле, мәҗбүри.

саный[1]. Шуның белән Курсави «каләм»челәргә дә каршы (соңыннан бу каршылыкны Муса һәм Ризалар бик нык көчәйттеләр).

Курсавиның тагын да шул вакыттагы әһәмиятле бер хәрәкәте иттереп суфилыкка (тәсаувыфка – мистикага), ишанлыкка каршы көрәш алып баруын санарга кирәк. Ул бу турыда үз заманы өчен шушы түбәндәге яңа һәм бик әһәмиятле сүзләрне яза: «Халык арасында безнең гасырыбызда һәм үткән гасырларда тәсаувыфка мәнсуб булу һәм «иршад» (изге юлга күндерү) вә «истиршад»ны (изге юлга күндерелү) дәгъва кылу таралып китте. Ләкин алар тәсаувыфның мәгънәсе һәм аннан максат нәрсә икәнен белмиләр. Шуңа карамастан, һаман алар берсе өстендә икенчесе булган катлаулы караңгылык эчендә томаланалар; яки болар төпсез диңгезгә батканнар да, анда дулкын өстенә дулкын күтәрелеп, аларны һаман каплый, баса бара» («әл-Иршад ли-л-гибад», 51 бит). Соңра ул суфилык дәгъва кылучы наданнарны ачыктан-ачык нык сүгә башлый, аларны «Алла диненнән башка бер дин белән динләнүче бозык, бидгатьче, зиндыйк – динсез» дип сыйфатлап китә[2].

[1] Курсави: «Безнең илебезнең яки теге илнең галимнәре: «Әнә шулай дип фәтва биргәннәр. Шулай булгач, аларның фәтвасынча гамәл кылу безгә ваҗиб. Аларның фәтвасына каршылык күрсәтү – бу бидгать вә заляләтдер *(ялгыш юлга керү)*», диләр», – ди дә шуңа каршы үзе: «Менә бу сүз үзе – бидгатьнең берсе», – дип куя. Кай мөтәгассыйбларның «Шушы фәлән китап шушы фәлән вә фәлән шәһәрдә, фәлән вә фәлән вакытлардан бирле мәшһүр булып килә. Шулай булгач, анда игътикадтан вә гамәли мәсьәләләрдән булган һәммә хөкемнәр хак, аңа каршы китү һич ярамый. Аңа каршы булган кеше – явыз кеше, азган кеше яки ул кяфер булып, аны үтерү хәләл, бәлки ваҗиб (тиеш); аны үтерүче саваплы булачак» илх *(һәм башкалар)*… кебек сүзләрен күчерә дә: «Шушы сүзләрне сөйләүчеләр артыннан бидгатьләр иясеннән һич аерылмый ияреп йөри торган эт кебек ияреп йөрерләр. Син аларга меңләп ныклы дәлилләр торгызсаң да, алар аны үз күзләре белән күрсәләр дә, алар шуны һаман игътираф итмәсләр *(ялгышларын танымаслар);* бәлки күзебез ялгышты, һәм без сихерләндек, диярләр», – ди («әл-Иршад ли-л-гибад», 40 бит).

Югарыдагыларга кушып, Курсавиның янә түбәндәге сүзләрен тыңлыйк: «Мең әмир яисә гыйлем киеме белән киенеп галим күренергә тырышкан меңнәрчә адәмнәр гамәл кылсалар да, аның белән гамәл кылырга, аңа ышанырга ярамый. Гамәл кылучыларның һәм әмирләрнең гамәлләренә дәлил итү һәм галимнәр эченнән шуларның ишек төпләрендә йөрүчеләрнең гамәлләрен таяныч ясау – бу гафләт вә җәһаләт әһелләренең вә мөһимнәре ясап чыгарган бер нәрсә генә», – ди («әл-Иршад ли-л-гибад», 42 бит). Янә «Фәлән кеше болай дип әйткән иде, ә фәлән кеше алай әйтми; без мөселман турында яман уй уйлый алмыйбыз, сүи зан кылмыйбыз *(начар сүз әйтмибез),* аның сүзен игътибарга алабыз. Бәс, аныңча гамәл безгә ваҗиб» дигән сүзләр янә үзләре бидгатьтер (ягъни мөселманлыкта булмаган, соңыннан тудырылган ялганнар)», – ди. *(Авт. иск.)*

[2] «Вә-әммас-суфиел-җаһил фәйәтәдәййәнә бигайри дини-Лләһи минәл-бидәгый вәл-әһваиш-шаига фин-нас фәйәкүнү зиндикан мөбтәдиган вә-лә йәкүнү филхакыйкати суфийән» (53 бит). *(Авт. иск.)*

Надан суфига килгәндә, ул Алла диненнән башка, кешеләр арасында таралган бидгать һәм мавыгуларга бәйле башка дингә иярә, һәм шуңа күрә ул уйлап чыгаручы динсез була һәм чын суфи булмый.

Үзенең 1905 елгы революциядән соңгы беренче шигырьләрендә (XX йөздә дә әле) Тукайның суфилар, ишаннарны сүгеп чыгуын, шундый феодал калдыкларына һөҗүмен, шулай ук Ф. Әмирхан, Гаяз кебекләрнең дә шундый феодализм калдыклары белән бик ныклап көрәшүләрен искә алсак та, Курсавиның бу көрәшне инде XIX йөзнең әүвәлләрендә үк башлаганын уйласак, аның татар иҗтимагый фикри хәрәкәт тарихында нинди урын тотканлыгын, тотарга тиешлеген артык сөйләп торырга да хаҗәт калмас. Кыскасы, Курсави – татар дөньясында, татар буржуа тормышының, татар сәүдә капиталы адәмнәренең үз вакытыннан иртәрәк җитешкән бер гыйльми вәкиле иде. Шуның өчен ул вакыттагы татар әдәбиятына [аның] турыдан-туры артык тәэсире була алмады. Әдәбият һаман Урта Азия рухында тәсаувыф юлыннан китте.

Курсавига болай озынрак тукталуыбыз әнә шул, аның татарда фикри хәрәкәт тарихында беренче баш каһарман һәм татар буржуасының беренче гыйльми вәкиле булганлыгы өчендер.

Ләкин шушы Курсави фикереннән файдаланучыларның күбесе татар буржуазиясенең соңыннан җәдитчелек хәрәкәтендә эшләүчеләр булдылар. Шуның өстенә болар Курсавиның дини-фәлсәфи фикерен заманга муафыйк рәвештә киңәйтә бардылар.

Курсавиның татар телендә безгә мәгълүм булган әсәре – «Һәфтияк тәфсире»дер. Аннан башка тагын аның татарча язган китаплары булса да, алары югалгандыр.

**Сыйнфый лирика.** Шушы беренче дәвердә, икенче яктан, татар крестьянына каршы каты бер сыйнфый дошманлык лирикасы – дөньяви вә сыйнфый бер лирика да баш күтәрде. Кандалый[1] дигән бер рухани татар шагыйре (1850 елда вафат) шуның баш вәкиле булды. Сөяк җелекләренә кадәр эшче-крестьянга дошманлык тойгысы белән сугарылган бу чын реалист татар лиригы, шулай итеп, татар әдәбиятына сыйнфый көрәш орлыгын китереп салды. Шуның белән бергә татар язма әдәбиятының лирика кыйсемендә шуның аркылы

[1] Габделҗаббар Габделмәҗит улы Кандалый (1797–1860) – шагыйрь, татар һәм гарәп телләрендә яза. Беренче «Рисаләи-әл-иршад» («Тугры юлга күндерүче китап», 1815/1816 тирәсе) әсәрен Кандалый мәдрәсәдә укыган чорда иҗат итә. Бу дини-дидактик әсәрендә автор укучыны мөселман дине кысаларында гына мөмкин булган дөреслеккә өнди. Гыйлемлелекне югары бәяләп, Кандалый крестьянга карата беркадәр һавалылык (тәкәбберлек) күрсәтә. Аныңча, укымышлы кешегә игенчелек хезмәте килешми. Шулай ук заманасына күрә новаторлык рухында иҗат ителгән «Сәхипҗамал» поэмасында да Кандалый гади хезмәт кешесен укымышлы дин әһеленә каршы куеп сурәтли. Г. Сәгъди шагыйрьнең әнә шул әсәрләрен күздә тота булса кирәк.

беренче мәртәбә реализм адымы атланды. Һәм шул юлда хәзерге мәгънәсе белән татар теле рухында садә, ләкин рус теле тәэсиренә бирелә башлаган бер өслүб мәйданга ташланган булды.

Бу дәвернең ахырында татар феодал җәмәгате эченнән татар баш руханиларының, мөфти һәм байларының мәддахлары[1] да җитеште. Гали Чокрый[2] (1889да вафат) кебек шагыйрьләр шуларның иң нык күзгә ташланганнарыннан булдылар[3]. Ләкин, шуның белән бергә, бу шагыйрь татар феодал әдәбиятының соңгы вәкиле булды.

**Гыйшык дастаннары.** Әдәбиятның шушы югарыдагы бүлеме белән бергә, шул ук дәвер әдәбиятының дәвамы булып, хәтта XIX йөзнең соңнарында татарның гавамы өчен шул ук тәмам кадим Шәрык мәүзугында иң җиңел, ул вакытта иң гавами бер өслүбтә, ләкин бераз казакъ теле тәэсире астында «Таһир-Зөһрә», «Бүз егет» кебек гыйшык дастаннары (поэма) язылды. Шулар аркылы иске Шәрык гыйшкы һәм шул юлда күрсәтелгән хыялый каһарманлыклар белән гавам егетләре, гавам кызлары өчен әдәби азык бирелде. Уразаи-Кормашиның[4]

---

[1] Мәддахлары – мәдхиячеләре.

[2] Гали Чокрый (Мөхәммәдгали Габдессалих углы Көеков, 1826–1889) – шагыйрь, мәдхияләр, элегияләр, дини-дидактик әсәрләргә шәрехләр, юлъязмалар, тарихи хезмәтләр авторы. Дини-мистик идеяләр хас «Замме нәзыйр», «Тәрхибе рамазан» һ. б. әсәрләрендә Г. Чокрый дини үгет-нәсыйхәт бирә, исламга һәм аның эшлеклеләренә мәдхия укый. Чокрыйның замандашларына багышланган мәдхияләрендә аларның ватандашлары алдындагы казанышларына аеруча игътибар бирелә.

[3] Аның дүртенче мөфти Сәлимгәрәй мирза Тәфкилев турында:

«Лотфы Хакла булды чөнкем мөфтилектә мәнсабы,
Лотфыйлә бәс гамил улды хаҗи мирза Тәфтилев.
Ул үзе бер боярдыр, малы-милке бихисап,
Мөслиминә кул-канаттыр хаҗи мирза Тәфтилев.
Дәүләте чук, хөрмәте чук, илдә-көндә бер кеше,
Йөз мең ирдән мәшһүр улды хаҗи мирза Тәфтилев.
Йорты мәгъмүр, малы мәүфүр, кальбе салим бәс аның,
Ришвәт алмас һич галимдән хаҗи мирза Тәфтилев.
Рөтбә вирде һәр имамга иҗтиһады микъдар ул,
Нәчәләрне тархан итде хаҗи мирза Тәфтилев.
Дәүләте[н] Хак даим итсен, мәнсабын һәм мөстәдам,
Чөнки мәнсаб берлә кылды ихсан безгә Тәфтилев», –

дигән тезмәләре шулар рәтеннәндер. Икенче яктан, бу шигырьләр безгә ул вакытларда мөфти һәм мирзаларның татар руханилары өстеннән хакимлекләре ни дәрәҗәдә икәнен ачып бирү өчен дә бик кирәкле бер тарихи материаллар булып торалар. *(Авт. иск.)*

[4] Кормаши (Әхмәд Мөхәммәдзариф улы Уразаев, 1855–1883) – XIX йөз шагыйре. Мәхәббәт турында ике романтик поэма-дастан авторы: «Кыйссаи бүз егет» (1874) поэмасы татар шагыйре Баһавинең шул исемдәге поэмасына нигезләнеп языла, «Кыйссаи Таһир илә Зөһрә» (1876) – Шәрыкта киң таралган сюжетка язылган төрек вариантының ирекле тәрҗемәсе. Ике поэмасы да зур популярлык казана һәм 1917 елга кадәр берничә тапкыр басыла.

бу әсәрләрен ак өстендә караны әз генә аера ала торган татар яшьләре, егетләре күп укый торган булдылар. Шулай итеп, болар вакытында татар массасына нык тәэсир күрсәтте, әдәби зәвык бирделәр.

**Кыска сүз.** Югарыда сөйләгәннәрне бик кыска итеп җыеп әйткәндә, болай була:

1) су кырыйларындагы игенлекле җирләрдән аерылу, үзәкләрдән ерак җирләргә күчерелеп яисә сөрелеп, иген эшләре белән шөгыльләнүдән күп файда булмау;

2) Мәскәү сәүдә капитализмының көчле тәэсире;

3) крестьяннары чукынып та, алпавытлары үзләре чукынмасалар, крестьяннарыннан аерылу кебек хәлләр;

4) шулар өстенә Шәрыкның телен, гореф-гадәтен, психологияләрен белүләре аркасында татар алпавытларының, мирзаларының үзләре өчен дә Шәрык сәүдәсендә Мәскәүгә васита булулары файдалырак дип табылып, аларның сәүдәгәрлеккә чыгарга теләүләре кебек сәбәпләр белән, татар феодаллары XVIII йөздә алпавыт, тылмач-чиновник, сәүдәгәр, фабрикант, крестьян рәвешендә берничә төркемгә бүленгән һәм татар сәүдә капитализмы үсә башлаган иде. Татарның һәм рухани, һәм дөньяви феодалларының Мәскәү сәясәте нигезендә татар массасы өстеннән хакимлеге Мәхкәмәи шәргыя һәм «указ» аркылы рәсмиләштереп ныгытылган, шулай ук кадим Шәрык идеологиясенә беркетелүдә көч ала башлаган иде.

Шул халәттә XIX йөзнең икенче ярымнарына кадәр һаман көчәя барып дәвам итте.

Шуның өчен шушы беренче дәвердәге әдәбият та, чын мәгънәсе белән кадим Шәрык, феодалчылык нигезендә үсеп, югарыдагы икътисади, сәяси хәлләрнең бер табигый нәтиҗәсе булып туды.

Бу дәвердәге әдәбиятның мөндәриҗә[1], тел, өслүб, тезмә формалары да Урта Азия тәэсиренә нык бирелеп килде.

Әдәбиятыбызның икенче дәверенә – XIX йөзнең соңындагы әдәби хәрәкәтләргә – без менә шундый юллар белән хәзерләнеп, шундый әдәби сәрмаяләр[2] белән килеп кердек.

---

[1] Мөндәриҗә – эчтәлек.
[2] Сәрмаяләр – байлык.

# ИКЕНЧЕ ДӘВЕР

## БЕРЕНЧЕ БАСКЫЧ

### [I]
### Икенче дәвердә икътисади, иҗтимагый-сәяси як

Беренче дәвернең ахырларында, ягъни XIX йөзнең икенче ярымында Русиядәге гомуми икътисади барыш юлында рус сәүдә капиталы рәтеннән татар сәүдә капиталы да инде үзен күрсәтә башлаганын күреп үткән идек. Шул ук йөзнең башларында хокуклы купецлардан тик Казан купецларының саны гына йөз гаиләдән артык булу безгә шуны ачык күрсәтә.

Кыскасы, XVIII йөзнең соңнарында үсү адымын башлаган татар сәүдә капиталы ияләре дә XIX йөзнең башларында инде буржуазлану ягына таба авыша баралар. Шулай итеп, XIX йөзнең башларыннан ук (бәлки XVIII йөзнең ахырларында ук) татарның әүвәлге хаким сыйныфлары, ягъни мирза, алпавытлары урынына яңа бер сыйныф – буржуа сыйныфы хәзерләнү хәрәкәте башлана.

Гәрчә тарихи мәнбәгъләр[1] XVIII йөзнең соңнары һәм XIX йөзнең башларында татар сәүдә капиталының суммасы 10–20 меңнәр чамасыннан арта алмаганнарын күрсәтсәләр дә, XIX йөзнең урталарына таба шул сумма бик тизлек белән кызу үсү юлын ала. XIX йөзнең башларыннан кустарьлыктан мануфактурага әйләнә башлау рәвешендә татарда күп кенә завод-фабриклар да тудырыла. Бу йөзгә кергәндә, Казанда Татар ратушасына[2] караган кешеләр кулында гына барысы 24 завод була[3]. Фабриклардан Вятка губернасы, Уржум өязе, Протенар авылының йомышлы татары Мәхмүд Мамутовның комач фабригын (бу фабрик үзенә комач һәм мамыкны

[1] Мәнбәгъләр – чыганаклар.

[2] Биредә сүз Казан шәһәре татар бистәләре ратушасы – 1781–1855 елларда Казанда татар бистәләренең үзидарә органы турында бара. Ратуша составына ныклы тормышлы сәүдәгәрләр һәм эшмәкәрләрдән 30 яшьтән ким булмаган, «намуслы һәм тәртипле» кешеләр сайлап куела. Ратуша сәүдәгәрләр һәм мещаннар катлауларына язуны формалаштыру, сәүдә итәргә бару өчен паспортлар бирү, бурычларны эзләп алу, банкротлык эшләре, салымнар җыю, варислар арасында милек бүлү, корабльләр төзү өчен агач әзерләүгә җибәрү, рекрутлар җыю белән шөгыльләнә. Ратуша шәһәрнең татар җәмәгатьчелеген туплауда, татар сәүдәгәрләре һәм сәүдә капиталлары булдыруда мөһим роль уйный.

[3] 11 е – сабын заводы, 3 есе – казул заводы, 10 ысы – тире заводы. *(Авт. иск.)*

Бохарадан китертә булган) күрсәтә алабыз[1]. Шуның белән бергә, бу урында шушы заводлардан тик тире һәм сабын заводында гына татар авылларыннан җиде йөз кеше ялланып килеп эшләгәнлекләрен аеруча әйтеп үтәргә кирәк.

Шул рәвешчә, без XIX йөзнең башларыннан инде татар сәнәгать капиталы башлануының беренче зәгыйфь адымнары кузгалганын да күрәбез. Шул ук XIX йөзнең беренче ярымының соңнарында «бай» дип танылган татар купецларыннан ике миллион сумлылар, хәтта өч миллион сумнан артык суммага ия булган купецлар да була. Ярты миллионлы татар купецлары инде алар бу вакытларда күп булганнар. Болардан башка тагын зур гына капитал ияләре дә аз булмаганнар[2]. XIX йөзнең беренче ярымының соңнарында тик Казанның үзендә даими торучы беренче, икенче, өченче гильдия

[1] Бу заводлар-фабриклар крепостной көчләр белән түгел, бәлки ялланып эшләүчеләр көче белән дәвам иткәннәр. Бу эшчеләр татар ярлы һәм йомышлыларыннан һәм ясаклылар эченнән килгәннәр. *(Авт. иск.)*

[2] Бу турыда әле татар матбугат дөньясына чыкмаган кыйммәтле материаллар татар дөньясын, татар этнографиясен тикшерүче һәм гыйлем дөньясында танылган мәшһүр галим, врач К. Фукснең 1844 елда Казан университеты басмаханәсендә басылган «Казанские татары в статистическом и этнографическом отношениях» дигән әсәрендә бар (124, 131 битләр). Шулай да мәсьәләне, бу турыда яхшырак сурәтләндерү өчен, бу урында аннан алып, түбәндәге мәгълүматларны язып үтәбез: «XIX йөзнең беренче ярымының соңнарында Казан татарында елга илле мең пот яхшы сабын чыгара торган биш сабын заводы (кенәз Мирза Замановның һәм Юнысов, Арсаев, Апанаев, Якупов заводлары), елга бер йөз илле казул эшләп чыгара торган биш завод (Юнысов, Апанаев һәм Усманов заводлары), елга егерме мең пот май, шәм чыгара торган ике зур завод (Юнысов һәм Арсаев заводлары) һәм шул ук эш өчен Казанда болардан башка күп вак заводлар бар. Шулар өстенә биш туку фабригы (купецлардан Апаков, Газимов, Уразов, Габдуллин һәм Бикмөхәммәдевләрнең фабриклары) булып, болар үзләрендә эшләнгән товарларын Оренбург ярминкәләрендә саталар. Шулар белән бергә, тагын ике татар бистәсе (слободасы) арасында һәр ел илле мең пот чыгара торган тоз заводы (Алишев заводы), читек-кәвеш кайый торган фабриклар (Габдуллин һәм Фәйзуллиннарның фабриклары) бар. Бу заводта татар хатын-кызлары һәм шулар белән бергә рус кызлары да эшлиләр. Бу ике каю фабригыннан башка да күп татарлар читек каю белән мәшгуль булалар. Хәзер дә (шул ук йөзнең беренче ярымының соңнарында) бай дип бигрәк купецлар саналалар. Ике ярым миллион суммалы (Габдерәшид Юнысов кебек) купецлар булган шикелле, өч миллионнан артык суммалы купецлар да (Гобәйдуллин, Юнысов кебек) бар. Ярым миллион суммалы кешеләр дә (купецлар) шактый барлар (Хөсәен Апанаев, Апаков, Корбангали Арсаев, Исхак Якупов, Тимербулат Якупов, Давыт Хәйдегәрәев, Мостафа Ләбәхин, Миңлебай Козлов кебекләр). Болардан башка тагы зур гына капитал ияләре дә аз түгел (124–131 биткә каралсын).

Шул ук йөзнең соңыннан Казан базарларына төрле яклардан күп татар мещаннары җыелып, авыллардан чималлар (сырье) китерәләр. Һәр ел Казанга Кама артыннан, Уфадан, Оренбург тирәләреннән барысы миллион ярымга якын чи тире керә. Шулар эченнән, шулар ук кулыннан рус купецлары аркылы алты йөз мең сыер, дүрт йөз мең ат тиресе Петербургка (Ленинградка) озатыла, ел саен Казанның сабын һәм шәм

татар купецлары гына 76 булу, шулай ук авыл сатучылары – крестьяннар эченнән Казанга килеп йөрүче сатучыларның саннары 850 гә җитү бу вакытлардагы сәүдә капиталының хәлен безгә бик яхшы ачып сала.

Бу хәлләрдән без, XIX йөзнең икенче ярымына кергәндә, татарда капитализм тормышының яхшы ук нык үсә барганын, татар буржуа сыйныфының да инде чынлап баш күтәрә башлаганын; моның өстенә янә шулай ук татарлар арасында эшче сыйныфының – пролетариатның туып килүен (11 татар заводында тик авыллардан гына 700 эшче булганына дикъкать ителсен) ачык күрә алабыз. XIX йөзнең беренче ярымы эчендә татар купецлары, гомумән, сәүдәгәр татарлар рус купецлары, рус сәүдәгәр халкы белән яхшы ук бер-берсенә якыная, берсе икенчесенең сыйныфташ икәнлекләрен аңлый башлыйлар. «XVIII йөз башларында татарлар турында руслар тарафыннан әйтелә, сөйләнә торган каты, ямьсез сүзләр дә әйтелмәс була»[1]. Шулай итеп,

---

заводлары өчен бер йөз илле мең потлар чамасы эрегән туң май, ун мең потлар чамасы балавыз, егерме мең потлар чамасы бал керә.

Болар һәммәсе – тик татар тарафыннан, татар сәүдәгәрләре кулы аркылы гына кергәннәренең хисабы.

XIX йөзнең беренче ярымы эчендә татарлар руслар белән якыная, дуслашалар.

XVIII йөзнең башларында татар турында руслар тарафыннан әйтелә, сөйләнә торган каты, ямьсез сүзләр дә сөйләнмәс була (130 биткә каралсын). XIX йөзнең беренче ярымының соңнарында Казанның инде үзендә 1нче гильдияле купецлар – 5 гаилә, 2 нче гильдияле – 2 гаилә, 3 нче гильдияле 68 гаилә булалар. Шушы 76 гаиләдә барысы ир, хатыны 751 җан купецлар составы була. Мещаннар составы барысы 3670 җан була. Болар Татар бистәсенең даими торучылары булалар. Әмма шулар өстеннән тагын татар авылларыннан Казандагы татар сабын һәм тире заводларына җиде йөзләп кеше эшкә яллаunion килә. Шулар өстенә янә Казан губернасының һәр өязләреннән Казан мещаннары рәтенә язылмаган авыл сатучылары – крестьян эченнән чыккан сатучылар киләләр. Боларның саннары 850 гә җитә (1–2 биткә каралсын). *(Авт. иск.)*

[1] Фуксның югарыдагы әсәренә каралсын. Шулар өстенә Каюм Насыйри үзенең календаренда Казанның олуг вә могтәбәр «ингам вә ихсан иясе» *(яхшылык һәм изгелек иясе)* байларыннан 30 лап кешенең кыскача тәрҗемәи хәлен язып килеп, Гобәйдулла Юнысов кебек кайберләре турында: «Казан нахиясендә *(төбәгендә)* аның сөфрәсендән (*табыныннан*) нигъмәт ашамаган адәмләр бик аздыр. Рус мәмләкәтендә генә түгел, бәлки Яурупа йортларында мәшһүр вә мәгъруф *(билгеле)* иде», «Казан йортына падишаһ фамилиясендән ниндәен шәхесләр килсә, алар йортына кадәм *(аяк)* басмый калмадылар», дип сыйфатлавы, шулай ук Корбангали Арсаев (бу кеше Фукс китабында да әйтелә) турында язганда, шул уңай белән «бер заманда Казан шәһәрендә дүрт-биш бик мәшһүр, атаклы байларның берсе иде. Ул бер гасырда булган атаклы байларның берсе – Юныслар, икенче – Апанайлар, өченче – Апаклар, дүртенче Арсайлар иде. 30–40 нчы елларда шөһрәтләре бик куе иде Казан мөселманнарыннан иң әүвәл Почётный гражданлык гыйнванын алган кемсәләр ошбулардыр. Болар,ягъни Арсайлар асыл Олуг Кавал карьясеннәрдер. Аталары Әхмәр, әүвәл башта Җаекта сәүдә кылып, аннан соң Казанга килеп, май белән, поташ белән сәүдә кылдылар», – диюе дә югарыда Фукстан

моның белән татарның, гомумән, рус дөньясына, рус мәдәниятенә, рус һөнәр-сәнәгатенә якынлау, русның мәдәни тәэсире астына төшү, мәдәни-иҗтимагый хәрәкәттә яурупалашу ягына таба нык авышу хәрәкәтләре кузгала башлый, шуңа көчле зәмин[1] хәзерләнә.

Бу хәлне, ягъни яурупалаша башлауның беренче башлангыч галәмәтләрен без татар купецларының гаилә тормышында, өй җиһазларында да күрә башлыйбыз. Югарыда беренче дәвер турында да аңлатылып үтелгәнчә, «Татарлар – иске Мәскәү рус сәүдә капиталының көнчыгышка таба хәрәкәт юлында иң беренче очрашып, иң элек җиңелгән, кан, үлем эчендә иң элек Русиягә алынган халыкларның берседер. XVI йөздән алып, ике арада катнаш әле дуслык, әле дошманлык көннәрен кичереп килде. Әмма XX йөзгә кергәндә, бу өлкәнең колонизациясе әллә кайчан ук тәмам ителгән, татарның мәхкүмияте[2] бөтен мәгънәсе белән булып беткән иде»[3]. Менә шушы хәлнең табигый бер нәтиҗәсе булып, татарның икътисади, сәяси, иҗтимагый, мәдәни тормышлары да, XVI йөздән башлап, күп яктан төбендә бөтен Русиядәге икътисади, сәяси, иҗтимагый, мәдәни хәлләрнең гомуми барышлары белән багланып, шулар тәэсире астында дәвам итә килде. Бигрәк тә XIX йөз эчендә татар бюрократиясе, татар буржуазиясе белән рус бюрократиясе үзләренең уртак сызыкларын бергәрәк билгеләп бардылар. Киткән саен, һаман бер-берсен аңлаша, якынлаша тордылар. Татар буржуасы рус буржуасыннан, әкренләп булса да, һәр эштә һаман үрнәк ала, үзенә хәрәкәт сызыгын шуларга карап билгели барды.

Бу – бер. Икенче яктан, шуның бәрабәренә Русиядәге рус һәм татар бюрократиясенең, гомумән, буржуа сыйныфының эксплуатациясе, шулай ук самодержавие кысынкылыгы астында татарның эшче-крестьяны да рус эшче-крестьяны, рус пролетариаты белән якынлаша, бер-берсе белән аңлаша барды. Татар эшче-крестьяны бюрократиягә һәм, гомумән, буржуазиягә каршы хәрәкәттә рус пролетариатыннан үрнәк ала килде. Аның белән бергә бертөрле шартлар астында эшләп, сыйнфый якынлык фикерләрен миенә сала

алынган мәгълүматларның дөрес икәнен күрсәтә. Гомумән, Каюм Насыйриның шушы 1883 елгы календарендагы Казан байлары турында «Тәзкирә» дигән мәкаләсе (31–40 битләргә каралсын) – Казандагы татар сәүдә капиталы һәм аның ияләренең хәлләре белән яхшы танышу өчен әһәмиятле тарихи материалларның берседер. *(Авт. иск.)*

[1] Зәмин – нигез, җирлек.

[2] Мәхкүмияте – буйсынуы.

[3] «Татарлар арасында революция хәрәкәтләре». 6 бит. *(Авт. иск.)*

башлады. Шулай итеп, нәтиҗәдә, аның белән бер сызыктан хәрәкәт итү зәминнәре хәзерләнү юлы ачылган булды.

Менә шушы яклардан карап, татарның икътисади, сәяси, иҗтимагый, әдәби хәрәкәтләрен тикшергәндә, бөтен Русиядәге, ниһаять, Октябрьдән соң бөтен Советлар Союзындагы гомуми барыш белән бергә баглап тикшермичә булмый.

Шушы метод буенча тикшергәндә, эшнең барышы болай булды. Безгә мәгълүм: XIX йөзнең соңгы ярымында Русиядә гомуми икътисади, сәяси, иҗтимагый шартлар нык сизелерлек рәвештә бердән үзгәрә башлады. Гомуми хәлләр ягыннан караганда, шул ук сәүдә капитализмының үсүе һәм аның таләп итүенең мәҗбүрияте астында бу дәвернең баш ягы крестьяннарның крепостнойлыктан азат ителүләре, реформачылык хәрәкәтләре, земстволар ачылу эшләре белән башланып китте. Ләкин бу азатлык тиздән чабуларын җыйный, кире тарта башлады. [18]80 еллардан алып XX йөзгәчә (бәлки 1905 ел революциясенәчә) Русиядә икътисади як һәм хуҗалык эшләрендә һаман крепостнойлык калдыклары дәвам итте. Крестьяннар рәсмән азат ителгән булсалар да, чыннан да, алар һаман алпавытларга, зур җир ияләренә бәйләнеп калдырылдылар. Элекке җирләрен крестьян хуҗалыгы күтәрә алмаслык бер дәрәҗәдә кыйбат хак белән байлардан арендага (иҗарәгә) алып яшәү коллыгына төштеләр. Русиянең алпавытлык-түрәлек власте крестьянны яңадан шул хәлгә төшерде. Шуның өстенә 1890 елдагы ачлык та крестьянның икътисади яктан да ныграк изелүенә сәбәп булды.

Шул ук дәвердә Русиядә сәүдә капитализмы бик нык үсеп китте. Чит мәмләкәтләргә ашлык чыгаручылык хәрәкәтенең көчәюе дә моның өчен киң юл ачты. Җир эшләрендә кризис башланды. Авыллар пролетариатка һәм вак авыл буржуазиясенә бүленделәр. Авыл ярлылары да эш эзләп шәһәргә китү юлын алдылар. Сәүдә капитализмының таләбе буенча һәм аның файдасын саклап, крестьяннарның болай шәһәрләргә күчүләренә каршы хөкүмәт каты көрәш ачуга карамастан, бу хәрәкәт һаман дәвам итте. Ахырда барып, крестьяннар язмышы земский начальниклар кулына тапшырылды (1889 елда). Сәүдә капитализмы белән бергә үк бу дәвердә сәнәгать капитализмы да нык үсә башлады. 1890–1900 еллар арасында инде Русиядә эре сәнәгатьнең үсүе бик шәбәеп китте. Техника, машина эшләре тәрәккый итте, заводлар, фабриклар, шахталар, тимерьюллар, пароходлар артканнан-арта бардылыр.

XX йөз башларында Русиядә эшләп чыгаручылык, завод, фабрик сәнәгате һәм финанс капиталы үсте. Шәһәрләрдәге рус капиталистлары, шулар белән бергә үк, шулар эзеннән китеп, татар капиталистлары баедылар, шәһәрләрдә инде зур татар капиталистлары, фабрикантлар мәйданга чыкты.

Бу хәл авылларга да тәэсирсез калмады. Вак авыл буржуалары, авыл кулаклары мәйданга килде, хәтта XIX йөзнең ахырларында – XX йөзнең башларында татар авылларының күп кенә мулла-мәзиннәре дә сәүдәгәрлеккә әйләнеп, татар авылларында кибетләр ачылды. Анда да сәүдә эксплуатациясе кыздырыла башлады. Шулай ук авылларга яңа эш кораллары, машина һәм тимер сабаннар барып керде. Татар авыл ярлылары да шәһәргә күпләп агыла башладылар.

Шуның белән бергә, бу икътисади хәрәкәтләрдә татарның үзенә аерым роле дә булып алды. Шуның аркасында аның (татарның) Урта Азия белән килгән сәүдә капиталы көчәйде. Шуның өстенә бу сәүдә капиталының юнәлеш ноктасы да үзгәрде: татар буржуасы аны көнчыгыштан көнбатышка борды. Инде татар капиталы бигрәк көнбатышның – Мәскәүнең фабрика мәхсулатын[1] Урта Азиягә күчерүдә һәм аннан чимал (сырье) китерүдә хәтта монополия рәвешендә зур бер васитачылык[2] ролен алды. Шуның аркасында аның үз куәте дә күп артты.

Бу да шулай булды:

«XIX йөздә, бигрәк тә аның соңгы яртысыннан алып, дөньяның – Русиянең төрле өлешләре тимерьюллар белән бәйләнеп, Казан өлкәсе бер яктарак калуы сәбәбеннән, бу районның сәүдә, сәнәгатьтә роле кими башлагач, Русиядә кузгалган сәнәгать тәрәккыясе эчендә татар сәүдә капиталы үзенең зур куәтен читкә сипте. Элеккедән артык Башкортстан белән Себерне каплады, һәм Урта Азия белән Яурупа арасында көньяктан төньякка һәм көнчыгышка таба озын бер буй булып тезелгән шәһәрләрдә сәүдә эшләре бөтенләй диярлек татарга күчте. Әстерхан, Уральск, Оренбург, Орск, Троицк, Кызылъяр (Петропавел), Семипалат шәһәрләре менә шушы җөмләдән иде. Бу бөтен җәгърафи[3] бер буйдан башка Башкортстанның үзәгендәге Уфа һәм аның өязләре, Себер һәм Ерак Көнчыгышның да Чита, Харбин, Владивостокка чаклы җирләре татар сәүдә капиталының

[1] Мәхсулатын – эшләп чыгарган әйберләрен.
[2] Васитачылык – арадашлык.
[3] Җәгърафи – географик.

тармаклары, агентлары, бүлекләре белән капланды. Ләкин моның иң көчле җирләре әнә шул Урта Азия белән Яурупа арасындагы буйда, аеруча Оренбург, Каргалы, Троицк кебек урыннарда булды» («Татарлар арасында революция хәрәкәтләре», 10–11 бит)[1].

Сүзнең кыскасы, Русиядәге [18]61 елгы азатлык, гомуми реформа хәрәкәтләре руслар белән беррәттән татар дөньясында түбәндәге икътисади хәрәкәтләрне кузгатты: «Татар крестьяны башкалар белән бергә алпавыт истибдадыннан[2] азат булып, үз иркенә хуҗа булды. Элекке ярым натураль көнкүрешеннән чыгып, базар, сәүдә-сәнәгать дулкыны эченә таба кузгалды. Казан вак һөнәрчесенең зур бер груһы[3] эш эзләп читкә таралды. Калганының күбе, мөстәкыйльлеген җуеп, татар сәүдә капиталының эксплуатациясе астына керергә мәҗбүр булды. Татар, мишәр сәүдә капиталы исә элекке хәлләр белән чагыштырылмас дәрәҗәдә киңәйде, зурайды һәм көчәйде. Шуның белән бергә, сәнәгать эшенә (производствога) катнаша башлады. Боларның һәммәсе белән бергә татарның бөтен тормышы, бигрәк тә иң алгы һәм иң көчле булган татар, мишәр сәүдә-сәнәгать сыйныфы рус-Яурупаның техникасы, сәүдә-сәнәгать мәйданы дулкыны эченә керде. Шулар белән ярышырга, шулардан өйрәнергә, шулар коралы белән коралланып эш итәргә мәҗбүр булды. Теге элекке Шәрык кайдадыр артта, икенче планда калды. Дулкын Шәрыктан Гаребкә борылды[4]».

Шул рәвешчә, бер яктан, рус һәм татар буржуазиясе арасында шундый баю, зур капиталистлыкка әйләнү хәрәкәтләре барганда, икенче яктан, гомумән, Русиядә эшчеләр, крестьяннар һаман икътисади яктан нык кысылу астында яшәделәр. Сыйныф тартышлары кузгалды. Буржуа һәм пролетариат сыйныфы арасында икътисади көрәшләр башланды. Эш ташлаулар, забостовкалар, стачкалар көчәйде.

Шушы бөтен гомуми икътисади хәлләр нәтиҗәсендә һәм шул туфрак өстендә түбәндәгечә гомуми сәяси-иҗтимагый хәрәкәтләр

---

[1] XIX йөзнең соңгы яртысында татар сәүдә капиталы корольләреннән булган Гани, Әхмәт, Мәхмүд бай Хөсәеновлар татар сәүдә капиталының ничек үсү, киңәю һәм, гомумән, татар буржуазия хәрәкәтенең ничек көчәюе турында чыннан да ачык үрнәк була алалар. Бу материаллар шул ук «Татарлар арасында революция хәрәкәтләре»ндә бар. Шулай ук бу турыда тагын да киңрәк, тулырак материалларны Борһан Шәрәфнең «Гани бай» атлы тарихи әһәмиятле материалларны эченә алып яхшы язылган китабы бирә ала. Һәм Риза казыйның «Әхмәт бай»ы, Батталның «Яушев Вәли» дигән китаплары да кирәкле материалларны бирәләр. *(Авт. иск.)*

[2] Истибдадыннан – деспотизмыннан.

[3] Груһы – төркеме.

[4] Каюм Насыйри мәҗмугасы, 3 бит. *(Авт. иск.)*

кузгалды: руслардагы халыкчылар яисә халыкчы революционерлар – «Халык иреге» партиясе белән Русия монархия һәм түрәчелек патшалыгының нык көрәше барды. Террорлар башланды. Шул партия тарафыннан этисе үтерелгәннән соң тәхеткә утырган Александр III заманында эчке сәясәттә иң каты бер реакционерлык (гакселхәрәкәтчелек[1]) юлы тотылды.

Мәгариф эшләрендә дә бик тупас, куркыныч, бик каты бер рәвештә рус миллият сәясәте йөртелде. Руска башка халыкларны руслаштыру, тәрбия ягыннан начар куелган мәктәпләрне, бигрәк тә татарның кадим мәктәпләрен яклау, авыл мәктәпләре өстеннән гаять каты, кысынкы бер тикшерүләр йөртү кебек хәлләр әнә шушы сәясәтнең җимешләре иде. Менә шундый икътисади-сәяси һәи иҗтимагый шартлар астында рус зыялылары буржуазланып уңлаша башлады. Шул ук вакытта бу хәлнең тәэсире татар дөньясына да ташланды. Авыллар хисабына үскән сәнәгать капитализмының тәрәккыйсе һәм дә шәһәрләрнең үсүләре сәбәпле килеп чыккан шушы хәлләр, ягъни болай буржуазлану шартлары татарларга да нык тәэсир күрсәтте. Рус тәэсире астында калган татар мирзалары, татар байлары һәм аларның балалары да шушы гомуми сызыкка төштеләр. Буржуазлану, яңару аларның иҗтимагый тормышында да үзенең галәмәтләрен ачык күрсәтерлек бер хәлдә булып барды.

Ниһаять, югарыда күрсәтелгәнчә, бөтен тармаклары белән, Русиядәге шушы гомуми һәм хосусый иктисади-сәяси, иҗтимагыймәдәни шартлар астында татар буржуа сыйныфы да ачыктан-ачык аерым бер сыйныф булып дөньяга чыкты. Шуның белән бергә үк татар пролетариат сыйныфының тиздән үсү юллары да ачылып, шуңар зәмин хәзерләнгән булды.

Татар буржуасы көч алып, үз идеологиясенең сызыкларын билгели башлау мәртәбәсенә җиткәч, ул инде үз эчендә реформачылык хәрәкәтләрен сорый башлады. Заманасына муафыйк[2] рәвештә дини-әхлакый, гыйльми-әдәби, мәдәни-иҗтимагый яңалыклар ясый башларга керешүне кирәксенде. Үзен күптәннән басып килгән иске феодализмның, борынгы караңгылыкның үз тормышына аяк чалучы артык кара якларын, каты кысынкылыкларын моннан соң инде бөтене белән күтәреп бара алмаячагын сиздерде. Кыскасы, татар буржуазиясе, инде кара шәрыкчылык, борынгы урта азиячелек

[1] Гакселхәрәкәтчелек – каршылык.
[2] Муафыйк – ярашлы.

белән генә тотынып барып, тормышын яхшы юлда дәвам иттерә алу мөмкин түгеллеген күрде. Шуның белән бергә, бигрәк тә асыл мөселманчылыкны саклаган хәлдә, русча укуны, рус-Яурупа гыйлеменә, Яурупа мәдәниятенә якынлаша баруны һәм дә мөселман-татарчылык рухында яурупалаша башлауны нәүбәткә куярга мәҗбүр булды.

Бер яктан, рус-Яурупа тәэсире белән нык очрашу, капиталистлык юлына кереп китү; икенче яктан да, татарның үз эченнән шуны нык кирәксенүе, шуңа психологик бер хәзерлек ясалып өлгерү татар дөньясында шундый яңалыкларны, шундый иҗтимагый-мәдәни хәрәкәтләрне таләп итте. Кыскасы, «XIX йөзнең соңгы яртысында, бигрәк тә ахыргы чирегендә Русиядә капитализмның көчәюе, моның Урал-Волга буена һөҗүме, нәтиҗәдә, бездәге натураль хуҗалыкның җимерелә башлавы, шәһәрләрдә элекке вак һөнәрнең капиталга каршы җиңелүе; татар сәүдәгәренең ярыш мәйданында руска, яһүдкә, немецка җиңелмәс өчен яңа юллар, дошман коралы белән коралланулар, яурупалашулар лязем[1] икәнен гамәлдә күрү кебек хәлләр»[2] татар дөньясын иске караңгы Көнчыгыш юлыннан Көнбатыш юлына таба өстери башлады.

Матди тормышта, көнкүрештә булган техника-сәнәгать үзгәрешләре фикердә, идеологиядә дә яңаруга таба бару хәрәкәте кузгатты. Телдә дә, гыйлемдә дә, тәрбиядә дә яңару эзләре сизелә башлады. Төрле яңа эзләнүләр туды, әүвәлгеләре баш күтәрде. Электән, XIX йөзнең башларыннан ук башланып та, көч ала алмыйча килгән дини, фәлсәфи эзләнү-тикшерүләр өчен башка яңа куллар аркылы яңадан кузгалып киңәюгә, үсәргә юл ачылды.

Шуның белән бергә, шушы юлдагы хәрәкәтләрнең, эзләнүләрнең баш яктагылары да, ахыр якта булганнары да – һәммәсе дә, гәрчә тыш яктан төрлечә булып күренсәләр дә, эч яктан уртак бер үк төп юнәлеш, бер үк төп мәгънә белән берләшәләр иде. Боларның төп кыйблалары һәммәсенең бер иде, бу юлда эшләүчеләр һәм бу хәрәкәтләрнең юлбашчылары да «төрле җирдән, төрле юл белән бу кәгъбәгә барырга чыккан юлчылар иде».

Идеология дөньясында бу берлекнең, болай бер ноктага таба карап юнәлүнең төп мәгънәсе дә борынгы туң, караңгы, иске шәрыкчылыктан азмы-күпме Көнбатышка, Яурупага таба борылып, шул

---

[1] Лязем – тиеш.

[2] «Безнең юл», 1922 ел, 1 нче сан, 33–34 бит: «Иҗтимагый, әдәби хәрәкәтләр тарихын тикшерүдә марксизм ысулы» мәкаләсе. *(Авт. иск.)*

эз белән тәрәккый итүдән гыйбарәт булды. Икенче төрле әйткәндә, бу хәрәкәтнең идеологиядә төп ноктасы үз игътикадларынча[1], гүя Мөхәммәд һәм аның хәлифәләре заманындагы ислам нигезләре, борынгы ислам мәдәнияте, ислам әхлагы, ислам «өхуәте» (кардәшлеге) белән катыштырып, Яурупа мәдәнияте алу иде.

Шулай ук бу хәрәкәт, асылда төп иҗтимагый-сыйнфый нигезе белән буржуазия хәрәкәте булса да, иске феодализмны, караңгылыкны, схоластиканы җимереп, тормышны яңа адымга, яңа баскычка күчерү, Яурупа гыйлеменең яктылыгына таба әйләнү өчен булганга күрә, милләтнең башка сыйныфлары – эшчеләр, крестьяннар, хезмәт халыклары өчен дә кирәкле, файдалы хәрәкәт иде.

Кыскасы, Яурупадагы XV–XVI йөзләрне, шулай ук руслардагы XVIII йөзнең башларын хәтерләтә торган бу хәрәкәт, мәшһүр бер тәгъбире белән әйтсәк, татар дөньясында кузгалган гомуми бер яңаручылык, уртак реформачылыктан гыйбарәт тарихи бер хәрәкәт булды.

## II
## Реформа тармаклары

### 1. Әдәби тел
### *Гамәли як*

**Төрки тел**. Бөтен икътисади, иҗтимагый сәбәпләр буенча, XVI йөздән XIX йөзнең соңгы ярымынача дәвам иткән татар әдәби теле XIX йөзнең соңгы ярымында тудырылган тел түгел иде. Үзенең аталып, мәшһүр булып килгән тәгъбире белән әйтсәк, ул тел төрки теле иде. Ул, әдәби телнең төп тамыры кыпчак әдәби теле булган хәлдә, болгар, чыгтай, госманлы шивәләрнең сарыфы һәм нәхүе, шулай ук лөгави[2] төзелешләреннән катыш ясалган бер тел булды. XIX йөзнең башларында инде ул тел, Җ. Вәлиди[3] тәгъбиренчә әйтсәк, «буе – чыгтай, аркавы – госманлы» ителеп, шул телләрнең төзелешләреннән сугылган бер тел булып карарлашты.

Соң, болай борынгы татар әдәби теленең «төрки» исеме белән, төрле шивәләрдән катыш бер тел булып китүе ничек булды? Моны ачык аңлау өчен, бик кыска гына булса да, бу урында тарихка кайтып алыйк.

[1] Игътикадларынча – инануларынча.
[2] Лөгави – сүзләр.
[3] Җәмал Вәлиди (Җәмалетдин Җәләлетдин улы Вәлидов, 1887–1932) – тел галиме, тәнкыйтьче, әдәбият тарихчысы, педагог, җәмәгать эшлеклесе.

Татар халкы, икътисади-тарихи сәбәпләр белән XIII йөзнең башларында көнчыгыштан – Монголстаннан көчле бер тарихи дулкын булып күтәрелеп чыгып, көньяк-көнчыгыш һәм көньяк-көнбатышка, ахырдан турыдан-туры көнбатышка, Волга буйларына ябырылдылар. Урал-Волга буйларында алар, электән үк мәдәни булып яшәп килгән Кыпчак (коман-половец), Болгар дәүләтләренә һәм башка төрк җәмгыятьләренә очрап, аларны үз кул асларына алдылар.

Элек Волга тамагында Алтын Урда дәүләтен, соңыннан, ул зәгыйфьләнгәч, аннан аерылып чыгып, Казан дәүләтен (шулай ук Кырым, Нугай дәүләтен) төзеделәр. Татарлар (яисә магул-татарлар), кыпчак, болгар төркләрен сәясәттә үзләренә йотып, аларга «татар» дигән исемне дә гомуми бер исем итеп тагып, шуны сәясәт дөньясында гомумиләштереп җибәрделәр. Ләкин бу сәясәт һәм тарихта гына шулай булып калды. Шул җирләргә шамани булган татарлар килүдән элек, күптән үк андагы җирле төркләр (болгар, кыпчаклар вә башкалар) мөселманлыкны кабул итеп, шаманилыктан аерылган, ислам, гарәп тәэсире астына нык төшеп өлгергәннәр иде инде. Шул сәбәпле алар үзләре өстенә килеп хаким булучы татар халкына, шул ук ислам тәэсире астында, бу яктан начар карадылар. Татарлык исеме астына кермичә, алар һаман үзләрен «төрк» дип атап йөртергә тырыштылар; телләрен дә «татар теле» дип йөртәселәре килмәде: «төрки теле» дип калдырдылар.

Шуның өстенә, икенче яктан, сәясәттә өстен килгән татарлар, мәдәнияттә үзләреннән өстенрәк булган теге төркләр белән бер катышып киткәннән соң, тәмам аларның мәдәни тәэсире астында калдылар. Шулар аркылы ук гарәп, ислам тәэсиренә дә җиңелделәр. Инде татарлар, үзләре дә сизмәстән, әкрен генә, гореф-гадәттә, телдә, язу-әдәбиятта төркләшә башладылар[1]. Шуның өстенә татар язучылары, татар галимнәре үзләренә «Болгари» («Болгарныкы») дигән сөямәт (сөямә ат) куштылар. Һәм, Казан руслар тарафыннан алынганнан соң, үз илләрен дә «безнең Болгар йорты» дип йөртә башладылар, кыпчак, уйгур әдәби телләре, чыгтай әдәбияты тәэсире дә аларны әйләндереп алды. Соңыннан, XVII–XVIII йөздән игътибарән[2], шуларга госманлы тәэсире килеп кушылды.

[1] Бу турыда озын мәгълүмат мөхәррирнең «Кешелек дөньясында тел, әдәбият, язу һәм аларның тарихи үсүләре» дигән әсәрендә (218–230 битләр), шулай ук Г. Рәхим, Г. Гобәйдуллиннарның «Татар әдәбияты тарихы» дигән китапларында (36–37 битләр) бар. Шуларга каралсын. *(Авт. иск.)*

[2] Игътибарән – башлап.

Шулай итеп, Казан дәверендә дә, аннан соң да, XIX йөзнең соңгы ярымынача телдә төркилек хөкем сөрде һәм «төрки теле» дигән исем татар әдәби теленең исеме булып килде.

Ул әдәби телнең исеме генә «төрки» түгел иде. Аның, төбендә[1], әдәби ясалышы ук «төрки» иде. Югарыда әйтелгәнчә, ул сарфи[2] һәм нәхәви[3] төзелешендә, тезмә һәм чәчмә формасында кыпчак + болгар + уйгур + чыгтай + госманлы + бераз татарча телләрнең укмашыннан гыйбарәт бер татар әдәби теле иде.

Мәсьәләне ачык сурәтләндерү өчен, бу урында татарның XVI–XVII йөздән башлап XVIII йөздә һәм XIX йөзнең беренче ярымынача дәвам итеп эшләнеп килгән әдәби теленнән берничә мисал укып үтик.

*Төрки теленнән үрнәкләр*

***«Исмәгыйль ага сәяхәте»ннән[4]***

*(Бу мисал мөхәррирнең үз кулындагы асыл кульязмадан үз имлясы белән гайнән алына)*

«Тарих мең дә йите йөздә илле беренче ел ирде. Урынбурых[5] кашындагы Сәгыйд бистәсенең старшина Сәгыйд заманында, Аллаһы Тәгаләнең тәкъдире шәрифе илә, мулла Нәдер вә Ягъкуб һәм Исмәгыйль мулла, Нәдерның бер кушчысы[6] берлә һәр дүртесене базергянлыкка[7] Сәгыйд агай йибәрде. Бохара тарафына юлландылар. Әүвәл Урынбурыхдин чыккач, казакъ сәмтенә[8] вардык, казакъдин егерме ике көндә Өргәнечкә бардык, анда йите көн калдык, йите көндин соңра Өргәнеч кәрваны илә унике көндә Бохарага ирештек. Анда бер кыш калдык, чук-чук әүлия шөһәдага зиярәт кылдык[9]. Янә Бохарада иркәнемездә[10] артымыздин падишаһның әмере варды илче булып Һиндстана вармага, бәс ул хезмәтне йиренә килтермәк өчен, шөруг идеп[11], Һиндстана юлландык» (2 биттән).

[1] Төбендә – нигездә.
[2] Сарфи – морфологик.
[3] Нәхәви – синтаксик.
[4] Бу әсәр белән тәфсилле танышу өчен 9 нчы сан «Мәгариф»кә каралсын. 1925 ел. *(Авт. иск.)*
[5] Урынбурых – Оренбург.
[6] Кушчысы – юлда озата баручы хезмәтче.
[7] Базергянлыкка – сәүдәгәрлеккә.
[8] Сәмтенә – ягына.
[9] Чук-чук әүлия шөһәдага зиярәт кылдык – күп-күп изге шәһитләрнең каберен зиярәт кылдык.
[10] Иркәнебездә – булган вакытыбызда.
[11] Шөруг идеп – эшне башлап, керешеп.

«Андыйн соңра юлымыз дәрьяга ирешде, кәмәгә ултырдык, ул диңгез – Һиндстан диңгезедер. Ул диңгез илә биш көндин кәзин[1] янә бер шәһәргә ирешдек. Халкы – гарәбләрдер. Шәһәренә Басра дирләр, энҗе-мәрҗән ул шәһәрдә чыгар, диделәр. Анда бер ай калдык. Кәмә булмады, ике айдин кәзин бер тулу каек булдык, ул каекка ултыргач, ике көндин соңра мулла Нәдернең хезмәткәре вафат улды, дүрт адәм калдык, янә андыйн соңра унсигез көндә Бәндәресурәткә ирештек, Һиндстан шәһәредер, шәһәргә йитешемездә юнымыз затдылар суларымыз дөкәнмеш ирде[2], бер кечек каек илә алты адәм су алмага күндерделәр, бер сәгать улынмадин, хәрамиларга[3] раст килеп, куркып дүнделәр[4], чагырып[5] диделәр ки: «Угрылар киләдер, тупларыңызны вә һәм төфәңләреңезне[6] тултырыңыз, гафил улмаңыз», – дәю, илле танә[7] төфәң, дүрт танә туп вар иде. Ярагладылар[8], көннең вакыты ушал вакытта көнәш низә[9] буе калыкмыш ирде. Ардымызга карасак, алты каек һәм тупханәләре илә килүб ирешделәр, унике туплары вар иде, газыйм[10] дүкеш[11] улды, сабахдин ахшамга тигрү[12] вә әүвәлге тупларыны йибәрмешләр ирде. Безләр каек өстендә ятып торыр ирдек, бер туп мулла Нәдернең башына раст килеп, өзеп йибәрде. Без һәм Габдрахман илә бер күбчеккә[13] башымызны куйган ирдек, Габдрахманның һәм карынын ярып, икемезнең башымыз астындагы күбчекне өзеп алып китте. Янә кәмә сахибенең[14] ботын өзде. Мулла Ягъкуб ага бихәбәр[15] ул кәмә сахибен гаҗәбләп тормыш ирде[16]. Бән дидем ки: «Ягъкуб ага, күрсәнә, мулла Нәдер илә Габдеррахманны, бәнем борынларымдин һәм маңлаемдин хун рәван[17], һушым китмеш ирде. Бәңа һәм бөйлә улды», – дәю кәманә вармыш идем, бер замандин соң һушыма килдем, аңладым, Габдрахманның кулының кәсмекләре[18] бәңа уграмыш,

[1] Кәзин – соң.
[2] Дөкәнмеш ирде – беткән иде.
[3] Хәрамиларга – юлбасарларга.
[4] Дүнделәр – борылып кайттылар.
[5] Чагырып – кычкырып.
[6] Төфәңләреңезне – көпшәле ау коралы.
[7] Танә – данә.
[8] Ярагладылар – әзерләделәр.
[9] Низә – сөңге.
[10] Газыйм – көчле.
[11] Дүкеш – сугыш, бәрелеш.
[12] Тигрү – тикле.
[13] Күбчеккә – кечкенә мендәргә.
[14] Сахибенең – *биредә:* йөртүченең.
[15] Бихәбәр – хәбәрсез.
[16] Гаҗәбләп тормыш иде – гаҗәпләнеп карап тора иде.
[17] Хун рәван – кан ага.
[18] Кәсмекләре – кисәкләре.

талуч[1] күнгә тикрү колагым ишетмәде. Үлүкләрне дәрьяга салдык, ул вакытда Бәндәресурәткә дүгешмәгә фәрәнг[2] гаскәре килмеш ирде. Анлары булдык, анларга ике йөз сум акча бирдек, анлар безләрне үз кәмәләренә илтеп багладылар» (3 биттән).

«Андыйн соңра Ягъкуб аганың көндин-көн сырхавы агыр була башлады. Без дидек ки: «Сәнең хәлең күнер, васыять кыйлсаң кирәктер, үләсе булсаң, безләргә бу мал өчен дошман чук[3] улыр, безләрне зиндана куярлар. Бән сиңа дидем ки, мондаг олуг кемсәгә кермәек, үземезчә бер кеше булаек, дидем имди. Әгәр син үлсәң, бу малны бездин алырлар, васыять кыйлсаң, без хәляс улсак[4] кирәк, ушбу безләрнең миһман улган әү сахибе[5] – ул Шам Шәрифнең әфәндесе Дагстан әфәндедер». Ул вакыт Ягъкуб ага диде: «Хуш сүз, дирсән бар, шаһид булгыл ул Шамда үзенең кардәше мулла Мортаза дигән кемсә вар иде. Аны васые мохтар[6] әйләде, безләрне назыйр[7] әйләде, Дагстан әфәндене шаһит әйләделәр. Андыйн янә Шамда өч-дүрт үзбәк вар иде, һәр ни-нәрсә вар исә, аны яздырды. Ошбу Мортаза – карендәшемдер ул малны аңар тәслим итеңез», – диде. Андин соң унбиш көндин кәзин[8] Ягъкуб ага вафат улды. Бәгъдәһе[9] ул әфәнде капуны бикләде һәм мөһер сукты. Ягъкуб аганы дәфен кыйлдыкдин кәзин ике көндин соңра мөһерне боздылар, малны күтәрделәр, әфәнденең өенә илтделәр, Шамның җөмлә олугларны йыгмыш[10], әфәнде бу малны мөддәткә бирде[11], көлле[12] малны сату кылдырды. Икенче көн безләр бардык, сөаль кылдык: «Каны[13] малның акчасын биреңез», – дәю. Анлар җавап бирделәр ки: «Гәвер[14] туфрагыннан чыккан малдыр, сезгә бирелмәз», – диделәр. Андыйн кәзин безләр мәхрүм улып, нәүмиз улып кайтдык. Моның бәгъдендә[15] һичбер тарикъ[16] илә сөаль кылыр йиремез калмады. Янә берничә замандин соң үземезгә һәм бер гыйлләт[17] белгерде шөйлә кем һәр адәмигә

[1] Талуч – алдагы.
[2] Фәрәнг – европалы.
[3] Чук – күп.
[4] Хәляс улсак – котылсак.
[5] Әү сахибе – өй хуҗасы.
[6] Васые мохтар – баш душеприказчик.
[7] Назыйр – күзәтүче.
[8] Кәзин – соң.
[9] Бәгъдәһе – аннан соң.
[10] Йыгмыш – җыйган.
[11] Мөддәткә бирде – процентка бирде.
[12] Көлле – барлык.
[13] Каны – кайда.
[14] Гәвер – кяфер.
[15] Моның бәгъдендә – моннан соң.
[16] Тарикъ – юл.
[17] Гыйлләт – чир, авыру.

бер шеш чыкыюр, һичбер кемсә терелмәз, безгә һәм шул зәхмәт пәйда улып, кәфенләремезне хәзерләдек.

Бәс, тукыз көн булган ирде, шешемез ярылды һәм, лиллаһил-хәмед[1], сыйххәт улдык[2]. Янә андыйн кәзин мулла Мортазаның углына ваба гыйлләте белгерде, өч көндин кәзин вафат улды. Янә бер кызына тигде. Ул һәм үлде. Янә дүрт көндин соң мулла Мортаза һәм вафат улды. Янә биш көндин соң хатыны үлде. Безләр ялгыз калдык» (25 биттән).

*Хәлфиннән*

## ***Мөкәддимә***

Рус, нәмчә вә ләһ вә бәгъзе халаек улынсыннар ки кәнделәренең тәварихларында кадими Дәште Кыпчак вә Болгар, Кырым вә Казан ханлары вә халаекыны вә анларның вә дияры русигә хоруҗ идеп, бәгъзе хәребләрене вә нитәк хөкүмәтләрене вә һәм халаекы рус үзәренә салдыклары җизьяләрене улынсын вә анларның кәнде мабәенләрендә улынмыш бәгъзе әхвәле бу китапчыкдик ничә вә ничә хәвашиләр илә бу замана тигрү вә китабәт идә килмешләрдер. Ләкин дөрлү тәфавет вә бере-беренең кәлямене җәрех итмәклә бәгъзе хан мәкян, шәһәр вә кальга исемнәре вә бөньядлары вә тарихлары мөбһәм калып, кәмаль мәртәбәйә ирешмәмеш исә дә, әлбәттә, шимдеке заман шәһре Болгар вә гайреләрдә йир алтларыдин табылып, вә һәм бәгъзе мәкянләрдә сакланмыш мәгъдәни затлар вә шөйлә алтын-көмеш вә бакыр акчалар да күрелән хан вә шәһәр исемнәрене мөфәттишләр тәфтиш әйләдекләредә анлардин бәгъзеләрене сорап вә мөкәммәл итсәләр кирәкдер.

Анчак ошал китапчыкның таснифе кадим вә тәләффызлары себер татарынча кеби улып, бәгъзе мәхәлләре дәхи бу замандагы әһле тәварихлара мәкъбүл нәтиҗәләр имәз исәләр дә, имамыз бу китапчыкның 47 нче сәхифәсендәге тасвир улынан (Чыңгыз хан кәнде заманасыда бәкләренең һәрберенә союргаб тәгаенләю вирдеке) тамга вә кош кеби галәмәтләренең бәгъзесе йир алтындан чыкмыш акчаларның чугында күреләләр. Өйлә исә бу китапчыкның янә бер асылы улынып (ягъни, Казан татарларыдин кадими әхвәл вә хәвадисаты тәфсилән китабәт әйләдекләре (тәварихлар улынмадыкы лябөдди улынып), әмма ул тәварихлар шул замандагы ханларның рус халаекы илә хәрб-ү кыйталь вә тәхрикъ кеби һәрдөрлү мәмләкәтләредин заигъ (улып) Казанда вә этрафларында улан (булган) карья вә илләредә һичбере калмаган вә бу китабдин гайресе һәргиз монда күрелмәз анча надир бәлкем калмыш улынсалар да, Тубыл вә Өфе вә Каргалы вә Җаек халаеклары араларында улынмакла-

[1] Лиллаһил-хәмед – Аллага шөкер.
[2] Сыйххәт улдык – авырудан терелдек.

ры галибе занн улыныр. Зира бундан әкъдәм шөйлә Әбелгазый Баһадир ханның «Шәҗәрәи төрки» димәклә иштиһар әйләдеге төрки тәварихы Себер тарафларыда булынып, рус вә гайре лисанлара тәрҗемә улынмакла вә һәркайда русча басмасы чукдыр вә эчендә хәзрәте Адәме Сафиулладан та мәзкүр Әбелгазый Баһадир хан Харәзмигадик җамигъ татар вә магул ханларының нәселләрене вә хөкүмәтләрене, хосусан Чыңгыз ханның вөҗүдә кәлеп вафатыгача әхвале мөлек вә шөгабьләрене тәмам тәртипләрилә зикер идәр. Әмма ошал китабның асыл төркисе дәхи бу дияры Казанда һичкайда вә һичкемдә күрелмәеп вә һәргиз булынмас.

*Әбелмәнихтән*

***«Тәрҗемәи хаҗи Әбелмәних әл-Бистәви»***

*(«Хикәяте хамис[1]»тән 27 биттә. Китапның басылуы 1840 миладида)*

Торды дәрвиш, варды өенә рәван,
Дирде: «Һәб искичәләре һәман».
Сатубан базара ул мәрде Ходай,
Сатуб алды акчасилә ук-йай.
Варды, дотды дәхи Дәрбәнднең юлын,
Күзә дорды түрт яңа, саг вә сулын.
Чыка кәлде бернәчә хәрамиләр,
Нәчә еллар үлтерән адәмиләр.
Диделәр, күреб аны: «Нә кеше сән,
Канкы кәсеб идәченең юлдашы сән?»
Дидикем: «Угрымын, и кардәшләр,
Юл күзәдерәм, дүкәрәм яшьләр.
Бер кулай адәм кәлүрсә, нагяһан,
Суерам һич вирмәеб аңа әман».
Турук дәрвишләрдә улмаз һич ялан,
Тугрысыны диде бонлара һәман.
Диделәр: «Без дәхи сәңа ярымсыз,
Угрылык һәр дәмдә кәсбү кяремез.
Бер бүлек тажир кәлүрләр, хазыйр ул, –
Диделәр, – сән бер тарафда назыйр ул.
Күстәрәчәк вакыт ирер имди һөнәр,
Күрәлем имди һөнәрең нә кадәр».
Җөмләләре бер тарафда тордылар.
Кәлдүге дәм битәвәккыф ордылар.
Дотдылар, багладылар һәм әлләрен,
Бер йирә җәмгъ итделәр һәб малларын.

[1] Хамис – бишенче.

Бер-беридән аерубан анлары,
Китделәр алыб дүкәргә канлары[1].

*Шәмсетдин Зәкидән*

И дәрига! Тәкать, сабырым-карарым калмады,
Изтыйрара[2] дөшмешем чөн ихтыярым калмады.
Дөшде гамь гәрдабына[3] шимди вөҗүдем кимәсе[4],
Шөйлә батдым кем, мәтагым[5], рәхет парәм калмады[6].
Касд идәрем җаныма чөн сусамышым каныма,
Варлыгыма илтифат, игътибарым калмады.
Ошбу нәфесем афәтендән гәр хәлас итсәң[7] бәни,
Үзгә куркулардан асла зинһарым калмады.
Җәнг кылыб[8], нәфсеме үлдерсәм сәңа вармак өчен,
Гайре дошман илә һәргиз кяр-зарым калмады.
Күңелем үлмешдер, кәрам кыл нәфсеме белдер бәңа,
Та сәне беләм ки, сәндан гайре ярым калмады.
Акызыб күз яшеме, дәргяһә сөрсәм башымы,
Дәм-бәдәм сәңа ялынсам, үзгә кярем калмады.

*Һибәтулладан*

Буның тәмсиленә[9] бән бер хикәят
Бәян идәм, ишет сән, кыйл дираять[10].

---

[1] Торды дәрвиш, өенә тиз генә кайтып китте / «Иске-москыларны тиз генә җыегыз», – диде. / Сату белән базарда ул Хода бәндәсе, / Сатып алды акчасына ук һәм җәя. / Барды, тарлавыктагы юлга чыкты, / Күзәтеп тора дүрт ягын, уң һәм сулын. / Килеп чыкты берничә юлбасар / Ничә еллар [буе] кеше үтереп йөргәннәр. / Әйтteләр, аны күреп: «Нинди кеше син, Ни белән кәсеп итүченең юлдашы син?» / Диде: «Угры мин, и кардәшләр, Юл күзәтәм, кисәмен башлар: / Бер кулай адәм килеп чыкса кинәт, / Суярмын һич бирмичә аңа иминлек». / Төрки дәрвишләр арасында булмас һич ялган, / Турысын әйтте боларга ул һаман. / Тегеләр әйтте: «Без дә бит сиңа иптәш, Караклык – һәрвакыт кәсебебез һәм шөгылебез. / Бер төркем сәүдәгәрләр килә, хәзер бул, – / Диделәр, – син бер якта күзәтеп тор. / Инде һөнәр күрсәтер вакыт җитте, / Күрик әле, һөнәрең ни дәрәҗә икән». / Барысы да бер якта [качып] тордылар, / [Тегеләр] килеп җитүгә, кинәт ташландылар. / Тоттылар, бәйләделәр кулларын, / Бер җиргә өеп куйдылар барлык малларын. / Бер-береннән аерып аларны, / Киттеләр алып түгәргә каннарын.

[2] Изтыйрара – чарачызлыкка.

3 Гәрдабына – упкынына.

[4] Кимәсе – көймәсе.

[5] Мәтагым – малым.

[6] Рәхет парәм калмады – *биредә:* бер әйберем калмады.

[7] Хәлас итсәң – коткарсыз.

[8] Җәнг кылыб – сугышып.

[9] Буның тәмсиленә – моңа охшатып.

[10] Дираять – зирәклек.

Будыр чыкмыш ике ахмак сәфәргә
Ирешмешләр мәкяне пөр-хәтәргә[1],
У йирдә[2] бәс кылай дип истирахәт,
Бере дир: «Бән торыйм, сән борын[3] ят.
Бәс андин сән торурсән, бән ятаем,
Чө[4] дошман кәлсә, канинә батаем».
Бере ятды, бере саклап утырды,
Назар кылды[5] бә-нагяһ[6] аны күрде.
Кәлә йөрер[7] якында бер еланы,
Чагарга сахибене ул ниһани[8],
Күреб аны көтеб торды, йирендә,
Чакармы яки чакмазмы дир анда.
Идәрме аны дошманлык күрермен,
Әгәр чакса, аны бән үлтерермен.
Әгәр чакмаз исә, нәдер гөнаһы,
Китәрсә котлы улсын аңа раһы[9].
Елан ул дәм[10], якын кәлде йитешде,
Чакам дидекдә, күзе буңа төшде.
Диюр: «Чаксам бу дәм юлдашы назыйр
Һәлак идәр мәне ул монда хазир», –
Диеп, дәрхаль кире китде юлына
Нәзар һич итмәеб саг-сулына[11].
Утырыб калды ул ахмак бәс анда,
Бә-нагяһ күзе төшде бер заманда.
Оер[12] юлдашының анда йөзене,
Чебен басмыш тәмам ике күзене.
Газап тотды чебеннәрнең эшегә,
Гаҗәп дошман имешдер бу кешегә.
Кулымда булмады гөрзем[13] буңа, кяш[14],
Торып әленә алды бер олуг таш.

[1] Мәкяне пөр-хәтәргә – хәтәр тулы урынга.
[2] У йирдә – ул җирдә.
[3] Борын – башта.
[4] Чө – әгәр.
[5] Назар кылды – бакты, карады.
[6] Бә-нагяһ – кинәт.
[7] Кәлә йөрер – якынлаша.
[8] Ниһани – яшерен генә, мыштым гына.
[9] Раһы – юлы.
[10] Ул дәм – ул вакыт.
[11] Саг-сулына – уңына, сулына.
[12] Оер – йоклаган.
[13] Гөрзем – чукмарым.
[14] Кяш – кызганычка каршы.

Кәлүбән[1] орды тугры ул күзенә,
Күзе бәс әйләнеп чыкды йөзенә.
Йиреннән сачраеб[2] торды у мескен,
Ачыгындин[3] әленә алды сиккин[4].
Басып ике аякы берлә йөзен,
Уеб чыкарды аның ике күзен.
Үзе дәрхаль үенә[5] кайтыб ирде,
Үендә тормады, казыйә варды[6].

Менә XIX йөзнең икенче ярымынача булган татар әдәби теленең хәле шундый иде.

**Төркчелектән татарчылыкка.** Аннан соң инде татар әдәбиятында әдәби тел мәсьәләсендә яңа бер юл башланды. Инде татар әдәби теле борынгы төркилектән чыгып, хәзерге мәгънәсе белән татар теле булу юлын алды. Бу да татар сәүдә капиталының һәм татар халкының телдә дә яңаруга, садәләшүгә таба омтылуының нәтиҗәсе булды. Татар сәүдә капиталы өчен эчке базар, татар-башкорт базары әһәмиятләнә башлады. Шул сәбәпле татар сәүдә капиталының инде, татар крестьян массасы белән дә уңышлырак эш итү өчен, тик рухани феодаллар арасында гына түгел, бәлки бөтен татар халкы – гавам арасында да җиңел аңлашыла торган бер язу теле – әдәби тел тудырылуны теләве бик табигый бер хәл иде. Иске феодализмнан аерылу юлына кергән, буржуазлана һәм икътисади, иҗтимагый тормышында яурупалаша башлаган татар халкының бу беренче мәдәни кирәге һәм бу аның алдына килеп баскан беренче әдәби тәрәккый баскычы иде. Менә шушы кирәкне, шушы беренче тәрәккый адымын башлауның вакыты җиткәнен XIX йөзнең соңгы ярымындагы реформачы татар әдипләре нык сизеп, шул юлда нык эшкә керештеләр. Хәзерге мәгънәсе белән чын татар әдәби теле тудыру хәрәкәте кузгалды.

**Татарчылык хәрәкәте һәм Каюм Насыйри.** Бу юлда татар дөньясында беренче төпле гомуми баш хәрәкәт тә Каюм Насыйри белән башланды. «Каюм баба борынгы әдәби төрки теленнән ерып чыгып, яңа әдәби татар теленә башлап юл ачты»[7].

---

[1] Кәлүбән – килеп.
[2] Сачраеб – чәчрәп.
[3] Ачыгындин – ачуыннан.
[4] Сиккин – пычак.
[5] Үенә – өенә.
[6] «Мәҗмәгъ әл-әдәп», 15 бит (1868 дә басылган). *(Авт. иск.)*
[7] Галимҗан Ибраһимов. «Имля, тел, әдәбият мәсьәләләре» (122 бит) һәм «Татарлар арасында революция хәрәкәте» (223 бит). *(Авт. иск.)*

Каюм Насыйриның тәрҗемәи хәле: ул сәүдәгәр һәм руханилар нәселеннән булып[1], 1824 ел дөньяга килә. Вафаты 1902 елда. Әүвәл атасыннан укып, соңра Казан мәдрәсәләреннән берсендә (Әхмәд хәзрәт мәдрәсәсендә) тәхсил күрә[2]. Анда дини белемнәр өстенә гарәп һәм фарсы телләре өйрәнә. Шуның өстенә шул мәдрәсәдә чагында ук яшерен рәвештә русча укырга тотына. Татар буржуазиясе арасында сәүдә эшләре өчен дип русча өйрәнүнең кирәклеге аның әтиләре заманында ук нык сизелгән, һәм аның әтисе үзе ук русчаны, аның язуын әзме-күпме өйрәнеп алырга мәҗбүр булган иде. Каюм исә шул телне татарның яңаруы, яңа мәдәни хәрәкәте, аны яңа гыйлем дөньясына тартып чыгару өчен беренче корал икәнен аңлаучыларның да беренчеләреннән, юлбашчыларыннан булды. Насыйри, 1850 елда башлангыч дини рус мәктәпләрендә (Духовный училищеда), шулай ук Духовный семинариядә татар телен укытырга чакырылып, рус гыйлем дөньясына барып керә. Һәм мәшһүр Радлов[3] кебек галим, Яурупа тюркологлары белән якыннан таныша башлый. Соңыннан, 1873 елда татарлар өчен ачылган Учительский школа янындагы (бу школа 1872 елда ачыла) рус-татар башлангыч мәктәбенә рус теле укытучысы, ягъни татарлар арасыннан чыккан беренче учитель булып хезмәткә керешә; татар балаларына русча укыта башлый.

Шуның өстенә, үз фатирына җыйнап, мәдрәсә шәкертләрен русча укыта. Менә шулай итеп, Насыйри, рус дөньясы аркылы үзе яурупалашу белән бергә, татар балаларына, татар мәдрәсә шәкертләренә дә рус һәм татар теле аркылы Яурупа белемнәрен биреп, аларны Яурупа методы белән тәрбияли башлый.

Ниһаять Насыйри, Казан университетында сәмигъ[4] булып йөреп, үзенә югары мәгълүмат казана һәм шул ук университет янындагы

[1] К. Насыйриның әтисе русчадан мәгълүматлы бер сәүдәгәр (читкә йөреп һәм Мәкәрҗә ярминкәсенә йөреп сәүдә итә) һәм шуның белән бергә «җәмәгать хадиме» бер мулла булган кебек, Насыйриның туган агасы Габделхәй дә – Мәскәүдә торып, сабын һәм шәм эшләп, шуларны Русиядәге күп ярминкәләрдә сатып йөргән һәм соңра, шулай итеп, зур сәүдә ясаган, бик баеган, зур капитал иясе. (Ул соңыннан Казанга кайтып тора башлый.) Насыйриның энесе Габделгани дә – Себергә барып, алтын юган, ниһаять, үзенә бер прииска алган бер кеше. (Насыйриның тәфсилле тәрҗемәи хәле турында «Каюм Насыйри» мәҗмугасында Г. Рәхим мәкаләсенә каралсын. 18–76 бит). *(Авт. иск.)*

[2] Тәхсил күрә – гыйлем ала.

[3] Василий Васильевич Радлов (Фридрих Вильгельм Радлов, 1837–1918) – күренекле шәркыятчы галим һәм тюрколог, этнограф, археолог, төрки телләрне һәм халыкларны чагыштырма-тарихи планда өйрәнә башлаучыларның беренчеләреннән.

[4] Сәмигъ – тыңлаучы.

Археология җәмгыятенә[1] хакыйкый әгъза булып сайланып (1885 ел), чынлап та, Яурупа фән мохитенә кереп китә.

Шул рәвешчә, Яурупа белемнәре казанып, ми-фикере яурупалашкан Насыйри 1859 елда үзенең беренче мөхәррирлек адымнарын башлый. Шул вакыттан алып үлгәнче, 42 еллык гомерен татар телендә китаплар язу эшенә багышлый. Төн-көн шул юлда тырыша, казына, эзләнә. Татар телен һәм аның халык әдәбиятын, мифологиясен нык тикшерүгә тотына. Татар теленең грамматикасыннан, лөгатеннән, бәлягатеннән (әдәбият нәзариясенең өслүб бүлеменнән), татарлар өчен рус теленең грамматикасы һәм рус лөгатеннән, риязият[2], табигыят[3], тарих, җәгърафия, саулыкны саклау, анатомия-физиология, педагогия кебек фәннәрдән татар телендә оригиналь әсәрләр яза. Шуның белән бергә, татар теленә гарәпчә, төрекчә, русчадан тәрҗемәләр ясый. Шулай ук үзенең гыйльми мәкаләләре белән рус матбугат дөньясына чыга. Шулай итеп, анда да татар буржуазиясенең уяну тавышларын бирә. Татарча гәзит чыгарырга йөреп тә[4], рөхсәт ала алмавы сәбәбеннән ул эшне булдырып чыгара алмаса да, ул, ахырда, вакытында татарлар өчен һәм гәзит һәм журнал урынын тоткан үзенең «Календарь»ен чыгара башлый. Шуның ахырына кушып, үзенең төрле фәнни мәкалә һәм брошюраларын тарата[5].

Татар халкының беренче яурупеист һәм энциклопедист идеологы булган Каюмгача татар дөньясында хәзерге мәгънәсе белән татар телен тудыручы, аны татар теле дип күтәреп чыгып, шул турыда

[1] Казан университеты каршындагы «Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте» 1878 елда оеша һәм 1931 елга кадәр эшләп килә. Җәмгыятьнең максаты – «элеккеге Болгар-Хәзәр һәм Казан-Әстерхан патшалыклары җирлегендәге рус һәм башка халыкларның үткәнен һәм бүгенгесен өйрәнү». 1897 һәм 1917 елларда Уставка өйрәнү өлкәсен киңәйтүне күздә тоткан төзәтмәләр кертелә: Себер һәм Урта Азия территорияләрен өйрәнү, гомуми тарих мәсьәләләре өстәлә. Шул ук вакытта төп максаты булып, Казан төбәген һәм Көнчыгыш Россияне өйрәнү мәсьәләләре кала.

[2] Риязият – математика.

[3] Табигыят – табигать турындагы фән.

[4] 1871 елда чыга башлаган беренче елгы календаренда ул: «Бу календарь шаять 72 нче елга һәм чыкса кирәк. Аллаһы Тәгалә әҗәлгә мөһләт *(кичектерү)* бирсә, моңа охшаш дәхи татар телендә гәзит бастырырга ният бар. Ләкин халыкның рәгъбәте *(теләге, кызыксынуы)* ничек булыр. Укырга зәвыкланып, кул куючылар табылса, тәмам хәзерләнеп җиткәч, ул гәзит чыгар алдыннан мәгълүм ителер иде», – дип игълан итә. *(Авт. иск.)*

[5] Аның бөтен гомерендә язган әсәре (календареннан башка) 40 булып, барысы 4 мең биттән арта, әмма шуларга 1228 битләр чамасында булган календарьларын да кушсак (календаре 1871 елда чыга башлап, 1897 елгача һәр ел чыгып, тик 1886, [18]95, [18]97 елларда гына чыга алмый кала. 24 ел дәвам итеп килә), аның бөтен язганы биш мең ике йөз егерме сигез битләр чамасында була. *(Авт. иск.)*

юл яручы да юк иде. Менә шул зур эшне [18]60 еллардан ук Каюм Насыйри башлады. «Борынгыдан килгән төрки телебез бөтенләй чыгтай тәэсирендә барып, яртыдан күбе гарәпчә, фарсыча сүзләр белән тулы булганга, халык һичбернәрсә аңламый иде. Насыйри, башлап, менә шуңар сугыш ачкан, татарчылык нигезендә телне җиңеләйтү юлында тырышкан»[1] беренче каһарман булды. Гәрчә Хөсәен Фәезхани[2] «Насыйри белән Мәрҗанигә караганда сулрак» булса да, ул Каюм Насыйри шикелле татар халкы, татар теле дип күтәрелеп чыгуга, ул вакытта бу суллыкны эшләүгә батырчылык итә алмаган иде. Әнә шул зур батырлык, шушы иң читен тарихи бер хезмәтне без беренче мәртәбә Насыйрида күрдек.

Ул ачыктан-ачык иң әүвәл үз халкын – «татар халкы», телне дә «татар теле» дип шаулатып күтәреп чыгучы һәм Фәезханның остазы Мәрҗани «Лисане төрки мин әкъсарил-әлсинә вә әбгадиһа ган истыйлахатил-голум»»[3] дип, төрк-татар теленең ярлылыгын ачыктан-ачык сөйләп торган вакытта, татар теленең башка телләрдән бер дә ким түгел, бәлки артык яклары булганын кычкыручы, шуны дәлилләр белән исбат итүче булды. Ул үзенең «Кавагыйде китабәт»е[4] аркылы 1892 елда ук матбугатка: «Безләр – татармыз; үземезгә кирәк сүзләрне, тапсак, гарәбтән алабыз, тапсак, фарсыдан аламыз, тапсак, төректән аламыз, ләкин үз телемезнең нәхү кагыйдәсенә саламыз, үземезгә йитәрлек нәхүемез бар!»[5] – дип, уртага татарлык тимер казыгын ныгытып утыртып куйды. Ул безне гарәп,

[1] Галимҗан Ибраһимов. «Татарлар арасында революция хәрәкәтләре», 223 б. *(Авт. иск.)*

[2] Фәезхан Хөсәен улы Фәезханов (1823–1866) – тарихчы, филолог, педагог. Ш. Мәрҗанинең укучысы. 1840 еллар ахырыннан Казан университетының шәркыятчы галимнәре И.Н. Березин, А.К. Казимбәк, 1854 елдан академик Б.А. Дорн, В.В. Вельяминов-Зернов, М.И. Броссе, А.А. Куник (С.-Петербург) белән хезмәттәшлек итә. Гарәп кулъязмаларын, татар халкы, Казан һәм Кырым ханлыклары тарихы буенча материаллар җыю һәм тасвирлау белән шөгыльләнә, беренчеләрдән булып татарларның килеп чыгышы мәсьәләсе буенча тикшеренүләргә керешә. Х. Фәезханов – мөселман мәгарифен реформалау проекты авторы: «Ислах әл-мәдәррис» («Мәктәп реформасы», 1862) хезмәтендә татар мәгърифәтчеләреннән беренче булып Европа мәгарифе алымнарын татар мәгариф системасына кертү зарурлыгы турында нәтиҗә ясый, дин нигезләрен дөньяви фәннәр белән бергә укытуны тәкъдим итә.

[3] «Мөстәфад әл-әхбар», икенче бүлем, 46 бит («Төрк теле – телләрнең дә иң ярлысы, җитешсез һәм гыйльми атамалардан ерак булганы» дигән сүз). *(Авт. иск.)*

[4] Сүз К. Насыйриның фонетика һәм грамматика буенча «Кавагыйде китабәт, ягъни тасниф вә имля кагыйдәләрен бәян кыйлучы бер яңа фәндер» (1892) дигән хезмәте турында бара.

[5] Кавагыйде китабәт, 5 бит. *(Авт. иск.)*

фарсы теле әсирлегеннән коткару өчен көрәшкә чыкты. Бигрәк тә «борынгы хаким-диктатор гарәпчәдән татарга әйләнүдә Насыйри бездә беренче ачык кискен революционер» булды[1].

Кыскасы, ул үзенәчә булмаган бер әдәби тел тудырып бирде. Ул иң әүвәл татарларга үзләренең бер телләре бар икәнен белдертү өчен «Ләһҗә»[2] вә «Фәвакиһ әл-җөләса»[3] тәэлиф итүче[4] вә ул ук, иң әүвәл әсәрләрен татарча яза башлап, һәр язу таныган кеше өчен истифадә итәрлек[5] тарыз[6] да ясаучы»[7] булды.

«Кавагыйде китабәт»еннән соң, ул шушы ике әсәрендә ачыктан-ачык түбәндәге фикерләрне язды һәм шуларны гамәлгә ашырды:

I. «Имди телемезне игътибар кыйлыб, яхшы тәфтиш итеб карасак, мәгълүмдер ки: телемездә булган әбъят вә әшгар вә мәкаләт вә могаммат, ягъни әлфаз гаять мәүзүн вә мөсәҗҗәгъ тәсниф кыйлынадыр. Вә гарәб вә фарсы әлфазының иганәте белән бәлягатьтә вә ифадәи мәгънәдә гайре телләрдән ким түгелдер. Бәлки бәгъзе хосусда хасияте күбрәк булган урыннары һәм бардыр. Хосусан, фигыль бабында. Ләкин бары шул кадәресе бардыр ки: бер дә кузгалмыйча утырып калмышдыр. Хәлбуки, заманымызда гайре әҗнасеннән булган халыкның гарызы тел төзәтмәк вә тел ислах кыйлмакдыр[8].

II. Татар теле мөстәкыйль бер тел булса, әлбәттә, үзенә махсус кавагыйде нәхвиясе бардыр. Вә кәзалик рәсем, хат, бәян, мәсаил – нәхвиянең фөругате булмак хасиятендән гаять игътибар кылыначак шәйдер. Ләкин буны фәһем итәр кеше кем бар? Әмма өмиддер

[1] Галимҗан Ибраһимов. «Каюм Насыйри мәҗмугасы», 11 бит. *(Авт. иск.)*

[2] Сүз К. Насыйри тарафыннан төзелгән ике томлык «Ләһҗәи татар» (1895–1896) – татар теленең беренче аңлатмалы сүзлеге турында бара.

[3] Сүз К. Насыйриның «Фәвакиһ әл-җөләса фи әл-әдәбият» («Әдәбият турындагы мәҗлесләрнең җимешләре») (1884) хезмәте турында бара. Кеше акылына, фәнгә, этика, тел мәсьәләләренә, фольклор, әдәбият, музыкага һәм башкаларга багышланып, 40 бүлектән торган һәм, асылда, беренче татар энциклопедиясе дип аталырлык әлеге фундаменталь хезмәт татар тарихында зур яңалык була.

[4] Тәэлиф итүче – төзүче.

[5] Истифадә итәрлек – файдаланырлык.

[6] Тарыз – үрнәк.

[7] «Әл-Ислах». 1908 ел. 47 сан. Ф. Әмирхан. *(Авт. иск.)*

[8] Инде телемезне игътибар белән яхшылап тикшереп карасак, шул мәгълүм булыр: телемездә булган шигырьләр һәм мәкальләр һәм табышмаклар, ягъни сүзләр гаять ритмик һәм рифмалы тезеләдер. Гарәп һәм фарсы сүзләренең ярдәме белән, ул сөйләм төзеклеге һәм мәгънәне аңлатып бирү ягыннан башка телләрдән ким түгел. Бәлки аерым очракларда үзенә генә хас үзенчәлекләре дә бар. Аерым алганда, фигыльләрдә. Хәлбуки, заманыбызда башка нәселдән булган халыкның максаты – тел төзәтү һәм тел яңартудыр.

ки: бу кыйтгада бер данишмәнд вөҗүдкә кадим басып, ушбу өслүб үзрә әүкатын сарыф итеп, бу дәрәҗәгә итсә, мөәллифнең дә бәһасен фәһем итәр. Гәһа бәгъзе әрбабе гыйнаддан ишетерсең ки, татар телен телгә хисапламаслар. Сөбханаллаһил-Газыйм, хәтта гыйлем тәварих белмәгәнлекләрендән наши, татар ләфызын тәхмил кыйлмага тәкатьләре юкдыр»[1].

Татар вә магул кадим заманда икесе ике кавем вә телләре дәхи ике төрле тел иде. Озак заманлардан бирле бер-беренә катыша-катыша, халән[2] мәшһүррәге татар теле дип калмышдыр. Ләкин мәзкүр тарихтан та[3] бу заманамызга кадәр татар телемезгә хезмәтчеләр була килмәгәнлек сәбәпле, татар телемез артта, гаять бәгыйд[4] йоклаб калмышдыр. Әмма татар телемезгә хезмәтче мин булаем дип, утыз биш ел уздырдым. Ләкин күп мәгънә чыкмады. Төн-көн никадәр иҗтиһад кылсам, шулкадәр җәфа чикдем. Милләтемез халкын «татар» тәсмия кылсам[5], яратмадылар. «Татар теле», дисәм, яратмадылар» («Ләһҗәи татар», 3 бит, 1895 ел басылган).

Ул үзенең югарыдагы әсәрендә:

1. «Безләр татармыз» дип кырт кисеп, халкыбызны «татар» иттереп күтәреп, мәйданга чыга. Телебезне «татар теле» дип атый һәм аны «мөстәкыйль бер тел» дип дәгъва кыла: үзебезгә җитәрлек нәхүебез бар, чит сүзләрне дә «телебезнең үз нәхү кагыйдәсенә салабыз. Аның үзенең нәхү кагыйдәләре, имлясы бар», ди. Ләкин моны аңлый торган кем бар соң бездә? дип кайгыра, кайсыбер тискәре кешеләрнең (әрбабе гыйнадның) татар телен телгә исәпләмәүләрен һәм үзләрен татар дип атауны күтәрә алмауларын наданлыкларыннан, тарих белмәүләреннән саный.

2. Телебездә бәетләр, шигырьләр, мәкальләр, табышмаклар, такмаклар бик вәзенле[6], гармонияле, ди.

---

[1] «Фәвакиһ әл-җөләса», 593–594 бит, 1884 елда басылган. *(Авт. иск.)*

Татар теле мөстәкыйль тел булса, әлбәттә, үзенең махсус грамматик кагыйдәләре бардыр. Һәм шулай ук орфография – грамматик мәсьәләләрнең бер тармагы буларак, гаять игътибарга алынырга тиешле әйбер. Әмма моны аңлаучы кем бар? Әмма өметләнәм ки: җирдә бер галим дөньяга килеп, бу өлкәдә вакытын сарыф итеп, бу дәрәҗәгә җитсә, төзүченең дә бәясен аңлар. Кайчак тискәреләрдән татар телен телгә санамауларын ишетерсең. Сөбханаллаһил-Газыйм, хәтта тарих фәнен белмәгәнлекләреннән, татар сүзен күтәрергә теләкләре юк.

[2] Халән – хәзер.

[3] Мәзкүр тарихтан та – ерак тарихтан башлап.

[4] Бәгыйд – ерак.

[5] Тәсмия кылсам – атасам.

[6] Вәзенле – ритмлы.

3. Кирәк урыннарда гарәпчә һәм фарсыча сүзләрнең ярдәме белән бәлягатьтә һәм мәгънәне аңлатуда башка телләрдән бер дә ким түгел, ди.

4. Кайсыбер нокталарда, мәсәлән, фигыльләрдә башка телләрдән артык бай булган бер тел, ди.

5. Телебез, озак заманнардан башлап хәзергәчә үзен эшләүчеләр була килмәгәнлектән, эшләнмичә артта, бик артта, йоклап, бер дә кузгалмыйча утырып калган; шуның өчен аны уятырга, эшләргә, төзәтергә кирәк, ди. Моның өчен дә башка халыклардан гыйбрәт алырга чакыра: алар «тел төзәтмәк, тел ислах кыйлмак» теләгендәдер, бер дә булмаса, шуннан үрнәк алырга кирәк, ди.

6. Утыз биш елдан, ягъни [18]60 елдан бирле (чөнки ул бу сүзне 1895 елда әйтә), татар телебезгә хезмәтче булыйм дип, көн-төн бертуктаусыз никадәр тырышсам, шулкадәр дә шушы халыктан җәфа күрдем. Халыкның үзен «татар» диюемне дә, телен «татар теле» диюемне дә яратмадылар, ди.

Менә бу сүзләр, бу фикерләр – вакытында татар дөньясында да иң ят, иң яңа сүзләр, үзләрен гамәлгә ашыру бик кыен булган бер фикерләр иде. Шундый бер вакытта калкып килеп чыга да ул, «татар халкы, татар милләте» дип атый. Бу ноктада аңарчы әдәби тел хакында һичкем тарафыннан кузгатылмаган бер нәрсә иде. Насыйри боларны аңлап, кирәксенеп кузгата да, «шул юлда бер хезмәтче булам» дип, 35–40 еллар эшли, «камил сафлык бөтен көенчә булмаса да, шул татарчылыкка, сафлыкка, гавамлыкка баруны төп нигез итеп алганлык аның сүзендә генә түгел, бөтен әсәрендә күренә»[1].

Кыскасы, Каюм Насыйри каләме аркылы татар дөньясында хәзерге мәгънәсе белән булган татар әдәби теле дөньяга туып чыгып, үзенең аерым бер тел икәнен күрсәтте. Тагын да ачык иттереп әйткәндә, Насыйри татар әдәби телен генә түгел, бәлки шуның белән бергә яңа татар әдәбиятын тудыручы беренче татар әдибе булды[2].

«Каюм Насыйри – татар әдибе. Ул, дөрес, һичбер хикәя, һичбер роман, һичбер шигырь язмады. Ләкин шулай дә татар әдибе.

[1] Галимҗан Ибраһимов. «Татарлар арасында революция хәрәкәтләре», 223 б. *(Авт. иск.)*

[2] Җ. Вәлиди үзенең 1923 елда чыккан русча «Очерк истории образованности и литературы волжских татар» дигән әсәрендә (41 бит) Каюм Насыйрины «Переводно-календарная литература» кешесе итеп күрсәтә, бу – Каюм турында хата бер фикердер. *(Авт. иск.)*

Әдипнең мәгънәсе киң. Әдип булу өчен даһи (гениальный[1]) бер шагыйрь яки бер драматург, хәтта оста бер хикәяче булу да лязем түгел. Әдип, ягъни каләме белән әдәбиятка хезмәт итүче»[2].

Үзенең әсәрләренең тел-өслүбендә, язуында да Насыйрины башка чыгтайчы, төркиче татар мөхәррирләре белән каршы көрәшүче дип аңларга кирәк. «Насыйриның теле асла вә асла[3] чыгтай теле түгел. Ул бик аңлап һәм бик кагыйдәле рәвештә татар телен алга сөрә»[4].

Насыйри беренче мәртәбә татар балаларына мәктәптә дә, аларны өенә җыйнап та, аларның үз телләрен укытты. Аның грамматикасын, әдәбиятын өйрәтте. Шул телдә, әлифбасыннан башлап, бөтен фәннән беренче мәртәбә (татар грамматикасы, риязият, табигыят, тарих, җәгърафия, анатомия-физиология, тәрбия, саулыкны саклау, аш пешерү гыйлеме һәм башкалардан) дәреслекләр, кулланмалар язып, киң рәвештә шул телне татар дөньясына чыгарып, мөстәкыйль бер тел иттереп утыртып куйды. Үзе әйткәнчә, аны бу эше өчен татар халкының күп өлеше, бигрәк тә рухани феодаллар, мөселман төркичеләр яратмадылар. Моның өчен аннан көлделәр, аны хурладылар[5]. Ләкин ул, ахыр гомеренәчә һаман шул үз юлында булып, кабергә кергәнче шул үз идеалы өчен көрәшеп килеп, шул көрәшенең соңгы галәбә[6] өлешен XX йөзнең татар яшьләренә китереп тапшырып китте. XX йөзнең беренче уны эчендә инде татарның яшь әдипләре, бу галәбәне гамәли яктан дә, гыйльми яктан да тәгәлләп, эшне тәмам иттеләр (бу турыда сүз соңыннан килә).

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[2] Җ. Вәлиди. «Татар әдәбиятының барышы», 56–64 битләр, 1912 елда басылган. *(Авт. иск.)*

[3] Асла вә асла – һичбер вакытта да, һич кенә дә.

[4] «Каюм Насыйри» мәҗмугасы, Җ. Вәлиди мәкаләсе, 139–145 битләргә каралсын. *(Авт. иск.)*

[5] Бу турыда бу хәл хәтта XX йөз башларында да дәвам итә иде әле. Шушы сүзләребезгә куәт өчен Фатих Әмирханнан бу урында кирәкле вакыйганы күчереп үтик. Ф. Әмирхан әйтә: «Мәдрәсәдә торган заманларымның соңында, бервакыт базардан «Ләһҗәи татария» алып кереп карарга тотынган идем. Шәрикләремдән озын гына буйлы бик дәгъва, таза бер мишәр яныма килеп, нәрсә моталәгә итдекемне *(өйрәнүемне)* сорашды. Мин дә бәян итдем. Ул китапны ачты да иттифакый *(очраклы рәвештә)* «йумрык» дигән сүзгә күзен төшерде. Тәрҗемәсен укып карагач, күзләрен челәйтеп вә вәхшиянә *(кыргыйлык белән)* йозрыгын йомарлап: «Менә, аны китапдан укып беләсе юк, белмисең икән, күреп кал!» – дип, күз төбемә үк китереп һәм минем гомеремнең юкка заигъ (*әрәм*) булуына тәәссеф иткәнлеген *(кайгыруын)* һәм дамелла булса, бу эш өчен миңа җәза биргән булыр иде икәнчелеген бәян итдә. Менә татар шәкертләре татар әдәбияты белән нинди мөнәсәбәттәге заманлары бар иде». («Әл-Ислах». 47 сан. 1908 ел. «Әдәбиятка гаид» дигән мәкаләсе, 4 бит.) *(Авт. иск.)*

[6] Галәбә – җиңү.

**Әдәби телдә ике агым.** XIX йөзнең икенче ярымында борынгы «төрки»челеккә каршы Каюм Насыйри белән татарчылык агымы тудырылган булса, шуннан соң ук шул ук йөзнең дүртенче чиреге эчендә шуңа каршы төркчелек агымы туды. Татарчылыкка каршы булган яңа агым да Гаспринский[1] каләме, аның «Тәрҗеман»ы аркылы килеп чыкты. Шулай итеп, әүвәлге «төрки»челекне Гаспринский киң миллият әсасында[2] «төркчелек» белән алыштыру, татарчылык кебек аерым шивә әдәбиятларын бикләү юлын тотты. Кыскасы, Гаспринский үзенең 1883 елда чыга башлаган «Тәрҗеман» гәзите аркылы бөтен төрк халыклары өчен «Эштә, фикердә, телдә берлек» шигарен ташлап, шул юлда каты көрәш ачты. Төрк халыкларын гомуми әдәби телгә чакыра башлады. Менә бу көрәш Каюм Насыйри тарафыннан башланган татарчылык көрәшенә, шөбһәсез, нык каршы булган бер көрәш иде. Ләкин, Насыйри һичбер вакыт аның тәэсиренә төшмәде; аңа каршы көрәшендә үзенең татарчылык юлында нык дәвам итте. Теге шикелле үк бу да үзенә тарафдарлар тапты. Һаман «татар теле», «татар халкы» дип, шул юлда актык минутына кадәр сугышып барды. Дөрес, XIX йөзнең ахырларында һәм XX йөзнең беренче уны эчендә Гаспринский агымы – төркчелек хәрәкәте – Рәшидләр, Ризалар, Фатихлар, Мусалар аркылы нык көч алып китеп, Каюмның татарчылык агымын бераз басып яисә әкренәйтеп тора алганнар иде. Ләкин шул ук XX йөзнең беренче уны соңнарында татарчылык үзенең катгый галәбәсен[3] казану юлында соңгы моментларны, катгый хәрәкәтләрне ясый иде. Бу ике агым икесе дә тик әдәби телдә генә бер-берсеннән башка иделәр. Әмма идеологиянең дин өлешендә икесе бер үк юлда, икесе дә мөселман иде. Берсе «мөселман татарчылык» агымы булса, икенчесе «мөселман төркчелек» агымы иде. Бу ике агым татар дөньясында матур әдәбиятта да ике төрле әдәби тел агымы тудырды. Татардагы беренче роман – Муса Акъегетнең[4] «Хисаметдин менла» дигән романы – бераз рус теле тәэсире астында шул ук Гаспринскийның

[1] Исмәгыйль Мостафа улы Гаспринский (Гаспралы) (1851–1914) – җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, педагог, нашир. Кырымда, Бакчасарай шәһәрендә төрки-татар һәм рус (1905 елга кадәр) телләрендә нәшер ителгән «Тәрҗеман» әдәби-сәяси һәм фәнни газетасы мөхәррире һәм нашире.

[2] Әсасында – нигезендә.

[3] Галәбәсен – җиңүен.

[4] Муса Акъегет (Акҗегетов Муса Мөхәммәдан улы, 1864–1923) – язучы, журналист. Аның мәгърифәтчелек реализмы юнәлешендә язылган «Хисаметдин менла» (1886) әсәре укучылар арасында зур уңыш казана. Галимҗан Ибраһимов Акъегетзадәне «татар реализмы әдәбиятының атасы» дип бәяли.

төркчелек агымының татар матур әдәбиятында беренче башлангычы булса, XIX йөзнең соңнарында Заһир Бигинең[1] романнары, Риза казыйның «Әсма» һәм «Сәлимә»ләре[2] шул агымның һаман үсәргә таба баруының нәтиҗәсе иде. Гаспринскийның «Франкистан мәктүбләре» белән «Дар-әл-Рәхәт мөселманнары» дигән романнары шул юлда матур әдәбиятта баш адым иделәр.

Икенче яктан, иске төрк теленең садәләшеп, үзенә казакъ тәэсирен дә алып, татарлыкка таба нык авышкан Уразаи-Кормашиның[3] «Таһир-Зөһрә», «Бүз егет» поэмалары өстенә Габдрахман Ильясиның[4] «Бичара кыз» дигән драмасы да Каюмның татарчылык агымының татар матур әдәбиятында беренче баш адымы булдылар. Ф. Халиди[5] драмалары шуның дәвамы иде. Боларга тагы «Бигаять мәгъшукнамә»не[6] (1897дә басылган) һәм «Хикәят» (Габдулла Фәезхан углының мәҗмугатыннан булып, 1896да басылган[7]) кебек китапларны кушарга кирәк. «Чистай комедиясе»[8] исә матур әдәбиятта татарчылыкның һәм дә гавами татарчылыкның иң ачык бер үрнәге, төп орлыгы булып чыкты. XIX йөзнең соңында – XX йөзнең башларында инде менә шул

[1] Заһир Ярулла улы Бигиев (1870–1902) – язучы, публицист. Татар әдәбиятында реалистик роман жанрына нигез салучыларның берсе.

[2] Сүз Ризаэддин Фәхреддиннең «Сәлимә, яки Гыйффәт» (1899) һәм «Әсма, яхуд Гамәл вә җәза» (Оренбург, 1903) повестьлары турында бара.

[3] Кормаши (Әхмәд Мөхәммәдзариф улы Уразаев) (1855–1883) – шагыйрь, мәхәббәт турында ике романтик поэма-дастан авторы. «Кыйссаи бүз егет» (1874) поэмасы татар шагыйре Баһавиның шул исемдәге поэмасына нигезләнеп языла. «Кыйссаи Таһир илә Зөһрә» (1876) – киң таралган Шәрык сюжетына язылган әсәр. Ике поэмасы да зур популярлык казана һәм 1917 елга кадәр берничә тапкыр басыла. Кайбер мәгълүматларга караганда, Кормашиның бүтән әсәрләре дә булган, ләкин алар сакланмаган.

[4] Габдрахман Мөхәммәдәмин улы Ильяси (1856–1895) – драматург, археограф. Аның «Бичара кыз» әсәре (1887) – татар матбугатында беренче булып басылган пьеса. Әсәрдә заманы өчен актуаль булган шәхес иреге, хатын-кызларның ирләр белән бертигез хокукка ия булу, татарларны укыту мәсьәләләре күтәрелә. Бу әсәргә ияреп, Ф. Халиди «Рәдде бичара кыз» (1888) драмасын яза.

[5] Фатих Хаммат улы Халиди (1850–1923) – мәгърифәтче әдип, тәрҗемәче, татар әдәбиятында драматургиягә нигез салучыларның берсе. Ф. Халидинең «Рәдде бичара кыз» драмасы (1888) Г. Ильясиның «Бичара кыз» (1887) драмасына нәзыйрә рәвешендә иҗат ителә.

[6] Сүз авторы Бибигөлҗамал дип күрсәтелгән һәм Казанда басылган «Бигаять мәгъшукнамә» китабы турында бара.

[7] Биредә төгәлсезлек киткән булса кирәк: сүз тарихчы, филолог, тәрҗемәче, публицист Габделгалләм Фәезхан улы Фәезхановның «Хикәят вә мәкаләт» (1896) хезмәте турында барырга тиеш.

[8] Бу әсәрләр турында озын мәгълүмат алырга теләүчеләр «Татар театры» дигән мәҗмугада мөхәррирнең «Татар театр әдәбияты һәм аның тарихи үсүе» дигән мәкаләсенә карасыннар. 8–68 битләр. 1926 ел. *(Авт. иск.)*

рәвешчә төп нигезе, беренче төп сукмагы салынган җиңел яңа татарча әдәби телне Галиәсгар Камаллар[1], Фатих Кәримиләр[2], Гаязлар[3], Ярулла Вәлиләр[4] дәвам иттереп, киңәйтеп алып киттеләр.

Ләкин татар матур әдәбиятында көйле сүздә – тезмәдә татарчылык баш адымының беренче кузгалышы XIX йөзнең беренче ярымының соңнарында ук Кандалый[5] каләме аркылы күренеп үткән иде. Соңгылар Каюм сызыгын да шуны әдәби бер агымга әйләндерделәр.

Яңа татар теленең тудырылуы һәм ул телдә китаплар язылып, аның гамәли үсә башлавы турында сүз барганда, үзенең «Мөстәфад»лары аркылы шул ук татар мөхәррире булып мәйданга чыккан Шиһабетдин Мәрҗанине дә искә алып үтәргә тиешбез. Каюмның замандашы булган бу мөхәррир дә, «татарча китапны уку наданлык саналган һәм аталары хатны гарәпчә яза белмәгән өчен мәдрәсәдәге угылларын сүгәргә торган» бер «дәвердә үзенең күп хезмәт кергән әсәрен һәркем тарафыннан тәхкыйрь ителгән[6] татар теле белән язарга җәсарәт[7] итүе өчен», ул гамәли яктан татар теле файдасына хезмәт итүчеләрдән санала ала. Ул, әлбәттә, Каюм шикелле саф, җиңел татарча яза алмады. Шулай да аның шул «Мөстәфад әл-әхбар»ы[8] телдә гамәли яктан Каюмнар башлаган татарчылыкка, татар теленә таба авышу хәрәкәтенең берсе һәм әһәмиятлесе иде. Дөрес, Мәрҗани телендә гарәпчә, фарсыча сүзләр, шул телләрнең кагыйдәсенчә сүз оештырулар, шулар өстенә чыгтайчылык һәм госманлычылык бик күп урын ала. Шул яктан караганда, аның теле – искиткеч бер чуалчык тел. Бу яктан бәлки аны иске төркичелек агымыннан санарга да юл юк түгел. (Шуның белән бергә ул – нәзари яктан төрк телләрен иң ярлы телләрдән санаучы да. «Мөстәфад»ның икенче бүлемендә 46 биткә каралсын). Ләкин байтак урыннарда (бигрәк Мәрҗанинең ачуланган һәм каләмен тәнкыйтьчелек

[1] Галиәсгар Камал (Галиәсгар Галиәкбәр улы Камалетдинов, 1878–1933) – күренекле драматург, публицист, театр сәнгате һәм җәмәгать эшлеклесе.

[2] Фатих Кәрими (1870–1937) – язучы, нашир, җәмәгать эшлеклесе.

[3] Гаяз Исхакый (1878–1954) – язучы, публицист, җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе.

[4] Ярулла Вәлиулла улы Вәли (Вәлиев) (1879–1937) – язучы, драматург.

[5] Габделҗәббар Кандалый (1797–1860) – шагыйрь. Башлангыч чор әсәрләренең теле катлаулы һәм архаик, үз эченә гарәп-фарсы, угыз, чыгтай лексика һәм морфологиясе элементларын ала. Соңгы чор иҗатында халык теленә якыная.

[6] Тәхкыйрь ителгән – хурланган.

[7] Җәсарәт – батырчылык.

[8] «Мөстәфад әл-әхбар»ның беренче бүлеге – 1885 елда, икенче бүлеге 1900 елда басылды. *(Авт. иск.)*

юлына борган вакытларында), шулай ук, бәгъзе татар галимнәренең авызларыннан сүзләр күчергәндә, җөмлә төзүдә татарчылык, татар теле хосусиятләре, гомумән караганда, борынгы – кадим Шәрык дәверендәгедән һәрхәлдә күп көчле булганга, аны азмы-күпме татар теленә булышучы әсәрләр рәтеннән санамыйча үтә алмыйбыз. Гәрчә Каюм Насыйри да, гомумән, Мәрҗани әсәрләренең телен «гайре мөкәррәр тел» (яңадан кабатланмый торган яраксыз бер тел) дисә дә[1], ул кайсы вакыт яхшы ук ачык рәвештә чын татарча язып та җибәрә. Каюм шикелле үк, Мәрҗани – татар халкын үзенең әлеге тарихи әсәре аркылы татар дип чыгучыларның берсе[2]. Шулай булгач, Каюм Насыйриларның башлаган гамәле татарчылык көрәше файдасына аның бу дәгъвасының гыйльми яктан ярдәме һәм тәэсире булгандыр.

Каюмнарның татарчылыгы юлында шул адымның тәэсире белән үзенең «Тәварихе Болгария»се белән Хөсәен Әмирханов та (мәрхүм әдип Фатих Әмирханның карт атасы) азмы-күпме эшләргә тырышучылардан булды.

### *Нәзари як*

**Татар теленең гыйльми-нәзари эшләнүе юлында**. Татар теленең бер татар теле булу рәвешендә нәзари яктан фәнни эшләнә,

[1] Календарь 1884 ел. «Әт-тәфтиш вә әт-тәхакем» («Тикшерү һәм дәгъва») дигән тәнкыйди мәкалә, 38 б. *(Авт. иск.)*

[2] «Русия таифәсенең кәндләрендән нәфрин вә сүзәнеш мәкамендә татар дип тәнкыйс илә тәгъбир итдекендән бәгъзеләре татар улмакны ноксан фәһемләп, ул исемдән нәфрәт итеп: «Без татар дәгел, мөселман», – дию низаг вә мөҗадәлә идәләр. Һәйһат вә һәйһат вә шәтан бәйнән-Нил вәл-Фөрат и, мискин билфарыз сәнең мөселмандан гайре бер исемеңне дошман дин вә милләтең белмәсә, әлбәттә, сәни мөселман дию нәфрин идәр иде, татар улмасаң, гарәб вә таҗик вә нугай дәгел вә хытай вә рус вә әфрәнҗ вә прус вә немец дәхи дәгел. Имде кем булурсән? Хәйрият, сарт таифәсе, чирмеш вә мукшы вә ар таифәләренең вөҗүдләрене белмәдекләрендән, сәне ул исемнәрнең бере илә тәсмия кылмамышлар. А, хамиятсез, гафил ул тәкъдирдә үзеңне чирмеш я мукшы санаб, разый булып йөрер идеңме?». («Мөстәфад әл-әхбар», 1 ж., 6 бит.) *(Авт. иск.)*

Россия халыкларының кайберләре нәфрәт белән «татар» дип кимсетеп әйткәнлектән, кайберләре татар булуны кимчелек дип аңлап, ул исемгә нәфрәт белән карап: «Без татар түгел, без – мөселман» дип бәхәсләшәләр. Ләкин бу исемнәрнең арасында Нил белән Фөрат елгалары арасындагы ераклык кадәр аерма бар бит. И мескен! Әгәр дә синең «мөселман»нан башка бер исемеңне алар белмәсә иде, сине, әлбәттә, «мөселман» дип нәфрәт иткән булырлар иде. Татар булмасаң, гарәп, таҗик һәм нугай түгел, кытай, рус, француз һәм немец та түгел, инде кем булырсың? Яхшы ки, әле сарт халкы, чирмеш, мукшы һәм ар халыкларының барлыкларын белмәгәнлекләреннән, сине ул исемнәрнең берсе белән атамаганнар. Нинди саксыз, аңсыз син. Әгәр дә шулай булган булса, үзеңне чирмеш я мукшы санап, разый булып йөрер идеңме?

тикшерелә башлавы да беренче мәртәбә Каюм Насыйрида күрелде. Ул аны нәзари яктан да чын мәгънәсе белән татар теле итеп тикшерде. Аңарча мирзалардан Хәлфиннәр XVIII йөзнең соңнарында һәм XIX йөзнең башларында ук русларга укыту өчен грамматикалар язсалар да, алар чынында хәзерге мәгънәсе белән татар теленең грамматикасы түгел, бәлки иске «төрки теленең грамматикасы» иде[1]. Болар шул әлеге «буе – чыгтай; аркавы – госманлы» булып сугылган телнең грамматикасын эшләделәр. Боларның үзләренең язган телләре дә татар феодализм дәвере әдәбиятының чуар теленнән гыйбарәт иде. Хөсәен Фәезхани, үзе әйткәнчә, «төрки телен гайре телләргә бер дә тәкълид итми[2], хәтта анларның китапларына нәзар салмый[3]» (бу гыйбарәләр аның Шиһаб Мәрҗанигә язган хатыннан алына), Каюм Насыйриның татар телен тикшергәне шикелле үк, үзалдына иҗади бер юл белән үзбашлы (мөстәкыйль) тикшерә башлаган һәм руслар өчен шуның грамматикасын язган булса да, бердән, аның бу грамматикасы басыла алмады; икенчедән, ул, аны татарларга укытып, шуның гамәли тәэсирен дә аларга бирә алмады. Аның бу хезмәте, төркичелек юлында булуга карамастан, гамәли яктан да, нәзари яктан да татар дөньясыннан читтә һәм аңа тәэсирсез калды.

Ничек булганда да, Хәлфиннәр дә, Хөсәен Фәезханилар да, татар әдәби телен гамәли тудыру түгел, бәлки шул ук иске әдәби «төрки» теленә гамәли бер реформа да ясый алмаганнары шикелле, нәзари яктан янә бу турыда татар дөньясына тәэсирле бер эш эшли алмадылар. Алар тик русларга укыту өчен (чынында, ул вакытта Шәрыкка сузылган рус сәүдә капиталының, Шәрык колонизациясенең таләбе буенча, руслар өчен татар теле түгел, бигрәк Урта Азиягә якынлаштыра торган һәм чыгтайчага якын булган «төрки тел» кирәк иде) һәм шундый бер гамәли мәҗбүрият астында чыгтайлашкан, госманлылашкан иске әдәби татар теленең кагыйдәләрен өйрәтү юлында башлангыч бер хәрәкәт күрсәттеләр. Кыскасы, аларның бу хәрәкәтләре әүвәлдән тарихи хәзерлеге булган иске бер әдәби телне тикшерү, шуны русларга өйрәтү һәм шул юлдагы тикшерүләрен – грамматикаларын рус телендә язып калдырудан гыйбарәт булды.

---

[1] Сүз И.И. Хәлфиннең «Император Казан гимназиясендә укытыла торган, гарәп уку кагыйдәләре белән татар теле әлифбасы һәм грамматикасы» (1890) хезмәте турында бара.

[2] Тәкълид итми – охшатмый, ияртми.

[3] Нәзар салмый – күз салмый.

Монда янә әһәмиятле бер хәлне әйтеп үтми булмый: тегеләр (Хәлфин һәм Фәезханилар) төрки телен русларга укытучы булсалар, аларның грамматикалары да «тик фиһристне[1] тутыру өчен генә телгә алынырга ярый» торган «чуар грамматикалар» иде. Әмма Каюм Насыйри исә, тегеләрнең киресенчә, рус телен татарларга укытучы булды, рус теленең грамматикасын да шулар өчен язды.

Кыскасы, тегеләр «төрки» грамматикаларын руслар өчен язсалар, Каюм да рус грамматикасын татар теле белән чагыштыру юлында татарлар өчен язды. Менә шушы хәл дә Каюмга татар телен тагын да ныграк, төплерәк рәвештә тикшерү өчен ярдәм итте. Шуның өстенә ул рус телен татарларга үз телләренең сарыф, нәхү ягыннан төзелешләре белән чагыштырып укыту кирәклек фикерен дә алга алды.

**Татар теленең гыйльми грамматика нигезе һәм Каюм Насыйри.** Каюм Насыйриның татар телен нәзари эшләве аның беренче мәртәбә фәнни нигездә чын татар грамматикасын төзеп бирүендә булды. Бигрәк тә ул үзенең 1892 елда басылган «Кавагыйде китабәт»е һәм 1895 елда басылган «Әнмүзәҗ»[2] дигән грамматика китабы белән татар теленең фонетика, имля һәм морфология нигезен салды. «Бу әсәр («Әнмүзәҗ») – һич шөбһә юк, татар сарыфы фәненең нигезенә иң беренче таштыр. Сарыфчыларның кулында Каюм Насыйриның «Әнмүзәҗ»е булу аларның хезмәтен бик күп җиңеләйтә. Соңгы сарыфчылар, үзләренә эзләргә тиеш бик күп әсәрне Каюм әфәндедә эзләп табылган көе, ягъни әзер хәлендә күреп, аңардан күп файда алдылар»[3].

Каюмның «Әнмүзәҗ»е 1895 тә басылды. Ләкин әле аның, югарыда әйтеп үткәнебезчә, 1892 дә бастырган «Кавагыйде китабәт» дигән 26 битлек бер мөһим әсәре бар. Моны татар теленең бәлягатен өйрәтү, язу әдәпләрен белдерү өчен язса да, монда да ул татар

[1] Фиһристне – китаплар исемлеген, каталогны.

[2] Татар теленең сарыфы турындагы шушы «Әнмүзәҗ»ен бастырудан элек, Каюм татар балаларына рус телен татар теле белән чагыштырып укыту өчен «Кавагыйде кыйраәте рус» исемендә, илле сабаклык итеп, гамәли, нәзари бер дәреслек бастырган иде (1889 елда). Менә шушы әсәренә ул үзенең тагын аннан башка шул ук рус теленең нәхүен өйрәтә торган «Әнмүзәҗ» дигән китабыннан бер «Мөкаддимә» алып кушкан. («Моннан башка рус теленең нәхү кагыйдәләрен бәян кыйлгучы "Әнмүзәҗ" бер китабым бардыр. Бу мөкаддимә – аның мөкаддимәседер. Ул "Әнмүзәҗ", шаять, тиз чыгар». 17 бит.) Шушы мөкаддимәсендә рус телен татар теле белән чагыштырып, татар теле фонетикасының да төп хосусиятләрен ача. *(Авт. иск.)*

[3] Галимҗан Ибраһимов мәкаләсе // «Аң». 21–22 нче сан, 1915 ел. Һәм шул ук әдипнең «Имля, тел, әдәбият мәсьәләләре» дигән мәкаләләр мәҗмугасының 97–101 битләренә каралсын. *(Авт. иск.)*

теленең имлясы, сарыфы, нәхүе турында татарчылык рухында төпле бер башлангыч мәгълүмат биреп үтә. Шунда ул «Әнмүзәҗ» дигән әсәренең төп нигезен сала. Шулай итеп, аның «Әнмүзәҗ»е грамматика бүлемендә шул төп нәзари сызыкларның үстерелеп, киңәйтеп эшләнеп чыккан соңгы тулы бер рәвеше булды.

Гомумән, Каюм грамматикасында татар теленең өч ягына тукталып, кыскача бер караш ясап үтик:

1) Фонетика – имля, 2) сарыф, 3) нәхү. Ул үзенең югарыда әйтелгән «Кавагыйде китабәт»ендә сүз башында ук татарның язу телен юлга салырга, эшләргә тотынганын аңлатып үтә. Татарга фәнгыйлем теле эшләп биреп, аны «мәдәниятле адәм» ясамакчы була.

Шушы әсәренең беренче битендә ул әйтә:

«Мәдәниятле һәрбер адәмнең ике төрле теле булып, берсе – анасыннан сөт имгән мөддәттә[1] үгрәнгән теледер. Икенчесе – дәхи бер остадка[2] тәгълимгә[3] бирелгәч, гыйлем вә фән лөгатьләре[4] белән ачылган телдер. Әмма сөт телендә безнең эшемез юк. Чөнки бу кадәресе – анасының шаныдыр, атасы тарафыннан бер гафләтдер[5]. Имди шуңар бинаән[6] замана балалары әлфаз вә әлкабның[7] хикмәтеннән мәхрүм калмышлардыр. Чөнки телләр гыйлем вә фән теле белән ачылмактан мәгъзүрләрдер[8]. Олуглары гыйлемдән ләззәт алмаган булса, балалары ни белсен? Әлвәел сөммәл-вәел!» («Кайгы, кайгы соңындан кайгы» дигән сүз[9]). Ул ана сөте белән ачылган телне, фән-гыйлем сөте беләν, язуга да яраклы иттереп, әдәби рәвештә ачмакчы була. Татарның олугларының да, балаларының да язу, фән теленнән мәхрүм булуларына кайгыра.

Соңыннан иң элек эшкә татарның имлясыннан тотына. Имляны төзәтүдә татарча сүзләрнең әйтелгәнчә язылуының конкрет юлларын, мисалларын күрсәтә. Үз заманындагы язучыларның яңлыш имлялларын «галәт», «фәхеш» дип сүгә. Аларны татарча дөрес язарга чакыра.

[1] Мөддәттә – вакытта.
[2] Остадка – остазга.
[3] Тәгълимгә – укуга.
[4] Лөгатьләре – сүзләре.
[5] Гафләтдер – игътибарсызлык.
[6] Шуңар бинаән – шул сәбәпле.
[7] Әлфаз вә әлкабның – сүзләр һәм гыйбарәләрнең.
[8] Мәгъзүрләрдер – мәхрүмдер.
[9] Каюм Насыйрида нокта урынына шушы (–) сызыктан башка тыныш билгеләре юк, алар безнең тарафтан куелды. Әмма имляда, тарихи якны саклар өчен, Каюмның үзенчә калдырыла. *(Авт. иск.)*

Ул бу турыда менә болай ди:

1. «Вә янә «килде, китде»дигән кәлимәләрдә «китте, килде, китерде» дип язмак – галәт[1], фәхештер. Чөнки безләр татарлар «килде, китте» дип сарыф кәсра белән сөйләшәмез вә кәзалик[2] «ничә» вә «кирәк» дигән кәлимәләрдә халис кәсра белән әйтәмез: «кәрәк, нәчә, нәчек» язмак хатадыр. Янә бу заман язучыларының хатаи фәхешләрендәндер ки, «булды» урынына «улды» язалар. Телемездә «улды, улыр» кебек кәлимәләр юктыр. Вә кәзалик «бар» урынына – «вар», «бирде» урынына «вирде» язмаклары – сарыф хатадыр. Бәс мәгълүмдер ки: безләр татармыз, мәхрәҗгә[3] мохтаҗ түгелләрмез. Мәгәр әлфаз вә әлкаб[4] бабында мохтаҗлармыз. Үземезгә кирәк сүзләрне, тапсак, гарәптән аламыз, тапсак, фарсыдан аламыз, тапсак, төректән аламыз, ләкин үз телемезнең нәхү кагыйдәсенә саламыз. Үземезгә ятарлык нәхүемез бар» («Кавагыйде китабәт», 5 бит).

2. «Ушбу «сыз» хәрфе мөтәсалә[5] языла, ягъни «аяк сыз, кул сыз, юл сыз» хатадыр, вә кәзалик «түгел» хәрфе мөтәсалә язылмак хатадыр. Мәсәлән: «бай түгел» диясе урында «байтүгел» язылмас. Дәхи дә фәкать үз гыйбарәтемездә «дәгел» язмак хатадыр» (7 бит)

3. Хәзер дә шуны әйтермез бары: «кәлде» дип язма, «килде» дип яз. «Кәтте» дип язма, «китте» дип яз, «дәгел» дип язма, «түгел» диген! «Кәрәк» дип язма, «кирәк» дип яз! «Ничә» дип яз, «нәчә» димә! Дәхи[6] «нәчек» яки «нәчәк»дип язма, «ничек» дип яз! «Тиш» дип язарга кирәкмәс, «тиеш вә тиешле» язылыр. Янә хәрфе тәшбиһдән[7] «кебек» ләфзыйдыр ки, аны телеңдә «кеби» дип язма! Бу кәлимә асыл төрк телендә дә «кебек» дип мөстәгъмәл[8] булгандыр. Ләкин «кебек»нең ахыргы «кяф»ен шулкадәр йомшатмышлардыр ки, бәлки ишетелмәс булып калмыштыр. Мәсәлән, кызылбашларның «Күпек углы» дигән сүзләре кебек, чөнки ишетәмез: гүяки «Күпе углы» дип әйтәләр лә, иншаллаһ, бу сүзләр «Ләһҗәи татар» китабымда мөфәсәлә язылыр» (25 бит).

---

[1] Галәт – ялгыш.

[2] Кәзалик – шулай ук.

[3] Мәхрәҗгә – *биредә:* авазларны гарәп телендәге артикуляция үзенчәлекләре белән әйтүгә.

[4] Әлфаз вә әлкаб – атамалар һәм сүзләр.

[5] Мөтәсалә – кушылып.

[6] Дәхи – тагын.

[7] Хәрфе тәшбиһдән – чагыштыру бәйлегеннән.

[8] Мөстәгъмәл – кулланылган.

Каюмның фәнне дөрес бер тикшерүе аның татар телендәге авазларны дөрес, ачык билгели алуы булды. Ул бигрәк тә татар телендә ун сузык аваз (ун мәдд) булу хакыйкатен ачып биреп китте. Аның үз галәмәтләре белән күрсәтсәк, алар шулар: а (ат), ә (әтәч), у (ул, ун), ү (үч, үпкә)[1], о (он, оч), ө (өч, өмә)[2], и (ит), (э, ы)[3].

Ялгыз шунысы булды: ул, нәзариядә шулай ун сузык аваз күрсәтсә дә, язуда ун авазның һәрберсенә ун галәмәтне аерым куеп җибәрергә һәм үзе китапларын ун сузык белән язарга батырчылык итә алмады. Батырчылык итә алмады гына түгел, бәлки «ул дөрес имля белән язарга өмет тә итә алмый һәм мәгъзүр[4] дә: татар хәятының ул көннәрендә яңа имля белән язып бернәрсә аңлату түгел, халыкның шул иске имля астында язган язулары өчен дә мәрхүм Насыйри милләт каршында Алланың сукыр бәндәсе иде[5]».

Каюмның үз тәгъбире белән әйткәндә, ул «бизаруран» (гамәли ихтыярсызлык белән) шул әүвәлге өч сузык – «ә ү и» (а, у, ый) хәрефләре белән генә калды.

Кыскасы, аның өчен имля һәм фонетиканың нәзари ягын югарыда күрсәтелгәнчә тулы итеп ачу белән бергә, гамәлдә дә аңа шул дәрәҗәгә барып җитүгә әле ул чакта зәмин[6] дә, имкян[7] да юк иде. Чөнки ул вакытта «бу фикерне тудырган иҗтимагый хәрәкәт әле искене җиңмәгән иде. Картны сукыр Каюм, миссионер Каюм дип йөртәләр иде». Хәтта аңарча «атәч» (әтәч) дип язылып килгән сүзне «т» белән «ч» арасына «ә» кертеп, «тәч» рәвешендә язуны да гамәлгә куя алмады. «“Атәч” язылса мөмкин иде. Бер дә шулай язылган җире күренмәде[8]» дип, ул вакытта моның гамәлгә ашырылуы кыен булганын, чарасызлыгын аңлатып үтүдән башканы эшли алмады («ә»не үзенең тиешле һәр урынында кертеп җибәрү эшен гамәлгә ашыруда беренче адым соңыннан Һ. Максуди[9] тарафыннын атланды). Ләкин шушы хәлләрнең һәммәсе белән бергә, нәзари яктан

---

[1] Каюм бу икене «озын уау» дип йөртә. *(Авт. иск.)*
[2] Каюм бу икене «тупа уау» дип йөртә. *(Авт. иск.)*
[3] Соңгысын ул «ы» һәм «э» урынына йөртә. *(Авт. иск.)*
[4] Мәгъзүр – бу эшне башкаруда чарасыз, ихтыярсыз.
[5] «Имля, тел, әдәбият мәсьәләләре», 69 бит. *(Авт. иск.)*
[6] Зәмин – җирлек.
[7] Имкян – мөмкинлек.
[8] «Әнмүзәҗ», 3 бит. *(Авт. иск.)*
[9] Әхмәтһади Низаметдин улы Максуди (1868–1941) – педагог, нашир, журналист, сәясәт эшлеклесе.

татар дөньясында, һәрхәлдә «иске имляга каршы беренче көрәш башлап, яңага юл сызучы да ул булды»[1].

Каюмның татар телен нәзари яктан эшләвендә иң зур хезмәте татар теленең сарыфы – морфологиясе турындагы хезмәте булыр. Бу да аның атамаларын (истыйляхларны) татарча куюында түгел, ул бу яктан тәмам гарәп сарыфлары тәэсире астында. Сүзләрне тәгъриф кылулар[2], аңлатулар, төрләргә бүлүләр, классификацияләр дә шул ук гарәп сызыгында[3]. Метод та шулай ук иске, кыскасы, тыштан һәм өстән караганда, ул бөтенләй үк «гарәп сарыфы һәм нәхүе калыбына салынган» күренә.

Ләкин эшнең, аның эзләнүләренең төбен тикшерсәк тә, ул сарыфта татар теленең үзенең бер татар теле булу ягы белән казылып чыгарылган, актарып салынган эчке фәнни ягын карасак, моның иске калыпка, иске савытка салынган яп-яңа җәүһәрләр бирә торган гаять кыйммәтле бер нәрсә икәнен бик ачык күрәчәкбез. «Килгәннәр» (килгәнләр), «Казаннан» (Казандан), «ачтан» (ачдан) шикелле бер авазның икенче авазга әйләнүе; «карат» (кара ат) дигәндәге кебек ике сузык авазлар янәшә килгәндә, берсенең югалуы; «колагы, аягы» сүзләрендәге шикелле, соңнарында сузыклар килгәндә, «къ, к»ләрнең «гъ, г»гә әйләнүләре; шулай ук зат, сыйфат исемнәре, аларның төрләре, саннар, ирлек-оргачылык мәсьәләләре[4], хайваннарның исемнәре» («Әнмүзәҗ»нең 3–14 битләренә каралсын) – шөбһәсез, татар теленең шундый үз хосусиятләредер. Каюм бу мәсьәләләрдә, чыннан да, «тик татар теленең үз рухыннан туган кагыйдәләрдән бәхәс итә һәм соңгы сарыфчылар тарафыннан кабул ителгән хакыйкатьләрне ачадыр». Шулай ук монда ул «тик татар теленең үз эчендән генә чыккан мөнәсәбәтләрне бер канунга салган рәвештә» аңлатып бирә.

Фигыльләр бабында исә без инде Каюмны, чыннан да, татар теленең эченә тирәннән чума алган бер кеше итеп күрәбез. Ул бу турыда үзенең төпле тикшерүе белән татар теленең байлыгын ачып бирә, шул тикшерүенең нәтиҗәсе итеп, ул үзе дә: «Имди телемездә фигыль бабына керсәк вә дикъкать белән тәфтиш кыйлсак[5],

[1] «Имля, тел, әдәбият мәсьәләләре», 52 бит. *(Авт. иск.)*

[2] Тәгъриф кылулар – аңлатулар.

[3] Аның бу эше шушы китабын мәдрәсәдә укып, гарәп сарыфын, гарәп истыйляхларын белүчеләргә укыту өчен язганлыгыннан булырга мөмкин. *(Авт. иск.)*

[4] Ирлек-оргачылык мәсьәләләре – җенес мәсьәләләре.

[5] Тәфтиш кыйлсак – тикшерсәк.

күп гаҗәеп хикмәтләр заһир[1] булыр. Шөйлә ки җәмигъ мөштәкаты мөстәгъмәл булгучы бер фигыльне кямилән иштикак кыйлынса, йөзгә кадәр фигыль хасил булыр[2]. Телемезнең хасиятенә караганда, һич гаҗәп түкелдер» («Әнмүзәҗ», 14 бит). «Татар лисанымызның бәгъзе хосусиятендән бәян кылаек: әүвәл татар телемезнең иң олуг хасиятендәндер кем фигыль бабында гаять бай телдер» («Кавагыйде китабәт», 2 бит), дигән дөрес фикерне мәйданга куя.

Ул безгә фигыльләрнең ничек бабларга аерылуының бай, мөкәммәл[3] бер җәдвәлен[4] бирә (15–41 битләр). Фигыльләрдән дә үтеп, бәйлекләр, кушымталар, ярдәмлекләр бүлеменә килсәк (ул боларны гарәп атамасы белән «хоруфе җәр»[5] дип йөртә), монда әнә Каюм татар теленең үз эченә йотылып кереп китеп, ныклап тикшерә, шуның дөрес нәтиҗәләрен яза. Мисаллар да бөтенләй ачык татарча. Анда «энҗе шикелле чык тамчылары агач яфракларында тамчыланып тора – ак калфагың кар кебек» дигән шикелле саф татарча әдәби җөмләләрне дә күп очратабыз (41–81 битләргә каралсын).

Каюмның «Сарыф кагыйдәләре» дигән бүлеме тагын дә аеруча дикъкатьне үзенә нык каратырлык төпле, тирән бер тикшерү булып чыккан. Монда тагын да күп иҗади нәрсәләр бар (51–65 битләргә каралсын). Каюмның бу тикшерүләре тәмамы белән соңгы сарыфчылар өчен әзер материал булдылар. Алар шуны җиңелләштерде, садәләштерде[6] һәм шуларны яңа метод, яңа атамалар белән тагын да тәртипләндерә, системландыра төштеләр; аны тагын да киңәйттеләр.

Каюмның сарыфта фәнни бер иҗаты, «сез» дигән кушымтаның ялгыз исемгә генә хас бер хосусият булганын әйтеп, («сез – бу хоруфе мотлак нәфи[7] өчендер. Ләкин исемгә махсустыр», 41 бит) сүзләрне классификация өчен яңа бер юл тудыруга ишарә кылып калдыруы булды. Шуның өстенә ул «ма» галәмәтенең дә фигыльгә хас икәнен аңлатып китте (54 биткә каралсын).

Картның нәхү бүлеме дә нәкъ татар теле рухында эчке бер тикшерү булып чыккан (65–84 битләргә каралсын), ләкин бу бүлеме сарыф өлешенә караганда бераз йомшаграк, буталчыграк эшләнгән. Монда ул сарыф кагыйдәләре белән дә чуалткалый.

[1] Заһир – билгеле.
[2] Шулай бер тамырдан булган фигыльләрне төрләндерсәк, йөзгә якын фигыль ясалыр.
[3] Мөкәммәл – тулы.
[4] Җәдвәлен – таблицасын.
[5] Хоруфе җәр – хоруф – кисәкчә, җәр – бәйлек.
[6] Садәләштерде – гадиләштерде.
[7] Хоруфе мотлак нәфи – абсолют юклык кисәкчәсе.

Каюм сарыфта да, нәхүдә дә шәкелче[1] түгел, әлбәттә, ул – мантыйкый-рухи грамматикачы. Ул бигрәк мәгънәгә карап, мәгънә ягын алга куеп эш итә. Шәкелчелекне ул вакытта аннан таләп итү дә хаксызлык булыр иде.

Кыскасы, Каюмның «Әнмүзәҗ»е – тышкы ягы, методы белән гарәп калыбында булуы, шулай ук хәзерге күздән караганда үзенең бөтенсезлеге, җитешсезлеге белән бергә, хәзерге татар грамматикасының нәзари яктан эшләнү тарихында иң төп баш чишмәдер. «Киләчәкдә татар теленең нәзари яктан эшләнүе – татар сарыфларының фән рәвешендә тулы булып үсүе» тарихы, кайчан булса да һаман Каюмга әйләнеп, аның «Кавагыйде китабәт»енә, «Әнмүзәҗ»енә килеп төенләнәчәк. Ягъни «тел вә әдәбият агымларының башын эзләп бара торгач, һәр җирдә Каюм Насыйрига барып терәлдекебез кебек, имля, сарыф вә нәхү фәненең тарихын тикшерә башласак та, без, ихтыярсыз, Каюм Насыйрига барып туктыйбыз[2]» һәм тукталачакбыз.

Каюмның татар теленең бәлягате[3] нәзариясенә хезмәте дә бу урында әйтелеп үтелергә тиеш. Ул шул ук «Кавагыйде китабәт»ендә татар теленең бәлягать кагыйдәләрен, өслүб нәзарияләрен тикшерүнең, шуларны бер фән рәвешендә төзеп, ясап чыгаруның да беренче адымын салды. Ләкин аның бу хезмәте бәлягать фәне булу ягыннан йомшак бер хезмәт булды. Моннан имля, сарыф, нәхү кагыйдәләрен чыгарып алганда, бәлягать наменә бик аз нәрсә торып калачак. Аның да күпләре – «язу әдәпләре» рәвешендә бер нәрсә. Шулай да ул бу турыда моның белән беренче юлны башлады. Һич булмаса, «гыйлеменең тәхсиленең[4] сәбәпләренең олугы иҗтиһад[5] кыйлмактыр»[6] рәвешендә җөмлә тәртип итүләрне (телнең бәлягатен боза торган мондый җөмләләрне Г. Исхакыйда да байтак очратабыз), татар теленең бәлягать, фәсахәтенә[7] сыймавы кебек мәсьәләләрне аңлатып китте. Һәм шул мәүзуг[8] мөнәсәбәте белән

---

[1] Шәкелче – формалист.

[2] Галимҗан Ибраһимов, «Аң», 21–22 сан, 1915 ел һәм «Имля, тел, әдәбият мәсьәләләре». *(Авт. иск.)*

[3] Бәлягать – сүз сөйләүдә яки язуда булган матурлык; тулылык, төзеклек.

[4] Гыйлемнең тәхсиленең – гыйлем алуның.

[5] Иҗтиһад – тырышлык.

[6] «Кавагыйде китабәт», 21 бит. *(Авт. иск.)*

[7] Фәсахәтенә – сөйләм матурлыгына, төзеклегенә.

[8] Мәүзуг – мәсьәлә.

сарыф-нәхү китапларында әйтеп бетерә алмаган якларын тутырды. Аның бу юлдагы хезмәтенең кыйммәте дә әнә шунда.

Менә XIX йөзнең соңгы ярымы эчендә имля, фонетика, морфология, нәхү, бәлягать ягыннан татар теленең Каюм каләме аркылы нәзари эшләнүе шул дәрәҗәдә иде. Аның бу хезмәтләренә татар теленең лөгатен язуда беренче кыйммәтле адым булган «Ләһҗаи татария»сен дә кушсак (беренче бүлеме – [18]95, икенчесе [18]96 елда басылган), аның бу бабдагы хезмәтенең күренеше, үлчәве тәмам төгәлләнгән булыр.

## 2. Фәннәр

*(табигыят, риязият, тарих, этнография, тәрбия, педагогия)*

**Татарга Яурупа фәннәрен кертүдә беренче кузгалыш.** XIX йөзнең икенче ярымының соңларында татар дөньясына беренче мәртәбә Яурупа мәгънәсе белән гыйлем ишеге ачыла, фән әдәбияты туа башлый.

Татар реформа хәрәкәтенең иң нык күзгә ташланган ягының берсе дә менә шул була. Икътисади, иҗтимагый барышның таләбе буенча, Яурупа фәннәрен кирәксенеп, татар теле аркылы шуларны өйрәнә, өйрәтә башлау – бу татар халкының алдына килеп баскан иң зур мәдәни кирәкнең берсе булып күренә. Ләкин бу зур кирәкне башта аңлаучы бик аз була. Яисә аңлаучы булса да, шуны булдыручы, шул зур эшне башлап җибәрүче гыйльми көч булмый. Менә шушы беренче адымны башлап җибәрүче кешеләр шул фәннәрне татар телендә язачак каләмнәр көтелә; шуларга ихтыяҗ сизелә.

Бу юлда тагын беренче булып Каюм килеп чыга[1]. Ягъни шушы тарихи адым шул ук Каюм каләме белән башланып китә. «Ул – Яурупа фәннәрен безнең арага кертү юлында беренче карлыгач[2]» булып, мәйданга атыла.

Татар дөньясында беренче мәртәбә башлап үзенең календарьлары аркылы һәм шуларга аерым рисаләләрен куша барып, табигыят, җәгърафия, һәйәт[3], тарих, этнография, тәрбия-педагогия бе-

---

[1] Гәрчә Каюмнан алда Хәлфиннәр шикелле адәмнәр булса да, болар рус хөкүмәтенең татар телен белгән чиновник галимнәре генә иде, алар халыкның гыйлемдә тәрәккыйсы тарихында бертөрле дә эз, тәэсир калдыра алмадылар. *(Авт. иск.)*

[2] Газиз Гобәйдуллин мәкаләсеннән – «Каюм Насыйри мәҗмугасы». 90 бит. *(Авт. иск.)*

[3] Һәйәт – астрономия.

лемнәреннән, статистикадан мәгълүмат биреп тору өстенә, шул ук фәннәрдән тәрҗемә һәм оригиналь юллы төрле аерым мәкаләләр, китаплар яза.

Хисаптан, һәндәсәдән[1] дәреслекләр; җәгърафиядән, игенчелек, аш пешерү белемнәреннән, үсемлекләрдән, анатомия һәм физиологиядән, этнография һәм тарихтан мәкаләләр яза, кулланмалар тудыра.

*Каюм Насыйри әсәрләре*

*Риязияттән:*

1) «Хисаплык [ягъни гыйльме хисап кагыйдәләре, яки арифметика вә һәм хисаплык мәсьәләләре]» – хисап китабы. Ике басма күтәрә. Беренче басмасы – 1873 тә (52 бит зурлыгында), икенче басмасы 1899 да (зурайтылып 85 битлек булып) басыла. 2) «Истыйляхәт [гыйльме] һәндәсә» («Һәндәсә атамалары») 1895 дә басыла.

*Һәйәттән:*

1) «Көсүф вә хөсүф» («Кояш һәм ай тотылу») турында (мәкалә). [18]83 елгы календареның ахырына кушымта итеп басыла. 8 бит.

*Табигыяттән:*

1) «Мөнафигъ әгъза [вә кануны сихәт]» – анатомия, физиология, саулыкны саклау белеменнән (1894 тә басыла); 2) «Аракы дигән эчемлек – адәми зат өчен сарыф бер агудыр» – [18]89 елгы календарьда 8 битлек бер мәкалә (37–44 битләр); 3) «Әхвале шәрабеддөхан» («Тәмәке тартучының хәлләре») – [18]90 елгы календаренда 7 битлек мәкалә (26–32 битләр); 4) «Хәвасе нәбәтат» («Үсемлекләрнең хасиятләре») 1894 тә басыла. Бу рисаләсе шул ук елгы календарена кушылып басылган була.

*Җәгърафиядән:*

«[Ысулы] җәгърафияи кәбир» («Бөек җәгърафия»). Икенче һәм өченче җилдләр (икенче җилде – 1898 дә, өченчесе 1899 да басыла).

*Этнография, тарих һәм тәрҗемәи хәлдән:*

1) «Некролог вә һәм кабер ташлары» (мәкалә). 1877 елгы календаренда басыла (43–46 битләрдә); 2) «Кыска тәварих вә һәм кабер ташлары» (мәкалә) 1878 елгы календарьда басыла (30–32 битләр); 3) «Фәваиде тарихия мин тәварих әл-әнбия вә әл-голамаэ әл-мадия», 38 битлек бер әсәр булып, 1882 елгы календаренда басылды (26–63 битләргә каралсын); 4) «Казан шәһәрендәге мәсҗедләр һәм Казан шәһәре» (мәкаләләр) – шул ук [18]82 елгы

[1] Һәндәсәдән – геометриядән.

календаренда (74–79 битләргә каралсын); 5) «Тәзкирә». Бу мәкалә Казан байлары тарихыннан булып, 1883 елгы календаренда басылган. Татар сәүдә капитализмын өйрәнү өчен яхшы материал бирә торган бер мәкалә (31–38 битләргә каралсын); 6) «Әл-тәфтиш вә әлтәхәккем»[1] – 1885 елгы календареның 38–43 битләрендә басылган тарихи-тәнкыйди бер мәкалә. Монда ул Шиһаб Мәрҗанинең «Тәварихе Болгария» (Хисаметдин Мөслиминең[2]) турындагы тәнкыйтен тәнкыйть итә. Тәнкыйте каты, усал телле.

Каюм Насыйриның этнографиядән үзе исән вакытта басылмыйча калган кульязма әсәрләре әле соңыннан ([19]26 елда) табылып, Татарстан Гыйльми Үзәге карамагында бастырылдылар. Бу әсәрләр – аның үз бабында тагын да әһәмиятле әсәрләрдер. Сиксәненче елларда язылган бу әсәрләрнең теле саф татарча булулары үзләренә аеруча игътибарны карата.

**Табигыят һәм риязият белеме.** Каюмның фәндә зур хезмәте бигрәк табигыят, риязият һәм тәрбия-педагогия фәннәрендә булды. Бигрәк тә «Насыйриның татар өчен иң зур хезмәтләренең берсе – аның голүме табигыяне[3] гавамлаштыруындадыр[4]». Шуның өстенә ул татарлар өчен риязият фәннәре ишеген ачты. Татар дөньясында беренче мәртәбә хисап, һәндәсәдән дәреслекләр язды. Һәйәттән (космография) мәгълүмат бирде. Кыскасы, шул фәннәрне җиңел татар теле аркылы татар халкы арасына башлап китереп кертте.

**Иҗтимагый фәннәр**. Шулар өстенә ул ук иҗтимагый гыйлемнәрдән статистика фәненә дә зур әһәмият биреп, татарлар ара-

[1] «Тикшерү һәм хөкем».

[2] Шәрәфетдин бине Хисаметдин (әл-Мөслими әл-Болгари) – «Тәварихе Болгария» («Болгар иле тарихы», чама белән XVIII йөз ахыры – XIX йөз башына карый) исемле тарихи-әдәби әсәрнең уйдырма авторы. Тарихи әдәбиятта Шәрәфетдин бине Хисаметдин һәм аның әсәре төрлечә кабул ителә. Мәсәлән, Ш. Мәрҗани, Р. Фәхреддин кебек тикшеренүчеләр, «Тәварихе Болгария»дәге каршылыкларны һәм чагышмауларны күрсәтеп, әсәрне каты тәнкыйть утына тоталар. Ш. Мәрҗанинең «Мөстәфад әләхбар фи әхвали Казан вә Болгар» хезмәтендә ««Тәварихе Болгария» исемле китаптагы ачык ялгышлар, әшәке ялганнар һәм вакыйгаларның буташтырылулары турында аңлатма» дигән махсус бүлекчә урын ала, төрле ялгышларны санап-раслап барганнан соң, күренекле фикер иясе: «Хисаметдин бине Шәрәфетдин әл-Мөслиминең китабында булган ялгыш-ялганнар чиктән тыш күп. Берсен дә калдырмыйча аңлаткан тәкъдирдә берничә томлык зур китап язарга кирәк булачак», – дигән нәтиҗәгә килә.

[3] Голүме табигыяне – табигать турындагы фәнне.

[4] Газиз Гобәйдуллин. «Каюм Насыйри мәҗмугасы», 91 бит. «Насыйриның фәнләрне гавамлаштыруы юлында хезмәтләре» дигән мәкалә. Бу турыда тәфсилле мәгълүмат алырга теләүчеләр шушы мәкаләдән файдаланырга мөмкин.

сында шуның беренче юлын ачты. Календарьлары – аның шул эшенә ачыктан-ачык шаһитлар.

**Тарих.** Тарих фәнендә исә Каюм Насыйри артык мәшһүр булган бер галим түгел. Шулай да аның [19]26 елдагы басылган яңа әсәрләре Яурупа методлары белән тарих тикшерүче бер адәм булганын күрсәтәләр. Ләкин аның бу язган әсәрләре – бербөтен тарих булмау белән бергә, тарих фәне өчен беренче кул кыйммәтле ышанычлы материаллар алар.

Татарның уянуы, реформа хәрәкәте тарих фәнен дә бер фән сыйфаты белән мотлак[1] кирәксенә иде. Әнә шушы кирәкне үтәү юлында Мәрҗани, беренче зур адымнарны атлап, төрк-татар тарихына нигез ташы салды. Беренче җилде бөтен – төрк халыклары, икенчесендә тик татарлар турында язылган «Мөстәфад»ларын[2] татар телендә бастырып мәйданга куйды.

Мәрҗанинең тарихлары татарлар өчен, чыннан да, нык тикшерелеп, тәхкыйкланып[3] беренче кулдан язылган чын иҗади әсәрләр булып чыктылар. Алар мәнбәгъ[4] һәм вакыйгаларга чынлап та көчле, үткен бер тәнкыйди караш йөртеп язылганнар.

Алар – күп яктан турыдан-туры Мәрҗанинең үз эзләнүенең, үз иҗатының җимешләре. Шундый бер юлда язуы аркасында ул үзенең шул «Мөстәфад»лары аркылы тарих фәненең әкиятләрдән, анекдотлардан, аннан-моннан ишетелеп җыйналган асылсыз ялган хәбәрләрдән башы-аягы белән бөтенләй аерым бер нәрсә икәнен, аның бик нык тикшерелеп, төрле җирләрдән эзләнеп, казынып, күп китаплар актарып, шуның өстенә дә үзең ул турыда бик төптән уйланып, вакыйгаларны төрлечә уйлап карап языла һәм шул юл белән укытыла, укыла торган зур бер иҗтимагый фән икәнен татар дөньясында ап-ачык итеп мәйданга куйды. Гомуми уяну, реформа вакытларында татарлар өчен бу бик кирәкле бер эш иде. Бу эш, мондый бер юлдагы шундый төпле бер иҗади, кискен хәрәкәт аңарчы татар дөньясында юк иде. Ул әнә шуны беренче мәртәбә башлап бирүче көчле бер хезмәтче булды.

[1] Мотлак – һичшиксез.

[2] Сүз Ш. Мәрҗанинең «Мөстәфад әл-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» («Казан вә Болгар хәлләре турында файдалы хәбәрләр») хезмәте турында бара. Бу хезмәттә гарәп, фарсы һәм төрки чыганаклардан алынган күп кенә династияләр һәм шәхесләр турында тарихи-биографик белешмәләр, эпиграфика һәм нумизматика мәгълүматлары, телдән әйтелгән хәбәрләр, халык әкиятләре тупланган. Анда беренче тапкыр татар халкы тарихына караган хезмәт иҗат итү омтылышы ясала.

[3] Тәхкыйкланып – тикшерелеп.

[4] Мәнбәгъ – чыганак.

Шуның өстенә бу әсәрләре белән Мәрҗани үзеннән соңгы буынга бик күп «беренче кул» тарихи материаллар хәзерләп биреп китте.

Аннан соңгы Риза казый, Габәши[1], Зәки Вәлиди[2], Һади Атласи[3], Газиз Гобәйдуллин вә башкаларның тарихлары өчен Мәрҗани тарихы беренче юл ачты һәм аларга бик күп тарихи материаллар бирде, ышанычлы бер таяныч булып хезмәт итте.

Галимҗан иптәш Ибраһимов үзенең «Аң» журналында язган бер мәкаләсендә (1915 ел, 1 нче сан) Мәрҗанинең тарихка хезмәте, «Мөстәфад»ы турында шушы түбәндәге сүзләрне язып үткән иде: «Гомумән, әсәрдә куәтле иҗат истигъдады[4] ялтырып бара, дини фикердә игътикад[5] турыларында сәләф[6] дип, мәзһәб вә риваять дип гакылын богауларга риза булмаган бөек мөхәкъкыйкне[7] без монда да җиңел таныйбыз, ләкин ике юлда ике төрле эз кала. Дини мәсьәләдә Шиһаб хәзрәт – ватучы, җимерүче. Аның тәбган[8] хөр яратылган куәтле гакылы үзеннән элеккеләр тарафыннан ясалып калдырылган тар рамкаларга сыймый, ул аларны ватып чыга. Тарих бабында исә ул – ватучы, җимерүче түгел, бәлки яңаны ясаучы, үзенә кадәре булмаган нәрсәне тудыручы; китаплар сәхифәсендә – таркау яткан материалны бергә оештырып, аның өстенә карт мукшылар сүзен, иске дәфтәрләрдәге, туфрак астында калган кабер ташларындагы язуларны җыеп, милли тарихыбызга нигез салучы, тагы, кыскасы, тарихыбызның мәүҗидедер[9]».

Мәрҗани тарихы рус, Яурупа гыйлем дөньясында да зурлап, тәкъдир ителеп каршы алынды. Мәшһүр тюрколог профессор Катанов[10] аның беренче бүлем «Мөстәфад»ы турында шушы сүзләрне язып үтте: «Казан галиме Шиһаб Мәрҗанинең әсәре этнографик һәм тарихи мөндәриҗәгә бай. Ул – менә шушы ягы белән рус теленә генә түгел, бәлки башка Яурупа телләренә дә тәрҗемә ите-

---

[1] Хәсәнгата Габәши (1863–1936) – дин һәм җәмәгать эшлеклесе, тарихчы, педагог.

[2] Әхмәтзәки Әхмәтша улы Вәлиди (1890–1970) – башкорт милли хәрәкәте әйдаманы, галим, тюрколог, фәлсәфә докторы, Манчестер университетының мактаулы докторы (1967).

[3] Һади Атласи (1876–1938) – тарихчы, педагог, дин һәм җәмәгать эшлеклесе.

[4] Истигъдады – сәләте.

[5] Игътикад – инану.

[6] Сәләф – борынгы.

[7] Мөхәкъкыйкне – тикшерүчене.

[8] Тәбган – табигатьтән.

[9] Мәүҗиде – язучысы.

[10] Катанов Николай Федорович (1862–1922) – тюрколог, этнограф, фольклорчы.

лерлек бер әсәр. Мөхәррир Болгар һәм Казан патшалыгы турында үзенең биргән мәгълүматларын тәмам фәнни бер юлда төзеп чыгарган»[1].

Кыскасы, татар телен, аның фән әдәбиятын тудыручы, шуның беренче баш ноктасы Каюм Насыйри булса, татар тарих фәненең, тарих әдәбиятының баш чишмәсе, аны тудыручысы да Мәрҗани булды. Татар әдәбият тарихында аның иң зур роле дә әнә шундадыр.

**Педагогия фәне.** XIX йөзнең икенче ярымында кузгалган реформачылыкның иң әһәмиятле бер тармагы тәрбия мәсьәләсе булды. Иске мәдрәсәләр тәрбиясе, иске тәрбия, иске укыту нәзарияләре яраксыз табылды, шуларны яңарту кирәклеге сизелде. Нәтиҗәдә, тәрбия, укыту эшләрен Яурупа педагогиясе, Яурупа методы буенча кую хәрәкәте кузгалды. Шул юлда эшләнгән гамәли тәҗрибәләр өстенә татар дөньясында педагогия фәне тудырылды. Каюм Насыйриның: 1) «Балаларга тәгълим[2] бирмәк» (1882 елгы календарь, 78–79 битләр); 2) «Могыйн әт-дин»[3] ([18]84 елгы календарь, 31–32 битләр); 3) «Бала тәрбия кылгучы хатынларга нәсыйхәт» ([18]90 елгы календарь, 31–40 битләр); 4) «Тәрбия» (1891 елгы календарь, 31–34 битләр) дигән мәкаләләре татар педагогия фәненең һәм татарда шушы фән әдәбиятының беренче мәртәбә салынган нигез ташлары булдылар.

Мәкаләләрдә, чыннан да, шул вакыттагы Яурупа педагогиясе нәзариясенә муафыйк һәм хәзердә дә күпләре йөзгә кызыллык китерми торган тәрбия нәзарияләре, укыту кагыйдәләре язылды[4].

Бу нәзарияләр коры русчадан тәрҗемә генә түгел, бәлки Каюмның күпьеллык гамәли тәҗрибәләренең нәтиҗәсе иде. Ул 1850 елдан ук мөгаллимлек һәм учительлек итә башлый. Ул шул вакыттан ук тәрбиядә гамәли реформачы, яңа методлар белән тәҗрибә күрә башлаучы иде. Ул гомере буенча укытты, дәреслекләр, кулланмалар

---

[1] Известия общества Археологии, истории и этнографии при императорском Казанском университете, том 14, вып. 4, страница 469. *(Кирилл хәрефләре белән язылган)*

Катанов иң элек бу фикерләрен Казан «Археология, тарих һәм этнография» җәмгыятенең 1895 ел, 2 гыйнварда булган гомуми җыелышында шушы әсәр турында (шуның белән бергә «Чыңгызнамә» турында да) укыган докладында сөйли, һәм шул фикерләр, җыелыш тарафыннан тәсдыйк ителеп (*тәкъдим ителеп*), мәҗмугада басылып чыга.

[2] Тәгълим – дәрес, сабак.

[3] «Могыйн әт-дин» – «Дини ярдәмлек».

[4] Тәрбия техникумнарыбызда татар тәрбия тарихы үтелгәндә, беренче гамәли һәм нәзари татар педагогы Каюмның шушы мәкаләләре мотлак укылырга һәм болар тәрбия хрестоматияләренә кертелергә тиешле. *(Авт. иск.)*

язды. Шулар белән бергә татарда педагогия фәне, педагогия әдәбиятын тудырды.

Ләкин тәрбия реформасындагы гамәли хәрәкәттә Каюм ялгыз үзе генә түгел иде. Аның юлында эшләүче аның фикердәшләре, иптәшләре дә бар иде.

**Тәрбия-уку эшләрендә реформа ясауның югары баскычлары.** Башлангыч тәрбиядәге реформа хәрәкәтләре белән бергә урта һәм югары тәрбиядә реформа ясау хәрәкәте дә кузгалды. Бу да гыйльми-тәрбияви реформачылыкның Яурупа мәгънәсе белән тагын да зуррак үлчәүдә Яурупа ысулында урта мәктәпләр ачу юлында күтәрелгән беренче хәрәкәт иде. Бу хәрәкәтнең беренче каһарманы да Каюмның замандашы һәм Мәрҗанинең шәкерте Хөсәен Фәезхани булды. Петербург университетының Шәрык телләре бүлемендә гарәп, төрк-татар телләренең мөдәррисе булган бу реформачы шушы эшне башлады. Үзенең зур проектлары белән соңыннан Казанда – «Мөхәммәдия», Оренбургта – «Хөсәения», Бубыйда – «Бубый», Уфада – «Галия», Троицкида «Рәсүлия», «Әхмәдия» мәдрәсәләре тарафыннан XX йөздә һәм 1905 елгы революциядән соң гына гамәлгә ашыру мөмкин булган урта мәктәпләр, мәдрәсәләр реформасын күтәреп чыкты. Шушы эш артыннан тырышып йөреп күп көч сарыф итте, күп гайрәт күрсәтте. Хөкүмәттән моның өчен рөхсәт алу артыннан чабып йөрде. Ләкин аның бу хәрәкәтенә, шушы проектына ул вакытларда колак салучы, аңар игътибар итүче, ярдәм күрсәтүче булмады. Хәтта дошманнары, моның өчен халык арасында аны руска сатылган дип хәбәр таратып, провокация ясап, халыкны аннан биздерү юлына керделәр; мөселманнар зарарына тырыша дип, өстенә төрле-төрле ялганнар ыргыттылар. Шулай итеп, татар буржуазиясендә кузгалган шушы урта мәктәпләр, мәдрәсәләр реформасы хәрәкәте, ул вакытта бертөрле дә нәтиҗә бирә алмады. Хәзерләнгән зур проект та, гамәлгә аша алмыйча, тик проект кына булып калды.

Татарда уяну, яңару дәверенең вәкилләреннән берсе булган бу галим, шулай итеп, Русиянең үзәк шәһәрләреннән рус-Яурупа гыйлем дөньясы белән бик якыннан очрашып, шуннан татар дөньясына гыйльми-тәрбияви уяну тавышларын бирә башлады. Үз заманының рухы буенча мөселманлыкны нык саклаган хәлдә: «Гыйлем-тәрбия юлында киң үлчәүдә яурупалашу, Яурупа мәдәнияте белән кораллану кирәк», – дип тавыш күтәреп калдырды.

*Фәезханиның кыскача тәрҗемәи хәле*

Хөсәен Фәезхани 1821 елда туып, 1866 елда вафат була. Туган җире – Сембер губернасы Кормаш өязендә Сабаҗай авылы. Башта үз авылында укып, соңра Казанга килә. Анда элек башка берничә хәзрәттән укыгач, ахырда Шиһаб Мәрҗанидән файдаланып, аннан дини, тарихи гали дәресләр ала. 33 яшьләрендә Петербургтан (Ленинградтан) өйләнә[1]. (1916 елларда әле хатыны исән була – «Шура».)

Мәрҗани тәэсире белән булса кирәк, Хөсәен Фәезхани бигрәк тә тарих гыйлемен сөя. Хәтта шул фәндә русча әсәрләрдән файдалану өчен, күп тырышлык белән русча укып, шул телдә «моталәга[2] чыгарган» була. Шуның белән бергә үк ул Казанда рус ориенталистлары белән катышып, аларга язучылык хезмәтен дә үти.

Хөсәен Фәезхани 1853 ел тирәләрендә Петербургка барып, анда университетның Шәрык телләре бүлеменә мөгаллим булып билгеләнә. Анда гарәп телен, бигрәк тә төрк-татар телләрен укыта. Башта айлыксыз[3] буш укытып, соңыннан лекторлык өчен хөкүмәттән айлык ала башлый (айлык ала башлавы 1857 елда була). 1860 елдан башлап авыл халкы катлавыннан һәм салым түләүчеләр катлавыннан чыгарылып, дәүләт хезмәтчеләреннән санала. 1862 елда инде аны университетта Шәрык телләре бүлеменә лектор итеп фәрман чыгарыла.

1896 ел 22 мартта Мәгариф министрлыгы тарафыннан гыйльми хезмәт өчен биш ай мөддәт[4] белән кыргыз сахраларына сәяхәткә җибәрелә. Әнә шушы сәфәреннән кайтып килгәндә, шушы елның 28 августында үзенең туган авылында вафат була.

Хөсәен Фәезхани үзе Император археология җәмгыятендә әгъза була. Аның гыйльми, тарихи хезмәтләре түбәндәгеләр:

1. Икесе – Себердә, берсе Тәтеш өязендә өч кабер ташы таба. Болар турында «Император археология җәмгыяте хәбәрләре» мәҗмугасының 1863 ел 4 нче җилдендә бер мәкалә яза. Шушы мәкаләсендә ул Болгар кабер ташларын тикшерүгә чуваш теле аркылы керешү фикерен башлап рус гыйлем дөньясына ташлый: чувашларның борынгы болгарлар белән тел һәм нәселдә бер-берсенә якын икәнлекләрен, кардәшлекләрен ачып бирә.

---

[1] Бер вакытларда Дума әгъзасы булган Гаскәр Сыртланов белән Равил Сыртланов Хөсәен Фәезхани кызының балалары иде. *(Авт. иск.)*

[2] Моталәга – хөкем.

[3] Айлыксыз – хезмәт хаксыз.

[4] Мөддәт – срок.

2. Төрки телнең сарыф, нәхүен яза[1]. Фәезханиның бу грамматикасы рус телендә үз каләме белән ташбасмада 1862 елда йөз бит зурлыгында басылган була. Аның бу әсәре турында Зәки Вәлиди: «Бу әсәр мотлакан[2] тәкълид[3] юлы белән булмыйча, тәфтиш[4] юлынча язылганлыгы һәм күп җәһәтдән дөрестлеге вә бик әксам (озын да, кыска да түгел) булганлыгы өчен татарча сарыф китаплары эчендә мөһим урынны шөгыльләндерә. Ул бу китапта татарчаның сарыфын вә бик кыска рәвештә нәхүен язган һәм ахырына бик һәйбәт вә җиңел инша вә туры имля илә тәмрин[5] өчен берничә төркичә мәкаләләр дәрҗ[6] иткән[7]», – ди. (Аның бу гамматикасын күрә алмаганыбыз өчен, бу турыда, гәрчә Вәлиди бер филолог булмаса да, аның сүзен күчереп үтүне бу урында тиеш күрдек.)

3. «Кырым йортына вә ул тарафларга даир[8] ярлык вә хатлар». Бу әсәре дә аның иң мөһим, олы әсәрләреннән санала. Аның 941 бит зурлыгында тәрҗемә-фәләннән башка тик төркичә басылган бу әсәре, шуңар берничә юллык русча мөкаддимә язганлыгы өчен, академик Вельяминов-Зернов[9] исеме белән мәшһүр булып киткән.

4. Тарих хакында вә Русия мәдрәсәләре турысындагы әсәре. Аның бу әсәре турында Риза казый: «Кәнди вафатындан соң заигъ улдыгы мәрвидер»[10], – ди. («Асар», 2 нче җилд, 14 нче җөзьэ.)

---

[1] Шиһаб Мәрҗанигә язган бер хатында ул: «Бер-ике айдан бирле лисанымыз булган төрки теленең кавагыйде сарфия вә нәхвиясене шәкердләремез өчен русча язып шөгыльләндем. Һәфтә-ун көндән *(атна-ун көннән)* хәтем *(тәмам)* булса кирәк. Моннан соң билвасыйта *(кеше ярдәме белән)* рисаләи мәгъһүдәне *(вәгъдә иткән китапны)* табйиз кылырга *(акка күчерергә)* тотынам», – ди («Шура», 18 нче сан, 1916 ел). Тагын Мәрҗанигә моннан ел соң (1865 тә) язган икенче бер хатында: «Шул үз лисанымызның кавагыйде нәхвия һәм сарфиясендә бер китап язып идем. Укыганым саен төзәтергә вә я мәхү вә исабәт *(бозарга һәм төзәтергә)* итәргә хаҗәт күренә; ул һәм бераз вакытымны аладыр, ул бер нәүгый *(яңа)* һөнәр булып, гайреләргә бер дә тәкълид итми *(иярмичә),* хәтта анларның китапларына назар *(караш)* салмый тәртип кыйлдым. Шәкертләремез тәхсин кыйлалар *(мактыйлар). (Авт. иск.)*

[2] Мотлакан – шиксез.

[3] Тәкълид – иярү.

[4] Тәфтиш – эзләнү.

[5] Тәмрин – күнегү.

[6] Дәрҗ – теркәү.

[7] «Шура». 16 нчы сан, 1912 ел. *(Авт. иск.)*

[8] Даир – караган.

[9] Вельяминов-Зернов Владимир Владимирович (1830–1904) – рус шәркыятчысы, тарихчы-нумизмат, археолог. Хезмәтләре Россиядә яшәүче Шәрык халыклары тарихына һәм мәдәниятенә карый. Дүрт китаптан торган «Касыйм ханнары һәм ханзадәләре турында тикшерү» («Исследование о Касимовских царях и царевичах», 1863–1887) исемле хезмәт һәм төрки лексика сүзлекләре авторы.

[10] «Үзе вафатыннан соң [бу әсәре] юкка чыгуын сөйлиләр».

Хөсәен Фәезхани Шиһаб Мәрҗанинең иң якын күргән һәм аның иң яраткан шәкертләреннән, дусларыннан булган. Һәр турыда ул Мәрҗанинең уң канаты саналган. Петербургтан ул үзенең хатлары белән Мәрҗанине Русия һәм Яурупадагы гыйльми хәрәкәтләрдән, гыйльми эшләрдән хәбәрләндереп торган. Аның Мәрҗани белән хатлашуы еш булып тору өстенә һәм һәрвакыт гыйльми, иҗтимагый мәсьәләләр турында җитди язылганнар. Ул кайчагында Мәрҗанине тәнкыйть иткәләп тә ала. Аның Мәрҗанигә язган хатлары белән танышу өчен «Шура»ның 1916 елдагы 14, 15, 16, 17, 18, 19 нчы саннарына, аның тәрҗемәи хәле белән тәфсилләп танышу өчен дә «Асар»ның 2 нче җилд, 14 нче җөзьэнә карарга мөмкин.

### 3. Дин реформасы – дини уяну

Иске дин кысынкылыгына каршы XIX йөзнең икенче ярымында татар дөньясында башланган реформачылыкның, уяну-яңаруның өченче тармагы *дини реформачылык* булды. Моның нидән гыйбарәт булуын, ул вакыттагы әһәмиятенең дәрәҗәсен ачык аңлау өчен, татарның шушы йөзнең икенче ярымына килеп аяк басканда дини яктан нинди фикердә, нинди игътикадта[1] булуына бер күз ташлап үтү җитә. Шул вакытларда татар дөньясы һәртөрле дини хорафат, фикер тоткынлыгы, чиксез бер дини тәгассеб[2], бөтен руханиларга, ишаннарга сукырларча тәкълид[3] астында баш-аягы белән күмелеп калган, шулар тоткынлыгында изелүнең дә чигенә җиткән иде. Бөтен нәрсәне тәкъдиргә тапшыру да татар игътикадының үзәгендә иде.

Кыскасы, татарның иске Мәскәү патшалыгы тарафыннан Казан алынганнан соң та[4] XIX йөзнең соңгы ярымына кадәр сузылган *караңгылык заманнарында* татар дөньясының миен, йөрәген, акылын һәртөрле кара фикерләр, бозык карашлар каплап килде. Татар дөньясы шулар белән томаланып, аяк-кулы багланып калды. Урта Азия – Бохара белән мөнәсәбәт башланып, татар руханилары аннан тәрбия алып кайта башлагач, алар аркылы татар дөньясында шушы кара фикерләр тагын да нык куәт алып китте.

Татарның төрле икътисади сәбәпләр белән яңалыкка, яурупалашуга, җәдитләнүгә омтылуына, әлбәттә, бу карашлар, бу фикерләр

[1] Игътикадта – инануда.
[2] Тәгассеб – фанатиклык.
[3] Тәкълид – ияру.
[4] Та – башлап.

каршы килә иде. Болар аңа бик зур куркыныч, кара дивар булып тора иде. Шуның өчен татар реформациясе менә шушы дини иске карашларның кысынкылыгын әкренләп җимерә башлауны, шуларны төзәтү юлына керүне кирәксенде. Шуларны төзәтеп, үзенең тормышындагы яңалыкларны дин, Коръән белән татбикъ итеп[1], аның белән килештереп, яраштырып, дингә каршы түгел иттереп алып барырга азапланды. Үзенең дөньяви яңалыклары дингә сыя икәнен күрергә, күрсәтергә көчләнеп маташты.

Бу караңгылыкка, бу туңлыкка каршы көрәшнең беренче үткен чаткысын без XIX йөзнең башларында ук Курсави аркылы күреп үткән идек.

Ләкин ул әле бу караңгылыкка каршы бераз үз вакытыннан иртәрәк күтәрелгән бер чаткы иде. Шуның өчен татар дөньясында аның тәэсире, нәтиҗәләре нык җәелеп китә алмады, буылып калды.

Әмма XIX йөзнең яртыларында инде татарның икътисади торышы, үсүе, икътисади яңаруы әлеге каралыкларга, караңгылыкларга каршы аңар чынлап тәэсир итәрлек бер рәвештә ныклап күтәрелүнең зәмин-туфрагын хәзерләп өлгергән иде. Инде икътисади хәзерлек һәм капитал көче аркылы күтәрелүнең тарафдарлары да күп табылачак иде.

Нәтиҗәдә, «бөтен ислам дөньясын каплап, бөтен табигатьне караңгы зиндан ясап, авыр таш булып басып яткан бу калын тимер каплау XIX гасырның яртыларына таба төрле җирдән чатный-ярыла башлады».

**Дин реформасы хәрәкәтендә Мәрҗани.** Менә шушы куркыныч кара диварны җимерергә башлаучы, әллә ничә йөз еллар буенча калынлыгын һаман арттырып, киткән саен куркынычлана килгән шушы караңгылыкны бөтен куәте белән яктыртучы көчнең берсе, югарыда әйтелгәнчә, әдәби тел, гыйлем һәм тәрбия ягыннан Каюм Насыйри иде, дини реформатор да Шиһаб хәзрәт Мәрҗани булды. Әлеге караңгылыкның «басуына чыдый алмый җимереп өскә чыга башлаган кыю ирләр»нең икенчесе һәм татар дөньясында үз вакытында җитешкән «дин каһарманлары»ның да тәэсирлесе ул булып чыкты. «Курсави бездә бу ирләрнең беренчеләреннән» иде. «Ләкин аның мохиттә тудырган тәэсире ким булды. Мәрҗанидә исә без инде үз эшендә гаюр (гайрәтле) бер каһарман күрәбез». Мәрҗани-

[1] Татбикъ итеп – чагыштырып.

нең дини-гыйльми әсәрләре аркылы татар дөньясында Курсави нигезендә түбәндәге нәрсәләргә юл ачылды:

1. Иҗтиһад ишеге һәркемгә ачык (ягъни дини мәсьәләләрне Коръән буенча һәркем үзе тырышып, үзе эзләп, үз акылы белән уйлап табарга тиеш).

2. Тәкълид (башкаларга сукырларча иярүчелек) мотлакан бетәргә тиеш.

3. Мәдрәсәләрдән кирәкмәгән файдасыз иске схоластика китапларын чыгарырга кирәк.

4. Мәдрәсәләргә Коръән, хәдис, тарих (ислам тарихы) кертергә.

5. Фән, рус телен укырга карышмаска.

6. Мөселманнарны, Мөхәммәд өйрәткәнчә, ислам нигезендәге икътикадка утыртырга, аларны борынгы ислам мәдәнияте нигезендә яңадан мәдәниләштерергә.

Шиһаб Мәрҗани, үзенә каршы күтәрелгән күп көчле дошманнары булуга карамастан, аларга каршы әнә шушы таләпләр белән күтәрелеп чыгып, дини искелеккә, тәгассебкә каршы шәфкатьсез бер көрәш ачты. Үзенең мәдрәсәсендә, шәкертләре арасында дәресләрен шушы юлдан алып барган шикелле, икенче яктан, бөтен әсәрләрендә руханилар, шәкертләр арасына шул фикер, шул карашларны ахыр гомеренә кадәрле таратып барды. Дөнья куптарып, шул турыда муллалар бик зур шау-шу күтәрделәр. Шуңа карамастан, Мәрҗани байлар һәм галимнәрдән, руханилардан үзенә күп кенә тарафдарлар ясады, бу юлда көрәшне дәвам иттерүче көчле бер идеология гаскәре төзеде.

Бу хәрәкәт тә, соңыннан татар буржуазиясенең көчәя баруы дәрәҗәсендә, Рәшид[1] һәм Риза казыйлар, Галимҗан Барудилар[2], Мусалар[3], Зыялар[4] тарафыннан да Октябрьгәчә киңәйтелә, нык

[1] Рәшит Ибраһимов (Габдерәшит Гомәр улы Ибраһимов, 1857–1944) – дин, җәмәгать һәм сәясәт эшлелесе, публицист, нашир.

[2] Галимҗан Баруди (Галимҗан Мөхәммәтҗан улы Галиев, 1857–1921) – дин һәм җәмәгать эшлеклесе, нашир, җәдитчелек хәрәкәтен нигезләүчеләрнең берсе. Казанда 1882 елда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен ача, аның мөдәррисе була. 1891 елдан ул җитәкләгән мәдрәсәдә яңа ысул белән укыту кертелә, дөньяви фәннәрдән дә дәресләр бирелә башлый. «Әд-дин вә әл-әдәб» журналы нашире һәм мөхәррире (1906–1908, 1913–1917).

[3] Сүз дин галиме, публицист, җәмәгать һәм дин эшлеклесе Муса Бигиев турында бара.

[4] Зыя Камали (Зыяэтдин Җамалетдин улы Камалетдинов, 1873–1942) – мәгърифәтче, фәлсәфәче, дин һәм җәмәгать эшлеклесе, тәрҗемәче, мәдрәсә мөгаллиме, «Галия» мәдрәсәсен оештыручы һәм аның җитәкчесе (1906–1918).

тамырландырыла барылды. Татар буржуазиясе яңалыкны – дингә, динне яңалыкка татбикъ итүдә шушы соңгы дин каһарманнарыннан үзенә таяныч таба торды.

*Мәрҗанинең кыскача тәрҗемәи хәле*

Шиһабетдин Мәрҗани 1818 дә, 3 гыйнварда (искечә) дөньяга килә. Вафаты 1889 ел, 18 апрельдә. Әтисе Бәһаэтдин карт та Япанчы авылының имамы – хәзрәт (соңыннан Ташкичүгә күчә). Карт бабалары Казан тирәсендә Мәрҗан авылыныкылар. Аның үзенә Мәрҗани дигән сөялмә ат куюю шуның өчендер. Мәрҗанинең нәселе бер яктан Казанның зур байларына (Апанаевларга) барып баглана.

Мәрҗани яшьтән әтисе мәдрәсәсендә укый һәм 16 яшеннән башлап шул мәдрәсәдә хәлфәлек кыла. Ул яшьтән үк, шул мәдрәсәдә укыган чагында ук, китап моталәга кылуга һәвәсле булу өстенә, үзендә һәрнәрсә турында үзлекле һәм тәнкыйди караш сиздертә барган.

XVIII һәм XIX йөздә татар руханилары өчен гыйлем үзәге Бохара дип танылганга күрә, Мәрҗани 1838 елда егерме бер яшендә шунда китә. (Ләкин юлда Троицк шәһәрендә бераз тукталып, казакъкыргызлар арасында сату итеп, юллык акча хәзерләп алган була.) Бохарага баргач, андагы мәдрәсәләрнең укуларын, андагы схоластика методларын яратмый. Шуның өчен ул анда тик Бохараның иске бай китапханәләренә йөреп, үз-үзеннән гыйлем алырга тотына. Шулардагы тарих китапларыннан файдалана башлый.

Бохарада биш ел торгач, ул вакытларда Урта Азия гыйлем үзәкләренең икенчесе саналган Сәмәркандка килә. Анда казый Әбү Сәгыйть исемле бер галимнән файдалана. Бу галим үзенең бик бай китапханәсен тәмам Мәрҗанинең ихтыярына куя. Хәтта Мәрҗанинең тарих белән шөгыльләнеп китүенә, тарих китапларын укырга, тикшерүгә бирелүенә дә, Мәрҗанинең үз сүзләренә күрә, шул ук казый Әбү Сәгыйть баш сәбәп була.

Мәрҗани, Сәмәркандта ике ел торгач, тагын Бохарага китә, анда янә дүрт еллар чамасы тора. Соңыннан, 1849 елда Казанга кайта. 1850 елда указ алып, беренче мәхәллә мәчетенә мулла булып, 40 ел (үлгәнче) шунда имамлык кыла һәм мәдрәсә тотып дәрес әйтә. Үзенең хөр фикерлелеге, тәнкыйтьчелеге, каты теллелеге сәбәпле ике мәртәбә муллалыгыннан чыгарылган булса да, соңыннан шул урында ныгып кала һәм 1877 елда ахунд, мөхтәсиб була.

Мәрҗанинең тәфсилле тәрҗемәи хәле белән танышырга теләүчеләр аның «Мөстәфад»ының икенче бүлемендә үзе язган тәрҗемәи хәленә (42–60 битләр) һәм «Мәрҗани мәҗмугасы»на кайтып карарлар.

Мәрҗани Казандагы Учительский школада тугыз ел дин укыта. 1880 елда хаҗга барып, Гарәбстан һәм Төркиядә сәяхәт итеп кайта.

Мәрҗани Казандагы мөстәшрикълар (ориенталистлар) белән таныша, аралаша. Археология җәмгыятьләренең җыелышларына йөри.

Мәрҗани әллә ничә җилдлек тарихи, фәлсәфи күп әсәрләрен гарәпчә язган. («Мөстәфад»та үз тәрҗемәи хәлен язган урында барысы егерме дүртләп гарәпчә әсәре санала.) Үзе – гарәп телендә бик оста язучыларның берсе. Аның дини мәсьәләләрдәге тәнкыйди карашлары күбесе һәм төпплеләре шул гарәп телендәге әсәрләрендә язылган. Шул әсәрләре аркылы ул мөселман руханилары (бигрәк тә татар руханилары) арасында дини-фикри дулкын, дини бер яңару тудыра.

Татар телендә (дөресе төрки+татар телендә) язган әсәрләре ялгыз «Мөстәфад»лары белән 1897 елда Риза казый тарафыннан нәшер ителгән «Рихлә»сеннән[1] гыйбарәт. Болардан башка тагын Мәрҗани «Мөстәфад»ында «Китабе төркийә фи мәнәсик әл-хаҗ»[2] вә «Рисаләт охра төркийә»[3] дип, ике төрки китабын санаса да, без аларын күрә алмадык. Аның әсәрләрен төркичә язмавының да бер сәбәбе төрки телен ярлы телдән санавы булса кирәк. Чөнки ул мулла булып сайлануыннан элек, Казанда Ибраһим байның чакыруы белән Мәрҗанине имтихан кылып карар өчен, руханилар мәҗлесе ясала. Әнә шунда Мәрҗанинең гарәпчәләтеп сөйләвен яратмыйча, Мөхәммәд Кәрим дигән бер хәзрәт: «Юк, минем әле хаҗ кылганым юк, мин әле гарәби белмимен, миңа төрки гыйбарәт берлә әйт», – дип аңа каршы төшә. Мәрҗани дә аның шул игътиразыннан көлеп: «Гаҗәбән, лисане төрки мин әкъсарилләлсинә вә әбгадиһа ган истыйляхатил голум булса, аны ничек төрки тәгъбир кыйлмак кирәк[4]» дип җавап кайтара. Мәрҗанинең «Мөстәфад»ының гарәпчәләр белән артык чуалтып бетерелүнең дә бер мәгънәсен менә шуннан эзләргә кирәк булыр.

## 4. Җәдитчелек хәрәкәте һәм ысулы саутия

**XIX йөзнең икенче ярымының башларында татар дөньясында әдәби тел, фәннәр**. Тәрбия-укыту һәм дини мәсьәләләр турындагы реформация-ислах хәрәкәтләренең ничек һәм кемнәрнең юлбашчылыгы белән башланып киткәнен югарыда күреп үттек. Бу

[1] Ш. Мәрҗанинең шәкерте һәм аның эшен дәвам иттерүче Р. Фәхреддин 1897 елда аның хаҗ сәфәре белән бәйле «Рихләт әл-Мәрҗани» («Мәрҗанинең сәяхәте») исемле юлъязмаларын шәрехли һәм бастырып чыгара.

[2] «Хаҗ гамәле турында төрки телдә китап».

[3] «Башкача төрки китаплар».

[4] «Мөстәфад әл-әхбар», икенче бүлем, 46 бит. *(Авт. иск.)*

хәрәкәт гомумән Русиядә һәм татар дөньясында туган икътисади үзгәрешләр нигезендә һәм шуларның тәэсирләре белән кузгалган бер уяну, яңару – «җәдитләнү» хәрәкәте иде.

Менә бу хәрәкәт шушы йөзнең дүртенче чиреге эчендә яхшы ук үсә, киңәя башлады. «Ысулы җәдит» хәрәкәте исеме белән шау-шу күтәреп, татар дөньясының күп почмакларына таралу, таратылу юлын алды.

Бу да татар башлангыч мәктәпләренә «ысулы саутия» (звуковой метод[1]) кертелеп, иҗек ысулына каршы көрәш ачу белән шаулап китте. Чөнки бу ысул әле татар дөньясында бөтенләй яңа бер эш иде. Аңарча Каюмнар аркылы хисап, һәндәсә, җәгърафия, тарих кебек фәннәр укытыла башлаган һәм шул ук фәннәр мәктәпләр программына кертелү юлы ачылган булса да, әлифба укыту мәсьәләсендә Каюмнар саутияче түгел, бәлки хәрфияче (букво-слогательный метод[2]) яисә иҗекчеләр (слоговой метод белән баручылар) иде. Карт, аңлапмы, аңламыйчамы, бу мәсьәләдә аңарча үзебездә, русларда килгәнчә, хәрфия-иҗек ысулын алган, саутия ысулын башламаган иде. Шуның өчен саутия ысулы татар өчен үзе яп-яңа бер нәрсә булып чыкты. Иҗек ысулына каршы бу яңа ысул каты бер көрәш хәрәкәтен алды. Шулай ук бу ысул саутиягә бәйләп, Каюмнар тарафыннан башланган фәннәрнең татар башлангыч мәктәпләре программнарына кертелү хәрәкәтләрен гомумиләштерү, киңәйтелү эшләре кыздырылды. Ахырда бу гомуми бер агым хәленә әйләндерелде.

Кадимчелек, җәдитчелек низаглары нык баш күтәрде. Төрле шәһәрләрдә шул ук «ысулы саутия» исеме белән әлеге фәннәрдән балаларга башлангыч мәгълүматлар бирелә торган мәктәпләр ачыла башлады. Халык арасында әле бөтенләй яңа булган шул әлифба укытудагы яңа ысул (ысулы саутия) уңае белән бу мәктәпләр дә «ысулы җәдит мәктәпләре» дип (тагын да кыскача «ысулы җәдит» дип) мәшһүр булып китте. Бу хәрәкәт тә шуннан башлап «ысулы җәдит хәрәкәте» исемен алды. Югыйсә Яурупа фәннәрен ала башлау мәгънәсе белән булган җәдитлек һәм, гомумән, тәрбия-укыту эшләрен яурупача кую мәгънәсендәге ысулы җәдит хәрәкәте исә болай XIX йөзнең дүртенче чиреге эчендә генә түгел, бәлки югарыда әдәби тел, фәннәр, дин турыларында сөйләгәннәребездән аңлашылып үтелгәнчә, XIX йөзнең икенче ярымының башла-

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[2] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

рында ук башланган иде. Ялгыз әле ул вакытта бу хәрәкәтнең ике җитешмәгән ягы булды: бердән, әле ул җәдитлек хәрәкәте үзенең үсү-киңәю юлын башлый алмаган, икенчедән, әлифба укытуда әле ул иҗек ысулынча калынган, саутия ысулы кертелә алмаган иде.

Әлифба укытуда ысулы саутия кертелү һәм әлифбаны шул ысул белән укыта торган мәктәпләр ачыла башлау белән теге Каюмнар башлаган Яурупа фәннәрен укыту мәгънәсендәге җәдитчелек хәрәкәте дә гомумиләшеп көчәеп китте.

Кыскасы, ысулы җәдит хәрәкәте бездә уку-укыту эшләрендә киң реформация мәгънәсе белән XIX йөзнең икенче ярымының башларында ук Каюмнар, Хөсәен Фәезханилар белән башланган иде. Әмма шушы хәрәкәтнең тагын да бер үсә төшкәнрәк, киңрәк үлчәүдәгесе – әлифба укытуда саутия ысулы белән булганы шушы йөзнең дүртенче чиреге эчендә генә башланды.

**Ысулы җәдит хәрәкәте һәм Гаспринский.** Менә татар дөньясындагы реформа кузгалышларында шушы соңгы, тулырак мәгънәсе белән булган хәрәкәттә – ысулы саутия хәрәкәтендә беренче юлбашчылыкны Кырым мирзаларыннан Исмәгыйль Гаспринский күрсәтте. Төрк-татар дөньясында беренче мәртәбә саутия ысулы белән укыта торган мәктәпләр ачып, шуның беренче башлангыч үрнәген бирде. Аның 1883 елда чыгара башлаган «Тәрҗеман»ы шул ысулны халык арасына таратуда беренче көчле коралы булды. Анда ул һаман шул турыда кирәкле фикерләр, киңәшләрне бирә торды. Шуның белән, гомумән, ысулы җәдит хәрәкәтенә дә нык көч биреште. Кыскасы, татарның үз телендә һәм Яурупа фәннәрен татарларга укытырга керешү һәм шул фәннәрдән дәреслекләр, кулланмалар яза башлау мәгънәсе белән татар дөньясында беренче ысулы җәдит мөгаллиме булган Каюм Насыйри шул юлда бил буып, гамәли һәм нәзари яктан нык эшкә керешкән чагында әле дөньяга килмәгән Гаспринский (1851 елда туа), шулай итеп, соңыннан, [18]83 еллардан башлап, үзенең «Тәрҗеман»ы аркылы шушы хәрәкәтнең бөтен Русия мөселманнары эчендә авангарды булып мәйданга атылды. Шуны киңәйтү юлында нык, көчле бер көрәш, сугыш ачты. Ахырда ул ысулы җәдит, ысулы саутия хәрәкәтен бөтен татар дөньясында зур, көчле бер агым хәленә әйләндереп җибәрүдә баш командан кебек булып барды. Бу гәзит Казан татарларының ул вакыттагы зыялылары, бигрәк тә руханилары арасында да байтак

тарала башлагач, алар арасында бу хәрәкәтнең көчәюенә, тамырланып китә алуына зур тәэсир ясады.

Ул бу турыда гәзите аркылы фикер тарату, ысулы саутиягә димләү белән генә калмады, бәлки Бакчасарайда башлап шул ысул белән укытуда гамәли үрнәк күрсәтте, үзе башлап беренче мәртәбә ысулы саутия мәктәбе ачты. Шунда барып, Идел, Урал буе татарлары да бу яңа ысулдан үрнәк алып кайттылар. Һади Максуди кебек педагог-мөхәррирләребез шулар җөмләсеннән иделәр. Ләкин бу педагог-мөхәррир әлифба укытуда остазының ысулы – ысулы саутия белән китмичә, иҗек-мәддия ысулын татар дөньясына башлап таратты.

Шулар өстенә тагын Гаспринский, һәр ел Мәкәрҗә ярминкәсенә килеп, шул турыда татарлар-мөселманнар арасында фикер тарата. Хәтта Бакчасарайдагы үрнәк мәктәбендә укытучы беренче ысулы саутия мөгаллимен 1887 елда Ханкирмән (Касыйм) шәһәренә җибәреп, анда икенче бер үрнәк ысулы саутия мәктәбе ачтырта. Шуның тәэсире белән Нижний, Тамбов, Пенза татарлары арасында да ысулы саутия тарала башлауга юл ачкан була.

Тагын Гаспринский 1893 елда Сәмәркандка барып (гайре рәсми рәвештә), «татар сәүдә капиталы корольләре» булган Хөсәеновларның – Габделгани бай Хөсәеновның өендә дә ысулы саутия мәктәбе ача (бу мәктәп Урта Азиядә, үзбәкләр арасында «машина мәктәп» дип аталып китә) һәм икътисади эшләрдә, сәүдә мәсьәләсендә җәдитләнеп, яурупалашып баручы үткен акыллы бу байга юл күрсәтешә, киңәш бирешә.

**Татар буржуазиясе ысулы җәдит хәрәкәтендә юлбашчылыкны үз кулына ала.** 1890–1900 еллар арасында татар дөньясында ысулы җәдит хәрәкәте яхшы ук кыза. Бу вакыт эчендә бу хәрәкәткә юлбашчылыкны татар буржуазиясе үз кулына ала башлый. Икътисади тормышта яурупалашып, җәдитләнеп барган татар буржуазиясе бу хәрәкәткә көч бирүдә, аңа юлбашчылык итүдә үзенең зур икътисади һәм иҗтимагый файдаларын күрә. Моның аркылы татар буржуазиясе татар җәмәгать эшләренә катышып, ул эшләрне үз кулларына алып, халыкны үз тәэсирләре астына ныграк кертә башлыйлар. Бу эш аларның сәүдә эшләренә дә күп рәваж[1]

[1] Рәваҗ – уңыш.

бирә[1]. Себердә – Нигъмәтулла хаҗи[2], Казанда – Әхмәд бай[3], Оренбургта – Гани бай[4], Шакир Рәмиевләр[5], Сембердә – Акчуриннар һәм Уфадагы бәгъзе байлар шул юлда зур тәэсирле хәрәкәт күрсәтәләр.

Шуның өстенә моның белән татар буржуазиясенең үзенең сыйнфый идеологиясе татар мәктәпләрендә нык нигез сала башлый. Татарның бөтен зыялы сыйныфлары, мөхәррир һәм мөгаллимнәре турыдан-туры буржуазия тәэсире астына төшә. Татар руханилары да икегә аерылып, җәдитче, тәрәккыйче булганнары либераль буржуазия ягыннан шул нигездә яңа тәрбия, яңа идеологиядә гыйльми юлбашчы, мәдәни таяныч булып баралар. Башында мөфти торган хәлдә Мәхкәмәи шәргыя[6] әгъзалары булган казыйлар да, аның муллаларга, халыкка сүзе үтемле ахундлары да татар капиталының, татар байларының шушы юлдагы тәэсире астына керәләр. Рәшид, Риза казыйлар, Фатих Кәриминең әтисе Гыйльман

[1] Җөмләдән, мәсәлән: «Борадәран Хөсәеновларның, хосусан Әхмәд илә Габделганинең җәмәгать эшләрендә күп йөрүләре аларның фирмасына зур рәваҗ биргән. Халык арасында игътибарлы булуның сәүдәдә һәрвакыт зур ярдәм иткәнлеге мәгълүм. Банклар һәм вексельләр хаким булмаган базарларда исә боларның тәэсире мисалсыздыр. Мәсәлән, Казалыда бик күп сәүдәгәрләр акчаларын, казначейстvoга салган кебек, Гани байга амәнәт итеп куйганнар. Бу амәнәтнең 40–50 мең сумларга җитешкәне дә аз булмаган. Хөсәенов конторалары Төркестан белән Оренбург арасында акча переводына да күп хезмәт иткән. Кәрван юлына акча йөртәсе килмәгән кешеләр, акчаларын Казалыда, Ыргызда Хөсәенов конторына биреп, Оренбург яки Мәкәрҗәгә килеп акча алалар икән (Борһан Шәрәф. «Гани бай» китабы. 17 бит, 1913 ел). *(Авт. иск.)*

[2] Нигъмәтулла хаҗи Сәйдуков-Кармышаков (1829–1901) – 2 нче гильдияле сәүдәгәр һәм хәйрияче. XIX гасыр азагында себер татарларына белем бирүдә зур өлеш керткән шәхес.

[3] Әхмәт Мөхәммәтгали улы Хөсәенов (1837–1906) – Оренбург һәм Казанның 1нче гильдияле сәүдәгәре. 1861 елда бертуганнары белән сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы товарлары сәүдәсе алып барган «Әхмәт Хөсәенов һәм борадәрләре» фирмасын нигезли. Оренбург, Казанда мохтаҗларга ярдәм итү буенча төрле җәмгыятьләрнең эшендә катнашу белән беррәттән, аның ярдәме белән «Хөсәения» мәдрәсәсе, Оренбургта һәм Оренбург губернасында егермеләп мәчет төзелә. Вафатыннан соң 500 мең сумнан артык акчасын хәйрия эшенә (мохтаҗларга сәдака тарату, укытучыларга хезмәт хакы, яшьләрне укытуга стипендияләр түләү, «Хөсәения» мәдрәсәсен тоту һ. б.) васыять итә. Хәйрия капиталы белән идарә итү өчен Ә. Хөсәенов исемендәге попечительләр шурасы (1906–1917) оештырыла.

[4] Габделгани Мөхәммәтгали улы Хөсәенов (1839–1902) – Казалы шәһәренең 1 нче гильдияле сәүдәгәре. 1897–1902 елларда аның тарафыннан Оренбург өлкәсе авылларында йөзләп яңа ысуллы уку йортлары, егермедән артык хатын-кызлар мәктәпләре ачыла. Фатыйма Әдһәмованың хатын-кызлар мәктәбен финанслый.

[5] Мөхәммәдшакир Мөхәммәдсадыйк улы Рәмиев (1857–1912 елның 15 марты) – 1 нче гильдияле сәүдәгәр, алтын приискалары хуҗасы.

[6] Мәхкәмәи шәргыя – Эчке Русия һәм Себер мөселманнарының дини эшләрен караучы идарә.

ахундлар[1], Галимҗан Барудилар, Уфаның Хәйрулла Госманыйлар[2], Хәсәнгата Габәшиләр шул юлда татар буржуазиясенең нык гыйльми вә иҗтимагый таянычлары, фикри ярдәмчеләре булалар. Башларында Гаспринский торган хәлдә, Фатих Кәримиләр[3] бу хәрәкәткә тон биреп бара башлыйлар. Боларга Һади Максудилар, Учительский школа мөгаллимнәреннән Шакирҗан Таһири[4] кебекләр, шул ук мәктәпнең шәкертләреннән Гаяз Исхакыйлар килеп кушылып булышырга тотыналар.

Җәдитчелек хәрәкәтендә татар капиталының төп урыннары булган Казан, Оренбург, Уфа, Троицк шәһәрләре зур эшчәнлек күрсәтеләр. Либераль татар буржуазиясенең юлбашчылыгы һәм матди ярдәме астында бу шәһәрләрдә, [18]60 елларда, Фәезханилар уйлаганча, яңа типтагы мәдрәсәләр тудырыла башлый. Шулар янында башлангыч ысулы җәдит мәктәпләре ачыла бара.

[1] Гыйльман Ибраһим улы Кәримов (1841–1902) – дин эшлеклесе, нашир. Урта Идел буенда җәдит мәдрәсәләре оештыручыларның берсе, дәреслекләр авторы. 1899 елда дини эшчәнлектән ераклашып, китап басу эше белән шөгыльләнә башлый. 1900 елда Оренбург шәһәрендә зур булмаган басмаханә сатып ала. Гомуми тиражы 52,4 мең данә булган 27 исемдә китап бастыра. Кәримовның наширлек эшчәнлеген аның улы Фатих Кәрими дәвам итә.

[2] Хәйрулла Госман улы Госманов (1848–1907) – дин эшлеклесе. 1888 елдан Уфадагы 1 нче җамигъ мәчеттә имам хатыйб, 1890 елдан – ахун. Уфадагы «Госмания» мәдрәсәсенә нигез салучы һәм аның мөдәррисе (1906 елга кадәр). 1895 елдан биредә яңача уку ысулын (җәдитчелек) кертә. Җәдиди мәктәпләр өчен татар телендә гарәп теле дәреслеген башлап төзегән авторларның берсе. 1906 елдан Оренбург мөселман диния нәзарәтендә казый. Җәдитчелекнең урталык сәясәтен тотучы агымына кушыла. Исламны яңарту идеяләрен яклый.

[3] Фатих Гыйльман улы Кәрими (1870–1937) – язучы, нашир, җәмәгать эшлеклесе. 1902 елдан, атасы вафатыннан соң, «Кәримов, Хөсәенов вә шөрәкясе» басмаханәсе белән җитәкчелек итә. 1906 елдан «Иттифак әл-мөслимин» партиясе Үзәк комитеты әгъзасы була, 1906–1917 елларда – «Вакыт» газетасы баш мөхәррире, 1917 елда – Оренбург мөселманнары бюросы рәисе. Бөтенроссия мөселманнары корылтайларына (1905, 1906, 1914, 1917), 1917 елның маенда 1 нче Бөтенроссия мөселманнары корылтаенда Оренбург делегатларыннан Милли Шура әгъзасы итеп сайлана.

[4] Шакирҗан Әхмәтҗан улы Таһиров (1858–1918) – педагог, хаттат, рәссам, статский советник. 1883 елда Ш. Таһири, татарлардан беренче булып, Санкт-Петербург Сәнгать академиясеннән башлангыч мәктәпләрдә рәсем дәресе укытырга хокук бирүче таныклык ала. Ш. Таһири татар мәгарифе үсешенә сизелерлек өлеш кертә, төп игътибарны туган телне үстерүгә һәм сынлы сәнгатькә тискәре мөнәсәбәтне бетерүгә юнәлтә. Шәхси акчасына рус-татар училищесы бинасы төзи, Ләбибә Хөсәения мәктәбен оештыруда катнаша. К.Д. Ушинскийның педагогика ысуллары юлыннан бара, рус телен өйрәнү өчен беренче методик кулланмалар әзерли. Рус һәм чит телләрне уңышлы үзләштерү өчен укучыларга туган тел грамматикасын белү кирәк дип саный, шуның белән татарларны ассимиляцияләүгә юнәлдерелгән рәсми империя сәясәтенә объектив каршы тора. Ш. Таһири укучылары арасында күренекле шәхесләребездән Г. Исхакый, Г. Коләхмәтов, М. Корбангалиев, М. Солтангалиев, М. Фазлуллин, Х. Ямашев һәм башкалар бар.

Казанда – мәдрәсәи «Мөхәммәдия», Оренбургта – «Хөсәения», Троицкида – «Мөхәммәдия», «Рәсүлия», Уфада «Госмания» шундый мәдрәсәләрдән булалар.

Казан «Мөхәммәдия»сендә җәдитчелек хәрәкәте, шул мәдрәсәнең баш мөдәррисе Галимҗан Барудиның саутия ысулыннан башкасында консерваторлыгына карамастан, шул ук Насыйрилар, Фәезханилар белән башланган агымнар тәэсире белән киңәеп, һаман үсә бара. Чөнки Фәезханилар, Каюмнар җәдитлеге – дөньяви җәдитлек һәм бу юлда нәзари яктан да, гамәли яктан да либераль буржуазия теләгәнчә, либераль бер хәрәкәт иде. Әмма Барудиларныкы татар буржуазиясенең тәрәккыйсен чикли торган, тик дини бер җәдитлектән генә гыйбарәт булды. «Мөхәммәдия» таләбәләре[1] исә киткән саен һаман Барудилар тарафыннан бастырылырга тырышылган шул Каюмнар җәдитчелегенә, дөньяви җәдитчелеккә таба авыша, җәдитләнүнең төп сызыгын шулар юлында билгели бара. Шушы мәдрәсәләргә тәэсир итеп торучы татар буржуазиясенең төп теләге дә шуңар юнәлә.

Чыннан да, «әгәр беренче мәртәбә Кырымда бу бабта Исмәгыйль бәй Гаспринский башлаган булса, шул ук заманда нәзари рәвештә һәм эшли башлаган кеше – Русия татарлары арасында Насыйридыр. Насыйри бу яктан аннан соң зоһур иткән[2] шул җәдитчеләрдән күп өстен торадыр. Әгәр Насыйри «Галим җен» дип атый торган Галимҗан мулла Баруди, бу хакта эше белән вә бик аз вә сәтхи[3] дәреслекләре белән мәйданга чыккан икән, аның коры шөһрәте байлар сыйныфыннан килеп чыкканлыктан гынадыр. Әгәр Баруди вә аның әсхабы[4] ысулы җәдитне дин булышчысы итеп алсалар, Насыйри исә шул ук тәрбиягә даир әйткән фикерләре вә дәреслекләре белән бу яңа хәрәкәтне «дөнья булышчылыгы» итеп аладыр.

Беренче җәдитләр өчен дөнья гыйлемнәре дин өчен корал булса, Насыйри өчен дин үзе – дөнья көтүдә коралдыр. Шулар белән Насыйри хезмәте барудичылардан өстендер. Насыйриның бу ноктасы аеруча мөһимдер»[5].

Ысулы җәдитне Каюмнар шикелле «дөнья булышчылыгы» итеп алып, аны Барудиларга караганда төп либераль бер рәвештә куйдырырга теләүче Гани бай кебек либерал капиталистлар Оренбургтан

[1] Таләбәләре – укучылары.
[2] Зоһур иткән – мәйданга чыккан.
[3] Сәтхи – *биредә:* сай эчтәлекле.
[4] Әсхабы – *биредә:* фикердәшләре.
[5] Газиз Гобәйдуллин мәкаләсе, «Насыйри мәҗмугасы», 98 бит. *(Авт. иск.)*

үзенең хатлары аркылы һаман Казанга, Казан байларына да (шулар җөмләсеннән үзенең агасы Әхмәд бай һәм кодасы Галикәевләргә) команда биреп ята. Бигрәк тә Гани бай башлангыч мәктәпләрне чын ысулы җәдит мәктәпләре итеп җиткерә алмаганы өчен Барудилар турында шелтәле сүзләр яза: «Галимҗан мулла алты елдан бирле укыта. Шөһрәт чыгара алмады, хәлфә ясый алмады[1]», – ди. Аның яхшы куелган башлангыч ысулы җәдит мәктәпләрен барып күрә торуын, шулардан үрнәк алуын теләп, байларга махсус хатлар язган шикелле, аның үзенә дә ысулы җәдит мөгаллиме сайлый алмавы турында хат язып тәнбиһ[2] ясый. Гаяз Исхакыйны мактап, аның укытканын күреп чыгарга һәм Оренбургка килеп үз мәктәпләрен күреп китәргә киңәш бирә[3].

Җәдитчелек хәрәкәтендә татар буржуазиясенең эшне үз кулына алуы бигрәк тә башлангыч ысулы җәдит мөгаллимнәре хәзерләү өчен татар дөньясында беренче мәртәбә Мөгаллимнәр курсы ачуда булды.

Гани бай тарафыннан 1899 елда Каргалыда Мөгаллимнәр курсы (дарелмөгаллимин) ачылып, 1901 елгача дәвам итә. Фатих Кәрими дә шул курста беренче фән мөгаллиме була. Бу курста өч елда барысы ике йөздән артык ысулы җәдит мөгаллимнәре хәзерләнеп чыга.

Бу курсларга да хәзерге Татарстан һәм Башкортстаннан, Оренбургның үзеннән, Самар губернасыннан, Сибириядән – барысы унике губернадан мөгаллимнәр килгән булалар.

Татар буржуазиясенең иҗтимагый, мәдәни хәрәкәтендә үз вакытларында хезмәт күрсәтүчеләрдән Һади Атласов[4] белән Харис Фәйзи[5] кебекләр шушы курсның җимешләре иделәр.

Башында татар буржуазиясенең төп терәкләреннән булган Гани бай торган хәлдә, башлангыч ысулы саутия мәктәпләренең үсүендә һәм җәдитчелекнең кадимчелеккә каршы каты көрәш башлавында Оренбургтагы хәрәкәт татар либераль буржуазиясе файдасына тагын да күп гамәли нәтиҗәләр бирә. Тик Гани бай тарафыннан

[1] «Гани бай» китабы, 46 бит. Ул бу сүзләрне агасы Әхмәд байга 1898 елда язган хатында әйтә. *(Авт. иск.)*

[2] Тәнбиһ – кисәтү.

[3] «Гани бай» китабы, 87–88 битләр, [18]98 елда язган хатында. *(Авт. иск.)*

[4] Һади Атласи (Мөһәммәтһади Мифтахетдин улы Атласов, 1876–1938) – тарихчы, педагог, дин һәм җәмәгать эшлеклесе.

[5] Харис Зариф улы Фәйзи-Чистапули (1871–1933) – педагог, журналист. «Хөсәения» мәдрәсәсендә (Оренбург шәһәре) математика, физика, география укыта. Мәскәү хисапчылар курсларын тәмамлаганнан соң, сәүдәгәр Ә. Хөсәеновта Мәкәрҗә ярминкәсендә эшли. 1906 елдан Казанда: «Казан мөхбире» газетасы редакциясендә сәркатип, 1907–1908 елларда «Әхбәр» газетасының нашире һәм мөхәррире. Мәдрәсәләр өчен татар теле, тарих, география буенча дәреслекләр авторы.

гына 1897 елдан 1902гәчә биш ел эчендә йөздән артык ирләр, егермеләп кызлар мәктәбе ачыла һәм шуларга мөгаллим, мөгаллимәләр җитештерелә[1]. Ул мәктәпләрнең программнары, тәрбия ысуллары, укыту тәртипләренә һәм аларга яраклы мөгаллимнәр билгеләү мәсьәләләренә дә Гани бай турыдан-туры үзе катыша. Ысулы җәдит гамәлгә куела башлаган һәммә урыннан хәбәр алып, шуларга хатлар белән киңәш бирешеп тора[2]. Русиянең һәр тарафына тарала башлаган татар ысулы җәдит мәктәпләренең ничек барышын үз күзеннән үткәреп, шул турыда һәрвакыт хисап алып бара. Кадимчеләр, җәдитчелеккә каршы булган муллалар, хәзрәтләр белән турыдан-туры төрле юллар, төрле хәйләләр белән үзе көрәшә.

Оренбургта [18]90 елларда ачылган «Хөсәения» (Әхмәд, Гани байлар ачкан мәдрәсә) исә татар дөньясында татар буржуазиясенең теләгән җәдитчелеге юлында [18]60 елларда күтәрелгән урта мәктәпләр проектын чынлап гамәлгә куя башлау хәрәкәтенең икенче мөһим бер тармагы иде[3].

---

[1] Гани байның Оренбургтан чәчелгән мәктәпләре, мөгаллимнәре һәр җиргә таралалар. «Бер чите Оренбургтан Иләк буе, Җаек буе, Төркестанга барып калган» булса, икенче очы «Сакмар буе, Идел буе, Соран буе, Саелмыш буе, Үбигә җитеп» кала һәм бер чите «Бозаулык буе, Самар буе, Казанга ачылып» калган була («Гани бай» китабы – үз хатыннан, 35 бит). *(Авт. иск.)*

[2] Хәтта Һади Максуди, Гаяз Исхакый кебек ысулы җәдитче алдынгы мөгаллимнәргә дә Гани бай җәдитчелек юлында тәрбияви киңәшләр бирә. Һади Максудига: «Безнең монда «Мөгаллиме әүвәл» (Һади Максудиның мәддия ысулы белән язган әлифбасы) үтми, «Хуҗаи сыйбъян», «Бадьэ әт-тәгълим» (Шакирҗан Таһировныкы) шөһрәт алды» дип, ысулы саутиянең артыклыгын куәтли. («Гани бай» китабы, 51 бит). Шулай ук Гани бай Казан бае Галикәевләр мөгаллиме булган Гаяз Исхакыйны мактап яза: «Гаяздан өметебез күп иде, иншаллаһ, шулай булыр дип торамыз» («Гани бай» китабы, 37 бит). «Садыйк кодаң куйган Гаяз хәлфәләр шикелле хәлфәләр кирәк. Алар шикелле булса, шөһрәт таптырта. Начар хәлфә белән эш йөртеп булмый», «Казанга барып безнең хәлфә шөһрәт чыгарды» («Гани бай» китабы, 46–47 битләр), ди. Гаяз турында Гани байның шушы фикерен, ягъни аның либераль буржуазиягә файдалы кеше булып чыгуы турында алдан әйтеп куйган шушы сүзләрен соңыннан Гаязның хәзергәчә булган бөтен тарихы, бөтен хәрәкәте тәмам раслап бирде. Бу хәл – Гани байның кеше тануда бик үткен күзле булганын да күрсәтә торган бер факттыр. *(Авт. иск.)*

[3] «Хөсәения»не ачучы һәм татар дөньясында җәдитлек хәрәкәтен киңәйтү өчен фикере, малы белән бик зур хезмәт күрсәтүче татар буржуалар короле булган Әхмәд байның шушы мәктәпне ачудан максаты: «Милләт балалары мөселманча һәм русча шушы дәрәҗәдә мәгълүматлы булсыннар: бәнәгяһ *(көтмәгәндә)* дөньяга чыксалар, һәр эшкә яраклы, мәсәлән, сәүдәгәр, приказчик, конторщик, управляющий вә әмсале була алсыннар. Әгәр гыйлем эстәү юлында дәвам итсәләр, рус учебное заведениеләренә кергәндә, җиңел булсын. Мөселман мәдрәсәләрендә тәхсил арттырып, яхшы һәм ике күзле дин галиме вә дин мөгаллиме улырга да мәсафә (*ара*) җырак калмасын» («Гани бай» китабы – Хәсәнгата казый Габәши мәкаләсе, 183 бит) диюе дә бу мәктәпнең Фәезханилар проектында күрсәтелгән типтагы мәдрәсә икәнен ачык күрсәтә. *(Авт. иск.)*

## 5. Матур әдәбият

**Матур әдәбиятта яурупалашу.** Реформачылык, яурупалашу хәрәкәте XIX йөзнең икенче ярымының соңнарында татар матур әдәбиятында да үзен чагылдыра башлый. Бу да, бер яктан, турыдан-туры рус, икенче яктан, госманлы әдәбияты тәэсире аркылы килеп керә. Татарның шул вакыттагы зыялысында, укымышлы югары катлавында госманлы һәм рус әдәбиятын укып, шулар белән шөгыльләнү, шулар аркылы яңа әдәби формалар белән таныша башлау хәрәкәтләре кузгала. Шуның белән бергә, рус театрларына йөреп, тормышны сәхнәдә күрә, шуңар кызыга башлыйлар. Шулар нәтиҗәсендә, бара торгач, көнбатышлылар формасында рационализм, сентиментализм рухындагы хикәяләр, романнар, драма-театр әсәрләре туунның зәминнәре хәзерләнә. Шуларны әзме-күпме кирәксенү сизелә.

**Татарда беренче роман.** Татар дөньясында кузгалган яңа иҗтимагый-фикри хәрәкәт нәтиҗәсендә, татарның үз тормышыннан алынып, 1886 елда «Хисаметдин мулла» исемендә беренче роман басылып чыга[1]. Бу романны язучы – рус мәктәпләрендә укып яурупалашкан татар зыялысы Муса Акъегет дигән бер әдип. Бу әдип үзе – Исмәгыйль Гаспринскийның «Тәрҗеман»ын укып килүче һәм шуның мәсләгендәге кеше. Шуның өчен дә аның теле-өслүбе, җөмлә төзүдә үзенә рус теленең бераз хосусиятләрен йоктырган хәлдә, Исмәгыйль Гаспринскийның «гомуми төрк теле» сызыгында ясалып чыга.

Шулай итеп, Муса Акъегет каләме белән татар дөньясында, ләкин Гаспринскийның төркчелек юлында, беренче мәртәбә башлап Көнбатыш ысулында роман язучылык юлы ачылган була. Шулай ук моның белән татар матур әдәбиятында рационализм, сентиментализм катыш реализм адымы башлана. Шуның белән бергә, моның аркылы татар дөньясында драма әдәбияты туу өчен дә зәмин хәзерләнгән, юл күрсәтелгән була.

Романның кыскача мөндәриҗәсе болай:

1) Идел (Волга) буенда игенчелек белән яши торган, ләкин күп халыклары Әстерхан, Ростов, Казан шикелле шәһәрләргә эш һәм сәүдә өчен таралган бер татар авылы. Хисаметдин мулла дигән берәү (мулла

[1] Бу романның икенче басмасы «Татар әдәбияты көтепханәсе»ннән алтынчы китап булып, 1925 елда басылып чыкты. Беренче басмада романның исеме астына «Милли роман яки хикәя» дип куелган һәм «Әсәре Муса Акъегет. Һәр хокукы сахибенә гаиддер. Сахибендән рөхсәтсез басдырган адәм низамә җәзаланыр», диелгән. Китап Казан университеты басмаханәсендә басылган.

баласы), Истанбулда тәхсил күреп, әлеге үз авылына кайта да җәдитчелек белән үз өендә балалар укыта башлый[1]. Бу эше өчен халыкның кайсысы аны ярата, кайсысы аңар дошман була. Бигрәк тә шул авылның указлы мулласы (шул ук авылның Гали бай кияве булган Бикбулат хәзрәт), шуның өчен аның иң яман дошманы булып, аның турында әллә нинди ялган сүзләр белән аны халыкка яман күрсәтергә тырыша. Халыкны аңа, аның җәдитчә укытуына каршы котырта, кадимчәнең өстен калуы өчен көрәш ача.

2) Бервакытны Хисаметдин мулла шәһәргә китә. Ул анда Габбас исемле бер татар сәүдәгәренең мосафирханәсенә төшә. Шунда аның Хәнифә исемле кызын күреп, шуңа гашыйк булып кайта. Кызның да муллага күңеле бәйләнә (мулла 25 яшендә, матур гына бер кеше була).

3) Шул ук Хисаметдин мулла авылындагы бөтен авылга хуҗа булып алган, авылның баен-ярлысын, мулласын үз авызына караткан Гали Җәватов дигән бер атаклы бай була. Бервакыт Хисаметдин муллага дошман булган Бикбулат хәзрәт үзенең каенагасы булган әлеге байга килә дә Хисаметдин мулланы аңа черетә, бозык мулла итеп күрсәтә. Шулай ук Габбас байның кызы Хәнифәне (Хисаметдин мулланың мәгъшукасы) Гали байның улы Сибгатуллага димли. Үзен башкалар дәрәҗәсендә олыламаганы өчен, Хисаметдин мулланы Гали бай да күрә алмый. Гали бай Хисаметдин мулланы кеше алдында хурлату, базарын төшерү өчен мәҗлес ясамакчы була. Мәҗлес ясала. Шушы мәҗлестә Бикбулат хәзрәт һәм аның шәкертләренең башлавы белән Хисаметдин мулла белән ике арада шау-шу, талаш күтәрелә; Хисаметдин муллага һөҗүм башлана. Бигрәк тә аңар: «Мөселман теләнче баланы төрмәгә яптыргансың. Бу – җәдитлек, кяферлек», – дип бәйләнәләр. Араларында Коръәннән, хәдистән күп кенә сүз көрәштерүләр, тартышулар булып ала.

4) Хисаметдин мулла шушы Габбас байның кызы Хәнифәнең гыйшкы тәэсире белән инде шәһәргә еш-еш барып йөри башлый һәм төрле яшерен юллар аркылы кыз белән хатлашырга тотына. Кыздан да өметле җаваплар ала тора.

Ахырда ул бервакыт, ялган сатучы булып килеп, кыз белән йөзмә-йөз күреп сөйләшүгә, аңлашуга һәм кызга бүләк бирүгә дә муафыйк була.

5) Эшләр шулай барганда, көннәрдән бер көн Хисаметдин мулланың дошман хәзрәте (югарыдагы Бикбулат хәзрәт) хатыны белән, Габбас бай кызы Хәнифәне Гали бай улы Сибгатькә сорап, башкода булып килеп төшә, кызны аңа бирмәк булалар.

---

[1] Шуның белән бергә авылда яхшы гына тормыш корып җибәрә, ун дисәтинә җире, хезмәтчесе була. *(Авт. иск.)*

Башкодаларны озаталар, кыз бу эшне аңлап кайгыра башлый. Хисаметдин мулла да тиздән яңадан шәһәргә килгән була. Болар тагын кыз белән күрешеп, мәсьәләнең кайда барачагын аңлашып, бер-берсенә сүз куешалар. Шуннан соң Хисаметдин мулла үзенең шәһәрдәге дусларыннан һәм фикедәшләреннән милләтпәрвәр тәрәккыйче, мирза баласы гимназист Әбүзәр белән икесе, шул ук русчадан хәбәрдар тәрәккыйче дусларыннан «арыслан күз» Гайсә Озынколаков дигән бакыр остасына барып, аның анасы Гайниҗамал карчыкны башкода итеп җибәрәләр. Ләкин кыз үзе дә аналарына әйтеп караса да, эш барып чыкмый, шуның өстенә кызның анасы, аның күңелен Хисаметдин мулладан сүрелдерү өчен, кызны ишаннар, имчеләр чакырып имләтә башлый.

6) Габбас бай инде Хәнифәне Гали бай углына килешеп, «сый» мәҗлесендә булып, бирнәләр килә, кызга һәдияләр алына. Шулай итеп, никах туена хәзерләнелә. Гали бай, Бикбулат хәзрәт, кияү булачак егет – һәммәсе, авылны ду китереп, шатланып, шәһәргә никах туена китәләр. Туй кунаклары булган Гали байлар һәм кияү берничә чакрым баргач та, аларга каршы кызның атасыннан атлы хәбәрче килеп җитә дә, кызның качуы сәбәпле, туйның тукталуыннан хәбәр бирә. Туй-никах кунаклары, кияү, моңа кайгырып, кире кайтып китәләр. Гали бай белән Бикбулат хәзрәт, ачуланып, хәбәрче белән бергә шәһәргә, Габбас байга барсалар да, мәгънә чыкмый. Анда кода, кодагый белән ачуланышып, сугышып, болар да кире кайтып китүгә мәҗбүр булалар.

7) Кыз Гайниҗамал карчыкка (Хисаметдин мулланың дустының анасына) качкан була. Бу вакытта Хисаметдин мулланың, иптәшләре Әбүзәр һәм Озынколаковлар белән, Кырымнан соратып алган фән китапларын авылларга таратып килүгә дип чыгып киткән чагы була. Шулай йөреп үз авылына кайткач, вакыйгадан хәбәр ала да, мәсьәләне яхшырак аңлау өчен диеп, Хисаметдин мулла шәһәргә Зурколаковларга – Гайниҗамал абыстайдан сорашырга китә. Ләкин Гайниҗамал карчык улы Зурколаковка да, Хисаметдин муллага да үзендә Хисаметдин мулланың мәгъшукасы Хәнифә яшеренеп ятканын әйтми. Бер мосафир хатын, ди дә шуның белән эшне бетерә. Ахырында Хисаметдин мулла, өметсезләнеп, фатирына, Әбүзәр бәйгә кайтырга чыга. Шул хәлдә Хисаметдин мулла фатирына китеп барганда, Хәнифә, Гайни карчык өеннән дә качып, аның артыннан килеп җитә дә, шуннан ике сөюче бер-берсе белән кавышалар. Шуннан, шул ярым сәгать кичәр-кичмәс, Хисаметдин мулла йөгерек аты белән сөйгәнен авылына алып кайта.

Гайниҗамал карчык та вакыйганы кызның ата-анасына барып сөйли. Бай, кыза-кыза, судка бирү өчен адвокатларга чаба. Ләкин ахырда

кызның ата-анасы бу эшкә риза булырга мәҗбүр була. Бер атнадан соң инде Хисаметдин мулла өендә туй ясала. Туйда Хисаметдин мулланың дуслары Әбүзәр, Зурколаковлар хазир булалар[1]. Никахны Бикбулат хәзрәттән укыталар. Шулай итеп, Хисаметдин мулла белән Хәнифә туташ бик матур итеп, ирле-хатынлы бергә көн күрә башлыйлар.

8) Ике елдан соң Хисаметдин мулла гаиләсе белән, йорт-җирен сатып, Кавказга – Тифлискә күчә. Теләнчелек кылып йөргәне өчен Хисаметдин мулла үзен полиция кулына тотып биргән, ләкин соңыннан шул ук Хисаметдин мулла һәм аның иптәшләренең киңәше белән кәсепкә керешеп, ахырда Тифлистә зур сәүдәгәр булып алган Мохтар дигән кеше була (югарыда Бикбулат хәзрәтләрнең әйткән ятим балалары шул була). Әнә шул бай Хисаметдин мулланы Тифлискә муллалыкка чакыра. Мулла да, шуның чакыруы белән барып, имам була. Анда аңа шул ук Мохтарның акчасына мәдрәсә ачып биреп, Хисаметдин мулла да шунда дәрес әйтә башлый. Роман шуның белән тәмам була.

Әсәр үзенең мәүзуг итеп алган вакыйгасы һәм мөндәриҗәсе белән үзенең тарихи әһәмиятен бервакытта да югалтмый торган бер әсәр булып чыккан. Монда без иң әүвәл татар дөньясында XIX йөзнең соңгы ярымында башланган уяну, җәдитләнү, яурупалашу хәрәкәтенең, шул йөзнең дүртенче чиреге эчендә алган күренешеннән җанлы тормыш картиналарын күрәбез. Ул картиналардан без түбәндәге моментларны чыгарып ала алабыз:

1) татар сәүдә капиталының шәһәрләрдә һәм авылларда ничек үсүләре;

2) авыл байларының халык өстеннән ничек хөкем сөрүләре;

3) руханиларның һәм халыкның «җәдит», «кадим» дип ике лагерьга аерылулары. Шул ике лагерь арасында көрәш башлану;

4) татарга госманлы һәм рус әдәбияты, рус-Яурупа мәдәнияте тәэсире;

5) татар либераль буржуа элементларының кузгала башлавы, беренче тәрәккый чаткылары;

6) татар буржуазия сыйныфының яңа идеологиясе ничек эшләнеп, ничек системландырыла башлавы;

7) әдәби телдә Каюмнарның мөселман-татарчылык агымына каршы Исмәгыйль Гаспринскийларның мөселман-төркчелек агымының татар матур әдәбиятында беренче үрнәге бирелү;

[1] Хазир булалар – катнашалар.

8) җөмлә төзелешендә татар әдәби теленә рус теленең ничек тәэсир итүе;

9) хатын-кызларга хөррият таләп итү, татар кызларының үз ирексезлекләренә каршы күтәрелә башлауларының беренче адымнары;

10) җәдитче татар муллалары – либераль татар буржуазиясе лагереның юлбашчылары, шул лагерьның идеология таянычлары булып хәзерләнүләре һәм шул идеологларның Төркия – Истанбулдан хәзерләнеп кайткан беренче вәкилләре (Хисаметдин мулла – шул вәкилләрнең татарда беренче үрнәге).

11) либераль татар буржуа әдибе һәм аның татар матур әдәбиятында урнаштырган төп идеология орлыгы;

12) татар матур әдәбиятының ривая тармагында реализм агымының беренче адымы кайчан башлану;

13) татар җәдитче руханиларының хәзинәдән (дәүләттән) айлык сорау мәсьәләсен күтәрүләре. Матур әдәбиятны җәмгыятьне өйрәнүнең мөһим бер тармагы итеп карап, аны икътисади, иҗтимагый нигездә тикшерүче марксистлар өчен әсәрдәге бу моментлар иң әһәмиятле моментлардан саналырга тиеш.

Шулар өстенә, әсәрдәге Бикбулат хәзрәт, Хисаметдин мулла, Гали бай, гимназист Әбүзәр бәк, һөнәрче (бакырчы) Гайсә Озынколаков типлары – менә болар татар матур әдәбиятында беренче мәртәбә күренгән һәм шул дәверне үзләре аркылы сурәтләндерә, яшәтә торган тарихи типлардыр. Алар XX йөзнең башларында һәм 1905 еллардан соң татар буржуа тормышы шартлары эчендә татар дөньясында туган, тудырылган типларның төп орлыклары, тамырлары иде.

Андагы бу хосусият әсәрнең иң әһәмиятле якларыннан берсе саналырга тиеш. Алда күреләчәк Ильяси, Халиди драмалары, «Чистай комедиясе»[1] шикелле, моның да зур бер әдәби кыйммәте әнә шул ноктада: Октябрь революциясенәчә булган 15–20 ел эчендә «әдәбиятыбызда байтак әтрафлы вә әдәби сурәттә тасвир ителгән мәнфи вә мөсбәт[2] типларның үзләрен яки күләгәләрен тудыруында»[3] булды. Чөнки Риза казый, Фатих Кәрими, Галиәсгар Камал, Садри

[1] «Комедия Чистайда» (1895) – немец теленнән русчага тәрҗемә ителгән «О, время» дигән комедиянең билгесез автор тарафыннан татарчага тәрҗемәсе.

[2] Мәнфи вә мөсбәт – тискәре һәм уңай.

[3] Шуның өчен бу урында шул романның беренче басмасыннан 1) рус тәэсиреннән сафрак булган; 2) рус тәэсире бик ачык күренеп торган тапкырыннан ике мисал укып үтелергә тиеш. 2–3 һәм 12 битләрдән. 2 нче яңа басмасы [19]25 елда басылды. *(Авт. иск.)*

Максуди, Гаяз Исхакый, Фатих Әмирхан һәм кыйсмән[1] Галимҗан Ибраһимов кебек әдипләрнең әсәрләрендә без шул ук төп орлык типларның (прототип[2]) яңа шартлар астында тагын да киңәйтелеп, тулырак рәвештә үстерелеп сурәтләндерелүләрен күрәбез.

Кыскасы, икенче әдәби дәверебезнең соңнарында татар буржуа милли хәрәкәтенең кызуланган баскычында татар хатын-кызларының, мөгаллимнәрнең иҗтимагый, фикри хәрәкәтләре «Хисаметдин мулла»лар заманында игелгән орлыкларның киңәеп үсүләреннән башка нәрсә түгел иделәр. «Татар туташларының менә шул хәрәкәтләре яңа әдәбиятыбызда Галияләр, Мәрьямнәр шәкелендә күләгә төшергән кебек, Рокыялар сурәтендә һәм тәрҗемә ителде»[3].

Шул ук икенче дәвердә татар дөньясында тәрәккыйче, милләтче шәкертләр, җәдитче яшь муллалар, җәдитче мөгаллимнәр груһы да туды. Шуның өстенә шул ук дәвердә рус мәктәпләрендә укып йөреп яңа мөселманчылык рухында милли фикер, милли хисләр белән ялкынланып очкын чәчә башлаучы яшь зыялылар, гимназистлар, гимназисткалар мәйданга чыга башладылар. «Әсәрдәге гимназист Әбүзәр бәк, Хисаметдин мулла, Хәнифә туташ шуларның мөбәшширләре[4], күләгәләре[5]» иде.

Муса Акъегетнең теле-өслүбе – чыгтайлыктан, иске төркичелектән аерылып, Гаспринский нигезендә татар+госманлы булып сугылган, шуның өстенә үзенә рус теленең төзелеш тәэсирен ала башлаган бер тел. Моны югарыда аңлап үттек. Менә татар буржуа матур әдәбиятында бу рәвештәге бер тел һәм өслүб өчен бу китап – янә иң беренче башлангыч бер тарихи үрнәк.

Татар буржуазиясе, татар мирзалары, җәдитчеләр белән татар баш руханилары, алпавытлары арасындагы мөнәсәбәт һәм ике арада белек[6] ясала башлауның да беренче адымнарын бу әсәр безгә ачык күрсәтә ала. Монда мөхәррир шул вакытларда Петербургка узып баручы алпавыт мөфти Сәлимгәрәйне бик мактый (34–35 бит, [19]25 елдагы яңа нәшере) һәм аның авызыннан «гимназист формалы Әбүзәр бәк»кә: «Чук[7] шатландым ки исламдан мәгълүматы,

[1] Кыйсмән – өлешчә.
[2] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[3] Н. Гасрый «Аң». 23–24 сан; 1915 ел. *(Авт. иск.)*
[4] Мөбәшширләре – яхшы хәбәр белән сөендерүчеләре.
[5] Н. Гасрый, шул ук мәкаләдән. *(Авт. иск.)*
[6] Белек – «уртак кануннар, законнар» мәгънәсендә.
[7] Чук – бик.

мәгыйшәте тәхсил идән[1] зат күрәмез; укы, кардәш, хәзер заманлар тәбдил улды[2]. Рәхәт, сәламәт тормак өчен голуме гакълийә ляземдер[3]. Анчак Аллаһы Тәгаләдән тәуфыйк вә һидаять сора», – дигән кебек, шул заман татар буржуазиясе мәнфәгате өчен характерлы булган сүзләрне әйттертә.

Муса Акъегетнең тәрҗемәи хәле безгә төгәл мәгълүм түгел. Аның шушы әсәре турында татар матбугатында башлап беренче анализ ясаучы Нәҗип Гасрый[4] да аның тәрҗемәи хәле өчен бик аз материал бирә, аның биргән мәгълүмат вә материалы түбәндәгечә.

Акъегетзадә[5] Муса әфәнде, гимназияне бетерепме, бетермичәнме, Төркиягә һиҗрәт иткән. Аның бервакытлар Истанбулда мәктәбе хәрбиядә рус лисаны мөгаллиме булып торганлыгы, 1908 елда хөррият алынгач, «Мәтен» исемле матбага ачып, шул ук исемдә гәзит чыгарганлыгы мәгълүм.

Ләкин матбагада гәзит эшен алга җибәрә алмыйча, билахирә[6], Анатолида бер өязгә исправник булып киткән иде. Андан соңгы хәле мәгълүм булмады[7].

**Татарда беренче драма.** Татар буржуазиясенең иҗтимагый-әдәби кузгалышы, татар дөньясындагы төрле тармаклы реформа хәрәкәте феодализмга, иске Шәрык фанатизмына каршы күтәрелгән көрәшне сәхнәгә дә кертүне, аны драмаландыра башлауны да кирәксенде. Шуның нәтиҗәсендә татар матур әдәбиятының тагын аңарча күрелмәгән яңа бер тармагын тудыру эше ашыктырылды.

«Хисаметдин мулла» романыннан бер ел гына соң, 1887 ел, 27 октябрьдә, «Бичара кыз» исемендә беренче татар драмасы басылып чыкты.

Кечкенә кулда егерме бит зурлыгында, дүрт пәрдәдән гыйбарәт булган бу беренче драманы язучы – беренче татар драматургы да,

[1] Тәхсил идән – булган.
[2] Тәбдил улды – үзгәрде.
[3] Голуме гакълийә ляземдер – акыл гыйлемнәре зарур.
[4] Нәҗип Гасрый (Мөхәммәтнәҗип Аллабирде улы Мәүләмбирдиев, 1886–1937) – әдәбият тәнкыйтьчесе. «Ил», «Идел», «Йолдыз» журналларында басылган, XX йөз башы татар әдәбияты һәм татар әдәби теле мәсьәләләренә багышланган, Г. Тукай, М. Акъегетзадә, Г. Ибраһимов, Гыйффәт Туташ иҗатларына караган күпсанлы мәкаләләр авторы.
[5] Мөхәррир әсәренең беренче басмасында «Муса Акъегет» дип имза кылган. «Задә» диелмәгән. «Акъегет» аның авылының исеме булырга кирәк. *(Авт. иск.)*
[6] Билахирә – ахырда.
[7] «Аң», 1915 ел, 23–24 сан, 424 бит. Нәҗип Гасрый мәкаләсеннән, башы 9–10 нчы санда. *(Авт. иск.)*

Казанның шул вакыттагы тәрәккыйче зыялыларыннан Габдрахман Ильяси дигән бер җәдитче булды[1].

Әсәрдә «Хисаметдин мулла»дагы кебек хатын-кызлар хокукы мәсьәләсендә иске феодализм тәртибенә каршы баш күтәрү хәрәкәте тасвир ителә.

Әсәрнең мөндәриҗәсе түбәндәгечә:

«Кара» надан бер татар баеның Мәһитап исемле «бик матур» бер кызы була. Әти-әнисе аны икенче бер «бик бай кеше»нең «ямьсез, аңгыра» бер улына бирмәк булалар. Кыз моның өчен кайгыра. Гәзитләр укый торган, үзе тәрәккыйче Җанбай исемле «бик яхшы гына галим бер егет» үзенең бер дусты аркылы бу хәбәрне ишетә дә Мәһитапны бу һәлакәттән коткару чарасына керешә.

Мәһитап янына кияү ябабыз дип, теге «ямьсез, аңгыра» бай малаен көтеп торган чакларында, ишектән Җанбай килеп керә, чаршауны ачып, кыз янына бара. Аны бу бәладән коткарырга килгәнен әйтә. Икенче яктан кияү килде бугай дип килеп кергән яучы карчык, бу хәлне күреп, кызның әти-әниләренә чыгып әйтә. Кыз белән Җанбай кочаклашып торалар, шул вакытта кызның әтисе белән әнисе, яучы карчык, асрау кызлары дүртәү килеп керәләр дә, боларның кочаклашып торганнарын күреп, моңа хәйран калалар. Җанбай кызның әти-әниләрен бу җинаятьләре өчен каты сүгәргә, кыздырырга тотына.

Шул арада кызга кияү булачак теге «ямьсез, аңгыра» бай малае килеп керә. Үзе бөтенләй исерек бер хәлдә, кияүне каршы алмаганлыклары өчен лыгырдап, абына-сөртенә килә. Үзенә хатын булачак Мәһитапның Җанбай белән кочаклашып торганын күрә дә Җанбайга бәйләнә башлый. Җанбай аны кызга якын җибәрми. Мәһитап исә, һаман Җанбай куенына керә барып, аннан үзен тегеңә бирмәвен сорый. Кызның атасы бу хәлгә чыдый алмый, кыз янына килеп сүгә, аны орыша башлый. Җанбай аңа каршы каты, усал тел белән җавап кайтара. Кызга да «дөнья вә ахирәттә» үзе белән бергә булачагын әйтеп, аны юата. Кызның атасы моңар тагын аптырап кала. Кияү булачак теге бай малае һаман исерек хәлдә бер асрау кызга, бер Мәһитапка таба килергә маташа. Ахырда ул бик каты исереклегеннән егыла да сүгенә, янаша башлый. Мәһитапка «талак» дип кычкыра.

---

[1] Габдрахман Ильясиның шушы драмасы, Галиәсгар Камалның биргән мәгълүматына күрә, шул ук вакытларда мөхәррирнең үзенең өендә чаршаулар корып уйналып та каралган була. Татар дөньясындагы шушы беренче драманың беренче артисты да Габдрахман Ильяси үзе булган булса кирәк, дип уйлана. Рәшид казый Ибраһимовның беренче җөзьэ «Миръат»ында («Көзге») әйтелүгә караганда, 1900 елларга кадәр Касыйм шәһәрендә рәсми театр уйналган була. Әнә шунда уйналган әсәрләрнең берсе шушы «Бичара кыз» булуы бик мөмкин («Татар театры», Г. Сәгъди мәкаләсе, 14 бит, 1926 ел). *(Авт. иск.)*

Кыз моны ишетеп шатлана. Җанбайга: «Мин синеке», – дип куана. Җанбай да: «Минеке булдың», – дип, Маһитапны кат-кат үбә башлый. Бу хәлне күреп, кызның атасы һәм башкалар «авызына бармагын кабып», исләре китеп торалар. Шуның белән соңгы дүртенче пәрдә төшә[1].

Әсәрнең мөндәриҗәсеннән без драманың төп каһарманы мөтәгассыйб[2] бер татар баеның кызы Маһитап икәнен күрәбез. Ул – үзенең хокуксызлыгы, хәленең үзгәрмәве өчен кайгыручы, үз иркенчә яшәргә теләүче, җәдитләнеп килгән бер татар кызы. «Хисаметдин мулла»дагы үзенең хокуксызлыгына, татар гаиләсенең феодализм тәртибенә каршы гыйсъян кылучы Хәнифәнең икенче сыңары.

Дөрес, аның аркылы мөхәррир үзе, көчләнеп, яңа бер табигать бирергә маташкан: иҗтимагый аңы ачылган, үткен, батыр табигатьле яңа бер туташ ясап чыгарырга тырышкан[3] тырышуын. Шул сәбәпле Фатих Әмирханның Рокыяләре[4] шикелле үк, ул да үз заманында ясалма идеаль бер тип булып та чыккан. Хәтта мөхәррир аннан ул вакытта татар кызларында әле күренмәслек бер рәвештә, яхшы ук тирән генә шигъри, фәлсәфи сүзләр дә сөйләтә.

Ләкин шулай булуга карамастан, татарның шушы беренче драматургы булган Г. Ильяси уянган, яңарган, яурупалаша башлаган татар халкының хатын-кызлар мәсьәләсендә нинди идеалга карап хәрәкәт итә һәм итәргә тиеш икәнен, зәгыйфьрәк бер юлда булса да, үзенең шушы Маһитабы аркылы алга чыгарып бастырып биргән. Әсәрнең иҗтимагый бер әһәмиятле ягы менә шунда.

Икенче яктан, без бу әсәрдә гәзитләр укый торган, үзе тәрәккыйче һәм татар хатын-кызларының хокуксызлык богавын өзәргә тырышучы «бик яхшы гына галим бер егет»не күрәбез. Бу инде шул заманның татар иҗтимагый тормышында реформа ясауга омтылучы җәдитләнгән татар яшьләренең бер вәкиле.

Әсәрдәге менә шушы ике каһарман татар дөньясының шул вакыттагы реформа кешеләре – шул замандагы «яңа кешеләр».

Боларның каршысына да бер «бик бай кеше» – татарның феодаль тормышының бер вәкиле булган кара надан татар бае белән аның «ямьсез, аңгыра», көн-төн эчеп йөри торган әхлаксыз бер улы

[1] «Татар театры» мәҗмугасында китаптан клишеләр бар. Шунда каралсын. *(Авт. иск.)*

[2] Мөтәгассыйб – фанатик.

[3] «Татар театры» мәҗмугасы, Г. Сәгъди мәкаләсе, 17 бит. *(Авт. иск.)*

[4] Сүз Ф. Әмирханның «Тигезсезләр» (1914) пьесасы турында бара.

алына. Шулар өстенә монда татар феодализмының имче карчыкларының вәкиле булган Сәхибә әби бар.

Менә бу типларның һәммәсе турында шул ук «Хисаметдин мулла» романындагы типлар турында әйтелгән сүзләрне әйтәбез. Болар да татар әдәбиятының XIX йөзнең ахырларында – XX йөзнең башларында һәм 1905 елдан Октябрьгәчә булган татар хикәяләрендә, романнарында, драмаларында сәнгатьчә яхшылабрак эшләнеп чыккан типларның төп орлыклары һәм шул вакыттагы татар тормышында бик ачык күренә алганнары иде. Бу соңгы вакытларда инде без татар драмасында Ильяси вакытындагы идеалдагыча түгел, бәлки вакыйгдагыча тагын да җитешкәнрәк Маһитапларны күргән шикелле, һәрьяктан үсеп җиткән тәрәккыйче Җанбайларны да күп күрә башлыйбыз. Гаяз, Галиәсгар әсәрләре безгә боларны ачык күрсәтәләр.

Кыскасы, «бу пьеса яңа икътисади шартлар эчендә матди тормышта, идеологиядә иске төркилектән, Урта Азия – чыгтай тәэсиреннән котылу юлына төшеп, Яурупа тәэсиренә әйләнергә итә башлаган яңа бер тормыш әдәбиятының драма ишеген иң беренче мәртәбә башлап ачып биргән, иң тарихи бер уен китабы» булды. Тагын да чынын әйтсәк, бу – иске надан татар байларының тормышы белән яңа гына баш күтәрергә итә башлаган яшь татар буржуазиясе тормышы арасында көрәш башлануның иң беренче тарихи сигналы иде.

Бу ике тормыш арасында чын көрәш сәгате шуның белән суккан булды. Бу моннан Җанбай кебек замана гыйлеме, Яурупа белемен ала башлаган һәм гәзитләр дә укый торган, татар хатын-кызларының хокукларын таләп итү, шуны саклау фикере башларына кергән «бик яхшы гына галим бер егет»ләрне очрата башлыйбыз инде. Драманың баш каһарманы Маһитапның да татар кызларын кызның үз ризалыгыннан башка үзе сөймәгән егетләргә көчләп кияүгә бирү гадәтенә каршы беренче мәртәбә каты һәм гамәли бер юл белән протест ясаучы бер каһарман булып чыкканын күрәбез. Аның үзалдына сөйләнеп:

– Юк... Маһитап, көлмә, көлмә... Ела, ела... Уф! Мине Җантимергә (үзенең барырга теләмәгән бай малаеның исеме) бирсәләр, мин ул вакыт ни эшләрмен; юк! Юк! Бармам, бармам... Минем ризалыгымдан башка бирмәсләр! Аһ, гүзәл кыз, гүзәл кыз! Чынлап укмыни, син шул кабахәт Җантимер куенында булырсыңмы; аһ, минем бу сөалемә җавап бирүче бер дә юк... Аһ, җавап, җавап... – дигән сүзләре дә бит татар кызының беренче кузгалышындагы беренче гыйсъян сүзләре иде.

Вакытында бу драма халык арасында көчле бер тәэсир, зур гына бер йогынты да калдыра алган. Моны да без икенче бер аның туганы булган драма аркылы күрәбез[1].

«Хисаметдин мулла» романындагы шикелле үк, әсәрнең сәнгатьчә эшләнүендә беренче адым, беренче тәҗрибә булганлыгы өчен, әлбәттә, кимчелекләр аз түгел. Мөндәриҗәнең сайлыгы, техниканың зәгыйфьлеге, шуның өстенә табигыйлек сызыгыннан читкә чыгып китү кебек хәлләр, хәзерге заман күзлегеннән караганда, әсәрдә күзгә бик нык бәреләләр.

Ләкин әсәрнең безнең өчен иң кыйммәтле ике ягы бар: берсе – югарыда әйткәнебезчә, иҗтимагый ягы, икенчесе дә – теледер. Бу әсәрдә инде без, «Хисаметдин мулла» романының киресенчә, татарчылыкка күбрәк тартылган, Каюм Насыйрилар юлына төшелгән бер тел күрәбез. «Хисаметдин мулла» аркылы бик аз өлеше татарча, күп өлеше госманлычадан гыйбарәт булып эшләнә башлаган бер «гомуми төрк» теле бирелсә, монда инде шуның киресе алга куела.

Шулай итеп, беренче татар драмасы безгә матур әдәбиятның бу өлешендә төп төзелеше һәм күп өлеше татарча булган, ләкин шуңар бераз госманлы йогынтысы эләккән бер телне тудыра. Үзеннән соң киләчәк татар әдипләренә драмада татар теле алынуның баш сызыкларын, беренче эзләрен калдыра.

Шуның өстенә әсәрдә татар әдәбиятына Яурупа ысулындагы тыныш билгеләре кебек яңа техника галәмәтләре дә килеп керә.

«Бичара кыз»ның иң татарча язылган урыныннан мисал:

Маһитап: Әбием, җаным, кил, утыр, мин синдән бер сүз сорыйм, син карчык кеше дөрестне әйтерсең.

Сахибә: Сора, кызым, әстәгъфирулла, җалган сөйләдек...

Маһитап: Әби, син кияүгә бардыңмы?..

Сахибә: Бардым, бәбкәм...

Маһитап: Үзең яратканга бардыңмы? Көчләп бирделәрме?

Сахибә: Үзем сөйгәнгә бардым...

Маһитап: Ничек?..

Сахибә: Менә, кызым, мин сиңа сөйлим (як-ягына караныр, авызыны борыр һәм сөртер). Менә бервакытны әниләр кияүгә бирәселәре булды, карыйм. Карыйм. Мине икенче кешегә бирәләр. Күрдем, эш болай ярамый. Бервакыт әтиләр, әниләр уракка чыгарга хәзерләнәләр иде, мин башымны авыруга салып калдым, әни әйтте: «Алайса, кы-

[1] «Татар театры», Г. Сәгъди мәкаләсе, 19 бит. *(Авт. иск.)*

зым, менә мин чыкканда, Хәбибә абыстайга әйтә китәрмен, синең янга иптәшкә керер», – дип чыгып китделәр (янә авызын сөртеп алыр). Шундан соң Хәбибә абыстай да килде. «Әби, исән килдеңме?» – дидем. «Аллага шөкер», – диде. Безнең авылда Хәбибә абыстайдан яхшы хатын юк иде, Алла рәхмәт итсен бичарага. Шундан соң, сүздән сүз киткәч, мин үземнең хәлемне әйтдем. Хәбибә абыстайның шундыйга азрак осталыгы бар, диләр иде. Хәбибә абыстай әйтә: «Кызым, миндән бер яхшылык булсын, мин сиңа бер эш ясыйм», – дип, бер нәрсә өшкереп бирде. Андан соң бер дога бирде. «Боларны иртә берлән әтәч кычкырганчы бусагага кыстыр», – диде. Мин шуны шулай эшләдем, Хәбибә абыстайга бер уч киндер дә бирдем, шундан соң син күр дә, мин күр, әтиләр, димли торган йирдән кайтышып, үзем теләгәнгә бирә куйдылар. Мәрхүм, рәхмәтле Хәбибә абыстай шул эшне миңа да өйрәтде, менә мин шуны үземезнең авылда бер кызга ясап биргән идем, кул белән куйган күк булды...

Маһитап *(тез чүгеп):* Әби, җаным, ана бул, миңа да яса...

Сахибә: Ярый, бәбкәм, хәзер, тәһарәтем дә бар (дип, почмакка барып утыра).

Маһитап *(үз-үзенә):* Аһ, Алла, ниләр кылыйм... Никадәр гөнаһ кылам, дога, дога! Доганы бусагага куя алырмын... Әй, Раббым...

*(Сахибә хәзерләп бирер.)*

*(Маһитап, кулына алып, кием шкафыннан бер асыл күлмәк алып бирер, Сахибә китәр.)*

Сахибә: Хуш, кызым, минем кулым түгел, Әйшә-Патма кулы, хәерле сәгатьтә булсын (дип чыгар).

*(Маһитап, кулындагы әйбергә карап, имче хатынның юлына карап калыр[1].)*

Бу урында шушы беренче драманың янә игътибарга алына торган әһәмиятле бер ягын әйтеп үтәргә кирәк. Бу драма үз вакытында татар дөньясында «көчле бер тәэсир, зур гына бер йогынты да калдыра» алуы белән үзенә каршы кадимче татар байларының җавап авазларын алды. «Моны да без аның туганы булган икенче драма аркылы күрәбез», ягъни Габдрахман Ильясиның шушы «Бичара кыз» драмасы, татарда үзе артыннан икенче драманың тууына да сәбәп булып, шуңар юл ачты. Димәк, ул үзенә иярүчеләр дә тудыра алды.

[1] Габдрахман Ильяси әсәре «Бичара кыз» пьесасыннан асыл нөсхәдән үз имлясы, үз техникасы белән алынды. *(Авт. иск.)*

10–11 бит. Әсәр басылган 1887 елда. *(Авт. иск.)*

«Бичара кыз»га каршы иске татар буржуазиясенең авазы булган шушы икенче драма Ф. Халидинең «Рәдде бичара кыз»ы булды. Моның бер тарихи әһәмияте дә – теге беренче драмага каршы язылуындадыр.

Ф. Халидинең бу драмасы кечкенә кулда 30 бит зурлыгында булып, «Бичара кыз» драмасыннан өч ел соң (1890 елда май аенда) басылып чыга.

Бу пьесада:

– теге драма – «Бичара кыз» китабында әйткән «Маһитап, Җантимерләр кыйссасы»;

– «Ник бирсен Әхмәд бай Фәрханәне Ислам мулла улына; ахрысы, матур дип барырга Фәрханә җүләр түгел, матурлыгына кызыгып, бер ярлыга барырга. Ул теге «Бичара кыз» китабындагы әйткән: «Маһитапка туе булгач, кияү кергән кичне Маһитап, Җантимерне ямьсез дип, Җантимердән аерылып, Җанбайга, муллалыгы бар, үзе дә матур, ярлы булса, булсын, Җанбайга барам, дип язган. Мин, кунаклар, бу Маһитапның, ямьсез дип, бай егеттән аерылып, матур дип, бер ярлы егеткә барганына бер дә ышанмыйм! Ахрысы, бу була торган эш түгел, хатынлар сөяр байны, ирләр сөяр сауны, дигәнләр, бай иргә бару бик кыйбат. Әгәр нәфесе теләгән кеше, бай иргә баргач, кирәк булса, матур егетне табып була», – дип, Мәхмүд бай хатыны елмаеп көлде» дигән кебек, «Бичара кыз» китабына таянып әйтелгән сүзләр очрый (4, 5, 6, 15–23 битләрдә).

Андагы менә шундый сүзләр, бер яктан, Габдрахман Ильясиның «Бичара кыз» драмасы һәм андагы вакыйганың халык арасында үрнәк, гыйбрәт ителеп йөртелгәнен күрсәтсә; икенче яктан да, «Рәдде бичара кыз»ның аңар каршы бер юл белән язылганын ачып бирә. Мәхмүд бай хатыны авызыннан сөйләтелгән сүзләр шуны ачык белдереп торалар.

Ф. Халидинең бу әсәре тел ягыннан «Бичара кыз»га караганда татарчылыкта тагын да ачыграк, ләкин анда инде рус тәэсире сизелә. Ул пәрдәләрне дә «действие» дип йөртә башлый.

«Рәдде бичара кыз»ның мөндәриҗәсе:

1. Ишек төзәтеп йөрүче һәм иң ярлы яши торган Мирза исемле бер кеше була. Гаиләсе дә хатыны Сәлимә белән кызы Хәлимәдән гыйбарәт. Кызлары да бик матур була. Кызга фабрикант һәм Әхтәм байның айга өч мең сум жалуния ала торган Закир дигән приказчигыннан яучы килә. Кызның атасы белән анасы, киңәш итеп, Закир приказчикка

бирергә булалар. Биби карчык белән Закир килеп, кызны карап китә. Кыз егеткә ошый. Егет йөз сум акча биреп китә. Кайтып, Биби карчык аркылы күлмәкләр, фрукталар да җибәртә.

2. Икенче байларга кардәш булган Мәхбүб дигән бер яучы карчык, Биби яучының диме белән башланган ул эшкә каршы төшә. Кызны «зыяндашлы, төче зәхмәте белән сасып беткән» дип, кызның анасы сихерче дип, Закирга барып яманлый. Аның урынына Әхмәд бай хатыны Бикәнең кызын – Фәрханәне димли. Закир да, матур дип [кенә], бу ярлыны алмый: «Корысын матурлыгы. Ямьсез булсын, бай булсын», – ди дә, башлаган эшеннән дүнеп, Фәрханәне алмакчы булып, Мәхбүбкә сүз биреп һәм аны ун сум «мәгәричләп» җибәрә. Биби карчык Закирга яңадан килсә дә, булдыра алмый. Ахырда, Закир тарафыннан бирелгән акча белән асыл күлмәкләр кире кайтарылып алына. Әхтәм бай да Хәлимәне Закирга муафыйк күрсә дә, Закир шул сүзеннән кире кайткан көе кала.

3. Шул кайгыдан җәфаланып, елашып торган чакларында, Мирза агайның ишегалдыларында самавырларыннан ут чыга да, өйләре яна. Янгынны карарга дип базардан халык белән Әхтәм байның улы Әптәм дә килә. Ул шунда кызны күреп гашыйк була. Шуны үзенә хатынлыкка алып бирүләрен сорап, Әптәм әнисенә мәсьәләне ача. Әптәмнең әнисе Әлфия (Әхтәм бай хатыны), кызларны күрер өчен, үзендә мәҗлес ясый. Хәлимәне улына яраклы таба. Ире Әхтәм бай белән киңәшеп, кызны улларына алырга карар бирәләр.

4. Әхтәм бай Хәлимәнең этисе Мирзаны чакыра. Үзенә торырга күчеп килүләрен һәм үлгәнче тәрбияләвен өстенә алачагын әйтеп, кызларын улына бирүләрен сорый. Риза булышып, Мирза агай гаиләсе байга күчерелеп китерелә. Кыз да Әхтәм бай улына бирелә.

5. Байның гостинныенда никах мәҗлесе бара. Аның астында байның конторы булып, Закир шунда була. «Үзен Хәлимәдән дүндертү өчен, Мәхбүб карчыкны җибәртеп, хәйлә ясатты», – дип уйлап, әүвәл – Әптәмне, аннан соң үзен үтерергә дип, револьверын кесәсенә яшереп маташканда, атылып китә дә, Закир шуның белән үлә. Кунаклар да бу тавышка куркышып, аяк оч торалар. Шуның белән әсәр тәмам була.

Бу әсәр һәм анда тасвир ителгән вакыйга XIX йөзнең соңнарындагы татар ярлылары, татар эшчеләре белән татар байлары – татар капиталистлары арасындагы мөнәсәбәтне һәм аларның тормышларын, һәрхәлдә, бераз күрсәтә ала. Әсәр бу турыда тарих өчен дә файдалы бер материал булырлыктыр.

**Татарда беренче комедия.** Адымнар адымнарны тудырды. Татар реформа хәрәкәтенең феодализмга каршы көрәшендә көлү юлы

белән сәхнәгә чыгу адымнары да башланды: татарда беренче комедия («Чистай комедиясе») баш күтәрде. Ләкин «комедия» исеме белән 1893–[18]94 елларда язылып, [18]95 елда Казанда кечкенә кулда 28 бит зурлыгында басылып чыккан бу өч пәрдәлек пьесаның язучысы кем булганлыгы мәгълүм түгел. Үзе Чистайда булган бер кара, мөтәгассыйб бай гаиләсе тормышыннан алынып язылган.

«Чистай комедиясе»нең мөндәриҗәсе:

1. Чистайда Хәйри исемле алтмыш яшьлек бай бер тол хатынның – капиталистның – егерме мең сум мал белән кияүгә бара торган Мәрфуга исемле җиткән, ләкин укымаган бер кызы була. Үзенең тибы әсәрдә ачык мәгълүм булмаган Ибраһим дигән бер егет шул кызны үзенә хатынлыкка алырга тели. Шул эш артыннан Казанда гаскәри хезмәттә булган Әфлатун исемле акыллы, аңлы гына бер ир уртасы кеше белән Ибраһим Чистайга килә. (Ибраһим да, Әфлатун да замана кешеләре, яңаручы кешеләр булалар.)

2. Хәйри бик надан, холыксыз, саран, хезмәтчеләренә бик җәбер итүче, riячы, рибачы, кара мөтәгассыйб бер хатын була. Үзе һәрвакыт Мәрфугага кияү эзләп, шуны кайгыртып йөри.

Әфлатун, Ибраһим өчен, шул Мәрфуганы Ибраһимга алу турында Хәйри бикә белән сөйләшә, аны аннан кодалый. Ләкин сүз башланган саен, Хәйри бикә сүзне икенчегә, үзенең шомлануына, хосусый эшләренә борып җибәрә бирә.

3. Хәйри бикәнең үзе шикелле үк Фатыйха, Фатыйма исемле мөтәгассыйб һәм шомланучан ике дусты була. Алар кич гел Хәйри бикәгә килеп утыралар. Әфлатун белән Ибраһим кызны яучылап утырганда, шул ике карчык килеп керә. Фатыйха Ибраһимны яманлап, Хәйри бикәне андан дүндерә. Шуның өстенә Ибраһим белән Әфлатун тегеләрнең өйдәге чикерткә тавышыннан да шомланып, кайгырышып утыруларыннан көлеп җибәрәләр дә, шуның сәбәпле бу икене «һәммәсе дә сезнең гөнаһ шомлыгыгыздан» дип, куып чыгаралар. Кызны алудан өмет киселә.

4. Арага үткен генә асрау Хөсни катыша, тегеләрне, бигрәк тә Фатыйханы көйгә китерү хәйләсен эшли. Ибраһим белән Әфлатун авызыннан Фатыйханың гел макталганын сөйли. Фатыйха, Ибраһимның атасы белән катышып гомер иткәнен сөйләргә тотынып, аны мактарга керешә. Шул арада, асрау хәйләсе белән, Ибраһим кулындагы алтын йөзеккә күзе төшә. Ибраһимның әтисендә күргән йөзеккә охшаганын әйтә. Хөсни Ибраһимга ишарә кыла. Ибраһим, әтинең ядкәре булсын дип, йөзекне Фатыймага бирә. Фатыйма моңа каршы Ибраһимны ни белән бүләкләргә белми торганда, Мәрфуганы димләүне сорыйлар. Аның иптәш карчыгы Фатыйха каршы төшсә дә, ахырда Фатыйма

эшне булдырып чыгара. Мәрфуга да егерме мең сум акчасы белән Ибраһимга бирелә.

Әсәрнең мөндәриҗәсе, әлбәттә, сыек. Әсәрдәге уңышлылыкны моннан эзләп булмый. Пәрдәләрнең эшләнүләре дә тулы, төгәл түгел. Бу яктан караганда, әсәр башкалары шикелле үк башлангыч бер хәлдә. Шуның өчен аның әһәмияте хәзерге караштан сәнгатьчә шәп эшләнеп чыгуында булмаячак.

Әсәрнең кыйммәтле ноктасы икенче ягында. Югарыда әйткәнебезчә, аның кыйммәте бигрәк тә телендә: саф татар теленең матур әдәбиятта беренче һәм иң беренче үрнәге булуыдыр.

Бу – бер. Икенчедән, бу әсәр безгә татарның җәдитләнү, яурупалашу хәрәкәтенең күренешләрен; тормышта, фикердә кадимчелек белән җәдитчелек арасында башланган бәрелешүләрне күрсәтә. Өченчедән, бу әсәр татар дөньясында кузгалган сыйнфый каршылык фикерләрен, зәгыйфь бер рәвештә булса да, татарда беренче мәртәбә матур әдәбият мәйданына ташлый.

1) Хәйри бикәнең хезмәткәрләренең хезмәт хакларын төрле хәйләләр белән «ун тиен, биш тиен кысып» калуы; 2) динне үз мәнфәгатенә корал итеп, хезмәткәрләренә «кеше хакына тию гөнаһ» дип, көн саен һаман үгетләп торуы; 3) ике йөз сумлык нәрсәләрне егерме тәңкәгә закладка салып, шуның белән халыкны талавы; 4) ачуланган чагында хезмәтчеләрен «ашатмый, эчертми һәм бер җиргә җибәрми» (хәтта гаеткә дә җибәрми) интектерүе; 5) әз генә «әдәпсезлек»ләре өчен хезмәтчеләренә утызар камчы ордыртуы; 6) фәкыйрьләрне һәрвакыт хурлап сөйләве кебек хәлләр һәм боларга хезмәткәрләренең, асрауларының ачынып, үртәлеп йөрүләре шундый галәмәтләрдәндер.

Бу комедиядә юк-бар нәрсә белән гел шомланып гомер итүче кара надан, мөтәгассыйб, яңага каршы килеп, гел искечә, борынгыча яшәргә [теләүче], им-томга, ырым-шырымга ышанучы, гайбәтче, үзе кеше күзенә динле, изге булып күренергә тырышучы, шулай ук «менә бу замандагы шәкертләрнең төрле гыйлемлекләрне укуларын һәм рус язуы укуларын бер дә яратмый» торган гаять холыксыз Хәйри бикә белән аның шул юлдагы дусларыннан Фатыйма белән Фатыйха – болар кара динчелекнең XIX йөзнең соңгы ярымы эчендәге татар хатын-кызлары арасыннан алынган реаль вәкилләре. Болар инде соңгы әдәбиятыбызда Галиәсгарлар, Гаяз әсәрләрендә киңәйтелгән төп орлык типлар булып чыктылар. Шуларга каршы, икенче яктан,

тормышның яңа икътисади, иҗтимагый барышы тәэсире белән аңы ачылган, җәдитләнгән Әфлатун белән Ибраһим типлары бар. Гәрчә әсәрдә болар эшләнә алмаган бер хәлдә булсалар да, һәрхәлдә, гаскәриләр, яшьләр арасында яңа барышның тәэсирен күрсәтә алалар. Аның безнең өчен иң зур әһәмияте – телендә, өслүбендә, инша техникасында; «шуның өстенә хәтта чын типка якынлатып ук кайбер табигатьләрне әдәби эшләп чыгару белән йөзне кызартмаслык бер әсәр» булуындадыр. Шуңа тагын бу әсәрнең һәвәскәрләр тарафыннан төрле җирләрдә уйналып йөргәнлек хәбәрен дә өстәргә кирәк.

Әгәр дә сез аның өстенә карасаңыз, һәрбер киеме атасы-бабасы заманындагы кием төсле; шулай кыланып, ул кеше күзенә яхшы күренмәкче була; бар яхшылык киемдә дип фараз кыла.

Әфлатун: Хәйри абыстайның алай кылануы, минем белүемчә, дөнья күрмәгәнлектән һәм яхшы белән яманны аермаганлыктан; киемдә ни хикмәт бар, адәмнең игътикады дөрест булсын; әйтсәнә миңа, Хөсни, ул көн буе ни эшли, ни кыла?

Хөсни: Кем белә аның ни эшләгәнен: сәгать алтыда йокысыннан тора; йокысыннан тора да тәһарәт алып, иртә намазны укый, намаздан бушагач, карт мәчесенең бетен, борчасын карый, аны сөйгән була, сыйпаган була, андан соң чират безгә кала: ниндәй булса сылтау табып, каюбызны – чыра берлән, каюбызны бүтән нәрсә берлән кыйный, андан соң чәй эчә дә, бик зур хисап төшкән кеше күк, башын түбән салып, хисап итеп утыра, андан соң...

Әфлатун: Аның соң хисабы ни?

Хөсни: Мәрфугага кияү эзли.

Әфлатун: Андан соң дип, ни әйтә башлаган идең, мин синең сүзеңне бүлдем, әйтеп бетер.

Хөсни: Аннан соң келәткә чыгып, закладка салынган нәрсәләрне карый; аларны бер урындан икенче урынга күчерә, тузанларны кагыштыра... Әгәр дә хезмәтчеләрендән берәрсе ни булса гаеп эш эшләсә, ул хезмәтчегә ул көн рәхәтлек юк инде; аны ашатмый, эчертми һәм бер җиргә җибәрми, шулай үткән ел ат караучыга ни өчен булса ачуы килеп, шуның өчен аны гаеткә җибәрмәде – Корбан гаете көне иде...[1]

Менә бу мисалдан без, бердән, матур әдәбиятта һәр ягы белән җөмлә төзелеше саф татарчылык юлында булганын, саф, садә татар әдәбиятының беренче төп орлыгын шушы беренче комедия биргә-

[1] Бу мисалның баш ягы «Татар театры» мәҗмугасында, клише рәвешендә. Шунда каралсын. *(Авт. иск.)*

нен; шулай итеп, аның аркылы матур әдәбиятта саф татар әдәби теле тудырылганын, икенчедән, инша техникасының Көнбатыш ысулында яңа эзгә салынып, тыныш билгеләренең дә бик урынлы куелганлыкларын күрәбез.

Бу комедияне язган әдипнең кем икәне, аның тәрҗемәи хәле безгә әле караңгы. Шулай да югарыдагы хәл безне аның тәхрир[1] эшендә тәҗрибәле, әдәбияттан да яхшы ук хәбәрле һәм телдә Каюм Насыйрилар юлын бөтен киңлеге, бөтен садәлеге белән матур әдәбиятта бик нык гамәлгә куярга керешкән яурупеист чын татар әдибе булганлык фикеренә китерә.

Әлеге мисалдан югарыдагы ике хосусиятне аңлаганыбыз кебек, янә әсәрдәге дүртенче бер хосусиятне – иҗтимагый яктан бик әһәмиятле моментны да ачык күреп калабыз. Ул да – әсәрдәге сыйнфый каршылык моментыдыр. Мисалда, күрәсез: «Үзенең хезмәткәрләре хакларын сорарга килгәндә, вак акчам юк дип, ун тиен, биш тиен кысып кала», – диелә; менә бу – татар матур әдәбиятында беренче мәртәбә күренгән сыйнфый момент, хезмәт иясенең теленнән беренче мәртәбә әйтелгән беренче сыйнфый сүз. Бу – татар баенда изелүче бер татар кызының авызыннан ишетелгән, татар пролетариатының беренче сыйнфый көрәш орлыгы. Бу – әсәрнең шул вакыттагы сыйнфый каршылыкны характерландыру өчен иң мөһим бер моменты.

**«Зур гөнаһлар» («Гөнаһе кәбаир») дөньясында, яисә татарда икенче роман[2].** XIX йөзнең соңгы ярымында татар сәүдә капиталы һәм аның ияләре, бер яктан, рус һәм Яурупаның тормыш өчен кирәкле, файдалы эшләреннән үрнәк алып, яңара, җәдитләнә, яңа мәдәнияткә таба әйләнә башлаган булса, икенче яктан, Казан кебек шәһәрләрдә татар купецлары арасында җәдитләнүнең кара яклары да күзгә нык ташлана башлый. Алар рус трактир (мәйханә)ләренә йөри башлап, шунда яурупача кыланышлар һәм эчүчелек белән дә танышалар[3]. Шуның нәтиҗәсендә татар байлары арасында фәхешкә, эчкелеккә бирелү кебек хәлләр бик таралып китә. Бу хәл бигрәк тә XIX йөзнең икенче чирегендә көчәя. Күп татар купецлары һәм

[1] Тәхрир – мөхәррирлек.

[2] Әсәрнең татарча исеменең өстенә русча «Смертные грехи. Роман из уголовной хроники. Сочинение Магомет Загир Бигиева» дип язылган. *(Авт. иск.)*

[3] «Есть сильное стремление их к русским трактирам; где познакомились с Европейскою роскошью и пьянством. Такое стремление наиболее усилилось в течение последних 20 лет». «Казанские татары» К. Фукса. 1844 г. стр. 5. Бу әсәрдә шул турыда байтак мәгълүмат бар. *(Авт. иск.)*

мещаннары, һәркөн диярлек трактир-мәйханәләргә килеп, шунда күп акча түгеп чыга торган булалар.

Шуның өстенә мондый хәлләр Казандагы татар мәдрәсәсе шәкертләре – мулла балалары арасына килеп керә башлый. Шулай итеп, бай балалары да «Гөнаһе кәбаир» (зур гөнаһ)ларга мөбтәля булалар[1].

Менә шушы хәлләр татар әдәбият дөньясында икенче романның килеп чыгуына сәбәп була. Казанда Күл буе мәдрәсәсендә укыган татар әдипләреннән Заһир Биги [18]90 елларда, шул тормыштан алып, үзенең «Гөнаһе кәбаир» дигән романын яза. Бу инде татар әдәбият дөньясында басылып чыккан романнарның икенчесе була.

Уяну, җәдитләнү дәверендәге бер роман булып, шул вакытта татар сәүдә капиталы ияләренең һәм алар мохитенең нинди хәлдә икәнлекләрен ачып биргәнлеге өчен, бу урында «Гөнаһе кәбаир»нең кыскача мөндәриҗәсе белән танышып үтик:

1. Казан байларыннан Хәмзә Агиев дигән бер хаҗиның улы – Җиһангир – шул ук Казан бае Гали Ваһаповның бердәнбер бик матур кызы булган Маһруйга (роман аны матур булганлыгы өчен «Маһруй» дип йөртә) өйләнә. Күп вакыт үтми, Маһруйның этисе, Җиһангирның да этисе, әнисе дә үләләр. Бервакыт Маһруйның әнисе кияүләре белән бергә тора башлый. Җиһангир, кими башлаган байлыгын тутыру өчен, сәүдә белән Сибирия якларына чыгып китә. Шул форсаттан файдаланып, аның хатыны Маһруй, икенче бер бай улы Якуб Галиев белән йөреп, йөккә кала. Шул вакытларда иреннән «кайтам» дип хат килә. Хатын да, шул хәбәр белән, үзенең йөклелеге турында сөйләшү өчен, йөргән егетенә бара. Ләкин инде ул моны бик салкын кабул итә.

2. Шундый хатыннарны үз өендә тудырту белән көн күрә торган хәйләкәр һәм усал бер карчык була. Хатын, әнисенә авылга барып киләм дип, шул карчыкка барып, баласын дөньяга китерә. Карчыкның киңәше һәм васитачылыгы белән шул баланы тәрбия турында Маһруй йөргән кешесе – Якуб белән тагын күрешә. Ләкин Маһруй, инде бу юлы күрешкән урыннарында (мунчада) Якубның өстенә кайнар су коеп, аны үтерә.

3. Шуның нәтиҗәсендә Маһруй кулга алына, хөкемгә эләгә. Маһруй следовательдән карчыкны шаһиткә чакыртуларын сорый. Бу эшне сизеп алып, Маһруй белән йөргән егетнең – Якубның туганы Ибраһим Галиев дигән адвокат, карчыкка барып, ике йөз сум акча биреп, баланы үтерергә һәм үзе вакыйга турында һич белмәмешкә салынырга куша. Карчык шулай эшли.

[1] Мөбтәля булалар – дучар булалар.

4. Бу эшне хатынның үз ире кайтып аңлый да, хәлне сорашу өчен карчыкка килгәндә, карчык торган өйне карап торучы хезмәтчедән вакыйганы сорашып белә һәм аны следовательдән җавапка чакыртмакчы булып кайтып китә. Хезмәтче шуның өчен үзенә бирелгән егерме биш сум акчага эчеп, исереп кайта да, карчыкка кереп, шул турыда аны куркыта. Карчык та югарыда әйтелгән адвокатка бу хәбәрне шунда ук барып ирештерә.

5. Нижгород губернасындагы бер авыл имамының улы Казан мәдрәсәләренең беренә (Күл буе мәдрәсәсәсенә) укырга җибәрелгән була. Ул анда эчәргә өйрәнеп, бозык эшләргә катышып китә. Авторча әйткәндә, «гөнаһе кәбаир» (зур гөнаһларга) мөбтәля[1] булып, ахырда шуның белән мәдрәсәдән куыла да Казан харчевнялары (мөселман ашханәләре)нең берсендә тора башлый һәм мәйханәләрнең берсендә Мәмәт исемле эчеп, кеше үтереп йөри торган бер бозык яшь кеше белән иптәш булып ала да ахырда шуның юлына төшә.

Әнә шулар икесе (мулла баласы белән Мәмәт) бергә әлеге адвокаттан биш йөз сум акча алалар да югарыдагы хезмәтчене, исерек вакытында барып, үтереп чыгалар, шунлыктан следователь дә Маһруй файдасына аннан җавап ала алмый кала. Маһруйга инде каторга хөкем ителергә генә кала.

6. Соңыннан мулла малае белән Мәмәт угрылык өчен бер чиркәүгә төшәләр. Аннан алар, тотылып, төрмәгә ябылалар. Ләкин тентү нәтиҗәсендә кесәләрендәге язулардан аларның әлеге хезмәтчене үтерүләре мәгълүм була. Соңыннан алар бу вакыйгага асыл сәбәпче итеп югарыдагы адвокатны – Ибраһим Галиевне дә эләктертәләр. Боларның өчесе дә төрмәгә ябыла. (Бу вакытта карчык үлеп калган була.) Ләкин Мәмәтнең хәйләсе белән, төрмәгә ремонт ясаучы осталар – буяучыларны (болар өч кеше була) агулы аракы эчертеп, шулар киемен киеп, болар өчесе дә төрмәдән качалар.

7. Маһруйда төрмәдә каты авыру була. Бу вакыт аны доктор үлгән дип исәпләп, муллага күмәргә әмер бирдертә. Ләкин Маһруй әле үлмәгән була. Тере мәетне күмәргә дип барып (бу эш 1888–[18]89 елда була), җир туң булганлыктан, каберне казып бетерә алмыйлар да, үлекне шунда кабергә ташлап китәләр. Үлмичә, тик һушы «йокыга киграп» яткан Маһруй, тегеләр каберлектән киткәч тә искә килеп, кәфенләрен кием итә дә, әнисе, ире һәм бер кыз баласы аның үлүе өчен кайгырып, елашып утырган бер вакытларында өйләренә кайтып килеп, бергә күрешәләр. Маһруйның кабердән качуы да һичкемгә дә мәгълүм

[1] Мөбтәля – дучар.

булмый – муллалар, caберчеләр дә иртәгесен куркуларыннан буш каберне күмеп кайталар.

Романның иң зур әһәмияте мөндәриҗәсендә. Әмма сәнгатьчә эшләнүе «Хисаметдин мулла»дан түбән тора. Бу роман – татар әдәбиятында рационализм агымының бер саф үрнәге. Монда сентиментализм нокталары юк диярлек бер дәрәҗәдә. Үзе тәмам дини рух һәм үгетчелек, вәгазьчелек белән сугарыла. Мөселманнарның, бигрәк тә мәдрәсә шәкертләренең Казан мәдрәсәләрендә алган тәрбияләренең начарлыгын, аларның анда ничек «гөнаһе кәбаир» ияләре булып җитешә икәнлекләрен күрсәтеп, укучыларны шуннан гыйбрәтләндерү уе белән языла.

Теле-өслүбе ягыннан караганда, бу роман – бөтенләй «Хисаметдин мулла» романының туганы булып, татар матур әдәбиятында Исмәгыйль Гаспринскийның «гомуми төрк теле» идеалы сызыгында язылган бер әсәр. Тик каһарманнарның сүзләрен күчергәндә генә татарчылыкка төшкәләп алуын әйтмәгәндә, шул сызыктан һич язмый, нык бара. Шуның белән бергә, монда «Хисаметдин мулла»дагыча, үзенчә заманына күрә матур тасвирлар да очрамый.

Романның бу яклары шулай. Ләкин безнең өчен романның әһәмиятле ягы – бигрәк иҗтимагый ягында, мөндәриҗәсендә булып, анда шул ук XIX йөзнең ахырларында Казандагы татар бай балаларының һәм мәдрәсә шәкертләренең тормышын һәм татар байлары арасыннан җитешкән адвокатларның хәрәкәтләрен ачып бирүендәдер.

Монда без татар фәхеш галәмендә акушерлык итеп, шуның белән көн күрүче татар карчыкларын, шулай ук XIX йөз ахырларында татарда мәйдан алып киткән һәм XX йөз башларындагы татар әдәбиятында тасвир ителә торган ярминкә яучыларының, Мәкәрҗә кодагыйларының да монда шәүләләрен күреп калабыз.

Бу романдагы фәхешче бай малае Якуб, аның туганы адвокат Ибраһим, бай кызы Маһруй, мулла баласы – мәгъзүм (мәхдүм) Габделгафур, акушерка «изге» карчык, шулар өстенә татар арасында Мәмәт кебек усал, хәйләкәр, оста угрылар, кеше үтерүчеләр безгә шул замандагы татар тормышының бер өлеш каһарманнарын бирә. Шул замандагы татар тормышының кара якларын өйрәнү өчен шундый кирәкле материалларны бирү ягыннан бу роман үзендә тарихи бер әһәмиятне күрсәтә.

Шуның өстенә, телдә Каюмнарның татарчылык агымына каршы XX йөзнең башларына таба һаман икенче яктан «төркичелек»

агымының, Гаспринский юлының татар әдәбиятында көч ала баруын күрсәтү өчен дә бу – ачык үрнәкләрнең берсе[1].

Бу романда без татар учительләренең татар әдәби теленә *юрист, стул (урындык), кассирша, следователь, почётный гражданин, секретный чашка, копейка, бутышник, городовой, катор, повестка, акушерка, героиня, петля, автор, смотритель, школ, арестант* кебек рус телендәге сүзләрнең дә керә башлаганын күрәбез.

**Өченче роман.** Заһир Бигинең «Гөнаһе кәбаир»еннән соң татар әдәбият дөньясында өченче роман булып «Өлүф (меңнәр), яисә Гүзәл кыз Хәдичә»[2] дигән романы язылa. Кечерәк кулда 77 бит зурлыгында, 1886 елда басылып чыккан бу романда янә Казан байлары һәм мирза балалары тормышыннан алынган вакыйга тасвир ителә.

Әсәрнең кыскача мөндәриҗәсе:

1. Бервакыт Казан байларыннан берәүнең улы («казанский почётный гражданин») Муса Сәлимов дигән егет Петербургка бара. Анда ул «Татарский ресторан»да шул вакытларда гына, авыру сәбәпле, гаиләсе белән Петербургка килгән Кырым мирзаларыннан берәүнең бик матур кызын – Зөләйханы берничә мәртәбә күреп, аңа гашыйк була. Кыз да егеткә гашыйк була. Кызга хат язып, үзенә кәләш булырга сорый. Кыз риза була. Ләкин кызның әти-әниләре кызны Мусага бирергә риза булмыйча, шул көе Кырымга кайтып китәләр.

2. Зөләйханың әтисе үлгәч, бервакытны Казанга Габдуллин дигән кешенең номерына Зөләйха килеп төшә. Мусаны номерга үз янына чакырып хат җибәрә. Муса кич чакырылган вакытында аңа килә. Кыз да, үзенең Петербургтагы вәгъдәсе буенча, Мусага кәләшлеккә чыгарга килгән икәнен аңлата. Мусаның исә бу вакытта Казан байларыннан Әхмәди Хәмидов кызы Хәдичәне (шулай ук бик матур була) йөз мең сум акчасы белән алырга дип хәзерләнеп йөргән чагы була. Муса Зөләйхага әнә шушы хәлне әйтеп, үзен инде кәләшлеккә ала алмаячагын аңлата. Муса кайтып китә. Кыз да аларга мәхәббәт теләп торып кала. Иртәгесен шәһәрдә Зөләйханың номерда үтерелүе хәбәре тарала. Номерга күп халык җыела, шау-шу китә. Тикшерүләр башлана. Тикшерүләр нәтиҗәсендә, Зөләйханы үтерүче Муса дип аңлап, аны кулга алалар. Хөкем була. Муса унъеллык катор хезмәтенә хөкем ителә.

[1] Бу романның тел-өслүбеннән мисал өчен беренче басмасыннан 1–2 битләр укылыр. *(Авт. иск.)*

[2] Романның башына татарча исеменең өстенә русча исеме куела; шул рәвешчә: Олюф или красавица Хадича. Роман Загир ибне Ярулла Бигеева. Бу роман 1908 елда, «Бәян әл-хак» матбагасында өченче мәртәбә басыла. *(Авт. иск.)*

3. Йөз мең сум акчалы Хәдичәне, Муса белән ярышып, үзе алырга йөргән Габденнасыйр Хәбибуллин исемле (тышкы мөгамәләдә Мусаның дусты) янә бер егет була. Мусаның хөкемгә эләгүенә төп сәбәпче дә шул була. Муса каторга хөкем ителгәч, Габденнасыйр Хәдичәне үзенә алу чарасына керешә һәм кызны үзенә бирүләре турында ризалык та ала.

4. Мусаның туганы Нигъмәтулла, адвокатка яңадан мөрәҗәгать итеп, аны күпме генә акча бәрабәренә булса да коткаруын үтенә. Бик күп акчалар түгеп, шул эшкә тотыналар. Шул ук Мусаның Зөләйханы үтерүче дип гаепләнүенә сәбәп булган Шубин дигән бер эзләкче (*сыщик*) аркылы адвокат Зөләйханың үтерүчесен эзләттертә. Моның өчен Шубин Кырымга китә. Аннан барып, Зөләйханың үзен үтерер алдыннан әнисенә язган хаты барлыгын аңлый. Шул хатны Казанга алып кайта. Шуның аркасында Муса хөкемнән котылып, азат була да, Хәдичә Габденнасыйр кулыннан ычкына; инде аны аңа бирмичә, әүвәлге сөйгәне Мусага бирәләр. Габденнасыйр да шул кайгыдан агу эчеп, үзен үзе үтерә. Үләр алдыннан Зөләйханың үлеме өчен Мусаның хаксыз хөкем ителгәнен, шуңар үзе сәбәп булганын төрле яктан игътираф итеп[1] язу калдырып үлә.

Әсәрнең безгә әһәмиятле бер ягы – вакыйганың яурупалашкан татар байлары һәм мирзалары тормышыннан алынган булуында. Әсәрнең каһарманнарыннан Зөләйха белән Габденнасыйр Хәбибуллин гимназия бетергән булсалар, Муса Салихов та Петербург университетын тәмам иткән, үзләре бары да бик динлеләр. Вакыйга әнә шулар тормышыннан алына.

Шуның өстенә янә әсәрнең икенче бер игътибар ителә торган ягы шул: инде әдип бу әсәрендә «Гөнаһе кәбаир»нең теленә караганда күп җиңеләйтелгән, татарчалаштырылып, Каюмнар юлына якынлаштырылган бер тел белән яза. «Исмәгыйльчелек», ягъни «гомуми төркчелек» инде бу әсәрдә үзенең җиңелергә авыша башлавын ачык сиздертә.

**Сәяхәтнамәләр.** Беренче әдәби дәверебездә Исмәгыйль ага сәяхәтнамәсен әйтеп үткән идек. Бу татар әдәбиятында безгә мәгълүм булган беренче сәяхәтнамә иде.

Аннан соң Мәрҗанинең Гарәбстанга сәяхәт хатирәсе (дөресе, хаҗга бару хатирәсе) булды. Бу хатирә 1897 елда Риза казый тәхрире астында «Рихләте Мәрҗани» исеме белән басылып чыккан иде.

Шулардан соң татар әдәбиятында Заһир Биги тарафыннан «Мавәраэннәһердә сәяхәт» исемендә өченче сәяхәтнамә язылды.

[1] Игътираф итеп – раслап.

1893 еллар чамасында язылып та, 108 бит зурлыгында 1908 елда басылып чыккан бу сәяхәтнамә – исеменнән күренеп тора, Төркестанга сәяхәтнең нәтиҗәсе булып язылган бер әсәрдер. Монда Мавәраэннәһернең (бигрәк тә Бохара, Сәмәркандның) иҗтимагыймәдәни хәле, тәрбия, мәгарифе, гореф-гадәтләре, тормышлары турында языла. Әсәрдә байтак әһәмиятле тарихи мәгълүматлар һәм тәнкыйди карашлар бар. Кыскасы, тарихи яктан әһәмиятле мәгълүматны эченә алган[1].

Бу китапта Заһир Биги тагын да ачыграк бер рәвештә яурупалашкан, күзе тәмам ачылган бер татар язучысы булып күренә.

Китапның теленә килгәндә, бу да – шул ук «Гөнаһе кәбаир»нең туганы, шуның өстенә бусы тәмам госманлыча – Анатоли төркләре шивәсенчә язылган бер әсәр дип әйтерлек бер дәрәҗәгә килә язган; татар халкыннан бик күп озаклашкан гомуми төрк теле» идеалының бер нәмунәсе[2] булып чыккан.

*Заһир Бигинең кыскача тәрҗемәи хәле*

Мөхәммәт Заһир Бигиев 1870 ел Ростов-Донда дөньяга килеп, 1902 елда вафат иткән. Башлангыч укуны үз тирәсендәге иске мәдрәсәләрдән алганнан соң, Казанга килеп, Күл буе мәдрәсәсендә укыган. Соңыннан русча укып, рус әдәбиятын аңларлык, аннан файдаланырлык дәрәҗәгә килгән. Французчадан да бераз өлеше булган, диләр. Үзе Ростовта имам булып яшәгән.

Әсәрләре:

1. «Гүзәл кыз Хәдичә». Бу әсәрен ул «Погон за миллионами»[3] дигән бер русча әсәргә ияреп язган.

2. «Гөнаһе кәбаир» (югарыда моның белән танышып чыктык).

3. «Катилә». Бу әсәре Русия мөселманнарында хатын-кызларның җәберләнүләрен, тәрбиясезлекләрен күрсәтеп язылган. Моны бик оста тасвир белән язылган, диләр.

4. «Мөртәт». Аның шушы романы «Гөнаһе кәбаир»нең икенче кисәге яисә шуның дәвамы шикелле бер әсәр булырга кирәк. «Гөнаһе кәбаир»нең соңында: «Олуг юрист мәккяр вә мөфәттин[4] Ибраһим» илх[5]...

---

[1] Бу турыда «әл-Ислах», 21 нче сан, 1908 ел. «Дамелла» имзасы белән Ф. Әмирханның язган тәнкыйть һәм тәкъризе бар. Шунда каралсын. *(Авт. иск.)*

[2] Нәмунәсе – үрнәге.

[3] Сүз 1905 елда Варшавада басылып чыккан «Граф-самозванец, или Погоня за миллионами» романы (авторы билгесез) турында бара булса кирәк.

[4] Мәккяр вә мөфәттин – хәйләкәр һәм фетнәче.

[5] Илх – һәм башкалар.

дигән сүзләре белән Заһир Биги үзе үк тә шул романның шундый бер роман булачагын кыскача аңлатып үтә. Аңа алдан шундый кыскача бер характеристика биреп куя. Ләкин бу роман да «Катилә»се шикелле үк басыла алмады.

5) «Мавәраэннәһердә сәяхәт» (югарыда күзәтелеп үтелде).

## [III]
## XX йөзгә кергәндә

XX йөзгә кергәндә инде Русиядә иҗтимгый-сәяси хәрәкәт көчәя, революция дулкыннары үзләрен ачык сиздертә башлаган булалар. Әнә шул хәрәкәт, шул дулкыннар татарның тәраккый хәрәкәтен кыздыру өчен дә тәэсир итешәләр. Шуның нәтиҗәсендә татардагы яңа иҗтимагый хәрәкәт күзгә күренерлек булып киңәю юлын алды. Матди һәм фикри тормышта яурупалашу, җәдитчелек татар дөньясының һәр ягына тамырын җибәреп, кадим белән көрәш һаман үзенең көчен, кызулыгын арттыра барды. Шуның өстенә тагын җәдитнең кадимне җиңү адымнары күренде[1]. Кыскасы, XX йөзгә кергәндә, иске татар байларына, шуларның иске феодаль тормышларына, борынгы мәдәни тәртипләренә каршы татарның яңа либераль буржуазия сыйныфы яхшы ук нык оешкан хәлдә аерым бер җәмгыять булып мәйданга нык аяк басты. Инде ул өстенлекне, мәдәни-иҗтимагый юлбашчылыкны, хакимлекне ачыктан-ачык үзенә сорый башлады. Шуның нәтиҗәсендә, буржуазия тарафыннан түбәндәге таләпләр уртага ташланды:

1. Гарәпчә, фарсычалатып язмыйча, «аңлагандай кылып», ачык төрки белән язарга; мәктәпләрдә төркине нык укытырга.

Бу төркичә язуны да Каюмнарның «татарча» язулары дип аңларга кирәк. Татар буржуазиясе шул ук язуны «төрки» исеме белән нык сорый башлый. Мәсәлән, Гани бай үзенең берничә җәдит мәктәбе мөгаллимнәренә җибәргән хатларында хәтта бу турыда боерык рәвешендә менә болай дип яза:

а) «Миңа хатны язасың аять берлән, хәдис берлән; аять-хәдисне мин аңламыйм, бер мулла кирәк переводчик, мин сезне укыткан

[1] Гани бай инде һәммә җиргә, һәркемгә язган хатларында җәдитнең кадимне җиңә баруын яза башлый. Хәтта мөфтигә язган хатында да ул: «Хәзер безнең тараф җиңгән кебек күренә башлады», – дип куана («Гани бай» китабы, 50 бит). *(Авт. иск.)*

идем төрки язарга, укырга. Әле дә булса төркичә хат яза белмисең икән. Һәркемнең үзенә лаек хат язарга кирәк, аңлагандай кылып»;

б) «миңа хат язганда, төркичә языгыз, гарәпчәне мин белмим. Без сезләрне тәгълим кылган идек төркичә язарга, укырга. Безгә хатыгызны гарәпчә язасыз. Без гарәпчәне аңламыйбыз. Бер тәрҗеман кирәк. Хатыгызга караганда, төркичә яза белмисез икән, яза белмәгәч, төркичә сүзне дә сөйли белми торгансыздыр. Укыткан балаларыгызга ничек итеп өйрәтәсез икән. Бу эшләрегезгә без хәйранбыз. Мондан болай хатны төркичә яз, төркичә дә дога кылып буладыр» («Гани бай» китабы, 72 бит).

2. Дини яңалыкларны, дини реформаларны нык дәвам иттерү.

3. Диннең яңаруга, тәрәккыйгә, мәдәнияткә каршы түгеллеген шул ук диннең үз исеменнән, гыйльми-фәлсәфи, тарихи юл белән исбат итәргә маташып, халыкны шул якка аудару.

4. Дини нәрсәләрне, дини белемнәрне халыкның үз теленә әйләндереп өйрәтү.

5. Хатын-кызларга шәригать сыйдырган хөрриятне бирдерү һәм шул «шәригать сыйдыру»ның чиген тормыш кирәгенә каратыбрак киңәйтә бару.

6. Имляны гамәли бер тәртипкә сала башлау.

7. Мәрҗаниләр белән башланган төрк-татар тарихын, төрк халыкларын өйрәтә башлау хәрәкәтен кыздыру.

8. Русча укуны киңәйтү, рус дәүләт мәктәпләренә керүгә киң юл ачарга, шуңар күбрәк мөмкинлек тудырырга тырышу.

9. Яңа фән, гыйлем белән коралланган муллалар хәзерләү хәрәкәтен ашыктыру.

10. Җәмгыяте хәйрия, тәгавене ислам[1] кебек җәмгыятьләр тудырып, оешу хәрәкәтен бер юлга салу.

XX йөзгә кергәндә, татар буржуазиясенең икътисади барышы, яңа иҗтимагый-мәдәни хәрәкәте менә шундый таләпләрне инде ачык, гомуми бер таләп иттереп алган, шуларны тизләтү чараларын күрә башлаган иде.

Бу хәрәкәтләрдә идеология юлбашчысы, гыйльми-әдәби таяныч булырлык яңа кешеләр, яңа көчләр дә хәзерләнеп мәйданга чыга башлый. Төркия, Мисырларда укып кайтучылар шулай ук ул мәмләкәтләрдәге ачык фикерле дин галимнәренең яисә андагы дини-иҗтимагый реформачыларның әсәрләрен укып, шулар аркылы

[1] Тәгавене ислам – ислам ярдәме.

фикерләрен ачып өлгергән татар дин галимнәре арасыннан яңа дини реформаторлар чыгып, эшкә тотыналар. Болар шушы хәрәкәтләрендә һәрвакыт Оренбург, Казан, Уфа, Сембер, Троицк, Себер байлары белән бик якыннан аңлашып барып, татар буржуазиясенең идеологиясен күтәреп чыгалар һәм шуны яклауда, гомумән, дини-иҗтимагый реформачылыкта тагын да катгыйрак, батыррак хәрәкәт күрсәтә башлыйлар. Шуларга рус мәктәпләрендә укучылар, Учительский школа адәмнәре дә кушылалар. Фатих Кәрими, Рәшид казый, Риза казый, Хәсәнгата казый, Хәйрулла Госмани, Әхмәтҗан Мостафа[1], Һади Максуди, Шакирҗан Таһири, Гаяз Исхакый, Габделгалләм Фәезхани[2], Гайнетдин Әхмәров[3] һәм бәгъзе Троицк голәмалары кебекләр шулар җөмләсеннән булалар.

Менә шундый яңа гыйльми, әдәби көчләр аркылы төрле юллар белән дини, милли хисләр һаман үстерелгәннән үстерелә, көчәйтелә барыла. Шуның өстенә татар буржуазиясе арасында һаман ике агым – мөселман татарчылык агымы белән мөселман төркичелек агымы көчәеп, төркчелек галәбә кыла башлый. Беренче имкян[4] ачылу белән, тиздән, шаулатып, шуның байрагы күтәрелү хәзерлеге күрелә. Кыскасы, татар буржуазиясе инде динне үз мәнфәгате юлында гыйльми буяулар белән матурлап, шуны үзенә корал иткән хәлдә, мөселман төркчелек байрагы астында иске феодалчылыкка, иске тормышка, аның борынгы ямьсез гадәтләренә, традицияләренә каршы соңгы каты көрәш юлларына хәзерләнә.

Бу юлдагы көрәшләр дә гыйльми, әдәби юлдан бара. Бу көрәшләрдә юлбашчылык, команданлыкны да инде үзенең «Тәрҗеман» гәзите аркылы Исмәгыйль Гаспринский үз кулына ала. Кавказ матбугаты да шул юлда аңа юлдаш булып, ярдәмгә җитешә.

## 1. Белем әдәбияты

**Тарих һәм җәмәгатьчелек.** XX йөзгә кергәндә без, бер яктан, гыйльми әдәбияттан яңа әдәби көчләр аркылы тагын да яңа ысул, яңа материаллар белән тарих әдәбиятының баш күтәргәнен күрсәк;

[1] Әхмәтҗан Мөхәммәдрәхим улы Мостафин (1860–1938) – җәмәгать эшлеклесе, педагог һәм имлячы.

[2] Габделгалләм Фәезхан улы Фәезханов (1850–1910) – тарихчы, филолог, тәрҗемәче, публицист. Х. Фәезхановның энесе.

[3] Гайнетдин Нәҗметдин улы Әхмәрев (1864–1911) – тарихчы, археограф, педагог, җәмәгать эшлеклесе.

[4] Имкян – мөмкинлек.

икенче яктан, журнал рәвешендә, аерым бөтен бер китап булып та, дини-иҗтимагый әсәрләр чыга башлаганын күрәбез. Боларның һәммәсендә дә һаман шул ук көрәш – җәдитчелекнең кадим белән көрәше бар.

**Тарих әдәбияты һәм Риза.** Бу мәйданда Риза казыйның татар гыйлем дөньясында иң кыйммәтле һәм дәвамлы күп тарихи материалларны эченә алган «Асар»ның бер кисәге, 1898–[18]99 елларда язылып, 1900 елда басылып чыга. 1901 ел эчендә – икенче, [1]903 эчендә – өченче, дүртенче; [1]904 эчендә бишенче, алтынчы, җиденче, сигезенче кисәкләре басылып чыга һәм шул ук елда тугызынчы кисәген бастырырга рөхсәт алынган була[1].

«Асар»лар тик бер ялангач тарих булып кына язылмадылар. Монда Риза каләме аркылы, бердән, тарихи, гыйльми тәнкыйтьләр йөртелә; икенчедән, һәртөрле иҗтимагый, мәдәни һәи әдәби мәсьәләләргә кагылып, шул турыда яңа заман тонында яңа мөляхәзәләр[2], күп яңа фикерләр, ачы тәнкыйтьләр языла; шуның белән бергә, болардан Коръән исеменнән наданлык һәм тәкълидчелеккә[3], суфилык һәм ишанлыкларга, кадимчелеккә, өшкерүтөкерүләргә; кешене тиз генә кяфер дип печать басып баручылыкка; һәртөрле тәгассебләргә; дога белән, дин белән сәүдә итүчелек кебек хәлләргә шул ук дин, Коръән исеменнән шәфкатьсез рәвештә каты ташланыла. Укучыларга төрле иҗтимагый фикерләр бирелә.

Кыскасы, «Асар»да без дин белән фәннең укмаштырылуыннан хасил булган яңарган, яурупалашкан бер мөселман татар мөхәрриренең мие аркылы күп яңа фикерләр күрәбез. Шулай ук үзенчә бик матур оештырылган, тәртипләндерелгән бер буржуазия идеологиясе байрагын күтәргән көчле бер әдәби каләм белән очрашабыз.

**Төркчелек юлында аерым бер гыйльми әдәби тел.** Риза казыйның кирәк «Асар»ы кебек гыйльми әсәрләре, кирәк башка әдәби әсәрләре аркылы күтәреп чыккан әдәби теле, әлбәттә, Каюмнар татарчасы түгел. Шулай ук тәмамән «Тәрҗеман» төркчәсе дә түгел, бәлки төркчелек, тел якынлык нигезендә торып, шушы ике уртада булган бер «төрк теле» иде. Ләкин шуңа карамастан, бу әдипнең каләме, Каюмнан башка һәммә татар әдипләреннән дә алда, үзенә

[1] Беренче кисәге – Казанда университет матбагасында, калганнары Оренбургта Ф. Кәримов матбагасында бастырыла. *(Авт. иск.)*

[2] Мөляхәзәләр – фикерләр.

[3] Текстта «тәнкыйтьчелеккә».

аерым эшләнгән, үзе аркылы һәрвакыт иясенең әдәби кыяфәтен ачык күрсәтеп, танытып тора торган татлы, җанлы бер әдәби өслүб белән мәйданга чыгып, шул нигездә ахыр гомеренәчә дәвам итте. Ул бу турыда вакытындагы матбугатта да ачык игътираф ителеп үтте: «Өслүбе илә һәр язучыны аерырга мөмкин; әмма Риза казый бу турыда бигрәк мөмтаз[1]. Ул тарзы тәфәккердә һәм ифадәсендә[2] бигрәк мөстәкыйль бер шәхсият гарыз итә[3]».

XX йөзгә кергәч, татар әдәбият дөньясында, бер яктан, асыл нык тәэсирле тел, бигрәк тә гыйльми әдәбиятта үрнәк ителеп алына башлаган бер өслүб, «Тәрҗеман»ныкы булудан бигрәк, Ризаныкы булды. Бу өслүб татар әдәбият дөньясында хәтта [19]17 елларгача күп каләм ияләребезгә нык тәэсир итеп килде. Ләкин Ризаның теле-өслүбе, әлбәттә, Каюмнарныкына – саф татарчылыкка, бигрәк тә татарчылыкка каршы иде. Риза һичвакыт халыкны да, телне дә «татар» дип атауга риза булмады.

*Искәртмә:* Риза каләме белән XX йөзгә кергәндә алга ташланган гыйльми-әдәби телдән үрнәк өчен «Сәлимә, яки Гыйффәт» дигән хикәясенең 8 бите укылып үтелер (1899 да басылган). Шулай ук 4 нче җөзьэ «Асар»ның 94–95, «Әсма» дигән хикәясенең 20–22 битләреннән мисаллар укылыр.

**Җәмәгатьче каләм һәм «тарихи кыңгырау».** Гыйльми, дини, иҗтимагый әдәбиятта шул Ризалар белән бертөрле үк юлда һәм шул ук идеологиянең батыры булган икенче бер каләм аркылы журнал тибында бере артыннан икенчесе чыгып бара торган рәвештә «Миръат» («Көзге»)[4] исемендә рисаләләр чыгарыла башлады. 1900 елда чыгарыла башлаган бу рисаләләрнең 1904 елда 17 нче саны басылып чыккан иде инде.

Җәдитчелек көрәшендә тагын да гамәли һәм тагын да шау-шулырак батырлардан шушы рисаләләрне чыгаручы Рәшид казый булды.

---

[1] Мөмтаз – аерылып тора.

[2] Тарзы тәфәккердә һәм ифадәсендә – фикерләү рәвешендә һәм аңлатуында.

[3] Ж. Вәлиди, «Аң», сан 4, ел 1915. *(Авт. иск.)*

[4] «Миръат» («Көзге») – Рәшит Ибраһимов наширлегендә иҗат ителгән журнал тибындагы брошюралар сериясе. Басма татар иҗтимагый фикере барлыкка килүдә зур роль уйный. Аңарда татар җәмгыятенең дини һәм иҗтимагый-мәдәни тормышы мәсьәләләре яктыртыла. Төп игътибар халык мәгарифе, хәйриячелекне үстерү мәсьәләләренә юнәлтелә. Мәкаләләрне Р. Ибраһимов үзе яза, шулай ук укучылар хатлары да басыла. Брошюралар бигрәк тә җәдиди мәдрәсәләрдә укучы алдынгы шәкертләр арасында яратып укыла.

Татар дөньясының һәрбер почмагында шалтырап, халыкны уятып йөреп тә, соңыннан үзенә «тарихи кыңгырау»[1] дигән иң муафыйк бер исемне казана алган[2] бу мөхәррир дә армас-талмас бер каһарман булып чыкты. Ул татар дөньясында беренче мәртәбә каләмен рус самодержавиесенә каршы юнәлтте. [18]95 елда шундый рухтагы «Чулпан йолдызы» дигән әсәрен Истанбулда бастырды. Рус самодержавие цензоры бу әсәрне Русиягә кертүдән тыйса да, шул заманның беренче мәмнуг[3] әсәре бик күп яшерен юллар белән Русиягә керә иде.

Рәшид казый да «Миръат»ында мәдәни, иҗтимагый, гыйльми-әдәби күп мәсьәләләргә кагылды. Җәдитләнү, яурупалашу, Яурупа гыйлемен алу; кадимчелеккә, тәгассебкә, суфилык-ишанлыкларга каршы көрәшү юлында зур шау-шу күтәрде. Шул «Миръат»лары аркылы татар дөньясында күп тәэсир ясады.

Ләкин Рәшид казый Риза шикелле системлы, чын төпле гыйльми бер юлда килеп чыга алмады. Аның бөтен хикмәте, гыйльми-әдәби бер систем бирүдән бигрәк, һич тукталмый шалтырап тора торган «тарихи кыңгырау» булып, халыкны уятып йөрүендә күрелде. Ул: «Берлек, дустлык кирәк, бер-беребезгә ярдәм кирәк, гыйлем, һөнәр кирәк, тәрәккый кирәк, әдәбият-матбугат кирәк, театр кирәк, җәмгыяте хәйрияләр кирәк, фикере ачык, мәгълүматлы галимләр кирәк, хөкүмәт – рус мәктәпләрендә укырга кирәк, русча мәгълүматлы муллалар кирәк, төрле кимчелекләребез бик күп, шуларны берләшеп, бердәмлек белән бетерергә кирәк, «фанатизм» – наданлык тәгассебләреннән качарга кирәк, балаларны заманага яраклы итеп тәрбияләү кирәк, бигрәк тә иң элек кызларны укыту кирәк», – дип, һәр урында азан әйтеп, бөтен гомере буенча шыңгырады да йөрде. Кайсы вакыт урынлы-урынсыз хөкүмәткә тәрилкә тотып, аны бик урынсыз мактап куюларын игътибарга алмаганда, вакытында аның бу азаны иске феодализм калдыкларын җимерүдә татар өчен бик файдалы булып чыкты.

Рәшиднең әдәби теле Ризаларныкы шикелле матур итеп эшләнмәгән; аларныкы шикелле юнылмаган, шомартылмаган бер тел

[1] Бу тәгъбир Галимҗан Ибраһимовтан алына. *(Авт. иск.)*

[2] Татар сәясәтчесе, дин әһеле Габдерәшит Ибраһимовның вафатына багышлап, «Татарстан хәбәрләре» газетасының 1922 елгы 1 март (51 нче) санында «Галимҗан Ибраһимов» имзасы белән басылган «Тарихи кыңгырау өзелде (Рәшид бабай үлде)» мәкаләсе күздә тотыла.

[3] Мәмнуг – тыелган.

булса да, бу тел тегеләргә караганда бигрәк Каюмнар агымына күп якын иде. Ягъни аның теле, гәрчә госманлылык, төркчелек тәэсире астында исә дә, үзендә татарчылык өлеше күп булган бер тел иде. Шуның өстенә, ул «Миръат»ның соңгы кисәкләрендә һаман ныграк татарлаша барды.

Ләкин шуның белән бергә Рәшид казый, Ризалар шикелле үк, мөселман төркче түгел, мөселман татарчы иде.

Рәшид казый үзе, XX йөзгә аяк басканда, беренче «Миръат»ында татар мөхәррирләре турында: «Бу көн һәркаюсы кулына каләм тотып, китаплар вә төрле рисаләләр язарга керештеләр; кеме – татарча, кеме – төркчә, кеме нә татар вә нә төрки – ике арада бер тел берлән язып нәшер әйләделәр»[1], – дип яза. Әнә шушы өч төркем татар мөхәррирләре эчендә Рәшид казый шуларның өченчесе – «ике арада» булганы, ләкин татарчылыкка күбрәк авышканы иде. Ул, Ризалар шикелле, халкыбызны татар дип атаудан да курыкмады: «Безнең татарларда һәрнәрсәгә истигъдад вә кабилият[2] бар»[3] һәм «безнең бәгъзе мәктәпдән чыккан, гүзәл мәгълүмат әсхабе адәмләремез якын заманда һәртөрле фәнне вә әдәби китапларны рус теленнән халис татар теленә тәрҗемә идәрләр»[4], – дип, татарчылыкка тартып язды[5].

## 2. Матур әдәбият

**XX йөзгә кергәндә әдәби ике төркем.** XX йөзгә кергәндә, әдәби телдә ике төрле төркем ике юлда әдәби хәрәкәт алып бара. Берсе – Гаспринский нигезендә төркчелек хәрәкәте, икенчесе дә – татарчылык хәрәкәтедер. Татар тормышының барышы XIX йөзнең соңгы ярымы эчендә, үз-үзеннән мәҗбүри рәвештә, Каюм сызыгында матур татар әдәбиятын һәм аның телен эшләүче көчле бер әдәби төркем оештырды. XX йөзгә кергәндә, бу юлда шушы төркемнең эше күзгә күренерлек бер хәлдә иде. Бу төркем тарафыннан гавами татар әдәби теленең төп нигезе корылып, бу тел шул нигездә, шул төп сызыкта үстерелә башлаган иде. Төркемнең әгъзалары да Ильяси, Ф. Халиди, «Чистай комедиясе»нең иясе, Заһир Биги, Галиәсгар

[1] «Миръат», беренче кисәк, 9 бит. *(Авт. иск.)*
[2] Истигъдад вә кабилият – сәләт.
[3] «Миръат», икенче кисәк, 7 бит. *(Авт. иск.)*
[4] «Миръат», өченче кисәк, 10 бит. *(Авт. иск.)*
[5] Рәшид казыйның тел-өслүбеннән мисал итеп беренче «Миръат»ның 13–18 битләре укылыр. *(Авт. иск.)*

Камал, Фатих Кәрими, Садри Максуди, Гаяз Исхакый, Ярулла Вәли һәм үзенең «Чын әкият хикәяләре» исеме белән[1] зур кулда 52 бит зурлыгында 1901 елда басылып чыккан китабы аркылы мулла Шиһабетдин Рәхмәтуллин[2] вә башкалар булдылар.

XX йөзгә кергәч, аның беренче уны эчендә бу турыда шушы төркем әгъзаларыннан Галиәсгар Камал белән Гаяз кебек бәгъзе бер җитезрәкләре тагын да ныграк, кызурак бер эшчәнлек белән тагын да көчлерәк тәэсир күрсәтә башладылар (бу мәсьәләгә соңыннан тагы тукталыначак).

Боларга каршы яктан Исмәгыйль Гаспринский нигезендәге икенче төркем дә һаман көчәя барды. Аның әгъзалары да Муса Акъегет, Заһир Бигиләрдән соң Риза казый һәм башкалар булдылар.

**Төркчеләрнең көчле вәкиле һәм аның әдәби әсәрләре.** Төркчеләр төркеменең көчле вәкиле Риза булды, аның «Сәлимә» белән «Әсма»[3] дигән ике озын хикәясе (соңгысын кечкенәрәк бер роман дип тә була. Икесе дә Гафил бине Габдулла кушаматы белән) басылып чыкты. «Сәлимә» белән «Әсма» идеологиядә һәм телдә яурупалашкан, җәдитләнгән төрк-мөселманчылыкның татар матур әдәбиятында шактый бер сәнгатьчелек белән эшләнеп чыккан бер үрнәге һәм шул агымның матур әдәбиятыбызда һаман үсүгә, киңәюгә таба баруының дәвамы, шуның иң ачык бер галәмәте иде. Шуның белән бергә бу ике әсәр, чыннан да, үз вакытына күрә әдәби яктан үзенә билгеле бер юл белән үсеп җиткән көчле талантлы бер төрк-мөселман миенең җимеше иде. Шулай ук болар идеологиядә, төп максатта Гаспринскийның «Франкистан мәктүбләре» белән «Дар әр-рәхәт мөселманнары»ның бәлки игез туганы булып үскән бер әдәби җәүһәрләр иде.

Риза казыйның, гыйльми өслүбе шикелле, әдәби өслүбе дә нәкъ үзенеке булып, үзлекле бер рәвештә башкалардан аерылып, ялтырап ятканын без шушы ике хикәясендә бик ачык күрәбез. Аның өслүбе – «Казанчадан бозылган шәхси вә кәйфи[4] бер

[1] Бу китап Казанда Думбровский матбагасында Шәрәфетдин Шәһидуллин тарафыннан бастырылып таратыла. Бу китапның теле – үзенә русча сүзләр байтак катышкан гавами бер татарча тел. *(Авт. иск.)*

[2] Шиһабетдин Габделгазиз улы Рәхмәтуллин (XIX йөзнең икенче яртысы – XX йөз башы) – тәрҗемәче, нашир.

[3] «Сәлимә» дигән хикәясе – 1899 елда Терегулов һәм Шакир Таһировлар тарафыннан Казанда Думбровский типографиясендә, «Әсма»сы да 1903 елда Оренбургта Кәрими типографиясендә басылды («Әсма»ны басарга рөхсәт алыну 1902 елдадыр, язылуы 1901дә булса кирәк). *(Авт. иск.)*

[4] Кәйфи – кәефенә карап.

шивә»[1]. Ләкин әдәби матур эшләнгән, бизәкләнгән бер шивә, югары катлау, җәдит голәма шивәсе иде.

Татар дөньясында идеологиядә, төп максатта, әдәби телдә төрк-мөселманчылыкның беренче төп тамыры Исмәгыйль Гаспринский миендә үстерелеп, беренче мәртәбә шуның каләме аркылы аның «Тәрҗеман» гәзите, «Франкистан мәктүбләре», «Дар әр-рәхәт мөселманнары» дигән хикәяләре белән баш күтәреп килеп чыккан иде. Татар дөньясында Риза әнә шул тамырның икенче зур әдәби тармагы булды. Шулай итеп, Урал, Волга буйларында, «Уфа сахралары»нда тәрбияләнгән Риза мие Кара диңгез буйларында, Кырым дачаларында хәрәкәткә башлаган Исмәгыйль мирза Гаспринский миеннән үзенең төп әдәби-иҗтимагый илһам орлыгын алды, шуннан соң шул нигездә, шул юлда үз иҗатларын үстереп алып китте. Шуның өчен тел-өслүб, аның үткенлеге ягыннан болар ике бәрабәр сызык булып күренсәләр, әдәби әсәрләрнең мәүзуг, мөндәриҗәләре, максатлары, кыйблалары, алган әдәби тоннары ягыннан да бер-берсе белән бик якыннан ярашып, татар дөньясының ике почмагында берсе – мирзалардан, икенчесе руханилардан ике әдәби үрнәк булып бардылар.

«Сәлимә» хикәясе белән «Әсма» романы, гәрчә Гаспринский әсәрләре белән идеологиядә, идеалда бер төп сызыктан барсалар да, үзләренә мәүзуг, мөндәриҗә итеп алган иҗтимагый тормыш ягыннан болар бер-берсеннән аерылалар. Риза татарның үз тормышы эчендә әйләнергә тырыша. Аның «Сәлимә»се дә, «Әсма»сы да тормышка тагын да якын; бәлки боларда алынган каһарманнар, гәрчә күп идеаллаштырылып булса да, Идел буе татарларының үз икътисади, иҗтимагый тормышына, шундагы иҗтимагый-мәдәни хәрәкәтләрнең кузгалышына багланып баралар. Мөхәррир болардагы тасвирларында Урал-Волга тирәләрендәге табигать күренешләре эчендә әйләнә.

Чынында аның «Әсма» хикәясе кечкенәрәк бер роман рәвешендә булып, «Сәлимә»гә караганда күп яктан тулы, җитешлекле эшләнә; мөндәриҗәсе дә киң, тасвирлары тагын да күренешле, матур булып чыга: «Монда тормышыбызның һәр ягы вә һәр ягында булган яра вә ярыклары күрсәтелгән. Монда күрсәтелгән шәхесләр дөрес тип булмасалар да, аларның гамәл вә хәрәкәтләрендә һәм сүзләрендә бик типичный вә характерный нокталар бар»[2].

[1] «Аң», 3 нче сан, 1915 ел. Җ. Вәлиди. *(Авт. иск.)*
[2] Җ. Вәлидинең югарыдагы мәкаләсе. *(Авт. иск.)*

«Сәлимә» хикәясендә, яз көне Казан шәһәреннән башланып, Идел өстеннән Самарга[1] вә аннан, Әстерхан шәһәрене кичеп, Бакуга кадәр сузылган бер сәфәрдә очралган хәлләр, кешеләр, баштан кичерелгән һәм башкалардан алынган фикер вә әсәрләнүләр тасвир ителә. Шул ук сылтау, шул ук уңай белән әдип монда үзенең дини-әхлакый, мәдәни, иҗтимагый фикерләрен, иҗтимагый һәм гаиләви тормыш турындагы фәлсәфи карашларын, форсат чыккан саен, төрле юллар, төрле тайпылулар, төрле якка бәрелүләр, әйләнүләр белән һаман укучының миенә сала, шулай ук аңа төрле тарихи мәгълүматлар бирә бара.

Әсәрдә каһарман итеп алынган шәхес икәү: 1) Казаннан сәфәргә чыгучы аңлы, җәдитләнгән, Яурупа мәдәниятенә маңлае бәрелеп йокысы ачылган, уянган «чи мөселман» бер татар шәкерте яисә татар зыялысы, «ислам җәмгыятемез, гыйлем вә мәгърифәт, һөнәр вә сәнгать хосусларында түбән калган», моның «соңы, әлбәттә, хараплыктыр», «гәрчә гимназия тәмам итеп, университет күргән образованный[2] вә ислам мәдрәсәләрендә тәхсил иткән голәма дигән ике төрле таифәләремез[3] бар исә дә, бунларның берсе – ислам гыйлемнәрендән хәбәрсез вә икенчесе әхвәле дөньядан[4] мәгълүматсыз калдыклары өчен халкымызга юлбашчысы була алмазлар. Юлбашчыларымыз исә – ислам гыйлеме илә замана әхвәлене фәлсәфәсе илә белгән затлар булырга тиешледер» дип уйлый башлаган һәм «ислами илә бәрабәр русча белмәк» тарафдары булган чын мәгънәсе белән тәрәккыйче бер яшь мөселман.

2) Мисырда университетта укыган, үзенең ана теле булган фарсы теле шикелле итеп гарәпчәне, шуның өстенә мөкәммәл[5] рәвештә французча, инглизчә белә торган бер мөселман кыз – Иранның атаклы, зур купецларыннан берсенең кызы Сәлимә. Үзе – «һөнәрлелеге нисбәтендә мөлаем вә гакыллы; мөлаемлылыгы вә гакыллылыгы нисбәтендә һөнәрле» һәм «җазибәле[6], сөемле»; «әдәпле улдыгы кадәр мәхҗүб[7], гыйлемле улдыгы кадәр ләтыйф[8]», «май кебек

[1] Самара.
[2] Образованный – белемле.
[3] Таифәләремез – төркемебез.
[4] Әхвәле дөньядан – дөнья хәлләреннән.
[5] Мөкәммәл – камил.
[6] Җазибәле – үзенә каратучы.
[7] Мәхҗүб – тыйнак.
[8] Ләтыйф – гүзәл.

йомшак, сандугач мисаллы моңлы вә мөлаем тавышлары таң җиле рәвешендә җанны рәхәтләндерә, чыбыклар аркылы әсәр иткән елдырым куәте кебек», әдипнең «җөмлә варлыгына әсәр итә» торган һәм «гыйлем диңгезе» булган идеаль бер кыз.

Әсәрнең кыскача мөндәриҗәсе болай:

1) Иранның зур байларыннан берсенең кызы булып, ислам гыйлемнәре өстенә Яурупа фәннәрен казанган, Яурупа телләрен дә белгән Сәлимә туташ, анасы белән Ираннан Петербургка килеп, шуннан Мәскәү, Кострома, Казан аркылы Әстерханга, аннан үз илләренә кайтып баралар (туташ 18–19 яшьләрдә була).

2) Шул вакытларда Казанның иске мәдрәсәләреннән бизеп, Төркия, Мисыр, Кытай, Япон, Һиндстан якларына сәяхәт итү фикеренә төшкән бер шәкерт пароход белән Самар аркылы үзенең иленә – Уфага кайта. Болар пароходта күрешә, танышалар. Сәлимә туташ белән икесе гарәпчә һәм фарсыча сөйләшеп, серләшеп баралар. Бер-берсенең хәлләрен сорашалар. Шәкерт тә, ниһаять, Сәлимәгә, «Фәйзы Илаһи динелгән бер камәләт»тән[1] гыйбарәт яисә «бик әдәби һәм бик мәдәни» булган бер гыйшык белән гашыйк була.

3) Самарга җитәр алдыннан, Сәлимә туташ шәкерттән үзләре белән Бакуга кадәр бергә иптәш булып баруын үтенә. Безнең аңлы, яурупалашкан, тәрбияле ислам шәкерте дә бу үтенечне кабул итә. Самарага кереп чыгалар да, Бакуга аларны озатып бара. «Сәлимә туташтан алачак дәресләре» дә әле күп булып, шуны ул шушы уңай белән тәмам кыйлмак була.

4) Болар юлда һәр бабтан гыйлем, әдәбият, сәясәт, игенчелек, зирагать[2], сәүдә бабларыннан сөйләшеп баралар. Шәкерт Сәлимәне сөйсә дә, һичбер төрле әдәпсезлек, килешсезлек күрсәтми. Мөмкин кадәр аңа нәзакәтлек һәм гыйффәт галәмәтләрен сиздертеп бара. Кыз да моның алдында шундый мөгамәләдә була. (Шәкерт үз гомерендә анасыннан башка бер хатын-кызның кулын тотмаган һәм үпмәгән була.) Кыз да, шул дөньяда булмый торган бер рәвештә гыйффәтле булган өчен, шәкерткә мәхәббәт баглый.

5) Бакуга җитәләр. Шәкерт анда берничә көн кала. Кайтып китү өчен кызның рөхсәтен көтеп йөри. Соң уйламаган бер вакытта, кызны тәрбияләп үстергән бер хатын Сәлимә тарафыннан илче булып килә дә Сәлимәнең үзен үзе шәкерткә иптәшлеккә тәкъдим иткәнен белдерә. Шәкерт бу эшкә шатлыгыннан нишләргә белми. Әлбәттә, тәкъдимне кабул итә. Бер атнадан соң никахлары була. Кушылалар. Шулай итеп,

[1] Фәйзы Илаһи динелгән бер камәләт – Аллаһ тарафыннан бирелгән бер камиллек.
[2] Зирагать – авыл хуҗалыгы.

«гыйффәт»ле Сәлимә белән «гыйффәттән башка камәләте булмаган» җәдит бер татар шәкерте ирле-хатынлы бергә яши башлыйлар.

Бу ике каһарман яисә бу ике тип, әлбәттә, икесе дә ул чактагы татар тормышында төгәле белән юк иде. Булуы мөмкин дә түгел иде. Боларны әдип үз хыялында ясап, шуларны татар тормышына, татар мохитенә китереп кертеп, шулар аркылы татар дөньясы өчен яңа бер иҗтимагый-мәдәни тормыш идеалын ташламакчы булган.

Әдип бу хикәядә, шушы ике каһарманга һәм алар арасындагы вакыйга-хәлләргә баглап, шул вакыт өчен күптөрле яңа, кирәкле, кызыклы, татлы булып күренә торган иҗтимагый, әхлакый фикерләрне, гыйльми-тәрбияви карашларны уртага ташлый. Алар да шулар:

1. Дөнья тормышы өчен дин белән дөнья гыйлемен икесен бергә белергә кирәк.

2. Чын кеше булу өчен гыйлем белән күркәм холык кирәк.

3. Халыкка хезмәт итәрлек кеше булып җитешергә кирәк.

4. Иске мәдрәсә (бигрәк тә Казан мәдрәсәләре), иске тәрбиядән бернәрсә чыкмый, мәктәпләрне, укытуны, тәрбияне яңартырга, яңа укуны кабул итәргә кирәк.

5. Мөселман халыкларындагы фанатизм, икътисадсызлык, дин исеменнән халыкның надан калуын яклау, байлар хәтере өчен тиешле сүзләрне, үгетләрне әйтми калу бетәргә тиеш.

6. Бөтен халык файдасы өчен уйларга, халык, милләт өчен хезмәт итәргә кирәк.

7. Тәрәккый юллары ачылып, балаларга дин, һөнәр белдерелсен, үзебездән специалист галимнәр җитешсен, үз телебездә китаплар язылып, бастырылып таратылсын.

8. Мөселманча белән бергә русча белү кирәк; Көнбатыш һәм Көнчыгыш телләрен өйрәнү өчен махсус мәдрәсәләр ачылсын.

9. Русча белмичә торып, милләткә, халыкка хезмәт итеп булмый. «Милләтне мәсгуд[1] итмәк исә аларга җиңел укымак вә гүзәл кәсеп итеп, байлык тапмак юлларын күрсәтмәк илә, һөнәр вә сәнәгать белдермәк илә улыр. Русча яхшы белмәгәндә, бунларны мәйданга куймак мөмкин дәгел идеке шөбһәсездер».

10. Хатыннар ирләрдән ким түгел. Алар кимсетелмәскә тиеш.

11. Ысулы җәдит, ысулы кадим тартышы – юк талаш. Моны «ярты вә мәсләксез муллалар кузгаталар; бер вакытта иске ысулга

[1] Мәсгуд – бәхетле.

яңа дияләр иде, киләчәктә, бәлки, бу яңа ысулга һәм иске ысул исеме бирелер. Чөнки дәхи[1] җиңел вә яңа ысул дөньяга чыкмыш улыр».

12. Галим – башка, мулла – башка. «Шәригать асылларындан хәбәрдар булмаган хәлдә, андан-бундан ишеткән сүзләре илә гөрелте чыгарып, тәшвиш салучылар[2] галим дәгел, муллалардыр».

13. Әүлия дип, каберләренә барып, үлекләрне зиярәт итеп, алардан бер файда өмет итү – юк нәрсә, ялган ул.

14. Без – болгар төркләребез. «Татарларның сәяси өстенлеге сәбәпле, болгар төркләренә «татар» исеме бирелгән. Инде ошбу соң заманларда «татар» исеме бетеп, «төрк» исеме дөньяга чыкмакдадыр» (китапта «Казан төркләре» дип йөртелә, «Казан татарлары» диелми).

15. Рус, яһүд сәүдәгәрләреннән калышмас, шулар алдында юк булмас өчен, татарларда сәүдә ысулларын үзгәртергә, яңартырга, яурупалашырга кирәк. Бу турыда да ата-баба юлында, искечә калу – һәлакәт. Шулай ук татар сәүдәгәрләре Яурупа телләрен белсеннәр.

16. Татар байларының һәртөрле икътисадсызлыгы, күп акчалы, исрафлы туйлар ясаулар бетсен. Шулай ук инде хатын-кызлар кием-мода бәласеннән котылырга тиеш.

17. Иҗтимагый тормышта хатын-кызларның вазифалары бик зур. Бигрәк тә аларны укытырга, аларга яхшы тәрбия бирергә кирәк. «Бозу, төзәтү, сихерләү» кебек ялган ышанулар – «тәрбиясез хатыннар сәбәбеннән» таралган нәрсәләр алар.

Менә Ризаның әлеге оста, үткен каләм белән язылган хикәясендә төрле картиналар, тасвирлар аркылы сузылып, чәчелеп барган төп фикерләрен җыеп әйткәндә, әнә шул югарыдагы маддәләргә кайтып кала. XX йөзгә кергәндә, ул әнә шуларны ачык, куәтле рәвештә матур әдәбият аркылы урталыкка бастырды. Яисә шул яңа фикерләр, яңа карашлар өчен матур әдәбиятны корал итте.

Әсәрдә тегеләргә башка тагын Самарның зур бер сәүдәгәре белән (бу сәүдәгәр, элек надан муллаларга ышанып йөреп, җәдиткә каршы булса да, хикәядәге каһарман шәкертнең аңлатуы белән, ул юлыннан кайта) Мәскәү университетын тәмам итеп, үз губернасы булган Уфага кайтып барган һәм мәшһүр бер фамилиядән булган студентны да хикәягә катыштыра. Бу да шул югарыдагы фикерләрне төгәл чыгарып, әйтеп бетерү өчен эшләнә.

[1] Дәхи – тагын.
[2] Тәшвиш салучылар – бутаучылар.

Ризаның башка гыйльми-тарихи һәм әдәби әсәрләрендә дә соңыннан шул ук XX йөзгә кергәндәге иҗтимагый фикерләре һаман киңәйтелә, тармакландырыла, изах ителә[1] барылды. Татар буржуазиясенең көчле бер идеологы һәм юлбашчысы булган бу әдипнең башка әсәрләренең заманындагы иҗтимагый әһәмиятен, үтәгән рольләрен аңлау өчен дә кирәк булуын игътибарга алып, сүзне бераз озайта төшеп булса да, аның «Сәлимә»сен шул рәвешчә киңрәк ача төшүне тиеш күрдек.

Ризаның «Сәлимә» кебек «Әсма»сы да – тарихи яктан әһәмиятле әдәби әсәрләрнең берсе. Ничек булганда да, алар татар тормышыннан, татар мохитеннән алынып язылган әсәрләр. «Әсма» тагын да тормыш эчендәрәк һәм аңа караганда тулырак, әдәби яктан остарак язылган.

«Әсма» романының кыскача мөндәриҗәсе:

1. Идел-Урал буенда башкорт авылларыннан Бикмәт дигән бер авыл. XIX йөзнең дүртенче чиреге башларында шунда Габбас дигән бер мулла ысулы җәдит мәктәбе ача.

2. Шул ук авылның Хикмәт хаҗи исемле залим һәм чиксез бай бер сәүдәгәре төрле сәбәп һәм сылтаулар белән Габбас мулланың дошманы булып, бу юлда аның зарарына хәрәкәт итә. (Бу дошманлыкның көчәеп китүенең бер сәбәбе дә Габбас мулланың, Хикмәт хаҗи кызын алып, аның бишенче мулла кияве булмыйча, ярлы бер мөдәррис кызын алуы һәм байга тәрилкә тотмавы була.)

3. Шул арада төрле вакыйгалар булып үтә. Шулар уңае белән Хикмәт хаҗи Габбас мулланы төрмәгә яптыру чараларын күрә башлый. Ләкин шул вакытларда Габбас мулла хаҗ сәфәренә чыгып китә дә Хикмәт хаҗи тозагыннан котыла.

4. Хаҗда чагында Габбас мулланың үлү хәбәре килә. Ялган хәбәр. Бер елдан соң Габбас мулланың үзен кеше иткән хатыны – Гайшә ханым да дөньядан күчә. Әсма дигән бердәнбер кызлары ятим калу өстенә, шул вакытларда йортлары, бөтен нәрсәләре янып китә. Әмма Әсма кымыз ясап көн итүче Йосыф бай дигән берәүнең тәрбиясенә күчә.

5. Бервакыт бер шәһәрдән Хәмидә дигән бер карчык килә дә, анасы дустым иде, дип, Әсманы кунакка алып китә. Ләкин Әсманы кире китерми, бәлки аны тире авыруы белән үлде, дип хәбәр итә дә атасыз-анасыз калган кызларны җыеп, теләнчелек иттереп, шуның белән кәсеп итә торган Зәйнүш дигән бозык бер хатынга китереп тапшыра. Зәйнүш исә Әсманы, кыйнап, җәберләп, шәһәр вокзалларында башка кызлар белән

[1] Изах ителә – аңлатыла.

теләнчелек кылдыртып йөрткән чагында, фахишәләр белән сәүдә итеп, Эрбет ярминкәсеннән кайтып килүче бер хатынга сата. Ләкин анда әле Әсма бала гына булганга, вак-төяк йомышларны үтәп йөрү хезмәтендә генә була. Шул хезмәтләрне үтәп йөргәндә, ул, баскычтан егылып төшеп, больницага озатыла. Аннан сәламәтләнеп чыккач инде, ул шуннан дәваланып чыккан бер хатын белән авылга кача.

6. Әсма, үзен сатучы карчыкның паспортында язылу буенча, Зәйнәп дигән исем белән икенче бер шәһәргә, Салих бабай дигән кеше тарафыннан ачылган бер тәрбияханәгә килеп керә. Шунда тәрбияләнә, укый башлый.

7. Салих бабай хаҗга бара. Ул анда үзенең әүвәлге якын кешесе һәм тәрбияханә ачарга киңәш бирүчесе булган Габбас мулла белән күрешә. Аны үзенең тәрбияханәсенә кайтып, әхлак вә тәрбия гыйлемнәрен укытучылыкка чакыра. Габбас мулла инде бу вакытта бөтен гаиләсенең үлеп бетү хәбәрен ишеткән һәм гаилә әгъзасыннан терек булып ялгыз үзе генә калган дип уйлап йөри. Мулла да Юныс хәзрәт исеме белән кайта. Тәрбияханәдә укыта башлый. Әсма – этисе Габбас мулланы, Габбас мулла да Әсманы танымыйлар, белмиләр. Әмма Габбас мулла шушы тәрбия йортында кызына гүя бер чит мөгаллим кебек булып, аны ничә еллар тәрбия кылып үстерә. Кыз да егермеләргә җитеп, инде шул ук тәрбияханәгә үзе мөгаллимә булып билгеләнеп, Габбас мулла белән бергә хезмәт итә башлый.

8. Әсмага ике урыннан: берсе – бай баласыннан, берсе мөгаллим әдиптән яучы килә. Мөгаллимгә бара.

9. Никах укытыр алдыннан Әсманың чын үз исемен һәм фамилиясен, кем кызы икәнен ачарга кирәк була. Ул шуны ача: Габбас мулланың кызы икәнен тәрбияханә иясе Салих байга әйтә. Мәсьәлә ачыла, Әсма да этисе белән күрешеп, бәхетле була. Шуның өстенә Әсма да, кияве дә Йосыф бабайда чакларында бер-берсенә мәхәббәт куешып, вәгъдә бирешкән гашыйк белән мәгъшук булганлыкларын аңлыйлар (чөнки Әсма Йосыф бабайда чакта әлеге кияү кеше кымыз эчәргә килә дә, болар шунда бер-берсенә мәхәббәт баглаган һәм үзара вәгъдә куешкан булалар).

10. Татар халык әдәбиятының җанлы китабы дип әйтерлек булган Сәлим бабайның башыннан үткән хәлләр (моны әдип халык әдәбиятының әһәмиятен аңлату өчен ала).

11. Бер ишанның Муса исемле бер мөриде (үзе байларны мактаучы шагыйрь дә), мәчеткә дип, ялган рәвештә Габбас мулла исеме һәм шуның исеменнән язылган хат белән акча җыеп йөри дә, фәхешханәгә кереп, шунда бөтен акчасын туздыра, урлата. Һәм анда үз кызы белән кәеф-сафа сөргән була... (Шул вакыттан унсигез ел элек ул бер хаты-

нын кечкенә бер кызы белән аерып җибәргән була. Бу кыз, тәрбиясез калып, Хикмәт хаҗи улы тарафыннан «намусы да вәйран ителгәч», иң ахырда фәхешханәгә килеп кергән була.) Муса шунда ук полициягә алына, төрмәгә ябыла.

12. Хикмәт хаҗи бөлә, һәм улы да фәхешханәдә үлгән була. Аның бөлүенә дә сәбәп бер яһүд адвокатының хәйләсе белән «шәһәр кызы – образованный кыз» дип алган яшь хатыны Хәмидә була. Хикмәт хаҗи үзе дә ахырда ярлы бер башкорт өендә үлә.

13. Руста кучер булып йөргән берәүнең кызы Хәмидә яһүд адвокатының (Хикмәт хаҗиның үз адвокаты) хәйләсе аркылы күп мал белән Хикмәт хаҗидан аерыла да соңыннан, ул малларын бетергәч, ятим калган мөселман кызларын фәхешханәләргә илтеп сату белән яши башлый һәм анда үзенә йогышлы авыру эләктерә дә, Әсманың больницадан чыккан чагында, бу да больницага килеп керә.

14. Бай кияве буласы килеп, үзенең өлкән хатынын бөтен бала-чагалары белән аерып чыгарып җибәреп тә, Хикмәт хаҗиның бишенче мулла кияве булган Бикбулат хәзрәтнең планы барып чыкмый: үлгән байдан мал тими. Шуның өстенә Хикмәт хаҗи кызы бер дә уңмаган була. Көн-төн сугышып-кырылышып торалар.

15. Әсма, атасы белән күрешеп, шуның өстенә үзенең сөйгәненә барып, бәхетле булган чагында урамда ике аягы да киселгән хәлдә хәерчеләнеп йөргән һәм Әсманың үзен фәхешханәгә саткан Зәйнүш карчыкны очрата. Аңа, кызганып, ярдәм биреп китә.

Аның бу әсәрләре икесе дә – төгәл мәгънәсе белән иҗтимагый-гаиләви хикәяләрдер. Аның бөтен әсәрләрендә булган шикелле, хикәяләрендә дә иҗтимагый, әхлакый як бик көчле була. Шуның өстенә болар бөтенләй иҗтимагый-әхлакый фәлсәфә китабы булып чыкканнар. Ул алар аркылы татарда иҗтимагый-гаиләви реформа ясау өчен матур әдәбиятны тәмамән корал итеп ала да халыкка шул юл белән бик нык тәэсир ясамакчы була. Аның иҗтимагый типлары да – Сәлимә типлары шикелле үк, тормыштан алыну белән бергә идеаллаштырылган ясалма типлардыр.

Сәлимә кебек кызларның татарда җитешүе, шул вакытта Риза шикелле татарның идеология юлбашчыларының зур бер идеаллары булса, Әсма да, аның атасы Габбас мулла да, аның хатыны Гайшә ханым да, Салих бабай да, җырчы Сәлим бабай да – барысы да идеаллаштырылган типлар булып эшләнгәннәр. Юкса бу вакытта татарда андый шәхесләр төгәл хәлендә юк иде. Тагын да ачык әйткәндә, бу хикәяләрендә Риза материалның, мөндәриҗәнең байтак

өлешен тормыштан эләктергән дә, иҗаби[1] типларның әдәби сурәтләрен күккә менеп утырып эшләп чыгарган. Шуның өчен дә алар, җирнеке булудан бигрәк, сәмави[2] булып чыкканнар.

Әмма сәлби[3] типларга килгәндә, ул Хикмәт хаҗи, Бикбулат хәзрәт, Хәмидә карчык һәм Зәйнүш кебек хатыннар аркылы шул вакыттагы татар дөньясының, татар тормышының иң авыр, иң пычрак булган вакыйгый якларын тулы ачып бирә алган. Бу якларында арттыру юк – җиренә җиткерү бар.

Бу әсәр безгә үзенең Хикмәт хаҗие аркылы XIX йөзнең соңгы ярымы эчендә татар сәүдә капиталының шәһәр һәм авылларда ни хәлдә булуын, шулай ук кара надан татар байларының үз алларында татар муллаларын ничек биетүләрен, байларның җәдит, кадим булып икегә аерылып көрәшүләрен җанлы рәвештә яхшы ачып бирә, бу як – әсәрнең иң кыйммәтле бер ягы.

Алыйк Хикмәт хаҗины. Менә ул кем: «бөек мал вә күп әмляк сахибе[4]», чиксез бай бер татар сәүдәгәре, шуның белән бергә үзе «чиксез надан, риялы, мөтәкәббир[5] бер зат» һәм бик залим кеше. Бөтен халык аңа һәрвакыт кул кушырып кына тора. Берәү үзенә хөрмәт күрсәтмәсә, үзен зурламаса, аңа җәза бирдертә.

Әдип бу татар сәүдә капиталистының капиталистлык табигатен һәм болар аркылы халыкның ничек талашуларын түбәндәгечә тасвир итә:

1) «Яхшы нәрсәләр арасына начар нәрсәләр салып, бер бәһадән җибәрмәк, акчага гаҗиз булып карз[6] вирмеш кемсәя акча янына сигез тиенлек ситсаларны екерме тиен бәһагә куеп вирмәк, базарларда алучы вә сатучы күп килдекендә очсыз вә кыйммәт алып, чит сәүдәгәрләрне биздермәк, соңра тәмам үзе теләгәнчә ялгыз иркенләп сатмак» аның сәүдәгә осталыгы була.

2) «Үзе вә хезмәт итмәктә улан байның ике яшь углыны сәфаһәтә[7] үгрәтмеш, вә анлар акчага гаҗиз улдыклары бер сәгатьдә, һәр икесенә йөзәр тәңкә акча табып виреп, егермешәр мең тәңкәлек вексель алмашды. Мәзкүр бай вафат улдыгында, Мәзкүр байның

[1] Иҗаби – уңай.
[2] Сәмави – күкнеке.
[3] Сәлби – тискәре.
[4] Әмляк сахибе – милекләр иясе.
[5] Мөтәкәббир – тәкәббер.
[6] Карз – бурыч.
[7] Сәфаһәтә – малны әрәм-шәрәм итәргә.

хатыныны никах идеп, Мәзкүр угылларыны һәм бөтен милекдән куып чыгармышды».

3) «Москва вә Макарьядән кәнде әтрафында[1] улан байларның вексельләрене бунда алып кайтып, күп рибех[2] илә сахибләренә[3] сатар вә бәгъзе берләрене тәмам хәкыйк илә зәкят вә гошерләрә хисаб итеп вирер иде. Димәк, Хикмәт хаҗи адәмнәрдән генә рибех илә сату-алу итмәк илә канәгать әйләмәде, Җәнабе Аллаһа вирәчәкләрне һәм рибех алып вирер иде».

4) Хикмәт хаҗиның «агачтан да надан» дүрт кызы «Казан тарафындан олуг шөһрәт илә укып килмеш дүрт муллада» була. Болар дүртесе дә Хикмәт хаҗиның һәр эшенә фәтва вирерләр, хәтта кикерер исә дә, янында «ярхәмәкә... укып торыр» булалар. Хикмәт хаҗи болар өстеннән хаким булган шикелле, аның кызлары да ирләре өстендән атасы юлында хаким була.

Шулай ук бу әсәрдәге эчеп, исереп, кыйналып, больницага озатылган хәзрәтләр, фахешханәләрдә йөреп акчаларыннан язучы һәм анда үз кызлары белән хозур-кәеф сөрүче (аерып җибәргән хатынының бер кызы фәхешханәгә килеп кергән була) мөридләр, шулай ук муллаларның гавамга аларны «кәбестә баш», «каткан мужик» дип йөртү рәвешендәге мөнәсәбәтләре – шул дәвердәге татар тормышының эч йөзен ачу өчен иң кирәкле тарихи материаллар.

Бу әсәрләрендә Риза бай, тирән, көчле, ләкин шактый чуалчык, томанлы бер хыялга ия булган бер әдип булып күренә. Ризаның «Әсма»сындагы төп максаты: «Һәркемнең үз эшенең җимеше – җәзасы – дөньяда чагында ук үзенә кайта бара», дигән фикерне тормыштагы вакыйгалар аркылы сурәтләндерүдән гыйбарәт. Ул бу әсәрләрендә шуны «Аллаһы Тәгалә хәзрәтләренең хикмәте» итеп, дини бер юлда, ислам фәлсәфәсе, ислам әхлагы рухында күп тармаклы, реальчелек катыш киң хыялый картина итеп тәмамлаган да.

Кыскасы, Риза бу ике әсәре аркылы ислам идеологиясен, аның борынгы әхлагын, мәдәниятен, Яурупа буржуа идеологиясе һәм аның буржуа мәдәнияте белән катыштырып, яхшы ук оста бер каләм белән тасвир итә һәм шуны аңарча татар матур әдәбиятында, бәлки бөтен төрк әдәбиятында күренмәгән бер рәвештә күтәреп, идеаллаштырып, үсеп килгән татар буржуазиясе алдына ташлый. Татар

[1] Кәнде әтрафында – тирә-ягында.
[2] Рибех – табыш.
[3] Сахибләренә – ияләренә.

байлары, татар руханилары, татар мөгаллим вә мөгаллимәләре, татар әдип вә шагыйрьләре өчен киләчәктә үрнәк була торган иҗаби типлар; шулай ук киләчәктә татар дөньясыннан югалырга тиеш булган сәлби типлар тудыра.

**Матур әдәбиятта гавами татарчылык хәрәкәте һәм Галиәсгар Камал драмалары**. XX йөзгә кергәндә, телдә, әдәбиятта киңәя барган төркчелек агымына каршы икенче яктан матур әдәбиятта татарчылык агымы куәтләнүендә нык дәвам итте. Каюмнар тарафыннан нигезе корылган, Ильяси, Халиди, «Чистай комедияләре» тарафыннан матур әдәбиятта беренче эзе салынып калдырылган иң садә бер татар теле – әдәби «урам» теле белән язучылык сукмагы һаман әкренләп киңәя, тамырын төрле якка суза, ныклап эшләнә башлады.

«Бичара кыз», «Рәдде бичара кыз», «Чистай комедияләрен»нән соң баш күтәргән Галиәсгар Камал каләме аркылы татар драма әдәбиятының да, шуның белән бергә татар әдәби гавам – урам теленең дә әдәби яктан шактый эшләнгән, матурланган бер рәвеше уртага ташланды. Соңыннан бу тел «тормыштан алынган пьесалар өчен бездә классик бер телгә әверелеп китте». Чөнки ул «һәртөрле характерлы сүзләр белән чуарланган чын җанлы халык теле»[1] иде. [18]98 елда язылып, [18]99 елда басылуына рөхсәт алынган һәм 1900 елда уртача кулда, вак хәреф белән егерме бит зурлыгында имзасыз[2] басылып чыккан алты пәрдәлек «Бәхетсез егет» исемле драма[3] әнә шушы каләмнең беренче оригиналь җимеше иде. Мөндәриҗәсе ягыннан да, сәнгатьчә эшләнә алуы ягыннан да, телөслүбе ягыннан да татар әдәбият дөньясында бу әсәр үз юлында беренче уңышлы һәм башкаларга үрнәк булырлык бер адым булды.

Бу каләм шушы драманың «шундый бар кеше дә аңларлык урам теле»ндә яза алуы белән, халыкның шул эшкә көлеп каравына колак салмыйча, матур әдәбиятта шуны ачык мәйданга куеп, шул юлда көрәшүче кыяфәте белән килеп чыкты. Шушы әсәрнең ахырында ул ихтар[4] итеп: «Бәгъзе кешеләр бу китапны бигрәк урам телендә чы-

[1] «Галиәсгар Камал әсәрләре» – Г. Рәхим мөкаддимәсе, 17 бит, 1925 ел. *(Авт. иск.)*

[2] [19]25 елда басылган «Галиәсгар Камал әсәрләре»нә Г. Рәхим тарафыннан язылган «Берничә сүз»дә Г. Камалның беренче мәртәбә басылган шушы «Бәхетсез егет»е 16 битле булып «Г. Казанлы» имзасы белән басылган» дип яңлыш күрсәтелгән (7 биттә). *(Авт. иск.)*

[3] 1907 елда төзәтелеп, тагын киңәйтелеп – икенче мәртәбә; 1925 елда өченче мәртәбә басылды. *(Авт. иск.)*

[4] Ихтар – искәртмә.

гарган икән дип көләрләр, бәлкем, әмма ни зыян? Көлсеннәр. Дәхи дә шундый бар кеше дә аңларлык урам телендә булган китаплар булучылыгы насыйп булсын», – дип, Каюм Насыйрича эшкә бик аңлап, ныгытып тотынганын күрсәтте. Бу, чыннан да, татар матур әдәбиятында Каюм Насыйрича белә торып эшләнгән, каһарманнарча катгый максатлы беренче адым иде. (Ул чакта «урам теле» дип кимсетелгән хәзерге гавами әдәби татар теленең үсү тарихын, Каюм Насыйриларга каршы башлап кузгалган бу көлүнең алардан соң әле һаман дәвам иткәнлеген күрсәтү өчен дә бу юллар ачык бер документ була ала»[1].

1905 елгача ук үзләренең әдип, шагыйрьлекләрен күрсәтеп өлгерә алган башка татар әдипләре шикелле үк, Галиәсгар Камалга да алда әдәби яктан озак кайтып тормау өчен, бу урында аңа да тәфсилләбрәк тукталып үтик.

«Бәхетсез егет»тән башка тагын Г. Камалның 1902 елда «Өч бәдбәхет» дигән өч пәрдәлек бер әсәре (1911 елда «Уйнаш» исеме белән икенче мәртәбә төгәлләнеп бастырылды) басылып чыга. Ул, бер яктан, шул рәвешчә оригиналь әсәрләр тудырса, икенче яктан, шул ук вакытта башка телләрдән әдәби әсәрләр дә тәрҗемә итә башлый (бу турыда сүз түбәндә килә).

1905 елдан соң бу көчле драматург каләменең бер-бер артлы күп кенә драма һәм комедияләре чыкты.

«Беренче театр», «Бүләк өчен», «Банкрот», «Дәҗҗал», «Каениш», «Безнең шәһәрнең серләре», «Көндәш», «Өйләнәм – ник өйләндем» кебек әсәрләре шундый әсәрләреннән булып, болар шул XX йөзгә кергәндә һәм 1905 елгача булган бер заман эчендә беренче мәртәбәсендә үк ачык һәм җитешеп ялтыраган талантның тагын да ныграк ачыла баруының нәтиҗәләре иде.

1905 елгы революциядән соң ук татар дөньясында зур талантлы, көчле бер драматург сыйфаты белән иң элек бик хаклы рәвештә игътираф ителгән татар әдибе Галиәсгар Камал булды. Хаклы иде. Чөнки надан, бозык, мөтәгассыйб татар байларының һәм җәдитләнеп килгән татар мещан гаиләләренең тормышларын бөтен көлкеле яклары белән үзенең табигый типлары аркылы ачып бирүдә аның әсәрләре, шөбһәсез, беренчелекне ала торган әсәрләр иде.

«Чибәр әсәрләре белән яшь мөхәррирләребез арасында мөһим урын алган Галиәсгар әфәнде Камалдыр. Г. Камал әфәнде әсәрләрендә,

[1] «Театр мәҗмугасы», Г. Сәгъди мәкаләсе, 28 бит. *(Авт. иск.)*

хосусан, «Беренче театр»ында үзенең оста көлүче икәнен күрсәткән» иде.

«Үзе мәдрәсә мәхсуле[1] булып, иске тормышның инсанны кыса вә изә икәнен танып белгән вә шуны сизә башлаганнан бирле шуңар каршы җиһад илә мәшгуль булган бер заттыр» («әл-Ислах», 1908 ел,41 нче сан).

Шулай, тел ягыннан да, мөндәриҗә ягыннан да, чын сәнгатьчә эшләнү ягыннан да татар матур әдәбиятының драма, комедия өлешендә иң беренче карлыгачлардан Галиәсгар Камал әсәрләре булды.

Чын сәнгатьчә эшләнгән драма әдәбиятының беренче үрнәкләрен, шушы юлда беренче классик әсәрләрне башлап ул бирде. Галиәсгар – үзенең әсәрләре аркылы көлдерүче дә, көйдерүче дә. Ләкин аның әдәби талантының иң көчле ягы аның көлдерүчелегендә.

Галиәсгарның драмалары, комедияләре тулы мөндәриҗәле булалар. Ул әсәрләренә татар байлары тормышының аянычлы, көлкеле, серле якларын ачык, тулы иттереп ала белә. Бу – бер. Икенчедән, ул типларны сәнгатьчә зур бер осталык белән эшләп чыгара ала.

Күп драматурглар була: алар әсәрләрендә алынган каһарманнарына үз миләрен, үз йөрәкләрен бирәләр; аларны драма язучының нәкъ үз теле, үз өслүбе белән сөйләштерәләр. Шуның белән аларны табигыйлектән, чынлыктан аералар. Үзләрен каһарманнар тормышында һәм аларның табигатьләре белән яшәтеп, шуларның чын тормышларын үз башларыннан кичереп карый алмыйлар. Аларга үзләренең шәхси табигатьләрен яисә үз башларыннан уйлап чыгарылган бер табигатьне йөкләтәләр дә, нәтиҗәдә, каһарманнарының табигатьләре, сүзләре, эшләре, хәрәкәтләре бер-берсе белән оеша алмый торган булып чыга.

Галиәсгар Камал исә башкача. Ул каһарманнарын нәкъ үз тормышлары белән яшәтеп, аларга тәмам үз табигатьләренә яраклы сүзләр, хәрәкәтләр бирә. Сүз, табигать, эш, хәрәкәт, итенеш, кыланыш – болар аның каһарманнарында бер-берсе белән тәмам берләшә ала торган нәрсәләр. Шундый осталыгы аркасында ул шулар аркылы безгә яхшы гына эшләнгән сәнгатькяранә типлар бирә алды.

Бездә көчләнмичә яза алу, үгет-нәсыйхәт белән буталмаган һәм нәгыз[2] реаль әсәрләр бирә алуның беренче адымын Галиәсгар Камал атлады. Бу турыда беренче ачык үрнәкне ул бирде. Күп язучылар

[1] Мәхсуле – *бире дә:* шәкерте.

[2] Нәгыз – яхшы, гүзәл.

бар, алар әсәрләре аркылы үзләрен үзләре күрсәтергә тырышалар. Г. Камал андый әдипләрдән түгел. Ул әсәрләре аркылы үзен күрсәтергә, күрсәтелергә дә теләми, бәлки ул үзе чынында ничек булган булса, тик шулай булып күренә ала. Дөресе, ул әсәрләрендә үзеннән элек каһарманнарын күрсәтергә тырыша. Галиәсгар каләме аркылы тудырылган әсәрләрнең өченче кыйммәте менә шушы яктан.

Дүртенчедән, аның әсәрләре садә[1] эшләнгән. Матур әдәби татар теленең драмада беренче үрнәкләре булып килделәр.

Татар драма әдәбияты дөньясында һәрвакыт үзенең иҗаби ягы белән иң элек танылып, татар гаммәсе[2] арасында бик тиз мәшһүр булып китүе дә аның менә шушы яклары өчен булды.

Галиәсгар каләмендә көлке интригасы, көлү истигъдады[3] көчлерәк булганга, ул үз иҗатлары өчен күбрәк тормышның көлкеле, вак, түбән, кызганыч якларыннан материал сайлады, хәтта трагик мәүзугларда да аның күзеннән көлкеле моментлар яшеренеп кала алмады. Шуның өчен аның драмалары да, елау драмалары булудан бигрәк, көлү, көлү аркылы елау драмалары булып чыктылар.

Янә Галиәсгарны көлүче булудан бигрәк, көлдерә белүче бер әдип дип аңларга кирәк. Аның Галиәсгарлыгы, Камаллыгы да бигрәк әнә шунда: ул ачы һәм файдалы иттереп, бик табигый бер юл белән чәнчеп, тормышны да тормышның үзе аркылы тәнкыйть итеп көлә белде.

Тормышка тормышның нәкъ үз аршынын сала алучы бер татар әдибе әле юк вакытта, ул, шул аршынны тотып чыгып, шуның белән татар тормышын арттырмый, киметми дөрес үлчи алды. Шуның өчен дә ул аның иң дөрес, иң табигый картиналарын эшләп бирә алуга муәффәкъ булды. Аның драмалары да, комедияләре дә шуны ачык күрсәтәләр.

Тел ягыннан да, мөндәриҗә ягыннан да, чын сәнгатьчә эшләнү ягыннан да татар драма әдәбиятында иң беренче карлыгачлар Галиәсгар Камал әсәрләре булды. Димәк, татар драма әдәбиятының чын сәнгать юлы белән эшләнгән беренче үрнәкләре башлап шушы көчле талант тарафыннан бирелде, иске татар байларының җимерелү, бетү хәрәкәтләреннән татар сәхнәсендә эшләнеп калган иң тарихи кыйммәтле бер картина [тудырылды].

[1] Садә – гади.
[2] Гаммәсе – массасы.
[3] Истигъдады – сәләте.

Галиәсгар Камал драмаларындагы аерым бер сызык тагын менә шушы: ул хәйләкәр, ара бозгыч, имче-томчы карчыклар, бай хатыннары һәм асрауларның типларын аерым бер табигыйлек һәм осталык белән бирә ала. Надан, тәрбиясез байлар тибын ясауда янә бер осталык күрсәтә. («Беренче театр»дагы «Хәмзә бай һәм асрау, «Бәхетсез егет»тәге Мәгъри, «Бүләк өчен»дәге бай хатыны шуларга мисал.)

Г. Камал әсәрләрендә бу урында әйтелеп үтелергә тиешле булган бер кимчелек бар. Ул да бәгъзе урыннарында монологларның артык озын булып китүе. (Мәсәлән, «Бәхетсез егет»тә бай хатынының улы Закир турындагы монологы кебек, дүртенче пәрдәдә Гайни белән карчыкның диалоглары да шулай озын.)

Бу әсәрдә Уфа сәүдәгәрләреннән Сәгыйть Сабитовлар гаиләсе нәкъ яшь яурупалашкан яңа татар буржуазиясенең вәкилләре итеп алынган да иске Кәрим байларныкына каршы бер иҗтимагый көрәш күренеше булып чыккан.

Татар халкының иҗтимагый-әдәби тарихында Г. Камалның «Бәхетсез егет» драмасыннан соң иң кыйммәтле мәңгелек бер әсәре бигрәк аның «Беренче театр» дигән комедиясе булыр.

Аның бу әсәре чынында сәнгатьле (художестволы), мөндәриҗәле, бик матур бер комедия булып чыкты. Монда кешеләр, характерлар бик табигый, бик килешле, теле дә – бик эшләнгән, садә әдәби бер татар теле.

XX йөз башларына таба иске татар байларына, шуларның иске тормышлары, мәдәни тәртипләренә каршы татарның либераль вак буржуазия сыйныфы аерым бер җәмгыять булып мәйданга чыга. Иҗтимагый-мәдәни тарихыбызда менә шушы сыйныфның үсеп килә башлаган мөһим моментлары бар. Иҗтимагый-мәдәни көрәшләрнең шундый бер моментын матур татар әдәбиятында матур эшләнгән бер сурәт белән яшәтеп калдыруда «Беренче театр» тиңсез бер әсәр булып торачак.

Икенче төрле әйткәндә, надан, иске татар байларының яңа, яшь татар буржуа җәмгыяте төзелә башлау алдыннан күрсәткән җимерелү, бетү хәрәкәтләреннән татар әдәбиятында эшләнеп калган иң тарихи кыйммәтле бер картина – «Беренче театр»дыр[1].

Матур әсәрләрнең төзелешен, рухын, матурлык дәрәҗәсен яхшы аңлап, күп вакыт аларның әдәби кыйммәтен дөрес билгели алучы Фатих Әмирхан Г. Камалның «Беренче театр»ын бик хаклы рәвештә

[1] «Татар театры мәҗмугасы», Г. Сәгъди мәкаләсе, 29–30 битләр. *(Авт. иск.)*

«хәятлы комедия» дип атады һәм аның турында түбәндәге фикерләрне язды:

«Галиәсгар әфәнде бу әсәрен хосусый бер гаиләнең мәгыйшәтеннән алып язган булса да, урта буржуазный классның психологиясен бик яхшы төшенгәнлектән, комедиянең каһарманнарына бик оста сурәттә гомумият бирү вә, шулай итеп, бу кыска комедиясен гомуми, ярым “мөтәрәккый”[1] купецларыбызның мәгыйшәт вә дингә назарларының[2] бик тугры көзгесе итеп чыгарадыр».

«Әлхасыйль[3], комедия, үзенең кыскалыгына карамыйча, татар мәгыйшәтенең вә гайрәт вә диниясенең бик көлке тарафларының берникадәресен бик әсаслы күрсәтеп өлгерәдер» («әл-Ислах», 1908 ел, 33 нче сан, «Дамелла» кушаматы белән)[4].

Галиәсгар Камал әсәрләре турында татар матбугатында моңарчы әйтелгән фикерләр, язылган тәнкыйтьләрдә төбендә бер-берсенә каршылык, төрлелек юк. Һәммәсендә дә Галиәсгар Камал татарның иң беренче зур әдәби таланты, татарда беренче комик, беренче оста сатирик булып игътираф кылына[5] һәм аның әсәрләренең һәммәсе дә татарда чын мәгънәсе белән сәнгатьчә бер әдәби «иҗад», беренче классик әсәрләр дип тәсдыйк ителә.

Бу урында тагын шуны әйтеп үтәргә кирәк: сәхнә өчен иң яраклы әсәрләр Г. Камал әсәрләре булганлыгы артистлар һәм башкалар тарафыннан тәсдыйк ителә. «Аның пьесалары сәхнәдә ифрат җанлы, хәрәкәтле, куяр өчен дә уңайлы булалар» (Г. Рәхим). Моның да бер сәбәбе аның үзенең турыдан-туры сәхнә тормышына якын торып, бәлки үзе шул тормыш эчендә кайнап яшәвеннән икәнлегендә шөбһә юк.

Галиәсгар Камал татар дөньясында беренче мәртәбә гавами садә әдәби телдә сәнгатьчә эшләнгән театр әсәрләре биргән шикелле, шул ук тел белән башка телләрдән классик әдәби әсәрләрне – театр әсәрләрен тәрҗемә итү эшен дә шул ук XX йөзгә кергәндә татар дөньясында беренче мәртәбә ул башлап җибәрде.

---

[1] Мөтәрәккый – процесс яклы.

[2] Назарларының – карашларының.

[3] Әлхасыйль – җыеп әйткәндә.

[4] Галиәсгар Камал һәм аның әсәрләре турында тагы соңрак бәгъзе бер фикерләр, карашлар белән дә танышу өчен 1925 елда басылган «Галиәсгар Камал әсәрләре» Г. Рәхимнең язган мөкаддимәсенә – беренче сүзенә каралсын (бигрәк тә 11–13 битләргә). *(Авт. иск.)*

[5] Игътираф кылына – таныла.

Госманлы төркләренең мәшһүр, классик драматургларыннан Намык Кәмальнең[1] ул вакыттагы татар хәятына туры килә торган «Зәваллы чоҗук» дигән драмасын «Кызганыч бала» исеме белән тәрҗемә итеп, бу юлда беренче адымны салды[2]». Соңыннан ул шул ук Намык Кәмальнең «Ватан»ын тәрҗемә иткән шикелле, Габделхак Хәмитнең[3] «Һинд кызы»н, Осторвскийның[4] «Гроза»сын, Гогольнең[5] «Ревизор»ын, Горькийның[6] «На дне»сын тәрҗемә итте.

XX йөзнең башыннан алып хәзергәчә татар матур әдәбиятында «тәрҗемәләрнең иң күбе Галиәсгар Камал тарафыннан эшләнде. Хәтта аның уйналган һәм уйналмаган, басылган һәм басылмаган барлык тәрҗемәләрен йөзгә җитә, диләр[7]». Кыскасы, артист Мөхтәр Мутинның әйтүенчә, «бу драматург бер вакытларда тәрҗемә эшләрен машина шикелле берсе артыннан икенчесен тупырдатып эшләп чыгарып кына торган» булган.

**«Унтугыз яшьлек мөхәррир»нең беренче «милли хикәя»се.** Гаязлар белән бер вакытларда Учительский школада рус-Яурупа тәрбиясе алган Садри Максуди 1899 елда үзенең «Мәгыйшәт» («Тормыш») дигән хикәясен язып, шуны 1900 елда 83 бит зурлыгында бастырып чыгарта. («Ләкин бу «Мәгыйшәт»нең талигы[8] бик кызык» була: өч мең нөсхәдән ике меңгә якыны Казанда 1902 елда вакыйгъ булган зур янгында янып юкка чыга.)

Икенче басмасы 1914 елда «Вакыт» матбагасында бастырылып чыгарылган бу хикәягә шушы басмасында мөхәррирнең үзе тарафыннан характеристика да язылып кушыла.

Кирәк шушы характеристикадан, кирәк хикәяне үзебез укып чыкканнан соң булсын, бу хикәядә без түбәндәге нәрсәне ачык күрәбез: бу хикәядә Ризалар сызыгында һәм шул ук идеологияне татар буржуа яшьләре, гомумән, яурупалашып барган бөтен татар җәдит

---

[1] Намык Кәмаль (1840–1888) – атаклы төрек язучысы, драматург, публицист һәм җәмәгать эшлеклесе, төрек әдәбиятында роман жанрына нигез салучы.

[2] «Татар театры» мәҗмугасы, Г. Сәгъди мәкаләсе, 59 бит. *(Авт. иск.)*

[3] Габделхак Хәмит (1852–1937) – төрек шагыйре һәм драматургы. Төрек әдәбиятында романтизмга нигез салучылардан.

[4] Александр Николаевич Островский (1823–1886) – иҗаты рус драматургия үсешенең әһәмиятле этабын нигезләгән күренекле драматург.

[5] Николай Васильевич Гоголь (1809–1952) – рус классик язучысы, драматург, тәнкыйтьче һәм публицист.

[6] Максим Горький (Алексей Максимович Пешков, 1868–1936) – язучы, шагыйрь, драматург, журналист, публицист һәм җәмәгать эшлеклесе.

[7] «Татар театры» мәҗмугасы, 64 бит. Г. Сәгъди мәкаләсе. *(Авт. иск.)*

[8] Талигы – язмышы.

дөньясына шигъри формада укмаштырып йоттырырга тели, барлык көче белән шуңа омтыла. Шулай итеп, иске мәдрәсәләрдән җитешеп чыккан әдәби каләмнәр белән рус-Яурупа гыйлем бусагаларыннан башын күрсәтергә итә башлаган татар буржуа каләмнәре бер үк идеология мәйданында баш кушалар[1]. Болай баш кушуның да без Октябрь революциясенәчә татар буржуазиясенең иҗтимагый-мәдәни, әдәби хәрәкәтенә һаман бердәмлек белән дәвам итеп барганын күрәбез (алда 1905 елдан соңгы баскычларда болай баш кушуның эч йөзе тәмам ачылыр), моны да [18]99 елларда ук «Мәгыйшәт»тә алынган идеалның мөхәррир өчен 1914 елда да «зур идеал» икәне мөхәррир тарафыннан ачык әйтелеп, матбугатта шуның үз каләме белән тагын да бер кат ныгытып куелуы ачык күрсәтеп тора.

Мөхәррир хикәясенең теле «саф Казан шивәсендә язылган милли хикәяләрнең тарихән беренчесе» булуын ачыктан-ачык дәгъва итә. [19]14 елдагы икенче басмасын укып чыккач, бу дәгъваны бөтенләй хаксыз дип булмый. Әгәр икенче басмасында аның теле үзгәртелмәгән булса, ул вакытта Казан әдәби шивәсендә, ягъни Каюмнар, «Чистай комедияләре» башлаган сызыкта татар тормышыннан алынып язылган озын хикәяләрнең күзгә ачык ташлана торганы, бәлки, беренчесе шул булыр. Бу хикәянең теле Ризаныкы шикелле «казанчадан бозылган вә кәйфи бер шивә» түгел. Ул – Галиәсгар һәм Гаязларныкы белән түбәндә бер сызыкта булган татар теле.

«Мәгыйшәт» – реалист бер юлда язылса да, «фикер» тарату максаты белән, укучыда «әмәл» тугъдыру фикере белән язылган бер әсәрдер. Яшь мөхәррирнең милләт эчендә таратырга теләгән әмәлләре нидән гыйбарәт?

– Буны язып торырга хаҗәт юк, хикәяне укып чыккач, һәркемгә бу заһир булачактыр. Хикәянең каһарманы Фатих кечкенә углы Рәшиднең «галим, диндар, хәмиятле, дәүләтле, милли бер кеше булып, милләткә вә дингә теле, фигыле, малы белән файда итәрлек бер адәм булуыны Ходадан телидер».

– «Менә унтугыз яшьлек мөхәррирнең милләте әфрадына теләгән әмәлләре, идеаллары бундан гыйбарәт. Бу идеал – «Мәгыйшәт» мөхәрриренә хәзердә дә зур идеалдыр» («Мәгыйшәт» хикәясенең икенче басмасы. Мөхәррирнең үзе тарафыннан «Укучыларга» дип язылган башлангычы, бит I–II).

[1] Баш кушалар – «бергәләп хезмәт итәләр» мәгънәсендә.

**Матур әдәбият аркылы идеологиядә яңа көрәшчеләр.** XX йөзгә кергәндә, шул бер идеология, шул ук бер максат белән Исмәгыйльләр, Ризалар юлыннан татар матур әдәбиятында кызган яшь талантлар, кузгалып, мәйданга атылалар.

Матур әдәбиятта мәгълүм бер идеологияне бирергә тырышучы, шуның кызган идеологлары Ф. Кәрими белән Гаяз булды. Болар икесе дә мөгаллим, икесе дә җәдитчеләр булып, татар буржуазиясенең сулрак, радикальрәк булган яңа, яшь гыйльми-әдәби терәкләре – чын «яурупеист» юлбашчылары иде. Икесе ике яктан торып, буржуазиянең матди ярдәменә таянган хәлдә, эшне кызулата башладылар.

Бу ике әдип турында мәшһүр Йосыф Акчура углы[1] «Казан мөхбире»нең 1906 ел, 179 нчы санында шушы түбәндәге сүзләрне язды: «Милләттәшләрем арасында ике чын әдип йитешә: берсе – хәссас[2], атәшле[3], милләтпәрвәр идеалист вә романтик Гаяз; икенчесе – гасаби, тешләүчән, милләтне чеметеп сөя торган рационалист вә реалист Фатих».

Бу ике әдип матур әдәбиятта икесе дә баш адымнарын хикәячелектә күрсәттеләр.

**Фатих Кәрими.** Тикшерүне әүвәл Фатих Кәримидән башлыйк. Бу каләмнең 1900 елда (Петербургта) кечкенә кулда утыз бит зурлыгында «Җиһангир мәхдүм» дигән хикәясе басылып чыкты[4]. Хикәянең төп максаты иске авыл мәктәпләрен, андагы тәрбия, укыту ысулларының начарлыгын һәм яраксызлыгын күрсәтүдән гыйбарәт.

Әсәр үзе әдәби агым ягыннан Ризаларныкы шикелле үк, шул фикерчелек (фикер бирү), рационализм юлында язылган. Монда тормыштан картиналар, тасвирлар бирү үзе төп максат түгел, бәлки алар тик бер васита булып, асыл максат – шулар уңае белән мәдәният, тәрәккый, яңа укуның кирәклеге, иске укуның тормышка файдасызлыгы турында халыкка әйтә торган фикерләрне, үгетләрне биреп үтү, шул турыда үзенең көенүләрен аңлату. Иске мәктәпне тасвир итеп килә-килә дә ул хикәясенең бөтен рухын, максатын ачып бирә торган түбәндәге фикерләрне уртага ташлап үтә:

[1] Йосыф Акчура (Йосыф Хәсән улы Акчурин, 1876–1935) – сәясәтче, җәмәгать эшлеклесе, журналист.

[2] Хәссас – сизгер.

[3] Атәшле – ялкынлы.

[4] Бу хикәя «Татар әдәбияты көтепханәсе»ннән булган 12 нче мәҗмуга булган «Фатих Кәрими әсәрләре»ннән 1925 елда икенче мәртәбә басылып чыкты. *(Авт. иск.)*

«Мужиклар балаларыны, бик күп булса, тырышып-тырмашып, ике-өч санә[1] мәктәптә тоталар, бер-ике санәсе һичбер нәрсә аңламыйча, иҗек белән үтәдер. Калган бер-ике санәсендә “Кисекбаш”, “Бәдәвам”, “Кызыл алма”, “Фәзаил әш-шөһүр” кебек һич файдасыз китаплар укытылып, гомерләре заигъ[2] ителәдер.

Асыл һәрбер мөселман өчен лязем булган иман, игътикад вә әхкаме диниядән[3] вә дөньяга чыгулары илә һәркөн вә һәр сәгатьтә лязем булган язу, хисап, тарих вә җәгърафиядән һичбер хәбәре булмый кала. Мөселманлыкны мыек кисеп, баш кырдырып, кәләпүш киюдән вә яхшы чапан киеп, мәсҗедкә йөрүдән генә гыйбарәт дия игътикад итеп, фикере бозылып, сүз аңламый торган бер мөтәгассыйб (фанатик) була. Бөтен эше, көче кеше гайбәтене сатуга мөнхәсыйр булып[4], мәдәният вә тәрәккыяткә дүрт башлы дошман була. Үзе һичбер нәрсә белми вә башкасына инанмый, перепись вакытында “татар” дип язачак булсалар: “Юк, юк, мин татар түгел, мин – мөселман”, – дип сугыш чыгара. Менә безнең ибтидаи[5] мәктәпләребезнең барышлары шулардыр[6]».

Хикәянең 7, 10, 11 битләрендә шундый үгет вә ачынуларны ачык күрәбез. 18–19 битләрдә дә фикер бирүләр бар.

Ф. Кәриминең бу хикәясендә укытучы мулла, хәзрәтләрнең, андагы хәлфә, казыйларның, анда укучы шәкертләрнең кызганыч тормышлары, типлары татар матур әдәбиятында беренче мәртәбә бик яхшы бирелә алган, шулар ачык, тулы тасвир ителгән. Бу хикәяне укып чыккач, иске авыл мәдрәсәләре, андагы шәкертләр, аларның тормышлары, хәлфәләр, казыйлар, андагы дәрес бирүче хәзрәтнең табигать һәм тормышы, гавамның мәктәпкә мөнәсәбәтләре; авылның акыллы, тәҗрибәле, яшьләр тарафдары булган картлары күз алдында ачык гәүдәләнә ала. XX йөзнең башларына (бәлки, хәтта 1905 елларга кадәре) авыллардагы мәктәпләрнең күбесе шушы типтагы мәктәпләр, мәдрәсәләр иде. Хикәя, үзенең кыскалыгына карамастан, шул мәктәпләрне татар матур әдәбиятында яшәтеп калдырырлык сурәт бирә алган. Кыскасы, «Җиһангир мәхдүм»дә дә авылның иске мәдрәсәләре бик яхшы тасвир ителгәннәр. Ул бу

[1] Санә – ел.
[2] Заигъ – әрәм.
[3] Әхкяме диниядән – дини каннунардан.
[4] Мөнхасыйр булып – кайтып калып.
[5] Ибтидаи – башлангыч.
[6] «Фатих Кәрими әсәрләре», 1925 ел, 61 бит. *(Авт. иск.)*

бабта татар дөньясында әһәмиятле оригиналь бер хикәя һәм шул юлда беренче мәртәбә күренгән бер әсәр булды.

Әсәрнең теле – муллалар өчен махсус әйтелә торган кайбер мәҗбүри тәгъбир вә җөмләләрне калдырып, гомумән алганда, үзенә бик әз генә госманлы тәэсирен эләктергән татарча җиңел, садә тел. Аның соңгы әдәби әсәрләрендә дә теле, шул юлдарак барса да, күп вакыт һәм гыйльми мәкаләләрендә һаман госманлы тәэсиренә таба әйләнә барды да, соңыннан тагы төркчелек агымы җиңелгәч, татарчылыкка борылды (бу урында Фатих Кәриминең теленнән мисал өчен, аның 1925 елда басылган «Фатих Кәрими әсәрләре» мәҗмугасыннан «Җиһангир мәхдүм» хикәясеннән 55, 59, 60, 63, 64, 65, 70 битләрдән укылыр).

Ф. Кәриминең «Җиһангир мәхдүм»нән башка тагын, XX йөзгә кергәч үк, татар җәмәгате арасында бик зур шау-шу күтәргән һәм бу юлда беренче урын тоткан «Шәкерт илә студент» һәм «Салих бабайның өйләнүе» дигән ике кыска хикәяләре чыкты[1]. Бу хикәядә 1880 елларда пароходта кадимче татар муллалары, ишан, мөридләр белән очрашып, шуларның хәлләре, кыяфәтләре, аларның пароходтагы руслар һәм ориенталистлыкка хәзерләнүче бер рус студенты белән Яурупа кыяфәтендәге җәдит татар шәкерте алдындагы мөгамәләләре тасвир ителә. Монда да мөхәррир шул уңай белән яңа укуның, ысулы җәдитнең дингә каршы түгеллеге, мәдәният, тәрәккый, гыйлем вә һөнәр кебек мәсьәләләр турында әйтәчәк фикерләрен, үгетләрен биреп үтәсе килә. Укыту ысулы мәсьәләсенең дингә бәйланышы юк һәм җәдит-кадим низагысы чыгаруның бикяр[2] икәнлеге турындагы фикерләре дә Ризаның «Әсма»сындагы фикерләре белән бертуган һәм бер-берсенә бик ошаган күренәләр.

«Салих бабай» хикәясендә бер умарта караучы авыл картының ничек өйләнүе һәм балалар, яшьләр белән булган мөгамәләсе тасвир ителә. Ләкин балалар да, карт та монда табигый булып чыга алмаган, балаларга да, картка да үз табигате, үз телләре бирелә алмаган. Әсәрнең әдәби кыйммәте бу яктан шәп түгел.

Бу әсәрләренә тагын «Солтан гыйшкы», «Телсез хатын», «Хыялмы – хакыйкатьме?» дигән соңгы хикәяләрен кушарга кирәк.

[1] «Бер шәкерт илә студент» Казанда Думбровский типографиясендә 1903 елда басылды. Кечкенә кулда 40 бит зурлыгында. *(Авт. иск.)*

[2] Бикяр – файдасыз.

Гаяз Исхакый. Гаязның беренче хикәясе Галикәевләрдә, Яңа Бистәдә мөгаллим булып торган вакытта (һәм Гани бай тарафыннан макталган чагында) язган «Тәгаллемдә сәгадәт, яки Гыйлем үгрәнүдә рәхәт гомер» дигән хикәясе була. «Гаяз Гауни[1] әл-Исхакый» имзасы белән 1899 елда 24 бит зурлыгында басылып чыккан бу хикәя, ысулы җәдиткә, яңа мәктәпләрдә укырга кызыктырып язылган бер хикәя булып, Ризалар юлынча әдәбиятта рационализм агымының бер тамчысы иде. Бу хикәя, әле беренче тәҗрибә булганлыктан, һәрьяктан зәгыйфь, үзендә тасвир кылынган Хәлим дәрәҗәсендә шәкерт иде. Телендә дә мишәр йогынтысы белән бергә госманлылык тәэсире бар иде.

Шул ук вакытта 1900 елда урта кулда 30 бит зурлыгында «Кәләпүшче кыз» дигән хикәясе басылып чыгып[2], бу хикәя яңа татар әдибе була алу өметен баглатты. Ул вакытларда Гаяз белән мәсләктәш булган Йосыф Акчура улы кебек әдипләр 1906 ел «Казан мөхбире»нең 179 нчы санында аны мактап мәкаләләр дә яздылар.

Гаязның соңыннан басылган бөтен хикәя, романнары, пьесалары аның киң шашкын, котырык хыяллы һәм тасвирның күренешле (картиналы), җиңел алынмалы булуын күрсәтәләр. Бу хәл аның әнә шушы икенче хикәясендә үк сизелә иде.

Әдәби агым ягыннан әсәр – сентиментализмның татар әдәбиятында беренче ачык үрнәге. Ләкин фикерчелек-рационализмнан аерылып бетмәгән бер рәвештәгесе. Шулай да Риза казый, Ф. Кәрими һәм башкаларның каләмнәре аркылы киңәйтелә барган фикерчелеккә каршы сентименталистлыкны мәйданга бастыру юлында бу әсәр беренче адым булды.

Әсәр либераль буржуа сызыгында һәм тәмам дин-исламият рухы белән сугарылып язылган. Әсәр, мөндәриҗәсеннән ачык күренгәнчә, бер яктан, татар приказчикларының, икенче яктан, Ризаның «Әсма»сында да күрсәтелгән кебек, фәхешханәләргә илтеп кыз сату белән кәсеп итүче татар карчыкларының ни рәвешчә татар кызларының башларына җитүләрен тасвир итә.

Мөхәрриренең «бу хикәяне язган максад»ы «Камәр кебек булуның ахыры ни булачагын күрсәтеп», «милләтнең туташларын шул

[1] Текстта ялгышлык белән «Гаути» дип бирелгән.

[2] 1903 елда басылган «Ике гыйшык» дигән пьесаның тышында, ахырына бер хатынның озын гына бер хаты кушылып, икенче басылуы диелүгә караганда, тиз арада икенче басмасы да басылган булса кирәк. *(Авт. иск.)*

кара бәхетләрдән коткару өчен, аларга Камәр булуда нинди авырлыклар барлыгын белдереп, үзләрен саклар өчен бер тәнбиһә[1]» ясаудан гыйбарәт. Мөхәррир Камәрнең дучар булган әнә шушы хәлләрен, «милләте исламиябезгә бик зур кимчелекләр китерә торган сатлык галәме»н, «Камәрнең бу дәрәҗәдә бөтен галәме исламияттән мәнфур[2] улып, мөселманлыкка һич ярамаган хәлләрдә булуы өчен һәр мөселман егларлык»[3] рәвештә ялкынлы хис белән, сентиментальь рәвешендә янып-көеп тасвир иткән.

Әсәрдә алынган каһарман Камәр үз көнен үзе күреп тора торган бер гаиләдән. Ләкин әсәрдә Камәрнең атасы кем булганы һич күренми. Эшчеме, бер һөнәрчеме, сатучымы булган? – менә бу як мәгълүм түгел. Бу турыда әсәрдә ялгыз «Атасыннан калган бераз акча, йорт җиһазлары Камәр атасы өчен гомер үткәрерлек, дөнья уздырырлык булмады...» илх[4] сүзләр генә бар.

Гаяз каләме үзенә материалны күбрәк байлар һәм аларның яңаруына, тәрәккый хәрәкәтенә киртә булучы мөтәгассыйб руханилар, иске мәдрәсә шәкертләре тормышыннан тапты, шуларны тәнкыйть итте, шулардан көлде. Байлар һәм руханилар тормышының кара, кызганыч якларын күрсәтеп, шуларны төзәтергә тырышты. Гаязның шул ук максат белән, шул ук юлда 1896–[18]97 елда (Яңа бистәдә мөгаллим булган чагында) «Бай углы» дигән хикәясе язылып, беренче басмасы 1903 елда Оренбургта Ф. Кәрими матбагасында басылып чыкты.

Әдип әсәрендә бер үк бай гаиләсеннән, берсе – сәлби[5], берсе иҗаби[6] кылып, ике тип ясап чыгарган:

1) начар, иске тәрбиянең җимеше булган «тәүфыйксыз» Кәрим (сәлби тип) белән

2) яхшы, яңа тәрбия алган аның улы – «тәүфыйклы» Рәфгать (иҗаби тип).

Әдип, байлар өчен Рәфгатьне идеал тип итеп куеп, бай балаларының шулай булулары кирәклек юлына тарта һәм шулай булганда баерга, байлыкны сакларга, баеп рәхәт торырга мөмкинлекне күрсәтә.

---

[1] Әсәргә мөхәррирнең үзе тарафыннан язылган башлангычтан. *(Авт. иск.)*

[2] Мәнфур – нәфрәт уятырлык.

[3] Әсәрнең ахырына мөхәррир тарафыннан язылган «Хәтимә»дән. Әсәр тиз арада ике мәртәбә басыла. *(Авт. иск.)*

[4] Илх – һәм башка.

[5] Сәлби – тискәре.

[6] Иҗаби – уңай.

Мөхәррир әсәрендә төп максатны әсәренә язган башлангычында үзе үк: «Яздыгым романымда бай угылларымызның тәрбияләре нинди идекне вә бу тәрбияләрнең ни дәрәҗә зарарлы идекне укучыларымның күз алларына куймак эстәдем», «милләтемездә шул мәсьәләне ислах[1] фикере уянмасмы дип, мин шул эшләремезне булдыра алдыгым кадәр күрсәтмәк эстәдем. Җәнабе хак һәрберемезгә хак фикерләр биреп, хәмиятемезне уяндырыб, Ватанымыз, милләтемезнең файдасына тырышырга насыйб итсен», – дип, ачык билгеләп куя һәм ул шул максатына таба нык адымнар ташлый. Ризалар белән бер үк идеологиядә булган хәлдә, байлар тормышын ислах итү юлында Гаяз каләме хикәяләр язу белән бергә үк драмалар да язды. 1900 елда урта кулда 56 бит зурлыгында басылган «Өч хатын белән тормыш» исемле биш пәрдәлек беренче драмасы Гаязның шундый максатлар белән чыгуында бик характерлы бер әсәре булды.

Әсәрдә («Өч хатын белән тормыш»та) мөхәррирнең төп максаты байларның, өч хатын белән тору һәм шулар өстенә тагын башка хатыннар артыннан йөрү сәбәпле, гаилә тормышының рәхәтен (мөхәррирнең үзенчә әйткәндә, «фамилия рәхәте») күрә алмауларын һәм шул ук сәбәпле ахырда барып бөлүләрен тасвир итүдән гыйбарәт.

Әсәрдә Кәрим үзе сәлби баш тип итеп алынган булса, аңа каршы иҗаби тип итеп тә аның каенесе Риза алынган. Кәрим – Казан байларының надан, дини, иҗтимагый яктан иске фикерле, ләкин сәүдә бабында бераз яурупалашкан, рус-Яурупа сәүдә капиталистлары сызыгында эш итүче бер урта хәлле сәүдәгәр. Үз дөньясының рәхәтен хатын-кызлар арасында һәм күп хатыннар белән торуда күрергә теләүче бер кеше. Риза исә – дини, иҗтимагый яктан яңа фикерле, җәдитче, тәрәккыйче, «гыйлем, һөнәр, тәүфыйк»чы, дөнья белән «ахирәт сәгадәтен» бергә җыярга тырышучы һәм үзенчә хатын-кыз мәсьәләсендә дә ислам сызыгында гына торып, безнең динебездә бер хатын өстенә башка хатын алу дөрест түгел, мәгәр дөрест, әгәр бер кеше бер хатынга гына канәгать кылмаса, начар эшләр артыннан, хатын-кыз артыннан рисвай булып йөрерлек булса, ул вакытта да хатыннары арасын гаделләсә, юк исә, алай да ярамый» дип, XX йөзнең беренче уны эчендәге дини реформачылар нигезендә уйлаучы, өйләнү мәсьәләсендә дә «холыклары ярарлык», егет – кызның, кыз да егетнең «күңеленә туларлык» булуын

[1] Ислах – үзгәртү.

таләп итүче, шулар өстенә үзе «ничә төрле генә тел белә» торган укымышлы, урта тормышлы бер сәүдәгәр. Мөхәррир менә шушы тип авызыннан (Ризадан) мөселманлык нигезендә, Аллага сөялеп әхлак өйрәтү юлында фикерләр сөйләтә: «Эшләгән эшең әхлакка муафыйк булсын, мөселманлыкка тугры килсен, гадәткә тирес булмасын», «кешеләр Аллаһы Тәгаләнең боерыгын тотмаганнары өчен дөньяда һичбер вакытта рәхәт гомергә ирешә алмыйлар», – дигән сүзләрне әйттертә. Шуның өстенә: «Үзең көчләнсәң көчлән, кешене көчләмә, синең күз яшеңне түкдерсәләр дә, син кеше күз яшендән саклан! Күз яше – бик зур нәрсә», «Үзеңә зарар иткән кешедән үч алырга тырышма. Сиңа зарар итсен, син аңарга файда ит. Менә кешелек шунда, әгәр син усаллыкка яхшылык кайтарсаң, ул кеше, вөжданына газапланып, эче пошып, йөдәп чыга. Һәр эшкә бер җәза булганга, аны син кичерсәң дә, Аллаһы Тәгалә аны эч пошуы белән газаплаган була да, синең дә үчең алынган була» (27–28 битләр), – дип, гыйсавилек[1], толстойлык үгете бирдертә (толстойлыкның татар әдәбиятында тәэсире булды).

Китаптагы вакыйгаларның барышы да «һәр эшкә бер җәза булганга» карап нәтиҗәләнә бара. Һәркем үз эшенә карап, Риза казый әхлакчылыгында, ягъни («Әсма»да) күрсәтелгәнчә үк, үз җәзасын күрә бара: Кәрим байның хатыны үзенең акыллылыгы, түземлелеге, ире үзенә яманлык итсә дә, ул аңа һаман яхшылык итә баруы аркасында, ахырда, Кәрим үлгәндә, аннан яхшылык күреп, малга-акчага ия булып калуы – моның иң ачык бер мисалы.

Кыскасы, әдип Ризаны татар байларының яшьләре өчен идеал итеп алган булып чыга.

Шул ук нигездә, шул ук рухта, шул ук максат белән тагын аның биш пәрдәлек «Ике гыйшык» дигән пьесасы языла. 77 бит зурлыгында (урта кулда) 1903 елда Оренбургта Ф. Кәримов матбагасында басылып чыккан бу әсәр дә (басылуы өчен 1902 дә рөхсәт алынган була) һәрьяктан тегеләре җебенә тезелә.

Гаязның бу әсәре дә мещаннар, байлар тормышыннан алынып язылган. Бу пьесасында (мөхәррир үзе комедия дисә дә, чынында пьеса ул) Гаязның ике тибы бар. Берсе – Рәхмәтулла бай, икенчесе дә – аның улы Каюм.

Рәхмәтулла бай татарның иске феодал байлары тибы итеп алына. Иң иске фикерле, кара надан, «гәҗит» (гәзит) укуга, яңалыкка,

[1] Гыйсавилек – христианлык.

җәдиткә каршы, балага ата булып әтәчләнергә дә бик ярата торган һәм гел хатын сүзенә ияреп эш итүче бер татар купецы. Ул – хәтта үзенә сәлам бирмәүче хәерчеләрдән дә үч алучы бер бай.

Каюм исә – аңы ачылган, укымышлы, мәгълүматлы, ачык фикерле, яурупалашкан (музә[1], театр, көтепханәләрдә генә йөрүче) җәдит бер бай улы тибы итеп, идеаллаштырып алынган бер тип. (Шуның өстенә тагын үзе: «Дөньяда кылган яхшылыклар һәм яманлыклар һичберсе үзләренә тиешле җәза бирелмичә калмый», – дип уйлаучы.) Бу тип белән әдип бай балаларының чынында ничек булырга тиешлеген күрсәтергә тели. Әдип аны әхлаклы, вөҗданлы, изге, кешелекле итеп күрсәтергә тырыша (аңа каршы тагын Газиз дигән бозык бер бай малаен да китереп кыстырып үтә), ул – «Әй әхлак, әхлак! Бигрәк мөкатдәс нәрсәсең! Ярабби, шул холкымдан аерма», дип, күркәм холыкны үзенә идеал иткән бер егет.

«Ике гыйшык»ында Гаяз усал бер үги ана тибы да алган. Ләкин бу тегеләрне ачу өчен генә кирәк. Шуның өчен ул үги ана тибы булып тәмам эшләнеп чыкмаган. Шулай да ирләрен алдаучы, үзләренең усаллык һәм куштанлыклары белән үзләренә каратып, башларын әйләндереп алучы зәһәр хатыннар өчен мисал була ала.

**«Инкыйраз» һәм «болгарчылык».** 1904 елда Гаязның зурлыгы бер роман дәрәҗәсенә килгән «Ике йөз елдан соң инкыйраз» дигән, үзе хикәягә охшаган бер әсәре басылып чыга.

Чынында бу әсәрне Гаяз Исхакыйның ялкынлы, шашкынлы бер сүз куәте белән укучыларның ми һәм йөрәкләрендә нык уяну кузгалышын тудыру максаты белән язылган әдәби хөтбәсеннән – гомуми-тарихи бер реченнән гыйбарәт диярга мөмкин.

Гаяз монда, бөтенләй җибәрелеп, татарның (аның үзенчә, «болгар» халкының) XIX йөзнең башыннан XX йөзгәчә булган иҗтимагый-мәдәни хәрәкәтенең вакыйгый-тарихи барышын тасвир һәм тәнкыйть итсә, XX йөздә, шул XIX йөздәгегә карап, әдип хыялында сурәте билгеләнгән барышны – болгар халкының тәмам мөнкәрыйз булуын[2] сурәтләндерә.

«“Ике йөз елдан соң инкыйраз” – җитди бер әсәр. Ләкин Гаяз – монда да шагыйрь. Дөрест, монда сурәткә караганда фикер галиб[3], ләкин бу фикерләр берсе дә – тар мантыйк калыбына салынып, суык

[1] Музә – музей.
[2] Мөнкәрыйз булуын – бетүен.
[3] Галиб – өстен.

кан белән мөхакәмә ителгән[1] саф фикерләр түгел, бәлки гаять куәтле хис вә һәяҗан[2] белән кызган фикерләр. Боларны башдан бигрәк калеб эшләгән. “Инкыйраз” – ысуллы бер гыйльми мөхакәмә булмаган кебек, җиренә җиткереп эшләнгән бөтен бер тасвир да түгел. Күңелдән агып чыккан бу фикер вә хис агымын мөхәррир сурәтләргә сыйдыра алмаган, күп сурәт ясап маташмаган да. «Инкыйраз» – бездә дөньяга туп-туры караш вә мөстәкыйль фикер белән язылган иң элекке әсәр. “Инкыйраз”ны бөтен бер әсәр итеп алганда, анда зур бер оешкысызлык, фикерләрнең тәртип вә агымындагы табигыйлеккә зарар бирердәй мөбаләгә[3] вә ясалышлар, идея ача төшү өчен тиешендән артыграк куертылган буяулар бар» (Җамалетдин Вәлиди – Җәләй – «Вакыт» гәзите).

Гаяз бу әсәрендә XIX йөздә татар дөньясында, татар байлары һәм руханилары арасында таралган дүрт хәлне алып, аларны «курчак туе» дип атый да, шуларны чынлап та курчак уены кебек бер нәрсә сурәтләндерә. Бу курчак туйлары да:

1) татар байларының бер туйга хәтта кырык мең сумнар түгеп, исрафлы туй ясау гадәтләре;

2) татар руханиларының җәй көннәрендә – кыска төннәрдә ястү намазы фарызмы-түгелме, намаз вакыты кирәме-юкмы мәсьәләсе белән талашулары;

3) русча уку дин каршында дөресме-түгелме дигән мәсьәлә белән шау-шу килеп талашулар;

4) ысулы җәдит, ысулы кадим тартышыннан гыйбарәт.

Шуларга наданлык, әхлаксызлык, ярлылык, фәхеш, төрле һәлакәтле авыруларны китереп кушып, шул хәлләрендә барсалар, татарларның тәмам бетүгә, югалуга таба баруларын күрсәтә, шул барышларда кайсы вакытларда әзрәк тәрәккый хәрәкәтләрен дә күрсәткәләп алып, соңыннан XX йөзнең ахырында җир йөзендә татар (аныңча – болгар) халкының берсен дә калдырмыйча юк итеп чыгара – тәмам мөнкәрыйз булган итеп күрсәтә.

Әсәр, шөбһәсез, сентименталь бер юл белән тәмам тузылып, тәмам җибәрелеп, шашылып, утлы бер каләм белән язылган.

Гаяз башта ук татар либераль буржуазиясенең ялкынлы бер идеологы булырга тырышып мәйданга атылды. Ул «татар буржуазиясе-

---

[1] Мөхакәмә ителгән – табылган.
[2] Һәяҗан – дулкынлану.
[3] Мөбаләгә – арттыру.

нең оешып килгән яңа идеологиясе»н күтәреп чыгып, шуны «тәрәккый милләт» шигаре астында киңәйтеп, тамырландырып җибәрү юлында эшләүчеләр арасында булды.

Аның әлеге «Инкыйраз»ы да бу турыда аның юлын ачык билгеләүче бер маяк иде. Шушы әсәренә язган дүрт битлек башлангычында ул үзенең әдәби-иҗтимагый юлын, төп әмәлен (идеалын) ачык күрсәтте. Үзенең, чыннан да, татар буржуазиясенең идеологларыннан берсе булуын, булачагын ачык белдереп үтте.

Шул башлангычында ул милләтнең тәрәккыйсе өчен манигъларны[1] – «манигъ тәрәккыйләрне санап килеп, боларның берсе – мөтәгассыйб голәма» сыйныфы булуын, икенчесе – мәдрәсәләребезнең юклыгы һәм анда укылган гыйлемнәрнең бер «чепуха» булуларын әйткәннән соң, өченче «манигъ тәрәккый»гә күчеп болай ди: «Өченче манигъ тәрәккый һәм дә иң сизелә торган манигъ тәрәккый – милләтемездәге хезмәткә ярарлык кешеләрнең һәм хезмәт итә торганнарының бик фәкыйрь бер сыйныфдан чыгулары». «Бу мәсьәлә – затән[2], иң әһәмиятле, иң зур фикер сарыф кылына торган эшдер. Ләкин бу эш, безнең болгарларның бәхетсезлегенә каршы, башка милләтләрнең хилафына булгандыр. Башка халыкларда күбрәк әрбабе хәмият[3], бигрәк әрбабе каләм[4] зур байлардан, зур дәрәҗәле затлардан чыкмышдыр».

Ул ачыктан-ачык буржуазия-аристократия әдәбиятын тудыру һәм «зур байлардан, зур дәрәҗәле затлардан әрбабе каләм җитештереп чыгару» сызыгыннан хәрәкәт башлаганын ачык әйтеп биргән шикелле, ахырда да, шул ук юлда, шушы ук беренче идеалында нык торды. Бөтен көче белән шуңа таба омтылды, шуның өчен нык көрәш алып барды. Бу нәрсә, әлбәттә, татар буржуазиясенең иң беренче теләге иде. Гаяз «Инкыйраз»ы аркылы яңа бер агым кузгатты. Каюмнар күтәргән «татар» дигән исемне бетереп, «болгар» дигән исемне, шаулатып, уртага куярга азапланды. Татарны «татар» диюгә бөтенләй каршы юл тотты. Бик ялкынлы бер рәвештә «безнең болгар милләте», «болгар кызы, болгар егетләре» дип күтәрелеп чыкты. «Инкыйраз»ы белән «Теләнче кызы»сы әнә шуның тарихи бер маягы булып калды. Ләкин аның бу күтәргән яисә кыздырган агымы,

[1] Манигъларны – каршылыкларны.
[2] Затән – нигездә.
[3] Әрбабе хәмият – фидакярләр.
[4] Әрбабе каләм – каләм әһелләре.

шау-шуы, асылда, шул ук Гаспринскийларның, Ризаларның агымнары, алар шау-шуының әле тагын да яшь, тагын да утлы бер каләм аркылы яңадан кыздырылуыннан гына гыйбарәт иде. Шулай итеп, телдә шул ук татарчылыкны алган хәлдә, Гаяз каләме дә төп идеологиядә төркчелек юлында торып, Каюмнарның татарчылыгына каршы күтәрелеп карады. Ләкин Каюмнарның көчле агымы алдында чыдап бара алмады, татарчылыкка җиңелде: соңгы әсәрләрендә инде «болгар» дип шаулауны куеп, «татар» дип яза башлады.

Бу урында янә шул ук югарыда тикшерелеп үткән әсәрләре белән бер үк максатка караган, бер үк рухта булып, бер төрле үк идеология белән сугарылган «Теләнче кызы» дигән романын искә алып үтик. Өч кисәктән гыйбарәт булган[1] бу романында да Гаязны «әхлаклы», «вөҗданлы», «вөҗдан газабы» иясе, «тәүфыйклы», шулар өстенә тагы Толстой[2] әхлагы белән нык сугарылган бер әдип итеп таный алабыз. Шулай ук бу романында да ул – башка әсәрләрендәге шикелле, «фамилия сәгадәте» кешесе.

«Гаяз әфәнде «сәнгать – сәнгать өчен» дип белүчеләрдән түгел, ул сәнгатьне әхлак өчен дип белә вә аның һәрбер әдәби әсәренә әхлакый вә иҗтимагый идея әсас[3] була. Шуның өчен ул әдип Толстойга караганда философ Толстойны әллә кая артык күрә. Фәкать сәнгатькяр әдип Пушкинны халкының шулкадәр күтәрүенә төшенә алмый. Көяз сәнгатькярлек Гаяз әфәнденең әдәбилек психологиясенә бөтенләй ятмый. Ул ни генә язмасын, һәммәсе әхлакый вә иҗтимагый бер ноктага үз алдына тартылып тора. Гаяз әфәнде – әхлакчы вә уйлаучы иҗтимагый бер әдип. Монда шөбһә юк» (Җамалетдин Вәлиди – «Вакыт» гәзите).

«Сез карагыз аның элекке әсәре «Тәгаллемдә сәгадәт»кә, соңра «Кәләпүшче кыз» белән «Бай углы»на. Болар никадәр саф диләнә[4] вә никадәр әхлакчы. Боларда әле сәнгать бик аз эш күргән. Типлар

---

[1] Беренче кисәге кечкенә кулда 187 бит, икенче кисәге шул ук кечкенә кулда 87 бит (бусы 1909 елда басылган), өченче кисәге урта кулда 136 бит (бу соңгысы 1914 елда басылган). *(Авт. иск.)*

[2] Лев Николаевич Толстой (1828–1910) – күренекле рус язучысы һәм фикер иясе, мәгърифәтче, публицист, фәлсәфәче. Аның фикерләре яңа әхлакый юнәлешнең – толстойчылыкның нигезен тәшкил итә. Татар зыялылары Л.Н. Толстойның иҗтимагый эшчәнлеген зур игътибар белән күзәтәләр, татар укучысын аның иҗатына якынайтырга тырышалар. XX йөз башында татар дөньясында башка бер генә рус язучысы да Л.Н. Толстой дәрәҗәсендә популяр булмый.

[3] Әсас – нигез.

[4] Саф диләнә – саф күңелле.

юк. Сурәтләр дә гаять юка булып, алар артында яшеренгән вәгазь иң гади күзгә күренеп тора. Мөхәррир моңа гына канәгатьләнми, башка бер мөкаддимә язып, анда укучының гыйбрәт белән укуыны, вәгазь алуыны үтенә» (Җ. Вәлиди – «Вакыт» гәзите).

«Соңра «Өч хатын белән тормыш», «Ике гыйшык»лар тагын да сәнгатькяранә языла. «Очрашу»сы белән бик зур [алга] атлый. Монда Гаяз шагыйрь күренә. Бу әсәр «Инкыйраз»ларны, «Сөннәтче бабай»ларны вәгъдә итә» (шул ук гәзит, шул ук мәкалә).

Гаяз – беренче адымыннан ук матур әдәбият аркылы татар буржуазиясенең әхлак мөгаллиме, ул татар әдәбиятында буржуаның вөҗданлы, тәүфыйклы, шашкын бер хатыйбы – ораторы иде.

«Теләнче кызы»нда да без шушы Гаязны бик ачык күрәбез. Бу романында Гаязның өч каһарманы, өч тибы бар. Берсе – ярлы бер гаиләдән ятим калган кыз Сәгадәт, икенчесе – бай улы, «потомственный почётный гражданин» Габдулла Әмирханович, өченчесе – милләтче, буржуазия тормышын ислахчы, ятимнәр, бәхетсезләр өчен кайгыручы татар зыялысы Мансур.

Ата-анасыннан ятим калып, байларның зәкят өләшү вакытларында капкадан капкага йөреп, ахырда Габдулла тарафыннан мәсхәрә ителгән Сәгадәт, йөри торгач, фәхешханәгә барып керә. Мансур шул ук вакытларда Габдуллага рус теле һәм фәннәр укыта башлап, аңа тәрбия бирергә керешә. Мансурның тәэсире белән Габдулла да «үзенең гайрәтен, көчен кушып, шул пычрак, кабахәт Габдулла Әмирхановичтан яңа – вөҗданлы, кешелекле Габдулла әфәндене тудырмакчы була». Мансур да, «Габдулланың – шул черек, кабахәт, пычрак Габдулланың кешегә әйләнүе өчен», «бикәчкә керә торган егет кебек шатлык белән кабланган» була. «Үзенең тәэсире белән, йоклаган бер вөҗданның уянуы өчен, кешелекдән чыкды дип хөкем кылынган бер яшь татарның кешегә әйләнүе өчен, ул күңелендән бәйрәм ясый». Ниһаять, аны тәүфыйкка китерә, юлга сала. Ул инде хәтта үзенең бөтен ата-аналары һәм бөтен халык теленә төшеп, алар алдында хурлануына карамастан, Мансур белән фәхешханәдән фәхешханәгә кереп, әллә никадәр азаплар күтәреп, Сәгадәтне эзләп йөрерлек бер дәрәҗәдә яхшы бер бай малае булып әверелә. Ахырда Сәгадәтне фәхешханәдән алып, аның белән, өйләнеп, бергә яши башлый. Сәгадәт тә күп газаплардан соң беренче мәртәбә «сәгадәт»кә – байга бару сәгадәтенә ирешкән була. Бу гаилә Мансур һәм аның иптәшләре өчен дә милләткә һәм халыкка хезмәт эшләрен

кайгырта, үзендә төрле утырышлар, киңәшләр ясый торган җылы бер оя була. «Алар хәзер үзләренең бетмәс-төкәнмәс мәсьәләләрене мөляхәзә кылышыр[1] өчен, иксез-чиксез тормышның сөальләренә җавап табар өчен», «идәннән түшәмгә кадәр сузылган көзгеләр, пөхтә урындыклар, озын иттереп ак эскәтергә ябылган өстәлләр, роза гөлләре белән бизәлгән Габдуллаларның залларына күчерә башлыйлар» («Теләнче кызы», өченче кисәк, 16 бит). Бу рәвешчә «боларның ибдәшләренең артуы һәм дә шундый Габдулла кебек бер бай егетенең артуы боларның үзләренә, үзләренең киләчәкләренә, халыкның киләчәгенә иманнарыны бик артдырган» була.

Шушы мохиттә яшәп, шул ук Мансур һәм аның иптәшләренең тәэсире астында Сәгадәт тә фикер ягыннан күп күтәрелә. Фәкыйрьләргә, авыл халкына ярдәмле бер бай хатыны булып әверелә. «Аның юмартлык, йомшаклык шөһрәте бөтен Идел буена таралып» китә. Аның белән генә калмый, русча да укый башлый. Гимназиянең дүрт классына имтихан да тота. Ләкин Габдулла белән Сәгадәт арасында, Габдулланың һаман Сәгадәттән башка хатыннар белән дә чуалуы һәм артык комсыз бер бай булып әверелүе сәбәпле, салкынлык төшә башлый. Бара торгач, Сәгадәт, анна н аерылып, Петербургка укырга китү карарына килә. Мансур Сәгадәтнең Габдулладан суыну, аерылу хәрәкәтләренә каршы килеп, һаман боларның арасын килештереп килүгә карамыйча, Мансур Сәгадәтнең Габдуллага каршы хәрәкәтләрендә күп вакыткача: «Юк, алай түгел, ул кадәр ашыгырга ярамый, Габдулланы бераз хисапка алырга кирәк» (III кисәк, 87 бит), «Юк, Сәгадәт, мин сине аңлыйм, ләкин Габдулла да бит...» (89 бит), «андый вакытта хатыннар ул кадәр каты күңелле булмаска кирәк, гаепле кеше гаебеннән тәүбә иткәч, кичерергә кирәк» (89 бит), «Шулай шул, шуның кебек эшләр өчен хатыннар фамилия сәгадәтен бозмаска тиеш» (шул ук бит), «шундый авыр чакларда хатыннар каһарманлык күрсәтеп, фамилия сәгадәтен сакларга тиеш дип уйлыйм, Габдулла да кызганыч түгелме? Ул үзенең дус-ише арасындан чыкты, үзенең кардәш-кабиләсендән аерылды, бай булмый торган бер каһарманлык кылып, үзенең бурычын үтәде, шуларның һәммәсен синең өчен кылды. Хәзер син дә аны ташласаң, ул ни булып кала, аны да уйла!» (90 бит), «менә кыскасы гына, мин сезнең элгәреге кебек дус, бер-берегезгә иптәш булып, бер-берегезне сөешеп торуыгызны телим» (90 бит) дип, һаман Сәгадәтне тыя

[1] Мөляхәзә кылышыр – фикер алышыр.

килә. Шуның тәэсире белән «Сәгадәт белән Габдулланың фамилия сәгадәтенең кояшы элгәредән дә якты иттереп икесен дә елыта, кыздыра башлый» (93 нче бит). Ләкин ахырда Мансур бу юлда тәэсирсез кала. Сәгадәт үз дигәненчә эшли.

Ахырда Габдулла белән Сәгадәт аерылышалар да, Сәгадәт Мансур һәм иптәшләре тарафыннан Петербургка укырга озатыла.

«Теләнче кызы»ның мөндәриҗәсе, андагы вакыйгаларның, тасвирларның барышы белән танышу безгә Гаязның матур әдәбияттагы идеология йөзен бик нык ачып бирә. Монда ул мәсхәрә ителгән, хурланылган бер ятим кызны – Сәгадәтне ахырда бай хатыны булуы белән «сәгадәт»ле, бәхетле ясый. Сәгадәтне «үзенең фәхешханәдә изелүе, үзенең яңадан иске тормышына кайтуына, үзенең бай хатыны булуына акылы да җитми, күңеле дә ышанмый торган итеп чыгара. Ахырда аны буржуа рухлы бер буржуа зыялысы итеп, идеаль бер татар хатыны тибын ясап чыгара: ясалма бер тип тудыра. Шуның каршысында шулай ук күп өлеше ясалма булган Габдулланы күрәбез. Татар дөньясында андый дәрәҗәдә төзәлеп җиткән бай малае булу ихтималы юк. Дөрес, ул ахырда да шул үзенең әүвәлге сызыгына табарак борыла борылуын, ләкин аның болай борылуы Мансур уйлаганга башкарак булып чыга.

Әмма Мансур тибына килсәк, монда без шул XX йөз башларындагы һәм 1905 елгача татар тормышында булган, булуы мөмкин булган төрле фикерләр, төрле хыяллар, төрле өметләр артыннан чабучы ялтыравык идеяле татар яшь зыялысын, татар вак буржуа юлбашчысын күрәбез. Мансур тибын язучы каләменең тарихы белән яхшы таныш булган кеше өчен хәтта ул каләмнең иясен бу типтан аеру кыен булганны күрәчәк. Мансурның «ике катлы, иманлы» бер әдип тибы булып чыгуы моңа тагын куәт бирә. «Мин Мансурны Гаяз әфәнденең үзендән аера алмыйм. Ул үзендә үзенең рәсемен ясаган, ләкин күб идеаллашдырган» (Җ. Вәлиди – Җәләй, «Вакыт» гәзите, 1169 нчы сан).

Гаязның башка әдәби әсәрләре түбәндәгеләр: «Мулла бабай», «Шәкерт абый», «Сөннәтче бабай», «Тормышмы бу?», «Ул икеләнә иде», «Остазбикә» дигән роман вә хикәяләре, «Мөгаллим», «Алдым-бирдем», «Җәмгыять», «Тартышу», «Зөләйха» кебек пьесаларыннан гыйбарәт.

Гаязның Февраль революциясе белән бергә туган соңгы әсәрләреннән булган «Зөләйха» турында Төркия матбугатында түбәндәге

фикерләр язылды: «Зөләйха» сәрләүхәсе алтында Гаяз Исхакый бәгең өч нөсхәдән бере дәвам идән вә һәнүз аркасы улынмаян пьесасындан бер шәй аңламадык.

Гаяз Исхакый бәк безә рухымызы татмин идән бер әсәр китерәмәмешдер. Бу анчак дини җидалек дәвам иттеге бер мохит вә бер заманда бәлки бер тәэсир япа беләчәк бир тиятру ула белерде! Тиятру ула белерде, диюрыз. Чөнкә тиятру – бер сәнгатьтер. Бер кәррә мәүзугы фикре мохита тәмамилә япанчы, соңра тиятру сәнгате намына һичбер шәй юк.

Иң мөһим бер нокта – бу пьесаның кодрәте ифадәя малик уламамасыдыр. Ифадә чук бәяндыр. Сәхнә үзәрендә бер кәлимәнең белә әгъзами җанлылыгы ляземдер. Бондан башка безем гүзәл төрекчәмезе бозан җөмләләр вар. Хәтта сарыф вә нәхү хаталары вар.

Соңра безем өчен иң мөһим улан нокта – төрк йорды яңы төркең кукмыш гакыйдәләрә зарбә индермәктә иң куәтле силахыдыр, хорафатың биәман дошманыдыр. Буеныңдан нөсхә чыкаркан вә хорафая тапынмагы тәлкыйн идән бер мөхәррирең бу фикерене төрек йордында заляләт гадд идәрез.

Бөтен җидалемез – бу хорафае кырмактыр – вә Зөләйха маҗарасының кичтеге мохит – бу хорафатың корбаныдыр! Боны озатмыялым, чөнки төрк йордыда иң чук тәнкыйтә мөстәхак улан бер әсәрдер»[1].

Мәкалә имзасыз. Димәк, аерым бер язучыныкы гына булмыйча, гавами фикер шулай.

Гаяз – көчле татар язучыларының берсе. Шулай да 1917 елда басылган «Тартышу» дигән дүрт пәрдәлек әсәрендә инде бу каләмнең

---

[1] «Зөләйха» исеме астында Гаяз Исхакый бәкнең өч нөсхәдән берсе дәвам иткән һәм һич ахыры булмаган пьесасыннан берни аңламадык.

Гаяз Исхакый бәк рухыбызны канәгатьләндерерлек бер әсәр барлыкка китерә алмады. Бу фәкать дини көрәш дәвам иткән бер мохиттә һәм заманда бәлки тәэсир итә алырлык бер спектакль булыр да иде. Спектакль була алыр иде, дибез, чөнки спектакль – бер сәнгатьтер. Бер үк тема, фикер, сюжет белән чикләнеп, шуның белән канәгатьләнеп, шуннан соң театр сәнгате файдасына бүтән бернәрсә эшләмәде.

Иң мөһим нокта – бу спектакльнең аңлату көченә ия булмавы. Аңлату бик озын һәм хиссез. Сәхнәдә һәр сүзнең җанлылыгы зарур. Моннан башка безнең гүзәл төркчәбезне бозган җөмләләр бар. Хәтта морфологик һәм синтаксик хаталар бар.

Аннан соң безнең өчен иң мөһим булган нокта: төрк йорты – яңа төркнең искергән гадәтләргә зыян китерүдә иң куәтле коралыдыр, хорафатның аяусыз дошманыдыр [дигән фикер]. Куеныннан әсәр чыгарган һәм хорафат табылуын сеңдерергә тырышкан бер мөхәррирнең бу фикерен төрк йортында ялгышлык дип саныйбыз.

Бөтен көрәшебез – бу хорафатны бетерү, һәм Зөләйха маҗарасы белән бәйле мохит – бу хорафатның корбаныдыр! Моны озынга сузмыйм, чөнки төрк йотында иң зур тәнкыйтькә лаек булган бер әсәрдер.

күп йомшаганы, зәгыйфьләнгәне күренә. Гаязның «Мулла бабай» белән «Сөннәтче бабай»ы – яхшы чыккан әсәрләреннән. Без Гаязда тормышны, бигрәк тә муллалар, хәзрәтләр, шәкертләр, остазбикәләр, суфилар, сөннәтче бабайлар тормышын яхшы ук тулы оригиналь бер юл белән тасвир итү көчен, тасвирының да картиналы булуын күрәбез. Ләкин шуның белән бергә, кирәк романнарында, кирәк драмаларында булсын, табигый түгеллекләр, ясалмалыклар, реаль бер типны идеаллаштырып бозу кебек хәлләр дә юк түгел. Аның каһарманнарының сүзләре, табигатьләре, итенеш-кыланышлары бик үк оешып җитмәү кебек кимчелекләр дә бар. Драма һәм комедияләре дә сәхнәчә, сәнгатьчә тәмам уңышлы булып чыга алмый. Монологлар күп. Сәхнәдә уйнарга авыр булалар.

«Затән[1], Гаяз әфәнденең һәммә пьесаларында да сәхнә өчен авырлыклар, кирәкмәс дәрәҗәдә авыр монологлар бар. Аның «Өч хатын белән тормыш» драмасында Кәримнең үлеп яткан чагында халык көлә. Инде «Мөгаллимә» драмасында артистларны уңайсыз хәлдә калдыра торган сценалар бигрәк тә күп. Сәхнә әсәре булу ягыннан «Мөгаллимә» бигрәк дә авыр пьеса булып чыккан». «Пьесаның бу авыр һәм кирәкмәс дәрәҗәдә озын монологлары нинди оста артистларны булса да, ниһаять, уңайсыз вазгыятьләргә төшерми калдыра алмаячаклардыр» («Тормыш» гәзите, 188 нче сан, 1915 ел, Сәгыйть Рәмиев тәнкыйте).

«Соңгы дәвердәге әсәрләре белән бытописатель[2] булып күренгән Исхакый әфәнденең «Мөгаллимә» дигәне игълан кылынгач, хәят белән реаль әдәбият арасындагы мөнәсәбәтне аңлаган һәркем, әлбәттә, әсәрдә шул яңа сыйныфның мөгаллимәлекләрендән туган язмышы, шул язмышның тудырган сыйнфый сыйфатлары, ягъни татар хәятында бар булган мөгаллимә тибы күрсәтелгән дип уйлады. Шулай уйлаганлардыр, шулай көткәнләрдер. Ләкин боларның һәммәсе бушка чыкды.

Пьесада күп нәрсә, күп нотыклар, озын-озын хатлар бардыр. Ләкин күпчелекнең язмышы, шул югарыгыча булган татар мөгаллимәсе тибы юк. Мөхәррир әфәнде, мөгаллимәләрнең хәятын, табигый вә гади язмышларын тасвир итеп, укучыларны алар хакында уйларга мәҗбүр итәчәк бер нәрсә бирү кайда, хакыйкый мөгаллимә

---

[1] Затән – нигездә.

[2] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

язмышына гаид[1] бер ишарә дә юк» («Тормыш» гәзите, 1915 ел, 125 нче сан. Г. Ибраһимов).

«Мөгаллимә» – укып юаныр өчен күңелле бер әсәр. Әмма әдәби вә иҗтимагый кыйммәте (хәятның көзгесе була алмаганга) нульгә якын» (шул ук мәкалә, шул ук гәзит).

**Г. Исхакыйның теле, өслүбе.** Гаязның теле, өслүбе – үзенә махсусрак бер өслүб. Садә, җиңел. Ул «Бичара кыз», «Рәдде бичара кыз», «Чистай комедияләре» күтәргән һәм Галиәсгар Камал тарафыннан беренче мәртәбә сәнгатьчә эшләнгән гавами бер татар телен бөтен киңлеге белән алга алды. Шуны киң рәвештә гамәлгә ашырышты. Ризаларның төркичелегенә каршы, шуның галәбә[2] кылуына күп булышлык күрсәтте.

Ләкин ул, шушы хезмәтләреннән үтеп, ул телнең сәнгатьчә матур, нәфис эшләнеп чыгуы юлында күп хезмәт куша алмады. Ул телдә халык, масса бакчасын ачты. Ләкин аны матурлап эшләп бирә алмады. Аның әсәрләре тел ягыннан озын, төрле кирәкмәс үләннәр, чүпләр, әремнәр, билчәннәр, кырлы курайлар баскан, уталмаган бер бакчага охшыйлар.

Анатоли төркләренең әдәбиятчыларыннан Мәхмүд Әкрамның: «Артык кирәксез сүзләрдән тазартылмаган, җыйнаксыз бер әдәби әсәр бакча иясенең дикъкатьсезлегендән, ялкаулыгындан чүп баскан мөнтазам[3] бер бакчага охшый. Табигать ияләре аңа караган саен кайгырыр, аны сәер, тамаша итүдән күңеле суыныр»[4], – дигән сүзе бар. Менә шушы сүз тел-өслүб ягыннан Гаяз әсәрләренә дә туры килә.

1. «Зал тулы халыклар рәсемләрне карыйлар иде. Рәсемләр хакында мөхакәмәләр кылалар иде. Әллә никадәресе шул рәсемләрнең копияләрен алу тиешлекләрен сөйлиләр иде. Икенчеләре болгар мөхәррирләренең рәсемләре хакында, аларның төсләре хакында, тәрҗемәи хәлләре хакында сөйлиләр иде[5]» («Инкыйраз», 68 бит).

2. «Ул болардан җирәнгән кебек булды. Боларны кызганган кебек булды. Болардан оялган кебек булды» («Теләнче кызы», икенче кисәк, 16 бит).

[1] Гаид – бәйле.
[2] Галәбә – өстен чыгуына.
[3] Мөнтазам – тәртипсез, рәтсез.
[4] Г. Сәгъди. «Кәвагыйде әдәбия». 1911 ел, 29 бит. *(Авт. иск.)*
[5] Шул ук китап, шул ук бит. Шул ук әсәрдә бу өслүбне җыйнак кылып язып күрсәтү үрнәге бар. *(Авт. иск.)*

3. «Безнең Мансурлар, Габдуллалар, Сәгадәтләр әллә нинди зур мәсьәләләрне хәл кылыр өчен тырышкан вакытда, көндән-көн алар эчләрендән үзгәрә барган вакытда, аларга хәрәкәтләнми тора торган кебек күренә торган татар тарихы да бер дә селкенми XII гасырда басып тора торган кеби күренә торган заманда үзләренең юллары белән селкенәләр, үзләренең канунлары белән, акрын-акрын гына булса да, татар тормышының да бәгъзе якларына бәрелеп, бик нык түгел нигезләрне җимерәләр, ныграк җирләрне бәрелә-бәрелә шактый какшаталар иде» («Теләнче кызы», өченче кисәк, 1914 ел).

4. «Язарга кирәк дияләр иде, язалар иде. Сөйлиләр иде. Кычкыралар иде. Үз юлларында эшлиләр иде» («Инкыйраз», 28 бит). «Бу әллә нинди бер чир иде. Йогышлы иде. Бик тиз үтерә иде. Тагы гаҗәб шунысы: бу мөселманлар арасындан чыккан иде һәм шулар арасында гына патшалык сөрә иде. Бер Казанда гына һәр көнне йөзәр мөселман үлә иде[1]» («Инкыйраз», 39 бит).

5. «Һәммәбезгә дә сәгадәт юлы капланган иде. Бу күренеш моң иде. Егласыны китерә иде. Кызганыч иде. Аяныч иде, бәхетсез иде» («Очрашу, яки Гөлгыйзар», 144 бит, икенче басмасы, 1911). «Бу минутда мин йоклый идем, төш күрә идем, уяна идем, төш юрый идем, тагы йоклый идем» (шул әсәр, 133 бит). «Аларның икесенең дә күңеле хәзер бер һәлак була торган кызны коткару уе белән мәшгуль булганга, бөтен гайрәтләре, көчләре шуңарга гына багышланган булганга, шул минутда бөтен күңелләре шундый сатлык мәхәббәтләргә дошманлык белән тулы булганга...» («Теләнче кызы», 13 бит, икенче бүлем).

Гаязның өслүбе җыйнак булмау белән бергә, анда аһәңсезлек, таза булмаучылык кимчелекләре дә бар. Гаязның тел-өслүбендәге кимчелеге татар тәнкыйть дөньясында 11 нче елдан ук күрсәтелә килде (мөхәррирнең «Кавагыйде әдәбия», аңа «Гыйлавә»сенә, «Әдәбият мөгаллиме» дигән әсәрләренә каралсын).

Җамалетдин Вәлиди дә, югарыдагы әсәрләрне язучы «берәүнең Гаяз әфәндегә тел вә өслүб турысында булган яхшы гына хаклы игътиразыны» әйтеп үткәннән соң, түбәндәге фикерләрне язган иде: «Гаяз әфәнденең гыйбарә вә өслүб җәһәтендән искерәк әсәрләренең

[1] Г. Сәгъди. «Әдәбият мөгаллиме». 1913 ел, 76 бит. Бу китапта шул турыда Гаязның тагын башка әсәрләреннән дә мисаллар булу өстенә, шуларны җыйнак кылып язуның үрнәге күрсәтелә. Шунда кайтып каралсын. *(Авт. иск.)*

тәртипсез, чуалчык булуы – әдәбият әрбабына[1] мәгълүм бер хакыйкать. Аны Гаяз әфәнде үзе дә инкяр итмәс. Ләкин мондан аның әсәрләрендәге бөтен кыйммәт югалмый». «Гаяз әфәндене без дә тәкъдир итүчеләрдәнбез, ләкин аны тәнкыйть кабул итмәслек бер харика[2], бер могҗиза дип белмибез» («Вакыт» гәзите, 1913 ел. «Җәләй» кушаматы белән). «Татар теленең икенче хамисе[3] Гаяз Исхакыйда телемез янә бик аз эшләнде» (Җ. Вәлидинең «Тукай мәҗмугасы»на язган мөкаддимәсеннән, 1914 ел). «Гаяз әфәндедә гавами вә заһири караш[4] башка татар хикәячеләре вә романчыларындан аерыла торган бер нокта күрми. Хәтта ул аны аларның һәммәсенә караган вакытта да гадирәк таба. Аның әсәрләрендә ләфыз[5] уеннары, сүз ярышлары юк, аның өслүбе купшы һәм назлы түгел. Шулай ук мәүзуг җәһәтендән дә аның әсәрләрендә бер фәүкылгадәлек[6] юк. Анда ис китәрлек гаҗәб фикерләр, эч тотып көләрлек кызык вакыйгалар да булмый» (Җ. В.).

Гаязның тел-өслүбе татар әдәбиятында эмоцияле-дулкынлы чәчмә өслүбләргә беренче мәртәбә күренгән ачык мисал булды. Шуның белән бергә, фикердә, хистә, тел-өслүбтә икътисадсызлыкның да татар әдәбиятында ачык үрнәген ул бирде. Бигрәк тә анда «иде»ләрнең, «торган»нарның, «...ганга»ларның хисабы юк. Аннан башка кирәксез тәкрарлар да аз түгел. «Иде»ләре, «торган»нары, «...ганга»лары һәм урынсыз тәкрарлары белән ул күп вакытта өслүбенең аһәңен дә боза. Боларга Гаяз җөмләләренең бик озынлыгын да кушарга кирәк. Фикер, өслүбтә икътисад исә – сәнгатьчелекнең, әдиплекнең кирәк сыйфатларыннан берсе. Ләкин менә шушы турыда Гаязда, шөбһәсез, аксаганлык күренде.

Гаяз, кирәк фикер-хисләренең агышында, кирәк әсәрләренең мөндәриҗәсен урынлаштыруда, кирәк аларны тасвирда, кирәк тел-өслүбтә булсын, гомумән, бик җәелеп, шалтырап агарга ярата торган бер әдип булды. Ул аккан саен һаман киңәя барды, киңәйгән саен да саекканлыгын сиздертә торды. Ләкин тел-өслүбендәге кытыршылык һәм аксауларын шул турыдагы тәнкыйтьләрнең тәэсире белән соңга таба ул сизелерлек рәвештә төзәтә барды.

[1] Әдәбият әрбабына – әдәбият әһелләренә.
[2] Харика – гадәттән тыш нәрсә.
[3] Хамисе – яклаучысы, тел сагында торучысы.
[4] Гавами вә заһири караш – гомуми һәм тышкы караш.
[5] Ләфыз – сүз, сүзнең мәгънәсе.
[6] Фәүкылгадәлек – гайре табигыйлек.

Гаязның башта ике төрле тел, ике төрле өслүбе булды: 1) матур әдәбияттагы тел-өслүбе, 2) нәсери өслүбе. Матур әдәбияттагы өслүбе бәгъзе урыннарда госманлы тәэсире астына төшсә дә, гомумән, татарча. Әмма нәсери өслүбе исә, шул ук Риза, Фатихлар шикелле, сарфый, нәхви төзелешендә госманлы тәэсире астына төшкән бер тел булды. Фәкать ул соңыннан бу телен дә күп төзәтә алды (Гаязның нәсери өслүбе өчен «Капитан кызы»ның[1] мөкаддимәсеннән, «Тормышмы бу?»ның (1911 елда басылган) 16–17–18 битләреннән, «Очрашу, яки Гөлгыйзар»ның 114 битеннән (1911 елда басылган икенче басмасы) мисаллар укылыр).

Гаязның иҗтимагый-сәяси хәрәкәтендә тотрыксызлык, алга-артка таба авышу-сикергәләү булган шикелле (бу турыда сүз 1905 елдан соңгы бүлемдә килә), әдәби барышында да ул шундый ук хәлне күрсәтә килсә дә, соңыннан әйләнеп яңадан әүвәлге ноктасына кайтып утырды.

Мөхәррирләр, әдипләр: 1) я, башта нинди бер идеяне үзләренә кәгъбә итеп алган булсалар, та ахыр гомерләренәчә[2] шул юлда үсә, айкалмый, чайкалмый, шуның өчен ахыр чиккәчә көрәшә, каләменнән кәгазьгә сузылган бөтен хәрефләр, ноктaлар шуңа суга, шуңа таба өстериләр; 2) яисә икътисади, иҗтимагый тормышның агымы астында, шул тормыш белән бергә хәрәкәт итеп барып, фикри, рухи бер эволюция ясау рәвешендә бер идеядән икенчесенә күчә баралар. Ягъни бер идея, бер фикернең хаталылыгын, кимчелеген, җитешсезлеген тормыш тәҗрибәсе аркылы ачык күрә барып, тагын да аннан җитешлерәк булган икенче идеягә, икенче бер дөресрәк, турырак ноктага таба үсә торалар. Боларда инде кирегә таба сикерү булмый, бәлки һаман алга, һаман яхшыга, яңага таба үсә, күтәрелә бару гына була; 3) һавага, барышка карап, бер – алга, бер артка сикергәләп йөреп, ахырда әүвәлге ноктасына кайтып утыра торган булалар. Каюм Насыйри, Гаспринский, Риза һәм Рәшид казый, Фатих Кәрими кебекләр беренче тип әдипләрдән булсалар, Гаяз да өченче тип әдипләрдән булып чыкты.

Гаязның әдәби агышын өч баскычка кайтарырга мөмкин:

1. «Тәгаллемдә сәгадәт»еннән башлап, «Кәләпүшче кыз», «Ике гыйшык», «Өч хатын белән тормыш»ларны язып, «Инкыйраз»

[1] Гаяз Исхакый А.С. Пушкинның «Капитан кызы» әсәрен тәрҗемә итә. Сүз шул тәрҗемә турында бара.

[2] Та ахыр гомерләренәчә – гомеренең азагынача.

белән тәмамланган Гаяз – Гаязның җәдитчелек, тәрәккыйче милләтчелек идеясе каһарманы, шул кәгъбәнең идеологы булган заманы.

2. «Теләнче кызы», «Солдат», «Зиндан» җыентыклары аркылы күренергә иткән, үзеннән «аз гына социализмга охшаш бер ис аңкый» торган Гаяз.

3. «Тормышмы бу?», «Шәкерт абый», «Мәдрәсә җимешләре»н язган порнографияче Гаяз.

4. «Мөгаллимә»ле, «Зөләйха»лы Гаяз.

Соңгы Гаяз инде бер канаты – «Мөгаллимә», икенче канаты «Зөләйха»дан гыйбарәт булып, әүвәлге төп ноктасына, үз бүкәненә кайтып утырган Гаяз булып чыкты. Бу Гаяз әүвәлге дүрт төрле күләгәдә күренгән Гаязны һәммәсен каплап, шуларның соңгы, төгәл бөтене булды. Бу инде кирегә, төп урынына – «Тәгаллемдә сәгадәт», «Кәләпүшче кыз» һәм «Инкыйраз»лар баскычына кире сикергән Гаяздыр. Шулай итеп, ул, яңадан беренче ноктасына кайтып, Гани байларның «шөһрәт таптырта» торган Гаязы булып калып, ахырда шул ук ноктада карар тапты.

**Закир Һади.** XX йөзгә кергәндә, кадим, җәдитчелек ягы иске һәм яңа уку тартышуы, яурупалашу хәрәкәте көчәйгән, шуның белән татар җәмәгате ике зур лагерьга аерылып, шул турыда көрәш кызуланган иде. Бер якта – туң иске фикерле байлар, мөтәгассыйб муллалар, ишаннар, суфилар, иске мәдрәсә шәкертләре; икенче якта фикер ачылган, яурупалашуга, яңаруга омтылган яңа татар буржуазиясе, татар зыялылары, фикере ачык яңа муллалар, уянган шәкертләр, шулар арасыннан чыккан әдип, шагыйрьләр иде. Ул вакытларда татар матур әдәбияты бик табигый рәвештә үзенә мәүзуг, сюжет итеп әнә шул тартышны, шул юлдагы көрәшләрне, вакыйгаларны алды. Каһарманнар да шул юлда тартышучылар булдылар. Искелектән – кадимнән биздерү өчен, шул заманның татар әдипләре бигрәк иске мәдрәсә тормышын, иске тормышның нинди нәтиҗәләр бирүен шул тормышның үз каһарманнары аркылы ачып бирергә тиеш күрделәр һәм шуңар тырыштылар. Бигрәк тә шул тормышның, кадимчелекнең, схоластиканың төп терәкләре булган кадим хәзрәтләр, ишаннар, туң кара фикерле байлардан көләргә, тәнкыйть итәргә, аларның эшләрен, интригаларын халыкка һәм үзләренә ачып бирергә кирәк иде. Ул вакыттагы әдип-шагыйрьләргә үзләре дә шул тормышны башларыннан кичереп, шуның эчендә җитешкәнлекләреннән, язу өчен җиңел, якын һәм таныш тормыш та шул иде.

Икенче яктан, аларның үзләренең дә күбесе шул көрәшнең үз каһарманнары иде. Әнә шуның өчен ул заман әдипләренең һәммәсе диярлек шул «кадим», «җәдит»челек вакыйгалары, шуларның каһарманнары тирәсендә әйләнделәр. Матур әдәбиятка шуларны күтәреп чыктылар.

Шул тормышны, шул тартышларны язучыларның, әдипләрнең берсе Закир Һади булды. Бу әдипнең «Бәхетле кыз», «Хәер-дога» дигән хикәяләреннән башка безгә тагын да мәгълүмрәк булганнары – «Официант», «Мәгъсум», «Җиһанша хәзрәт» дигән хикәяләредер. Бу хикәяләргә алынган мәүзуг, сюжетның, каһарманнарның кемнәр икәне хикәяләрнең исемнәрендән үк ачык күренеп тора.

«Җиһанша хәзрәт» хикәясе муллалыкка ничек хәзерләнүне, муллалар, ишаннарның интригаларын, муллалык, ишанлык өчен аларның үзара тартышуларын, халык өстендә йөртелгән руханилык властьның шомлы нәтиҗәләрен гәүдәләндереп ачып бирә. «Мәгъсум»да иске мәдрәсә тәрбиясе сәбәпле яшүсмерләрнең ничек адәмчелектән чыгып, ничек харап булулары сурәтләнделә.

Ул вакыттагы әдипләр реаль юл белән тик вакыйгаларның үзләрен генә ялангач хәлдә тасвир итә алмыйлар, әсәрләрен язып бара торгач, ничек тә бер уңаен табып, урынлы-урынсыз, укучыга яңа фикерләр бирергә, үгетчелеккә, агитациягә керешеп китәләр иде. Бу хәл Риза казый, Ф. Кәрими, Гаяз Исхакыйларда булган шикелле, хәтта моннан чын реалист әдип Г. Камал да баш адымнарында тәмам котылып җитә алмый иде.

З. Һадида азмы-күпме шул хәлне күрәмез, шулай да Г. Камал шикелле үк, монда ул як бик аз урын ала. Г. Камал кебек, бу әдип тә күбрәк вакыйгаларны бирергә тырыша.

З. Һадида вакыйгалар яхшы ук җанлы, характерлы һәм күренешле тасвир ителәләр. Теле, әлбәттә, төркчелек сызыгыннан тәмам читкә китә алмый. Җөмлә төзелешендә, сарфый якларында ул шулай. Ләкин, гомумән, садә татарчага якынлыгы, җөмләләрнең кыска, җиңел, садә булучылыгы белән ул үзенә дикъкатьне тарта ала. Бәгъзе урыннарда сиҗгылап, кафияләп[1], сүз уены ясап киткән урыннары да юк түгел (мәсәлән, «Ул юлда ерак җирләргә китәр, башкорт авылларыннан үтәр, Бәләбәй каласына җитәр; бер аермасы Уфа шәһәренә дә илтер» рәвешендә).

Бу әдиптә әдәби куәт, тасвирчылык көчле, ләкин тәмам үсеп, шомарып җитә алмаган бер хәлдә күренә.

[1] Сәҗгылап, кафияләп – рифмалап.

# ИКЕНЧЕ БАСКЫЧ 1905–1917

## 1. Иҗтимагый-сәяси хәрәкәтләр һәм җәмәгатьчелек әдәбияты

**1905 елга нинди хәзерлек белән килеп кердек**. 1905 елга кергәндә, татар арасында сыйнфый аерылу һәм сыйнфый каршылыкларны аңлый башлау кебек хәлләр күзгә ташланырлык булган; татар буржуазиясе рус буржуазиясе сызыгында, сыйнфый мәнфәгать берлекне аңлап, үзен оештыра башлау хәрәкәтен кузгаткан иде. Шуның өстенә татар буржуазиясе иҗтимагый-сәяси яктан үзенең сыйныфташы булган рус буржуазиясе белән тигез хокукта булырга омтыла башлаган, дәүләт идарәсе эшләренә алар шикелле үк катнашасы килгән һәм азмы-күпме шуның хәзерлеген күрү юлына кергән иде. Шуның өчен татар буржуазиясендә аның хосусый рәвештә үз хокукына кысынкылык күрсәтүе белән самодержавиегә, царизмга каршы дошманлык тойгысы аерым рәвештә сакланып килде.

Сәяси-иҗтимагый ирек сорау һәм рус патшалыгын егыту[1] – самодержавиене җимерү юлында астыртын бер теләк үсә барды. Патшалыкны егытуда, машруталы[2] идарә төзүдә татар буржуазиясе үзенең азатлыгы һәм рус буржуазиясе белән бергәрәк үсә алуга юл ачылуны көтте. Шуның өчен гомумән Русиядә эшче-крестьян, пролетариат арасында самодержавиегә каршы шартлау дәрәҗәсенә якынлаган революция хәрәкәтләренә татар буржуа җәмәгате, төбендә рус либераль буржуазиясе, кадетлар сызыгында торып, яхшы карады. Ул хәрәкәткә кушылырга, аны көчәйтешергә хәзерләнә торды. Монда, әлбәттә, революцияне соңыннан, рус буржуазиясе белән бергә, үз мәнфәгатьләренә борып җибәрү өмете бар иде.

Менә бу як – 1905 елга кергәндә татар буржуазиясенең сәяси хәзерлек ягы. Аның иҗтимагый-әдәби хәзерлек ягына килгәндә, эш түбәндәгечә булды. Татар буржуазиясе инде татарның җәмәгать эшләрен үз кулына ала башлаган, ысулы җәдит мәктәпләрен, җәдитчелек хәрәкәтләрен үз идеологиясе, үз мәнфәгате нигезендә үз каравы астына керткән; кыскасы, шул турыларда татар массасына юлбашчылыкны үзенә каратып өлгергән иде. Рәшид казый, Риза ка-

[1] Егыту – егу.
[2] Машруталы – парламент белән чикләнгән.

зый, Фатих Кәрими, Гаяз Исхакый, Йосыф Акчура кебек гыйльми-иҗтимагый таянычлары, идеологлары, әдипләре бар; Шакирҗан Таһири кебек учительләр тәрбиядә юл күрсәтешәләр, аларга да Һади Максуди, Әхмәтҗан Мостафа, Хәсәнгата, Хәйрулла Госмани, Буби хәзрәтләре һәм Уральскида Мотыйгыйлар кебек ярдәмчеләр кушылганнар. Әхмәд байлар, Закир һәм Шакир Рәмиевләр[1], Яушевлар[2], Йосыф Дибердиевләр[3], Сембернең Акчуриннар[4] кебек бу хәрәкәтләрдә тәэсирле байлар, Сәедгәрәй Алкин[5], Әбүсогуд Әхтәмов[6], Котлуг Мөхәммәд мирза Тәфкилев кебек «мөтәррәкый» адвокатлар мәйданда. Казанның «Мөхәммәдия»се, Оренбургның «Госмания»се кебек мәдрәсәләрдә уяну хәрәкәтләре, либераль һәм вак буржуа элементлары чыга башлау галәмәтләре күренә. Гомумән, җәдитчелек көчәйгәннән-көчәя бара.

«Миръат»лар аркылы җәмәгатьчелек матбугаты туа башлаган, Ризаның «Асар»лары аркылы милли тарих бинасы корылу эшенә керешелгән, милли хисләрне кайнату казаны ягылган. Муса Акъегет, Ильясов, Фатих Халиди, «Чистай комедияләре»ннән соң Галиәсгар Камал, Фатих Кәрими, Гаяз Исхакыйлар татар матур әдәбиятының хикәя, драма өлешләрен үстерә баралар; шулар өстенә тагын, Акмулла шәкерте булып, тезмәдә үзенең «Себер тимер юлы» белән Мәҗит Гафури дигән бер шагыйрь дә Троицк ягыннан килеп чыккан иде.

1905 елга татар буржуазиясенең сәяси, иҗтимагый-әдәби хәзерлеге, бик җыйнак кылып, бик кыска итеп әйткәндә, әнә шул хәлдә иде.

XIX йөзнең соңгы уннарыннан ук инде рус пролетариаты хәрәкәтенә кушылып, алар белән бергә эшләшеп килгән татар

[1] Сүз Оренбург төбәге сәүдәгәрләре һәм алтын приискалары хуҗалары, җәмәгать эшлеклеләре, 1 нче гильдияле сәүдәгәрләр Мөхәммәдшакир Мөхәммәдсадыйк улы Рәмиев һәм Мөхәммәдзакир Мөхәммәдсадыйк улы Рәмиев (шагыйрь Дәрдмәнд) турында бара.

[2] Сүз Троицк сәүдәгәрләре һәм эшмәкәрләре, җәмәгать эшлеклеләре Яушевлар нәселе турында бара.

[3] Мөхәммәдйосыф Мөхәммәдсадыйк улы Дибердиев (? – 1926) – шагыйрь, публицист, фабрикант. Агалары белән берлектә Сембер губернасында фабрикалар тота. Мәчетләр төзетә, җәдиди мәдрәсәләргә ярдәм итә.

[4] Сүз Сембер губернасы сәүдәгәр-эшмәкәрләре, Сембер губернасында постау җитештерүне оештыручылар, җәмәгать эшлеклеләре булган Акчуриннар нәселе турында бара.

[5] Сәетгәрәй Шаһиәхмәт улы Алкин (1867–1919) – хокук белгече, җәмәгать эшлеклесе, «Иттифак әл-мөслимин» партиясен оештыручы һәм җитәкчеләренең берсе.

[6] Әбүсогуд Габделхаликъ улы Әхтәмов (1843–1918) – хокук белгече, эре җирбиләүче, «Иттифак әл-мөслимин» партиясен оештыручыларның берсе.

пролетариаты да[1] 1905 ел алдыннан үзенең бер сыйныф хәлендә аңлы булып үсеп килгәнен азмы-күпме сиздертә башлаган иде. Татарда большевиклык элементлары да бар иде инде. «Самодержавиегә каршы хәрәкәттә боларның шул ук рус пролетариаты белән бергә тагын да көчле, тагын да нык позиция тотачак»ларында шик юк иде.

Ләкин шулай булуга карамастан, 1905 ел революциясендә өстенлек, һәрхәлдә, татар буржуазиясе ягында калачак иде. Чөнки, бердән, татар буржуазиясенең хәзерлеге татар пролетариатының хәзерлегеннән күп өстен, ләкин татар пролетариатының хәзерлеге, оешуы, аңы күтәрелү әле зәгыйфь иде. Икенчедән, «самодержавие татарны дин, милләт исеменнән 300 ел буенча бик каты җәберләп килде. Ленин буенча без беләбез: бер халыкның дини, милли яктан җәберләнүе аның арасында сыйнфый каршылыкларны томалый, бу милләтнең югары сыйныфларына бөтен халык өчен тырышучы битлеге астында яшеренеп, массаны алдарга ярдәм бирә» иде («Татарлар арасында революция хәрәкәтләре», 172 бит).

1905 ел алдыннан «бездә менә бу момент бик зур роль уйнарга» хәзерләнә иде. Татар буржуазиясе бу революциядә, әлбәттә, шул яктан үз мәнфәгате юлында татар пролетариатыннан элегрәк файдаланачак, татар массасын, дин, милләт исеменнән самодержавиегә каршы көрәштә һәрхәлдә күзен томалап, үз сызыгына борачак иде.

1905 елга без менә шушы хәлдә килеп кердек.

**1905 ел буржуазиясеннән соң татарда иҗтимагый-сәяси хәрәкәтләр һәм идеология.** 1905 ел революциясе татар дөньясына, бердән, бик көчле бер гомуми тәэсир ясады. Аның һәр катлавын бик нык кузгатып җибәрде. Татарның асыл сәяси, иҗтимагый, әдәби хәрәкәте зур, көчле кабарынган бер хәрәкәт рәвешендә шушы революциядән башланды дисәк, дөрес булыр. Татар буржуазия идеологиясенә дә аерым билгеле бер идеология рәвешендә утырып, ныгып алырга шушы революция киң зәмин бирде.

«Русиянең бу революциясе – бөтен халык революциясе» (Ленин сүзе) булганы шушы революция белән дулкынланып котырган татар дөньясы аркылы тагын да ачык күренде. Монда «үзенең сыйнфый тарихи хәле буенча самодержавие сарайларына багланган азсанлы татар феодал фамилияләр һәм көнитешләре буенча Русиядә татар арасында иске тәртипнең, кадим фикернең сафлануын теләгән бер

[1] Бу турыда Галимҗан Ибраһимовның «Татарлар арасында революция хәрәкәтләре» дигән әсәрнең икенче бабына 30–78 һәм 11(?)–141 битләренә каралсын. *(Авт. иск.)*

төркем ишаннар белән аларга мөрид кара сәүдәгәрләрдән башка һәркем, һәммә сыйныфлар самодержавиегә каршы, үзе белгәнчә, сыйнфый дәрәҗәсе кушканча, хәзерлегенчә көрәшкә чыкты»[1]. Мондый революциягә алдан һич хәзерлеге булмаган татар халкы, шушы революция ялкыны белән бердән кабынып китеп, нык көрәште, күп шаулады, дулады, революция дулкынында төрлечә айкалды, төрле якка бәргәләнде, суккаланды да, ахырда шуның нәтиҗәсендә татарда физиономияләре бик ачык булган берничә иҗтимагый төркемнәр килеп чыгып, шулар арасында көрәш башланды. Сыйнфый каршылыклар, ачык бер төс, билгеле бер сызык алып, иҗтимагый-сәяси агым хәленә әйләнде.

1905 елгы революция нәтиҗәсендә иң элек татарда бер-берсенә капма-каршы ике зур сыйнфый хәрәкәт күрдек:

1) татар буржуазиясенең хәрәкәте;

2) татар пролетариатының хәрәкәте.

«Табигый, әле үзенең азлыгы, көчсезлеге белән татар пролетариаты хәрәкәте ул вакытта көч алып китә алмады. Шуның өчен өстенлек буржуа хәрәкәте ягында калды»[2]. Чөнки татар буржуазиясенең, сәяси булмаганда да, һич булмаса иҗтимагый-әдәби хәрәкәте ягыннан бу революциягәчә ярым гасырлык бер хәзерлеге бар иде. Әнә шушы хәзерлек татар буржуазиясенә 1905 елгы революция заманнарында һәм аннан соңгы көннәрдә төп хәрәкәт сызыкларын билгеләүгә, шулай ук бу революциядән, үзенең сыйнфый мәнфәгате ягыннан яхшы файдаланып, татарның иҗтимагый-мәдәни хәрәкәтен алда үз идеологиясе нигезендә үстереп алып китүнең дә уңышлы чараларын күрергә күп ярдәм итте. Ә татар пролетариаты бу яктан татар буржуазиясенә каршы өзлексез нык көрәш алып баруга чыдарлык бер хәлдә түгел иде. Икенче яктан, реакция дә, рус пролетариаты хәрәкәтен шәфкатьсез кысканы шикелле, татар пролетариат хәрәкәтен дә кузгала алмаслык итеп бастырып куйды.

**Татарның буржуазия хәрәкәте.** Тышкы яктан төрле булып күренгән бу хәрәкәт төбендә үзенең бөтен төрләре, эреле-ваклы бөтен төркемнәре белән бер үк кыйблага караган, бер төрле максатка бәйләнгән киң бер хәрәкәт иде. Аның вак төркемнәренең төрлечә кузгалыш һәм тайпылулары булса, алар тик бер үк юлдан өелеп барган

[1] «Татарлар арасында революция хәрәкәтләре». Галимҗан Ибраһимов. *(Авт. иск.)*

[2] «Безнең юл», 3 нче сан, 1926 ел. Г. Сәгъди мәкаләсе – Фатих Әмирхан турында язылган мәкалә. *(Авт. иск.)*

чакта төрле якка уйнаклап, кабыргага бәреп чыгу яисә төрле яктан чабып сикергәләп карау кебек хәлләрдән генә гыйбарәт булдылар.

Бу хәрәкәт, бер тамырдан ярып чыгу рәвешендә, иң элек икегә аерылды:

1) Урта яисә тәрәккыйчы либераль татар буржуазиясенең хәрәкәте. Бу хәрәкәт адәмнәрен руслардагы «Кадетлар партиясенең татар бүлеге» дип атасак, дөрес булыр (боларны «Урал»чыларда шулай дип атый).

Болар «иттифак»чылар – «Русия мөселманлары иттифакы» кешеләре. Татарның алпавытлары, мирзалары, фабрикантлары, эре сәүдәгәрләре, тәрәккыйчы җәдитләнгән зур руханилары, ачык фикерле хәрәкәтләре, җәмәгатьче мөхәррирләре шушы төркем адәмнәреннән булып, алар тәмам бердәмлек белән шул хәрәкәтне кызу алып бардылар.

Җәмәгатьче мөхәррирләрдән хәрәкәт башында торучылар, шул сыйныф, шул хәрәкәтнең юлбашчы идеологлары Гаспринский, Рәшид казый, Йосыф Акчурин, Муса Биги, Фатих Кәрими, адвокатлардан Тупчибашев[1], Тәфкилев, Сыртланов[2], Алкиннар[3] булдылар. Муллалардан – Галимҗан Баруди, Апанаевлар[4]. Ләкин бу партиянең шалтыравыклы кыңгыравы рәвешендә казый[5] булса, иң төпле гыйльми терәге дә Акчурин иде. Аның тарихчысы да Муса Биги булды. «Мөселманнар иттифакы» дигән берләшү хәрәкәте барысы өч мәртәбә җыелыш ясап, зур шау-шу күтәрделәр. Беренче җыелышлары 1905 ел августның 15 ендә Ука[6] суында пароходта оештырылды. Революция дулкыннарының көчәю тәэсире белән татар буржуазиясе Ука елгасындагы пароходлардан берсен сатып алды да шунда җыелыш ясады. Җыелышны да «беренче съезд» дип атадылар. Шунда 5–6 маддәдән гыйбарәт бер программ кабул ителде.

---

[1] Галимәрдан бәк Галиәкбәр улы Тупчибашев (1863–1934) – азәрбайҗан дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе, юрист һәм журналист.

[2] Сыртланов Шаһхәйдәр Шаһигардан улы (1847 – ?) – дворян нәселеннән, Уфа губернасыннан беренче (1906) һәм икенче (1907) чакырылыш Дәүләт думасы әгъзасы.

[3] Сүз Сәетгәрәй Шаһиәхмәт улы Алкин турында бара.

[4] Габдулла Габделкәрим улы Апанаев (1862–1919) – күренекле сәүдәгәр Апанаевлар нәселеннән дин һәм җәмәгать эшлеклесе, нашир. Татар милли азатлык хәрәкәтендә әйдәп йөрүчеләрдән. «Иттифак әл-мөслимин» партиясен оештыруда, аның программасын төзүдә катнаша; партиянең Үзәк Комитеты һәм Казан бюросы әгъзасы. «Азат» газетасының нашире һәм мөхәррире (1906).

[5] Сүз Рәшит казый – Рәшит Ибраһимов турында бара.

[6] Укада – Ока елгасында.

Бу җыелыш турында шул ук «Иттифак»ның тарихчысы Муса Биги болай дип язды: «Хакыйкта Макарья җәмгыяте иң беренче иң бөек бер гомуми җәмгыять иде. Бурада[1] Русия дәүләтенең һәр тарафыннан кәлмеш әһле ислам вар иде. Төркестанның һәр җәһәтеннән, Сибириянең иң озак урыннарыннан, дәхли[2] вилаятьләренең һәр шәһәрендән, Кырым, Кавказдан бер-ике дәгел, бәк күп адәмләр кәлмеш иде. Бакуның иң мәшһүр әгънияләрендән[3], иң могтәбәр әһле гыйлемләрендән бәк чук зәват хазир иде[4]».

«Шу җәмгыять кәбирең[5] хәбәре һәр телдә сөйләнде: күп җәридәләрдә[6] язылды: карар намәсе, резолюциясе һәр тарафә таралды. Шу җәмгыятьең шөгъбәләре[7] һәр тарафда тәэсис идәлмәмеш[8] исә дә, Русия мөселманларының хәрәкәт фикрия вә сәясияләренә 18 август җәмгыяте пакь, бөек котлар бирде. Һәммә Русия мөселманларыны иттифакка берлекгә сәвекъ итде[9]».

«Шу җәһәтләрдән 15 августны Русия мөселманларының хәрәкәтләренә, берлекләренә, җәмгыятьләренә рәэс[10] тарих итмәк бәк мөнасиб[11] бәлки ляземдер» («Өлфәт» гәзите, 1906 ел, 8 нче сан).

Соңыннан бу «Иттифак»ның 1906 елның гыйнвар аенда Петербургта икенче җыелышы ясала. Ләкин бу җыелыш та тегесе шикелле үк «гайре рәсми» бер җыелыш була[12].

Монда инде программ 74 маддәлек бер хәлгә килә. «Иттифак»ның өченче җыелышы 1906 елның 16 августында, Рәшид казыйларның башлап, рөхсәт алып йөрүләре белән, Петербургта ясала[13].

«Иттифак әл-мөслимин» партиясе хәтта башта бөтен дөнья мөселманларын берләштерү хыялына да төшкән, шуны төп кәгъбә ясаган иде.

---

[1] Бурада – монда.

[2] Дәхли – эчке.

[3] Әгънияләрендән – байларыннан, мәртәбәле кешеләреннән.

[4] Бәк чук зәват хазир иде – бик күп кеше катнашты.

[5] Шу җәмгыять кәбирең – бу мөһим җәмгыятьнең.

[6] Җәридәләрдә – газеталарда.

[7] Шөгъбәләре – бүлекләре.

[8] Тәэсис идәлмәмеш – төзелгән.

[9] Сәвекъ итде – этәрде.

[10] Рәэс – баш.

[11] Мөнасиб – яраклы.

[12] Бу турыда шул ук Муса Бигинең мәкаләсенә каралсын, «Өлфәт» гәзите, 5 нче сан, 1906 ел. *(Авт. иск.)*

[13] Бу өченче җыелыштан элек, аның турында «Өлфәт»тә Муса Биги тарафыннан язылган фикерләр белән танышу өчен, шул гәзитнең 1906 ел 33 нче санына каралсын. *(Авт. иск.)*

Алар түбәндәгечә уйлыйлар иде: «Шәригать горрәэ Мөхәммәдиягә сарыларак, әл әлә вireп[1], бер гаилә улады кеби эш күрәлем мөэмин кардәшләремез әгълаэ Кәлам Аллаһ өчен бер ләүхәйә җәмгъ идәлем вә Русия мөселманлары "Иттифак"ны рәсми сурәтдә мәйданә вәзыг идүб[2] иттихад[3] иттифак кәлмәләрине балаларымыз зәбанында[4] вәрд идереп[5], шул даирәгә мөселманлары җәмгъ итмәк өчен сәгый[6] вә гайрәт идәлем. Безә бундан соңра бер мөкатдәс вазифа бар исә, у да мөселманларны шул иттифак казыгына багламакдыр. Татар, нугай, сарт, казакъ, кавказлы, кырымлы – һәммәсене шу мәркәзә җәмгъ итмәкдер. Русия хөкүмәте тәхет идарәсендә әүвәлән мөселманлар өчен бер раһ хак[7] вар исә, у да бу "Иттифак" җәмәгасене тәкъвия итеп[8], мал вә җан илә бунның рәсми сурәтдә мәйданә вәзыг улынмасына гайрәт итмәкдер. Бу көндән игътибарән[9] һәр мөселман бу бабда гафләт итмиюб, бунның комитетына галәкадәр[10] булыб, мәгыйшәт сәясиядә бу мәркәзе үзләренә рәһбәр иттихад итсүнләр[11] кәрәк».

«Мөселманлар иттифакы партиясе ялгыз дини бер партия түгелдер. Бәлки һәм дини-сәяси, һәм икътисади партиядер. Без мөселманлар Русия хөкүмәт тәхте идарәсендә булындыкча, бу "Иттифакы" үземезә рәһбәр иденмәк важибдер».

«Әгәр Русия мөселманлары шул мәркәзә тәҗәммегъ итеп[12], иң вөҗүд, иң дил уларак заманайә муафыйк мәктәп вә мәдрәсәләр ислахына һиммәт вә гайрәт идерләрсә, аз бер заман эчендә булындыклары мәүкыйларында[13] хиссиятләрене мөхафәза идәчәкләре мокыйрердер[14], хәтта шимди тәэсис улынмыш Русия мөселманлары иттифакы берзаман көррәи арызда мәүҗүд[15] өч йөз миллион мөселманлары иттифакы өчен бөйлә бер мәүкыйгы шимдидән дәхи күрә

[1] Сарыларак, әл әлә вireп – сарылып, кулга-кул тотышып.
[2] Мәйданә вәзыг идүб – мәйданга куеп.
[3] Иттихад – фикер берлеге.
[4] Зәбанында – телендә.
[5] Вәрд идереп – кабатлатып.
[6] Сәгый – тырышлык.
[7] Раһ хак – дөрес, туры юл.
[8] Тәкъвия итеп – яклап, ныгытып.
[9] Игътибарән – башлап.
[10] Галәкадәр – бәйләнешле.
[11] Рәһбәр иттихад итсүнләр – юлбашчы сайласыннар.
[12] Тәҗәммегъ итеп – җыелып.
[13] Мәүкыйларында – эшләрендә.
[14] Мөхафәза идәчәкләре мокыйрердер – саклаячаклары танылыр.
[15] Көррәи арызда мәүҗүд – җирдә яшәгән.

алмак мөнасибдыр[1]» («Өлфәт» гәзите, 1906 ел, «Тәрәккый вә татарлар» дигән мәкаләдән, 48 нче сан).

Бу өченче җыелыш һәм анда катышучылар турында «Иттифак»ның юлбашчысы Акчура түбәндәге фикерләрне язып үтте: «Җыелган кешеләрнең һәммәсе сәясәтдән бер уйда гына түгел, эчләрендә бер-берсенә тәмәман гаксе[2] сәяси вә икътисади фикер ияләре бар, ләкин җөмләсене баглый торган куәтле ике рабита[3] мәүҗүд[4] ки, нәсел һәм диндә бер булучылыкларыдыр; җыенда хазир булганларның барчасы – төрк мөселманларыдыр. Әгъзаның һәммәсе мөрәххәс[5] тә, вәкил дә түгел иделәр. Ләкин җөмләсе нөмаяндә (представитель[6]), бер җирнең яхуд бер сыйныфның әфкяр-мәталибене[7] күрсәтә ала торган нөмаяндәләре иде. Хөласа[8], бу җыенлар нә митинг, нә съезд, бәлки Русиядәге мөселманларның дини, милли, сәяси вә иҗтимагый ихтыяҗларыны бергәләшеп кайгырта торган бер нәүгъ[9] милли мәшүрәт[10] мәҗлесләре – “шураи өммәт”ләре, фирканың тәгъбирене мәгънәи лөгависендә истигмаль итәрсәк[11] милли парламентлары иде».

«Өченче җыенда хазир булган халыкны сәяси вә иҗтимагый канәгатьләре ягыннан дүрткә бүләргә мөмкиндер: бу тәкъсим[12] сабикъ[13] думадагы тәкъсиматка охшыйдыр. Мәркәздә зур бер әксәрият[14] “иттифакчылар”ның сулында микъдарча аз, ләкин кәнеҗ[15], фәгъгаль (эшлекле) вә хыялый мәгълүматы сәясияле, күп тавышчан яшьләр – бонларга “суллар” һәм “таңчылар” дип дә йөртелде. Уңда микъдарларыны тәгаен бик читен, хәятларыны күрсәтә алмаганлыкдан куәтсезлекләре мәгълүм “мөхафәзакярләр”, ниһаять, тәрбия вә

[1] Мөнасибдыр – яраклы.
[2] Гаксе – каршы.
[3] Рабита – бәйләнеш.
[4] Мәүҗүд – бар.
[5] Мөрәххәс – илче.
[6] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[7] Әфкяр-мәталибене – фикер-теләкләрен.
[8] Хөласа – нәтиҗә ясап әйткәндә.
[9] Бер нәүгъ – бер төрле.
[10] Мәшүрәт – киңәш.
[11] Фирканың тәгъбирене мәгънәи лөгависендә истигмаль итәрсәк – «фирка» сүзен үз мәгънәсендә кулланачак.
[12] Тәкъсим – бүленеш.
[13] Сабикъ – булып үткән, элекке.
[14] Әксәрият – күпчелек.
[15] Кәнеҗ – яшь.

мәгълүмат вә хәтта хиссияте вә иҗтимагыясе бөтенләй мәфкуд[1] булган өчен һичберсенә катыша алмый йөргән кешеләр» («Казан мөхбире», 1906 ел, 155 нче сан. «Йосыф Акчура» мәкаләсеннән)[2].

Бу «Иттифак» партиясе үзен русча «Мусульманская конституционно-народная партия»[3] дип атаган иде. Бу өченче җыелышта «Иттифак»ның үзәк идарәсе дә төзелеп, аңа түбәндәге кешеләр сайландылар: Рәшид казый, Йосыф Акчурин[4], Сәидгәрәй Алкин, Исмәгыйль Гаспринский, Галимәрдан Тупчибашев, Габдулла хәзрәт Апанаев, Галимҗан хәзрәт Баруди, Садретдин Максуди, Шаһхәйдәр Сыртланов, Муса Биги, Габдулла Буби, Һади Максуди, Мостафа Давыдович (Бакчасарайның шәһәр башлыгы), Шаһмәрдан Кошчыгулов (казакълардан дума әгъзасы), Сәлимгәрәй Җантурин (земство һәм дума әгъзасы).

Бу әгъзалар үзләре үк бу партиянең нинди партия икәнен күрсәтеп торалар. Гаяз Исхакыйлар, Фуад Туктаровлар[5], Һади Атласовлар да шушы җыелышка аның сулрак канаты булып нык катнашучылардан иделәр[6].

**Вак татар буржуа хәрәкәте.** Бу хәрәкәт адәмнәре үзләре дүрт төркемгә бүленделәр:

а) реформачы-ислахчы, гыйсъянчы шәкертләр;

ә) приказчиклар;

б) «таңчы» эсерлар;

в) «думачы» трудовиклар.

---

[1] Мәфкуд – югалган.

[2] «Иттифак» турында «Йолдыз» фикере һәм аның иттифакчылыгы белән танышу өчен, «Йолдыз»ның 1906 ел 8 нче санына «Иттифак» дигән мәкаләгә карарга мөмкин. *(Авт. иск.)*

[3] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[4] «Әхбар»ның 1906 ел 80 нче санында язган мәкаләсендә Йосыф Акчура «Дума белән рабита» дигән мәкаләсендә, сүз ахыры итеп: «Әгәр Русиядәге мөселманлар да үз уй һәм теләкләрене даимә мәбгусләренә (*депутатларына*) белдереп торырга теләсәләр, «Русия мөселманлары иттифакы»ны мөкәммәл, мөнтазам, мөрәттәб (*камил, тәртипкә салынган*) бер җәмгыять, бер партия хәленә китерүләре әлзәмдер (*кирәк*)», – ди. *(Авт. иск.)*

[5] Фуад (Мәхмүтфуад) Фәсах улы Туктаров (1880–1938) – җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, журналист. Укытучылар мәктәбендә укыган вакытта иҗтимагый-сәяси эшчәнлек белән мавыга, «Шәкертлек», «Хөррият» студентлар төркеме әгъзасы була; Г. Исхакый, Г. Терегулов, Ш. Мөхәммәдьяров, Х. Ямашев белән таныша.

[6] «Иттифак» партиясе, асылда, кадет партиясенең татар бүлеге булып, татар эшче-крестьянының моңа бертөрле дә катнашы булмавы турында тәфсилле мәгълүмат, дөрес бер характеристика алу өчен, Галимҗан Ибраһимовның «Татарлар арасында революция хәрәкәте» дигән китабына каралсын. *(Авт. иск.)*

Беренче төркем – мәдәни хәрәкәтчеләр, мәдрәсәләргә ислах, фән сораучылар булып, моның башында Фатих Әмирхан, Вафа Бәхтияров[1] һәм Борһан Шәрәфләр[2] тордылар.

Ислахчы шәкертләр, ягъни иске дини мәдрәсәләрдә укучылар эченнән чыккан реформачылар кузгалышы татар иҗтимагыймәдәни хәрәкәтендә иң әһәмиятле бер вакыйга иде. Вакытында болар татар дөньясын иң нык шаулаттылар. Иске мәдрәсәләргә, аның тәрбиясенә, укыту ысулларына, андагы тәрбияләргә, анда укытучы хәзрәтләргә, мөдәррисләргә каршы көчле бер гыйсъян күтәрделәр, бунт чыгардылар.

Шәкерт арасындагы бу хәрәкәт һәм гыйсъяннарның кайчаннан башлап, ничек хәзерләнә килүләре турында үзе шул гыйсъяннар дулкыны эчендә булган Фатих Сәйфи[3] татар матбугатына ун ел тулу уңае белән 1916 елгы «Тормыш»ның 390 нчы санында тарихи әһәмиятле бер мәкалә язган иде. Татардагы бу мөһим хәрәкәтнең тарихи ягы тагын да яхшы, тулы ачылсын өчен, шул мәкаләдән бәгъзе фикерләрне түбәндә күчереп үтәбез.

«Әгәр дә шул замандагыларның фикерләрен бергә җыебрак әйтсәк: бөтен татар хәятының кызганыч хәлдә калуы, аның киләчәгенең өметсезлеге фәкать мәдрәсәләрдә тәфсир, хәдиснең укылмавы, хисап, җәгърафиядән хәбәрсезлектән дип уйлыйлар иде».

«Менә шәкертләр үзләренең наданлыкларының ачуын мәдрәсәләрдән алырга тотындылар. Аларга төрле пәрвайсызлыклар[4] күрсәтеп, алардан төрле урында көлешеп йөри башладылар. Хәзер шәкерт Учительский школа шәкертләре белән катнаша, шәкерт өчәүләп базарга да чыга. Шәкерт күбәүләп “Сарай” номерларына бара. Кәләпүшсез, колакларны каплаган озын чәчен кирегә сыпыра-сыпыра, “фикер” сатып чәй эчә. Шәкерт, бергә җыелышып, “Тәрҗеман” гәзитенә мөштәри[5] булып языла. Инде шәкерт ысулы җәдидә белән ысулы кадимә бәхәсләрен вак нәрсә исәпли».

[1] Вафа (Әхмәтвафа) Гали улы Бәхтияров (1881–1960) – журналист, җәмәгать эшлеклесе һәм педагог. Татар яшьләре тарафыннан чыгарылган «әл-Ислах» (1907–1909) газетасының рәсми мөхәррире.

[2] Борһан Шәрәф (1883–1942) – җәмәгать эшлеклесе, язучы, нашир, педагог.

[3] Фатих Сәйфи-Казанлы (Мөхәммәтфатих Камалетдин улы Сәйфуллин, 1888–1937) – язучы, җәмәгать эшлеклесе.

[4] Пәрвайсызлыклар – игътибарсызлыклар.

[5] Мөштәри – абунәче.

«1902–[190]3 елларда рус хәятының һәр эшендә, гомумән, бертөрле наразыйлык[1] сизеләдер. Сизелә генә түгел, күп урыннарда беленәдер иде. Һәркем бертөрле яңа тормышны хыял итә, шуңар матдимы, мәгънәвиме ярдәм итәргә тырыша, тарих көпчәге яңа хәяткә якынайган кебек сизеләдер иде. Шул тормышка зәмин хәзерләүче, шөбһәсез, шул еллар эчендә кирәк эшче, кирәк укучы сыйныф арасында “идән асты әдәбияты”ның чамадан тыш таралуы аның халыкны бер якты ноктага илтә торган булып күренәдер. Ул заманда кем белми земство хадимнәренең “Освобождение[2]” исемендәге журналларын, с.д.ларның[3] “Образование[4]”, с.р.ларның[5] “Революционная Россия[6]” кебек нөсхәләрен? Һәм әллә никадәр кыска-кыска язылган да рөхсәтсез басылган китаплар да күп иде. Менә шул типтагы “идән асты әдәбияты” күпләп-күпләп Казанның Учительский школасына агыла иде».

«Андагы шәкертләр дә бирелеп укырга тотындылар, хәтта әз заман эчендә шул әдәбият идеясе белән исерергә өлгерделәр. Школаның күбрәк шәкертләре мәдрәсәдән чыккан шәкертләр булганга, мондый ихтилял[7] фикерләре боларның электә дә яраланган йөрәкләренә көткәннән артык әсәр итәдер иде. Тиз арада шундый «идән асты әдәбияты» тирәсенә школаның бөтен истигъдадлы[8] һәм булдыклы шәкертләре җыелдылар. Шулай итеп, татар милләтенең маенда пешеп, кинәт сәяси ихтилялчылар груһсы ясап эшкә дә керештеләр...»

«Боларда әсасән сәяси фиркаләрнең бер-берсеннән аермаларын, аларның кайсы ноктада аерылышып киткәнләрен һәм үзләренең теләкләрен җитди сурәттә билгеләү юк иде. Бары туктамыйча хөкүмәтне, шулар белән бергә руханиларны, байларны алып-алып селкеп салганчы тәнкыйть итеп, шәрран яра кычкыру гына иде».

«Әлбәттә, бу ихтилял фикере школа дивары[9] эчендә генә калмады, ул тиз генә мәдрәсә шәкертләре арасында таралды. Моңа кадәр мөдәррис сүгеп, бөтен мәхлукатның төзәлүен хәдис белән тәфсир укуга терәлеп тора дип уйлый торган шәкертләрнең фикерләре, эле-

[1] Наразыйлык – ризасызлык.
[2] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[3] Социал-демократларның.
[4] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[5] Социал-революционерларның (эсерларның).
[6] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[7] Ихтилял – фетнә.
[8] Истигъдадлы – сәләтле.
[9] Учительский школаны әйтә. *(Авт. иск.)*

ге мәгыйши-сәяси мәсьәләләрнең күтәрелүе, азрак аңлый башлаулары белән, тагын чуалырга тотынды. Руслар тарафыннан школага рус телендә килгән “идән асты әдәбияты”, тиз арада татар теленә тәрҗемә ителеп, шәкертләр арасына тарала иде».

«Шулай аз гомер эчендә озын чәчле, тула бишмәтле школа шәкерте белән озын җиләнле, ябык йөзле шәкерт бер-берсенә кушылдылар, фикерләштеләр. Еш-еш “Сарай” номерларында җыела башладылар. Теге көтелгән бөек үзгәреш көннән-көн якынайган кебек сизеләдер иде. Сәяси һава куерганнан-куерадыр иде. 1904 елларның ахырында школа һәм мәдрәсә шәкертләреннән кушылган бу һәйәт[1] “идән асты әдәбияты”, “Хөррият” исемле бер журнал сыман нәрсә нәшер итәргә тотынды».

Фатих Әмирхан һәм аның иптәшләренең тәшәббесе[2] белән, 1904–[190]5 елларда татар шәкертләренең үзләренә аерым бер организация булып оешулары башланды. «әл-Ислах» комитеты төзелде. Бу комитет та «татар социал-демократлар тәэсирендәрәк барырга» тырышты[3].

Бу урында ислахчы яисә «әл-Ислах»чы шәкертләрнең хәрәкәтендә күрелгән берничә моментларга тукталып үтик. Бу хәрәкәттә түбәндәге моментларны күрәбез:

1. 1905 ел революциясе башланган заманнарда болар (ислахчы шәкертләр), Рәшид казыйлар эзенә басып, аның «Өлфәт» гәзите белән ми вә акылларын ризыкландырып килүчеләр иде. Бу хәлдә татар шәкертенең фикере үсүендә беренче баскыч булып алды. Бу баскыч та мөселманчылык куәте белән христианлыкка һәм христианлык сакчысы булган самодержавиегә, кадимчелеккә, схоластикага каршы тору баскычы иде.

2. Сыйнфый, сәяси вә иҗтимагый мәгънәсе белән революция хәрәкәтләренә кушылып алу баскычы, ягъни «Уян, шәкерт!» дип йырлаудан «Марсельеза»ны йырлый башлау моментына күчү баскычы. Революция хәрәкәтләренә кушылып, «социалист» булырга тырышу; буржуага, капитализмга дошманлык авазларын чыгара башлау – вак буржуа социализмына омтылу – шушы икенче баскычның хосусиятләреннән иде.

[1] Һәйәт – төркем.

[2] Тәшәббесе – тырышлыгы, инициативасы.

[3] Бу комитетка каршы Фуад, Гаязлар тарафыннан «таң»чы эсерлар оешмасы төзелә. («Татарлар арасында революция хәрәкәтләре», 183 бит. Галимҗан Ибраһимов). *(Авт. иск.)*

3. Революция бастырылып, реакция кузгалу белән, әүвәлдәге җилкенүләрнең һәммәсеннән кайтып, урта буржуа сызыгында мәдәни бер көрәш алып бару һәм шунда ныгып, уңланып, эш күреп китү баскычы.

Бу өченче баскыч турында тулы һәм дөрес бер аңлату түбәндәгечәдер.

«Революция басылу белән, һәммәсенең төсе ачылды. Бар да асылына кайтты. Хәрәкәт үзенең нәтиҗәсе буенча мәдәни бер көрәш булы чыкты. Уку-укыту, мәктәп вә мәдрәсә эшләре искечә куелганлар. Болар шәкерткә тормыш өчен ярамый. Мондан тик муллалар гына чыга...»

«Шәкертнең башка милләт зыялылары кебек адәмчә яшисе килә».

«Ата-баба, гаилә, өст-баш, гыйлем, мәгърифәт эшләрендә рус-Яурупа буржуазия нигезендәге кебек мәдәни рәвештә буласы килә. “Дин, дин, дин” дип кенә ми черетүдән котылып, рус-Яурупа мәктәпләрендәге кебек тәрбия аласы килә. Болар һәммәсе, әлбәттә, бик кирәкле нәрсәләр иде. Иске Көнчыгыш хәерчелегендән, наданлыгындан Яурупа буржуа мәдәниятенә таба бару, әлбәттә, зур бер адым алга атлау иде, реформа хәрәкәтенең нык үсүе иде, ләкин монда бер тиенлек дә социализм юк иде».

«Бу шул XIX йөзнең соңгы яртысында ялланган татар буржуазиясенең яңалык, реформачылык, яурупачылык хәрәкәтенең ачык, кискен куелган рәвеше, татар либерализмының вак буржуазия социализмы рәвешендә чыккан революционер-радикал фракциясе иде».

«Революция дулкыны кайткач, һәм аның шулай икәне ачык күренде. Бөтен ул хәрәкәт,үзенең тарихи мәгънәсе буенча, татар мәдәниятенең зур бер бүлеге булган уку-укыту мәсьәләсен Яурупа буржуазиясе дөньясындагы нигезгә куйды, татар шәкертен буржуазия мәдәниятендәге мәдәни, зыялы адәм дәрәҗәсенә мендерү кебек табигый, иҗаби бер максуд ачык булып калды.

Моның табигый рәвештә ачылуы 1907–1908 елларда чыккан “әл-Ислах” гәзитендә булды.

Бу гәзитнең беренче номерында баш мәкаләсендә социаллыкны аңлаткан “сәгадәте гомуми” сүзе бар иде. Елдан артык дәвамында бу гәзит турыдан-туры безнең мәдәни һәм тәгълим[1] эшләребезне

[1] Тәгълим – уку-укыту.

Яурупа буржуазия мәдәнияте нигезендә торырга чакыручы либералланучы шәкертләргә бер орган булып чыкды.

Социализмндан һичнәрсә калмады. Бөтен хәрәкәт өчен бу мисал булды» («Татарлар арасында революция хәрәкәтләре» – Г. Ибраһимов).

Икенче төркем – сәясәткә бик нык чумдырылган профессия хәрәкәтенең батырлары – приказчиклар иде. Өченчеләре исә *«татарның милли социализмасының фиркасе булып, мәйданга атыла» һәм «миллилекне үзләренең программаларының бер ноктасы итеп алып бара»* торган адәмнәр иде. Бу соңгылар үзләренә шаулатып «социалист» исемен бирүче «эсер партиясенең татар группасы» адәмнәре һәм татар вак буржуа төркемнәренең «сул радикал канаты» иделәр. Йосыф Акчура боларны 1908 ел «Әхбар»да (13 нче сан) язган «Һәмшәриләремә[1] хатлар» дигән мәкаләсендә «ике ел әүвәлге чамасыз эсселәрдә иртәрәк кызарып алган берничә яшь егетебез» дип йөртә (шуңа кушып, янә «болардан гайре безнең халыкның җөмләсе милләтче» дип ныгытып куя). «Йолдыз»ча әйткәндә, болар – «дәгъвалары үзләрендән зур булган бәгъзе бер сикерепчыгарлар» булалар («Йолдыз», 1591 нче сан, 1916 ел, унъеллык юбилей номеры).

Болар, чынлыкта сүздә генә социалист булып, эштә шул ук либераль татар буржуазиясе белән кулга-кул тотышып баручылар булдылар. Болар төбендә «“Иттифакы мөслимин”челәр белән кодаланучылар, дин, мәдәният, идеология мәсьәләләрендә буржуазиягә кул суза» торган социалистлар булып чыктылар. Бу төркемнең башлыклары Гаяз Исхакый, Фуад Туктаров һәм Сәгыйть Рәмиевләр иде.

Дүртенче төркем исә шул ук «Мөселман иттифакы» партиясенең сул кабыргасыннан яралган кешеләрнең төркеме булып, болар үзләрен «Мөселманнарның хезмәт таифәсе» дип атадылар.

Бу төркем, боларны мактаучы Туктаров сүзләре белән әйткәндә, «диннең, милләтнең һәм халыкның бөтен хаҗәтләренә муафыйк программа ясап» алучылар, «авылның һәм мөселманларның дини вә милли файдаларын күзәтү өчен ясалган хезмәт таифәсе»ндән гыйбарәт бер төркем иде. Болар, «Дума» исемендә гәзит чыгарганлыклары өчен, «думачылар» дип тә йөртеләләр. Бу төркемнең башында Һади Атласов (Бөгелмәдән), мулла Габдулла Нәҗметдинов (Сембердән), Гариф Бадамшин (Чистай сәүдәгәре), Кәлимулла Хәсәнов (Бөре өязе учителе), ахунд Габдерахман Мәсгудов (Алабуга

[1] Һәмшәримәләремә – иптәшләремә.

өязе), Зәйналов (Кавказлы) кебек адәмнәр иде. «Болар һәммәсе үзләренең иҗтимагый хәлләре буенча урта тип сәүдәгәр, кулак һәм шуңа багланган динче яки зыялы элементлар булып, бөтен эшләре дә шул нигездән барды» («Татарлар арасында буржуазия революция хәрәкәтләре», 216 бит).

Менә шушы югарыдагы төркемнәрнең дүртесе дә шул ук тәрәккыйчы, либераль буржуазия төркеменең бер тармагы икәнен үзләренең соңгы эш баскычларында тагын да ачык, тагын да катгый рәвештә күрсәтеп бирделәр. Вакытында сүздә үзләрен ачыктан-ачык «социалист» дип игълан кылып, тыштан караганда «Иттифак»ка каршы шауласалар да, шуның өстәвенә, татар дөньясында беренче мәртәбә «сүгенү», «мактану» методын алып, «Иттифак» юлбашчыларыннан Акчурин, Гаспринский, Фатих Кәрими кебекләрне эштән чыгарып сүксәләр дә, соңыннан бик тиз вакыт эчендә үзләре дә шул ук юлда икәнлекләрен – «иттифакчы» булганлыкларын – үзләре үк эшләре, сүзләре белән ачып салдылар. Бәлки бу юлда тегеләрдән дә ашырып җибәрделәр.

Бу социалистлар эченнән дә 1906–[190]6 елда исламны, милләтне, «Иттифак» партиясен эштән чыгарып сүккән «таңчылар» 1913 елда 22 октябрьдә «Ил» гәзите чыгара башлаганнар иде[1]. Әнә шул гәзитнең беренче санында «Гаяз» имзасы белән язылган баш мәкаләдә үзләренең социализмнан тәүбәләрен түбәндәгечә игълан кылдылар: «Без, төрк балалары, әллә ничә йөз еллардан бирле мөселман булганга, ислам дине, безгә ата-бабадан күчә-күчә килә-килә, безнеңканымызга сеңешеп беткәнгә, исламның бөтен матур тугры тәрбияләре бездә калырга тиешдер. Без Яурупада яши торган халык булганга, хәзерге Яурупаның техникасы, экономикасы, сәнаигы нәфисәсе безгә тәэсир итеп торганга вә торачак булганга, без Яурупа мәдәниятен кабул итәргә мәҗбүр. Безнең сәламәтлегемез, безнең бер милләт булып яшәвемез өчен мондан башка юл юкдыр. Ләкин яурупалашуны без үземезнең әлеге төрк табигате, исламның матур әхлагы аша сөзеп алырга теләгәнгә, без киләчәкдә төрк-мөселман халкының мәдәни бер ботагы булырга омтыламыз...» («Ил» гәзите, 1914 ел, 32 нче сан. Гаяз Исхакый мәкаләсеннән).

[1] Гәзитнең төп язучылары төркемендә «Иттифак»ның үзәге булган Акчура улы Йосыфның, шулай ук Муса Бигинең булуы үзе үк Гаяз кул астында чыга торган бу гәзитнең нинди юл алганын ачык күрсәтеп тора иде. Башка төп язучылар янә Зәки Вәлиди, М. Гафури, Ш. Мөхәммәдьяров, Фуад Туктаров, Нәҗип Гасрый һәм Сәгыйть Рәмиевләр иде. *(Авт. иск.)*

«Иншаллаһ, дини-милли кайгыруларымызны бергәләшеп уртаклашып килгән укучыларымыз да мондан соң да безнең белән бер сафда, бер юлда булырлар. Эш-гайрәт – бездән, алга җибәрү, тәрәккый итдерешү – сездән, тәүфыйк-һидаять» («Ил» гәзите, 1914 ел, 41 нче сан, Гаяз мәкаләсеннән).

«Күп миллионнарга саны ирешкән халыкны, мөселман динендә улдыгы хәлдә, каумиятен югалтмадыгы хәлдә Яурупа мәдәниятен кабул итеп, шул мәдәниятдән үзенең хәятына кирәкле көчләрен сайлап ала белер диеп ышанамыз» («Сүз» гәзите, 47 нче сан, 1916 ел. Исхакый мәкаләсе).

Революция дулкыннары басылгач һәм реакциядән соң, бөтен вак буржуа төркемнәре, берсе – алай, берсе болай сибелеп бетеп, үз юлларына кайттылар. Байтак өлеше дә тәррәккыйче либераль буржуа төркеме агачына ныклап ашланып[1], та[2] Октябрь революциясенәчә татар буржуазиясе фронтында шул фронтның ялкынлы идеологлары булып хезмәт иттеләр. Мәсьәлә түбәндәгечә булды:

1. «Зур шау-шу белән «Марсельеза» җырлаган шәкерт массасы яңа тип мулла яки мөгаллим булып китте».

2. «Приказчиклар массасы, яңадан асылына кайтып, баю, кечкенә булса да кибет ачу хыялына төштеләр. Авангард саналганнардан Шаһиәхмәд Вәлиев кебекләр («Шаһ») провокатор булдылар. Партия организацияләрен партиягә сатты. Тик бик азлары гына күңелдән эчке революционерлыкны саклап калды».

3. Революционерлык, шәплек, фидакярлек ягыннан үзләрен күкләргә күтәргән мактанчык эсерлар – буржуа «таңчылар» группасы түбәндәгечә сүтелде: «Боларның алдынгы кешеләрендән генә гәзитләренең редакторы Сәгыйть Рәмиев, Исхак Бикчуриннар, бераз зинданда утырып чыккач, провокатор булдылар. Төхфәт Мәмлиев тә шул юлга керде. Муса Янбулатов чукынды, провокатор булды».

«Аның атаманларындан Г. Исхакый, берничә ай зинданда утырып, Архангел ягында берничә ел сөргендә йөреп кайтды. Ачыктан-ачык социализмга хыянәт кылды. Кичә эт итеп сүккән динче, милләтче, “иттифакчы” Рәшид казыйлар, Фатих Кәримиләр, Садри Максудилар сафына, ягъни татар буржуазиясе мәсләгенә күчде. Ренегат, мөртәт булды. Туктаров, Мөхәммәдьяровлар да шуңа иярделәр».

[1] Ашланып – берегеп.
[2] Та – кадәр, чаклы.

4. «“Думачылар”, мәхәлләләренә, хуҗалыкларына кайтып тынычландылар».

Вак төркемнәр тарафыннан сүгелгән тәрәккыйче либераль буржуа төркеме исә та Октябрьгә үз юлында какшамыйча нык барды: «Беренче революциядә “Иттифак” партиясе төзеп йөрүчеләр реакция, сугыш вакытында думадагы фракцияләре, бюролары аркылы үзләренең хәрәкәтләрен дәвам кылдырдылар. Февраль революциясендә болар һаман дәвам итеп, Милли шура, Хәрби шура, Милли идарә, Милли-мәдәни мохтарият кебек байраклар астында “Иттифак”ның сыйнфый нигезләрендә эшләделәр. Теге вак буржуа эсер “таңчылар” бу хәрәкәттә ачыктан-ачык элек – “иттифакчы”, соңыннан “милли идарәче” буржуалар белән бергә барды» («Татарлар арасында революция хәрәкәтләре», 231 бит).

**Татар пролетариаты хәрәкәте һәм «уралчылар».** Татарда 1905 ел оешып килеп чыккан иҗтимагый хәрәкәтнең бер өлеше буржуазия төркемнәре хәрәкәтенә каршы булган пролетариат хәрәкәте булды. Бу хәрәкәтнең дә юлбашчылары, идеологлары «уралчылар» («Урал»[1] гәзите чыгаручылар) Хөсәен Ямашев[2], Сәйфетдинов[3], Моратов[4] һәм аларның иптәшләре булдылар.

Болар, үзләренең «Урал»лары аркылы, реакциянең каты башланган чакларында «социалист партияләр, социализм өчен көрәшергә куәтле бер армия ясар өчен, капитализм золымында изелә торган эшчеләрне дин, милләт аермасына карамыйча, үзенең флагы астына чакырадыр» («Урал», 21 нче сан, 2 бит) дип, марксизм-большевизм байрагын саклау өчен көрәштеләр. Татар дөньясында беренче мәртәбә кадалган шушы большевизм байрагы астында татар буржуазия хәрәкәтенә, татар буржуа төркемнәренә каршы нык көрәш алып бардылар. Татарлар арасында бик кызу марксизм-большевизм фикерләрен тараттылар.

«Русиядә иске тәртипкә каршы булган көрәш иркенлекне теләгән һәр сыйныфның бунынчы (моңарчы) алдагы сыйныфларның гына

[1] «Урал» – татар телендә беренче социал-демократик газета. 1907 елның 4 гыйнварыннан алып 27 апреленә кадәр Оренбургта атнасына 2–3 тапкыр нәшер ителә, барысы 31 саны чыга. Язмаларның күп өлешен Хөсәен Ямашев бастыра.

[2] Хөсәен Минһаҗетдин улы Ямашев (1882–1912) – революцион хәрәкәт эшлеклесе. Г. Тукай, Ш. Мөхәммәдов, Г. Камал, М. Гафури һ. б. татар зыялыларының иҗатына зур йогынты ясый.

[3] Галимҗан Җәмалетдин улы Сәйфетдинов (1882–1918) – сәясәт эшлеклесе.

[4] Ибраһим Моратов революционер, беренче татар социал-демократларыннан берсе Зариф Садыйковның (1883–1912) тәхәллүсе булырга тиеш.

эше иде. Әмма хәзер бөтен халыкның эшенә әйләнә бара, ягъни иске тәртипкә каршы көрәш тирәнләнә һәм киңәя барадыр».

Гәзит үз телендә мәсьәләне болай билгеләде: «Шулай ук бу көрәштә халыкның төрле сыйныфларының арасындагы каршылык көндән-көн өскә чыга бара.

Хәзер эшчеләр сыйныфының бурычы – үзен сыйнфый дошманлардан алдатмаенча, бу көрәшне ахырына чаклы җиткереп, үзенең олуг булган теләге – социализм өчен көрәшкә җул ачудыр.

Буның өчен пролетариат (эшчеләр сыйныфы) бергәләшкән һәм сыйныфына билгеле файдаларын аңлаган булырга тиешле.

Икенче якдан, бу көрәшне ахырына җиткерү, бу көрәшдә пролетариатның якын иптәше булырлык крестьян халкының һәм шәһәр җирләрендәге фәкыйрь халыкның үзләренең фаидә вә зарурларын аңлаулары артудан һәм үзара берегешеп кушылуларындан булачакдыр.

Шуңа күрә без үземезнең гәзитемездә, пролетариатны бергә кушылуга өндәп, аның сыйныфына билгеле аңын артдырырга булышу кеби, крестьян халкын һәм шәһәр фәкыйрьләрен дә үзара кушылырга өндәячәкмез» («Урал», 1 нче сан).

Ләкин революциянең кысуы, мәҗбүр итүе белән, бу гәзит күп дәвам итә алмый. 1907 елның 1 гыйнварыннан башлап шул ук елның 18 апреленәчә барысы 30 номер гына чыга да шуның белән бөтенләй туктап кала.

Әле татар пролетариатының, татар буржуа сыйныфына, буржуа төркемнәренә караганда, бердән, сәяси, мәдәни хәзерлеге, көче азлыгы, икенчедән, реакциянең боларга артык каты бер кысынкылык күрсәтүе сәбәпле, бу хәрәкәт татар буржуасының буржуазия төркемнәренең хәрәкәтләре алдында вакытлыча җиңелеп калырга мәҗбүр була. Бөтен татар буржуа төркемнәре, югарыда ачык аңлашылганча, ахырда һәммәсендә бер казыкка – «иттифакчылар» казыгына утырып алып, татар милли буржуа хәрәкәтен һәрьяктан киңәйтеп, тирәнәйтеп җибәрәләр.

Нәтиҗәдә, татарның бөтен иҗтимагый-мәдәни хәрәкәте, әдәбияты татар буржуазиясе юлбашчылыгы, шуның контроле астында Октябрьгәчә һаман үсә, үз юлы белән һаман киңәя, татар матбугат һәм әдәбиятында үз идеологиясенең тамырын һаман озакларга суза иде.

**1905 елдан соң татарда буржуа җәмәгатьчелек әдәбияты.** 1905 ел революциясе белән татар дөньясында иң элек күзгә ташланган нәрсә җәмәгатьчелек әдәбияты булды. Шуның өчен, тикшерүне

элек шуннан башлыйбыз. Революция хәрәкәте кузгалу, 17 октябрь манифесты чыгу белән, татар дөньясында, бердән, вакытлы матбугат – җәмәгатьчелек әдәбияты баш күтәрде. Буылып торган бер буаның бердән ерып киткәне шикелле, һәр якта бер-бер артлы гәзитләр чыга башлап, шулар аркылы төрле фикерләр, тойгылар, теләкәмәлләр кайнатыла башлады.

1905 елгача татарда Каюм Насыйриның календарьларыннан, Рәшид казыйның 1900 елда журнал рәвешендә чыга башлаган «Миръат»ларыннан башка җәмәгатьчелек әдәбияты – вакытлы матбугат юк иде. Аңарча Идел буе татарының нәкъ үз телендә, үзенә караган бер гәзите дә була алмады. [19]70–[19]80 елларда ук Каюм Насыйрилар, аннан соң Ильясилар, гәзит чыгарырга тырышып, хөкүмәттән рөхсәт сорап йөргән булсалар да, рөхсәт бирелмәгәнлектән чыгара алмадылар. Шулай булса да, Татарстанның алдынгы сыйныфы, буржуа катлавы, зыялысы, тәрәккыйче сәүдәгәре, ачык фикерле мулласы, казыйсы аңарча дәвам итеп килгән «Тәрҗеман» гәзитеннән файдалана тордылар. Кавказ гәзитләре дә укыла иде. Гәзитләргә язасы килгән татар мөхәррирләре дә аңарча әнә шушы гәзитләрдә язышып килделәр. Рәшид казый, Фатих Кәрими һәм Һ. Максудиларның язышулары шул җөмләдән иде. 1905 елгы революция белән татарда вакытлы матбугат әүвәл Петербургтан (Ленинградтан) башланды. Аннан соң Казаннан, Оренбургтан, Уральскидан күтәрелде.

Бу урында әүвәл үк шуны әйтеп үтәргә кирәк: бу матбугатның күбесе төбендә бер мәсләктә – татар либераль буржуа мәсләгендә иде. Һәммәсенең дә күз төбәмәсе, кайсыбер тайпылулар белән бергә, төбендә бер якка, бер кыйблага караган иде. Боларның күбесе шул мәсләктән булганлыктан, «иттифакчы» икәнлекләрен («Өлфәт», «Казан мөхбире», «Әхбар», «Азат», «Вакыт» кебекләре) алдан ачыктан-ачык гәзитләренең беренче саннарында ук шаулатып билгеләп куйдылар. Әммә Һади Максудиның «Йолдыз»ы кебек кайберләре: «Без билгеле бер мәсләк тота алмыйбыз, хәзерге дулкынлы-өермәле вакытта билгеле бер мәсләк алу кыен», – дигән мәгънәдә тыштан мәсләксезлек күрсәтсәләр дә, шулай ук Гаязларның «Таң»нары, шәкертләрнең «әл-Ислах»лары социалистлык буявына буялган, өс-башларына караганда, кызыл төскә кергән кебек булсалар да, болар да төбендә шул ук тәрәккыйче татар либераль буржуасының кыйбласына таба буйлаучылар, үзләре дә сизмәгәннәре хәлдә, шушы зур тегермәнгә су коючылар иде.

Боларга кушылмаучы, боларга тәмам башка мәсләкле ике татар гәзите генә болардан аерылып чыкты: бу икенең дә берсе – мөселман карагруһлары гәзите булган «Нур»[1], икенчесе дә татар пролетариаты, большевиклары гәзите булган «Урал» булды.

Югарыда иҗтимагый-фикри хәрәкәтләрне бүлгәнебез шикелле, татар гәзитләрен дә түбәндәгечә берничә типка аерып тикшереп үтик: 1) либераль буржуа гәзитләре; 2) пролетариат гәзите.

Буржуа гәзитләре үзләре ике тип: а) тәрәккыйче либераль буржуа гәзитләре – ачыктан-ачык «иттифакчылар»; б) вак буржуа гәзитләре – «иттифакчылар»ның сабый туганнары.

Иң элек чыккан гәзит татарлар арасында рус самодержавиесе сәясәте, шуның акча һәм акыл ярдәме белән чыгарылган «Нур» гәзите булды (1905 ел сентябрьдә чыкты, моның мөхәррире һәм нашире Петербургның Габдулла ахунд Баязитов иде. Үзе вафат булгач, аны угылы Сафа Баязитов (соңында Февраль революциясе алдыннан мөфти булган кеше) чыгара башлады).

Либераль һәм ярым либераль буржуа гәзитләребездән иң элек чыкканы икәү булды. Берсе – Петербургта «Өлфәт», икенчесе дә Казанда «Казан мөхбире» иде («Өлфәт» 1905 елның ахыргы айларында атнага бер чыга торган гәзит булып, 4 нче саны гыйнварның бишендә чыккан. «Казан мөхбире» дә 1905 елның 29 октябрендә чыга башлый). «Өлфәт»не чыгаручы һәм аның мәсьүл[2] мөхәррире «Иттифак» кыңгыравы Рәшид казый Ибраһимов булса, «Казан мөхбире»н чыгаручы һәм аның баш мөхәррире дә шул ук «Иттифак» әгъзасы – адвокат Сәидгәрәй Алкин була. Бу гәзитнең мөхәррирлеге Борһан Шәрәфкә күчә. «Казан мөхбире»нең баш мөхәрриренә киңәшче, шулай ук гәзитнең гыйльми һәм сәяси нык терәге дә «Иттифак»ның иң көчле, Яурупа мәгънәсе белән иң галим идеологы булган кадет Йосыф Акчура булып, бу гәзит үзенең сотрудниклары ягыннан бөтене белән «Иттифак»ның беренче арка таянычы, шуның көчле бер фикер тарату органы булып барды.

Бу гәзитнең үз теленнән мәсләге:

---

[1] «Нур» – 1905 елның 2 сентябреннән 1914 елның 22 июненә кадәр Санкт-Петербургта нәшер ителгән атналык иҗтимагый-сәяси, әдәби газета. Татар телендә беренче вакытлы матбугат басмасы. Оештыручы, нашир һәм мөхәррире – Гатаулла Баязитов. Барлыгы 310 саны дөнья күрә, К. Бәкер, Г. Еникеев, Г. Исхакый, Ш. Камал, Ф. Кәрими, С. Максуди, Һ. Максуди, К. Мотыйгый, С. Сүнчәләй, К. Тәфкилев һәм башкалар хезмәттәшлек итә.

[2] Мәсьүл – җаваплы.

«Гәзит халыкның фикеренә иярү белән түгел, әфкяр гомумияне[1] ясау белән мөкәлләфтер[2].

Вә: “Халык төрле уйда, төрле ихтыяҗда, төрле теләктә, хәлбуки, бу күптөрле уй, хаҗәт вә теләкләрнең һәммәсенә муафыйк килә торган мәсләк була алмыйдыр, зирә[3] боларның бәгъзеләренә каршыдыр”.

Вә: “Моны халыкларның соң замандагы теләк вә хәрәкәтләре ике зур әсастан чыкты, ул әсаслар – «хөррият вә мөсәвәт»тер[4]. Без – бу ике әсасны араларында низаг чыкканчы тәгъкыйб итүчеләрдәнбез[5]”.

“Казан мөхбире” әсасы – хөрриятләрнең, ягъни хөррияте вөҗдания, хөррияте шәхсия, хөррияте кяләмия, хөррияте матбугат, хөррияте иҗтимагъ вә хөррияте җәмгыятьнең тарафдар вә мөдафигыдыр[6]».

“Казан мөхбире” сәяси вә мөлки 157 хокукда Русиядәге һәр диннең, һәр милләтнең, һәр фәрднең[7] кәмаль мөсавилекне[8] телидер.

“Казан мөхбире” – татар һәм мөселмандыр. Бинаән галәйһи[9] мөселман диненә булган һәртөрле тәгъризларга[10] мөдафәга итү[11] – “Казан мөхбире”нең максады, вазифаларының бередер» («Казан мөхбире», 1 нче сан, 1 бит, 2–3–4 баганалар, 1905 ел).

1907 елда «Казан мөхбире» гәзите «Әхбар»га әйләнде. Шушы елның 10 нчы декабрендә чыга башлаган бу гәзит Казанның зур байларыннан төзелгән бер ширкәт тарафыннан матди яктан тәмам тәэмин ителеп чыгарыла башлый. Үзе «җитди вә милли гәзит булырга һәм шул замандагы тәгъбире белән әйтсәк, буржуазный орган булырга тырыша»[12]. Мәгънәви ягы да, шулай ук буржуа идеологиясе нигезендә зур көчләр белән нык тәэмин ителә. Мәсләге шул ук «Казан мөхбире»нең мәсләге булып, анда язышкан һәммә мөхәррирләр монда күчәләр. Гәзитнең рәсми баш мөхәррире Харис

[1] Әфкяр гомумияне – гомуми фикер, нәтиҗәне.
[2] Мөкәлләфтер – җаваплы.
[3] Зирә – чөнки.
[4] Мөсәвәт – тигезлек.
[5] Тәгъкыйб итүчеләрдәнбез – күзәтүчеләрдәнбез.
[6] Мөдафигы – яклаучысы.
[7] Фәрднең – шәхеснең.
[8] Мөсавилекне – тигезлекне.
[9] Бинаән галәйһи – шуңа күрә.
[10] Тәгъризларга – ризасызлыкларга.
[11] Мөдафәга итү – каршы тору.
[12] Җ. Вәлиди. «Тукай мәҗмугаи әсаре»нә язган мөкаддимә һәм анализында. *(Авт. иск.)*

Фәйзи булган шикелле, оаширләре дә аңа сөялә. Бу гәзит, барысы 84 сан чыгып, 1908 ел июль 27 сендә туктала.

Шул ук мәсләкнең, шул ук «Иттифак» партиясенең фикер таратучысы булып, шушы партиянең бер актив әгъзасы Габдулла мулла Апанаев тарафыннан 1906 ел 1 февраль «Азат» гәзите чыгарыла башлады.

Үзенең бер мәсләккә, бер партиягә дә сөялмәвен игълан иткән хәлдә, «Иттифак»ның фикер таратучысы булып, тагын 1906 елның 15 гыйнварында Һади Максуди тарафыннан «Йолдыз» чыгарыла башлый. Бу гәзит озын гомерле булып, Февраль революциясенәчә дәвам итә.

Гәзитнең үз теленнән мәсләге:

«Бу еллар кеби мәсләкләр чуалган заманда, бер мәсләкне тәгаенләп куюда, безнең гөманча, бераз мөшкеллек бардыр».

«Сәясәт хосусындагы мәсләкне тәгаен мөмкин булса да, мәгыйшәт хосусында мәсләкләрнең берсене мөляхәзәсез ихтыяр вә тәгаен итмәк бераз ашыгычлык буладыр. Фикердә истигъҗал[1] исә мантыйк кагыйдәләренчә бик мәкъбүл[2] түгелдер». «Дөньяда һичбер мәсләкләргә артык һилаф кителми торган берничә төрле фикерләр бардыр ки, һәркемгә һәр йирдә шул фикерләрдә булмак мөмкиндер».

«“Йолдыз” гәзите милли бер гәзит булмак фикерендәдер». «Әһле исламның һәр хосусда тәрәккыйдә булуларына кулындан килгән микъдарында тырышачакдыр». «Дине исламның кавагыйде сәясиясенә муафыйк булган һәрбер мәгъкуль фикерләрне “Йолдыз” кабул итәдер».

«“Йолдыз” – казанидыр». «“Йолдыз” – җәридәи төркдер[3]».

«“Йолдыз”ның беренче санында «Иттифакы мөслимин җәмгыяте мәҗлесе» дип хәбәр яза. Шунда ул «Иттифакы мөслимин»не «Әһле ислам партиясе» дип атый.

Шулай ук «Йолдыз» гәзите үзенең унъеллык юбилей санында түбәндәге фикерләрне яза:

«Бу ун санәлек мәддәт[4] эчендә мәмләкәтемездә бер гасырлык тәбдил[5] вә үзгәрешләр булып кичкәне һәркемнең мәгълүмедер. Бу

[1] Истигъҗал – ашыгычлык.
[2] Мәкъбүл – яраклы.
[3] Җәридәи төрк – төрки газета.
[4] Мәддәт – вакыт.
[5] Тәбдил – үзгәреш, алмашу.

мәддәтдә мәмләкәтемезнең дәхелендә[1] фикер вә мәсләкләр бик күп төрлегә авышдылар. Гяһ[2] бик суллык вә гяһ бик уңлык шаигъ була иде[3]. Суллык мода булган заманда милләт фикеренә игътибар юк иде. Миллилек бер нәүгъ[4] уңлык санала иде. Хөррият вә мөсавияткә тәгаллекъле[5] эшләрдә суллыкларны тәмамилә кабул вә тәкъвия итдеке[6] хәлдә, милләткә гаид[7] эшләрдә «Йолдыз» һич сулланмады. Һаман милләт фикерен тәкъвия кылып барды. Әүвәл заманда күп гәзитләр хак вә хакыйкатьдән артык модага ияре иделәр. Милләт ноктасында калу Хакка әтбагъ исә дә[8], ул вакытда бик авыр иде; авыр булса да, «Йолдыз» бу дәгъвасында сабит калды[9]. Йиңеллегенә кызыгып, тиз мәнсух булачак[10] мода артындан китмәде. Шул вакытда мода йиле белән искән гәзитләргә каршы милләтне мөдафәга кылуын[11] «Йолдыз» үзенең фидаилыгындан саный».

«Әхвәлдән хәбәрсез мөхафәзакярләрнең һәм дәгъвалары үзләрендән зур булган бәгъзе бер «сикерепчыгар»ларның сүзләренә илтифат итмичә, «Йолдыз» үзенең файдалы мәсләкендә дәвам итәчәкдер» («Йолдыз» гәзите, 1916 ел, 1591 нче сан).

Шул ук тәрәккыйче либераль буржуазиянең фикер таратучысы һәм «Иттифак»ның икенче нык арка таянычы, юлбашчысы булып, 1906 ел, 21 февральдә татар буржуазиясенең күптән бирле икенче бер оясы булып килгән Оренбург шәһәрендә «Вакыт» гәзите чыгарыла. Баш мөхәррирләре – татарда беренче оста җәмәгатьче, мәшһүр мөхәррир Фатих Кәрими, гәзитне таратучылар да алтынчы (сәнәгать капиталистлары) Шакир, Закир (Дәрдмәнд) Рәмиевләр була.

«Вакыт» гәзите Февраль революциясенә чаклы бездә таралган гәзитләр арасында, шөбһәсез, гәзитчелек ягыннан иң яхшы куелган һәм Яурупа мәгънәсе белән либерализм фикерендә кебек адымнар белән нык барган беренче гәзит булды. Моңа да бик зур сәбәпләрнең берсе гәзитне матди яктан тәэмин итүче либераль татар

[1] Дәхелендә – йогынтысында.
[2] Гяһ – кайчак.
[3] Шаигъ була иде – халык арасында тарала иде.
[4] Нәүгъ – төр.
[5] Тәгаллекъле – бәйләнешле.
[6] Тәкъвия итдеке – якланган, ныгытылган.
[7] Гаид – кагылышлы.
[8] Хакка әтбагъ исә дә – Аллаһка хезмәт булса да.
[9] Сабит калды – үз позициясендә калды.
[10] Мәнсух булачак – кире кагылачак, гамәлдән чыгачак.
[11] Мөдафәга кылуын – *биредә:* яклавын.

капиталистлары Рәмиевләрнең алтыны булса, икенче зур төп сәбәбе – гәзитнең беренче көненнән үк башына куелып, Февральгәчә юлбашчылыкта дәвам иткән Фатих Кәрими иде.

Бу мөхәррирдә көчле әдәби талант булып, югарыда әйтелгәнчә, ул бераз матур хикәяләр дә бирде. Шунык өстенә, соңыннан кайбер тарих әсәрләре язды. Бик күп файдалы тәрҗемәләр дә бирде. Гомумән, бу мөхәррир әдәбият вә матбугат эшендә бик киң куллы, күп җимешле, үз заманы өчен күп файдалы һәм чиксез энергияле, зур хәзерлекле бер каләм булды. Ләкин бу мөхәррирнең бик төпле хезмәте – татар буржуа вакытлы матбугаты эчендә зур ролендәдер. Моның аркасында «Вакыт» үзен Яурупаның кечкенә үлчәүдә, яхшы техникалы, монтазам[1] куелган капиталист гәзите булу дәрәҗәсенә мендереп җиткән иде. Бу гәзит һәм аның мөхәррире, үзенең нигезендә капитализмга хезмәтне төп махсуд итеп кую белән бергә, татар дөньясының милли мәсьәләләре үзләренең бөтен тармаклары, бөтен төрләре белән мәгълүм либералчылык ноктасыннан каралып, шул турыда юлбашчылык итә барды.

Г. Тукайның «Японияне мөселман идәчәк голяма нәрәдә?» (1906) шигыреннән.

Сез, и чалмалылар, безне моңарчы йокыда тоттыгыз;
Уку урынына вакытыбызны бушка әрәм иттегез. <...>

«Вакыт» үзенә күрә ул заманның активистлары арасында бердәнбер төпле гәзит итеп карала, аның сүзләренә юлбашчы органның фикере кебегрәк кыйммәт бирелә иде. Шушы капиталист либераль гәзитнең мондый мәгънәви юлбашчылыкны ала алуы, шөбһәсез, Фатих Кәрими каләме аркасында булды.

Шуның белән бергә бу мөхәррир үз тирәсенә үз юлына муафыйк сотрудникларны да җыйнады. Кәбир Бәкер[2], Г. Баттал, Борһан Шәрәф, Ш. Камал, Ярулла Вәли, Г. Фәхретдинов[3] кебек язучылар шулар җөмләсеннән булдылар.

Бу гәзитнең заманында иң төпле икенче бер гыйльми терәге Мәрҗанидән кала татарның иң зур тарихчысы Риза казый булып,

[1] Монтазам – тәртипкә, рәткә салынган.

[2] Кәбир Бәкер (Кәбир Кәрим улы Бәкеров, 1885–1944) – журналист, драматург, театр тәнкыйтьчесе.

[3] Габдрахман Ризаэддин улы Фәхретдинов (1887–1937) – журналист, тәрҗемәче. 1906–1913 елларда «Вакыт» газетасы җаваплы сәркатибе. 1913 елдан газетаның икенче мөхәррире булып, мәдәният һәм эчке хәбәрләр сәхифләрен алып бара.

моның башка сотрудниклары да татарда шул вакыттагы көчле дип танылган каләмнәр иде.

1906 елда Әстерханда Габдрахман Гомәров[1] тарафыннан чыгарыла башлаган (башта мөхәррире Заһидулла Шәрифуллин булса да, аның вафатыннан соң мөхәррирлеге дә мулла Гомәровка күчә) «Идел»[2] гәзитләрен дә шул катарга[3] төзергә кирәк.

1912 елдан башлап, шушы югарыдагыларга Казанда «Кояш»[4] (нашире – зур капиталистлардан борадарән Кәримовлар, мөхәррире – Зәкәрия Садретдинов), «Тормыш»[5] (1913 елда чыга башлап, нашире һәм мөхәррире башта Вәгыйзь Нәүрүз[6] булса да, соңыннан наширлек Уфа байларыннан Гыйбадулла Госмановка, мөхәррирлек тә мәгълүм исламчы Закир Кадыйровка[7] күчә) гәзитләрен, шулай ук бигрәк тә 1913 ел 22 октябрьдә Петроградта Гаяз Исхакый тарафыннан чыгарыла башлаган (бу гәзит соңыннан 1914 елда Мәскәүгә күчеп, ноябрьнең 14 ендә 41 нче саны анда чыга; Петроград һәм Мәскәүдә барысы 89 сан чыкты) «Ил»[8], шул ук Петроградта

[1] Габдрахман Гомәри (Габдрахман Исмәгыйль улы Гомәров, 1867–1833) – дин эшлеклесе, исламият галиме, нашир. Ш. Мәрҗани шәкерте һәм аның тарафдары. Әстерханда 1893 елда «Низамия» мәктәбен (соңрак мәдрәсә) оештыра (соңрак бу уку йорты бөтен Түбән Идел буе мөселманнары өчен укыту-тәрбия үзәгенә әверелә), 1907 елда басмаханә ача, «Мәгариф» журналын, «Идел» газетасын нәшер итә.

[2] «Идел» – 1907 елның сентябреннән 1914 елның декабренә кадәр Әстерханда басылган милли-демократик газета. Барлыгы 623 саны дөнья күрә.

[3] Катарга – рәткә, сафка.

[4] «Кояш» – 1912 елның 10 декабреннән 1918 елның 11 июненә кадәр атнага өч мәртәбә Казанда татар телендә чыккан иҗтимагый-сәяси, әдәби, либераль-демократик юнәлешле көндәлек газета. Барлыгы 1245 саны дөнья күрә.

[5] «Тормыш» – 1913 елның 18 октябреннән 1918 елның 29 апреленә кадәр Уфа шәһәрендә татар телендә нәшер ителгән иҗтимагый-сәяси һәм икътисади газета. Баштарак – атнага өч тапкыр, аннан соң көн саен чыга, 800 гә якын саны дөнья күрә. Мәгариф, дин, татар теле, эшмәкәрлекне үстерү, хатын-кызларның җәмгыятьтәге урыны, авыл тормышы мәсьәләләренә багышланган мәкаләләр дөнья күрә.

[6] Вәгыйзь (Мөхәммәтвәгыйзь) Шаһвәли улы Нәүрүзев – укытучы, журналист, «Сибирия», «Тормыш», «Ак Идел» һәм «Ватан» газеталары мөхәррире.

[7] Закир Хәлим улы Кадыйри (1878–1954) – җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, илаһият галиме, журналист. 1914–1918 елларда «Тормыш» газетасы мөхәррире. «Тормыш» газетасы ябылганнан соң (1919), Финляндиягә китә, мәдрәсәдә укыта. Соңрак Төркиягә күчеп килә. Илаһият һәм фәлсәфә, мөселман мәдәнияте тарихы буенча хезмәтләр; тел белеме ярдәмлекләре, Көнчыгыш һәм Европа галимнәре хезмәтләренең татар теленә күпсанлы тәрҗемәләре авторы.

[8] «Ил» – Гаяз Исхакый мөхәррирлегендә Петербургта 1913 елның 22 октябрендә басыла башлаган иҗтимагый-сәяси газета. 1915 елның 27 мартыннан туктатыла, шул елның 13 декабрендә Мәскәүдә «Сүз» исеме белән дәвам иттерелеп, яңадан ябылгач, кабат «Безнең ил» һәм «Ил» исемнәре астында 1918 елгача нәшер ителә.

1914 елда Сәлимгәрәй Җантурин[1] белән Биниәмин Әхтәмовлар тарафыннан чыгарылган «Милләт»[2], Әстерхандагы «Халык[3]» янә «Ил» урынына 1915 елда шул ук Гаязның канаты астында Габдулла Сәгыйдев мөхәррирлеге, Әхмәдбәк Салихов наширлеге белән чыгарылган «Сүз» гәзитләрен кушарга кирәк. Болар һәммәсе, әнә шушы [190]5–[190]6 еллардагы тәрәккыйче татар либераль буржуа гәзитләре рәтенә тезелеп, шуларга, шул идеологиягә хезмәт иттеләр.

1906–[190]7 елларда чыккан вак буржуазия төркемнәренең гәзитләре түбәндәгеләр иде:

1. **«Таң йолдызы».** Үзләрен социалист-революционерлар дип күрсәтүче бер төркемнең органы булган бу гәзит 1906 ел 18 майда Казанда чыга башлый. 9 нчы сангача мөхәррире дә, нашире дә Гали Путилаков булып, 10 нчы саныннан башлап, мөхәррирлек Сәгыйть Рәмиевкә күчә. 22 нче саныннан башлап Фуад Туктаров мөхәррир була. Бу гәзит 62 сан чыгып, шул ук елның 11 ноябрендә туктый да, аның урынына тагын «Таң мәҗмугасы», «Тавыш» дигән гәзитләр чыгып карый. Г. Исхакый да бу гәзитнең төп язучыларыннан иде.

2. **«Азат халык».** Казанда 1906 елның 4 июнендә чыга башлый. Барысы 14 сан чыгып, шул елның 12 сентябрендә туктала. Нашир һәм мөхәррире Галиәсгар Камал була (бу гәзитне туктаткач, Г. Камал «Йолдыз»га сәркатип һәм мөдир булып күчә).

«Бу гәзитнең мөхәррире рәсми бер партия члены түгел, ләкин ул заманның сул агымнарын яклаучы иде. «Иттифак» партиясенә баштан ук каршы барды. Үзенең битләрендә бу партиянең программасын да, җыелышларын да, кешеләрен дә тәнкыйть кылып, көлеп язды».

---

[1] Сәлимгәрәй Сәетхан улы Җантурин (1864–1926) – җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе,1913–1916 елларда «Милләт» газетасын чыгаручыларның берсе.

[2] «Милләт» – 1913 елның 28 декабреннән 1915 елның 7 февраленә кадәр Петроградта нәшер ителгән көндәлек иҗтимагый-сәяси, икътисади газета, 4 нче Дәүләт думасының мөселманнар фракциясе органы. 19 саны дөнья күрә. Текстлар татар һәм рус телләрендә басыла. «Мөселман фракциясе», «Мөселман басмасы», «Безнең хәбәрләр» һәм башка рубрикаларда илдәге сәяси вазгыять, Дәүләт думасында мөселманнар эшчәнлеге, Мөселман иҗтимагый оешмалары съезды эше, халык мәгарифе, яралы хәрбиләр һәм аларның гаиләләренә ярдәм итү һәм башка мәсьәләләр яктыртыла.

[3] «Халык» – 1914 елның апреленнән 1915 елның 20 февраленә кадәр Әстерхан шәһәрендә атнага ике тапкыр татар телендә нәшер ителгән иҗтимагый-сәяси, әдәби, икътисади газета. 65 саны дөнья күрә. Газета Әстерхан төбәгендә яшәүче мөселман, төрки халыклар вәкилләренең берләшүе һәм һәрьяклап белемле булуы, аларның мәдәнияте һәм теле үсеше идеяләрен пропагандалый. Татарлар өчен мөһим булган иҗтимагый-сәяси вакыйгалар киң яктыртыла; мәгълүмат, нигездә, Казан газеталарыннан килеп ирешә.

«Бу, иң күп булганда, аерымачык рәвешдә бер партия эченә кереп билгеләнә алмаган, үзе күңелендән буржуазиягә, аның партияләренә каршы булган һәм социализмны яклаган вак буржуазия революционерларының гәзите иде. «Таң»да, «Дума»да басарга мөмкин булмаганга, ул вакытда үзләренең гәзитләре «Урал» әле чыкмаганга, татар большевиклары үзләренең кайбер фикерләрен үткәрүдә бу «Азат халык»ның битләрендән файдаландылар».

«Әмма төп асылда «азат халыкчылар» ул елларда бик киң җәелгән вак буржуа социализмы агымларының кечкенә бер ермагы иделәр» («Татарларда революция хәрәкәтләре», 217–219 битләр).

3) **«Фикер».** Уральскида 1906 елда чыга башлый. Нашире һәм мөхәррире – Камил Мотыйгый[1].

4) **«әл-Ислах»**. Ислахчы, гыйсъянчы шәкертләр гәзите булып, 1907 ел 3 октябрьдә чыга башлый. Нашир һәм рәсми мөхәррире Вафа Бәхтияров була. Ләкин гәзитнең бөтен рухын билгеләүче, аның иң нык терәге Фатих Әмирхан иде.

Гәзитнең үз теленнән мәсләге:

«Әлхасыйль[2], вакытымызда мәгыйшәтнең һәр тарафы, матди вә мәгънәви җәһәтләре һәммәсе мәктәп-мәдрәсәләр өстенә бина кылынгандыр. Мәктәп вә мәдрәсәләр әсаслы вә заманның һәр таләпләренә муафыйк булса, мәгыйшәт әсаслы вә заманга муафыйк, әгәр әсассыз, иске вә черек булса, мәгыйшәт шулар нигезендә әсассыз вә черек. Бер кавемнең мәгыйшәтене асылдан бозар өчен, аларның балалары тәхсил итә[3] торган мәктәпләрне бозу кямилән[4] [кирәк] икәнлеге кеби, черегән вә бозылган мәгыйшәтне төзәтү өчен дә мәктәп вә мәдрәсәләрне төзәтү тиеш вә шул кяфилдер[5]».

«Татарның мәгыйшәтене асылдан сүтеп төзәтергә кирәк! Безгә аның урынына яңа мәгыйшәт кирәк. Әүвәлдәге наданлар урынына – галим вә зыялылар, әүвәлдәге мөтәгассыйблар урынына ачык

[1] Камил Мотыйгулла улы Мотыйгый (Төхфәтуллин) (1883–1941) – журналист, нашир, җырлар авторы. 1902–1907 елларда «Мотыйгия» мәдрәсәсендә укыта, Г. Тукайның дөньяга карашы һәм аның шагыйрь булып формалашуында мөһим роль уйный. 1905–1907 елларда «әл-Гаср әл-җәдид», «Уклар» журналларын, «Фикер» газетасын нигезләүче, аларның нашире һәм мөхәррире, «Уралец» (1906 елдан – «Уральск көндәлеге») газетасының нашире. «Яңа тормыш» газетасын оештыручыларның берсе (1907–1909).

[2] Әлхасыйль – җыеп әйткәндә.

[3] Тәхсил итә – белем ала.

[4] Бозу кямилән – «тәмам бозу» мәгънәсендә.

[5] Кяфилдер – зарурдыр.

фикерле вә яңа хәрәкәтләрне алып баручылар, һөнәр вә сәнәгатьле мәгыйшәт сугышында мәгълүб булмаслык[1] татарлар кирәк! Әүвәлге сыйныф икенчесенә урын бирергә, үзләре анда тәрбия ала алмаганлар, вакытлары узмаганларга шундый тәрбия вә гыйлем ханәләремезне әсасындан ислах итәргә кирәк! Әүвәлдәге гайрәт вә эшкә икътидарны[2] бетереп, сукыр мөтәгассыйблар чыгара торган мәктәп вә мәдрәсә тәртибе, фән мөдәррисләре урынына эшкә игътибарлы, гайрәтле, зыялы татарлар чыгара торган мәктәп вә мәдрәсә тәртибе, фән мөдәррисләре кирәк!»

«Иске фәнләр, тәртипләр, мөдәррисләр яңаларга урын бирергә вакыт! Кабил[3], ислах мәдрәсәләрне ярым юлда гына калдырмыйча, асыллы ислах итәргә, кабил түгелләрене, милләтемезнең яшь гомерләрен моңар кадәр һәлак итеп килгәнләре шикелле, мондан соң да һәлак итеп тормасыннлар өчен, үзләренең мәүте табигый[4] белән үлүләрене көтмичә, йир йөзендән юк итәргә вакыт!»

«Менә гәзитемезнең мәсләге».

«Моның белән бергә гәзитемезнең сәяси мәсләге дә тәгаен ителәдер: гыйлем юлларыны һәрбер сыйныфка бертигез ачык итә торган сәяси хизебләр[5] – безнең дустларымыздыр».

«Әлхасыйль, лозунгымыз – “Гыйлем, мәгарифнең милләтемез арасына интишары[6] вә сәгадәте гомумия”дер» («әл-Ислах», 1907 ел, 1 нче сан, баш мәкаләдән).

5) **«Борһане тәрәккый»**. 1906 елның җәендә Әстерханда чыга башлаган бу гәзитнең нашир һәм мөхәррире шамахайлы[7] Мостафа Лотфи[8] иде. «Борһане тәрәккый»нең өч-дүрт ай кызылланып, мөселман «Иттифак»ларын сүгеп, социал булып яшәгән заманы

---

[1] Мәгълүб булмаслык – җиңелмәслек.
[2] Икътидарны – сәләтне.
[3] Кабил – булдыклы.
[4] Мәүте табигый – табигый үлеме.
[5] Хизебләр – партияләр.
[6] Интишары – таралуы.
[7] Шамахайлы – Азәрбайҗандагы Шамахы шәһәре кешесе, шамахылы.
[8] Мостафа Лотфи Исмәгыйлев-Ширванский – Бакуда туып үскән публицист һәм нашир. Төркиядә белем алганнан соң Әстерханга шәһәренә күчеп китә, анда актив җәмәгать эшчәнлеге алып бара: 1906 елда «Шураи ислам» (ярлы татарларга ярдәм җәмгыяте) оештыра һәм аның рәисе була, җәмгыять әгъзаларыннан җыелган акчага ятим һәм фәкыйрь балалар өчен җәдиди «Дар әл-әдәб» (1906–1910) мәктәбе ача; Әстерханда беренче булып татар телендә әдәби кичәләр, спектакльләр оештыра; «Мизан» нәшриятын һәм басмаханәсен ача, анда «Борһане тәрәккый», «Хәмият», «Мизан» газеталары басыла, 1906–1911 елларда шул газеталарның нашире һәм мөхәррире була.

бар. «Тәрҗеман» баба моңа каршы зур гауга куптарган иде. «Ул гәзитнең болай алмашуына, башлыча, сәбәп Моратов иптәш иде».

Җәмәгатьчелек әдәбиятыннан либераль һәм вак буржуазия төркемнәренең фикер тарату органнары булган гәзитләрдән мөһимнәре әнә шул югарыда күрсәтелгәннәр иде.

**Журналлар**. Беренче журнал Камил Мотыйгый тарафыннан 1906 елда чыгарылган «әл-Гаср әл-җәдит» журналы булды. Монда Риза казый, Гаяз Исхакый, Рәшид казый, Һади Максуди, Фатих Кәрими, Галиәсгар Гафури (Чыгтай), Тукай, Нәҗип Думави, Зариф Бәшири кебек әдип вә шагыйрьләр катышалар, Кәрим Сәгыйть[1], Хәбибрахман Зәбири[2], Насретдин Хуҗаш, Мөхәммәтфуад Туктаров, Әхмәтҗан Биктимеров[3], Муса Бигиев һәм ахуннардан Хәйрулла Госманов, Гатаулла Баязитов кебекләр дә шушы журналда языштылар.

Журнал дини, милли, әдәби иде. Ләкин теле ягыннан бик чуар, мөндәриҗә ягыннан да әле сай һәм бала иде.

Журналның үз теленнән мәсләге:

«“Әл-гаср әл-җәдит” журналының баш мәсләке Русия мөселманларының мәдәният кәсеп итмәләренә[4] мәгариф артырмагларына вә билҗөмлә башка милләтләр илә гомуми мәгълүмат һәм мөнәсәбәт хасил итмәләренә вә иттиһад[5] юлында булынмакларына хезмәт һәм гайрәт итмәкдер» (1905 ел, «Әл-гаср әл-җәдит» журналының мөфассал[6] игъланы).

1906 елның 5 декабрендә чыккан 12 нче санында бу журнал «Әл-гаср әл-җәдит» вә фикерләре идарә өчен һәйәте идарә тарафындан йөз биң рубль акча тәхсил[7] вә тәгаен иделде» дисә дә, дәвам итә алмады. Шул ук елга чыкканда, бу журнал инде мәсләген болай дип аңлатырга тырышты:

[1] Кәрим Сәгыйть (1888–1939) – журналист һәм җәмәгать эшлеклесе.

[2] Хәбибрахман Габделвәли улы Зәбири (Чистапули) (1881–1942) – язучы, педагог. «Тәрбия» журналының фактик мөхәррире.

[3] Әхмәтҗан Биктимеров (? – 1915) – язучы, журналист. 1907–1908 елларда Ташкентта «Шөһрәт» газетасында эшли, «Азия» исемле газета чыгара, «Фикер», «Бәян әл-хак», «Сибирия», «Идел» газеталарында да язышa. Төрки халыкларның тарихы, мәдәнияте, тормыш-көнкүреше турында күп кенә публицистик мәкаләләр, «Үткән мәхәббәт» (1905), «Ятим Сабир, яхуд Бай кызы» (1907), «Хәлфә» (1912) исемле проза китаплары, мәктәпләр өчен «Русия тарихы» (1914) дәреслеге авторы.

[4] Мәдәният кәсеп итмәләренә – мәдәниләшүләренә.

[5] Иттиһад – берләшү.

[6] Мөфассал – тулы.

[7] Тәхсил – *биредә:* табылды.

«Безем башлыча максадымыз – милләтемезе инкыйраздан кортармак[1] юлында бихак[2] социалист-демократ мәсләкендә уларак там[3] хөррият казанмайә хезмәт итмәкдер.

– Долой бюрократ провокаторларны!

– Долой инсанларә зарарлы адәмләрне!

Менә безнең сүйли торган сүзләремез ошбулардыр. Эштә безим мәсләк будыр» («әл-Гаср әл-җәдит» журналы, 1906 ел, 12 нче сан).

Шулар белән бергә тагын берничә гыйльми, әдәби, иҗтимагый журналлар чыгарылды. Журналлар эченнән иң әһәмиятлеләре һәм Октябрьгәчә дәвам иткәннәре 1908 елда гыйнвар 15 ендә чыга башлаган «Шура» белән 1912 елның 15 декабрендә Казанда чыга башлаган «Аң» журналлары булды. Беренчесенең нашире татар сәнәгать капиталистлары Шакир, Закир Рәмиевләр булып, мөхәррире – Риза казый, икенчесенең нашир вә мөхәррире дә Әхмәтгәрәй Хәсәни[4] иде.

Беренчесе дини, милли, тарихи, иҗтимагый материалларга бик бай булу өстенә татар дөньясында ул заманда иң беренче җитди бер журнал булса, икенчесе дә милли, әдәби, гыйльми, фәлсәфи материалларга бай иде. Һәр ике журналның тирәсенә шул дәвер эчендә татарның бик зур гыйльми, әдәби көчләре җыелдылар. Либераль һәм вак буржуа элементлары барысы да диярлек шул ике журнал җебенә килеп төенләнделәр.

Бу журналларның икесе дә бер үк байракны – татарның либераль тәрәккыйче буржуазиясенең дини-милли байрагын күтәргән хәлдә, бер үк идеологияне төрле юллар белән гыйльми яктан тигезләндерергә, шуны тәртипләнгән, нык бер систем алган көчле бер идеология хәлендә куярга тырыштылар. Кыскасы, бу ике журнал һәм аларның юлдашлары булган башка журналлар гыйльми

[1] Куртармак – коткармак.

[2] Бихак – чын, асыл.

[3] Там – тулы, бөтен.

[4] Әхмәтгәрәй Сибгатулла улы Хәсәни (1883–1933) – нашир, тәрҗемәче, язучы. 1907 елда Г. Рәхмәтуллин белән «Гасыр» нәшриятын оештыра. 1910 елда басмаханә эшен өйрәнү өчен Швейцария, Польша, Германия, Франциягә бара. 1912 елның 15 декабреннән 1918 елның мартына кадәр Казанда айга ике тапкыр татар телендә нәшер ителгән «Аң» журналының нашире һәм мөхәррире. «Аң» – татар халкының социаль, рухи һәм мәдәни проблемаларын яктырткан абруйлы һәм популяр басмаларның берсе. Журнал битләрендә сәнгать мәсьәләләренә кагылышлы бәхәсләр алып барыла, Шәрык, рус һәм дөнья классикасы әсәрләре басыла. «Аң» полиграфия эшләнеше һәм зәвыклылык белән аерылып тора. Татар басмалары арасында беренчеләрдән булып Леонардо да Винчи, Рафаэль, Рембрандт, В.В. Верещагин, И.К. Айвазовский, И.Е. Репин һәм башка рәссамнар әсәрләренең репродукцияләрен бастыра башлый.

яктан системланган бер идеология байрагы астында, ярлысы-бае, мулласы-мужигы, мөгаллиме-учителе бергә булган хәлдә, бөтен татар халкын бергә оештырырга, бер эзгә салырга тырыштылар. Шул юлда югарыдагы гәзитләрнең гыйльми терәге булдылар.

Боларга ярдәмче журналлар түбәндәгеләр иде:

1) **«Сөембикә»**. Хатын-кызларга махсус ирләр тарафыннан чыгарылган журнал. 1913 елда чыга башлый. Нашир һәм мөхәррире – Ягъкуб Хәлили[1].

**2**. **«Русия сәүдәсе».** Сәүдә һәм сәнагать турындагы журнал булып, Казанда 1914 елның 15 октябрендә чыга башлый. Нашире һәм мөхәррире – Шәрәфетдин Шәһидуллин[2].

3. **«Тәрбият әл-әтфаль».** Балаларга махсус бер журнал булып, Мәскәүдә 1906 елның декабрендә чыга башлап, 1907 елның апрелендә туктала. Нашир һәм мөхәррире – Заһидбәк Шамил[3], мәсьүл сәркатибе дә – Ф. Әмирхан.

4. **«Икътисад».** 1913 елның 15 сентябрендә чыгарыла башлый. Нашир һәм мөхәррире – Самара имамы Фатих Мортазин[4].

5. **«Мәктәп».** Педагогия журналы, нашире – «Сабах» ширкәте, мөхәррире – Шиһап Әхмәров[5]. 1913 елның 21 февралендә Казанда чыга.

---

[1] Ягъкуб Ибраһим улы Хәлили (1877–1938) – журналист, нашир, 1913–1918 елларда татар хатын-кызларның беренче «Сөембикә» журналы нашире һәм мөхәррире, шул ук вакытта, 1917–1918 елларда «Балалар дөньясы» журналын чыгара. «Юл» ширкәте әгъзасы буларак, китаплар нәшер итүдә актив катнаша.

[2] Шәрәфетдин Кәшшафетдин улы Шәһидуллин (1879–1942) – нашир, журналист, «Игъланәт» газетасы һәм «Россия сәүдәсе» журналы мөхәррире.

[3] Заһит Шамил (1868–1920) – нашир, журналист. Аның наширлегендә дөнья күргән «Тәрбият әл-әтфаль» – мәктәп укучылары өчен татар телендә булган беренче журнал – яшь буынның акыл дәрәҗәсен үстерүне, милли гореф-гадәтләр белән тәрбияләүне үзмаксат итеп куя. Журналда төрле фәннәрнең нигезләре турындагы; тарих, география буенча; Россиянең сәяси һәм икътисади хәле, Истанбул, Мәккә, Мәдинә һәм башка шәһәрләр тасвирланган мәкаләләр басыла; ул Европа һәм мөселман мәдәнияте, әдәбияты, тарихы белән таныштыра. Үз заманы өчен иң бай рәсемле татар басмасы булып тора: аның битләрендә 50 гә якын фотосурәт һәм рәсем урын ала.

[4] Мөхәммәтфатих Шиһабетдин улы Мортазин (1875–1938) – журналист, дин эшлеклесе. Татар телендәге иң беренче икътисади вакытлы матбугат органы булган «Икътисад» (1908–1913) журналының нашире һәм мөхәррире була, «Вакыт», «Йолдыз» газеталары, «Шура» журналы белән хезмәттәшлек итә.

[5] Шиһап (Шиһабетдин) Шәрәфетдин улы Әхмәров (1882–1966) – педагог, журналист. 1908–1918 елларда Казанда «Сабах» нәшриятында эшли, җаваплы вазифалар башкара, бер үк вакытта 1913–1914 елларда «Мәктәп» журналы мөхәррире.

6. **«Ак юл».** Балаларга каратылган бер журнал булып, 1913 елның 15 апрелендә Фәхрелислам Агиев[1] тарафыннан Казанда чыгарыла башлады.

7. **«Мөгаллим»**. Педагогия журналы. Нашир һәм мөхәррире – Хәсән Гали. 1914–[19]15 елда чыга[2].

8. **«Хокук вә хәят».** 1913 ел Казанда чыга. Мөхәррире – Шәйхегаттар Иманаев[3].

Боларның һәммәсенә каршы татар карагруһлары, мөтәгассыйб руханилар тарафыннан монархист, фанатик, консерватор бер журнал[4] чыгарылды. Журналны чыгаручы да татар либераль буржуасының короле җәдитче Гани байга каршы булган аның зур улы – кадимче Вәли мулла Хөсәенов[5] иде. Журнал 1906 елда 31 декабрьдә чыга башлады. Рәсми мөхәррире Фәезхан Давыдов булды.

«Бу атналык журнал сәяси карагруһлар белән бергә Көнчыгыш искелекләренең, кадимчелекнең дә органы иде. Монда патша һәм аның иске тәртибе белән бергә иске дин, иске схоластика, иске мәдрәсә, иске программа яклана. Һәммә яңалыкка, реформаларга,

---

[1] Фәхрелислам Нигъмәтулла улы Агиев (1887–1938) – журналист, педагог, язучы. 1907 елдан башлап «Аң», «Мәктәп» журналларында, «әл-Ислах», «Кояш», «Йолдыз», «Бәян әл-хак», «Ил» газеталарында мәкаләләрен һәм хикәяләрен бастыра. Балалар өчен рәсемле «Ак юл» журналының нашире. Журнал милләтнең терәге булырдай укымышлы, югары әхлакый сыйфатларга ия булган буын тәрбияләүне максат итеп куя, балаларны милләткә хезмәт итәрлек итеп үз-үзләрен камилләштерергә чакыра. Гаиләдә һәм мәктәптә балалар тәрбияләү проблемаларын күтәрә, балалар өчен язылган шигырь һәм проза әсәрләрен, рус һәм чит ил классик язучыларының әсәрләрен тәрҗемә итеп бастыра. «Ак юл» 1916 елның 22 гыйнварына кадәр Казанда айга ике тапкыр татар телендә нәшер ителә, барлыгы 74 саны чыга.

[2] Биредә төгәлсезлек киткән. «Мөгаллим» журналы 1913 елның октябреннән 1914 елның 15 апреленә кадәр Оренбург шәһәрендә татар телендә аена ике тапкыр чыгып килә, барысы 9 саны дөнья күрә. Татар башлангыч һәм урта мәктәп укытучыларының күбесе өчен алыштыргысыз ярдәмлеккә әверелә.

[3] Шәйхаттар Хәсән улы Иманаев (1875–1939) – хокук белгече, филолог. Барысы ун саны дөнья күргән «Хокук вә хәят» журналының нашире һәм мөхәррире, «Бәян әл-хак» газетасының соңгы мөхәррире (1914). «Мөселман», «Имам», «Нашир» псевдонимнары астында яза, туган тел, милләтләрнең тигезлеге, кеше хокукы, татарларның хокукны белү дәрәҗәсе мәсьәләләрен күтәрә. «Төрек-татар теленең фәнни грамматикасы тәҗрибәсе» («Опыт научной грамматики турецко-татарского языка», 1910) һәм «Татар теленең нәхүе һәм сарыфы» (1910) исемле китаплар авторы.

[4] Сүз 1906 елның 31 декабреннән 1918 елның февраленә кадәр Оренбург шәһәрендә татар телендә нәшер ителгән, барлыгы 555 саны дөнья күргән атналык сәяси, дини һәм әдәби «Дин вә мәгыйшәт» журналы турында бара.

[5] Мөхәммәтвәли Габделгани улы Хөсәенов (1871–1933) – Оренбургның 1 нче мәчете имамы, «Вәлия» мәдрәсәсе мөдире, «Дин вә мәгыйшәт» журналы нашире, басмаханә иясе.

җәдитлеккә, театрга, рус-яурупача киенүгә, Яурупа гыйлем, мәдәниятенә каршы көрәш алып барыла иде. Бу журнал шул типны, реакция, сугыш вакытларында саклап, Февраль-Октябрьгәчә алып килде. Бу – җимерелгән, үзенең ролен бетергән, мәйданны буржуазиягә тапшырып җиңелгән иске феодализм калдыгының актык тыпырчынуы иде. Моның фикере, материалы гына түгел, тел-өслүбе, имлясы да искечә иде» («Татарлар арасында революция хәрәкәтләре», Галимҗан Ибраһимов, 220–221 битләр).

Моңа караганда сул тәрәккыйчерәк, ләкин тегеләргә («Шура» белән «Аң»га) караганда күп уң позициядә барган «әд-Дин вә әл-әдәп»[1] журналын да монда теркәп үтәргә кирәк. Моның нашир һәм мөхәррире Галимҗан Баруди иде.

Көлке журналларыннан да «Ялт-Йолт»[2], «Чүкеч»[3] (1906 елда Оренбургта Тимерша Соловьев тарафыннан чыгарыла), «Карчыга»[4] (Оренбургта), «Яз»[5] (Оренбургта), «Уклар»[6], «Туп»[7],

[1] «Әд-Дин вә әл-әдәп» – 1906 елның 17 мартыннан 1917 елга кадәр (1908–1913 елларда чыкмый тора) Казанда татар телендә атнага өч тапкыр нәшер ителгән әдәби-дини журнал. Барлыгы 122 саны дөнья күрә. Журналның зур өлешен дини-фәлсәфи проблемаларга багышланган материаллар тәшкил итә, ислам тарихы, шәригать кануннарын үтәү нечкәлекләре, дини бәйрәмнәр (Корбан, Ураза, Мәүлид һ. б.) турында сөйләнелә. Мәктәпләр һәм мәдрәсәләр проблемалары карала, татар милли мәгариф системасы Франция һәм Американыкы белән чагыштырыла, шәкертләрнең үз хокуклары өчен хәрәкәтләре яктыртыла, җәдитчелек турында мәгълүматлар китерелә. Татар мәдәниятенең күренекле вәкилләренең тормышы һәм эшчәнлеге турында материаллар урнаштырыла.

[2] «Ялт-Йолт» – 1910 елның 15 маеннан 1918 елның июненә кадәр Казанда татар телендә нәшер ителгән рәсемле сатирик журнал. Мөхәррире – Ә. Урманчиев, җаваплы сәркатибе – Г. Тукай, ул баш мөхәррир вазифасын да башкара.

[3] «Чүкеч» – 1906 елның 22 июненнән 1910 елның мартына кадәр Оренбург шәһәрендә татар телендә нәшер ителгән иҗтимагый-сәяси, әдәби, рәсемле сатирик журнал.

[4] «Карчыга» – Оренбург шәһәрендә татар телендә 1906 елның 25 сентябреннән 1907 елның июненә кадәр барлыгы 9 саны чыгып өлгергән айлык сатирик-юмористик, иҗтимагый-сәяси журнал. Нашире һәм мөхәррире – Ш. Мөхәммәдев. Революцион-демократик идеяләрне пропагандалауны үзенә максат итеп куя. Журналның идея-тематик эчтәлегенә «Урал» газетасы мөхәррире Х. Ямашев зур йогынты ясый.

[5] «Яз» – 1907 елның мартында Оренбург шәһәрендә 2 саны чыгып калган рәсемле иҗтимагый-сәяси, әдәби, юмористик һәм сатирик журнал. Нашире һәм мөхәррире – Й. Мозаффаров.

[6] «Уклар» – 1906 елның июненнән ноябренә кадәр Уральск шәһәрендә татар телендә нәшер ителеп, 6 саны чыгып калган рәсемле айлык сатирик журнал.

Нашире һәм мөхәррире – К. Мотыйгый, фактик җитәкчесе – Г. Тукай. К. Мотыйгый басмаханәсендә басыла. Күп язмаларның авторлары – Г. Тукай һәм К. Мотыйгый, шулай ук Петербургның «Стрела» журналыннан да тәрҗемәләр урын алган.

[7] «Туп» – 1907 елның мартыннан 3 апреленә кадәр Әстерхан шәһәрендә татар телендә нәшер ителеп, барысы 3 саны чыгып калган рәсемле сәяси, әдәби, икътисади һәм сатирик журнал. Нашире – К. Иримбитов, мөхәррире – Х. Гомәров, фактик мөхәррире – М. Галәү.

«Яшен»[1] (1908 елның август башында Галиәсгар Камал тарафыннан чыгарыла башлый), «Акмулла»[2] (1912 елда Троицкида чыга башлый, нашир һәм мөхәррире – Хәбибрахман Ганиев), «Кармак»[3] (нашир һәм мөхәррире – Мәхмүт Галәэтдинов[4] булып, Оренбургта 1914 елда чыга башлый) журналларын да өстәсәк, татар буржуазиясенең җәмәгатьчелек әдәбиятының күренеше тәмам булыр.

Бу гәзит-журналлар эчендә Февраль революциясе алдыннан дәвам иткәннәре Оренбургта – «Вакыт», Казанда – «Йолдыз», Мәскәүдә – «Сүз», Уфада «Тормыш» иде. Журналлардан «Шура» белән «Аң» булды.

1916 ел татар матбугатына ун ел тулу уңае белән рус дөньясында татарда гәзитчелек һәм татар гәзитләре турында «Русские ведомости» гәзитендә язган мәкаләсендә профессор В. Гордлевский[5] шушы түбәндәге тарихи әһәмиятле фикерләрне язып үткән иде: «Бу бәдбәхет гөнаһ дөньясына җирәнеп карау схоластикасының идеалы XIX гасырның соңгы яртысында игътибардан төшеп, татарлар арасында Яурупа мәдәниятенә игътибар белән карау дәвере башланды. Алышыну татарларның сәүдә вә дини мәркәзләре булган Казаннан башланды. Вә милли барлыкны һәлакәттән саклауга чакырган нидалар[6] ишетелә башлады. Беренче сүз 1902 елда вафат булган вә иске мәдрәсәләр тәрбиясе белән генә җитешкән Габделкаюм Насыйридан ишетелде. 1880 елда “Таң йолдызы” дигән бер татар гәзите чыгарылырга теләнсә дә, ул хосуста булган өмиден мәңгегә үзе белән алып китте. Мәрхүмнең ул юлдагы өмиден 1883 елда Бакчасарайда

[1] «Яшен» – 1908 елның августыннан 1909 елның 24 июненә кадәр айга ике тапкыр Казанда татар телендә нәшер ителгән сатирик журнал. Нашире, мөхәррире һәм рәссамы – Г. Камал. Журналны оештыруда Г. Тукай, Ф. Әмирхан катнаша. Барлыгы 10 саны дөнья күрә.

[2] «Акмулла» – 1911 елның 15 июленнән 1916 елның 29 гыйнварына кадәр Троицк шәһәрендә (Оренбург губернасы) татар телендә айга ике тапкыр нәшер ителгән рәсемле сатирик журнал. Барлыгы 51 саны дөнья күрә. Журнал татарларның иҗтимагый тормышындагы җитешсезлекләрне, иске карашлы дин әһелләрен, ялкау, гамьсез, надан шәкертләрне көлке утына ала. Сәяси вакыйгаларга карата урталык позициясендә тора.

[3] «Кармак» – 1915 елның гыйнварыннан 1917 елның сентябренә кадәр айга ике тапкыр Оренбургта татар телендә нәшер ителгән әдәби-сәяси сатирик журнал. Нашире һәм мөхәррире – М. Галәү.

[4] Мәхмүт Галәү (Мәхмүт Галәветдин улы Мәрҗани, 1886–1935) – язучы, журналист, тәрҗемәче. 1914 елда үзенең 1918 елга кадәр эшләп килгән «Белек» нәшриятын ача һәм анда «Кармак» журналын, фәнни-популяр брошюралар, уку-укыту әсбаплары һәм дәреслекләр редакцияли һәм бастыра.

[5] Владимир Александрович Гордлевский (1876–1956) – рус шәркыятчысы.

[6] Нидалар – өндәүләр.

чыга башлаган “Тәрҗеман” беркадәр төгәлләмеш исә дә, ярым ясалмыш телдә булган ул гәзит бер кыйсем[1] зыялылар арасыннан үтә алмады. Вә гавам халкы арасына яңа фикер тарата алмады. Ильясов, Әхмәдов вә гайреләр Казанда гәзит чыгарырга сорап йөрсәләр дә, аларга бик кыска гына манигъ җавабы бирелде.

Ниһаять, 1905 ел 17 октябрь манифесты Русиянең бөтен әхвәле сәясиясенә зур тәэсир биргән кебек, татарларга да тәэсир бирде. Вә дәгъва вәкиле Алкин “Казан мөхбире” исемендә русча вә татарча бер гәзит чыгарырга рөхсәт алды. Башта татар язучылары шул гәзит тирәсенә җыелсалар да, сәяси карашлары сәбәпле, аның язучылары бик тиз таралыштылар. Шул елда ахунд Баязитов тарафыннан Петербургта “Нур” исемле татар гәзите чыгарыла башлаган булса да, руханилар нөфүзенә (клерикальлеккә) хезмәт итәргә теләгән ул гәзит игътибарга кермәде. “Казан мөхбире” шөгурлы[2] кадет Акчуринның кулында вә аның кебекләрнең нашире әфкяре булырга теләгәнгә, “таңчылар” дигән фирка үзләре тарафыннан “Таң” гәзите чыгара башладылар. Соңра бер мәсләк билгеләмәүдә үзенең мәгъзурын[3] күрсәткән “Йолдыз” һәм ике айдан соң Оренбургта “Вакыт” чыга башлады.

Татар гәзитләре һичбер вакытта да Русиянең гомуми китешеннән аерылып яшәмәделәр һәм күзәтмәделәр. Боларның һәркаюсы Русиянең гомуми китеше белән укмашып барырга вә бергә тәрәккый итәргә телиләр. Болар Русиянең гомуми хәятын уртаклашалар.

Татар матбугаты ун ел эчендә бик зур хезмәтләр күрсәтте: инде татарның мәктәп вә мәдрәсәсен төзәттеләр. Көтепханәләр ачтылар. Вә татар яшьләренең дистәләп кенә түгел, йөзләп гимназияләргә вә дарелфөнүннәргә тулуларына сәбәп булдылар. Башта татар матбугатының укучысы бер яки ярты меңнән узмый иде. Хәзердә 25 меңләп укучысы бар.

Шулай итеп, 1905 ел татарлар өчен яңа дәвер, яңа тормышның битен ачты. Хәзердә татар матбугатының аш-су һәм һава белән бер дәрәҗәдә кирәкле бер нәрсә икәнен игътираф итәләр[4]!» («Тормыш» гәзите, 401 нче сан, 1916 ел).

[1] Кыйсем – *биредә:* төркем.
[2] Шөгурлы – акыллы, аңлы.
[3] Мәгъзурын – әһәмиятен.
[4] Игътираф итәләр – таныйлар.

**Татар пролетариатының җәмәгатьчелек әдәбияты.** 1905 ел революциясе белән татар буржуазия хәрәкәтенә каршы татар пролетариаты хәрәкәте кузгалган, аның юлбашчылары да кемнәр булганын югарыда күреп үткән идек. Менә бу хәрәкәт үзенең җәмәгатьчелек әдәбиятын, үзенең матбугатын да тудырып калдырды.

Хөсәен Ямашев белән Сәйфетдинов, Моратов татар пролетариатының беренче идеологлары, каһарманнары булган шикелле, ул сыйныфның беренче җәмәгатьче мөхәррирләре шулар эченнән чыгып, югарыда әйткәнебезчә, 1907 ел Оренбургта «Урал» гәзите чыгара башладылар. Бу гәзит татар дөньясында аңарча күрелмәгән бердәнбер баш орган – большевизм органы иде. Ул татарлар арасында беренче мәртәбә большевизм идеологиясен таратучы, шуны татарга бер системга, билгеле бер тәртипкә куеп бирергә тырышучы, шул идеология флагы астында бөтен татар пролетариат җәмәгатен оештыру юлында буржуазия төркемнәре белән нык көрәш алып баручы беренче пионер булды.

Болар, шул ук «Урал» гәзитенә кушып, татар пролетариатының сәяси әдәбиятын тудыруның берничә нигез ташларын да салып калдырдылар.

1. «Төрле милләтләрне җәберләү кемгә кирәк? (кечкенә кулда 23 бит).

2. «Гомуми сайлау правасы турында».

3. «Русия социал-демократлар партиясе ул халык өчен нәрсә булдырырга тырыша?» (22 бит).

4. «Эшчеләрнең котылуы үзләренең эше булырга тиеш» (кечкенә кулда 35 бит).

5. «Безнең якында булдырырга теләгән нәрсәләребез һәм төп максудыбыз» (зур кулда 45 бит).

Бу рисаләләрдә һәм гәзитнең кайбер мәкаләләрендә, Галимҗан Ибраһимов әйткәнчә, «берничә эздән меньшевизм зәхмәте кагылып китә» торган «аяк тайган урыннары» булса да, һәрхәлдә, «тактика, программа мәсьәләсендә социал-демократ большевиклар юлы белән барганлыклары күренә. Ямашевның баш мәкаләләрендә, Галимҗан Сәйфетдиновның зур мәүзуглардагы фельетоннарында бу принциплар нык саклананалар. Тәрҗемә кылып чыгарган китапларында да шул нигездән баралар. Шундыйларны саклыйлар». Әмма боларның «ара-тирә күрелгән меньшевизм хаталары әһәмиятсез,

иттифакый моментлар иде» (Галимҗан Ибраһимов – «Татарлар арасында революция хәрәкәтләре», 96–97 бит).

«Үзенең принципларында нык тору, берничә моменттан башкада һәммә мәсьәләләрне революционер социал демократия нигезләре буенча аңлату, һичбер турыда һичбер юлсызлыкларга аяк басмау кебек хасиятләр ягыннан «Урал» гәзите, шөбһәсез, татар дөньясында һәм беренче иде һәм аерым югары урын тота иде».

«Урал» гәзите һәм «уралчылар»ның бу урында үзләренең алган юлларын да ныклап күрсәтүче бер фактны да әйтеп үтик. Болар, «таңчылар» кебек «Иттифакы мөслимин» партиясе белән бергә катышып эшләү түгел, аларның күләгәсенә дә якын бармадылар. Аларның һичбер төрле җыелышларына катышмадылар, аларга тәмам протест игълан кылдылар, алар белән бөтен мөнәсәбәтләрне кистеләр. Һәрвакыт аларга каршы ныклык, тотрыклы каршылык күрсәттеләр.

Хәтта аларның болай итүләре өчен Гаяз Исхакый бераз үпкәләп тә алды: «[190]6 елда Мәкәрҗә съездында җыелган халык “Мөселман иттифакы”ның программасын мөзәкәрә итәчәк булса да, мөнәкъкыйд[1] сыйфаты белән дә шунда “уралчылар” килмәделәр вә шул мәҗлесләрдә йөрүне, сөйләүне файдасыз табып, шул зур съездга – эш ягыннан булмаса да, фикер ягыннан бик күп хезмәт иткән съездга катышмадылар вә шундагы фикер, мәсләк тартышуында, халкыбызга “булачак”ны, “мөмкин”не, “хыял”дан аерып бирүдә “таңчылар”ны ялгыз калдырдылар» («Сүз», 1916 ел, 7 нче сан).

Ләкин аларның бу үпкәләүләре «уралчылар»ның шунда катышып, үз нөфүзләрен йөртергә тырышмауларыннан түгел, бәлки «иттифакчылар» белән «таңчылар»ның вәкилләре бергә утыралар иде» һәм «таңчылар» да – бу ел гына тагундан[2] качкан кебек качылган «таңчылар» да – шул мәҗлестә бер хакыйкый әгъза булып эшлиләр иде» булганлыктан, «уралчылар»ның да, «таңчылар» шикелле, «Иттифак»ның бер әгъзасы булырга теләмәгәнлекләреннән һәм аларга баш-аяклары белән каршы булганлыкларыннан иде. Гаяз үзенең югарыдагы сүзләрен әнә шуның өчен кайгыру йөзеннән язды.

---

[1] Мөнәкъкыйд – тәнкыйтьче.

[2] Тагундан – чума авыруыннан.

## 2. Әдәби тел

### *Гамәли як*

### 1905–1907

**Революция һәм реакция көннәрендә телдә ике агым көрәше.** Беренче дәвердә без әдәби телдә төркчелек, татарчылык агымнары белән танышып үткән идек. 1905 ел белән күтәрелгән матбугат һәм әдәбиятта шушы агымнар янә бик кызулык белән көрәш башладылар. Ләкин инде төркчелек юк иде. Мәйданда Гаспринский һәм Ризаларның төркчелеге белән Каюм Насыйриларның татарчылыгы тартыша иде.

1905 ел революциясе көннәрендә бигрәк вакытлы матбугат шаулады. Революциядән элекке карт әдипләр булсын, революция белән туып күтәрелеп чыккан яшь каләмнәр булсын – әдәби әсәрләрен шунда бастыралар, яшьләр дә беренче әдәби йөзләрен әле гәзитләр аша күрсәтәләр, шулар аркылы тәҗрибә эшләрен аткаралар иде. Ә шуларның һәммәсен җыеп, тикшереп караганда, боларда, үзләре дә сизмәстән, телдә ике әдәби агымның тартышы барды. Казан гәзит-журналларында (монда да бәгъзе бер истисна[1] бар) каюмчылык, татарчылык кыздырылса, Петербургта («Өлфәт» кебек) һәм Урта Азия чикләрендә (Оренбургта «Вакыт», «Шура», Уральскида «әл-Гаср әл-җәдит» кебекләр) төркчелек белән сугарылып баралар иде. Боларда язылган мәкаләләрдә дә, хәбәрләрдә дә, шигырь һәм хикәяләрдә дә шулай иде.

Телдә болай төркчелек агымын алып баручылар ике төрле тип халык иде. Берсе – Риза һәм Фатихлар, Рәшид казыйлар, Мусалар шикелле, шуны төп максат итеп аңлап, белеп алып баручылар; икенчесе дә – госманлы (Анатоли төркләре) әдәбиятын укып килеп, шул юлда азмы-күпме яза алу күнегүе (тәмрин) ясап өлгергәнлектән, шулардан әдәби үрнәк ала килгәнлекләреннән һәм шуның өстенә тегеләрнең болар өстеннән тәэсир күрсәтеп торуларыннан гына эшләүчеләр иде. Болар әз генә бер имкян[2] табу белән яисә татарча язуга әз генә күнегү, аннан бераз гына әдәби үрнәкләр күрү белән, тизме-әкренме, һәрхәлдә, татарчылыкка авышачак иделәр. Каюм сызыгына, Каюм оясына якын торган язучылар, бигрәк тә Каюм казанында яшәп, шул казанда кайнаучылар ул якка тизрәк, җиңелрәк авыштылар.

[1] Истисна – чыгарылма.
[2] Имкян – мөмкинлек.

Яшь каләмнәргә бу турыда Каюм Насыйри, Ильяси, Фатих Халиди әсәрләре һәм «Чистай комедиясе» кебек бәгъзе гавами татарча әдәби әсәрләр беренче үрнәк булдылар. Шулар өстенә бигрәк тә Галиәсгар Камал, Гаяз Исхакый әсәрләре һәм Фатих Кәриминең беренче хикәяләре бу турыда яшьләргә тагын да якыннан торып, тагын да үтемлерәк йогынты ясыйлар иде.

Гәрчә үзе (бигрәк тә мөхәррире Һади Максуди мәкаләләре) гамәлдә һаман төркчелек белән татарчылык арасында буталса да[1], һаман әле, татар теле дип әйтергә куркып, «"Йолдыз" – казанидыр», «"Йолдыз" – җәридәи төрктер» дип, «төрки теле», «казан төркисе» дип йөртсә дә, бу тик бер аның сәясәте генә иде. Төбендә, ул, һәрхәлдә, татарча әдәби телне идеал итеп алган, шуңа омтыла башлаган иде. Сәяси эшләрдә мәсләксезлекне үзенә мәсләк иткән «Йолдыз» бу турыда мәсләксез булмады.

Чыннан да, тел мәсьәләсенә гамәли яктан да, нәзари яктан да аерым мәсьәлә итеп карап, ахыр гомеренә кадәр (тукталганчы) шуңа күбрәк игътибар итүче, үзен дә шул мәсьәләләр өчен урынны башкаларга караганда күбрәк бирүче гәзит «Йолдыз» булды. Бу – «Йолдыз»ның абруе күтәрелергә, аның өчен язучы каләмнәр табылырга бер сәбәп иде.

Әдәби телдә гамәли яктан белеп, аңлап татарчылык нигезенә бина утыртучы гәзитләрдән бигрәк «Таң» белән «Урал»ны, «әл-Ислах»ны, «Азат халык»ны әйтергә кирәк. Шулар өстенә көлке журналларын кушарга тиешбез.

Шулай да әле татар әдәби теле, гомумән, гәзитләрдә революция һәм реакция көннәрендә, имлясы шикелле үк, һаман чуар тел булып барды. Буталчык, тотрыксыз булды. Татарчылык юлындагыларда да әле төркчелек, госманлылык йогынтысы көчле иде. Болар да, никадәр тырышсалар да, аннан тиз генә котылып чыга алмадылар. Шуның өчен бер үк гәзиттә төрле үк тел белән язылган мәкаләләрне, хәбәрләрне күрү мөмкин иде.

Шуның өстенә боларда яңа мәфһүмнәр[2] өчен Яурупа-рус сүзләрен алуда билгеле бер чик куелмыйча, аларны теләгәнчә кертә бирүгә дә артык каршылык сизелми иде. Бу мәсьәләдә аларның

[1] «Йолдыз»ның телдә төркчелек белән татарчылык буталчыгыннан мисал: «Һәр милләт үзенең культурный тәрәккыяте өчен үзе иҗтиһад кылмаклыгы тәкъсим мөсагыйд вә тәүзигъ әгмаль җәһәтендән дә мөнасибдер» (беренче ел, 25 нче сан). *(Авт. иск.)*

[2] Мәфһүмнәр – төшенчәләр.

«Йолдыз»дан аерылган бер яклары да шушы ноктада күрелде. Ул, яңа мәфһүмнәр өчен сүз алганда, татарчада булмаганда, гарәпчә, төркчәдән алуны алга куйса, болар Яурупа-рус сүзләрен алга сөрделәр. «Урал»да без бу хәлне бигрәк тә ачык күрәбез.

Гәзит телләренең әдәби эшләнеп, билгеле бер юлга төшеп яхшы гына утырып җиткәнче, байтак вакытлар үтте. [19]12–[19]15 еллар арасында инде татар гәзитләренең телләре гәзит теле булу ягыннан азмы-күпме бер сызыккарак тартылып килә иде.

Гомумән, әдәбиятта татарчылыкның төркчелеккә каршы гамәли яктан соңгы кискен өстенлеге (катгый галәбәсе[1]) дә 1912 елларда булды. Моннан соң инде без шушы өстенлекнең тәэсире белән хәтта Риза шикелле төркчеләрнең тел-өслүбләрендә дә татарчылык процессының күп артканын күрәбез.

Телдә гел тискәрелек күрсәтеп баручы мөхәррир Муса Биги булды. Татар әдәбиятында үзенә аерым бер жаргон тудырган, ләкин сукдырмалы, куәтле бер өслүбкә, шиддәтле[2] бер аңлатуга ия булган бу дини «фәйләсуф» гәзиттә язган мәкаләләрендә дә, аерым китап итеп язган әсәрләрендә дә ахыр чиккәчә шул ук кара-чуар телендә дәвам итте. Ләкин аның теле ялгыз дин галимнәренә, хәзрәтләргә, гарәпчә, төрекчә укыган мөгаллимнәргә һәм гарәп, фарсы, госманлы, беразда татар телләрен – һәммәсен яхшы белүче тел белгечләренә генә аңлашыла торган бер сыйфатта иде. Масса аның ни әйткәнен дә аңламады. Аның фикерләренең әлифе түгел, бер ноктасы да аның үз теле белән татар халкының колагына якын бара алмады.

**Матур әдәбиятта чуар тел.** Госманлы тәэсире мәгънәсе белән әдәби телдә чуарлык башта матур әдәбиятта да барды. Мәҗит Гафури, Тукай, Зариф Бәшири, Думави кебекләрдә дә боларны күрдек.

### Мисаллар

*Мәҗит Гафуридан:*

Галәм хазир фирдәвесе мәгъмүрият[3],
Һәр кавем табып алды мәдәният.
Мәүланең кодрәтләре заһир[4] улып,
Аеруча дөньйа вирде зиннәт.

[1] Галәбәсе – җиңүе.
[2] Шиддәтле – көчле.
[3] Галәм хазир фирдәвесе мәгъмүрият – галәм булды җәннәт бинасы.
[4] Заһир – ачык.

Руи зәминне зиннәтләян[1] Хак Тәгалә,
Мәстүр[2] булмыш серләр заһир улды халия[3].
Мәүланең кодрәтләрен хис итмәян,
Мәҗнүндер яисә сабый бала.
Мәүламез хисапсыз идәр ихсан[4]
Хис итмәян бу ихсаннан габый[5] инсан.
Мәүламез инсанә җәүһәр сонды[6],
Күп милләтдән адәмләр кулын сузды.
(«Себер тимерьюлы», бит 4)

Бу җиһанда һичбер әшъя
Күрмәдем үзгәрмәгән.
Һичбер вакыт тәгыйире кабил
Булмаган Коръән, беләм.
(«Яшь гомерем»нән)

Вә:

Бу шәүкәтнең ливасын[7] кулга алмак
Тәвәкъкыф әйләмешдер[8] иҗтиһадә.
Җәмигъ максудлары кулда идәмез
Дәвам итсәк җәһаләтлә җиһада. <...>

Гыйлемсезләр җиһаны вар идән аласыны белмәз,
Шу гыйлем саясендә бән бер Алланы да бар белдем.
(«Милләт мәхәббәте»ннән)

*Тукайдан:*

И каләм! Китсен әләм, сән әйлә безне шадыман;
Без дә саяңдә улалым тугры юла кадыман.

Без өсәраи, көсаляи дә сәүкъит һиммәтә;
Кыйл тәрәххем милләтә[9] – калдырма, зинһар, зилләтә. <...>

И каләм, сәндин кәлер һәп бәхтемез, икъбалемез;
Бәкләнәр дүрт күз илә лотфыңда истикъбалемез.

[1] Руи зәминне зиннәтләян – җир йөзен зиннәтләгән.
[2] Мәстүр – яшерен.
[3] Халия – шул вакытта.
[4] Ихсан – ярдәм.
[5] Габый – ахмак.
[6] Сонды – бирде.
[7] Шәүкәтнең ливасын – көчнең байрагын.
[8] Тәвәкъкыф әйләмешдер – тукталыш ясар.
[9] Чыганакта төгәлсезлек киткән: «һиммәтә» дип язылган.

Кичмәсен караңгылыкта маһемез һәм салемез;
Гафилез без, җаһилез – вай халемез, вай халемез![1]
(«И каләм!» дигән шигыреннән)

Шигърә чук итдем һәвәс кальбем илә, җанымла бән,
Чөнки итдем ифтиракъ җанымла, җананымла бән. <...>

Агъладыб китдең бези бер залимә, и залимә!
Әкләнеркән нуры хөснең – нуры мөҗгяныңлә бән.

Дәм-бә-дәм илһам идәр дәрдең бәңа гыйльмелгаруз;
Нә кадәр яздымса – яздым җөмлә илһамыңла бән[2].
(«Ифтиракъ соңында» дигән шигыреннән)

*Зариф Бәширидән:*

«Әтрафымызда улан имам вә голәмаларымыз улсын гәзит вә журнал алмаюрлар вә укымаюрлар, хәтта ки гәзит вә мәҗәллә укымагый харам диюрләр»[3].

* * *

3 нче номер «әл-Гаср әл-җәдит»е күрдем, хөснед-дөнья вәл-ахирә улан[4] мөэмин кардәшләремезнең күзене ачмая чалышан[5] журналыңызы гаять шатлыклы милләте мөхәммәдияи исламия[6] исеменә бар вөҗүдем илә тәбрик идәрәк афәрин вә уралар илә алкышлаюрым милләтемезнең өмиде истикъбале[7] сезнең кеби рәһбәре

---

[1] И каләм! Китсен газап, ит син безне шат;
Без дә синең аркаңда туры юлга басыйк аяк.
Без әсирләрне, ялкауларны да зур эшкә этәр;
Милләткә мәрхәмәт ит, – зинһар, хурлыкка калдырма. <...>
И каләм, бәхет һәм якты киләчәгебез синнән килер;
Якты киләчәгебез дүрт күз белән рәхмәтеңнән көтелә.
Үтмәсен караңгылыкта айларыбыз, көннәребез,
Гамьсез дә без, надан да без – вай хәлебез, вай хәлебез!

[2] Бик һәвәсләндем шигырьгә күңелем, җаным белән,
Чөнки аерылыштым мин җаным-җанашым белән. <...>
Син, җылатып безне, бер явызга киттең, и явыз!
Гүзәллегеңә сокланып кына яшәгәндә без.
Һәр сулуда шигырь илһам итә сине сөюем,
Күпме язсам да язам тик илһамың белән синең.

[3] Тирәбездәге имам һәм галимнәребез газета-журналлар укымыйлар, хәтта газета һәм журнал уку хәрәм, диләр.

[4] Хөснед-дөнья вәл-ахирә улан – дөнья вә ахирәт күрке булган.

[5] Чалышан – тырышкан.

[6] Милләте мөхәммәдияи исламия – мөселман милләте.

[7] Өмиде истикъбале – бәхетле киләчәк өмете.

хакыйкать[1], вә әрбабе мәгариф улан[2] остазларымызың мөнәүвәр[3] каләмләрендәдер әлдә форсат вар икән[4], милләтемезе бәхре җәһалеттән чыкармая[5] юл араңыз[6], журнал вә гәзитләреңез илә әфкяре нафигалар[7] мөнтәшәр улып[8], гыйлем, мәгариф йыгачлары[9] яфрак ярыб, сачәк атыб, безләре хуш исләре илә сәрхуш әйләсен («әл-Гаср әл-җәдит», 7 сан, 1906 ел).

Бел, суфилар төнлә торып –
Әйләюрмиде тәгать?
Гәрчә өмид багчасында
Васыл җәннәт улмаса. <...>

Кабды кальбемә нәтиҗәэ –
Гыйшык: «атыш парә».
Җисем һәлак, җаным вәйран
Улды, шәфкать улмаса!

(«Иртәнге азан» дигән шигырь мәҗмугасыннан, 1909 да басылган)

*Нәҗип Думавидан:*

Икенче сүз илә ошбу капитал дәверенең җәе,
Гаҗәбдер бит карап торсаң, капитал нишләмәс безә.
Тырыш, тырмаш, череп беткел һаман ул якаюр бае,
Өшеп туң да чахот улгыл, һаман эшлә, һаман эшлә,
Ләкин шу шарт илә эшлә: вирерсең байларә мае,
Берәүләр яхшы залларда саф һава иснәп,
Берәүләр җир казыйлар таш кебек тавы,
Берәүләр йоклыйлар мамык түшәк һәм татлы язларда,
Сыгук нидер, кахыт нидер – татымас һич аның җаны.
Берәүләр кан косар эшләп җәһәннәмдәй тишекләрдә,
Язып бетмәс тизүк китмәс бозылмыш бунларың хали.
Язарсың да, сүләрсең дә – һәнүз бер мәнфәгать чыкмас,
Булып торгач бу дөньяның капитал – мөхтәрәм ханы.

(«Эч поша, күңел болгана» дигән шигыреннән)

[1] Рәһбәре хакыйкать – хакыйкать юлбашчылары.
[2] Әрбабе мәгариф улан – мәгърифәт ияләре булган.
[3] Мөнәүвәр – нурлы.
[4] Әлдә форсат вар икән – кулда форсат булганда.
[5] Бәхре җәһалеттән чыкармая – наданлык диңгезеннән чыгаруга.
[6] Араңыз – эзләгез.
[7] Әфкяре нафигалар – файдалы фикерләр.
[8] Мөнтәшәр улып – таралып.
[9] Йыгачлары – агачлары.

**Октябрьгәчә ун ел эчендә әдәби тел.** 1907 еллардан соң әдәби телдә нәгыз, садә татарчылык агымы көч алып, соңгы галәбәсен[1] күрсәтүгә таба омтыла.

Шул ук революция аркасында татарлар арасында көчәйгән татарчылык хәрәкәте әдәби татар телен тазалау, аны чын язма халык – гавам теле итү юлына таба авышу эшләрен нык көчәйтә. Аңарча бик чуар телдә – ярым госманлы, ярым чыгтай өслүбендә язып килгән әдәби көчләр хәзер инде гади татарчылык сызыгына төштеләр. Мәҗит Гафури, Думави, З. Бәшири һәм Тукайлар, элекке жаргоннарын ташлап, нәгыз халык сөйләвенчә язарга тырыша башладылар. Болар эченнән тел-өслүб ягыннан иң алда барганы, шөбһәсез, Тукай булды. Аның 1906 елда язылган югарыдагы «И каләм!» кебек иң чуар-чуалчык теленнән «Шүрәле», «Пар ат» шигырьләрен язу дәрәҗәсенә барып җитү[е] бу тезмәдә җанлы бер рәвештә саф татарча язучылыкта, шөбһәсез, бик зур бер үсү иде. Тукайларны болай сафлык юлына төшергән төп сәбәп, әлбәттә, революция җимеше иде. «Әгәр 1905 ел җиле исеп, һавабыз башкарып китмәсә иде, ихтимал, Тукаевның кувәи шигъриясе бөтенләй могатталь[2] калыр, яки булса "Урамларда гизәр көн бән бәнагяһ – Тәвәкъкыф әйләдем, улдым агяһ"»[3] (Җ. Вәлиди. «Тукай мәҗмугасы»на язган мөкаддимәсеннән) сызыгында булып калыр иде. Ләкин Тукайның Казанга күчүе бу турыда аңа аерым зур ярдәм итте[4].

Кыскасы, Тукай соңыннан татар теленең тезмә бүлемендә күп шагыйрьләргә үрнәк булырлык, бу юлда бер мәктәп тудырырлык дәрәҗәдә классик бер хәлгә килде. Аның соңгы шигырьләренең тел-өслүбләре бөтенесе шуны ачык күрсәтәләр. Ул татар теленә, нәкъ татар теле, татар өслүбе итеп, тезмәдә беренче мәртәбә аһәң бирде. Аны шыңгырый, яңгырый торган бер тел ясады. Аны сүз белән әйтелгән фикер һәм тойгыларның, тыңлаучыларның миләренә, аларның колак ярыларын имгәтмичә генә түгел, бәлки аны зәвыкландыра-зәвыкландыра, рәхәтләндерә-рәхәтләндерә барып кереп, тыңлаучының ми сизү тамырлары системасында да уйнак, җиңел

[1] Галәбәсен – җиңүен, өстенлеген.

[2] Могатталь – буш, эшсез.

[3] Г. Тукайның «Шәкерт, яхуд Бер тәсадеф» (1906) шигыреннән. Хәзерге әдәби телдә: «Урамнарда гизгәндә, мин кинәт / Туктадым һәм искәрдем».

[4] Бу урында Тукайның соңгы теленнән мисал өчен «Шүрәле»се, «Пар ат»ы, «Сәрләүхәсез»е, «Шагыйрь», «Өзелгән өмид»е, «Утырышу»ы, «Бер татар шагыйренең сүзләре», «Яңа Кисекбаш»ы укылып үтелер. *(Авт. иск.)*

агымлы бер мусыкыйлек[1], шаян бер аһәң тудырырлык бер хәлгә куешты. Шаянлык, уенчанлык, чеметүчәнлек һәм шуның өстенә тагын йөрәкләрне өздереп-өздереп әрнетүчәнлек кебек төрле яктан төрлечә дулкыннар күрсәтә торган төрле рухи хәлләрне саф татар телендә дөрес самими, табигый аңлатып бирә алу кебек хосусиятләрнең беренче ачык үрнәге дә тезмәдә Тукай каләме аркылы күренде. Кыскасы, «Габдулла Тукаев (шигырьләре) теленең садәлеге, өслүбенең матурлыгы, татар тормышын тасвирда маһирлеге хасиятенә малик булалар» («Аң», 21 нче сан, 1913 ел. Ф. Сәйфи-Казанлының «Сәгыйть Сүнчәләй шигырьләре» дигән тәнкыйтьтән).

Шулай итеп, беренче адымнарында «Каләм», «Ифтиракъ соңында» һәм башкалар кебек тезмәләре белән телдә бик түбән баскычтан күтәрелгән Тукай ахырда, күтәрелә-күтәрелә, «татарча иң матур сүзләр сөйләү, татар теленә шигъри төс вә әдәби кыйммәт бәхеш итү[2]»[3] дәрәҗәсенә барып җитте.

Бу – бер. Өстенә, тагын Тукай шигырьләре аркылы татар теленә багышлаган менә шушы түбәндәге хосусиятләрне иң әһәмиятле бер хосусият итеп өстәргә кирәк: «Тукайда сүзләр бик оста да, шуның белән бергә бик табигый, бик урында сөйләнгән булалар. Әйтергә мөмкин ки, Тукайда сүзләр, чынлап та, аның фикер вә хисләре белән бергә ихтыярсыз туалар. Анда сүз белән мәгънәне бер-берсеннән аерып булмый».

«Шуның белән бергә, Тукайның сүзләре, тәгъбирләре мәгънәгә тәмам тулып, симереп, бүртенеп киләләр. Аның һәрбер сүзе бер яңа мәгънә, яңа хис, яңа куәт вә зәвык күтәреп килә»[4]. Аның сүзләренең ничек тә булса бер яктан йөрәккә чиртүчелек хосусияте бар.

Шагыйрьләрнең шигырьләрен тикшергәндә, аларның сүзләрен, тәгъбирләрен бәреп, чиртеп карау мөмкин булса иде. Көчсез шагыйрьләрнең сүзләре, тәгъбирләре буш савытлар кебек шыңкылдап торганы хәлдә, Тукай сүзләре эчке тыгызланып тутырылган савытларга охшап, дөңгелдәп торган булырлар иде. Кыскасы, Тукай каләме аркылы татар теле, татар сүзләре мәгънәгә күп баетылды, тулды, матурланды.

---

[1] Мусыкыйлек – музыкальлек.

[2] Бәхеш итү – бирү.

[3] Җ. Вәлиди. «Тукай мәҗмугасы»на язган анализы. 1914 ел. *(Авт. иск.)*

[4] «Безнең юл», 8–9 нчы сан, 1923 ел. Мөхәррирнең «Татар шагыйрьләре арасында Тукай» дигән мәкаләсе. *(Авт. иск.)*

«Тукай тезмәдә заманында татарга яңа, садә әдәби бер тел эшләп бирде. Безне җиңел әдәби сөйләргә, садә бер рәвештә әдәби көйләргә өйрәтте. Анда чәчмәдә дә садәлек вә осталык күрәбез[1]. Хәтта чәчмәсе тезмәсеннән дә җиңел вә садәрәк. Соңыннан күп шагыйрьләребез тезмәдә аңа ияреп, аның юлы белән киттеләр, аның тәэсире астында эшләп киттеләр. Яки күпләре, башта аның эзеннән барып, соңыннан үзләренә истикъялият[2] казандылар»[3]. Тукай каләме аркылы бигрәк 5, 7, 11, 12, 15 иҗекле вәзеннәр нык эшләнеп, татар әдәбиятында шуларга гомумилек бирелде. Шуның өстенә ул «Зиләйлүк» вәзеннәрендә шигырьләр язды.

Болар эченнән Укмасый[4] гына башта ук саф авыл татар теле белән язу сызыгыннан хәрәкәт башлаган иде. 1907–[190]8 елларда инде Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов, Сәгыйть Рәмиев кебек татар әдәбият дөньясына килеп чыккан яшь көчле талантлар татар телен эшләү, садәләштерү юлында эшне кыздыра башладылар.

Чәчмә (нәсер)дә татар теленең бу дәвер эчендә чын әдәби татар теле белән эшләнүендә иң зур хезмәт һәм бу турыда башкаларга зур тәэсир ясау Фатих Әмирхан белән Галимҗан Ибраһимов әсәрләре аркылы күренде. Болар беренче адымнарында ук татарча язу ягыннан шулай булган шикелле, аны сәнгатьчә эшләү ягыннан да шундый хезмәтләр күрсәттеләр.

Ләкин бу ике әдип телне эшләүдә ике төрле юл белән китте. Берсе – Фатих Әмирхан әсәрләренең бөтен мәүзугы, мөндәриҗәсе шикелле үк, телен, өслүбен дә буржуа рухына, шуның зәүкына каратып алды. Аның соңгы «Кадерле минутлар», «Хәят», «Урталыкта», «Тигезсезләр»е телдә дә шуның ачык мисаллары иде. Икенчесе – Галимҗан Ибраһимов әсәрләренә мәүзуг, мөндәриҗәләрне ничек ярлылар, эшче-крестьяннар һәм шулар арасыннан урта хәлле крестьяннар

[1] Тукай башта «әл-Гаср әл-җәдит»тә язган чагында чәчмәдә ике телдә язды: госманлыча һәм татарча. Чәчмәдә Тукай башта ук татарча яза ала иде һәм матур гына, ачык кына яза иде. *(Авт. иск.)*

[2] Истикъялият – бәйсезлек.

[3] «Безнең юл», 8–9 нчы сан, 1923 ел. Мөхәррирнең «Татар шагыйрьләре арасында Тукай» мәкаләсе. *(Авт. иск.)*

[4] Укмасый (Миргазиз Габделкаюм улы Зәбиров, 1884–1948) – шагыйрь. Тукай шигърият мәктәбен дәвам итүче буларак билгеле. Беренче шигырьләрен 1905–1907 елларда «Казан мөхбире», «Бәян әл-хак», «Азат», «Йолдыз» һ. б. газеталарда бастыра. «Хатирә, яки Дустларыма сүзләрем» (1906), «Алданма кызыл алмага» (1907), «Миргазиз Укмасый шигырьләре» (1909), «Өмид йолдызым» (1912) шигырь җыентыклары, «Хәлифәлек өчен көрәш» (1917 елда «Сәйяр» труппасы куя) пьесалары, К. Насыйри, Г. Тукай, Ф. Әмирхан турында истәлекләр, әдәби тәнкыйть мәкаләләре авторы.

тормышыннан алса, тел-өслүбендә дә ул һаман шул якка каерды. Татар әдәби телен шуларга якынайта барып, һаман садәләштереп үстерә килү юлын алды. Башта гарәпчәдән ялгыз-ялгыз алынган, масса өчен авыррак булган сүзләрне кулланса да, соңыннан ул алардан да котылу, алар урынында татарчадан сүз табып кую юлына керде. Ахырда килеп, без аның каләменнән матур татар әдәбиятында «Табигать балалары», «Безнең көннәр» (ике табагы 1914 елда басылган иде), «Көтүче» һәм «Карт ялчы» кебек әсәрләрне күргән шикелле, 1909 елда язылып, Октябрьдән соң басылган «Казакъ кызы» (һәм «Кызыл чәчәкләр»е) кебек классик әсәрләрендә инде моның бу юлда соңгы үсеп җиткән югары баскычын күрдек.

«Казакъ кызы», гомумән, сәнгать ягыннан караганда иң югары бер әсәр булган кебек, тел әсасында бу юлда иң саф татарча, иң бай, нык эшләнгән бер нәрсә булды[1].

Фатих белән Галимҗан икесе дә татар әдәби теленә икътисад керттеләр, татар әдәби теленә аңарча күрелмәгән бер матурлык, киңлек бирделәр. Югарыда да әйткәнебезчә, Гаязлар каләме аркылы бу эшләнә алмаган иде. Болар әнә шуны тутырдылар. Ләкин бу ике әдип икесе ике төрле сызыктан китте.

Фатихныкы артык иелмәле-сыгылмалы һәм ясалмарак бер тел – буржуа сәнгать теле белән эшләнгән булса, Галимҗанныкы гаммә[2] кирәгенә, гаммә тормышына терәлеп эшләнгән, ягъни матур һәм шуның белән бергә нык буынлы, акыллы бер тел булды. Теге бигрәк тәкәллеф белән зиннәтләнгән буржуа сарайлары эчендә «господа»лар арасында, йомшак креслолар арасында матур шыңгыратыла торган бер тел булып басылды. Шуның өчен дә ул татар гаммәсе өчен тормышлы бер тел түгел иде. Ул үзенә күп иярченнәр дә алмады дияргә ярый. Ә Галимҗанныкы хезмәт, газап, көрәш-тартыш эчендә эш энергиясе белән туган һәм шуның өчен дә ул эш-энергия дөньясында сөйләнә торган гамәли бер тел булып эшләнде. Шуның өстенә ул ашкыну-шашыну теле дә түгел, уйлану теле, тирән, кискен

[1] Боларның беренче мәртәбә язылган әдәби әсәрләренең теленнән мисал өчен Фатих Әмирханның «Гарәфә кич төшемдә» дигән хикәясе белән Галимҗан Ибраһимовның «Зәки шәкерт» дигән хикәясеннән парчалар укыйлар (Зәки шәкерттән мисал «әл-Ислах»ның 28 нче саныннан алыныр). Бу ике әдипнең соңгы әсәрләренең сәнгатьчә эшләнгән әдәби телләреннән мисал өчен янә Әмирханның «Кадерле минутлар»ы, «Татар кызы» һәм «Халык кызлары» белән Галимҗан Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр», «Ялчы карт», «Көтүчеләр», «Безнең көннәр», «Табигать балалары, «Кызыл чәчәкләр» һәм «Казакъ кызы»ннан сайлап алыныр. *(Авт. иск.)*

[2] Гаммә – халык, масса.

бер акыл теле булды. Әдип үзе каләмен тибрәтә башлаган сәгатеннән алып, шул көнгәчә бик күп уйлый-уйлый дулкынланып үскән кебек, аның теле дә шуның классик бер үрнәге булып чыкты. Тагын да ачык әйтсәк, татар матур әдәбиятында үзенең садәлеге, матурлыгы, самимилеге белән бергә үзеннән фәлсәфи тамырлар җибәреп үсә торган киң, тирән бай бер тел шушы классик әдип каләме аркылы күренде. Шунлыктан башын күп уйлатып ватасы килмәгән бәгъзе берәүләр өчен аның теленең аңлануы авыррак булган чаклары да килеп чыгарга мөмкин. Аның телендәге икътисад һәм тынычлык та үзенә дикъкатьне аеруча каратырлык. Тик бәгъзе вакыт шигъри сыйфатларның күбәеп китүләре күренсә дә, бу тегеңә зарар итәрлек түгел.

Галимҗан Ибраһимов каләме аркылы күрсәтелгән әдәби телнең башкалардан аерымлыгы, югарылыгы, сәнгатьчә оста эшләнгән бер тел икәнлеге турында татар матбугатында ике фикер булмады, тәнкыйтьләрнең һәммәсе дә аның шул хосусиятен игътираф иттеләр[1]. Шулардан берничәсен монда да күреп үтик:

«Галимҗан Ибраһимов – татар язучылары арасында техникасының югарылыгы, өслүбенең шомалыгы, теленең байлыгы ягыннан күптән игътираф ителгән бер язучы» (Ф. Сәйфи-Казанлы. «Кызыл Шәрык» журналы, 3–4 нче сан, 1920 ел. «Матбугат һәм тәнкыйть» дигән мәкаләдән).

«Галимҗан Ибраһимов үзенең әсәрләренең тышкы, өслүб якларына бик дикъкать итә, бу турыда ул уңышлы нәтиҗәләргә ирешә. Аның теле – нәгыз халык теле, ләкин урыны белән бик нәфис эшләнеп чыккан була. Бер яктан, ул – өслүбкә әһәмиятсез карап, ашыгып яза торган Исхаковның киресенчә инде. Ибраһимовның телендә тагын шундый бер артыклык бар: ул, казакъ шивәсенең тар рамкасыннан чыгып, Шәрык яисә Урал, Оренбург шивәләре яки башкорт-типтәр сүзләре белән баета, моны да ул белә торып, аңлап эшли. Шулай ук ул Исхаков белән Әмирханда шулар эчендә булган хәлдә, күп татар язучылары мөбтәля булган[2] кабиләчелек (провинциализм)ны да күрсәтми. Татар теленең көнбатыш һәм көнчыгыш хосусиятләре Ибраһимовта гармонияле рәвештә икесе бергә килеп кушыла алалар» (Җәмалетдин Вәлиди «Очерки истории образованности и литературы Волжских татар. стр. 94, 1923 г.[3]).

---

[1] Игътираф иттеләр – таныдылар.
[2] Мөбтәля булган – дучар булган.
[3] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

Аның әдәби әсәрләрендә генә түгел, гыйльми әсәрләрендә дә шул ук хосусият бар.

Ул аларында да оста, шома, үткен яза. Фикерләрне аңлатуда тулылык, киң[лек] һәм икътисад күрсәтә. Өслүб бик шома, агымлы бара, татар тәнкыйть дөньясында аның телендәге шушы як та ачык әйтелде.

«Галимҗан Ибраһимовның өслүбендә булган үзенә бертөрле җитезлек, агымлылык һәм гармония, гыйльми садәлек өстенә, йөрәк самимилеге катыш ялкынлылык укучыны ихтыярсыз үзенә тартып тора» (Хәйретдин Вәли[1]. «Безнең юл», 4 нче сан, 1925 ел).

«Өченчедән, Г. Ибраһимовның татар телен киңәйтеп, тагын башка әдәби төрки телләр белән дә якынлаша алырлык бер хәлгә китерүе турында түбәндәге фикерләр язылды: «Казакъ кызы» теле ягыннан бик әһәмиятле[2]. Роман, кыргызча гыйбарә төзелешләрен һәм кыргыз шивәсенең күп сүзләрен саклаганы хәлдә, татар телендә язылган. Мөхәррир бу ике телне шул рәвешчә җиңеллек белән бергә куша алган ки, әсәрнең теле үзе шушы һәр ике халыкка (татар һәм казакъка) аңлаешлы булган хәлдә, ул кыргыз колоритына малик» (Газиз Гобәйдуллин мәкаләсе. «Вестник татароведения», № 1–2, 1925 г.[3]). Бу әдәби тел авыр тәҗрибә, авыр тормыш нәтиҗәсе иде. Шуның өчен ул тормышлы бер тел булып эшләнде дә. Татар әдәбиятында зур тәэсир ясады. Тел-өслүбендә аның шәкертләре, иярченнәре дә аз булмады. Совет әдәбиятындагы яшь язучыларның байтагысының телендә дә аның тәэсире ачык күренә.

Татар әдәби теленең чәчмә бүлемендә үсүе өчен Шәриф Камал каләме дә байтак зур тәэсир ясады. Ул татар телендә җиңел, җитез, кыска җөмләле өслүб тудырды. Соңыннан татар телен чәчмәдә киңәйтешүдә Кәрим Тинчурин, Гали Рәхим, Садри Җәлал, М. Галиләрнең[4] азмы-күпме хезмәтләре кушылды.

---

[1] Хәйретдин Вәли (1893–1963) – әдәби тәнкыйтьче.

[2] Тел турында бу фикерләрне язучы Газиз Гобәйдуллин бу романның иң әһәмиятле якларыннан беренчесе итеп аның номадлар – кыргыз-кайсаклар тормышын чиктән тыш ачык матур тасвир итүен, икенчедән, аның хәзерге казакъ-кыргызларны этнография ягыннан тикшерү өчен чиктән тыш кыйммәтле бер әсәр икәнен әйтә. *(Авт. иск.)*

[3] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[4] Мөхәммәт Вәли улы Гали (Галиев) (1893–1952) – язучы, журналист, әдәбият галиме. «Сабан туенда» (1921), «Балалык көннәремдә» (1925), «Кала кешеләре булдык» (1928), «М. Гали әсәрләре» (1929–1931) китаплары, «Теләнчеләр, яки бәхет эзләгәндә» (1936), «Имана» (1939), «Каюм Насыйри» (1945, Х. Уразиков белән берлектә языла һәм Татар академия театрында куела) пьесалары авторы. Тәнкыйди хезмәтләрендә XVIII–XX йөз башы татар әдәбияты тарихы, Г. Каргалый, Г. Утыз Имәни, Г. Курсави, Акмулла, Г. Тукай, Дәрдмәнд, Г. Камал, С. Рәмиев, Ш. Камал, М. Гафуриның тормыш юллары һәм иҗатлары яктыртыла.

Тезмәдә татар теленә Гафури, Тукайлардан соң, ләкин алар юлы белән түгел, үз юлларынча, оригиналь бер сызык белән нык тәэсир ясаучы классик шагыйрьләр Дәрдмәнд белән Сәгыйть Рәми булды. Шулай ук бу вакытларда Сәгыйть Сүнчәләй хезмәтләре кушылды. Тезмәдә Дәрдмәнд теле дә – чәчмәдә Фатих Әмирханныкы шикелле үк, үзенчәлеге эчендә үзе һәлак булырлык дәрәҗәдә нәзек, ләкин Фатих Әмирханныкына каршы, бөтенләй Шәрык рухына манчылган, иске Шәрык нотасына утыртылган ясалма бер тел иде. Шуның өчен татар дөньясында бу да тормышсыз бер тел булды. Бу дәвердә татар теле Шәрык өслүбендә һәм буржуа рухында үзенең бик сонгый[1] музыкальлеген, бу ысул белән тезмәдә сәнгатьчә иң сонгый матурлыгын, аһәңен шушы каләм аркылы күрсәтте. Чыннан да, «Дәрдмәндне гаҗәп аһәң вә гармониясе өчен моталәга итәсең[2]» (Ф. Сәйфи-Казанлы, «Аң», 21 нче сан, 1913 ел – «Сәгыйть Сүнчәләй шигырьләре» дигән тәнкыйтеннән). Татар сәнгать буржуазиясе җитештергән бу көчле талантлы шагыйрьнең аһәң өчен мисал булырлык шигырьләреннән «Кораб»ы белән «Бәлли-бәү»е инде мәктәп балаларына да мәгълүм.

Шуларга «Без»е белән «Хәят»ын, «Бүзләрем маналмадым»ын да кушарга кирәк. Шулай булса да:

Кемгә васләт[3], кемгә өмет нигъмәтен бирде фәләк[4],
Мин өметнең сул кулындан бер сынык нан[5] алмадым!
Кемгә васләт, кемгә өмет?..
Мин сынык нан алмадым!
Кайда бер тау, кайда мәэмүл чишмәи әбелхәят[6].
Тез йөгендем, яшь тамыздым, дәрткә дәрман алмадым.
...Вәйля[7]!..
Дәригъ!
Бүзләрем маналмадым[8].

* * *

Сорды ул гөл кем: «Нидер сәүда?» Дидем: «Сәүдаи гыйшык[9]!»
Тамды гөлләр, түкде ул дөррләр[10]: «Керәм уртагына!..» <...>

---

[1] Сонгый – ясалма.
[2] Моталәга итсәк – укысак.
[3] Васләт – кавышу.
[4] Фәләк – язмыш.
[5] Нан – икмәк.
[6] Мәэмүл чишмәи әбелхәят – булыр дип фараз ителгән мәңгелек чишмә.
[7] Вәйля – ни үкенеч.
[8] Дәрдмәнднең «Бүзләрем маналмадым» шигыреннән.
[9] Сәүдаи гыйшык – гыйшык сәүдәсе, гыйшык уты.
[10] Дөррләр – энҗе бөртекләре.

Очмак өчендер мәхәббәт багына ул гандәлиб[1],
Чәч тарап, көзге карап санкем[2] канаткай кагына. <...>

Ул гасырлар, кем һәнүз[3] көтмәктәдер зәүкый хәят[4],
Шушылардыр бу әсир төшкән килеп чәч багына[5],

рәвешендә язып, татарчылык сызыгыннан чыккан иде. Бу – татар өчен, әлбәттә, тормышлы бер тел, яшәешле бер өслүб түгел иде. Татар гаммәсе, татар пролетариаты өчен әйтмисең дә инде. Татар буржуазиясе үзе үк, әгәр бу сыйныф кулында влас[6] калган тәкъдирдә, бу телдән бик тиз аерылачак иде. Аңа тик югары сыйныф, өйләренә артык бер зиннәт биреп торсын өчен, әллә нинди бизәкле савытлар эчендәге асыл – тормыш өчен кирәге булмаган гөлләр шикелле итеп караячак иде. Чыннан да, аның шигырьләре, теле шикелле үк, мөндәриҗә һәм рух ягы белән дә буржуазиянең тормыштан бизгән яисә үзенә каршы торган икенче көчле бер сыйныф – пролетариат алдында үзенең һәлакәтен алдан сизгән минутларында гына үзен искәреп моңлана, шуның исләре белән үзен юата торган бер гөле булып чыкты. Бу гөлдән буржуазиянең инкыйразы бик нык аңкый иде. Бу сыйныфны ул гүя шушы инкыйразга алдан хәзерләшә, фикерләрне шуның ачылыкларына алдан күндерешә торды.

Телдә Дәрдмәндкә иярченләр дә булды. Кәрим Әмири[7] беренче адымында шул иярүчеләрнең берсе иде.

Кәрим Әмири башта үзенең Дәрдмәнд шикелле үк нечкә уйлап караучылык һәм аның өслүбендә язучылык тәҗрибәсе заманында:

Заманага аяк баскан мосафир
Тирән сазга кереп батып адашса,
Юлын тапмак насыйпмы ул гарипкә,
Сүнәр шәм берлә эзләргә маташса? –

дигән фәлсәфи шигырьләре өстенә 1921 елда да әле:

Әй ләтыйф җил, ни сөйлисең бөдрә тал яфрагына?
Шатланыпмы җилферди ул, баш орып як-ягына.

[1] Гандәлиб – сандугач.
[2] Санкем – гүя.
[3] Һәнүз – һаман.
[4] Зәүкый хәят – тормыш ләззәте.
[5] Дәрдмәнднең «Хәят» шигыреннән.
[6] Власть.
[7] Кәрим Әмири (Кәрим Хөсәен улы Әмиров, 1893–1962) – язучы. Беренче әсәрләре 1913 елда «Шура» журналында басыла. Иҗатының иң актив чоры 1920–1930 елларга туры килә.

Сөйлә, җил, ач эч сереңне,
Сүз бирәм сакларыма, –

рәвешендәге Дәрдмәнд телендә, аның өслүбендә язуны ташламаган иде.

Сәгыйть Рәми исә телендә бөтенләй моңа каршы бер тормыш алды. Ул татар теленә болай артык нечкәлекне түгел, бәлки катылыкны, ныклыкны кертте. Аның шигырьләре аркылы татар әдәби теле тезмәдә беренче мәртәбә үзендә иске Шәрык, чыгтай нотасына каршылык тудырды. Иске калыпны ярып чыгып, бу юлда революция күтәрде. Тезмәдә тормыш теле булу юлын алды. Һәрбер революция вакытларында күбрәк җимерү хәрәкәте барып, төзү эшләре соңрак башлану – бу һәркемгә мәгълүм булган табигый бер нәрсә. Тел мәсьәләсендә Сәгыйтьтә шул ук хәл күренде. Ул тезмәдә иске традицияне җимерде, ләкин искенең сәнгатьчә эшләнүе дәрәҗәсендә оста, аһәңле бер эшләрне бирә алмады. Нәтиҗәдә, тел-өслүбенең мусыйкый булмавына, ягъни аһәңе зәгыйфь чыккан бер өслүбкә аның байтак шигырьләре мисал булудан котыла алмаслык бер хәлдә калды.

Ләкин, югарыда әйткәнебезчә, аның өчен бу табигый иде. Чөнки ул бу турыда ялгызы башлап юл яра, татар теленә тезмәдә катылык, үткенлек, ныклык, кискенлек бирергә тырыша иде. Ул шушы вазифасын яхшы үтәде. Әмма шуның өстенә шул катылык, ныклык, кискенлекләрнең ишетүче, тыңлаучының миенә колак ярыларын имгәтмичә барып җитәрлек дәрәҗәдә тулы бер аһәңне аның каләме биреп җиткерә алмады (бу кимчелекнең тутырыла башлавын инде без Октябрьдән соңгы яшь каләмнәрдә күрә башладык[1]).

Сәгыйть Рәминең түбәндәге мисраглары шундый мисаллардан иде:

...Юк, канәгать итми күңлем:
Тар миңа чикле иман...
Мин мөселман диң, имеш дә,
Үсмә, тар тор, тар инан?![2]

Ярый, әй таң! Талигъ[3] агызып,
Матурлап сип нур-утыңны!
Чырагын бәхтенең кабызып,
Кадап куй, юл бул: ул торды.

(«Аң», 9 нчы сан, 1916 ел. «Ул торды» дигән шигырьдән)

[1] Сәгыйть Рәминең теленнән мисал өчен «Татар йокысы», «Пирчәткә»се, «Алданган», «Авыл», «Ул торды» («Аң», 2 нче сан, 1916 ел), «...»сы укылып чыгар. *(Авт. иск.)*

[2] С. Рәмиевнең «Киң иман» шигыреннән.

[3] Талигъ – бәхет.

Һәм:

Караңгы һәм тар бар күк асты,
Тапмый күңлем бер карар һичкайда;
Карыйм да күккә, очарга уйлыйм,
Уйлыйм, әмма күрмим нур һәм айда.
Нурсыз ул, нурсыз йолдызлар да,
Хәят беткән, җаны юк таңның да.
Торам да карыйм, юк, таң атмый;
Янам, көям, сызланып кайгымда...[1]

Татар әдәби теленең тезмә-көйле сүзләр бүлемендә Тукай нигезендә, аның алган юлында эшләнүендә берничә шагыйрь эшчәнлек күрсәтте. Сүнчәләй, Шәехзадә, Фәтхи Бурнаш, Гыйффәт[2] шуларның күзгә элек ташланганнарыннан булды.

Бу урында тезмәдә Тукай өслүбе нигезендә һәм шушы әдәби сукмак кырыенда эшләүченең берсе булган Сүнчәләйнең башка телләрдән зур гына әсәрләр тәрҗемә итү тәҗрибәсен күрсәтеп үтә алабыз. Аңарча тезмәдә зур тәрҗемәләрдән мәхрүм булган татар әдәбият дөньясына «Әлмансур», «Галиб», «Шильон» кебек поэмаларны[3] тәрҗемә итеп чыгару бу каләм аркылы күренде. Гәрчә аның «Әлмансур» тәрҗемәсенә 1915 елгы «Аң» журналында (83–103, 165, 180 нче саннарда) Ф. Сәйфи-Казанлы озын бер каты тәнкыйть язып, Һейненың шул әсәре Сәгыйть каләменнән асылыннан күп үзгәртелгәнлеген күрсәтеп, аңа күбрәк сәлби кыйммәт бирсә дә, гәрчә ул Сәгыйтьне анда «җитәр-җитмәс тел»ле «аңлатмау»чы дип сыйфатласа да һәм икенче бер тәнкыйтьтә (1913 ел, «Аң» 21 дә) аның телен «куәтсез мөтәрҗимнәр теле» белән язучы бер шагыйрь итеп күрсәтсә дә, шулай ук хәтта аның «Мәхбүс»ен дә (Шильонның беренче басмасын «Мәхбүс» исеме белән басылган иде) «бу тәрҗемә дә башыннан ахырына кадәр Тукайның кызыл карасы белән бизәкләнеп чykканга, «Мәхбүс» тә Тукайныкыдыр», дисә дә, шуның белән бергә үк һәрхәлдә «Тукаевтан кала сиҗгы[4], кафия[5] белән тәрҗемә итүче

[1] С. Рәмиевнең «Минем төн» шигыреннән.

[2] Гыйффәт Туташ (Заһидә Хөсәен кызы Бурнашева, 1895–1977) – шагыйрә, җәмәгать эшлеклесе. «Гыйффәт Туташ шигырьләре» (1915–1917) исемле өч җыентык, «Татар хатын-кызлары хәрәкәте тарихыннан» (1971) исемле автобиографик китап авторы. Шигырьләренең төп мотивы – татар хатын-кызының катлаулы язмышы.

[3] Сүз Һейненың «Әлмансур», Байронның «Шильон мәхбүсе» һәм А.С. Пушкинның «Тазит»ыннан үзгәртеп эшләнгән «Галиб» поэмаларының С. Сүнчәләй тарафыннан эшләнгән тәрҗемәләре турында бара.

[4] Сиҗгы – рифмалы проза.

[5] Кафия – рифма.

матбугатта күзгә чалынган зат – Сәгыйть әфәнде Сүнчәләй» икәне аны каты тәнкыйть итүче шушы каләм тарафыннан да тәсдикъ ителде. Шагыйрьлек көче артык куәтле булмаганлыктан һәм игътибары күбрәк бетемнәрдә – кафияләрдә әйләнеп калганга, аһәңе, рухы, садәлеге, җиңеллеге ягыннан Тукай сукмагына керә алмады.

Бабич үзенең кыска гомерендә татар әдәби теленең тезмә бүлемендә Тукай юлы буенча, ләкин эшләнү җитешлелеге ягыннан аңа караганда өстен, җанлы, үткен шигырьләр бирде. Аның көлкедәге өслүбе, бигрәк тә «Газазил»е һәм башкалары безнең әдәбиятыбызда үзләренең теле-өслүбе белән беренче урында торган кыйммәтле нәрсәләрдән булды. Октябрьдән әүвәлге әдәби ун елның соңгы баскычларында, ягъни 1915–[19]16 елларда татар әдәбиятына үзенең поэмалары аркылы аяк баскан Ф. Бурнаш теле, өслүбе, рухы белән Тукай чишмәсеннән, аның юлыннан агып килеп чыккан шикелле, Тукай өслүбендә, аның алган вәзеннәрендә тырышып эшләде. Бу юлда татар әдәби телен эшләшүдә бу шагыйрьнең байтак хезмәте булды.

1916 ел «Аң» журналында басылган «Җәйге таң», «Җәйге кич», «Мәдрәсәдә» дигән тезмәләре һәм «Качкын», «Сукбай» дигән поэмалары (7, 11, 12, 14, 19–20 нче саннар) белән чыгып, Октябрьгәчә үзен романтик-идеалист шагыйрь рәтендә күрсәткән Нәкый Исәнбәтне дә монда әйтеп үтәргә кирәк. Ул да үзенең шул шигырьләре (һәм 1917 [елгы] «Аң»дагы «Теләк» – 8–9 нчы сан, «Шәрык кызы», «Табигать почмагында»лары) белән Тукай шәкерте булып чыкты.

Болардан башка тагын Вакыйф Җәлал[1], Ярмәки[2], Г. Харис[3], Г. Сөнгати[4] вә башкаларның да азмы-күпме хезмәтләре, әлбәттә, булды. Билгеле, һәрбер шагыйрьнең азмы-күпме хезмәте булмый

[1] Вакыйф Җәлал (1886–1922) – шагыйрь. «Сәдаи мәдәният» (1908), «Күз нурларым» (1913), «Яңа Гөлстан» (1917), «Вакыйф Җәлал шигырьләре» (1918) һ. б. дистәгә якын шигъри җыентык, «Кара тормыш» (1913) исемле хикәя авторы.

[2] Зыя Ярмәки (Әхмәтзыя Шәйхи улы Насыйров, 1887–1965) – шагыйрь, «Яшьлек дәрте», «Күрсәтәм» (1912), «Әдәбият гөлләре» (1913), «Тойгыларым» (1913) һ. б. шигырь җыентыклары авторы.

[3] Габдулла Харис (1893–1931) – шагыйрь. Шигырь-поэмалары «Аң», «Ялт-йолт», «Сөембикә» журналларында, «Кояш», «Йолдыз» газеталарында басылган. «Күңел көзгесе» (1913) исемле шигырьләр җыентыгы авторы.

[4] Габдерахман Сөнгатулла улы Сөнгати (1894–?) – шагыйрь, «Ак юл» журналының җаваплы сәркатибе (1914–1915). 1915 елда Беренче бөтендөнья сугышына алына һәм хәбәрсез югала. Шигырьләре һәм поэмалары «Аң», «Ак юл», «Сөембикә» журналларында, «Кояш», «Халык» газеталарында басыла. «Таңгы җырларым» (1915) исемле шигырьләр һәм «Ил фәрештәсе» дип аталган хикәяләр җыентыгы авторы.

калмый. Ләкин болардан мисал алып күрсәтү китапның күләмен артык зурайтачак булганга, алардан мисал китерелмәде.

**Татар теленең гыйлем теле булып эшләнүе.** Татар теленең гыйлем теле булып эшләнүе дә икенче дәвернең соңында, Октябрьдән әүвәлге ун ел эчендә күзгә нык ташланырлык, үзенә игътибарны каратырлык бер рәвештә булды. Бу турыда бөтен урта мәктәпләр һәм гыйлем каләмнәре хезмәт иттеләр. Болар аркылы фәннән күп кенә атамалар ясалды.

Риза казый, Фатих Кәрими, Харис Фәйзи, Зәки Вәлиди, Һади Максуди, Габдулла Шонаси[1] Галимҗан Ибраһимов, Җәмал Вәлиди, Һади Атласов, Газиз Гобәйдуллин, Закир Кадыйри, М. Хәнәфи[2], Габдерәшид Фәхретдинов[3], Гыйбад Алпаров[4], Гыймад Нугайбәков[5], Мөхетдин Корбангалиев[6], Хуҗа Бәдигый[7], Г. Сәгъди, Хәсән Гали[8], мөгаллим Фатих Сәйфи, Нургали Надиев[9] кебекләрнең һәммәсенең бу турыда төрле юллар белән төрле яктан әдәбият мәйданына хезмәтләре булды. Болар җәгърафия, табигыят, риязият, тарих, педагогика, тел-әдәбият фәннәрен татар телендә бирү юлында, әлбәттә, төрлесе төрле үлчәүдә, хәлле-хәленчә хезмәт куйдылар.

Шушы хезмәтләрнең һәммәсенең нәтиҗәсендә, шушы Октябрьгәчә булган соңгы ун ел эчендә татар теленең бер белем теле булып эшләнүендә зур гына хәзерлек ясалды, гыйльми тел байтак югарыга күтәрелеп өлгерде. Татар телендә инде, кайсы фәнне булса да, артык кыенлык чикмәстән яза, аңлата алырлык бер хәлгә киленде.

---

[1] Габдулла Сабир улы Шонаси (1885–1938) – педагог, җәмәгать эшлеклесе.

[2] М. Хәнәфи (Мөхәммәтхәнәфи Сәетгали улы Кайбышев, 1892 – ?) – язучы. Татар әдәбиятына хас булмаган үзенчәлекле күп әсәрләр яза. Татар дөньясындагы гомуми атмосфера хакында аналитик күзәтүләр авторы.

[3] Габдерәшид Фәхретдинов (1892–1953) – озак еллар Уфа авиация техникумында эшләгән педагог, төгәл һәм табигать фәннәреннән дәреслекләр авторы.

[4] Гыйбадулла Хәбибулла улы Алпаров (1888–1936) – күренекле тел галиме, профессор, филология фәннәре докторы, язучы һәм педагог.

[5] Гыймад (Гыймадетдин) Шәрифҗан улы Нугайбәк (1881–1943) – тел галиме, журналист. Хезмәтләре татар алфавитын һәм орфографиясен камилләштерүгә, лексикографиягә карый.

[6] Мөхетдин Хафизетдин улы Корбангалиев (1873–1941) – педагог, тел белгече, җәмәгать эшлеклесе.

[7] Хуҗа Габделбәдигъ улы Бәдигый (1887–1940) – тел галиме, фольклорчы. Хезмәтләре татар әдәби теле тарихына карый. Татар фольклоры җыентыкларын төзи. Мәктәпләр һәм югары уку йортлары өчен татар теле дәреслекләре авторы.

[8] Хәсән Гали (Хәсән Шәяхмәт улы Галиев) (1878–1940) – тел галиме, әдәбият тәнкыйтьчесе, педагог.

[9] Нургали Сибгатулла улы Надиев (1882–1940) – педагог. «Ибтидаи мәктәптә хисап укыту ысуллары» (1918) хезмәте авторы.

Атамаларның да байтагы инде эшләнеп гамәлгә ашты. Дөрес, әле бу турыда күп җитешсезлекләр сизелә иде. Шулай да бу үсү аркасында ул җитешсезлекләрне бетерә алу өмете нык иде инде.

*Нәзари як*

**Ун ел эчендә татар теленең гыйльми эшләнүе һәм телдә икенче баскыч реформаторлык.** Татар теленең гыйльми-нәзари яктан эшләнә башлануының төп ноктасы Каюм каләменә барып тукталганын беләбез. Менә шушы эшнең дәвамын яисә бу юлдагы икенче реформаторлыкның башлануын шушы Октябрьгәчә булган соңгы ун ел эчендә күрдек. Каюмнан ун еллар соң кузгалган бу хәрәкәт тә 1910 елларда башланды. Әхмәтҗан Мостафаның «Төрки сарыфы»сы, Һади Максудиның «Сарфы төрки», «Нәхәви төрки»се, Мөгаллим Кәбүтәринең[1] «Тәртибе җәберлә мөхтасар сарфы төрки»се, Шәйхгаттар Иманаевның «Нәхү вә сарыф» кебек әсәрләре шул хәрәкәтнең хәзерлек баскычындагы хезмәтләр иде. Галимҗан Ибраһимов болар турында: «Кимчелекләр илә бәрабәр болар татар сарыфы фәнендә азмы-күпме кагыйдәләр куштылар, хосусан, Максудов сарыфы бу мәсьәләнең әһелләре өчен Каюм Насыйридан соң бераз ук яңа мөнәсәбәтләр эзләп чыгара, шуны кагыйдә рәвешенә кертә», – дигәннән соң, Максуди сарыфлары турында: «Мин үзем тәҗрибә белән беләм, сарыф язганда, миңа аның байтак файдасы тиде», – дип өсти («Аң», 21–22 нче сан, 1915 ел). «Төрки сарфы һәм төрки нәхүе» – телебезне чыннан тикшереп язылган беренче әсәрләрдәндер (Җ. Вәлиди. «Татар теленең грамматикасы», 10 бит).

Ләкин бу юлда Каюмнан соң иң элек чынлап та телгә икенче яңа реформация ясарга керешүче (беренчесе безгә мәгълүм Каюм Насыйри иде) ике каләм күренде. Берсе – Гыймад Нугайбәк, икенчесе Галимҗан Ибраһимов иде. Беренчесе үзенең нәгыз, садә, табигый татар теле белән язылган «Төрлек»е[2] аркылы бу турыда күп материаллар биреште, телне фәнни тикшерү юлына каратышты. Шуның белән бергә аның бу әсәре үз юлында чыннан оригиналь бер әсәр булды. Ул, Каюм шикелле үк, имляда ун сузык алды. Һәм, шуларга үзеннән махсус галәмәтләр куеп, гамәлгә кертүнең беренче тәҗрибәсен ясап карады. Телдән бөтен истисналарны чыгарырга

[1] Кәбүтәри Хәсән – тел белгече, мөгаллим.

[2] Нугайбәк гарәпчә «Сарыф» сүзе урынына «Төрлек» дип исем куя. Аның бу әсәре 1911 елда Казанда, урта кулда 80 бит зурлыгында басылып чыга. *(Авт. иск.)*

теләде. Ләкин «телдә булган сүзләрнең мөнәсәбәтеннән туарга тиеш кагыйдәләрне бәян өчен юл сайлауда хәрфиян[1] рус грамматикаларына тәкълид кылган[2]» булып чыкты. Әмма «саф татар теле белән язылып, атамалары да саф татарча ясалып алынган» булучылыгы һәм «телебезнең фонетика һәм морфология кануннарын матур бер тәртипкә салып күрсәтү ягыннан»[3], шөбһәсез, кыйммәтле бер хезмәт иде. Югарыдагы «Сарфы төрки»ләр бөтенләй гарәп вә госманлы әсәрләренә ияргәннәр иде. «Төрлек» бөтен мәгънәсе белән шуларның реакциясе – киреседер. Мөхәррире гүя китапның башына язып куйган: «Бу әсәргә һичбер чит сүз кермәс!!» һәм шуны ригая кылган[4]. Бөтенләй татарлашып беткән «хәреф» дигән бер сүзне алмасак, сиксән битле китапта башка һичбер чит – русча, гарәпчә я фарсыча сүз очрата алмадым, мөхәррирнең бу фикере гамәлгә керергә мөмкин булмаса да, әсәре татар телен сафлау юлында эшләүчеләргә зур хәзинә идекендә шөбһә юк. Гыймад эзләгән, тикшергән, онытылган сүзләрне кабердән чыгарган. Биш-алты йөзгә якын яңа истыйлях[5] ясаган. Болар, әлбәттә, безнең тел тикшерүчеләребезгә зур материал булачак» (Галимҗан Ибраһимов. «Аң», 21–22 нче сан, 1915 ел).

Ләкин татар теленең нәзари эшләнүендә тормышка ашарлык бер юл белән реформа ясау юлында беренче юлбашчылык күрсәтү, нәзари һәм гамәли төп сызыкларны ачык, катгый сызып, шуларны мәктәпләр аркылы тормышка ашыруның да беренче зур адымын атлау икенчесенең өлешенә тиде. Үзенең «Татар сарыфы», «Татар нәхүе»ләре белән Галимҗан Ибраһимов шушы икенче реформациянең төп нигез ташын салды, шул бинаның дүрт почмагын корды. Шуның өчен дә бу китаплар турында, бик хаклы уларак, татар матбугатында түбәндәге фикерләр язылып үтте:

«Һәрхәлдә, китап үз юлында беренче вә бердәнбер булганлыктан, әлбәттә, анда кимчелекләр булу да бик мөмкиндер». «Телебезнең сарыф вә нәхүен тәртипкә салудагы беренчелек шәрәфе бу китапкадыр». «Кыскасы, бу китапның һәм тәртибе, һәм истыйляхлары, кагыйдә вә тәгърифләре[6] яңадыр. Телебездәге сүзләрнең һәммә кыйсеме диярлек бу китапка кереп, бер кагыйдә өстенә язылган. Телебездә

[1] Хәрфиян – сүзгә-сүз.
[2] Тәкълид кылган – ияргән.
[3] Г. Алпаров – «Шәкли нигездә татар грамматикасы». 17 бит. *(Авт. иск.)*
[4] Ригая кылган – *бередә:* тормышка ашырган.
[5] Истыйлях – термин.
[6] Тәгърифләре – аңлатмалары.

сирәк истигъмаль итеmenә[1] торган сүзләр бөйлә[2] бу китапка кергәләгән, бу җиһәте белән китап бик нык дикъкатьле эшләнгән, үзенә күп хезмәт кергән, ләкин бу китаплар дәреслек булып язылган булсалар да, алар «дәреслек булудан бигрәк гыйльми булып чыккан»[3].

«Ул үзеннән соңгы яңа сарыфчыларга төп гамәли сызыкларны сызды. Телебезнең эшләнү тарихының бу дәверендә иң зур урын тоткан әсәр Галимҗан Ибраһимовның “Татар сарыфы” белән “Татар нәхүе” булса кирәк. Элгәреге сарыфларның, бер яктан, гарәпкә иярүләре, икенче яктан, тел кагыйдәләрен ачык тел белән аңлатып бирә алмаулары татар дөньясын канәгатьләндерә алмаган иде. Оста, көчле каләм белән язылган “Татар сарыфы” турында телебезнең фонетика һәм морфология ягыннан булган бөтен табигатьләре, аермалыклары кыскача, бик ачык бер тәртипкә салынып, телебезнең табигатенә муафыйк атамалар һәм татар әдәбиятыннан алынган мисаллар белән аңлатылалар»[4]. Шулар өстенә шушы «Татар сарыфы», «Татар нәхүе»ләренең басылып чыгулары белән татар дөньясын нык шаулатканлыгын, татар мәктәпләрендә беренче мәртәбә шаулатып барып кереп, нык урын алганлыкларын да кушарга кирәк.

Бу әсәрләр төп сызыкларны сызулары белән бергә, әлбәттә, кимчелексез түгел иделәр. Ул кимчелекләрне дә соңыннан аз бер истисна белән шул ук төп сызыкларда татар теленең сарыф-нәхүен киңәйтеп алып китүчеләр тутырыштылар һәм үзләре ягыннан шуларга байтак яңа үзләнмәләр, яңа тикшерүләр, тутырмалар куштылар.

«“Татар сарыфы”ннан соң 1913 елларда мөгаллим Ф. Сәйфинең “Мәктәптә татар теле дәресләре”, Габдрахман Сәгъдинең “Телебезнең сарыфы”, “Телебезнең нәхүе” дигән китаплары, Җәмал Вәлидинең “Татар теле кагыйдәләре” килеп чыга. 1915 елда Габдрахман Сәгъдинең яңадан “Мөкәммәл сарыф-нәхү”е , 1918 елда Мөхетдин Корбангалиев, Г. Баттал һәм Хуҗа Бәдигыйләрнең “Татар теле сарыфы”, “Ана теле нәхүе”, 1919 елда Җәмалетдин Вәлидинең “Татар теле грамматикасы” басылып чыгалар»[5].

---

[1] Истигъмаль ителәә – кулланыла.

[2] Бөйлә – шулай.

[3] «Мөгаллим Фатих Сәйфи доклады. Уфа земство мөселман мәгариф шөгъбәсе янында дәреслекләр тикшерү өчен чакырылган киңәш мәҗлесенең протокол һәм карарлары» дигән мәҗмугадан. 1915 ел. Уфа земство басмасы. *(Авт. иск.)*

[4] «Шәкли нигездә татар грамматикасы» – Г. Алпаров. 17 бит. 1926 ел. *(Авт. иск.)*

[5] «Шәкли нигездә татар теле грамматикасы» – Гыйбад Алпаров. 1926 ел. 17–18 нче битләр. *(Авт. иск.)*

«Унберенче елларда «Татар сарыфы» язылды. Бер-ике-өч ел туктау булды. Менә бу ел ([19]15 елны әйтә) өч данә сарыф китабы чыкты: 1) Фатих Сәйфинең «Мәктәптә татар теле дәресләре»; 2) Җамалетдин Вәлидинең «Татар теле кагыйдәләре»; 3) Г. Сәгъдинең «Үз телебезчә мөкәммәл сарыф-нәхү»е[1], бу әсәрләрнең чыгуы белән ачылган яңа бер хакыйкать – татар сарыфы фәненең бөтен вә эшләнгән бер рәвешкә кергәнлеге безгә ачык күренүедер» («Аң». 21 нче сан, 1915 ел).

Татар теленең сарыф-нәхүләре турында Октябрьдән әүвәлге ун ел Җәмал Вәлидинең 1919 елда басылып чыккан «Татар теленең грамматикасы» исемендә 171 битлек зур гына бер әсәре – кулланмасы басылып чыгу белән тәмам булды. Аңарча булган бөтен сарыф, нәхү китапларындагы тикшерүләрнең һәм мөхәррирнең үзенең байтак еллык тикшерү һәм тәҗрибәләренең нәтиҗәсе булып төзелгән бу китап татар теленең сарыф-нәхүен тикшерүдә бердәнбер зур кулланма булырлык рәвешкә килде. «Җамал Вәлидинең 1919 елда чыккан грамматикасы телебезнең табигатен тикшерүдә тагын да тирәнрәк, тагын да киңрәк адымнар ясый», «анда телебезнең фонетикасы, авазларның үзгәреш кануннары, басымнар, хәреф-имля мәсьәләләре, телебезнең морфология һәм нәхәви төзелеше бик төпле рәвештә тикшерелә». «Татар теле грамматикасында телебезнең нәхәви төзелеше мантыйкый җиһәтне әсас итү юлы белән тикшерелгән. Шуңа күрә бу ягы белән ул грамматикалыктан чыгып, мантыйкка якынлаша төшкән. Һәрхәлдә, бу китап – кирәк тәфсилатка[2] байлыгы белән, кирәк фәнни багажы белән телебезне өйрәнүчеләргә кыйммәтле бер кулланма итеп тотылырга хаклы бер әсәр»[3].

Октябрьдән элек үзенең гәзит һәм журналлардагы мәкаләләре белән Нигъмәт Хәким[4] каләме дә татар теленең сарыф-нәхүен тикшерү юлында чыгып эшкә керешкән иде.

Бу урында Октябрьдән соң татар телен яңа метод – шәкли метод белән тикшерүдә үзенең «шәкли нигездә татар теле грамматикасы» дигән әһәмиятле әсәрен биргән (1926 ел Казанда басылып чыкты)

[1] «Мөкәммәл сарыф-нәхү»нең иҗади яклары бигрәк аның нәхү кыйсемендә һәм тәртип ысулында иде. *(Авт. иск.)*

[2] Тәфсилатка – аңлатмалылыкка.

[3] «Шәкли нигездә татар теле грамматикасы». – Г. Алпаров. *(Авт. иск.)*

[4] Нигъмәт Хәким (Нигъмәтулла Гыйниятулла улы Хәкимов, 1889–1937) – тел галиме, шагыйрь. Хезмәтләре ислам тарихына, татар тел белеменә карый. «Күңел дулкыннары» (1913), «Күңел музыкасы» (1913) шигъри җыентыклары авторы.

Гыйбадулла Алпаровның 1912 елда басылып чыккан «Хәреф вә имлямыз» дигән әсәрен дә истән чыгармаска тиешләрбез. Монда ул кыскача әлифба тарихы, татар теленең имлясы, кыскача фонетикасы, хәрефләрне бер шәкелгә калдыру кебек мәсьәләләрне тикшерә. Монда аның бигрәк яңа бер оригиналь сызыгы – гарәп хәрефләрен ислах мәсьәләсен дә кузгатуы булды.

**Татар теленең әдәбият белемен тудыру юлында.** Татар теленең өслүб-бәлягать кагыйдәләрен тикшерү-эзләүнең, зәгыйфь булса да, беренче адымы Каюм Насыйри тарафыннан башланганын, аның «Кавагыйде китабәт»ендә татар теленең өслүбе, бәлягате турында азмы-күпме тикшеренү хезмәте күренгәнен югарыда әйтеп киткән идек. Ләкин әле ул әдәбият белеме түгел иде, тик өслүб кыйсемендә кайбер шуның өчен кирәкле булган материалларны гына алга куюдан гыйбарәт иде.

Татар дөньясында бу белемнең беренче мәртәбә башлануы 1910–[19]11 елларда булды. Госманлы әдәбият белеменең методы тәэсире астындарак язылган «Кавагыйде әдәбия» һәм аңа «Гыйләвә»[1], «Әдәбият ысуллары», «Әдәбият мөгаллиме» дигән[2] китаплар шул юлда

[1] «Кавәгыйде әдәбия» һәм аңа «Гыйләвә» 1911 елда Уфада Шәрык матбагасында «Кәримов, Хөсәенов вә шөрәкәсе»нең Уфа шөгъбәсе тарафыннан бастырылды. Икесе урта кулда 167 бит зурлыгында. «Әдәбият ысуллары» 1912 елда «Вакыт» нәшрияты тарафыннан (53 бит зурлыгында), «Әдәбият мөгаллиме» дә 1913 ел Хөсәенов көтебханәсе тарафыннан (82 бит зурлыгында) бастырылды. «Нәзарияте әдәбия» исә 1913 елда Казанда «Өмид» матбагасында китапның мөәллифе Г. Батталның үзе тарафыннан бастырылып нәшер ителде. *(Авт. иск.)*

[2] Бу китаплар чыгу белән матбугатта зур шау-шу кузгалды, «Шура» һәм «Аң» журналларында шушы китапларда кузгатылган байтак мәсьәләләрдә Г. Сәгъди белән Нәҗип Хәлфиннең кызу полемикалары барды. Шуның өстенә «Кояш» гәзитендә «Гыйләвә»гә «бәла» күтәрелде.

Бу китаплар уңае белән күтәрелгән мәсьәлә «сәнгать – сәнгать өченме, әллә сәнгать – тормыш һәм файда өченме?» мәсьәләсе белән әдәбият, сәнгатьтә өслүб, форманың әһәмияте мәсьәләсе иде. Әлеге китапларда «сәнгатьнең максаты-гаясе (*омтылышы*) мәсьәләсе тузгытылып, аларда «сәнгать, әдәбият – тормыш һәм файда өчен» булырга тиешлеге язылган иде. Шулай ук мөндәриҗә белән өслүб, форманың бер-берсенә нык баглы бернәрсә икәнлекләре күрсәтелеп, бу яктан тел-өслүбнең әһәмиятенә, тәэсиренә артык тукталынган иде. «Кояш» белән «Аң»да әнә шуңа каршы көрәш күтәрелде. Бигрәк тә «Әдәбияты нәфисә дөнья эшләрене үзенә әсла гараз (*максат*) итә алмый» дип, «сәнгать – сәнгать өчен» булырга тиешлек исбат ителергә тырышылды. Бу турыдагы фикерләр белән танышу өчен, 1913–[19]14 елгы «Аң»ның 6, 7, 1 нче саннарына (Н. Хәлфин 1914 елгы «Аң»ның 1 нче санында татар шагыйрьләрен «сәнгать – сәнгать өчен» сызыгына өндәп маташты). Шагыйрьләрнең «Шигырьдә сәнгать почмагыннан дөнья вә гараз чатына таба күчкән»лекләреннән зарланды, «дөнья гаразына хезмәт итү»не шагыйрьләрне «һәлак иткән нәрсә» дип аңлады), 1913 елгы «Шура»ның 10–11 нче саннарына (мөхәррирнең мәкаләләренә) кайтып карарга мөмкин. *(Авт. иск.)*

беренче тәҗрибә адымы иделәр. Соңыннан бу хезмәт рус әдәбият нәзарияләре тәэсире астында һәм күбрәк шулардан үрнәк, гыйльми материаллар алып, Г. Баттал тарафыннан язылган «Нәзарияте әдәбия» китабы аркылы киңрәк планда дәвам итте.

«Ахырда «Татар сарыфы», «Татар нәхүе» иясе тарафыннан язылып, 1916 елда басылып чыккан «Әдәбият кагыйдәләре» аркылы бу турыда тегеләргә караганда күп төгәл хезмәт күрсәтелде. Мәктәпләргә кулланма итеп яратып кабул ителгән дә шул булды. Гәрчә, хәзерге үлчәү белән караганда, әле бу әсәрдә дә методы, мөндәриҗәсе ягыннан җитешсезлекләр байтак булса да, ул заманда оста каләм белән татар теленә ятыштырылып, тәртиплерәк бер юл белән язылган бердәнбер кулланма шул иде.

Шул рәвешчә, шушы югарыдагы китаплар аркылы Октябрь революциясеннән әүвәлге ун ел эчендә татар теленең әдәбият белеме, бер систем алып, бер белем хәлендә күзгә күренерлек булган иде.

Шулар ук рәтеннән тел-әдәбият укыту методлары турындагы хезмәтләргә каратып та берничә сүз әйтеп үтик. Бу турыда мөхәрриренең 1914–[19]15–[19]16 елгы «Шура»ларда мәкалә булып бүленеп басылган «Тел-әдәбият укыту ысуллары» (әлифба, уку, имля, инша, сарыф-нәхү дәресләрен ничек укыту турында) дигән әсәрдән башка тагын Галимҗан Ибраһимовның «Татар телен ничек укытырга?», М. Корбангалиев, Г. Баттал, Хуҗа Бәдигыйлар тарафыннан язылган «Татар телен укыту методикасы», Кибарисов, Галә Ходаяров[1] тарафыннан төзелгән «Аңлатып укыту методикасы» дигән китаплары чыкты. Боларның соңгы икесе бу турыда зур күләмдә, тулырак мөндәриҗәдә язылган китаплар иде. Татар телен укыту методикасы турында профессор Кульманның[2] «Методика русского языка»[3] (1913 елда басылган) дигән мөһим әсәренең эчендәге мәгълүматлар өстенә, татарның үзенә махсус мәгълүматлар, мисаллар арттырылып язылган әһәмиятле бер кулланма иде. Соңгысы төрле Яурупа, рус педагоглары әсәреннән, бигрәк тә Балталоннан[4]

[1] Галә Ходаяров (Галәветдин Гайнетдин улы Кудаяров, 1891–1966) – педагог, тәрҗемәче, дәүләт эшлеклесе.

[2] Николай Карлович Кульман (1871–1940) – әдәбият тарихчысы, тел галиме, җәмәгать эшлеклесе.

[3] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[4] Цезарь Павлович Балталон (1855–1913) – педагог, мәктәпкәчә яшьтәге һәм башлангыч мәктәп укучыларын укыту методикасы буенча хезмәтләр авторы. Аңлатып укуга каршы чыгып, тәрбияви уку ысулын яклый.

файдаланып язылган булды. Һәрхәлдә, икесе дә бу юлда әһәмиятле адымнар иде.

Бу урында әлифба укыту ысулларыннан Шакирҗан Таһириның «Мифтахы бадьэ әл-тәгълим»е[1] белән Гайнетдин Әхмәровнның «Әлифба китапларына тәнкыйть»ен һәм М. Корбангалиевнең «Гавам мәктәбендә дәрес бирү намунәләре»н дә әйтеп үтәргә кирәк. Болар да татар дөньясында методика әдәбиятында үз бабларында беренче тәҗрибәләр иде.

**Халык әдәбиятын җыйнау, шуны тикшерү юлында.** Татар халык әдәбиятын җыйнау, шуны тикшерү беренче мәртәбә Каюм Насыйри белән башланган иде. Бу хезмәт соңыннан Габделгалләм Фәезхани, Тукай, Хуҗа Бәдигый, Фазыл Туйкә[2], Г. Рәхимнәр тарафыннан дәвам иттерелде. Күптәннән бирле халык әдәбиятын, материалларын җыйнап, шуларны тикшереп килгән Фазыл Туйкәнең «Җырлар әхтәрисе», Хуҗа Бәдигыйның «Мәкальләр», «Табышмаклар»ы басылып чыкты. Ләкин әле болар да – шуларны җыеп бастыру хезмәтләре генә иде. Әмма боларга анализ ясау, аларны бер системга кую, тарихларын билгеләү кебек эшләр юк дип әйтерлек иде. Тик бу турыда Тукайның «Халык әдәбияты» дигән бер кечкенә рисаләләрдән кыска гына бер анализ ясалып үтте. Шул уңай белән шуңар Зәки Вәлидинең «Шура»дагы мәкаләләре өстәлде. Шуңа янә Мәхбүбҗәмал Акчурина[3] ханымның «Кыз йыглату» мәкаләсе кушылды.

1914 елгы «Аң»ның 2 нче санында Ф. Сәйфи-Казанлы тарафыннан язылган «Халыкның әдәби иҗаты» дигән мәкалә өстенә, шул ук ел «Аң»ның 14, 16, 17, 19, 20, 21 нче саннарында Г. Рәхимнең озын гына әһәмиятле мәкаләсе басылып чыкты. Шуның белән бу бабта кирәкле бер адым атланды. Ул бу мәкаләләрендә, үзе әйтмешли, «халык әдәбиятыбызга өстән генә булса да гомумән бер караш ясап тәдкыйк кылып чыгарга тырышу» читенлеген өстенә алган булса да, заманына күрә ярыйсы гына уңышлы бер эш эшләде. Монда кыскача гомумән халык әдәбиятының ничек тууы, тарихы язылып, аннан соң татар халык әдәбиятының эчке-тышкы яклары турында

[1] «Башлап укытырга өйрәтү ачкычы».

[2] Фазыл Туйкә (Фазыл Әхмәткәрим улы Туйкин, 1887–1938) – татар драматургы, педагог, фольклорчы. «Шура», «Безнең юл», «Мәгариф» кебек журналларда күпсанлы мәкаләләре басыла.

[3] Мәхбүбҗамал Акчурина (1869–1948) – язучы. Язмалары татар җәмгыятенең XX йөз башындагы иҗтимагый һәм әхлакый мәсьәләләренә – балалар тәрбияләүгә, татар хатын-кызының җәмгыятьтә тоткан урынына һ. б. багышлана.

күп кенә мисаллар аркылы ачык кына, матур гына тел белән мәгълүмат бирелеп үтелде. Татар халык әдәбиятыннан җырларга бер анализ ясалды. Аларның тарихларын, вәзеннәрен[1] һәм көйләрне тикшерү юлында әһәмиятле тәҗрибә сызыгы булды. Әмма мәкальләр[2] турында «Әдәбият ысуллары» китабындагыдан башка бер тәхлил күренмәде. Әкиятләрне тикшерү турында янә әйтерлек бер адым атланмады. Г. Рәхимнең шул югарыда башлаган эш[не] ахырынача дәвам иттерүге көтелсә дә, ни өчендер матбугатта тукталып калды.

**Әдәбият тарихын тикшерү юлында.** Бу турыда беренче мәртәбә Ф. Әмирханның «әл-Ислах»тагы «Әдәбиятка гаид» дигән мәкаләсеннән соң аерым китап рәвешендә Җәмалетдин Вәлидинең «Татар әдәбиятының барышы» язылып басылды. Насыйриның календарьларында, Мәрҗанинең «Мөстәфад»ларында, Ризаның «Асар»ында һәм шул ук Риза казыйның «Шура»да бирелә килгән материалларыннан башка татар әдәбият, матбугатының тарихи-тәнкыйди мәкаләләре дәвам итте. Болар һәммәсе дә соңгы тарихчылар өчен, шөбһәсез, беренче кирәкле материаллар иде. Ләкин бу турыда Җамалетдин китабыннан башка аерым бер китап рәвешендә әсәр чыкмады.

Димәк, аңарчы татар әдәбиятының бу яктан эшләнүе турындагы хезмәтләр матбугатта аерым китап рәвешендә күренә алмый торды. Бу эшләрнең кыздырылу галәмәтләрен без Октябрьдән соң гына ачык күрә һәм сизә башладык.

## 3. [Октябрьдән элек] ун ел эчендә белем әдәбияты

*Дәреслекләр һәм кулланмалар*

Октябрь революциясенәчә булган ун ел эчендә белем әдәбияты матур әдәбият дәрәҗәсендә үк күзгә күренерлек бер үсү күрсәтте. Әлбәттә, фәннәрнең һәр төреннән күп җилдле әсәрләрне әйтмибез. Боларны тудырырга әле бик иртә иде. Гыйлем хәзерлеге һәм шуларны тудырачак гыйлем көчләре, шулай ук аларны укучы җәмәгатьнең саны, аңы, мәгълүматы ягыннан да, икътисад ягыннан да әле фәннәрдән зур китаплар язуга, бастыруга мөмкинлек юк иде.

[1] Халык вәзене, гомумән, татар телендәге вәзеннәр тикшерелү уңае белән халык көйләреннән «Зиләйлүк» белән «Тәфтиләү» вәзеннәре турында шушы китап мөхәрриренең дә «Шура»да бер тикшерүе булып үткән иде. *(Авт. иск.)*

[2] Текстта «мәкаләләр».

Шулай да фәннәрнең һәр тармагыннан һич булмаганда мәктәпләр өчен дәреслекләр, мөгаллимнәр өчен кулланмалар байтак кына язылды һәм шулар басылып күп кенә таралдылар да. Бу вакыт эчендәге белем әдәбияты, әйтергә кирәк, күбрәк башлангыч мәктәпләр, бераз өлеше дә урта мәктәпләр өчен дәреслекләрдән гыйбарәт булды. Бу дәреслекләр, бер яктан, мәктәпләргә дәреслек булсалар, икенче яктан да, башлангыч мәктәп мөгаллимнәребезнең үзләре өчен дә дәреслек, кулланма булу хезмәтен үтиләр, үтәргә тиешләр иде. Боларның төзелешендә алынган метод, шулай ук мөндәриҗә, тәртип яклары да шуңа каратылган иде.

Тел, әдәбият фәненең ничек эшләнә башлаганын һәм күпме, ни дәрәҗәдә шулай ук кемнәр тарафыннан эшләнеп килгәнен югарыда, тел мәсьәләләре тикшерелгәндә күреп киткән идек. Инде бу турыда фән әдәбиятының башка тармакларына күчәбез.

**Тарих һәм тәрҗемәи хәл.** Тарихтан Риза казый каләме үзенең «Шура»сы аркылы аның һәр саны саен диярлек кирәкле, кыйммәтле материалларны бирә барды. «Мәшһүр ирләр»не дәвам иттереп, әүвәлге «Ибн Рөштә»ләре өстенә «Имам Газали», «Әбүл Галә әл-Мәгарри», «Мөхетдин ибн Гарәби», «Ибне Тәймия», «Көтебе ситтә вә мөәллифләре», «Әхмәд Мидхәт», «Әхмәд бай» кебек, гәрчә дини рухта булса да, ислам дөньясын өйрәнү өчен гыйльми-тарихи кыйммәтләр булган әсәрләрен бирде. Шуның белән бергә болар аркылы татар арасына ислам фәлсәфәсе дә кертелә башлаган булды.

Шул ук Шәрыкны – исламны өйрәнү юлында, ләкин ислам идеологиясен ныграк тамырландыру максатына багланып, Шәһәр Шәрәфнең[1] «Гасры сәгадәт»е, «Әсхабе кирам»нары, Сәлах Камалның[2] «Ислам тарихы»лары, Сөнгатулла Бикбулатовның[3] яхшы ук калынлыкта «Хәзрәти Мөхәммәд»е, Закир Кадыйриның мәшһүр тәхкыйклы[4] гарәп тарихчысы Җөрҗи Зәйданнан[5] тәрҗемә «Ислам

[1] Шәһәр (Шәһретдин) Шәрәф (1877–1933) – җәмәгать һәм дин эшлеклесе, язучы, педагог.

[2] Сәлах Камал (1885–1954) – каллиграф, рәссам, педагог, җәмәгать эшлеклесе һәм эпитафик ташбилгеләр ясау остасы.

[3] Сөнгатулла Нигъмәтулла улы Бикбулатов (1886–1955) – дин эшлеклесе. Хезмәтләре гарәп теленә, ислам дине һәм татар халкы тарихына карый. Бикбулатов тарафыннан төзелгән гарәп теле дәреслеге татар мәктәпләрендә киң кулланыла, ул 1917 елдан соң да берничә тапкыр нәшер ителә.

[4] Тәхкыйклы – мәсьәләнең дөреслеген, тулылыгын тикшереп табучы, хакыйкать эзләүче.

[5] Җөрҗи Зәйдан (1861–1914) – гарәп тарихчысы, публицист, галим, язучы.

мәдәнияте», Г. Батталның «Ислам фәйләсүфләре» кебек әсәрләр басылдылар. Октябрьдән соң, гәрчә системсыз булса да, «Татарларда сыйныфлар тарихы» дигән үз бабында яңа бер әсәр язган Газиз Гобәйдуллинның «Диннәр тарихы»н да шушы дини тарихлар рәтеннән санап үтәргә кирәк. Болар, әлбәттә, Шәрыкны өйрәнүче яшьләребез һәм марксист тарихчыларыбыз өчен кирәкле бер материал булып торачаклар.

Төрк-татар тарихыннан Мәрҗанилəрдән соң үзенең күп мәгълүмат туплавы ягыннан Хәсәнгата казыйның «Мөфассал тарихе төрки»[1] атлы әсәре чыкты. Бу китап, чи, таркау материалга бай гына бер әсәр булганлыктан, бездә генә түгел, Төркия тарихчылары арасында да телгә алынып үтте. Шул ук заманда Мәрҗани белән Габәшидән соң әһәмиятле әсәрләрнең берсе Зәки Вәлидинең «Төрк-татар тарихы» дигән китабы булды. Бу дәреслек түгел, бер кулланма иде. Бу мәүзугда Шәрык мәнбәгъләре[2] өстенә рус-Яурупа галимнәренең тикшерүләрен күп укыган, моның өчен рус мәнбәгъләре өстендә күп казынган, күп тикшеренгән бу тарихчының шушы китабы, үзенең артык зур булмавына да карамастан, шөбһәсез, татар өчен ул заманда бай материаллы, ләкин системсыз, чуалчык төзелгән бер әсәр иде. Төрк-татар тарихы турындагы мәнбәгъләрне укуы, тикшерүе, шул турыдагы мәгълүматы шиксез күп, ләкин системы юк яисә бик зәгыйфь – менә бу тарихны язучы галимнең һәм аның шушы әсәренең туры бәһасе шу[л]дыр. Шуның өстенә әсәр, шөбһәсез, буржуазия карашы белән идеализм нигезендә һәм тәмамән милли бер рухта, милли тойгылар ялкыны астында төзелгән бер әсәр булды.

Тарих әдәбиятыбызга Һади Атласов та «Сөембикә» дигән бер рисаләсе өстенә «Казан тарихы», «Себер тарихы» исемнәре белән күләме зур гына ике китап бирде. Рус мәнбәгъләрендәге мәгълүматларның мәҗмугасы булган бу китаплар – үзләренең зурлыклары ягыннан бәлки татар дөньясында беренче мәртәбә күренгән әсәрләр иде.

Төрк-татар тарихыннан дәреслек булып Зәки Вәлидинең югарыда әйтелгән әсәреннән кыскартып язылган рәсемле тарихыннан башка Г. Батталның «Татар тарихы» һәм Ф. Туйкә, К. Туйкәләрнең тарихлары чыкты[3]. Телләренең яхшы эшләнүе, ачык һәм җиңел

[1] Сүз Хәсәнгата Габәшинең шәкертләргә уку әсбабы итеп эшләнгән «Мөфассал тарихе кауме төрки» (1909) хезмәте турында бара.

[2] Мәнбәгъләре – чыганаклары.

[3] Сүз бертуган Фазыл һәм Кәбир Туйкиннар тарафыннан язылып, 1919 елда Оренбургта нәшер ителгән «Төрк тарихы» дигән дәреслек турында бара.

тәртипле булулары ягыннан үз заманнарында шушы соңгы ике дәреслек игътибар казанды.

Гомуми тарихтан Харис Фәйзинең татар дөньясында беренче чыккан «Тарихе гомумиләре»[1], гомуми этнография һәм тарихи материалдан Ф. Кәримовның «Нәшрияте Кәрими» исеме белән русчадан тәрҗемә кылып, һәр халык турында үзенә аерым-аерым чыгара барган әһәмиятле китаплары өстенә, урта мәктәпләр өчен махсус язган «Тарихе гомуми»се[2] булды. Болар татар дөньясында бу турыда беренче адымнар иде. Бу каләм ислам тарихыннан да дәреслекләр язды. Соңыннан Газиз Гобәйдуллинның Виппердан[3] тәрҗемә һәм икътибас[4] юлы белән язган тарихы гомумисе чыкты. Теле эшләнмәгән чуалчык булса да, бу үз бабында тәрҗемәдән беренче тәҗрибә иде. Боларга Нургали Надиевның «Русия тарихы»н да кушарга кирәк.

**Табигыят һәм җәгърафия.** Табигыяттән Шакирҗан Хәмидинең[5] «Адәм», «Хәйванат»[6], «Нәбатат»[7]лары, Һади Атласиның кечкенә бер «Тарихы табигый»сы, мөгаллим Гобәйдулла Рәдүдинең[8] «Табигать эчендә» дигән калын гына, ләкин бәгъзе урыннарында шигырь теле белән хискә биреләбрәк язылган бер әсәре белән башланган бу мәйдан соңыннан Харис Фәйзи, Шонаси, Габдерәшит Фәхретдинов, Габдулла Гыйсмәти[9], Хәнәфи Бакиров[10] кебек төрк һәм рус мәктәпләрендә мәгълүмат алган кешеләр аркылы киңәйтелә барды. Харис Фәйзинең «Гыйльме әшья»лары белән Шонасиның «Физика» һәм «Кимия»ләре татар мәктәпләрендә дәреслек булып

[1] Сүз Харис Фәйзи-Чистапулиның 1903–1904 елларда нәшер ителгән алты китаптан торган «Хөләсаи тарихе гомуми» хезмәте турында бара. Заманында бик популяр һәм бай эчтәлекле бу дәреслек, 1907 елда Мөгаллимнәр җәмгыяте тарафыннан мәдрәсәләрдә куллану өчен тәкъдим ителгән.

[2] Сүз Фатих Кәриминең 1911 елда нәшер ителгән «Мөхтәсар тарихе гомуми» китабы турында бара.

[3] Роберт Юрьевич (Георгиевич) Виппер (1859–1954) – тарихчы.

[4] Икътибас – цитата китерү.

[5] Шакирҗан Хәмиди (Шакирҗан Әсәдулла улы Хәмидуллин, 1878 яки 1880–1921 елдан соң) – мулла, мөгаллим, инкыйлабчы, язучы, мөхәррир.

[6] Хәйванат – зоология.

[7] Нәбатат – ботаника.

[8] Гобәйдулла Габделмөэмин улы Рәдүди (1885–1912) – шагыйрь, педагог. «Кыйссалы вә хиссалы шигырьләр» (1907), «Гөлзаре сыйбъян» («Балаларга чәчәк түтәле», 1907), «Мәктәп өчен шигырьләр» (1909) исемле шигъри җыентыклар, «Табигатькә сәяхәт, яки тарихы табигыйә» (1908 ), «Тәсһиле җәгърафия» («Җиңел аңлаешлы география», 1911) дәреслекләре авторы.

[9] Габдулла Төхфәтулла улы Гыйсмәти (1883–1938) – журналист, мәгариф эшлеклесе, башлангыч мәктәпләр өчен әлифба, татар теле һәм туган тел дәреслекләре авторы.

[10] Хәнәфи Кәрим улы Бакиров (1884–1934) – педагог, мәгариф эшлеклесе.

кулландылар. Гыйсмәтинең «Су»ы да үз бабында зур гына бер әсәр иде. Ләкин Советлар төзелгәннән соң да бу юлда кызу эшләп килүче Шонаси бу бабта иң кызу эшчәнлек күрсәтүчеләрдән һәм төпле киң эз салып баручылардан булды. Октябрьдән соң татар дөньясында фәннәрне җиңел татар телендә гомумиләштерү – популяризация ясау эшендә дә уңышлылык күрсәтүче бу педагог-мөхәррирнең дәреслекләре күбрәк мәкъбүл булып[1], күп таралды, тәкрар басылдылар. Ләкин атамалар мәсьәләсендә бу мөхәррир башта күбрәк госманлы истыйляхларын алган иде. Янә бу мәүзугларда югарыдагы китапларга «Шура», «Аң» журналларындагы төрле кешеләр тарафыннан язылган гыйльми мәкаләләрне кушарга кирәк.

Шушы табигыят китаплары белән бергә үк аны укыту методлары да языла башлады. Бу юлда беренче адым карт педагог-методист, мөхәррир Мөхетдин Корбангалиевнең журналлардагы мәкаләләре белән башланды. Болар бу турыда, шөбһәсез, әһәмиятле беренче адымнар иде.

Җәгърафиядә беренче карлыгачлар Харис Фәйзинең «Ысулы җәгърафия» исемле зур, тулы әсәре (Каюм Насыйридан соң), Фатих Кәриминең «Мөхтәсар җәгърафия»се белән янә Харис Фәйзинең «Тәгаллиме җәгърафия»се кебек китаплар булдылар. Ләкин боларда да атамалар төрек җәгърафиясе атамалары иде. Соңыннан җәгърафиядә уңышлы адымнарны Мөхетдин Корбангалинең «Дөнья»лары[2] белән Габдерәшит Фәхретдиновның «Рәсемле җәгърафия»ләре күрсәттеләр. Мөндәриҗәсе, тәртипләре ягыннан да, тел-атамалары ягыннан да болар шулай булдылар.

«Мәктәпләр гыйлеме өчен булган яңа нәрсәләрдән итеп «Мәгариф» нәшер иткән «Дөнья» җәгърафияләрен алырга ярый. Корбангалиев бу әсәрендә яңа рух күрсәтә. Җәгърафия дәресләрен коры исем ятлау, сан бикләүдән хәяткә, табигатькә төшерә. Студент Габдерәшит әфәнденең дә мәктәпләр юлында ике тәҗрибәсе: «Рәсемле җәгърафия»се белән «Рәсемле нәбатат»ы чыкты.

Корбангалиев белән Фәхретдинов әсәрләрен күргәч, икенче бер нәрсә дәхи күңелгә йылы бирә: болар рус мәдәнияте эченнән чыгучыларның безем матбугатта эшли башлавын – татар матбугаты эченә яңа рух керә башлавын күрсәтә. Шуның белән бергә фәнни

[1] Мәкъбүл булып – кабул ителеп.

[2] Сүз Мөхетдин Корбангалиевнең 1912 елда басылган «Дөнья» исемле табигать белеме дәреслеге турында бара.

истилахлар юлында үзгәреш туарга ихтималлана. Болар гарәпчә аз белә, русча алса, килештерми, ирекле-ирексез, татар сүзен эзләргә тырыша. Дөрес, муәффәкыятьсез урыннары да бар, ләкин боларның беренче тәҗрибә икәнлеге безне юатырга тиешле» («Аң», 1 нче сан, 1914 ел. Г. Ибраһимов мәкаләсеннән).

Җәгърафия дәреслекләре белән бер уңайдан шуны да әйтеп үтәргә кирәк: Мөхетдин Корбангалиев үзенең әлифбалары, уку китаплары белән бездә мәктәп эшләрен бөтен көче белән Яурупа нигезенә салу юлында эшләүче зур татар методистларыннан беренчесе булды. Янә Вафа Надиевның җәгърафияләре[1] чыкты. Ләкин алар госманлы теле аралаш чуар тел белән язылган җәгърафия китаплары булдылар.

**Риязият.** Бу ун ел эчендә риязият әдәбияты да үз юлында үсүендә двәам итсә дә, әдәбиятның башка тармаклары эчендә иң йомшагы шушы бүлем булды. Хисаптан, һәндәсәдән зуррак күләмдә күп китаплар чыга алмады.

Риязият методикаларыннан Нургали Надиевнең 1917 елда «Хисап методикасы» дигән бер кулланмасы чыкты.

**Педагогия.** Бездә педагогия әдәбиятыннан иң беренче адым, беренче тәҗрибә булып Риза казыйның «Әдәбе тәгълим» (1902 елларда) басылган иде. Соңыннан Әхмәтҗан Мостафаның Мисыр педагогларыннан Хәсән Тәүфыйктан тәрҗемә кылган «Педагогияи гыйльмия», «Педагогияи гамәлия»ләре[2] һәм Г. Әмининең дә «Ысулы тәрбия вә тәгълим» дигән китаплары басылдылар. Боларның әүвәлгесе бөтенләй ислам рухында идеализм тамырыннан үсеп чыгып, ислам фәйләсүфләре һәм педагогларының тәрбия нәзарияләре, әхлакый тәгълиматларына нигезләнеп, иске ысулда язылган, ләкин дини һәм авторитарный[3] бер педагогия яисә дөресрәге ислам сызыгында бер әхлак тәрбиясе китабы иде. Китапның исеменең «Әдәбе тәгълим» булуы һәм китапның исеме астына да «Гыйльме әхлакдан тугызынчы җөзьә» дип куелуы шуны үзе үк күрсәтеп тора. Бу китап аркылы Рагыйб Исфаһани[4], Ибн Мискәвия[5], Газали,

[1] Сүз Вафа Надиевнең 1908 елда басылган «Русиянең мөфассал җәгърафиясе» китабы турында бара булса кирәк.

[2] Сүз Хәсән Тәүфыйк Мисрыйның «Педагогияи гыйльмия вә гамәлия» хезмәте турында бара. Ул, Әхмәтҗан Мостафа тарафыннан тәрҗемә ителеп, «Дин вә әдәп» журналының 1907 елгы – 5–14, 1908 елгы 1–7 нче саннарында басылып чыга.

[3] *Кирилл хәрефләре белән язылган*.

[4] Рагыйб Исфаһани (1108 елда вафат) – исламият галиме, тәфсирче.

[5] Ибн Мискәвия (Мискавейх; якынча 932/936–1030) – фарсы тарихчысы, шагыйрь һәм фәлсәфәче.

Борһан әт-Дин Зәрнүҗи[1] («Тәгълим әл-мөтәгаллим» иясе) кебек зур ислам педагогларының фикерләре дә кергезелгән булып, гомумән, монда тәрбия турында күп Шәрык-ислам галимнәренең фәлсәфи карашлары, гыйльме тәрбиягә хезмәтләре, тоткан ысуллары күрсәтелә бара. Ризаның оста каләменнән үзенә махсус ярым төркчә бер өслүб белән язылган бу педагогия китабы берничә басма күтәрде.

Икенчесе исә – Яурупа буржуазиясе педагогиясенә нигезләнеп, Яурупа мәгънәсе белән гыйльми бер юлда язылган Хәсән Тәүфыйк педагогиясенең тәрҗемәсе. Теле бик күп гарәпчә атамалар, гарәпчә сүзләр белән чуарланып беткән һәм әдәби яктан Ризаныкы дәрәҗәсендә җиңел, гыйльми булып эшләнә алмаган булса да, гомумән сүз төзелешләре ягыннан аңа караганда татарчага тартымрак булып чыккан иде.

Өченчесе, (Г. Әмининеке) исә үзенең «әл-Ислах»тагы игъланы буенча, «туганыннан алып сын балигына кадәрле балаларны тәрбияләмәк, әлифба, кыйраәт, гыйльме халь[2], лисан, тарих, җәгърафия, хисап кеби мәктәбе ибтидаия вә рөшдия[3] дәресләрене тәгълим итмәк ысулыны Яурупа лисаннарында улан ысулы тәрбия вә педагогия китапларына муафыйк рәвешчә бәян иткән». Ләкин, икенчесе шикелле үк, ни өчендер матбугатта артык игътибар казана алмаган бер әсәр булды.

Һәрхәлдә, бу өч әсәр өчесе дә үзләренең һәрьяктан күп кимчелекләре белән бергә татар педагогия әдәбиятының башлангычлары, беренче адымнары иде. Боларның инде әһәмиятләре, шул рәвешчә, тарихи яктан гынадыр.

Соңыннан Октябрьгәчә булган ун ел эчендә татар педагогия әдәбияты заманага тагын да ачыграк, тулырак җавап бирә ала торган берничә зур гына әсәрләргә ия булды: Шонаси төрекчә М. Кязимнан татарчага «Тәгълим вә тәрбия тарихы һәм дөньяның зур фәйләсүфләре» исеме белән бер тәрбия тарихы тәрҗемә итте. Шуның өстенә шул ук Шонаси тарафыннан, яурупалаша башлаган госманлы педагогиясенә нигезләнеп, шулардан материал алып, шул ук ме-

[1] Борһан әт-Дин Зәрнүҗи – XIV йөздә яшәгән исламият галиме, «Тәгълим әл-мөтәгаллим» («Гыйлем эстәүчеләргә гыйлем алу юллары турында нәсыйхәтләр) китабы авторы.

[2] XIX гасырда һәм XX гасыр башында бик күп басылып, сорау-җаваплардан торган татар телендәге дәреслекләр «Гыйльме халь» дип аталган.

[3] Мәктәбе ибтидаия вә рөшдия – башлангыч һәм урта мәктәп.

тод белән «[Ысулы тәгълим вә тәрбиядән] фәнни тәдрис»[1] язылды һәм берничә басма күтәрде. Октябрьдән алда Г. Сәгъдинең «Фәнни тәрбия дәресләре» белән «Фәнни тәрбия вә тәгълим»е басылып чыкты. Рус, Яурупа методы белән язылган бу ике әсәрнең әүвәлгесе конспект рәвешендә кыска дәреслек итеп язылган булса, икенчесе дә татар педагогия әдәбиятында күләм ягыннан зурысы иде. Болардан соң татар дөньясына тәрбия бабында күп тәҗрибәле карт педагог Хәсән Галинең педагогия һәм дидактикасы басылып чыкты. Телләре, аңлатуларының җиңеллеге ягыннан да, турыдан-туры тәҗрибәгә таянылып, шуның өстенә Яурупа педагогиясе нигезендә төзелгән һәм мөндәриҗәгә дә тегеләр шикелле үк бай булулары ягыннан да бу әсәрләр мөһим әсәрләрдән иде.

Билгеле, башка тәрбия китаплары шикелле үк, болар да марксизм методы белән язылмаганнар иде. Боларда, әлбәттә, һәммәсендә дә идеализм шаукымнары, буржуазия идеологиясе «зәхмәте» бар иде. Болар, шул замана гөнаһларын исәпкә алмаганда, татар педагогия әдәбиятыннан соңгы әһәмиятле әсәрләр булдылар.

**Дини фәлсәфә.** Бездә Октябрьгәчә булган ун ел эчендә иң кызу үсеп киткән әдәбиятның берсе фәлсәфә, фәлсәфи мәсьәләләр әдәбияты булды. Аңарча үзенең «Изһар әл-хак»лары белән Мөхәммәд Күлтәси бар иде. Бу мәйданда кызу эшчәнлек күрсәтүчеләр күбрәк дини галимнәрдән Риза казый, Муса Биги, Зыя Камали, Закир әл-Кадыйри каләмнәре булды. Бу бабта хосусан Риза, Муса һәм Зыя Камалилар бик шауладылар. Матбугат бервакыт бөтенләй шулар мәсьәләсе белән мәшгуль булып китте. Шулар өстенә Яурупа мәгънәсе белән фәлсәфи каләм иясе булып «Аң»да өзексез язып килүче М. Хәнәфи[2] иде. Аның «Хәят вә фәлсәфә» («Аң», 1912–[19]13 ел, 2, 21, 22, 23 нче сан; 1912 ел, 2 нче сан) дигән исем астында язып килгән мәкаләләре заманында әһәмиятле мәкаләләр иде. Журналлардан боларның киң урыннары «Аң» белән «Шура» булды.

1905 ел революциясеннән алда ук, татарның әдәби-фикри яңару хәрәкәте эчендә эшләп, берничә әсәрләре аркылы җитди каләме белән танылган Г. Чыгтай[3], үзенең күптән эшләнеп килгән әсәренең беренче бүлеген бастырып чыгарып, дингә каршы әдәбиятның беренче адымын күрсәтте. 1905 ел революциясе аркасында бездә

[1] «Белем һәм тәрбия бирүнең фәнни принциплары».
[2] Бу «фәйләсүф» доктор соңыннан провокатор булып чыкты. *(Авт. иск.)*
[3] Чыгтай (Галиәсгар Мөгыйн улы Гафуров, 1867–1942) – язучы, журналист.

яшьләр арасында дингә каршы фикерләр яхшы ук таралып барадыр иде. Хәтта «Галия» кебек дин мәдрәсәләрендәге укучылар арасында да бу турыда гамәли хәрәкәтләр сыман эшләр күренгәләп үтте. Мәсәлән, динсезлек фикерләре белән сугарылып, соңыннан мөхәррир булып китәчәк Г. Ибраһимов тарафыннан «Галия»дә шәкерт чагында «Коръән Алладанмы, түгелме?» исемендә Коръәнгә каршы язылган, ләкин басылмыйча калган әсәре шул хәрәкәтләрнең бер галәмәте иде. Ләкин әле мондый әйберләр шәкертчә бер язу булудан уза алмыйлар иде. Әмма Чыгтай, бу мәсьәләгә өлгереп, пешеп җиткән каләмен тотып, үзенең «Исабәт»ен[1] чыгара.

Бу әсәр түземле, акыллы, ләкин ачык үткен рәвештә Мөхәммәднең илаһи түгеллеген, пәйгамбәр булмаганлыгын, ләкин гарәпнең шул замандагы икътисади, мәдәни-иҗтимагый шартлары астында гына килеп чыккан бер юлбашчы икәнен исбат итте. Моның басылып чыгуыннан соң, татар дөньясында бик зур шау-шулы хәрәкәт кузгалды. Иң башта «Буби» мәдрәсәсенең мөгаллимнәренең матбугат аркылы моңа каршы зур протестлары булып үтте. Гәзит-журналларда да моңа каршы бер-бер артлы каты һөҗүмнәр башланды. Кәбир Бәкер – «Йолдыз»да, Г. Баттал «Вакыт»та бу әсәр хакында, мактап, берәр генә иҗаби мәкалә кертеп калган булсалар да, шулардан башка бу китап турында матбугатта җылы сүз әйтүнең тишеге бикләнде, юл бирелмәде. Хәтта үзен динсез санап йөргән зыялылар, гүя тактика юлыннан, Чыгтайның шул әсәрен яклыйсылары килмәде.

Бу авыр көрәшнең ахыры мәгълүм: Г. Чыгтай бу әсәргә каршы кузгалган шул хәрәкәтләр дулкынында җиңелеп калырга, хәтта әсәрен җыеп яндырырга ризалык күрсәтү дәрәҗәсенә кадәр барырга мәҗбүр ителде. Тик революциядән соң гына бу әсәр иреккә чыгып тарала башлады (бу хакта шул ук мөхәррирнең «Исабәт эшләре, исабәт юлдашы» дигән китабыннан мәгълүмат алырга кирәк).

Шулай ук бу мөхәррир, шул башланган эшен иркенләп дәвам иттереп, Октябрьдән соң «Исабәт»нең II, III китапларын дөньяга чыгару чараларын күрде. Казанда басылган «Коръәнне тикшерү» – шул китапның II бүлегедер.

[1] Сүз Галиәсгар Гафуров-Чыгтайның исламның төп кагыйдәләренә каршы чыккан «Исабәт» исемле публицистик хезмәте (1909) турында бара. Коръән һәм шәригатьнең күп кенә кагыйдәләрен шик астына куйган бу китап өчен автор руханилык дәрәҗәсеннән мәхрүм ителә.

## 4. Ун ел эчендә матур әдәбият

Октябрьгәчә булган ун ел эчендә татар әдәбият дөньясында иң кызу үскәне матур әдәбият булды. Бу вакыт эчендә Галиәсгар Камал, Фатих Кәрими, Гаяз Исхакый, Закир Һадилар кебек, 1905 ел революциясенәчә җитешкән әдипләр каләме һаман әүвәлге юллары, әүвәлге идеяләре буенча кызу эшчәнлек күрсәтүләрендә дәвам иткән шикелле, революция белән һәм революциядән соң җитешкән яшь әдип-шагыйрьләр эшне нык кыздырып алып киттеләр.

Революциягәчә, ягъни икенче әдәби дәверебезнең беренче баскычында җитешкән әдипләребезгә югарыда үз урыннарында озын тукталып үткәнлегебездән, бу урында аларның каләмнәре аркылы тудырылган әдәби хадисәләргә, түбәндә шул ук әүвәлге сызыкларында дәвам иткәнлекләре өчен, яңадан кайтып тормаячакбыз. Безнең бу урында тукталачак әдәби хадисәләребез бигрәк соңгылар булачак.

**Лирика һәм лирикларыбыз.** Татар матур әдәбиятының лирика бүлемен һәм шуларны иҗат итүче лирикларга күчүдән элек, кыска гына рәвештә булса да, иҗатларның төре белән таныштырып үтик.

Соңгы фәннирәк юл белән әдәби иҗатлар икегә аерылалар: 1) кешенең эчке дулкыннарын, тойгыларын күрсәтүче яки шуларны тасвир итүче иҗатлар; 2) турыдан-туры тышкы дөньяны, матди-иҗтимагый тормышны сурәтләндерүче иҗатлар (жизнеобразное творчество[1]).

Боларның беренчесе – «лирика» (йөрәк шигырьләре) дип атала. Боларда шагыйрь бигрәк шәхси һәм иҗтимагый хисләрне, өмет һәм теләкләрне, ачу һәм шатлыкларны, фикер һәм тойгының да юнәлешеннән бигрәк омтылышларын тасвир итә. Боларда өслүб тә эмоцияле була. Икенчесе, тышкы матди тормышны, шуның сурәтен бирүне төп максат иткәнлеге өчен, «тормыш рәвешле иҗат» (яисә тормыш сурәтле иҗат)лар дип атала. Иҗатның бу төренә хикәя, роман, поэма һәм театр әсәрләре керә. Бу ике иҗат бер-берсеннән әсасән башка. Әсасән, дибез, чөнки боларның башкалыгы, аермасы тасвир рәвешендә, язылу формаларында гына түгел, бәлки алар үзләренең эчке мөндәриҗәләре, төп максатлары белән бер-берсеннән нык аерылалар[2].

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[2] Лирик иҗатлар алар шагыйрьнең эчке рухи дулкыннарының кайнавыннан, шуларның сүз аркылы куелуыннан гыйбарәт. Лирик шигырьләрдә рухи гонсырлар аһәңе бер рәвештә үзара бергә кушылып тоташа һәм шуның аркылы эчке-рухи бер вәзен (акыл-хис вәзене) тудырыла. Икенче төрле әйткәндә, лирикалар йөрәк эмоциясен, йөрәк дулкыннарын, йөрәк кабарынмаларын тасвир итәләр. Лирикалардан башка

Бездә 1905 ел революциясе белән бик кызу күтәрелгән әдәби хадисәләр матур әдәбиятыбызның лирика өлеше булды. Бу юлда беренче адым Мәҗит Гафури белән башланган хәлдә, аның белән бергә Тукай, Думави, Зариф Бәшири, Укмасыйлар йөрәге дулкынланып китте. Боларның лирикалары башта гәзит, журналларда, соңыннан аерым китап булып басылып тарала башлады. Вакытында татарның әдәбият укучылары, гомумән, татардагы укучы җәмәгать боларны яратып укыды: мәктәпләрдә һәм дәреслекләрдә дә шуларның шигырьләре укылды, шулар тикшерелде. Шулар мисалга алынып йөреде.

**Бу вакыт эчендәге лирикада мәүзуг һәм мөндәриҗә.** Дин, милләт кайгысы, милли-дини тәрәккый, җәдитчелек, Яурупа белеменә кызыгу һәм шуңа кызыктыру, кадимчелеккә, тәгассебкә һөҗүм, шуннан көлү; хатын-кызлар хөррияте, күңелләргә ислам диненең тәрәккыйгә каршы түгел икәнлек тойгысын салу, исламга мәхәббәт, борынгы ислам мәдәниятен мактап, шуңа Яурупа мәдәниятен катыштырып, шуларның икесеннән укмаштырылган яңа бер мәдәнияткә кызыктыру, «милләт хадимнәре»н һәм хөрриятне, җәдитчелекне мактау, шулар өстенә шәхси һәм иҗтимагый төрле гаҗизлекләрдән, көчсезлекләрдән зарлану я Аллага ялвару яисә аннан бөтенләй йөз дүндерү, дәһрилек тойгылары – менә 1905 ел революциясе белән күтәрелгән һәм аннан соң да Октябрьгәчә дәвам

---

шигъри иҗатлардан көтелгән максат, алардан көтелгән фикер, мәгънә дә көтелми. Музыка турында «фикер», «мәгънә» сүзе ничек татбикъ ителсә, шул турыда аны ничек дип аңласак, лирикада да шулай. Лириканың үзенә махсус төп максаты хисләргә, хис-фикер дулкыннарына тәртип кертү, рухи хәлләрне күтәрү, камилләштерү һәм аларга тулы бер аһәң бирү, шулай ук, рухи көчләрдә икътисад ясаудан гыйбарәт. Ничек тә булса, бер вәзен-аһәң – лириканың аерым бер импульсы. Мөндәриҗә белән өслүб, шәкел белән мәгънәнең бер-берсеннән аерылмау хосусияте дә һәрнәрсәдән элек лирикаларда ачык беленә. Шуның өстенә, лирикаларда тел-өслүбнең хисле, дулкынлы-эмоцияле булуы да зур әһәмиятле. Эчке дулкыннарны, кәеф һәм зәвыкларны башкаларның ми һәм йөрәкләренә дә барып керерлек, аларда да шуларны уйгатырлык, кузгатырлык итеп бирә белү – менә лириканың һәм лирик бер шагыйрьнең төп сыйфаты, шулай ук төп вазифасы шушы. Тормыш рәвешле иҗатлар эчке-рухи тормышны, андагы тышкы-гомуми хәлләрне, булган, булып торган, булачак булган яисә булуы хыял ителгән тышкы вакыйгаларны тасвир кыла, һәм ул шуны төп максат итә. Алар укучының дикъкатен тышкы якка, матди дөньяга, вакыйгый эшләргә карата, шуңа бәйлиләр. Шулай ук боларда шагыйрь үзен онытырга, үзенең тойгыларына, үз кәеф һәм рәвешләренең аңлатылуына, күрсәтелүенә бер дә юл куймаска мөмкин (лирикада исә шагыйрьнең үзлеге, үз кәефе, үз зәвыгы нык катнаша). Тормыш сурәтле иҗатларда объектив булу сызыгы – төп сызык. Шагыйрь-әдип, һәрхәлдә, вакыйга алдында тынычрак булырга тырыша (лирикада бу булмый), тормыш сурәтле иҗатларда төп максатның үзәге – типлар, җанлы табигатьләр (характерлар) тудыру. Аларның төп сәнгатьчелек сыйфатларының бер тамыры да шул ноктада. *(Авт. иск.)*

иткән лирикаларыбызның уртак мәүзуглары, төп мөндәриҗәләре шушы нәрсәләр иде. Шуның белән бергә, бу вакыт эчендәге лирикалар үгетчелектән, әдәби вәгазь булучылыктан да аерылып җитмәделәр. Башта бу хәл бик куәтле булса да, соңга таба йомшады йомшавын, шулай да һаман моннан котылып бетә алмыйлар иде.

**Бу вакыт эчендәге лирикаларда идеология.** Лирикаларыбызның югарыдагы мәүзуг, мөндәриҗәләре бу вакыт эчендәге лирикаларда идеологиянең төп сызыклары ничек булганлыгын үзе үк күрсәтеп тора. Болар, шөбһәсез, либераль буржуа, аша китсә «социалист киселгән» вак буржуа рухында, шушы сызыкта кайнап үсәләр иде. Өметлелек белән өметсезлек катыш яисә, гомумән, өметсезлеккә – пессимизмга нык авышкан хәлдә, болар һаман татар буржуазиясенең «кәгъбә»сенә таба актылар. Бу шагыйрьләрнең кыска тәгърифе: болар «илһам»чы, «фәрештә»че, «оҗмах-җәннәт»че, «илаһ»чы шагыйрьләр, дин һәм милләт былбыллары иде.

Бара торгач, бу шагыйрьләрнең эченнән татарда ялкынлы пессимизм тойгыларын көйләүче Тукай, Сәгыйть Рәми, Дәрдмәнд кебек киң канатлы, көчле талантлы чын классик шагыйрьләр дә эшләнеп чыкты.

**Лирикаларга әдәби агымнар ягыннан караш.** Бу дәвер лирикаларының бер өлеше рационализм-фикерчелек лирикаларыннан гыйбарәт булса, икенче бер зур өлеше дә баш-аягы белән романтизмга баткан лирикалар булдылар. Мәсьәлә яхшырак ачылсын өчен, туры юлыбыздан әз генә читкә каерылып чыгып булса да, бу урында әдәби агымнар турында кыска гына мәгълүмат биреп үтик. Әдәби агым дип әдип-шагыйрьләрнең шигырь язуда, шигъри иҗатларында алган фикри-рухи юнәлешләренә әйтәләр.

Әдәби агымнарның берсе – рационализм, фикерчелек дип аталган агым. Бу агымның төп хосусияте әдәбиятта һәрнәрсәдән элек акылга, фикергә әһәмият бирүдән гыйбарәт. Акыл, фикер һәм аларны тәрбия – бу агымда төп нигез. Бу агым адәмнәре әдәбият аркылы һәрнәрсәдән элек халыкның акылына тәэсир итәргә, халыкка яңа тәэсирләр бирергә тырыштылар, әдәбият тәмам шуның коралы ителде.

Бөтен мәдәни халыкларның уяну дәверләрендәге әдәбиятлары башта шушы агымны үткәрделәр, Гаребтә дә, Шәрыкта дә бу шулай булды. Яурупада бу агым XVII–XVIII йөзләрдә руханилар һәм дворяннарның золымнарына, төрле тигезсезлекләргә, ялган һәм хорафатларга каршы күтәрелде, шуларга һөҗүм белән башланды. Халык

арасында шуларга каршы фикер таратылды, бу да, билгеле, Яурупадагы икътисади тормышның үзгәреше һәм техникадагы яңалыклар сәбәпле туган иҗтимагый-сәяси кузгалышларның, руханилар, дворяннар җиңелеп, буржуаның аларга галиб[1] булуының җимеше иде.

Бу агымга «агарту агымы» дип тә әйтелә. Бу агым татар әдәбиятында 1905 ел революциясеннән элек үк, Муса Акъегетзадә, Ильяси, Ф. Халиди, Заһир Бигиләр заманында ук башланып, Ризаның «Әсма» һәм «Сәлимә»ләре белән көчәйтелеп, Фатих Кәрими белән Гаязның әүвәлге әсәрләре аркылы дәвам иттерелеп килгән булса да, лирикада әле ул көч ала алмаган иде. 1905 елдан соң инде без татар әдәбиятының лирика бүлемендә Мәҗит, Тукай, Бәшири, Думавилар каләме аркылы шул агымның кыздырылып җибәрелгәнен күрдек. Дөрес, бу нәгыз[2] рационализм булып күп дәвам итә алмады. Үзенә тиз вакыт эчендә сентиментализм, романтизм гонсырлары[3] катыштырып, ниһаять, нәгыз романтизмга әйләнде. Ләкин һаман аннан тазаланып бетә алмый иде. Бу турыда бигрәк тә нык торучылыкны Мәҗит [Гафури] каләме күрсәтте.

Әдәби агымнарның икенчесе – романтизм агымы. Шагыйрьләрнең кайсылары күбрәк үзенең эчке дөньясына нык юнәлү белән бергә, дөнья тормышыннан, матди тормыштан бигрәк хыялый тормышны, хис һәм хыял белән яшәүне алга алалар. Хыялда, хистә кабарынган, чын матди тормыштан озак яисә аңа ят булган тормышка, шундый бер тормышның матурлыкларына, шуның хыялый күренешләренә кызыга һәм шигырьләрендә, иҗатларында, ничек кенә булса да, шул якка каералар. Чын матди тормышны да чын үз төсе белән түгел, шагыйрьнең хыялында буялып сурәтләнгән, үзенең шәхси тойгылары, шәхси карашлары тәэсире астында бизәлеп күренгән бер сурәт аркылы төшенәләр.

Шагыйрьләрдәге менә шушы хәл, матур әдәбиятта күренгән менә шушы юнәлеш *романтизм* дип атала. Һәрнәрсәдән элек хискә, хисси-хыялый нәрсәләргә, дини-милли тойгыларга әһәмият бирү; борынгы үткән заман тормышына омтылу, шуларны сагыну; хәзерге тормыштан, хәзерге мәдәни-иҗтимагый барыштан риза түгеллек, шуннан зарлану; шундагы бәхетсезлекләрне күреп, шуның өчен елау, сыктау, рәнҗү, сыкрану, ниһаять, матди тормыштан, аның

[1] Галиб – җиңүче.
[2] Нәгыз – саф.
[3] Гонсырлары – элементлары.

шартларыннан тәмам бизеп, әллә нинди икенче бер матди булмаган хыялый тормыш эзләү, икенче төрле әйткәндә, «рухлар дөньясы»на – гүя күзгә күренми торган, тик акыл, рух белән генә сизелеп беленә торган бер дөньяга ышану; төп мәңгелек тормышны, чын бәхетне дә шунда күрү; дингә – Аллага бәйләнеш, гүя аның ярдәменә, көченә сыгыну, мәгънәви, илаһи мәхәббәт, кодсият кебек нәрсәләргә алдану һәм шулар өстенә дә халыкчылык кебек хәлләр – һәммәсе дә романтизмның төп хосусиятләре һәм аның белән бергә була торган сыйфатлардыр.

Бу агымның баш адымнары, бигрәк тә хискә, хисси нәрсәләргә артык әһәмият бирү, күбрәк хис белән яшәү баскычы булып, бу баскыч Яурупа телендә «сентиментализм» дип атала. Романтизмның соңгы баскычы тәмам өметсезлек, пессимизмнан гыйбарәт. Моның да икенче бер рәвеше – символистлыктыр. «Символ» сүзе юнанчадан алынган бер сүз булып, асылда «аз галәмәтләргә багланган маһият – барлык» дигән мәгънәдә, әдәбиятта исә бу сүздән, гадәттә, ишарә, ымлау юлы белән әйтелгән кинаяле мәгънәләрне эченә алган күренешле (картиналы) тасвирларны аңлыйлар. Символизмның романтизмнан аермасы да – фикер-мәгънәне төрле катлаулы ишарәләр, киң, тирән кинаяләр, төенле, бикле сүзләр белән аңлатуда һәм сүзләрнең мәгънәләренең артык нечкәләндерелеп ялтыратылуында, аһәң, музыкальлелеккә артык әһәмият бирүендәдер. Символизмда фикер-мәгънәләр төгәл әйтелеп бетерелми, бәлки фикер-мәгънә җепләренең очлары яшерелеп, тик күбрәк шуларга ишарәләр, ымлаулар белән генә канәгатьләндерелә. Бу агым буенча, сүзләр фикер-мәгънәләрне төгәл аңлата алмыйлар, аларча, сүзләр – фикер-мәгънәләрне ачык аңлатып бирүнең коралы яисә савыты түгел, бәлки аларның тик бер маяклары, иероглифлары булып кына хезмәт итә алалар. Бу агым шагыйрьләре өчен *рәмез-символ* – тасвирның тамыры, төп алымы (приемы[1])дыр.

«Символизм агымында табигатьтәге бер нәрсә, бер хадисә, бер вакыйга, матди бер күренеш тасвир ителергә мөмкин. Ләкин монда төп максат шуларның үзләрен тасвир итү булмый, бәлки андан төп максат, шулар аркылы, шул тасвир, шул күренешләр ярдәме белән, шагыйрьнең фикер һәм хисләренә, аның эчке рухи тойгыларына, хыялларына, кәефенә, башыннан кичергәнләренә ымлау һәм шуңа ишарә кылудан гыйбарәт була».

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

«Рәмезче-символист шагыйрьләр бу дөньяга икенче бер яшерен булган дөньяларны – «сер дөньясы»н каршы куйдылар. Алар шагыйрьне гүя бер кяһин[1], гүя бер пәйгамбәр кебек таныдылар. Аларча, шагыйрь – яшерен белемнәр, серләр иясе. Ул үзенең рәмез-символлары аркылы «әсрар»[2] адәмләре белән күз кысыша. Символист бер шагыйрь өчен символ дигән нәрсә ул – «сер ачкычы», ул аның өчен «мәңгегә караган бер тәрәзә». Гүя ул шул тәрәзә аркылы бу дөньядан икенче бер моңа башка, моңа ят булган дөньяга карый. Аларча, мәгънә, фикернең чиге юк, ә сүзләр аларны чиклиләр. Рәмезләр-символлар исә әнә шушы чиксез мәгънәләрнең якларын күрсәтәләр.

Кыскасы, символистлар – вакыйгый-реаль тормыштан тәмам аерылган, баш-аяклары белән тәмам «мәгънәви» тормышның эченә кереп гарык булган шагыйрьләрдер. Бу агымның төбендә рухан[3] икегә бүленү ята. Ике дөньяны бер-берсенә каршы куеп, бу дөньядан, аның күренешләрендән һәм шул күренешләр аркылы икенче бер беленмәгән, күренмәгән «ят дөнья»га качу – менә бу аларның әсаслары[4]. Мәшһүр рус шагыйре Валерий Брюсов[5] тәгъбиренчә әйткәндә, символистлар шушы тормыш буранларындан, андагы кагылу-сугылулардан раһибләр[6] оясына (ханәка[7] вә сәүмәгәгә) яшеренеп, гөлләр белән бизәлгән тәрәзәле манараларга менеп алалар да, буддилык тынычлыгы эчендә, тыныч һәм рәхәт кенә бер хәлдә, чуалган, изелгән тормышны тәрәзәдән карап, моталәга кылып[8] яталар. Шундан алар үзләренең легендаларын, сәнгатьчелек шәкелләрен иҗат итәләр»[9].

Кыскасы, символистлар үз эчләрендә, үзләренең рухи дөньяларының тирәнлеге эчендә югалучылар булып, болар һәрнәрсәдән элек сәнгатькә, сәнгатьчелеккә табыналар. Болар үзләрен үзләре сәнгатьнең санигы – сәнгатьне яратучы, бар итүче дип беләләр. Алар сәнгать һәм сәнгатьчелек белән тәмам исерәләр, аларны, Шәрык теле

[1] Кяһин – күрәзәче.

[2] Әсрар – серләр.

[3] Рухан – рухи яктан.

[4] Әсаслары – нигезләре.

[5] Валерий Яковлевич Брюсов (1873–1924) – шагыйрь, прозаик, драматург, тәрҗемәче, әдәбият белгече, тәнкыйтьче һәм тарихчы. Рус символизмы теоретигы һәм аңа нигез салучыларның берсе.

[6] Раһибләр – монахлар.

[7] Ханәка – суфиларның, дәрвишләрнең тора торган урыны.

[8] Моталәга кылып – өйрәнеп, хөкем чыгарып.

[9] Мөхәррирнең үзбәк телендә 1925 елда басылган «Гамәли һәм нәзари әдәбият дәресләре» дигән китабының икенче басмасы, 119–121 бит. Гомумән, әдәби агымнар турында озын мәгълүмат алу өчен шушы китаптан файдаланырга мөмкин. *(Авт. иск.)*

белән әйткәндә, «җәзебләнүчеләр»[1], «рухиятчеләр» дип әйтергә була. Шуның белән бергә, болар үзләрен бик аз белүчеләр дип саныйлар. Болар – белмәүчелек һәм караңгылык томаннары эченә батучылардыр. Шуның өчен дә алар фикер-мәгънәне ачык итеп аңлатудан качтылар. Томанлы, күләгәле һәм пәрдәле булган шигырьләрне сөйделәр. Ике йөзле һәм ике төрле якка сузыла-тартыла ала торган мәгънәле символлар аркылы үзләренең бөтен рухи хәлләрен, кәеф һәм зәвыкларын аңлатмак булдылар. Менә бу – символизмның беренче төп хосусияте. Алар моң һәм аһәңгә артык авышу күрсәттеләр. Шуның өстенә, артык нечкәләнделәр дә. Нечкәлек – символизмның төп хосусияте. Алар үзләренең фикер һәм йөрәк дулкыннарын, кәефләрен, моң һәм зарларын бигрәк тә сүзләрнең аһәңе, музыкалы булуы аркылы тыңларга, башкаларга да шул юл белән тыңлатырга теләделәр. Гомумән, символистлар сүзләрнең, аңлатуларның музыкалы булуына, аһәңгә табындылар. Менә бусы – символизмның икенче төп хосусиятеннән. Алар рухан музыкалы булмаучыларны һичнәрсәне аңламаучылар дип карыйлар. Символ, аларча, рухның музыкалылыгын кузгата. Алар әйтәләр: «Дөнья безнең рухыбызга кергән чагында, рух һәрвакыт яңгырый; ә рух үзе дөнья булып әйләнгәндә, инде ул дөньяның тышында була», – диләр. Аларча, музыка үзе идеал булып, символны аңлатса, символның үзеннән янә музыкалылык чәчелә; символ ул, аларча, һәрвакыт музыкалы була.

Кыскасы, болар:

1) мәдәнияткә чынлап хөрмәт итүчеләр (бу урында романтиклардан аерылалар);

2) ләкин реализм – чынлыкка бик каты дошманнар;

3) сәясәт эшләренә бик тыныч һәм салкын караучылар;

4) «сәнгать – сәнгать өчен» дип баралар, шигырь һәм сәнгатьнең, романтиклар шикелле үк, тәмам ирекле булуын таләп итәләр;

5) болар – индивидуалистлар, үземчелекне һәрнәрсәдән алга куючылар;

6) болар – сер һәм символ адәмнәре – ишарәчеләр;

7) аһәң, сүзнең музыкалы булуы – боларның җан азыклары.

Әдәбияттагы романтизм, символизм агымы фәлсәфәдәге идеализм – мәгънәвиятчелек мәсләге белән бертуган, болар икесе дә бер үк чишмәнең ике тармагы, яисә әдәбияттагы романтизм – фәлсәфәдәге идеализм чишмәсенең сәнгатьчә бормаланып, шаулап

[1] Җәзебләнү – гыйбадәттә шашу дәрәҗәсенә җитү.

аккан киң бер ермагы. Символизм да – шул ук романтизм, идеализм елгасының тавышлы бер шөлэләсе.

Әдәбияттагы һәрбер агым кебек, романтизм, символизм агымы да һәр халыкта, әлбәттә, икътисади, иҗтимагый тормыш шартларының җимеше булып туды[1]. Шундый ук шартлар астында бөтен Яурупа әдәбият дөньясында XIX йөз шушы романтизм агымы белән башланып китте. Бездә – татар дөньясында исә моңа киң бер мәйдан 1905 революциясе соңында, каты реакция заманнарында ачылды.

Әдәбиятта реализм агымы исә – тәмам романтизмның киресе. Романтиклар күк, хыял кешеләре, җир тормышыннан бизгән, аннан качкан шагыйрьләр булсалар, реалистлар җир, матди тормыш шагыйрьләре, чын вакыйгыйлык тасвирчылары булдылар. Шулай итеп, болар сәнгать һәм әдәбиятны күктән җиргә иңдерделәр. Язылa, тасвир ителә торган бер нәрсәне яисә бер эш, бер хадисә, бер вакыйганы иң әүвәл бик дикъкать белән дөрес тикшереп, аны дөрес өйрәнеп алып та, соңыннан шуны ачык, уяу күз белән, тәмам туры бер рәвештә тасвир итү – менә реализм агымының төп тамыры шунда.

Реалист шагыйрьләр матди тормышны, шушы тормыш эчендә булган яисә аннан туган нәрсәләрне вакыйгый бер хәлдә тасвир ителәр. Мәүзуг, мөндәриҗәләрне турыдан-туры матди тормышның үзеннән алдылар. Бу агым шагыйрьләре әллә нинди серләрдән, серле булулардан, яшеренлекләрдән, алдану, кызыгулардан, шулай ук өслүбтә, тезмәдә тышкы яктан артык елтырап торучылыктан, артык бер шашкынлык, артык бер дулкын күрсәтүдән качтылар. Болар ничек тә тормышның үзеннән алып, чын тормыш картиналары бирергә тырыштылар.

Яурупада бу агым XIX йөзнең 30 нчы елларында, романтиклык агымының инкыйразы заманнарында башланды. Шушы йөзнең урталарында инде бу агым тәмам көчәеп ала. Ләкин [18]80 елларда зәгыйфьләнә башлап, урынын символизмга бирергә мәҗбүр була.

Реализм агымының тууына баш сәбәп шул ук икътисади, сәяси, иҗтимагый үзгәрешләр булган шикелле, символизм агымының тууында да шулай булды.

Без беләбез: XIX йөзнең беренче уны эчендә буржуазиянең руханилар һәм дворяннарга каршы үзенең сәяси хакимият көрәше бе-

[1] Бу турыдагы икътисади, иҗтимагый сәбәпләр мөхәррирнең үзбәкчә «Гамәли һәм нәзари әдәбият дәресләре» дигән китабында озын бәян ителгән. Болар белән танышу өчен, мөтәхәссисләргә шунда карарга мөмкин. *(Авт. иск.)*

теп, Яурупада капитализмның көче ныгый башлый. Буржуазия инде хакимлекне тәмам үз кулына алган була. Инде бу яңа сыйныфның бөтен дикъкате тик үз алдында басып торган гамәли эшләргә, матди тормыш мәсьәләләренә генә каратыла. Байлык, капитал җыю төп максат ителә. Шуның өстенә, янә фәлсәфә мәйданында немец философы Иммануил Кантның[1] (1724–1804) «Саф акылны тәнкыйть» фәлсәфәсе бәрабәренә француз философы Огюст Контның[2] (1857–1898) позитивизм фәлсәфәсе мәйдан ала[3].

Бөтен әнә шушы хәлләрнең тәэсире белән, Яурупада матур әдәбият – шигырь дә үзгәрә. Шул дәвернең шагыйрьләре шушы хәлләргә муафыйк яңа бер әдәби агым тудыралар, реализм агымын мәйданга чыгаралар. Бу агым, романтизм белән бик нык көрәшеп, ахырдан аны тәмам җиңә.

Реалистларның янә бер хосусиятләре шул: аларның каһарманнары да, романтик шагыйрьләрнең каһарманнары шикелле башкалардан күп югары, аерым яисә кешелектән, кеше тормышыннан өстен торган, шулай ук һәрнәрсәдән өмет өзгән затлар булмыйлар, бәлки гади тормыш адәмнәре булалар. Аларның каһарманнарын күктән дә, җирдән дә эзләргә түгел; бәлки алар үзләре үк шул әсәрне укучыга көн саен, сәгать саен очрарга, күренеп торырга мөмкин. Чөнки болар шушы күпчелекнең матди тормышыннан алынган типлар булалар. Болар эчендә зурлар гына түгел, бик түбән саналганнар да, башкалар тарафыннан кимсетелгән, хурланган, мәсхәрә ителгәннәр дә аз булмый.

Менә шушы реализм агымы татар әдәбиятында, гәрчә нәгыз хәлендә булмыйча, үзенә бераз рационализмны һәм сентиментализмны катыштырган хәлдә булса да, Муса Акъегет романы белән башланган; Ильяси, Халиди драмалары һәм «Чистай комедияләре», Заһир Биги әсәрләре аркылы үстерелә башлаган иде. XX йөзнең башларына таба моның нәгыз бер рәвешен Г. Камалның «Бәхетсез егет»е биргән һәм Гаяз Исхакыйның «Өч хатын белән тормыш»лары күрсәткән иде. Әмма 1905 ел революциясе татар әдәбиятында бу агымны да бердән кыздырып җибәрде. Югарыдагы әдипләр өстенә, Гафур Коләхмәтов, Ф. Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов, Шәриф Камал, Ф. Сәйфиләр бу агымны киңәйтеп, үстереп алып киттеләр.

---

[1] Иммануил Кант (1724–1804) – алман фәлсәфәчесе.

[2] Исидор Мари Огюст Франсуа Ксавье Конт (1857–1898) – француз фәлсәфәчесе, социология фәненә һәм фәлсәфи позитивизмга нигез салучы.

[3] Мөхәррирнең «Гамәли һәм нәзари әдәбият дәресләре», 115–118 бит. *(Авт. иск.)*

Боларга түбәндә үз урыннарында тукталырбыз. Инде шушы мәгълүматларны исебездә тоткан хәлдә, югарыдагы төп мәсьәләбезгә – лирикаларыбызга әйләнеп кайтып карыйк.

1905 ел революциясеннән соңгы заман – татарда, гомумән, романтизмның көчәйгән бер заманы. Татарда романтизм чәчәк атарга кирәк булган булса, бу дәвер татарның үз үлчәвенә, үзенең әдәби хәзерлегенә караганда, әнә шуның чынлап та чәчәкләнгән, нык пешкән, ләкин иң күңелсез, иң авыр, иң ачы җимешләрен йөрәкләргә урнаштырган бер дәвере булды. Бу дәвердә риваятьләрдә, театр әсәрләрендә Галиәсгар Камал, Фатих Кәрими, соңыннан Галимҗан Ибраһимов, Фатих Әмирхан, Шәриф Камал, Гаяз Исхакый һәм башкаларның каләмнәре аркылы дәвам иткән, көчәйтелгән реализмчылык агымына каршы, шулай итеп, бу дәвер лирикларында романтизм бөтен көче белән үзен үстерә барды. Хәтта шуларның тәэсире белән Октябрьгәчә булган ун елның соңнарында, Февраль-Октябрь революцияләре алдыннан җитешкән Ф. Бурнаш, Исәнбәт, Ченәкәй[1] кебек яшь романтик шагыйрьләр килеп чыгып, шул ук агымда, шул ук карага манып, каләмнәрен тибрәтеп киттеләр.

Февраль революциясеннән, хәтта Октябрьдән соң да бу агым, яңа төсләрдә дәвам итеп, «әдәби реакция» рәвешенә әйләнде.

Октябрьгәчә булган ун ел эчендә шул ук романтизмның икенче төрле баскычы булган символизм – рәмезчелекнең дә татар әдәбиятында беренче чаткылары күренеп калды. Дәрдмәнд белән Сәгыйть Рәми шигырьләрендә, шөбһәсез, шушы чаткылар бар иде (Октябрьдән соң бу чаткылардан әз генә бер вакытка, Такташ, К. Нәҗмиләр каләме аркылы, тәшвишле, куәтле бер янгын да чыгып алды).

**Мәҗит Гафури.** Милләт, тәрәккый кайгысы белән кабынып китүче татар шагыйренең берсе һәм иң карты Мәҗит Гафури булды. Октябрьдән соң язган «Эшче» поэмасы белән үзенең иң соңгы әдәби үсү дәрәҗәсен ачык күрсәткән бу шагыйрьнең башта төп йөрәк орлыгы ике тармаклы булып кыяк җибәргән иде. Берсе – аның фикерчелеге (рационалистлыгы) һәм шуның белән бергә үгетчелеге, икенчесе дә сентименталистлыгы иде. Башта анда менә шушы ике хосусият катышып барды. «Себер тимер юлы», «Яшь гомерем»е,

[1] Төхфәтулла Гыйззәтулла улы Ченәкәй (1893–1959) – шагыйрь, «Өмет очкыннары» (1918), «Теләкләр төркеме» (1918), «Кан дулкыннары, яки Сугыш» (1919), «Бакчаларда» (1928), «Карагайлы каен урманында» (1928) һ. б. шигырь һәм җыр җыентыклары авторы.

«Милләт мәхәббәт»е кебек шигырьләре һәм «Аң»дагы шигырьләре шуның ачык мисаллары булды. Озакламыйча ук, шушы ике тармак, ике кыяк уртасыннан ул реализм ботагы үстерә башлады. Хикәяләре шуңар мисал булдылар.

Бу шагыйрьнең беренче шигыре 1902 елда «Тәрҗеман»да басылып чыкса да, татар әдәбият дөньясында аерым китап рәвешендә аның беренче адымы 1904 елда «Себер тимер юлы» яки «Әхвәле милләт»е белән башланган иде.

Ул үзенең шушы беренче әсәрендә Яурупаның мәдәниятен, һөнәрен, сәнгатен, фәнен, машинасын, телеграф, телефоннар иҗат итүен, гимназия, дарелфөнүн (университет), академия ачуларын мактап җырлады. Татарларны шулардан гыйбрәт алырга өндәп, татарның наданлыгы, тәгассебе, тәрәккыйдән качулары өчен кайгырды. Аларны тәрәккыйгә чакырды. Ахырда Русия патшалыгының көчен мактап, сүзен тәмам итте.

Ләкин бу шагыйрь бу адымнарында төбендә казакъ шагыйре Акмулла шәкерте булып мәйданга чыккан һәм әле, шагыйрь булудан да бигрәк, Акмулла өслүбендәге бер тезмәче (назыйм) генә иде. Вәзен, өслүбтә Акмулла тәэсире анда соңыннан да байтакка сузылды.

1905 ел революциясеннән соң Гафури «Казан мөхбире» һәм «Әхбар»да үзенең шул ук милли-дини рухтагы һәм рационализм юлындагы, ләкин үзендә ярлыларны, мәзлумнарны кызгану, шуларга якынлык тойгыларын аңкыта торган тезмәләр дә язды. Ләкин ул һаман әле Акмулла тәэсирендә булса да, аның шагыйрьлеге әкренләп ачыла барды. 1906 елда инде Гафуриның «Яшь гомерем» дигән шигырь мәҗмугасы басылып чыкты. Үзен шагыйрь дип таныта башлаган бу әсәрендә дә әле ул өслүб, вәзен ягыннан Акмулла шәкерте иде. Әдәби агым ягыннан исә монда инде рационалистлык белән сентименталистлык бер шагыйрьдә бер тамырның ике тармагы яисә бер үзәкнең ике кыягы булып үсә башлаган иде.

«Яшь гомерем»е чыккач, Мәҗит Гафури татар дөньясында «милли шагыйребез» дигән исемне алды. Монда:

> Һәр мәкъсудны Хак Тәгалә үзе бирер,
> Тәвәккәл кыл, иҗтиһад ит, эшкә кереш! –

дип, татарны дини рухта эшкә өндәүче бу шагыйрь үзенең шушы мәҗмугасы аркылы әле иске «дини, милли» тәрбиясе тәэсирендә, рационализм сызыгында илһамланучы һәм революция дулкыны эчендә фикере ачыла башлаган бер тезмәче, шулай ук шагыйрьлек

сызыгына аяк басучы икәнен күрсәтә иде. Бу шигырьләрендә шагыйрьнең яшь чагында башыннан кичкәннәре хикәя кылынды. Болардагы бәгъзе шигырьләре аркылы үзендә лиризм чаткысының бара-бара көчәю өмете дә күренде. Бу шигырь мәҗмугасында, заманынча, чыныннан шигырь диярлек матур урыннары юк түгел иде.

Яз булса, дуслар илә уйнап-көлеп,
Сәер кылып йөрер идек Идел буен.
Ул заман үтеп китте судай аккан,
Матур кыздай, ишек ачып, кире япкан.
Аh орсаң да, ул заманнар кире килмәс,
Бәйләвеннән ычкынган эттәй чапкан.

мисраглары һәм:

Бөйлә матур төрле чәчәк үскән ничек,
Төрле тараф башын бора, җилләр исеп;
Күз салсаң, ул кызыллы манзарасы
Хыянәтсез саф күңелне китә кичеп, –

дип башланып, шуннан соңгы 36 мисраг матур шигырьләреннән булып, үзләре җиңел, садә татарча белән язылганнар иде. Шуның белән бергә, бу шагыйрь беренче чыгышларында ук ач-ялангачларны, ярлыларны кайгыртучы бер шагыйрь булып чыкты. Аның шушы ук мәҗмугасындагы:

Инсаннарның бәгъзесе тук, бәгъзесе ач;
Ачларга мәрхәмәтле күзеңне ач.
Дөнья тулган мәзлумнарга күзе төшеп,
Габделмәҗит шигырь яза, аптырагач, –

дигән мисраглары шуны ачык күрсәтә иде.

Аның бу әсәре чыккач, Риза казый тарафыннан аның турында түбәндәге фикерләр язылып үткән иде: «Габделмәҗит әфәнде милли шагыйрьләремездәндер. Шигырьләрне Акмуллага тәкълид[1] яхуд нәзыйрә юллау сөйләдекене дәгъва иделер вар. Ихтимал ки, бу шәй беркадәр дөрест улыр, фәкать буның шигырьләре мәгънә вә әсәр[2] җәһәтенчә Акмулла шигырьләрендән гали идеке мәйдандадыр.

Истибдад[3] гасыры илә хөррият гасыры арасында фәрекъ[4] нә кадәр улыр исә, бунларның адымлары арасында улан фәрекъ шул

[1] Тәкълид – иярү.
[2] Әсәр – тәэсирлелек.
[3] Истибдад – абсолютизм.
[4] Фәрекъ – аерма.

дәрәҗәдә бөекдер. Хөррият гасырының вә хөррият мәмләкәтенең иң бөек әсәре[1] заһири[2] хәлләрдә дәгел, бәлки батыйндадыр[3]. Һәр мәмләкәтдә зиһен – саф, хәят – гали, әфкар[4] шамуллы улыр. Шул җәһәттән, 17 октябрьгә ирешмәгән Акмулла бәним кашымда мәгъзүрдер[5].

Мәзмуны[6] милләт, гыйлем, җәһаләт, иттифак кеби хакыйкый вә файдалы шәйләрдән гыйбарәт улдыгы җәһәтлә Габделмәҗит әфәнденең шигырьләре, әлбәттә, бәһаледер, ләззәтледер. Әгәр дә ошбу өслүбендә дәвам идәр улса, халыкларының бөек саналырына мәзһәр[7] улыначагында шөбһә юк. Шөйлә исә дә җөзьи[8] бер нәсыйхәт вирер улсак, шагыйрь әфәнде хөсне ниятебезгә[9] хөрмәт идәрәк сүземезне тәхмил итсә[10] кирәк. Бу да – сөйләячәк шигырьләре ата-ана, угыл-кыздан гыйбарәт улан гаилә җәмгыяте арасында йөз кызартмас рәвештә укылачак сурәтдә улса иде. Буңа күрә 4 нче бәет вә 14 нче мисраг йиренә башка шәйләр куелса, гүзәл улмыш улырды.

Бән, гарәп шигырьләрендә, гадәттә, гашыйк улдыгым хәлдә, күб шигырьләре гаилә җәмгыятендә укылырлык улмадыгы җәһәтлә әсәф әйләдем[11]. «Яшь гомерем»не укыдыгымда мәктәб вакытлары кичдекне шагыйрь илә берлектә тәәссыф идерәк дәвам әйләдем исә дә, 9 нчы бәеттә улан Уфа сахраларыны сөйләдеке җирдә, үз-үземне забыт идә алмый[12], шагыйрьдән аерылып калдым. Бу вакытлар бән һәм шул җирләрнең суларыны эчмеш вә һаваларыны да юламыш идем.

Тәшбиһ[13] дөрестме, дәгелме, бән «әл-Гаср әл-җәдит» мәҗәлләсендә[14] шигырьләре күрелмеш Г. Тукай әфәндене – Мәгарригә[15] вә Габделмәҗит әфәндене Зофраигә охшатмакдаем. Бу көн уйлә

[1] Әсәре – йогынтысы.
[2] Заһири – тышкы.
[3] Батыйндадыр – эчке яктадыр.
[4] Әфкяр – фикерләр.
[5] Мәгъзурдер – гозерледер.
[6] Мәзмуны – эчтәлеге.
[7] Мәзһәр – чыганак, сәбәп.
[8] Җөзьи – кыска.
[9] Хөсне ниятебезгә – яхшы ниятебезгә.
[10] Тәхмил итсә – *биредә:* кабул итсә, сүз күтәрсә.
[11] Әсәф әйләдем – ачындым, көендем.
[12] Забыт идә алмый – җиңә алмый.
[13] Тәшбиһ – чагыштыру.
[14] Мәҗәлләсендә – журналында.
[15] Әл-Мәгарри Әбүл-Галә (973 – 1057/1058) – гарәп шагыйре һәм фикер иясе, фәнни трактатлар, фәлсәфи-гуманистик эчтәлекле шигырьләр, тезмә әсәрләр авторы. XX йөз башында шагыйрь идеяләре татар дөньясында аеруча популяр булып китә. Аның турында Р. Фәхреддин, Н. Думави яза, әсәрләре татар теленә тәрҗемә ителә.

улмазлар исә дә, беркөн шуйлә улачакларына өмидем камилдер» («Вакыт» гәзите, «Миръат» имзасы белән язылган).

Мәҗит Гафури шигырьләре аркылы халыкка ике төрле яктан әдәби, иҗтимагый тәрбия бирелә: 1) дини-әхлакый һәм милли тәрбия; 2) динсезлек һәм советчылык юлына тарту – советчылык тәрбиясе.

Шуның өчен Гафури шигырьләрен һәм, шуңа карап, аның әдәби гомерен икегә аерып тикшерә алабыз. Шул яктан карап, Мәҗитнең шигырьләрен, аның әдәби әсәрләрен тикшергәндә, без ике төрле Мәҗит күрәбез! Берсе – милли-дини шагыйрь Мәҗит, икенчесе – советчы, динсез материалист Мәҗит.

«Себер тимер юлы», «Яшь гомерем», «Милләт мәхәббәте» (1907 елда басылды), «Ирләргә махсус милли шигырьләр», «Кызларга махсус милли шигырьләр»не язган Мәҗит – динле, милләтче идеалист Мәҗит иде. Хәтта аның Февраль революциясеннән соң басылган «Кызыл байрак»ында да андагы бу рухи салыныш көчле иде әле. Октябрь революциясен бик яратып көтеп каршы алган һәм революция ялкыны белән яңадан нык күтәрелгән Мәҗит анда да әле:

Изге, ак, пакь юл белән барганда булсын җан фида,
Шул вакытта алсаң ал бу пакь җанымны, йә Ходa! –

дип, башта ук Ходага эндәшеп, аңа ялынып башлаган булса, шул ук шигыренең ахырында:

Әй шәһид! Әле дә синең рухың янып шул гөл кебек,
Сайрый торгандыр һаман да моңланып, былбыл кебек, –
(«Изге юлда» дигән шигыреннән)

дип, рух дигән бер нәрсәнең барлыгын һәм аның мәңгелеген тәлкыйн итүдән[1] котыла алмаган иде. Монда:

Булса күңелең киң, сыярсың,
Тәңренең киң дөньясы.
(«Күңелгә» дигән шигыреннән)

Нинде сер шатлыклы, якты? Өнме бу я төшме бу?
Тәңренең кодрәт кулы белән кылынган эшме бу?
(«Азатлык хөрмәтенә» дигән шигыреннән)

Китте өстән ул караңгы пәрдәләрнең һәммәсе,
Бетте коллыклар, бүген сез тик Ходайның бәндәсе.
(«Курыкмагыз» дигән шигыреннән)

[1] Тәлкыйн итүдән – әйтеп торудан.

Рәхмәт яудырсын сезгә бер Хода,
Бәйрәм көнендә бездән бер дога, –
(«Шәһитләр рухына» дигән шигыреннән)

кебек юллар беренче Мәҗитне ачык күрсәтәләр иде.

Шуның өстенә шагыйрь әле боларда һаман «ак» пакь, ак таң, киң ак юл кебек томанлы, сузылмалы мәгънәле сыйфатлар белән генә канәгатьләнә, шулай ук, сыйныфка аермастан, «халык», «татар халкы» сүзләрен куллана иде.

«Кызыл татар байрагы» дигән шигырендә:

Дүрт йөз ел буе тәхкыйр ителгән
Татарның туы[1] бүген эленгән.

Һәм:

Башка байраклар белән бер сафтан
Барсын бу байрак, алсын бетмәс дан, –

дигән кебек юллар да беренче Мәҗит шигырьләре булдылар. Чөнки кып-кызыл татар байрагы моннан дүрт йөз ел элек тәхкыйр ителгән татар ханнарының милли байрагы түгел, бәлки яңа сыйнфый бер байрак иде.

Ләкин шуларга карамастан, шагыйрьлек таланты үсү ягыннан инде ул бу шигырьләрендә беренче Мәҗит – «Яшь гомерем», «Милләт мәхәббәте» кебек тезмәләрне язган Мәҗит түгел иде. Инде ул чынлап та үзен шагыйрь дип өзеп әйттерерлек бер баскычка ныгып утырып алган иде. Бу мәҗмугасындагы шул ук «Кызыл татар байрагы», «Татар егетенә», «Сәлам», «Бир кулыңны», «Гаһед», «Безнең юл», «Вөҗдан», «Хөррият иртәсе» дигән шигырьләре чыннан шигырь, чынлап та, көчле ялкынлы самими лирикалар булдылар. Бу шагыйрьнең «Кызыл байрак» дигән шигырь мәҗмугасындагы шигырьләре эчендә «Татар егетенә», «Сәлам», «Гаһед» дигән шигырьләре Мәҗиткә революция сызыгындагы матур әдәбиятның тарихыннан урын бирдертсәләр, «Бир кулыңны» дигәне эшчеләр йөрәгендә аңа чыннан кадерле урын багышлаттыра алырлык булып чыкты.

1914 елда Галимҗан Ибраһимов каләменнән: «Бу сыйныфның (шагыйрьләрне әйтә) иң чыдамлы ирләреннән Мәҗит Гафури булып чыкты. Ул яңа шагыйрьләрнең һәммәсеннән элек күренгән иде. Башкалары кайсы кая таралып беткәч тә, ул һаман яза, һаман яза. Мин үзем рухан[2] аңа якын түгелмен. Өслүбенә дә ихтирамым аз.

[1] Туы – байрагы.
[2] Рухан – рухи яктан.

Аның әүвәлге «Яшь гомерем»енә караганда, хәзергеләре шөбһәсез карт икәнлеге дә ачык сизелә»[1], – рәвешендә сыйфатланган Мәҗит, шулай итеп, Февраль революциясеннән соң үзенең «Кызыл байрак»ы аркылы шагыйрьлеге ягыннан үзенә мондый бер карашны үзгәртерлек бер дәрәҗәгә килеп баса алды.

Шул ук әүвәлге шигырьләре һәм «Үги балалар»ы аркылы күренгән Мәҗит шул вакытта ук татар әдәби тәнкыйть дөньясында Ф. Әмирхан һәм башкалар тарафыннан бик каты сәлби[2] тәнкыйтьләргә очраган иде («әл-Ислах», 12 нче сан, 1907 ел; 25 нче сан, 1908 ел).

М. Гафури кадәрле идеология ягыннан да, тасвир, тел-өслүб ягыннан да заманның зур вакыйгалары, аның фикеренә тәэсире аркасында үсә-үзгәрә барган бер шагыйрь, бәлки, татар әдәбият дөньясында бик сирәк күрелер. Ул һич туктаусыз, ләкин сиздермәслек бер рәвештә әкренлек белән та Февраль революциясенәчә һаман үзгәрә, үсә, үстерелә килде. Октябрьдән соң исә аның үзгәрүе, үсүе, үстерелүе тагын да нык, ачык күзгә ташланды.

Ул, бер яктан, фикер, рух салынышы, идеологиясе белән үсеп үзгәрә барган булса, икенче яктан, теле, вәзене, өслүбе белән үсте дә, бара торгач, башта үзендә бик нык тамырланган Акмулла тәэсиреннән дә котыла алды.

Без аның идеологиясендә 1910 елларда түбәндәге:

Дин низагыннан башың ал, кач ерак,
Юк урында башың ватмау яхшырак.
Бак күзең алдында торган дөньяга,
Дин низагын бир әнә шул муллага! –

дигән кебек диннән, дин бәхәсләреннән суына башлавын аңлаткан шигырьләрен укысак, 1912–1915 еллар арасындагы шигырьләрне эченә алган «Янган йөрәк» дигән шигырьләрендә инде гәрчә әле тәмам инкяр түгел, бәлки Аллага иркәләнү юлы белән язылган булса да:

Юктырсың ла, Алла!.. Әгәр булсаң,
Сабыр итмәс идең бу эшкә.
Бөтен кодрәтеңне баглап куймас
Идек җирдә, алтын-көмешкә, –

дип, Алланы инкяр итү, динсезлек, дәһрилек юлына таба адымнар башларга уйлаганын да күрә идек.

[1] «Аң», 1 нче сан, 1914 ел. «Матбугат вә әдәбиятыбызның барышы» дигән мәкаләдән. *(Авт. иск.)*

[2] Сәлби – тискәре.

Октябрьдән соң (1923 елда) без бу шагыйрьнең иске «тәгълимат»[1] белән тулган «Күңел сәхифәләре»нең шагыйрьнең үз кулы белән ертылып ташланган, шуңа яңа «сәхифә»ләр ялганганын да ачык күрдек. Ул инде:

Кем күтәрер калын пәрдәләрне?
Үзем әүвәл барып тотмасам!..
Кемләр ертыр бозык тәгълиматны
Әүвәл үзем башлап ертмасам?..
Шул сүздән соң күңелем китабының
Баш битләрен карый башладым.
Һәммәсендә пычрак, ямьсез табып,
Тар-мар итеп ертып ташладым.
Калган битләренә язып куйдым
Яңа иман, яңа көч сүзен, –

дип җырлый башлый. Моңа да тагын шул ук елда:

Җырлама син безгә «күк җырларын...»
Ялыктырды безне «күк җыры...»
Мин җырлармын сиңа җир җырларын,
Илһам алып эштән туп-туры.

Һәм:

Сине саташтырган иблисләрне
Онытгырыр минем эшләрем...
Син уйлаган бөек «күк көчләре»н
Тар-мар итә минем көчләрем... –

дип, күк белән бөтенләй бәйләнеше өзелгәнен, инде үзенең бөтенләй җир тормышы шагыйре булып әверелгәнен, эш һәм эшчеләр тормышын, аларның идеологиясен көйләүче бер шагыйрь булып киткәнен ачык игълан кылды.

Аның менә шушы моменты – әүвәлге, беренче Мәҗитнең карт көнендә тәмам икенче Мәҗиткә әйләнеп җитүенең шигырь теле аркылы рәсми бер игъланы иде. Ләкин без аның идеология ягыннан да, тел-өслүб ягыннан да икенче Мәҗиткә әйләнүенең беренче иң зур адымын аның «Эшче» дигән поэмасы аркылы моннан элек 1920 елларда ук күреп үткән идек.

Ул «татар әдәбиятының юргасы» булмыйча, тик аның «сука аты» булса да, ләкин шушы соңгы әсәрләре белән эшче-пролетариат аты булганын, карт көнендә өстенә пролетариат йөген күтәреп, шуны, тик шуны гына тарта башлаганын күрсәтте.

[1] Тәгълимат – белемнәр.

Шулай итеп, соңыннан да «аны тәгъмим иткән, аны мәшһүр шагыйрь ясаган гамил[1], шөбһәсез, үзенең эшлеклелеге, тәнкыйть вә матбугатның игътибар итү-итмәвенә карамастан, армый-талмый бертуктаусыз язып торуы» һәм шуның аркасында үзенең рухан тәмам үзгәреп, икенче Мәҗит булып чыгарга тырышуы булды.

«Мәҗит Гафури үзенең әдәби гомерендә татар әдәбияты уздырган һәммә дәверләрне үткәрде. Аны яңа татар әдәбиятының үзе белән бергә туган дисәк тә ярый. Аның аергыч хасиятләреннән берсе – заман үзгәрүе белән бергә үзгәрә баруыдыр. Аның шагыйрьлегенең эволюциясе бөтен татар тормышы вә әдәбиятының эволюциясе белән кулга-кул тотышып барды. Гафури гаҗәп рәвештә замана белән үзләшә, вакытының төп рух вә фикере агымнарына үзенең каләм вә фикерен ияртә белә. Аның әсәрләрен күздән кичергәндә, без үзгәрүне һәм телдә, һәм формада, һәм фикер вә идеяләрдә күрәбез» («Безнең юл», 10–11 нче сан, 1923 ел, «Мәҗит Гафури» дигән мәкаләдән).

Хәзер инде Мәҗит Гафури – милләтче түгел, революцияче бер шагыйрь. Ул, дөрес, «революцияне ясаучылардан түгел, бәлки гаҗәпләнеп, шатланып каршы алучылардан гына»; ул Октябрь революциясенә, аның идеологиясенә кушылучылардан гына, шуның өчен бәлки аның турында дөрес сүз аны «юлчы» (попутчик) шагыйрьләребезнең дә атасы һәм беренче күчергече», дип әйтүдән гыйбарәт булып калыр.

«Феодализм хәрабәләре эчендә тәрбияләнеп тә, төрле баскычларны үтә-үтә, туктаусыз үсә-үсә, коммунист пролетариат сафына килеп ирешү, актык көчне шул көрәшче пролетариат белән бер сызыкта торып, инсаният дөньясының олуг әмәлләре өчен сарыф кылу – бу һәркемгә насыйп була торган бәхет имәс»[2]. Икенче Мәҗит әнә шушы бәхеткә ирешүче бер шагыйрь булды. Мәҗитнең татар әдәбиятында бер әһәмиятле адымы да аның Крыловтан[3] тәрҗемә итеп, бездә мәсәлчелек сукмагын салуы иде.

Кайбер шагыйрьләр була – алар тәрҗемәдә үзләренә муафыйк бер вәзен таба алмый йөдиләр. Бездә Мәҗит тә шундый шагыйрьләрдән булды. Ул күбрәк 11, 12, 15, 16 иҗекле вәзеннәрдә язды. Халык вәзеннәрен башта бер дә алмады. Яисә ала алмады. Аның

[1] Гамил – хезмәт.

[2] «Башкортстан» гәзите, 1923 ел, 58 нче сан. Галимҗан Ибраһимов мәкаләсе. *(Авт. иск.)*

[3] Иван Андреевич Крылов (1769–1844) – язучы, рус әдәбияты тарихында иң күренекле мәсәлчеләрнең берсе, сатирик журналлар нашире, библиограф.

шигырьләрендәге уңышсызлыгы да, бер яктан, шул сәбәпләрдән сизелә иде. Октябрь революциясеннән соң ул менә бу яктан да төзәлде. Үзенә файдалы һәм үз табигатенә муафыйк бер вәзенне ала алды. Бу да аның «Зиләйлүк» вәзенен сайлап, шул вәзеннән яза башлавы булды. Аның тел-өслүбтә, аһәңдә күрсәткән уңышлыгы бигрәк вәзендә күренде.

Шуның белән бергә бу урында шуны да әйтергә кирәк: ул өслүб-вәзендә яңа бер тәкълидчелек тә күрсәтте: Октябрьдән соң октябрь яшьләренең кызу башлаган иректе вәзеннәренә күчте. Ул моның белән янә үзенең вәзен-өслүб мәсьәләсендә һаман үзгәрә, агымга иярә баручы икәнен ачык мәйданга куйды[1].

Мәҗитнең шигырьләреннән башка тагын аның романтизм юлында һәм реализм сызыгындарак язган күп кенә хикәяләре дә булды. Болар арасында беренче мәҗитчелекне күрсәтә торганнары булган шикелле, икенче Мәҗитне сиздертә торган матурлары да юк түгел иде. Ләкин ул бигрәк хикәяләре белән түгел, шигырьләре белән игътибар казанганлыктан, без дә хикәяләренә күп тукталуга артык бер ихтыяҗ күрмәдек. 1926 елда аның «Кызыл йолдыз» дигән дүрт пәрдәлек бер пьесасы да басылып чыкты. Бу аның Октябрь тәэсире белән пьесалар язарга керешүенең дә беренче адымы булды.

**Тукай.** Татар лирикасы романтизм юлында һәм көчле бер милли-дини рухта Тукай шигырьләре аркылы киңлек тапты. Башка берничә татар шагыйрьләре шикелле үк, үзенең шагыйрьлек баскычын бик түбәннән башлаган, ләкин соңыннан бик тиз ачылган, тиз үсеп өлгергән бу шагыйрь беренче адымнарында ук Анатоли (госманлы) романтизмы; «Мөхәммәдия»[2], «Бакырган»[3] тәэсире астында чуар телле бер романтик булып мәйданга атылган иде. Тиз вакыт эчендә чуар телдән дә аерылып, чын татар телендә бер-беренә каршы

[1] Мәҗит турында үз урынында, үзенең җитешкән дәверендә әйтеләчәк сүзләрне әйтеп бирү өчен, без югарыда аның турыда сүзне Октябрьгә китереп кенә туктатмыйча, хәзергәчә суздык. Чөнки шулай итмәгәндә, Мәҗит турындагы сүзләр аның хезмәтләре турындагы фикерләр тәмам булмыйча өзелеп туктаган яисә безгә тик беренче Мәҗит белән генә канәгатьләнеп, шул беренче Мәҗиттән ясалып чыккан икенче Мәҗит аннан аерылып калган булыр иде. Әнә шушы өзелүне ясамас өчен, планыбыздан чыгып булса да, аның турында Октябрьнең бу ягына да чыгып сөйләргә мәҗбүр булдык. Башка әдип-шагыйрьләр турында да шундый юл тотылачак. *(Авт. иск.)*

[2] «Мөхәммәдия» – төрек шагыйре Мөхәммәт Чәләбинең 1449 елда язып тәмамлаган китабы. Казанда 1845 елдан 1917 елга кадәр 24 тапкыр бастырыла. Ул укылу ешлыгы буенча Коръәннән соң икенче урында торган.

[3] «Бакырган китабы» – XII гасырга караган төрки әдәби ядкәр. Төрле суфи шагыйрьләр – Сөләйман Бакыргани, Әхмәд Ясәви, Нәсими һ. б. әсәрләреннән тора.

төрле фикер, хис дулкыннары эчендә көчле романтик шагыйрь булып үсеп китте.

Тукай башта ук динче, милләтче булып чыккан иде. Ләкин әле аның милләте ул вакытта татар түгел, бөтен «әһле ислам», «ислам милләте» иде. Аның 1907 елгача булган дәверендәге шигырьләре аркылы әнә шул юлда «ислам» һәм «милләт» кайгысы белән яну гайрәте чәчелә. «Һәр тараф мөселманнары» белән бергә торып, аларның «бәхете сиаһ» (кара бәхетләре) өчен аһ ора:

Бакма һич кәс хәтеринә, милләтең дәрденә бак!
Бәддога – явыз догая һәр заман асма колак. <…>

Һәр тараф мөслимләри бер-бер идәрләр аһе-ваһ!
Нә сәбәбле кәлди безгә бөйлә бер бәхте сияһ?
(«Каләм»[1] дигән шигыреннән).

Шул ук рух белән муллаларга, ишаннарга да каты һөҗүм башлады:

Сез, әй чалмалылар, безне моңа дик иттегез игъфал,
Вә тәхсили дә тәгълими сәрасәр иттегез иһмал. <…>

Итеп мәсҗедләре базар, гавамә саттыгыз әгъмал,
Сатып гокъбәи дөньяйа, хакыйкать улдыгыз бәкъкал[2].

* * *

Милләти вәйран идән ишан икәндер, белмәдем,
Ул ишанлар милләтә дошман икәндер, белмәдем[3], –

мисраглары шул һөҗүмнең нәтиҗәләре иде. 1907 елдан башлап инде ул татар милләтчелеге баскычына күчә:

Җырлап торам, торган җирем тар булса да,
Курыкмыйм, сөйгән халкым татар булса да;
Күкрәк биреп каршы торам, миңа милләт
Хәзерге көн мылтык, ук атар булса да, –
(«Бер татар шагыйренең сүзләре»)

дип, «милләт» сүзен татар милләте мәгънәсенә күчереп, үзен[ең] шул милләтнең куркусыз, көчле бер көрәшче шагыйре булуын җырлый башлый.

---

[1] Сүз Г. Тукайның 1906 елда язылган «И каләм!» шигыре турында бара.

[2] Халыкка намаз саттыгыз, мәчетләрне базар ясап,
Чын-чын сәүдәгәр булдыгыз, ахирәтне дөньяга сатып.

[3] Г. Тукайның «Мөридләр каберстаныннан бер аваз» (1906) шигыреннән.
Таркатучы милләтне ишан икәндер, белмәдем;
Ул ишаннар милләткә дошман икәндер, белмәдем.

Уңга, сулга аумыйм, һаман алга барам,
Юлда манигъ күрсәм, тибәм дә аударам;
Каләм кулда була торып, яшь шагыйрьгә,
Мәгълүмдер ки, курку белән өркү харам, –

дип, шул юлда зур гайрәт күрсәтә.

1905 ел революциясенең ялкыны белән күтәрелеп, милләт кайгысы белән шаулап йөреп тә, соңыннан реакция тәэсире белән сүнә, сүтелә башлаган милләтчеләр Тукайның фикер-хисләрен икенче якка сикертеп алалар. Ул, гүя, вак буржуазия социалистлары сафына төшеп, милләтчеләрдән көлә һәм, гүя, милли хәрәкәттән өмет өзеп, аннан кул селтәргә омтылып карагандай була:

Татар халкы, син үләргә мәхкүм инде,
Дару үтмәс дәрәҗәдә мәсмүм[1] инде;
Тыпырчынма, терелмисең, юл өстендә
Ятма аунап, үзеңне үзең күм инде.
Милләтчеләр фәкать сине алдый гына,
Дигән булып: «Җанланасың син тиз менә».
Алданма син, калган акчаң өчен алар,
Укыйлар ич баш очыңда ясин генә.

* * *

Алданмыйча, газиз башың кабергә керт,
Милләтчеләр барчасы да эшсез шәкерт.
Алар өчен барыбер: син, теләсәң, бет!
Алданма син, шәкерт алар, шәкерт, шәкерт!

(1908 елда язган «Милләтчеләр» шигыреннән).

Шул рәвешчә, 1908 елда милләтчеләрдән кул селтәгән Тукай [19]10 елда инде милләтчеләрдән социалистлык рухы белән көлеп түгел, бәлки милли рухта һәм милли кайгы астында өметсезләнү тәэсире белән, «Яшьләр» дигән шигырендә болай язды:

Бара милләт зәгыйфь, абыныр-абынмас,
Сүнә яшьләрдә ут кабыныр-кабынмас.

Кичә якты вә милли бер күңелдән
Бүген тычкан утыдай нур табылмас. <…>

Шулай, яшьләр дә юлда күрсә алтын,
Баюдан башкага күңелен дә салмас. <…>

Тотып милләт ливасын[2] юлга чыктык,
«Бу куллар мәңге дип, җиргә салынмас!»

[1] Мәсмүм – агуланган.
[2] Ливасын – байрагын.

Егылдык без, ике-өч чакрым да китми;
Егетләр! Бездә көч юк, – ахры, булмас! –

дип, милли пессимизм моңнарын җырлый башлады. Аның бу юлдагы пессимистлыгы шул ук елда язылган «Өзелгән өмид»ендә:

Күпме моңлансам кунып милли агачлар өстенә,
Барысы корыган, бер генә юк җанлысы, яфраклысы, –

дигән мисрагы белән үзенә үк каратылып, ачык тасвир ителде. Тукай 1909 елда ук «мең җан бирергә урыны бар» булган «гали матлаб»лы «югарылык белән типкән вә селкенгән», «тумыштан гарше әгъляларга җилкенгән күңел»енең югары төп ноктасы Раббы, Илаһ – Тәңре булганын үзенең:

Инкисар ит[1] гадәтеңчә, ян, күңел, сызлан, күңел,
Күп сөекледер бүтәннән Тәңрегә сынган күңел, –

дип башлаган «Күңел» дигән шигыре аркылы җилкенеп күрсәткән иде. Әмма шул ук елда ул:

Кайт, и нәфсе мотмәиннәм, бар, юнәл, кит, Тәңреңә,
Бирдең арканңны моңарчы, инде бир бит әмеренә.

Дустларым, кардәшләрем, сез муллаларга әйтегез:
Бу ике юлны, мине күмгәч, укырлар каберемә.

Әһле тәфкир бер гаҗәпләнсен, күреп актык сүзем:
Күр, нә рәсмә тулган иман берлә Коръән садремә[2], –

дигән васыяте белән ул инде башта үзе сүккән муллаларга таба әйләнгәнен, алар кәгъбәсенә үк карап, иманлы (бу сүзнең дини мәгънәсе белән), Коръәнле булганын; тәмам Тәңресенә кайтып, тәүбәгә килгәнен, шаулатып, шигырь теле белән игълан кылды.

Менә бу хәл шагыйрьнең рәсми рәвештә һәм катгый рәвештә дингә, мөселманчылыкка кайтып ныгып утыруы, сулышын шул рух белән ала башлавы иде. 1910 елда инде ул:

Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңелем кошы,
Шад яратса да, җиһанга ят яраткан Раббысы[3], –

дип, үзенең дөньядан бизүен, пессимистлыгын да Раббының хөкеменнән күреп, шуннан җан юанычы тапты.

[1] Инкисар ит – йомша.
[2] Г. Тукайның «Васыятем» (1909) шигыреннән.
[3] Г. Тукайның «Өзелгән өмид» шигыреннән.

Соңыннан, аның шагыйрьлеге көчәйгән саен, аның шул гали ноктасы Раббы булганы һаман башка шигырьләре аркылы ачылганнан-ачыла барды. Соңгы шигырьләре һәммәсе дә 1908 елда:

Итмә үз тормышны, тап башка җиһан, башка хәят!
Дөньяның бу шау-шуы шагыйрьгә чит, шагыйрьгә ят[1], –

дигән мисраглары белән билгеләнгән ноктасына карап омтылуының нәтиҗәсе, шул юлда кайнаучы пессимист бер йөрәкнең тибүләрен тасвирчы булып әйләнделәр. Иң ахырда, үләреннән бер ел элек:

Зур җаным сөйми җиһанны, чөнки бар дөнья фәна,
Анда тормакка һәвәслек берлә ваклар мөбтәля[2], –

дип, җаны дөньядан гүя һаман суырыла, Раббысына кайтуга юнәлә бара иде. Үләр елында ([19]13 ел, 12 гыйнвар) язган «Хәстә күңеле» дигән шигырендә үзендәге шәхси кызганычлыкны да үтеп, бөтен ислам дөньясының хәле белән юанмакчы булды. Тагы 1906 еллардагы үзенең исламчылыгына кайтып карады, ләкин анда да җанына җылы бер нәрсә таба алмыйча:

Юк нәҗат[3], фикерем чөерсәм дә, үземнән үзгәгә,
Козгын ислам гәүдәсендә, кәгъбәсендә пот күрәм, –

дип, актыккы мөселманлык күз яшен түкте.

Менә шушы югарыдагы тикшерүләребезгә Тукайның фикри кузгалышын: 1) динчелек, исламчылык белән башлап, 2) шуннан татар милләтчелегенә, аннан соң 3) милләтчелектән, милләтчеләрдән йөз дүндерү сызыгына каерылып алып, милли һәм дини өметсезлеккә төшеп алуын, иң соңында янә 4) реакция чагында бөтен йөз проценты белән дингә, Аллага, милләтчелеккә кайтып, бөтен шигырьләренең динчелек белән сугарылганын күрсәтәләр; хәтта ул соңыннан, әүвәлге кебек шаяру юлы белән булса да муллаларга тел тидерүдән дә тукталды. Тукай лирикасындагы фикри үсү һәм үсү баскычлары әнә шулай иде.

1905 ел революциясе белән кузгалган социализм хәрәкәтләре тәэсире белән Тукай башта байларга, буржуазиягә дә бик каты һәм ачы тел белән ташланган, аларга каршы:

Аристократ сорыкортлар, калын корсак, кечек башлар,
Ашыйлар соң бирән булган кешеләр, ну гаҗәп, ай-яй! <…>

[1] Г. Тукайның «...гә (Ядкәр)» (1909) шигыреннән.
[2] Г. Тукайның «Дошманнар» (1912) шигыреннән.
[3] Нәҗат – котылу.

Ашар безне дә бу корсак, басар тиз, без болай торсак,
Ая корсак, вая корсак, җиһанны капладың вай-вай! <…>

Матур булыр бу корсакларга каршы чаралар корсак,
Тотып ярсак боларны без, заман үткәрми – картаймай.

Ярыйк, дустлар, ярыйк, дим, чөнки безнең бәхетебез шунда,
Шулар йоткан безем икъбалемезне[1] бер дә кызганмай.

Җитәр инде, җитәр инде, давайте сызганыйк җиңне,
Салып ташлыйк киемне, һич өмет юк, җиңне сызганмай. <…>

Язам, юк, туктамыйм мин һич, алардан бер дә кот чыкмый;
Нидәндер җаннарым бу куркулардан бер дә сызланмай.

Чебен җанымны чын юлда бирәм мең кәррә, кызганмыйм,
Минем чөн мәсләгем-юлым бөтенләй социаллардай[2], –

дип һөҗүм ясаган иде. Бу аның, үзе әйтмешли, чынлап та «мәсләге бөтенләй социалистлардай» булганын күрсәтә иде. Шуңа аның «Тавыш» гәзите хакында язганы да кушылган иде. Ләкин реакция катылыгы аның каләмен дә бу юлда артык сүз сөйләүдән тыеп, аны моннан тәүбә иттерде. 1907–[190]8 елда исә байларга каршы, югарыдагы «Сорыкортлар»да күрсәтелгәнчә, бар көрәшне тәмам ташлап, бу яктан да тирән бер пессимизмга төште; «Дөньяда торыйммы? дип киңәшләшкән дустыма»сы белән 1907 елда ук капитал көченнән курыккан, «тиздән дарга» менеп асылуга хәзерләнә башлаган, шулай ук Тәгаләсенә хитап итеп, «Алтынга» (хәзерге тел белән капиталга) каршы теләккә генә тотынган иде:

Яратырга ярый кышны, вәләкин зәмһәрире бар,
Киемсез калтырап торган мәсакине, фәкыйре бар.

Яратырга ярый җәйне, матур ул, анда зур ямь бар,
Вәләкин таш бинасы юк, фәкыйрьләргә җәһәннәм бар, –

дип, өметсезлек белән зарлануга әйләнде. Моның өчен ул ахырда:

Яратырга ярый дөнья: матур кырлар, матур таулар,
Яратмыйм мин вәләкин һич, сәбәп шул: ибне Адәм бар[3], –

дип, хәтта бөтен адәмнәрдән, аларның көрәшләреннән кул селтәргә дә мәҗбүр булды. Шуның белән бергә, ярлыларга, теләнчеләргә шәфкать юлында нәсыйхәтләр сөйли башлады.

[1] Икъбалемезне – бәхетебезне.
[2] Тукайның «Сорыкортларга» (1906) шигыреннән.
[3] Г. Тукайның «Яратырга ярый» (1909) шигыреннән.

Тукай [19]12 елларда инде, хәтта 1905 елда татарның социализм хәрәкәтләрен мәгънәсез табып, аларның «аңгы-миңке баш белән» эшләнгән эш булганын яза башлады. Шушы елда «Аң» журналы турында язган шигырендә:

Булса да ул чакта бездә керсез иман, саф күңел,
Күз һаман булды эренле, йөз дә саф һәм пакь түгел.

Шул сәбәпле дустыны, дошманыны дөрес фәрекъ итмичә[1],
Күп саташтырдык рәзил[2] шайтанны чын инсан белән, –

дигәннән соң:

Үтте инде, дусларым, ул үткән эш, ни булса ул,
Инде эшлик саф ачык күзләр белән, чын «Аң» белән, –

дип, татар буржуазиясе хәрәкәтенә өндәде. Шул ук елда язылган «Татар яшьләре» дә аның шул ук рухта иде. Ул монда:

Дикъкатә лаек хәзерге көн татарның яшьләре,
Аңламак, белмәк мәгърифәт хикмәт белән. <…>

Күк булып күкрәү һавада, хөр яшәү тавышлары,
Ялтырар изге көрәшнең хәнҗәре, алмаслары.
Йөрмәсен бәгъре өзек милләт киеп кашсыз йөзек,
Без аның бик зур фәхерле[3] чын бриллиант кашлары! –

дип, татар буржуазиясенең киләчәктә өмет ителгән «хакыйкый яурупеист»ларча булган галәбәсенә өметләнеп алган иде. Ләкин аның бу өмете дә үләр алдындагы өметсезлегеннән коткара алмады. Ул һаман пессимист булып, дөньядан үтте.

Тукай болай буржуазиягә якты бите белән әйләнгән булса да, буржуазиянең кайбер тармаклары (мәсәлән, оренбурглылар) белән килешә алмыйча, алар белән бәргәләшеп тә барды.

Тукай лирикасына бөтен мөндәриҗәсе, тел-өслүбе, рухы ягыннан гомумән карап хөкем йөрткәндә, ул, шөбһәсез, түбәндә татар либераль буржуазиясенең кыйбласына караган, аның рухы белән нык сугарылган иҗатлар булдылар. Бу яктан бу юлдагы беренче романтик халык шагыйре дә ул булып чыкты. Тукай лирикаларында күренгән төп бер хосусият – аларның тиз сизүчән бер йөрәкнең, тиз аулап алучы бер минең җимеше булып тууларындадыр. Вакытында

[1] Фәрекъ итмичә – аермыйча.
[2] Рәзил – начар, түбән.
[3] Фәхерле – намуслы, горур.

татар иҗтимагый тормышының һәммә почмакларына, һәммә иҗтимагый яңгыравыкларына чакырыла белү – менә бу хәл Тукайның аерым бер сыйфаты. Икенче бер хосусият исә аның, башка бәгъзе шагыйрьләр шикелле соңга калмыйча, бәлки булган вакыйга һәм хәлләрне, җәмгыятьтәге билгеле бер настроениене шунда ук эләктереп алып, шуларны тизлек белән җиңел, матур татар телендә шигырь калыпларына сала баруында күренде.

Бигрәк тә реакция вакытында халыкта гына түгел, бәлки элекке «кызыл яшьләр»дә уянган динлелек, милләтчелекне яклау, шуны соңгы бөтен шигырьләрендә оста тел белән матур иттереп бирә белү һәм шул ягы белән динчелек, милләтчелек идеологиясенең шигырьдә тулы бер тәгъбирчесе була алу – менә бу як үзенең бөтен тулылыгы белән Тукайда табыла иде. Ул, чынлап та, җәмгыять эчендә туган (дин, милләт, миллият фикере, искедән, вакыты белән милләтчелектән көлү кебек) фикер, хис, зәвыкларны бик тиз аулап алып, шуларны тизлек белән, шул җәмгыять кешеләренең яшекарты аңларлык бер рәвештә, сәнгатьчә бик матур иттереп шигырь теленә күчерә белде. Шулай ук бөтен шушы фикер, хис дулкыннарына муафыйк иң уйгын сүзләр, тәгъбирләр таба алуда да ул вакытында зур бер осталык күрсәтте.

Тукай, чыннан да, идеолог бер лирик иде. Ул үзенең шигырьләре аркылы татар либераль буржуазиясенең дини, милли идеологиясенә ачык бер систем биреште. Шул юлда әдәбиятның оештыручылык хезмәте дә Тукай шигырьләрендә бик ачык сизелде. Татар дөньясында аның кадәр дини-милли кайгыларны яңа замана киеменә киендереп, матурлап, аның шикелле таратучы булмады. Мондый тойгыларны соңыннан үзләре белән көрәшеп җиңү өчен күп заманнар, күп көч сорый торган бер рәвештә татар дөньясына таратышып, җәеп җибәрешүдә аның шигырьләре көче, үтеме ягыннан аерым урын алдылар. Бу фикерләр, бу тойгыларның мәктәп почмакларында нык оя коруларында да аның шигырьләренең тәэсире аз булмады, шул шигырьләр аркылы мәктәп балаларының бөтен йөрәкләренә, бөтен тамырларына дини-милли рух үткәрелде.

Октябрьдән әүвәлге ун ел эчендә татар әдәбият дөньясында Тукай лирикаларының хезмәте, тәэсире әнә шул рәвештә иде. Аның лирикалары аркылы татар массасына әнә шундый тәрбия бирелде.

Тукай, идеологиясе, рухи салынышы, әдәби агымы ягыннан караганда, ул түбәндәгечә иде:

1) Тукай – табган[1], татарның иң көчле бер сентименталист романтик йөрәк шагыйре. Шуның өстенә ул – бу бабта татарлар өчен классик бер шагыйрь. Анда икенче дәрәҗә реалистлык та юк түгел.

Йөрәк шигырьләрендә (лирикада) иң күзәтелгән нәрсә – самимият, ягъни чын күңелдән булу, эчтән кайнап чыгу. Йөрәк шигырьләренең чынлыгы-хакыйкате дә шунда. Тукайда менә бу хосусият төгәл мәгънәсе белән бар. Шуның белән бергә андагы бу самимият табигыйлек белән дә башкалардан күп аерым тора. Тагын бу бар: «Бәгъзе шагыйрьләребез кебек, Тукай – эффект кешесе түгел, эмоция кешесе. Ул шашмый, сабырлык белән уйлап кына ташый, котырынмый, тилерми, ләкин һичвзлексез дулкынлана».

2) Тукайның бөтен шигырьләрендә аның үзлеге (шәхсияте, ягъни Тукайлыгы) бик ачык күренеп бара. Хосусан, әдәбиятта романтизм агымының бердәнбер таныган төп кануны да – шушы ноктадыр.

3) Тукайның тел вә өслүбендәге аһәң, вәзен, кафия дә – тышкы вәзен, коры тышкы сызык, ясалма бер аһәң генә түгел, бәлки бу анда рухтан – ми вә йөрәктән туган эчке вә тирән бер хосусият. Ягъни бу – андагы тәсаувырлар[2], фикер, хис вә хыяллар арасындагы эчке рухи бер сыйфат. Аның фикер вә хисләре шулай оешканнар. Әнә шушы хосусият Тукайның тел вә өслүбендә гәүдәләнгән.

4) Тукай хыялга бай һәм аның хыялы – хисе вә фикере кебек уйнак хыял. Тукай – тиз сизүчән һәм нечкә хисле бер шагыйрь. Ул – Дәрдмәнд кебек, фикер шагыйре түгел, хис шагыйре. Шулай булса да, аның хисләре фикер карамагы астында матур вә назик[3] кыяфәттә гәүдәләнәләр. Дәрдмәндтә фикерләр йомшак хисләр белән бизәкләндерелгән булса, Тукайда хисләр фикергә чыланган була.

5) Тукай шаян вә уйнаклы бер фикергә, шук, тынгысыз бер хискә малик. Шуның белән бергә, аның күз яшендә – көлке, көлкесендә күз яше бар. Ачуында – мәрхәмәт, ләгънәтендә шәфкать бар.

6) Тукайның йөрәкчелеге, ягъни хисе, кузгалып киткәндә, халыкча табигый нигездә ага.

7) Ул тезмәдә заманында татарга яңа, садә әдәби бер тел эшләүчеләрнең алгы сафында барды. Анда чәчмәдә дә садәлек күрәбез[4].

---

[1] Табган – табигате белән.

[2] Тәсавырлар – күзаллаулар.

[3] Назик – нечкә, нәфис.

[4] 1906 елда «әл-Гаср әл-җәдит»тә тезмәдә чуар тел белән язган Тукай чәчмәдә шул вакытта ук җиңел татарча белән яза иде. *(Авт. иск.)*

8) Тукай, татар әдәбиятында беренче мәртәбә шигъри һөҗү ишеген ачып, шуңа ачык, киң юл ясады. Чын әдәби һөҗүнең безгә дөрес үрнәген күрсәтте[1].

Инде Тукайга аның шагыйрьлеге, сәнгатьчелеге ягыннан тукталып үтик. Тукай сүз сәнгатендә татарның классик шагыйрьләреннән иде. Ул әйтергә теләгән фикерен, тасвир итәргә уйлаган хисләрен ачык, аңлаешлы, үтемле итү белән бергә матур язды. Татар теленең киңлеген, матурлыгын ачты. Фикер, хисләрне аңлатуда иң уйгын сүзләрне, матур, үткен тәгъбирләрне таба алды.

Һәрхәлдә, ул үзенең тасвирларында һаман сәнгатькяр, һаман көчле талантлы татар шагыйрьләренең берсе – классик бер шагыйрь булды. Шулай ук тыгыз мәгънәле, фикер, өслүбтә бик икътисадлы бер шагыйрь иде.

Тукайның сәнгатьчелеген, көчле шагыйрь икәнен күрсәтә торган шигырьләре күп. Шуның өчен алардан бу урында мисал китереп бетерү мөмкин түгел, шулай да без Тукайның сәнгатьче, көчле, оста бер шагыйрь икәнен күрсәтә торган лирикасыннан берничәсен түбәндә атап үтәбез: «Бер татар шагыйренең сүзләре», «Утырышу», «Гашыйк», «Бәйрәм вә сабыйлык вакыты», «Чын белән ялган», «Күңел», «Вакъты гаҗезем», «Тәрәддөд вә шөбһә», «Сөбханалла, сөбханалла», «Милләтчеләр», «...кә», «Мигъраж», «Өзелгән өмид», «Дөньяда торыйммы дип киңәшләшкән дустыма», «Алтынга каршы», «Өмет», «Шагыйрь», «Кызык гыйшык», «Бер рәсемгә», «Эштән чыгарылган татар кызына», «Сәрләүхәсез», «Ачы тәҗрибә авазы», «Үкенеч», «Күңел йолдызы», «Буран», «Казан вә Кабан арты», «Хөрмәтле Хөсәен ядкәре», «Шиһаб хәзрәт», «Тәмсил», «Кыйтга», «Ислахчыларга», «Үз-үземә», «Теләнче», «Мөбарәк тәсбих өзелде», «Үтенеч», «Читен хәл», «Дошманнар», «Кичке теләк», «Ваксынмыйм», «Сагыныр вакытлар», «Көзге җилләр», «Авыл мәдрәсәсе», «Дин вә гавам», «Мөхәрриргә» вә башкалар. Аның сүз сәнгатьчесе икәнен ачык күрсәтә торган әсәрләреннән озынраклары «Шүрәле»се белән «Печән базары» (яисә «Яңа Кисекбаш»ы) булды. Ул боларның икесендә дә халык экиятләреннән матур бер шигырь ләүхәсе (картинасы) тудырды.

Фәкать вәзен, өслүб мәсьәләсендә Тукай үзеннән бөтенләй оригиналь яңа бер сызык сала алмады. Аның бу турыдагы хезмәте искеләрне матурлап эшләвендә, халык вәзеннәрен киң иттереп татар

[1] «Безнең юл», 8–9 нчы сан, 1923 ел. Г. Сәгъди мәкаләсе. *(Авт. иск.)*

шигырендә татбикында[1] булды. Ул, бердән, ана теле, чыгтай, кыпчак әдәбиятындагы вәзеннәрне татар теле рухына каратып эшләгән яисә шуларны бармак саны, иҗек саны вәзененә әйләндергән булса, икенчедән, халык вәзененнән «Зиләйлүк», «Тәфтиләү», «Әллүки» көйләренә килә торган вәзеннәр белән 5, 7 иҗекләрне кулланып китте. Иске төрк әдәбият вәзеннәреннән аның кулланганы 11, 12, 15, 16 иҗеклегә килә торганнары булды.

Заманында, Сәгыйть Рәми кебек, ул вәзеннәргә һәм ул фикерләргә, идеологияләргә сыя алмый торган яисә шулардан чыгарга теләгән шагыйрьләр аның турында: «Ул иске Кисекбаш, Бакырган һәм Йосыф китапларын гына яңа төрлеләтеп, аларга соңгы мода сүзләрдән кушымталар гына калдырып китте» дип тә язып үттеләр («Ил», 23 нче сан, 1914 ел. С. Рәми мәкаләсе).

Тукай, русчадан һәм татар халык әдәбиятыннан файдаланып, балалар, мәктәп, уку китаплары өчен дә теле, тасвиры ягыннан күп кенә матур шигырьләр бирде. Шулай итеп, бу яктан аның татар әдәбиятының балалар, башлангыч мәктәпләр өчен булган бүлемен тудырышуда да зур хезмәте булды. Бәлки тезмәдә моның матур сукмакларын ул салды. Ләкин бу шигырьләренең күп өлеше тәмам дини-милли рухта булып («Аллаһы Тәгалә», «Ана догасы», «Туган тел», «Авыл», «Ана илә бала» кебекләр), яшүсмерләрне Алла, фәрештә, дога кебек нәрсәләргә баглыйлар, балалар йөрәгенә шул рухны нык өрәләр иде. Шуның өчен аның андый шигырьләре кыска гомерле булып, хәзер инде аларның күбесе мәктәп балалары өчен үзләренең рухы, мөндәриҗәләре һәм бераз өлешендә теле ягыннан да яраксыз булып калдылар.

Тукай тәрҗемә турында, бигрәк тә русчадан һәм башка телдә язучы шагыйрьләрдән файдаланып язуда артык бер осталык күрсәтте. Чынлап та, «анда шундый бер куәт бар ки, ул мәгънәне рус шәкел вә стиленнән тамчысын калдырмыйча, кысып аерып ала да аны гаять нәфис вә табигый бер шәкелдә татарча, Тукайча иттереп безнең күз алдыбызга утыртып куя»[2].

Җ. Вәлиди Тукайны «тәкълид итә-итә иҗат кылды», аның «иҗаты һәрвакыт тәкълид нигезенә бина кылынган», ул «үзенең мәһарәтене[3] иҗадта түгел, тәкълидтә күрсәтте, мәрхүм тәкълид ителми торган бер мөкаллид[4] иде», дип күрсәтә.

[1] Татбикында – яраштыруында.
[2] Җ. Вәлиди. «Тукаев мәҗмугасы»на язган мөкаддимәсеннән. *(Авт. иск.)*
[3] Мәһарәтене – сәләтен.
[4] Мөкаллид – иярүче.

Заманындагы татар шагыйрьләренә түгел, бәлки рус шагыйрьләренә һәм иске төрек әдәбиятына, шулай ук халык әкиятләре, халык легендаларына тәкълид һәм шулардан файдалану, үрнәк алу мәгънәсе белән бу сүзләр әсасән дөрес булыр. Ләкин моңа шуны кушарга кирәк: һәр шагыйрьнең төп маясы башта, әлбәттә, тәкълид була. Иҗат шуннан соң шуның үзлекләндерелгән бер җимеше булып мәйданга килә. Бу – асыл иҗатның беренче баскычы. Оста тәкълидче оста иҗатчы да була ала. Фәкать башка шагыйрьләребез шикелле үк, Тукайга да үзенең наданлыгы, мәгълүматсызлыгы аңа күп зарар итте.

Тукайның тик үзеннән, һичкемгә тәкълидсез вә иярмичә язган шигырьләреннән җитди шигырьләре җиде йөз мисраглар чамасы (655–675 арасында) бар. Димәк, болар урта кулда кырык биш битләр чамасы бер китап була. Шундый шигырьләреннән һөҗүвиләре мең мисраглар чамасында булып, 55–60 битләр зурлыгында (урта кулда) бер китап буладыр.

Тукайның русча вә төрекчәдән файдаланып яки шуларга тәкълид һәм шулардан тәрҗемә вә икътибас кылып, үзгәртеп яисә шуларның тәэсире белән язган шигырьләре барысы мең мисрагтан артыграк. Бусы үзе, димәк, 60 битләр чамасында бер китап булып чыга.

Тукай күбрәк Пушкин һәм Лермонтовтан файдаланган, икътибас кылган яки тәрҗемә иткән. Толстой, Майков[1], Плещеев[2], Фёдоров[3], Крылов, Буренилнардан[4] да икътибас вә тәрҗемәләре байтак бар («Җәйге таң» – Фёдоровтан мөкътәбәс, «Япун хикәясе» – Буренилнан тәрҗемәдер). Гёте һәм Шиллердан, Байроннан, Шекспирдан да файдаланган. Ләкин болардан аз алган. Позняковтан[5], «Сатирикон»нан[6], Бальмонттан[7] да файдаланган. Ивановтан[8] да файдалануы бар.

[1] Аполлон Николаевич Майков (1821–1897) – рус шагыйре.

[2] Алексей Николаевич Плещеев (1825–1893) – шагыйрь, язучы, тәрҗемәче, әдәбият һәм театр тәнкыйтьчесе.

[3] Александр Митрофанович Фёдоров (1868–1949) – шагыйрь, прозаик, тәрҗемәче һәм драматург.

[4] Виктор Петрович Буренин (1841–1926) – сатирик шагыйрь, драматург, тәрҗемәче, әдәбият һәм театр тәнкыйтьчесе.

[5] Николай Иванович Позняков (1856–1910) – язучы, шагыйрь, тәрҗемәче.

[6] «Сатирикон» –1908–1914 елларда Петербургта рус телендә чыккан атналык сатирик журнал.

[7] Константин Дмитриевич Бальмонт (1867–1942) – символист шагыйрь, тәрҗемәче, рус әдәбияты Көмеш гасырының иң күренекле вәкилләреннән берсе.

[8] Алексей Фёдорович Иванов (тәхәллүсе – Классик) (1841–1894) – юмористик шигырьләре белән танылган рус шагыйре.

Югарыдагы шагыйрьләрнең шигырьләреннән тәрҗемә вә икътибасларын Тукай шигырьләренең башына күбесен үзе әйтеп, язып куйган. Тукайның бөтен әсәрләре 456 бит кадәр.

Тукайның «Пар ат» шигыре Лермонтовның «Тройка»сының тәэсире белән язылган. «Тәэссере» Лермонтовка тәкълид нәтиҗәсе булып туган. «Алдандым» янә шуңа тәкълид белән язылган. «Хур кызына» – Лермонтовтан зәгыйфь бер тәрҗемәсе (үзе әйтүе буенча, төрекләргә тәкълид вакытында), «Мәхбүс» Пушкиннан алынган, «Шагыйрьгә» Лермонтовтан үзгәртелгән, «Исемдә» – русчадан, «Газаптан соң» – Майковтан мөкътәбәс, «Бишектәге бала» – Лермонтовтан, «Җәйге таң» – Федоровтан мөкътәбәс. «Япун хикәясе» – Буририннан, «Вәгазь» – Лермонтовтан, «Кемнән ярдәм эзләргә?» – Майковтан тәрҗемә. «Шатлык вә хәсрәт» – Плещеевтан, «Соңра» Лермонтовтан үзгәртелгән. «Төлке һәм йөзем җимеше» – Крыловтан, «Теләү бетте» – Пушкиннан мөкътәбәс. «Китап» – бераз гынасы русчадан. «Киңәш» Позняковтан үзгәртелгән, «...га» – Лермонтовтан мөкътәбәс, «Сөткә төшкән тычкан» – бер Америка гәзитеннән. «Кемне сөяргә кирәк?» – Пушкиннан, «Мужик йокысы» – Кольцовтан тәрҗемә вә икътибас. «Төш» – Гётедан. «Гөнаһ» Бальмонттан үзгәртелгән, «Кадер кич» – сүрәи Кадердән, «Тәүбә вә истигъфар» Пушкиннан үзгәртелгән. «Монафикъка» – русчадан. «Мәҗлес» – Пушкиннан. «Өч хакыйкать» – Майковтан. «Хатыннар хөррияте» – «Сатирикон»нан, «Мулланың зары» – «Мулла Насретдин»нән. «Вөждан зарары»[1] – «Будильник»тан[2]. «Өйләнү – түгел сөйләнү» – Ивановтан. «Күгәрчен», «Иссез чәчәк» – русчадан. «Яз хәбәре» – русчадан. «Эшкә өндәү» – Плещеевтан. «Елның дүрт фасылы» – русчадан. Барысы кырыклап шигырь.

**Сәгыйть Рәмиев.** Сәгыйть Рәмиевның шагыйрьлеге Беренче рус революциясе җимерелеп, каты реакция кергәч башланды. Шуның каты кысуы, караңгылыгы анда өметсезлек тудырды. Ул менә шушы караңгылык эчендә ялгыз адашып, дошманга каршы ялгыз көрәшүче анархи-индивидуалист булып чыкты. Аның шигырьләре аркылы татар лирикасы беренче мәртәбә дин караңгылыгына һәм дөньяның бөтен кануннарына каршы көчле гыйсъян күтәрде:

«Мин!» димен мин; «мин», дидисәм,
Миңа зур бер көч керә:

[1] Текстта «Вөждан хөррияте».
[2] «Будильник» – 1865–1871 елларда – Петербургта, 1878–1917 елларда Мәскәүдә чыккан атналык сатирик журнал.

Аллалар, шаһлар, кануннар
Булалар бер чүп кенә[1], –

дигән юллар әнә шул шагыйрьнең каләме аркылы татар дөньясында шундый көчле бер гыйсъянның беренче мәртәбә кузгалуы, шартлавы иде. Һичкемнән, һичнәрсәдән курыкмыйча, бу рәвештә бер катылык, кискенлек белән Алла, патша һәм аның кануннарына каршы сугыш ачу татар шагыйрьләре арасында аңарча юк иде. Аның югарыдагы юллары әнә шул сугышның гүя беренче команданы кулыннан, аның беренче атыш коралыннан чәчрәгән зәһәрле пулялар булдылар. Шулар өстенә, Алланың үзенә төбәп, ул:

Масайма син, Раббым, кодрәтеңә,
Тартып алып ни бар бәхетемне;
Килер бер көн: ватар, көл итәрмен
Гарше, көрси, сәмәк, тәхетеңне![2] –

рәвешендә икенче бер төрле шартлау белән ташланды.

Менә бу гыйсъян, бу шартлаулар татар дөньясында үз вакытында бик зур бер шау-шу күтәрде. Хәтта Сәгыйтьне: «Мондагы «Алла» сүзе турында халык игътикадындагы Алла түгел, бәлки аннан үзләрен аллалык дәрәҗәсенә куючы ишаннар, ялган аллалар морад[3]», – дигән мәфһүмдә[4] изах[5] яздыртуга мәҗбүр иттеләр.

Сәгыйть тә, Тукайлар шикелле үк, 1905 ел революциясенең дулкыны эчендә татарлар турында күп өметләр белән күтәрелеп чыгып, әдәбият, матбугат мәйданына атылган яшьләрнең берсе иде. Ул бу юлдагы адымнарын башта ук Тукайлар шикелле шигырь язу белән башламады, җәмәгатьчелек юлында эшләргә тотынды. Башка «таңчылар» белән бергә «таңчы» булып, социал-революционерлык кызулыгы белән шунда эшләде. Анда әле ул өметле Сәгыйть булып, мәкаләләрендә зур өметләр, үз теләкләренә ирешү, өстенлек казану дәртләре белән яза иде.

Менә каты реакция кузгалды. Хөррият хәрәкәтләрен соң дәрәҗәдә аяусыз-кансыз бер рәвештә кыса, хөрриятчеләрне һәрьяктан изә башладылар. Әнә шушы хәлләр Сәгыйтьтә өметсезлек тудырды.

[1] С. Рәмиевнең «Мин» (1908) шигыреннән.
[2] С. Рәмиевнең «Мәҗид сүзе» шигыреннән.
[3] Морад – күздә тотыла.
[4] Мәфһүмдә – эчтәлектә.
[5] Изах – аңлатма.

«Татарча гына әйткәндә, идарәдә бер пожар иде[1]. Мин дә, атлар-атламас кына кереп, бер номер гәзитләрен алып, читкәрәк кенә утырып, «әл-Ислах»ның баганалары буенча салмак кына күзләремне йөртә башладым.

Һаман үзем идарәдә утырып, күзем гәзит юлларында йөрсә дә, күңелем һаман өметсезлектә, һаман үзенең: «Ничек кенә итеп бу залим, надан, рәхимсез татар галәменнән котылырмын да, кайчан гына теге караңгы, тар, суык, ләкин рәхәт булыр төсле күренгән кабергә барып керермен икән», – дигән ямьсез уйлар гына уйлауда иде.

Моннан берничә ай гына элек мин дә шулай, шушы шәкертләр кебек гәзит идарәләрендә эшләп, гәзитебезнең һәрбер чыккан яңа номеры саен үзенә башка кабат-кабат куанып: «Менә, Алла теләсә, татарлар да кеше булырлар, татарларның да күңеленә рәхмәт салыныр, нур керер, татарларның күзләрендә дә мәхәббәт йолдызлары ялтыраганын күрәчәк көнебез булыр», дигән өмет белән яшь балалар кебек очына идем.

Шушындый саф көмеш кебек ак өметләремнең ахыры тигезлек, дуслык, мәхәббәт булачак урынына дошманлык, өметсезлек, караңгылык булып чыкканга, шәкертләрнең өметләрен дә мин үз өметемә, мондагы хәрәкәтләрне дә мин синемотографтагы пожарга гына охшата идем.

Барча кызыктан бизгән, барча өметләремдән кул селтәгән, барча галәмдән аерылган, тик үләсем генә, ничек тә булса бу галәмдән китәсем генә килә иде»[2].

Бу революциядән ашкынып күпне көткән һәм шул юлда байтак кыенлыкларны башыннан кичереп өлгергән Сәгыйть өчен шул өметләрнең, көтелгәннәрнең юкка чыгуын, җилгә очуын күрү, әлбәттә, авыр иде. Әнә шушы хәлләрнең тәэсире белән Сәгыйтьтә өметсезлек белән сугарылган көчле бер лиризм уты кабынды. Ул, кабынып, шуның куәте белән күтәрелеп, бөтен барлыгы белән ташып кайный башлады. Ниһаять ул, Аллага, патшага, кануннарга гына түгел, хәтта бөтен дөньяга, бөтен тормышка, бөтен адәмнәргә, кыскасы, һәммә нәрсәгә дошман булып әверелде. Бөтен сизү тамырлары ташыган, бөтен ми-йөрәгеннән кызу ут алган хәлдә, шуларның барлык куәте белән һәммә нәрсәгә һөҗүм ясады. Һәммә нәрсәне

[1] Югарыда «әл-Ислах» идарәсенә килеп керүен, идарәдә кызу эш баруын сөйләп килә. *(Авт. иск.)*

[2] «Әл-Ислах», 11 нче сан, 1907 ел, Сәгыйть Рәмиев мәкаләсеннән. *(Авт. иск.)*

инкяр кылу дәрәҗәсенә барып җитте. Шушы рухи хәл аның шигъри иҗатларында төп куәт булды. Аның бу юлдагы беренче адымы 1908 ел «әл-Ислах»ның 4 нче санында басылган «Алданган» шигыре белән башланды. Ахырда ул, югарыда китерелгән мисаллардан күренгәнчә, бөтен нәрсәне җимерү, «мин»еннән башка бер нәрсәгә дә баш имәү баскычына күтәрелде. Уңлы-суллы төрле якка ташланып, каты-каты шартлаулар ясады.

Менә бу – Сәгыйтьнең гыйсъянчылык, анархи-индивидуалистлык, дәһрилек дәвере иде. Аның шагыйрьлек талантының бөтен үткен, кискен яклары, иң зур куәте дә аның шушы дәверендә күренеп калды. Ул үзе беренче көчле талантлы шагыйрь булып шул дәверендә танылды. Татарның классик бер шагыйре булучылык дәрәҗәсен дә аңа шул дәверендәге шигырьләре алып бирделәр.

Соңыннан исә «Аң»да язган шигырьләре аның икенче дәверен ачтылар. Бу шигырьләрендә инде без беренче Сәгыйтьнең югалганын, аның урынына икенче Сәгыйтьнең туганын күрдек. Бу турыда ул нәкъ Мәҗит Гафуриның киресен күрсәтте. Идеологиясендә шулай булган шикелле, тел-өслүбендә дә шулай булды.

Бу икенче дәверендә инде без аның, Тукайлар, Гаяз Исхакыйлар шикелле үк, дин һәм Аллалык юлына кабат әйләнеп төшкәнен күрдек. Беренче көчле, һәр нәрсәне җимерергә омтылучы, һәр нәрсәдән өстен булырга җилкенүче Сәгыйть инде:

Әй, Илаһым, тот сүзеңне!
Үз сүзең «аны кариб».
Әмереңә сәмган вә тәга
Мөстәҗибмен[1] мин гариб.
Мөстәҗибмен һәм теләгем
Кушмасы юк бик бәсыйт[2]:
Алдагы бәйрәм көнең бер
Шат күрергә ит насыйп (1916 ел, «Аң»), –

дип, Аллага ялвара торган гариб бер Сәгыйть булып әверелде. Менә бу Сәгыйть – шөбһәсез, җиңелгән, әүвәлге көчен югалткан динле, илаһлы бер Сәгыйть иде.

Ачык, кискен, нәгыз татар теле белән яза торган, татар теленә катылык, ныклык, сафлык бирүче Сәгыйтьнең дә бу шигырьләрендә инде юклыгы нык сизелде. Инде аның теле дә чуарланды: «Кирамен

[1] Сәмган вә тәга мөстәҗибмен – баш өсте, ләббәйкә, дип үтәүче.
[2] Бәсыйт – гади.

кятибин[1], гамь, бәсыйт, вөҗүд, талигъ[2], мөстәҗиб, сәмган вә тәга» кебек авыр гарәп сүзләре белән буталган бер жаргон хәлен алды. Бу яктан инде ул Тукайларның киресенә әйләнергә иткән күренде.

Сәгыйть Рәми – Октябрь революциясенә килеп җиткән һәм, бу революция тамырланып алып, советчылык төзелгәч, советка кушылып эшли башлаган бер шагыйрь. Ләкин ни өчендер революция, Мәҗитләрне уяткан шикелле, аны уята алмады. Гәрчә ул үзенең әүвәлге «таңчылык» заманындагы мәсләктәше Гаяз Исхакыйның [19]25–[19]26 елда Төркиядә большевикларга каршы хәрәкәте өчен аңа ачуланып, аны шуның өчен ахмаклардан санаса да[3], шулай ук ул Октябрь революциясенә, аның биргән нәтиҗәләренә бик яхшы карап, советка якынласа да, аның якынлашуы, совет юлындагы хезмәте Җир эшләре халык комиссарлыгында эшләп гомер үткәрүдән артыкны бирә алмады. Әдәбият, матбугатта яңа бер нәрсәсе күренмәде. Матбугатка катышмады. Чөнки авырып хәлдән тайган иде... Октябрь куәте белән яңадан дәртләнеп, гайрәтләнеп шартлау, шашыну да анда күренмәде. Бу революцияне шатлык белән каршы алу дулкыннары да аның йөрәгендә күтәрелеп таша алмады. Ул һаман әүвәлге өметсез хәлендә калды. Шулай ук бу хәлләр берсе дә аның шигъри талантын яңадан уята алмадылар. Ул һаман әүвәлге Сәгыйтьне кайтармады. Бәлки «1907 ел соңындагы реакция җилләре аның үз кәгъбәсен үзгәртеп, үзенең шәэненә[4] ятмаган кара эшләр белән юлыннан капыл йөзен чөерде»[5] булып чыгуы аңа яңадан революция рухы белән шашып таша башлауга имкян бирмәгәндер. Ни булса да, инде әүвәлге Сәгыйть кайтмады.

Дөрес, ул 1923 елда чыккан «Башкортстан»ның 5 нче санында «Сүзем һәм үзем» дигән бер шигырь язган иде. Монда ул:

Тутыкмый ул сүз кылычым кынысында
Тору берлән халкы бердәм тынышында.
Сайкалыны[6] ачарга дип куелган ул
Кара каннан, япкан ирек сугышында.

[1] Кирамен кятибин – кешенең яхшы һәм яман эшләрен язып торучы фәрештәләр.

[2] Талигъ – бәхет, яхшы киләчәк, өлеш.

[3] Бу турыда Газыйм Касыймның [19]26 елда «Яңа авыл» гәзитендәге мәкаләсенә каралсын. Бу мәкалә, кыскартылып, шул ук елның 3 нче сан «Безнең юл»да да басылып чыкты. *(Авт. иск.)*

[4] Шәэненә – холкына.

[5] «Безнең юл», 3 нче сан, 1926 ел. «Эшче» гәзитеннән. Давыт Юлтый сүзләре. *(Авт. иск.)*

[6] Сайкалыны – ялтыравыгын.

Җиһанда ләшәй[1] аңар атар ук та,
Юл өстендә ятар дәрья, янар ут та, –

дип, әүвәлге «Сәгыйтьлек» чаткысын очырырга итсә дә,

Вәләкин ул әрәм җиргә ялтырау бирми,
Буш һавада, әзерләнгән зәмин юкта, –

дип, үзенә зәмин беткәнен аңлатты. Шуның өстенә, тагын ул монда:

Күрерсез сез хасымының аптырашын,
Хак алдында батыйльнең[2] дер калтырашын,
Әгәр зәмин әзер булып, тоталсагыз
Сез һавадан аның яшен ялтырашын, –

дип, әллә нәрсәләргә ишарә кылганнан соң:

Сүз көчле ул, мәгънәле ул, сирәк булса,
Тыңлаучы да сүз аңлаган зирәк булса;
«Көн» дигәнмен, беләсез, «фәякүн»[3] булган,
Тагын әйтермен, тагы булыр, кирәк булса,

һәм:

Тугры юллы көрәштем мин Алла белән,
Гарше көрси ваттым сүздә балга[4] белән,
Чөнки үзе бәндә мәхлугы булса да,
Патшаларга шул сакчы иде алдау белән, –

дип, әүвәлге алласызлыгы белән мактанса да, янә үзе турында:

Мин тормышта күңел белән генә торып,
Тормыш аны рәхим-шәфкатьсез изсә дә,
Һаман янам сәгадәтне идеал корып,
Барып җиткәч ләкин аннан җил иссә дә.
Һаман бер көй, кайгырам тик рәхмәт эзләп,
Бер көй миндә, сүремәс кан, сүнмәс җан бар,
Йокымны да бүлсә бүлә, рәхәтсезләп,
Миңсылулар, Минҗамал һәм Минҗиһаннар[5], –

диюе белән ул һаман шул ук үзенең индивидуалист-идеалистлыгын тәкрар көйләде.

---

[1] Дөресе: җиһадында ләшәй – җиһатта берни түгел.
[2] Батыйльнең – бозык кешенең.
[3] Биредә «көн фәякүн» – «Бул!» дию белән үк булуны аңлаткан гыйбарә күздә тотыла.
[4] Балга – зур чүкеч.
[5] Ул бу шигырьнең башына шушы түбәндәге юлларны язып куйган:
Язачагым шигырь түгел, бер мәнзумә,
Җавап итәм газыйм иптәш һәм мәнзумгә;
Сүзләреннән бер мәҗлестә үз-үземне
Юллы-юлсыз хисап иттем дә мәзлумга. *(Авт. иск.)*

Аh!..
Чорналганмын шул мәхәббәт богавына!
Ик-чик белмим матурлыкның мин багына;
Бер зур эштән – бер җиһаддан бушадыммы,
Һаман күңелем матурлыкка тик табына, –

дигән мисраглары белән дә шул югарыдагы сыйфатын тәэкид итте[1]. Ләкин шул шигыренең иң ахырында ул:

Сәгадәттән бер дә өмет кискәнем юк:
Хәят белән арам төенен чишкәнем юк.
Касәсеннән хәятның, раст, авыз итсәм дә,
Ләкин әле төбенә хәтле эчкәнем юк, –

дип бетерә. Димәк, аның әле «хәят касә»сенең төбенә кадәр җиткереп эчәргә өмете бар иде. Әнә шул өметенә ул ирешә алмыйча дөньядан үтте. Шуның өчен дә ул идеалист-индивидуалистлыгында гына әүвәлгечә калып, әмма әүвәлге шашкын, гыйсъянчы Сәгыйтьнең әсәре монда юк иде. Тел-өслүб, вәзен ягыннан да монда әүвәлге «Сәгыйтьлек» аз күренә, аның бу соңгы шигырендә мәгънәнең бик үк ачык аңлашылып җитмәү сыйфаты да юк түгел иде.

Сәгыйть Рәми Дәрдмәнд шикелле үк иң аз язучылардан булды. Ләкин ул әүвәлге шигырьләре белән яисә әүвәлге «Сәгыйтьлеге» белән, шөбһәсез, көчле бер лирик, татарның романтик-пессимистик бер классигы иде. Ләкин, югарыда әйткәнебезчә, күбрәк яза башлагач, соңыннан ул йомшады йомшавын. Әүвәлге көче, әүвәлге шашкын таланты сүнде. Чынлап та, ул «бөтен дөньяны яндыру уе белән бердән даулап кабынып киткән, ләкин уты белән төтене аерыла алмаган бер янгын» иде, ахырда шул төтене эчендә үзе дә һәлакәткә очраучы бер реакция корбаны булып дөньядан үтте.

Янә бу бар: Дәрдмәнд шигырьләрен халык-масса аңламаган шикелле үк, Сәгыйтьне һәм аның шигырьләрен дә аңлый алмады. Хәлбуки, ул үзе сүз сайлауда тик татарча (әүвәлге шигырьләрендә) булу юлын тотты. Башка шагыйрьләр, мәсәлән Тукайлар кебек, чит сүзләрне дә ул башта бер дә кулланмады диярлек, шулай булып торып та, ул халык өчен җиңел аңлашылырлык бер шагыйрь булмады. Моңа, икенче яктан, бәлки аның артык җимерүчелеге, баштагы алласызлыгы да бер сәбәп булгандыр.

[1] Тәэкид итте – раслады.

Ләкин аның гаммәгә – массага аңлаешлы булмавының төп сәбәбе – аның үз вакытында халыкка кирәкне җырлый алмавы иде. Ул артык үз эченә бикләнгән, үзенең «үзлеге» эчендә нык төренгән бер шагыйрь булды. Икенче төрле әйткәндә, ул артык бер индивидуалист һәм байтак өлешендә символист бер шагыйрь иде. Ләкин ул, шушы хәлләргә карамастан, әдәбият һәм сәнгать ияләре каршында, татар лирикасында үзенә аерым бер урын алучы, үзенә башка бер юл яручы онытылмаслык бер классик шагыйрь булып калды.

**Дәрдмәнд.** Бу шагыйрьнең лирикалары үзендә тирәнлек белән нечкәлек сыйфаты бергә җыйналган куәтле бер минең татар әдәбиятында беренче иҗаты иде. Аның шигырьләре, хистән бигрәк фикер тирәнлеге эченә чумылып, озак төшенүнең җимеше булдылар. Ул әүвәл хис итмәде, төшенде; төшенгәнен хискә әйләндерде. Яисә аның хисләре аркылы фикере түгел, фикере аркылы хисләре туды. Хисләрен ул фикеренә, төшенүенә ияртте, Тукай кебек, ул әүвәл хис итеп, шуннан соң уйламады. Әүвәл уйлап, аннан соң хис итте. Сәгыйть Рәми кебек шашкынлы бер хис, дөньяга кискен бер нәфрәт уты эчендә дә чолганып калмады. Шулай ук Сәгыйтьтәге кебек шау-шулы язгы ташкынга охшау да анда юк. Ул бик әкрен, тирән, киң алымлы, бормалы дулкыннар белән аккан бер дәрья шикелле тавышсыз, ләкин гаять кайгылы бер тон белән акты. Аның кайгысы да реакция соңында татар өстенә әүвәлге җәберләрнең кайту хәвефе иде.

Дәрдмәнд Яурупа мәгънәсе белән чын либераль буржуа лиригы иде. Аның шигырьләрендә гыйлемле, мәгълүматлы һәм мәдәнилектә үсеп җиткән, ләкин тарихи мәҗбүри бер һәлакәтне алдан төшенеп өлгергән бер минең ялтыравы күренде.

Шулай да ул моның өчен шашынып, акылыннан язып аһ ормады. Өзелә-өзелә, сыгыла-сыгыла моңайды. Аның күз яшьләре уйлыйуйлый, төшенә-төшенә түгелделәр. Бу күз яшьләрен дә алдагы өмет нуры сүнгән бер сыйныфның – буржуазия сыйныфының күз яшьләре дип аңларга кирәк.

Дәрдмәндтә тагын менә шундый бер хосусият бар: ул фикерхисләренә, моң-зарларына гомумилек, җиһанилык сыйфатын бирергә тырыша. Гүя ул үзе өчен түгел, милләт, ил өчен һәм аннан да аша китеп, гүя ул бөтен кешелек хәяты өчен, бөтен илләрнең, бөтен кешелекнең юк булып китүе өчен әрнүче булып күренә. Аның өметсезлеге дә – гүя бөтен җиһанның, бөтен илнең өметсезлеге. Аның «Без» шигырендәге:

Гасырлар кичте, китте... кичте еллар!
Нәбиләр, падишаһлар сөрде дәүран[1]...
Гомерләрдер, күчеп кәрван вә кәрван,
Килеп кичте җиһаннан канча[2] илләр.

Сүнеп, вәйран булып мәгъмүр[3] төякләр,
Җир астында тезелде ку сөякләр!..
Исә җилләр... Күчә комнар, бетә эз...
Дәрийгъ, мәхзүн[4] күңел, без дә бетәбез!!

Мосафир кем, җиһанга басты ботны,
Биетте ажгырып аны замана...
Өеп чергән өмидне, төртте утны,
Йотып утларны, китте яна-яна... –

мисраглары өстенә, «Бүзләрем маналмадым» шигыре баштанаяк шуны аңдырды. Андагы:

Гәрчә мин дә бар саналдым, ил катар саналмадым,
Илдә йөрдем, хазлар[5] алдым, уйласам, сан алмадым!
Янды Мәҗнүн, янды Фәрһад, бер янып ат алдылар,
Мин гариб мең кат янып та, яндыга саналмадым;
Уйлагыз, мәгъшука меңләр!...
Мин гашыйк саналмадым!

һәм:

Әйттеләр кем: бер бәхетсез илгә гашыйксың, фәкыйрь,
Бер кызардым, бер бузардым... ни таныйм... таналмадым.
Ни таныйм?! Таналмадым!
Сезне, милләт кызлары, аһ, и өмид йолдызлары!
Таң сәхрәләр эзләп-эзләп, бер күреп каналмадым.
И өмид йолдызлары!
Бер күреп каналмадым.
Исте җилләр ил эчендә иртән, кич, салдым колак,
Җил-җиләсләрнең моңыннан зәүкы әлхан[6] алмадым, –

дигән мисраглары мәгълүм бер ил, милләт кайгысы белән сугарылганын аңлаттылар. Болар барысы да аның Сәгыйть кебек индивидуалист түгел, идеализм нигезендә объективист булып һәм җәмәгатьчелек рухында моңланганын яисә шулай моңланырга тырышканын

[1] Дәүран – гомер.
[2] Канча –күпме.
[3] Мәгъмүр – төзек.
[4] Мәгъзүн – кайгылы.
[5] Хаз – гарәпчә сүз булып, «өлеш», «хисса» мәгънәсендә. *(Авт. иск.)*
[6] Зәүкы әлхан – көйләр ләззәте.

күрсәтәләр. Аның «Хәят» дигән шигыре дә – гүя бөтен кешелек тормышының, бөтен мәдәният хәятының музыка уеннары аркылы күрсәтелгән бер картинасы.

Шулай итеп, бу шагыйрь үзенең үзлеген «зәүкы хәят көткән гасырлар», «калын ил» моңнары, «хәят» уеннары эчендә яшереп, үзен шулар аркылы күрсәтергә тырыша. Аның мәшһүр «Кораб»ы да шундый ук бер рухта. Анда:

Чыкты җилләр, купты дулкын, ил корабын җил сөрә,
Кайсы җилләр, нинди упкын тарта безне җан сорап? –

дигән мисрагы шуны ачык сиздертә.

Дәрдмәнд – реакция заманының романтик-пессимист шагыйре. Ул – татар лирикасында романтизмны көчле бер пессимизм рухы белән тирәнәйтүче. Ләкин Сәгыйть кебек үзлекле пессимизм белән түгел, иҗтимагый пессимизм рухы белән. Анда, бер шәхси бәхетсезлектән бигрәк, иҗтимагый бәхетсезлектән, ил бәхетсезлегеннән зарланганны күрәбез.

Шуның өстенә ул татар лирикасында тирән бер фәлсәфи тамыр үстерде. Икенче төрле әйткәндә, ул философ бер лирик һәм фикер шагыйре булды. Аның югарыдагы шигырьләрен алмыйча, тик:

Ул калын ил кем гадәмдән сил булып[1] килмәктәдер,
Шәвыклар[2] бирмәктә андан бу вөҗүд ирмагына[3], –

дигән ике мисрагын алып күрсәтү үзе генә дә моның өчен җитә.

Дәрдмәнд – татар лирикасында көчле символизм һәм декадентлык чаткысын күтәрүче шагыйрьнең берсе, бәлки беренчесе. Бу сыйфат анда Сәгыйтьтәгедән дә ачык күренә. Аның югарыда әйтелеп үтелгән «Кораб»ы белән «Хәят»ы – моның өчен ачык мисал. «Кораб»та татар халкының авыр тормыш көрәшендә югалу куркынычын тасвир итә.

Дәрдмәнд шигырьләрен тикшергәндә, үзенә игътибарны аерым караткан тагын бер як менә шушы: ул, Мәҗитләр, Тукайлар, Сәгыйть Рәмиләр кебек «Алла», «Тәңре», «Раббы»лар белән дә чуалмый[4], аның төп иҗатларында болар һич яд ителмиләр. Ул андый бер куәт-

[1] Гадәмдән сил булып – билгесез яткан ташкын булып.
[2] Шәвыклар – *бирелә:* өметләр.
[3] Дәрдмәнднең «Хәят» шигыреннән.
[4] Анда тик:

Ачыдыр күз яше, табган, газизем,
Ходаның хөкеме бу – юктыр гөнаһым, –

дигән бер шигырендә, бер мисрагында гына «Хода» сүзен очратабыз. *(Авт. иск.)*

кә сыгынмый да. Бу ягы белән ул үзендә югары дәрәҗәдә бер буржуа зыялылыгын күрсәтә; юаш булса да, бер дәһрилек рухын сиздертә.

Татар буржуазиясе үзе өчен ике типлы сәнгатьче җитештерде. Чәчмәдә – хикәя, романнарда Ф. Әмирхан булса, тезмәдә дә Дәрдмәнд булды.

Дәрдмәнд – тезмәдә, чынлап та, татар либераль буржуазиясенең сүз сәнгатьчесе. Ул үзе җырлап, шул ук вакытта үзе музыка уйнап торучы бер сәнгатьчегә охшый. Ләкин аның кулында кыллы музыка юк. Ул музыка тавышы белән үз тавышының җитешсезлеген дә каплаучы түгел. Шуның белән бергә коры сүз уены да ясамый. Ул фикер, хисләрендәге бик назик бер музыкавилекне сүз музыкасы белән, чынлап та, иҗади бер юлда, искиткеч бер рәвештә сәнгатьчелек күрсәтеп аралаштыра ала. Аның шигырьләрендә фикер белән сүз, форма белән мәгънә һәм мөндәриҗә – бер-берсеннән гүя һич аерыла алмый торган бер нәрсә. Андагы тулы аһәң дә шул икенең нык берләшә алуыннан туган эчке, самими бер музыкавилек булып чыга. Кыскасы, форма белән мәгънәнең, мөндәриҗәнең берләшүе анда һичкем инкяр итмәслек бер дәрәҗәдә матурлык күрсәтә. «Сәнгать – сәнгать өчен» нәзариясе нигезендә шигырь иҗат итүдә татар әдәбиятының тезмә бүлемендә Дәрдмәнд шигырьләре иң ачык бер мисал була алалар.

Дәрдмәнд иҗатында сүзләр шул дәрәҗәдә бер осталык белән сайланган була ки, аның сүзләрен икенче сүзләр белән алыштыру һич мөмкин булмый. Сүз һәм җөмләләрнең корылыш һәм төзелешләрендә гаҗиб бер эчке бағланыш күренә, бер сүз яисә бер җөмләнең үз урынын алмаштыру дигән сүз ул Дәрдмәнд шигыренең бөтен бинасын җимерү дигән сүз булачак. Кыскасы, ул тел-өслүб, вәзен техникасында зур бер оста, олы бер специалист булып чыкты.

Ләкин бу техника, бу осталык, югарыда үз урынында әйтеп үткәнебезчә, нәгыз татар теле рухында түгел иде. Гарәп сүзләре, фарсы теле өслүбенчә сүз оештырулар аның шигырьләренең тамырында ята. Тик шунысы бар: болар башка шагыйрьләрнең шигырьләрендәге шикелле коры вәзен тутыру, бетем (кафия) ясау өчен генә китерелми. Алар гүя шагыйрьнең фикер һәм хисләрен үзе теләгәнчә тулы һәм аһәңле итеп аңлату өчен зур бер шигъри хезмәт үтиләр. Шуның белән алар Дәрдмәнд шигырьләре өчен бик табигый рәвештә матур төзеләләр.

Кыскасы, «үзенең коелган корыч кебек өслүбе, тирән мәгънәсе, һичбер шагыйребездә булмаган аһәңе – музыкасы белән татар

әдәбиятында бөтенләй аерым, ялгыз торган шагыйрь Дәрдмәнд»[1] булды. Ул һәр ягы белән Октябрьгәчә булган ун ел эчендә татар классикларының да иң көчлесе булып калды.

Дәрдмәнд татар лирикасында үзенә аерым бер мәктәп, аерым бер агым тудырды. Аның шәкертләре, иярченнәре дә булды. Фиракый һәм беренче адымнарында Кәрим Әмири[2], тагын башкалар шул мәктәпкә мәнсуб иделәр[3].

Ләкин Дәрдмәнд, үзенең шушы җитешлекләре белән бергә, шөбһәсез, татарның массасыннан, укымышлыларыннан, эшче-крестьяннан, аның теләк һәм кирәкләреннән тәмам читтә торган бер сәнгатьче иде. Идеологиясе, мөндәриҗәсе, рухы, теле-өслүбе белән дә ул аңа һич якын түгел. Шуның өчен дә аны, татар массасы аның шигырьләрен турыдан-туры үзе аңлап укып, таный алмады. Аның танылуы тар бер түгәрәктә, әдәбиятчылар, укымышлылар арасында гына калды, әле дә эшче-крестьян массасы аны таныса да, тик тәнкыйтьләр, аңлатулар аша гына таный алачак.

Ул – шәп шагыйрь, классик шагыйрь, ләкин эшче-крестьянныкы түгел; буржуа сыйныфыныкы. Ул – бөтен мәгънәсе белән буржуа туфрагыннан, шуның үзәгеннән ярып чыгып үскән, шуның һавасы эчендә тәрбияләнеп, шуңа яраклы җимеш биргән бер шагыйрь. Шуңа күрә ул һәм аның шигырьләре хәзерге өчен үзенең идеологиясе, мөндәриҗәсе, теле-өслүбе белән файдалы бер иҗат булып

---

[1] Г. Ибраһимов, «Татарстан» гәзите, 1922 ел, Дәрдмәнд вафат булгач язган «Еллык хисаб»ыннан. *(Авт. иск.)*

[2] Кәрим Әмири башта, үзенең Дәрдмәнд шикелле үк нечкә көйлап карауучылык һәм аның өслүбендә язучылык тәҗрибәсе заманында:

Очар кош! Оч, канат как! Үрлә күккә,
Сәгадәт талларын күктән табарсың...
Үләксә тупрагы җир-кулләрендә,
Бәхет юк, анда тик кортлар табарсың.

вә:

Заманага аяк баскан мосафир
Тирән сазга кереп батып адашса,
Юлын тапмак насыйпмы ул гарибкә,
Сүнәр шәм берлә эзләргә маташса, –

дигән фәлсәфи шигырьләр өстенә, хәтта 1921 елда да әле:

Әй, ләтыйф җил, ни сөйлисең бөдрә тал яфрагына?
Шатланыпмы җилферди ул – баш орып як-ягына.
Сөйлә, җил, ач эч сереңне,
Сүз бирәм сакларыма, –

рәвешендә Дәрдмәнд телендә, аның өслүбендә язуны ташламаган иде. *(Авт. иск.)*

[3] Мәнсуб иделәр – караган иделәр.

түгел, бәлки тик тарихи бер хадисә, тарихи бер факт булып кына тикшерелә ала.

Аның теле дә, техникасы да турыдан-туры татар хәятына ошарлык түгел; хәзер инде аның теле тормыш теле булудан бигрәк тә ерак тора. Аның шигырьләренең хәзер дә безнең өчен әһәмияте тик ике яктан гына. Берсе – алар татар әдәбиятында чын сәнгатьчә эшләнгән иң аһәңле, иң икътисадлы бер өслүб өчен ачык бер үрнәк, икенчесе – фикер, фәлсәфә лирикасыннан алар Яурупа мәгънәсе белән матур, тирән мөндәриҗәле бер иҗат булып торалар. Дәрдмәнд лирикасының татар әдәбиятында, татар әдәбият тарихында гомере әнә шушы ике ягы белән тәэмин ителә.

Нечкә, матур, тирән фикеренең музыкалы бер тел аркылы бик зур бер осталык белән бирелә алуы – менә Дәрдмәнд лирикасының татар әдәбиятында бөтен кыйммәте шуннан гыйбарәт. Аңа шуннан башка кыска бер тәгъриф[1] тә юк.

**Зариф Бәшири.** Татар романтизм лирикасыннан Зариф Бәшири лирикаларын да санарга кирәк. 1905 ел революциясе дулкыннары арасында күтәрелгән романтик-лирик шагыйрьнең берсе шул иде. Ул әүвәл «Казан мөхбире», «Әхбар» һәм «Йолдыз»да язды. Бу шигырьләре соңыннан «Милләт кайгысы» исеме белән басылып чыктылар. 1908–[190]9 елларда – «Тутый тавышы», «Язгы кояш», «Ядкәр», «Иртәнге азан», «Юаткыч»лары, 1910 «Яз тамчылары», «Хиссият баскычлары» басылдылар. Бу шагыйрьнең лирикалары, аның Октябрь революциясенәчә язылып басылган шигырьләре шул ук романтизм чишмәсеннән агалар иде. Ул башта ук хис, мәхәббәт көйләде. Бу шагыйрьдә башта ук хис, мәхәббәт чаткылары куәтле генә күренделәр, аның «Сакла гыйффәтеңне» шигырьләре белән «Барлык хәятның сафасы» кебек шигырьләре шуны күрсәттеләр. Ул «хиссият баскычлары» белән үрләүче бер шагыйрь иде. Шулай ук бу шагыйрьнең дә әүвәлге шигырьләре милли хисләр белән сугарылдылар.

Бу шагыйрь Октябрь үзгәрешеннән соң дүртьеллык бер мөддәт эчендә бераз тукталып тору (фитрәт) дәвере кичерде. Шуннан соң ул тагын кузгалды, инде аның шигырьләре әүвәлгедән куәтлерәк, ләкин һаман романтизм рухында күренделәр. Бу соңгы шигырьләрендә аның хыял канаты тагын киңәя төшкән, матурлык, нәфасәт баскычларына омтыла башлаган күренде. Аның «Тау кызы», «Ак фәрештәм сау булганда», «Рәнҗетмә, илкәем» дигән шигырьләре әнә шуны

[1] Тәгъриф – аңлатма.

күрсәттеләр. Аның «Көзге җилләр хәбәре», «Танышуга теләү хаты» дигән шигырьләре дә шуларга кушымта булалар.

Ләкин З. Бәширинең Октябрь революциясеннән өч ел үткәч язган «Тау букетлары» дигән шигырь мәҗмугасындагы шигырьләреннән байтагы чыннан революция, көрәш рухындалар. Моны күргәч, миллият дәверендә җитешкән, милли рухта көйли башлаган бер шагыйрьнең йөрәгенә революция һәм көрәш уты, социализм ялкыны тиз генә кабынып алуын һәм шагыйрьне үзенең көчле тәэсире астында калдыруын аңлыйсың.

[19]22 елдан соң Үзбәкстан матбугатында Октябрь рухы белән бик ялкынлап эшләп киткән һәм каләмен гәзитчелек юлында эшче-крестьяннар (диһканнар) файдасына зур эшчәнлек күрсәтү сызыгына борган бу шагыйрь инде лирикаларында да:

Чишелде кул, чыктым сезгә сәлам белән,
Котлыйм сезне ирек, кызыл әләм белән.
Ерткычларны сез көч белән изгән чакта,
Чәнчермен мин дә үткен каләм белән.

Мактамыйм мин бай кызының күркен хәзер,
Котлап җырлыйм юксылларның иркен хәзер;
Иркә кызның калфагыннан артык күрәм
Фәтхулланың иске ертык бүркен хәзер[1], –

дип, ачыктан-ачык юксылларны мактап җырлый башлады. Гәрчә әле басылмаган булса да, [19]21–[19]22 елларда Ташкентта шау-шу күтәргән «Ул хәнҗәр минеке»се белән бу шагыйрь каләменең үсеп шомарып, матурланып җиткәнен дә күрсәткән иде.

Зариф Бәшири Мәҗит Гафури, Тукай шикелле баштагы шигырьләрендә үк ярлыларга якын торып язучы шагыйрьләрдән булды. Октябрьдән соң инде ул, Октябрь тәэсире белән, үзенең тиешле сызыгына тәмам борылган күренде.

Бу шагыйрьнең шагыйрь булып танылуы лирикасы аркылы булса да, ул шулар өстенә хикәяләр дә язды. Аның «Чуваш кызы», «Картада отылган кыз», «Исламчылыкта» дигән хикәяләре шулар җөмләсеннәндер. Шуның өстенә ул «Чувашлар» турында «Шура»да язган мәкаләләре белән тарих һәм этнография өчен кирәкле тикшерүләр – мәгълүматлар да бирде (бөтен шушы югарыдагы хезмәтләре өчен Үзбәкстан җөмһүрияте аның егерме еллык юбилеен ясап үткәрде, татар матбугаты да моңар катнашты).

[1] Зариф Бәширинең «Яшәсен ярлы-ябагайлар!» (1922) шигыреннән.

**Нәҗип Думави.** Татар тәнкыйть дөньясында үз вакытында да, соңыннан да үзе турында ачык билгеле бер караш әйтелмәгән һәм тавышсыз басылыбрак калган чын идеалист романтик лирик шагыйрь Думави булды. Моның бөтен шигырьләре динлелек, «илаһи»лык белән сугарылган булуга карамастан, көчле бер лиризм җимешләре иде. Аның 1909 елда басылган «Дөньяга ачык хат» дигән шигыре үзе генә дә Думавиның шагыйрьлеген күрсәтер өчен җитә. Инде аның «Аң»дагы башка шигырьләрен, поэмаларын да шуңа кушсак, фикер, хис һәм хыялның һәрберсеннән тигез өлеш алган хәлдә, ул мөтәфәккир[1] бер шагыйрь булып күренә. Тукай, Дәрдмәнд, Сәгыйть Рәмиләрдән кала, бу дәвернең көчле шагыйренең берсе шул иде. Аның шигырьләрендә «рухи кол»чылык, «вәхдәте вөҗүт» фәлсәфәсе дә нык аңкый.

1905 ел революциясе тәэсире астында «әл-Гаср әл-җәдит»тә язган шигырендә капиталга дошманлык тойгысы белән чыккан бу шагыйрь соңыннан тәмам боекты, өметсезләнде. Ахырда ул шул ук, югарыда әйтелгән «Дөньяга ачык хат» дигән шигырендә дөньядан тәмам бизгәнлеген күрсәтте. Ул анда:

> Тавың булса, тавында мәңге бетмәслек шавың бардыр,
> Җәһәннәмнән кызу кайнар эреп чыккан лавың бардыр.
> Кирәкмәс, бармыймын инде кырыңа да, беләм инде:
> Кырыңда хәл кылынмаслык тирән, төпсез давың бардыр! –

дип, бөтен дөньяга кул селтәде. Аның башка шигырьләре дә шул юлда дәвам итеп, ахырда ул тәмам «вәхдәте вөҗүт»че булып китте.

Думави матур тасвирлы, ачык һәм аһәңле язучы шагыйрьләрдән. Ул фикер шагыйре булу ягыннан Дәрдмәндкә якын торса, өслүбтә Тукайга якын.

**Укмасый.** Тукайлар, Зариф Бәшири һәм Думавилар белән бер заманда күтәрелеп тә, башта ук нәгыз татарча яза башлаучы бу шагыйрьдә аерым бер хосусият – аның лирикалары күбрәк табигатьне, табигать күренешләрен тасвир белән бәйләнгән булуыдыр. Аның түбәндәге «Кояш чыкканда» шигыре – шуның ачык мисалы:

> Төрле якта кошлар чурлый, һава томан,
> Нур тарала юаш кына, күренә урман;
> Алтын тавы артыннан кояш көлә,
> Ярты карап уйный безгә, үзе поскан.

[1] Мөтәфәккир – фикер иясе.

Болытлар ахакланган алтын катнаш,
Чирәмнәрнең күзе яшьле нур аралаш;
Бәхетле таң, яңа таңны котлау өчен,
Урман эчен шыңгырдата бер сандугач.
Таң чишмәсе чыр-чыр күздән яшен коя,
Йолдызлар җылтыр-җылтыр нурын җуя;
Тау буйлары, итәкләре исәнләште,
Агачлар бер-берсенә башын ия.
Су өсләре елмаешып парланалар,
Балыкчылар ашыгып-ашыгып ау салалар;
Һәрбер нәрсә, мәгънәви бер тел белән,
Үтеп киткән кара төннән зарланалар.
Балыклар, уйнап, суда боҗра ясый,
Инде чумды су төбенә Су анасы;
Һәрбер җан арлы-бирле кәсеп башлап,
Кортлар да эшкә китте – балын ташый.
Күбәләкләр кинәнәләр, чәчәк кочып,
Карлыгачлар уйнашалар тиз-тиз очып;
Таң вакыты ләтафәтен чәчеп үтте,
Көлеп чыкты кояш безгә, исәнләшеп.

Телгә, тасвирга матурлык кертүдә аның шигырьләренең дә күп хезмәте, тәэсире булды. Мәктәпләрдә, уку китапларында аның шигырьләре әһәмиятле урын алдылар.

**Зыя Ярмәки.** Үзен «Тукайның иркәсе» дип атаган бу шагыйрьнең:

Кер вә таплардан агардым мин хәзер кош кеби,
Ялтырарга уйлыймын күктә матур йолдыз кеби;
Күп авырлыкларга, әнкәй, түзде бәбкәң җилкәсе,
Шул ачы яшьләр, әни, итте Тукайның иркәсе[1], –

дигән сүзе үзе турында дөрес бер сүз дияргә ярый. Тел-өслүбтә ул, чынлап та, Тукай иркәсе иде. Шигырьләрен караганда, бу шагыйрь, әлбәттә, татарның шигырь кояшы яисә ае түгел. Ул – татар шигырь дөньясының бер почмагында матур гына ялтырап, җемелдәп торучы кечкенә бер йолдыз.

Бу шагыйрь һәрнәрсәдән бигрәк табигатьне һәм табигать күренешләрен тасвирда яхшы ук бер көч күрсәтә. Моның лирикаларында, гомумән, нечкәлек һәм эчтән астыртын сиздертеп яндырта торган мәрхәмәтле бер ялкын бар. Аның шигырьләре укучыны яндырырлык, көйдерерлек яисә аны шаштырырлык бер рәвештә тү-

[1] Зыя Ярмәкинең «Әнкәемә» (1912) шигыреннән.

гел. Ул укучы йөрәгендә уртача, йомшак бер хәрәкәт тудыра; эчке һәм басынкы бер кузгалыш, шундый бер зәвык уята.

Зыя Ярмәки – Укмасый белән бер үлчәүдә, бер рухтарак булган бер шагыйрь. Бу шагыйрьнең дә башка шагыйрьләрдән аерымлыгы – Укмасый шикелле үк, табигатьне, табигый күренешләрне тасвирындадыр.

**Сәгыйть Сүнчәләй.** Бу шагыйрь үзенең лирикаларында башта ук эшче-юксыллар көен көйләп чыкты. Ярлылар моңын җырлау белән башлады. Ләкин анда хыял куәте йомшак, фикер көче зәгыйфьрәк, йөрәк уты ялкынсызрак булып чыкты. Ул сүз төзүгә, кафиягә оста, ләкин болар аркылы сыеграк, самимиятсезрәк мәгънәләр бирелде. Шушы яклары белән бу шагыйрь татар тәнкыйть дөньясында үз вакытында, үзенең шигырьләр мәҗмугасы басылып чыккач, Ф. Сәйфи кебекләрнең каләмнәре аркылы каты тәнкыйтьләргә дә очрамыйча кала алмады.

Шуларның һичберсенә карамастан, бу шагыйрь, Октябрьгәчә өзлексез язып килгән шикелле, аннан соң да язуында дәвам итте. Революцияне яратып каршы алучылардан һәм шул юлда эшләүчеләрдән булды.

**Әхнәф Тангатар.** Шул ук романтизм һәм өметсезлек юлында чәчмә өслүб белән лирика язучылыкта күзгә ачык ташланырлык бер осталык күрсәтүче әдип Әхнәф Тангатар булды. Дәрдмәнд, Сәгыйтьләр шикелле үк, массага аз таныш булган бу шагыйрьнең язганнары тәмам романтизм рухында, чәчмәдәге лирик шигырьләр өчен иң яхшы үрнәк булырлык бер хасият күрсәтәләр. Анда кайнар һәм бик кискен бер тойгы, үткен, киң бер хыял бар. Бәлки ул – тилергән хыяллы бер шагыйрь. Шагыйрьләребез эчендә хыялы киң канатлы шагыйрьләребезнең алдынгыларыннан берсе – шөбһәсез, Әхнәфтер. Тел-өслүбе дә чын мәгънәсе белән татарча, чын татар теле нигезендә, шуның белән бергә ул үткен, кискен һәм ялкынлы тәгъбирләргә дә бай, аның сүзләре, тәгъбирләре йөрәкнең иң төпке, тирән бер ноктасына барып тукынырлык бер көч күрсәтәләр. Аһәң-уйгынлык кебек шартлар да аның өслүбендә тәмам җиренә җиткерелгән була.

Бу шагыйрь чәчмәдә тойгы (хиссият) ташкынлыгын ихтыярсыз үзенә тартучы бер өслүб белән тасвир итүдә бөтенләй үзенә аерым бер урын тота. Аның һәрбер шигъри әсәрендә бер яңалык, үзенә аерым бер көчле зәвык була. Өслүбенең чәчмәдә сәнгатьчә эшләнүендә аны тезмәдә артык бер сәнгатьчәнлек күрсәтүче Дәрдмәндкә

бәрабәр куеп була. Ләкин теге Шәрык ысулында, Шәрык аһәңендә булса, бу – татар рухында, татар аһәңендә.

Әхнәф күп язмады. Ул әүвәл «Шура»да язды. Октябрьдән соң хикәяләре гәзитләрдә күренде. «Ходаяр хан бакчасындагы хыялым», «Кыз еглату», «Ни ул?», «Тауларга караганда», «Анама» дигән чәчмә шигырьләре үзе турында югарыда сөйләгәннәрне тәмам раслыйлар. Болар татар сүз сәнгате дөньясында Әхнәфкә зур урын бирдертәләр.

«Ходаяр хан бакчасындагы хыялым» сәрләүхәсе белән язылган шигырендәге тасвирның гүзәллеге, сылулыгы аеруча дикъкатьне үзенә тартырлык. Мондагы тасвирлар шагыйрьдә хыял вә тасвир куәте ни дәрәҗәдә көчле һәм кискен булганын йомык күзләргә дә ачык күрсәтә алачаклар. Монда тик үзенең гөнаһ шомлыгыннан бәла һәм һәлакәткә төшкән бер кешенең башкалардан һәм дә бер дә гөнаһсыз булган кешеләрдән, барлык гөнаһсыз нәрсәләрдән үч алырга җилкенүе, үч алуы кебек кешедәге иң куркыныч бер рухи халәт шушы тасвирда аяклы гәүдәсе белән тәмам күз алдыбызга китерелеп бастырыла.

Без бу шагыйрьгә югарыдагы бәһане сәнгатьчә карап бирдек. Иҗтимагый яктан, идеология сызыгыннан караганда, шушы югарыдагы әсәрләре белән ул – шөбһәсез, барып торган бер идеалист, милләтче. Ләкин соң дәрәҗәдә пессимист бер шагыйрь иде.

**Ибраһим Башмаков.** Шигъри таланты ачыла башлап, үзенең шагыйрьлеген күрсәткәч кенә, бик яшь көе чахотка белән үлүгә мәхкүм булучы бу шагыйрь баш-аягы, эче-тышы белән пессимизмга чолганган көчле бер лирик иде. Аның «Аң»дагы шигырьләреннән башка, «Бикмирза» имзасы белән «Шура»да басылган «Уйланам» дигән шигыре, чыннан да, чиксез авырлыклар, интегүләр белән өзгәләнгән, парчаланган өметсез бер йөрәктән чәчрәгән кискен бер шигъри чаткылар иде. Халык вәзененнән «Зиләйлүк» вәзенендә язучы бу пессимист шагыйрьдә дә көчле, үткен тәгъбирләр, оста, кискен охшатулар күрәбез. «Аңарда, чыннан да, шагыйрьлек тамыры бар. Ләкин баягы сүз, каһәрле татар сазында аның назлы сандугачлары тиз тавышларын югалталар. Ибраһим әфәнде исә – сайрый башламас борын тавышын, тавышын гына түгел, үзен дә югалткannardan, әрәм булган талантлардан бередер»[1].

Ибраһим Башмаков Пенза губернасы Инсар өязе Үрләдем авылының имамы Йосыф мулла улы булып, берничә ел «Галия»-дә укып чыга. Соңыннан Оренбургка килеп, «Вакыт»та эшли,

[1] «Аң», 1нче сан, 1914 ел. Г. Ибраһимов мәкаләсе. *(Авт. иск.)*

«Шура»да языша башлый. Ниһаять, чахотка белән 1913 ел октябрь 9 ында 19–20 яшьләрендә шул ук Оренбургта вафат була.

**Вакыйф Җәлал.** Бу шагыйрьнең дә шагыйрьлеге бик түбән баскычтан башланды: тик коры тезмәчелектән, назыймлыктан башланып китте.

Мәсәлән, ул, әле шигырь вә әдәбият мәйданында байтак чабышканнан соң, 1911 елда «Дилбәремә» дип түбәндәге шигырен язды:

Әй, мәхәббәт гончәсе[1], тәхсин[2] сиңа, мең афәрин!
Нинди рәхмәт ихсан иткән[3] сиңа Раббил галәмин!
Күзең ал, бак, нинди мөлкәт берлә тулган ай йөзең!
Әйлидер гарзе мәхәббәт, чәһрәи руи зәмин.
Нindidер фәйзе илаһи[4] каплаган рухың тәмам!
Һәммәсен күр, көнләшерләр дөхтәран[5] әсхабе дин[6].

Менә бу шигыре Вакыйф Җәлалның шигърият дөньясында артык түбән баскычтан башлаганын безгә ачык күрсәтеп тора. Аның 1908 һәм [190]9 елларда язган шигырьләре дә шушы рухта булып, аны ул чаклардагы әсәрләре шагыйрь түгел, бәлки дини бер назыйм итеп кенә танышталар.

Әмма бу шагыйрь соңыннан, хосусан инкыйлабтан соң, кинәт ачылып, куәтләнеп китеп, «“Кызыл Шәрык”ка» («Кызыл Шәрык» журналында, 2 нче санында басылды) дигән шигырен һәм «Вакыйф Җәлал шигырьләре» дигән әсәрен мәйданга китерде ки, инде боларда бер назыйм Вакыйфны түгел, бәлки яхшы ук куәтле шагыйрь булып әверелгән Вакыйф Җәлалны күрәбез. Бу шигырьләре аңа татар шагыйрьләре сафыннан бер урынны аерып куйдыртуга хак казандыра. Аның шигырьләрендәге сүз вә тәгъбирләр, бара торгач, үткенләнеп, кискенләнеп китте. Шуның өстенә ул вәзен вә кафиягә бик оста, өслүбе аһәңле, тасвир куәтле. Хикмәт вә фәлсәфә белән сугарылмаган шигырьләре моның аз булыр. Аның каләме хикмәтләндерелүне ярата. Бу шагыйрь ачлык фаҗигалары вакытында 1922 елда Ташкентта кызганыч рәвештә вафат итте.

[1] Гончәсе – бөресе.
[2] Тәхсин – мактау.
[3] Ихсан иткән – бүләк иткән.
[4] Фәйзе илаһи – илаһи нур.
[5] Дөхтәран – кыздан.
[6] Әсхабе дин – дин әһелләре.

***Тормышны сурәтләндерүче иҗатлар һәм шуларны тудыручы әдипләр***

Тормышны сурәтләндерүче иҗатлар бездә XIX йөзнең соңгы ярымы эчендә яхшы ук үсә башлаганын без югарыда күреп үткән идек. Ул иҗатлар һәммәсе буржуазия рухында булып, мәүзугы, мөндәриҗәсе, теле, өслүбе һәм бөтен рухлары белән шул сыйныфның кыйбласына караган иделәр. 1905 елдан соң алар тагын да киңәеп, нык тамырланып, кызу үсеп киттеләр. Галиәсгар Камал, Фатих Кәрими, Гаяз Исхакый, Ярулла Вәли кебек әүвәлге әдипләр янына татар буржуазиясенең Фатих Әмирхан кебек көчле яшь талантлары килеп кушылып, матур әдәбиятның бу төре чын мәгънәсе белән буржуазия ноктасына каратылды. Матур әдәбиятны бөтенләй шул ноктага борырга, шул рух белән сугарырга, сугартырга тырыштылар. Күп лирик шагыйрьләребез шул сыйныфның, шундый буржуа агымының көчле тәэсиреннән котыла алмаган кебек, күп кенә яшь беллетристларыбыз да аларның тәэсиренә каршы тора алуда үзләрен көчсез сизделәр. Хәтта Галимҗан Ибраһимов, Фатих Сәйфи, Шәриф Камал кебекләр дә (гәрчә буржуазия белән килешә алмыйча, аларга каршы сызыктарак торып, буржуазиягә оппозиция ясап барырга тырышсалар да) шул тәэсиргә җиңелеп калалар иде.

**Гафур Коләхмәтов һәм татар пролетариат әдәбиятына беренче адым.** 1905 ел революциясе татарны буржуазия һәм пролетариат сыйныфына нык аерган һәм шул фактны ачык күрсәткән шикелле, аның әдәбиятын да ике тармакка аеру юлын ачты. Аңарчы, югарыда әйткәнебезчә, татарда буржуа рухында, шуның кәгъбәсенә караган әдәбият туып, үсеп килсә һәм 1905 ел, бер яктан, шундый иҗатларга юлны тагын да киңәйткән булса, икенче яктан, пролетариат әдәбиятына таба яисә шуны тудыру ноктасына юнәлергә теләгән адымнарга да хәрәкәт бирде. Ниһаять, бу юлда татар дөньясында башлап беренче адым атланды яисә татар пролетариат әдәбиятының беренче башлангыч орлыгы утыртылды.

Моны да без татарлар арасында большевиклар партиясе фикерләрен, марксизм идеологиясен таратуда Ямашев, [Галимҗан] Сәйфетдинов, Моратов вә иптәшләренең беренче ярдәмчесе булган беренче революционер драматург, әдип Гафур Коләхмәтов каләме аркылы күрдек. Аның өч пәрдәлек «Ике фикер»е белән «Яшь гомер» дигән биш пәрдәлек драмасы шуның татар матур әдәбиятында беренче башлангыч адымы булды.

1905 ел революциясе татарны пролетариат һәм буржуа сыйныфына нык аерып ташлаганын югарыда күреп үткән идек. Әнә шуның беренче үткен башлангыч әдәби чаткылары татар драма әдәбиятында килеп чыкты. Бу әдәби хәрәкәт татар эшчеләренең, татар пролетариат сыйныфының драма әдәбиятын һәм сәхнәне үз ягына, үз идеологиясе ноктасына таба әйләндерергә теләвенең, шуны таләбенең беренче нәтиҗәсе иде. Яисә бу – татар буржуа әдәбияты, буржуа сәнгатенә каршы татар пролетариат әдәбияты, пролетариат сыйныфының әдәби фронты ачылу дигән сүз иде.

Шулай итеп, бу әсәрләр аркылы татар социалист зыялылары, татар большевик эшчеләре тарафыннан матур әдәбиятта һәм дә сәхнә әдәбиятында пролетариат сыйныфының үз таләпләре кузгатылган; шулай ук буржуа сыйныфының һәвәс, зәвыкларына каршы пролетариат сыйныфының һәвәсләре, аның зәвыклары аяк баскан булды.

Гафур Коләхмәтов үзенең әлеге «Яшь гомер» драмасы белән «Татар социалист зыялыларын, татар эшчеләрен, аларның партия әгъзаларын татар драмасының баш каһарманнары итеп алуның беренче юлын ачты»[1]. Бу әсәрдәге Гали, Вәли, Йосыф дигән каһарманнар – ул вакытта татар драма әдәбиятында чыннан да беренче мәртәбә күренгән каһарманнар иде.

Әсәрнең каһарманнарыннан дөньяны күп күрүче, укымаган, ләкин үзенең эшче булуы, байлар һәм самодержавие кулында изелүе белән генә сыйнфый мәнфәгатен ачык аңлый алучы Йосыфның: «Менә бу агачларда да минем хакым бар. Бу җирдә дә минем хакым бар. Бөтен дөнья малында да минем хакым бар. Хакым күп җирдә бар. Әмма акчам юк. Бу ник болай икән?

Шулкадәр беләләр, шулкадәр кара халыкны алдыйлар, һич тә сизәрлек түгел! Менә безнең татар байлары Мәкәрҗәдә җыелган булдылар да «Мөселман иттифакы» партиясе оештырган булдылар. Үзләренә күрә комитет та сайлап куйдылар. Комитетка кемнәр керде?.. Һәрбер член комитет кушканча эшләсен, имеш! Мәсәлән, Думага сайлау турысында әйтик: комитет тотар да менә шуны, шуны, шуны сайлагыз, дияр, ягъни байларны сайлагыз, дип әйтер. Член булдың исә, сайламый хәлең юк шул. Юк, башка кешеләрне алдасагыз да, без эшчеләрне алдый алмассыз!..»; «Алар пычакка пычак килә торган ике сыйныфны бергә катыштырмакчы булалар. Катыштырмый торыгыз әле...» – дигән сүзләре һәм алган юлында нык торучы эшче социалист

[1] «Татар театры» мәҗмугасы, 35 бит. Сәгъди мәкаләсе. *(Авт. иск.)*

Вәлинең дә: «Гали эчемне пошыра башлады... И, интеллигентлар, интеллигентлар!.. Шушы интеллигентларга карап гаҗәпкә калам. Гаҗәпкә калмый хәлең дә юк шул. Менә еракка бармыйча, Галигә генә карыйк. Ул йөз утыз миллион Русия кешеләре, шакшы җан ияләре кебек, былчыракта коенып торган вакытта, халыкка хезмәт итәм дип, Зөләйханы коткара, имеш! Бу Зөләйха артыннан йөри-йөри, никадәр вакыты әрәм үтте, никадәр эше калды. Кирәкле кәгазьләр вакытында язылмаган, кирәкле урыннарга вакытында барылмаган. Кирәкле урыннарга вакытында бара алмауга сәбәпче ни? Зөләйха! Шушы интеллигентларны, күтләренә тибеп, партиядән куалап чыгарасы иде – ярамый! Аларның фикерләре эшче фикерләреннән җиңел булса да, эшчеләргә юл күрсәтеп торуы һәм эшчеләрнең фикерләрен ачулары кирәк шул...» – дигән сүзләре мөхәрриренең алган каһарманнары нинди типтагы кешеләр икәнен безгә ачып салалар. Шуларга аларның эшләрен, башкалар белән булган мөгамәләләрен дә кушарга кирәк[1].

Коләхмәтовның «Ике фикер»е – «Яшь гомер»еннән элек язылган, ләкин Октябрьгәчә басыла да, күп уйнала да алмыйча калган бер әсәре булып, ярым символизм юлында гаять оста, матур фәлсәфи бер тел белән язылган бер пьеса[2]. Әсәр, чынлап та, пролетариат революциясе һәм каты сыйнфый көрәш рухында язылып, марксизм идеологиясен матур бер әдәби, фәлсәфи калыпка салып биргән. Кыскасы, аның беренче иҗаты булган шушы пьесасы – Октябрьгәчә булган татар матур әдәбиятында чын революция рухында, марксизм-большевизм нигезендә һәм баштанаяк шул идеология белән сугарылып язылган, шулай ук чынлап та әдәби кыйммәткә ия була алган әсәрләрнең беренчесе, төп маясыдыр. Мәүзуг, мөндәриҗә ягыннан да, каһарманнары ягыннан да, сәнгатьчә эшләнүе белән дә бу шулай.

Кара фикер белән Кызыл фикер (самодержавие белән марксизм – большевиклык идеологиясе) арасында калып, каты бер көрәш, рухи бер тартыш тудырып, ахырда Кызыл фикерне үзенә юлбашчы итеп «Алга!» юнәлгән Давыт – монда баш каһарман. Бу тип – чын марксист революционер тибы. Аны сөюче Галия дә – шушы ык идеаллы беренче татар марксист революционерын аңлап, аның

[1] «Татар театры» мәҗмугасы, 35–36 бит. Мөхәррир мәкаләсе. *(Авт. иск.)*

[2] 1925 елда СССР Халыкларының Үзәк нәшрияты тарафыннан басылган «Гафур Коләхмәтов мәҗмугасы»нда Агиев тарафыннан: «Гафурның өслүб һәм телендә булган кайбер авырлыкларын төзәтү минем тарафымнан булды», – дисә дә (бу эш белән ул тарихка бик зур бер гөнаһ эшләде), асылыннан, үзенең хосусиятләреннән, һәрхәлдә, чыгарылмагандыр дип уйлана. *(Авт. иск.)*

юлына төшеп, аның белән бергә Кызыл фикер артыннан «Алга!» омтылучы акыллы бер татар хатыны[1].

Бу әсәрнең баш каһарманы Давыт авызыннан түбәндәге фикерләр сөйләтелә: «Адәм нихәтле нык табигатьле булса да, нихәтле аның гыйлеме зур, фикере киң булса да, тарихны тудыра алмый; бәлки адәмне үзен тарих тудыра. Нәрсә ул тарих? Тарих – гавамның ничә мең еллар эчендә килә торган сыйныфлар көрәшенең тезмәсе; тарих – сыйныфлар көрәшенең көзгесе. Ялгыз кеше дөньяда бу көрәштә берни дә итә алмый. Адәм тик гавам эчендә генә яши ала. Тик шул көрәштә генә үзенә ләззәт таба ала. Кешеләрнең бер төркеме дөньяда булган барлык байлыкны үз кулларына кертергә тырышалар; гавамны, маңгай тире, үз кул көче белән яши торган гавамны үзенә кол итәргә, богауда тотарга тырыша... Ә гавам, шул коллыкка эләкмәс өчен, эләккәч, азат булыр өчен көрәшә, кулына салынган богауларны өзеп ташларга тели».

«Көлешәләр... Шатланышалар... Уйнашалар... Димәк, аларга күңелле... Әнә теге – йөзләре ябык, күзләре сүнгән, куллары богаулы гавам нигә көлми? Ул ник ыңгыраша?!. Маңгаеннан тир агыза, үзе ут газабы эчендә яши... ә алдында тик... өмете генә бар... Бу уенкөлке арасында түгел, әнә шул гавам арасында яшисе, аның белән бергә газап чигәсе, аның белән бергә үләсе килә...»

«Менә шуңа пьесадагы Кызыл фикердән сөйләтелгән тирән хикмәтле, корыч сүзләрне дә китереп кушсагыз, мәсьәлә бөтене белән үз-үзеннән ачылыр. Әдипнең Давыты белән бергә Кызыл фикере бишенче ел белән Октябрь революциясе арасында татар драма әдәбиятында утыртылып калган беренче тарихи кызыл маяклар икәне дә үзеннән-үзе ачык күрелер»[2].

Әсәрдәге Давыт тибының үзенең кай сыйныфтан булуы һәм нинди тәрбия күргән бер кеше икәне гәрчә томанлы калса да, бу яктан әсәр бу типны тулы күрсәтә алмаса да, әсәр, моңа карап, үзенең әдәби-иҗтимагый кыйммәтен киметми.

«Яшь гомер»ендә исә, Йосыф, чынлап та, сәнгатьчә реаль бер юлда эшләнгән эшче тибы булып чыккан. Аның бөтен итенешкыланышы, эше-сүзе, фикере һәм хәрәкәте – һәммәсе шушы Йосыф табигатенә килешә дә тора. Вәли белән Гали типлары да шул заманның татар социалистларының байтак сызыкларын эләктергәннәр.

[1] «Татар театры» мәҗмугасы, 37 бит. Мөхәррир мәкаләсе. *(Авт. иск.)*
[2] «Татар театры» мәҗмугасы, 36 бит. *(Авт. иск.)*

**Фатих Әмирхан.** Фатих Әмирхан 1905 елның тәэсире эчендә күтәрелгән вак буржуазия социализмыннан башлап, реакция астында бөтен мәгънәсе белән яңа татар буржуазиясенең «хакыйкый яурупеист булу» лозунгысы астында аның сыйнфый аңлы мөхәррире булып җитешкән татар әдипләренең берсе булды.

1907 елда басылган «Гарәфә көн төшемдә» дигән хикәясендә сурәтләндерелгән хыялый, 1908 елда «Яшьләр колагына» дип язган иҗтимагый мәкаләсендә «хакыйкый яурупеист булу» шигаре белән ачык вә гаять җитди рәвештә татар яшьләре, шулай ук татар буржуазиясе өчен бер идеал итеп куелган иде. Һәм шул ук 1908 елда «Гыйбадәт» дигән кыска бер лирикасы белән дә шул идеалның лязем бер ноктасына ишарә бирелгән булды.

Ф. Әмирханның соңгы бөтен әдәби әсәрләрендә (һәм иҗтимагый мәкаләләрендә) әнә шушы идеалы төрле картиналар, типлар аркылы һаман киңәйтелә, шулай ук аңар ирешү юллары, аның вакыйгый бер нәрсә булачагы да төрле шигъри сурәтләрдә күрсәтелә бара. Февраль революциясеннән соң бу идеал да «Богаулар өзеләләр» дигән мәкалә («Аң», 1917 ел, 3–4 нче сан) аркылы соңгы ачык шәкелен бирде[1]. 1922 елда «Ярдәм мәҗмугасы»ның икенче китабындагы «Тәгъзия»дә шуның иң соңгы тәмамлану ноктасын күрсәтте.

Бу идеал, әлбәттә, Ф. Әмирханның үзенеке генә түгел, ягъни аны әдип үз миеннән генә уйлап чыгарган бер нәрсә түгел иде, бәлки ул тик шуның вәкиле, шуны әйтеп бирүче генә иде. Әдипләр, шагыйрьләр бит алар үзләре мәгълүм бер икътисади, иҗтимагый шартлар астындагы мәгълүм бер җәмәгать тормышының җимешләре булалар. Шуның белән бергә алар – шул җәмәгатьнең психологиясен, идеологиясен мәгълүм бер идеология рәвешендә калыпка салучы, шуларны шигъри сурәтләрдә гәүдәләндерүче, шуңа ачык, катгый бер систем бирүчеләрдер. Ф. Әмирхан да татар буржуа җәмәгатенең шундый көчле бер вәкиле иде. Югарыдагы идеалны да аның миенә, йөрәгенә татар буржуа хәрәкәте, шуның икътисади барышы, иҗтимагый-мәдәни юнәлеше салган, яшь татар буржуасы, буржуа яшьләре мохите аны шуңар хәзерләгән иде.

[1] Бу мәкаләсендә ул гаять куәтле дини рух белән, «насыйп итсә», «Аллаһның гыйнаяте белән» кебек дини, илаһи шатлыклы тәгъбирләр белән революция булуга куанып яза. «Милли иманлы кешеләр» булуга өндәп: «Булырга!», «Милләт сәҗдәи шөкер итсен!» кебек дәртләр белән яза. «Милли кяферләр» булмаска, дип чакыра. Хасил, бу мәкалә бөтене белән, «Русия мөселманнары» булып, хөррият хәрәкәтендә нык эшчәнлек күрсәтергә өнди. *(Авт. иск.)*

Ф. Әмирхан әнә шушы мохит һәм шушы хәрәкәтнең омтылыш, теләкләрен күрсәтүчеләрдән булып барды. Талантлы, көчле бу әдип үзенең әсәрләрендә аларны шул идеология белән нык сугарды, тәрбияләде, ризыкландырды. Үсеп барган татар буржуазиясенең зыялы кыйсеме аның әсәрләрен идеология ягыннан, шулай ук аның тасвирындагы форма, тел-өслүб ягыннан да бик хаклы рәвештә яратып каршы алды.

Ф. Әмирханның югарыда әйтелеп үтелгән хикәяләре, «Яшьләр», «Тигезсезләр» дигән пьесалары, «Кадерле минутлар»ы, «Хәят»ы, «Урталыкта»сы вә башкалары татар буржуа җәмәгатенең идеологиясе ягыннан иң сөеп укыган әсәрләреннән булдылар. Бу әсәрләрдәге Газизләр, Йосыфлар, Рокыялар, Сөләйманнар, Гомәрләр, Закирлар, Сәлимәләр, Алялар, Хәятлар, Хөршитләр, Хәсән Арслановлар алар өчен зәвык бирәчәк, үрнәк булачак типлар иде.

Икенче яктан, Ф. Әмирхан иске тормышка, феодализм тормышына каршы бик усал, агулы тел белән ташланучы һөҗүви әсәрләр дә бирде. «Фәтхулла хәзрәт», «[Хәзрәт] үгетләргә килде»[1] («Аң», 1 нче сан, «Ташмөхәммәт» кушаматы белән), «Габделбасыйр гыйшкы» («Аң», шул ук ел, 11, 13, 14, 15 нче саннарда, 1914 ел), «Салихҗан карый» («Аң», шул ук ел, 11–12 нче саннар), «Сәмигулла абзый» («Аң», шул ук ел, 19–20 нче саннар) аның саташулы, киң, уйнак, шук хыялыннан туган шундый әсәрләреннән иделәр.

Ләкин шуны әйтергә кирәк: аның алган типлары һәммәсе диярлек «хакыйкый яурупеист булу» әмәленең лязем иткән типлары – буржуа яшьләре һәм дә бик килештереп, яурупача итенә, яурупача нечкәләнә, боргалана-сыргалана белә торган гимназист, гимназисткалар тормышыннан яисә шундый тормыш эчендә кайнаша торган буржуаланучы типлар алар. Фатих Әмирханның күп әсәрләре үзләренә шушы

[1] Бу хикәя соңыннан, [19]18 елда, «Көлке вә һөҗүви хикәяләре» исеме белән чыгарылган «Беренче мәҗмуга»сында тел, өслүб, тасвир ягыннан күп үзгәртелеп, төзәтелеп бастырылган, әдәби бер әсәрне болай үзгәртү, әлбәттә, тиешле түгел иде. Ләкин, аңа карамастан, бу эшләнгән. Шуның белән бергә, икенче яктан, бу хәл, Ф. Әмирханның әдәби вә тасвирый яктан 1918 елда да үзенең әүвәлге тасвирыннан, өслүбеннән канәгать түгел икәнен, бәлки, тәгъбир мөмкин булса, аның әдәби сәясәтсезлеген, әүвәлге өслүбенең кимчелекләрен тутырырга тырышканлыгын күрсәтә. Шөбһәсез, әдипләр туктаусыз үсәргә, өслүб вә тасвирда күтәрелә барырга мөмкин. Ләкин моны әүвәлге язганнарын төзәтеп бастыру юлы белән түгел, бәлки яңа әсәрләр язу юлы белән күрсәтергә кирәк иде. Гыйльми бер мәкалә яки фәнни бер әсәр һәр басылган саен төзәтелергә мөмкин, әдәби әсәрләргә, шигырьләргә бу турыда юл куелырга мөмкин түгел. Бу – әдәби ысул тарихын югалтырга тырышудан башка бер нәрсә түгел. *(Авт. иск.)*

тормышны мәүзуг итәләр. Чынында ул, әгәр әйтергә мөмкин булса, гимназист вә гимназисткалар әдибе, шуларның художнигы иде.

Ф. Әмирханның бер эшче тормышыннан да, авыл һәм крестьяннар тормышыннан да һичбер мәүзуг алып язганы юк. Аның хосусый тормыш картиналары да моңа имкян бирә торган бер юлда түгел иде. Шуның өчен ул бөтенләй шәһәрдәге югары катлау тормышының әдибе булды.

Кыскасы, Фатих Әмирхан, үзенең иҗтимагый, әдәби фикере үсүендә «хакыйкый яурупеист булу» идеалы белән башлап, ниһаять, тасаувыф, вәхдәте вөҗүд – пантеизм яисә, рус тәнкыйть дөньясында йөртелгән тәгъбир белән әйтсәк, Великий Пан[1] ноктасына килеп, шунда ныгып алып, ахыр гомерен янә шул ук ноктада тәмам итте.

«Сәҗдәи шөкер» аның соңгы идеологик һәм әдәби сулышы булды. Беренче әдәби әсәре булган «Гарәфә кич төшемдә» һәм аннан соң язылган «Гыйбадәт»е аның әдәби, иҗтимагый юнәлешенең үсә башлаган баш ноктасы вә «Яшьләр»е дә шуның сәхнәдә күренгән беренче картинасы булса, [19]22 елда язылган «Тәгъзия»се дә әдәби-фикри үсүенең тәмамланган, төенләнгән соңгы ноктасы һәм әдәби, фикри гомеренең дә хатимәсе булды[2] («Безнең юл», 1926 ел, 3 нче сан. Мөхәррир мәкаләсе).

Фатих Әмирхан каләме чын мәгънәсе белән либераль буржуа каләме иде. Бу каләм, бер яктан, чын буржуа сызыгында әдәби-шигъри җәүһәрләр бирсә, икенче яктан, ул шул ук рухта әдәби-иҗтимагый тәнкыйтьләр дә язды. 1905 ел революциясе белән татар матбугатында әдәби тәнкыйтьләр дә туган иде. 1907 елдан башлап бу каләм шуны яңа бер әсаста дәвам иттереп китүче булды. Ул «үткен, акыллы, җитез мөхакәмәле[3] бер тәнкыйтьче» иде. Шуның өстенә ул, гомумән, куркусыз, кискен, ачы телле, каты тәнкыйтьле бер адәм булды. Шулай да ул тәнкыйтьләрендә кайбер әдип вә шагыйрьләр турында үзен артык катыланудан да тыя алмаган шикелле, кайберәүләрне ефәк вә ягымлы тел беләнрәк тә уздыргалады. Бу хәл анда мәгълүм бер тенденция барлыкны да сиздертеп куя иде.

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[2] Аның «Тәгъзия»сендәге бу соңгы әдәби тавышы – шөбһәсез, романтик төрек әдибе Халид Зыяның «Мазардан сәсләр» (Г. Сәгъди тарафыннан бу әсәр 1910 елда «Кабердән тавышлар» исемендә татарчага тәрҗемә ителеп бастырылган иде) дигән хикәясендәге тавышларның татар буржуа әдәбиятында яңгырап алуы, ләкин сәнгатьчә бик зәгыйфь бер рәвештә эшләнеп чыкканы иде. *(Авт. иск.)*

[3] Мөхакәмәле – хөкемле.

Татар дөньясында мәйданга иң беренче чыккан татар драматургы Габдрахман Ильяси һәм аннан соңгы Ф. Халиди кебекләргә, ни өчендер, заманына карап, туры бер үлчәү бирергә дә теләмәде.

Шулай булуга карамастан, гомумән алганда, Ф. Әмирханның тәнкыйтьләре – заманында, шөбһәсез, әһәмиятле, бик вакытлы һәм файдалы тәнкыйтьләр иде. Ул – гомумән, тәнкыйтьче табигатьле бер әдип. Тәнкыйть карасына манып язмаса, аның каләме канәгатьләнә алмый. Аның әдәби тәнкыйть бабындагы кызу эшчәнлек заманы «әл-Ислах» дәверенә кайта. Бу гәзиттә аның 20 ләп тәнкыйте бар. Тәнкыйтьләре «Дамелла» кушаматы белән язылдылар.

Ф. Әмирхан каләме әдәби җәүһәрләр бирү, әдәби тәнкыйтьләр язу белән генә дә калмады. Ул – шулар өстенә, җәмәгатьче бер каләм. Татарның иҗтимагый-мәдәни хәрәкәтенең әһәмиятле бер өлеше булган шәкертләр кузгалышында, бигрәк тә «әл-Ислах» гәзите дәверендә зур эшчәнлек күрсәтүчеләрдән һәм шуның юлбашчыларыннан булган Фатих Әмирхан татар буржуазиясенең җәмәгатьчелек матбугатында, Фатих Кәримидән кала, иң игътибарлы, тәэсирле бер әдип иде. Бигрәк тә ул үзенең «әл-Ислах» дәверендә һәм шул гәзиттә язган мәкаләләре аркылы мөтәгассыйб картлар белән күзе ачыла башлаган буржуа яшьләрен капма-каршы куеп, шул вакыттагы яшьләр тарафыннан сугыш командасы биреп барды. Шуның өчен дә Ф. Әмирханның гомерендә һәм аның әдәби-иҗтимагый тарихында аның «әл-Ислах» дәвере – аеруча әһәмиятле бер дәвер. Ул соңыннан Кәримовларның «Кояш»ында эшләп, аңарга әһәмиятле тон биреп барса да, һәрхәлдә, аның «әл-Ислах» дәвере аннан өстен тора. «Әл-Ислах»та ул үзенең махсус мәкаләләре белән ачыктан-ачык «хакыйкый яурупеист булу» фикерен таратты: татар либераль буржуазиясе өчен шушы вакытлы, табигый бер шигарьне ташлады[1].

«Әл-Ислах» дәверендә Ф. Әмирхан каләме буржуазиянең сул-радикаль канаты сызыгыннан бара иде. «Кояш» дәверендә исә ул һәрьяктан уңлашты. Бу дәверендә ул иҗтимагый-мәдәни хәрәкәттә вак буржуа социализмыннан тәүбә итеп, тәмам гомуми татар буржуа либерализмы сызыгына, Акчуриннар һәм «Вакыт»лар юлына төшеп җитте. Бу да социализм эзендә барган вак буржуазиянең, реакция сәбәпле, эре буржуазия канаты астына сыенуының бер нәтиҗәсе иде.

[1] [19]12–[19]13 елларда Гаяз Исхакыйлар да шул шигарь билгеләгән сызык белән киттеләр. *(Авт. иск.)*

Кыскасы, «әл-Ислах»ның 1907 елдагы 4 нче санында басылган «Гарәфә көн төшемдә» дигән хикәясендә татарның дини гаетен мәдәни гаеткә алыштыру хыялының картиналарын биргән Ф. Әмирхан, соңыннан, шул ук ике гаетне «хакыйкый яурупеист» – буржуазия яурупеисты булу сызыгында берләштерү, ягъни татар гаетен дини-мәдәни гает итеп күрәсе килү юлына төште[1].

Шул рәвешчә, Фатих Әмирхан да, башка татар шәкертләренең, югарыда (вак буржуа төркемнәре турында сүз барганда) әйтелеп үтелгәнчә, берничә баскычлы иҗтимагый-әдәби хәрәкәтләрендә кызу эшләшеп барган хәлдә, шул баскычларның һәммәсен үтеп, ахырда, алар шикелле үк, өченче баскычта туктап, шунда ныгып алып, үлгәнче шул ноктада әдәби-иҗтимагый хезмәтен дәвам иттерде. Ул бу өченче баскычка «әл-Ислах» заманында ук төшкән иде. Шул юлда «әл-Ислах» гәзитенең башында торып, аңа шушы тонны ачык бирә барган иде. «Кояш»та инде бу баскычның тагын да ныгытылуы күренде.

1905 ел революциясеннән соңгы реакция Фатих Әмирханга да бик нык тәэсир итеп өлгерде. Сәяси яктан гайре мөгайян[2] бер суллык белән булса да, «әл-Ислах»ның 12 нче санына кадәр сәяси мәкаләләр язып килгән Ф. Әмирхан[3], шуннан соң, ягъни 1907 елның 24 декабреннән соң андый мәкаләләр язудан тукталды. Инде тик әдәби тәнкыйтьләр, хикәяләр язуга гына бирелде. Бәгъзе имзасыз мәкаләләр булса да, зәгыйфь чыгалар иде. Хасил реакция Ф. Әмирхан каләмен дә тәмам өркетте, богаулады. 20 нче сан «әл-Ислах»тагы «Казан. 23 февраль» дигән имзасыз баш мәкаләдә без инде реакция тәэсире астында тәмам бер өметсезлек чаткылары чәчрәгәнен күрәбез. Бу мәкалә бу юлда, чынлап та, бик характерлы тарихи бер мәкалә булып чыккан. Анда: «Бөтен Русиядә халыкның рухы күтәренке вакытта безнең дә рухларыбыз күтәрелде, халыкның рәсми табәкасындагы[4] бу рух төшкәч, бездә дә төште», – дип, үз-үзләрен моның өчен юатырга тырышу да күренә.

[1] Шул ук хикәясендә ул татарларны, яурупалыларның сөйләшкәне шикелле, «къ, гъ»ларсыз гына булып, колакка бертөрле йомшак вә кәефле ишетелеп тора торган бер рәвештә «дөрест сөйләшү»ләрен дә хыял итсә дә, соңыннан аның болай сөйләшүгә кызыгып язганнары да күренмәде. *(Авт. иск.)*

[2] Гайре мөгайян – ачык булмаган.

[3] Аның «әл-Ислах»тагы сәяси мәкаләләре шулар: «Думалар» (1 нче сан), «3 нче июнь кануны вә партияләре» (2–3 нче сан), «3 нче Дума» (4 нче сан), «Дума ачылды» (5 нче сан), «Думада центр» (6 нчы сан), «Дума» (9 нчы сан), «Сәясәт аләмендә» (11 нче сан), «Беренче Дума әгъзаларына хөкем» (12 нче сан). *(Авт. иск.)*

[4] Табәкасындагы – катлавындагы.

Ләкин, югарыда да әйткәнебезчә, «әл-Ислах» дәвере Ф. Әмирханның, чынлап та, нык җанланган, һәр якка ташланып эшләгән бер дәвере иде. Ул анда сәяси мәкаләләрдән башка тагын иҗтимагый, әдәби мәкаләләр дә язды: «Тел мәсьәләсенә бер караш» (24 нче сан), «Яшьләр колагына бер сүз» (29 нчы сан), «Әдәбиятка гаид» (44, 47 нче сан) дигән мәкаләләре шундый мәкаләләреннән булып, «Дамелла» кушаматы белән басылдылар. Бу соңгы мәкаләсендә ул кыскача татар әдәбияты тарихыннан мәгълүмат бирә. Монда күзгә ташланган бер ягы – аның К. Насыйрины тәкъдир итә белүеде.

Ф. Әмирхан «әл-Ислах»та байтак фельетоннар да язды. Бу фельетоннар да иҗтимагый рухта булып, һөҗүви булалар иде. Фельетоннарында кушаматы «Ташмөхәммәт» иде. «Әл-Ислах»та барысы тугыз фельетоны булды.

Ничек булганда да, Фатих Әмирхан һәр ягы белән татарның классик буржуа әдипләренең берсе булып, татар әдәбиятында зур урын тотты һәм татар әдәбиятының иң көчле бер гамиле булды.

**Галимҗан Ибраһимов.** Киң крестьян дөньясына, эш халкының көрәш һәм хезмәт вакыйгаларына, бигрәк тә яшьләрнең төрле хәрәкәтләренә якын торган әдипләрнең берсе Галимҗан Ибраһимов булды. Ул яңа фикерле шәкертнең иске тәрбия, схоластикага, иске мәдрәсәләргә каршы көрәшеп куылулары белән башлап, гаилә тартышлары, аталар белән балалар арасындагы көрәшләр эченнән барды да хезмәт халыкларының гомуми иҗтимагый азатлык юлындагы көрәшләре белән тәмам итте.

Беренче хикәясе булган «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» («әл-Ислах», 1907 ел) дигән әсәрендә әле яшь фикернең иске караңгы фикергә каршы көрәшүе күрсәтелә. Аннан соң «Яшьләр хәятыннан бер ләүхә»дә (1909 ел) исә бу көрәш һәм киңәя, һәм тирәнәя бара: монда инде динчелек, исламчылык, милләтчелек һәм бәйнәлмиләл социалистлык дулкыннары эчендә яшьләрнең чайкалуы бар. «Яшь йөрәкләр»дә (1912 ел) аталар белән балалар арасындагы һәм халыклар эчендә булып килгән көрәшнең үзебезнең татар мохитендә ничек булганы тасвир ителә. «Татар хатыны ниләр күрми» (1910 ел) дигән хикәясендә мөхәррир татар дөньясында хатыннарның ни дәрәҗәдә җәберләнеп яшәгәнлекләрен яза. Шуның белән бергә, шул ук җәберләр төрле сурәтләр аркылы «Яшь йөрәкләр» белән «Безнең көннәр»дә һәм башкаларында һаман киңәйтелә, үстерелә бара.

Болар белән бергә татар дөньясындагы сыйнфый каршылыклар беренче әсәрләреннән үк диярлек өзексез күренә килде. «Татар

хатыныниләр күрми» дигән хикәясе татар авылының бай кулагын, башкортның бай асабасын[1] ачып бирә. «Ялчы карт»та (1911) бөтен гомере ялчылыкта үтеп тә, әле сыйнфый аңы ачыла алмаган авыл батрагы тибы бирелә. «Көтүчеләр»гә (1913) килсәк, инде монда авыл ярлылары арасында аерым рәвештә изелеп килүче көтүчеләрнең сәнгатьчә матур эшләнеп бирелгән ачык бер картинасын күрәбез.

Крестьянның кулаклары белән ярлылары арасында киңәеп сузылып яткан урта крестьяннар дөньясы да бу әдип каләме аркылы күп мәртәбәләр сурәтләндерелде. «Табигать балалары» – аның шундый әсәрләреннән. Әдипнең бу әсәре теле-өслүбе ягыннан да, тасвиры ягыннан да татарның сүз сәнгате дөньясында иң табигый, иң матур классик бер әсәр булып чыкты. Бу әсәр сүз һәм фикердә, тасвирда икътисад канунының да ачык бер үрнәге булып калды.

Бу әдип каләме аркылы 1910 еллардан ук күренә башлаган крестьяннар арасында өч төрле сыйнфый катлау (кулак, урта, ярлы)ны тасвир сызыклары Февраль-Октябрь соңыннан тагын да иркен алым белән тирәнәеп китте. Мәсәлән, «Яңа кешеләр» драмасы (1919), «Кызыл чәчәкләр» хикәясе (1921), «Адәмнәр» (1923) һәм башка хикәяләре ул әүвәлге сыйнфый каршылык дулкыннарының аңлап эшләнгән сыйнфый көрәш хәрәкәтләренә әйләнгәнен күрсәттеләр.

Авылдагы бу каршылыклар, бу хәрәкәтләр белән бергә, шәһәрдә дә татар халкы арасында шундый ук көрәшләр, сыйнфый каршылыклар булганы мөхәррирнең берничә әсәрендә тасвир кылына. «Яшьләр хәятыннан бер ләүхә» хикәясенең баш каһарманнары булган Сәлимнәр, Фазыллар шәһәр мәдәнияте эчендә җитешеп, шундагы вакыйгалар эчендә көрәшүчеләр иде. Шулар өстенә «Яшь йөрәкләр»дәге мирзаларның да кайберләре – шәһәргә багланып, анда торучылардыр. «Безнең көннәр»гә килсәк, монда инде шәһәр үзенең бөтен сыйнфый каршылыклары, сугышлары, көрәшләре, үзенең төрле типтагы каһарманнары белән күз алдыбыздан гәүдәләнеп үтәләр. Бер яктан – либераль капиталист Кадыйр бай һәм Йосыфҗаннар, икенче яктан – боларга каршы аңлы пролетарий Габдулла абзый белән аның хатыны Хәдичә җиңги, шулай ук каты революционер Гәрәй, Солтаннар көрәшәләр. Өченчедән – Кадыйр байлар тирәсендә буржуа зыялылары, бай муллалар оешалар. Гәрәй, Солтаннар тирәсендә исә буржуазиядән өметләре киселгән ярлы яшьләр, шәкертләр кайнашалар. Бу ике зур лагерьның уртасында торып, киң вак буржуазия катлаулары

[1] Асаба – башкорт җирбиләүчесен белдергән атама.

(мәсәлән, приказчиклар, вак һөнәрчеләр, түбән катлау зыялылары) хәрәкәтләнәләр. Болар һәммәсе шәһәр эчендәләр.

Шул рәвешчә, көрәш һәм тартышның бик күп төрләре татар халкының төрле катлаулары уртасында ничек була килгәнлеге Галимҗан Ибраһимовның әсәрләрендә үзләренең төрле сурәтләре белән чыгарыла киләләр.

Шул көрәшләр белән бер дәрәҗәдә үк, аның әсәрләрендә төп урын тоткан мөндәриҗәләрнең икенче өлеше хезмәт процесслары турында булды. Мәсәлән, «Ялчы карт»та – көзге иген ташу эшләре; «Татар хатыны ниләр күрми»дә – крестьян массасының һәммә хезмәт рәвешләре; «Табигать балалары», «Яшь йөрәкләр»дә, «Кызыл чәчәкләр»дә авыл көнкүрешендә зур роль уйнап килгән бөтен хезмәт тармаклары-процесслары, мәсәлән, печән чабу, урак уру, урман ташу, сабан сөрү, йорт-җир карау, мал саклау кебек хәлләр киң урын алалар.

Димәк, бу әдипнең бөтен төр әсәрләрен җыйнап, тикшереп караганда, анда шушы түбәндәге ике төп хосусият кызыл җеп булып сузылып барганы күренә: 1) көрәш, 2) хезмәт.

Инде бу әдип әсәрләренең эшләнүләре, эчке әдәби төзелешләре ягына килгәндә, без бу урында аның башка кечерәк хикәяләреннән үтеп, туры беренче романы булган «Яшь йөрәкләр»гә тукталуны тиеш табабыз.

«Яшь йөрәкләр» романы әдипнең сентименталистлык-романтиклык дәверен кичереп торуының зур бер җимеше иде, ләкин татар әдәбият дөньясы аңарча күренмәгән бу беренче зур әдәби адымны яратып, бәлки шаулатып каршы алды. Әсәрнең сентиментализм, романтизм белән сугарылган булуы өчен мөхәррир тәнкыйтькә эләкмәде, бәлки моның өчен ул татар матбугатында тәкъдир ителде.

«Юк! Мин хәзерге реалист булып азаплануны үзен ялган реализм дияр идем. Чөнки безнең хәзер милли хисебез куәтләнгән, милли музыка, халык җыры вә музыкасына әһәмият биргән, үзебезнең үткән көннәребезне артыбызга борылып карый башлаган бер заманыбыз – бездә ник романтизм булмасын? Гаребтә, мәсәлән, Германиядә дә шундый бер заман да булган иде бит! Шуңар күрә мин безнең романнарыбызның күбесендә очрый торган, бигрәк тә Галимҗан әфәнденең әсәрендә табыла торган чын яхшы яклары белән булган романтизмны чын тарихи бер вакыйга, шулай кирәк иде, шунсыз чарасыз иде дип ышанам» («Аң», 11 нче сан, 1912 ел. Г. Газиз).

Әсәр татардагы романтизм дулкыннары астында калып, шуның тәэсире белән язылуга карамастан, мәүзугының яңалыгы,

мөндәриҗәсенең киңлеге, алган каһарманнары, тел-өслүбенең яңа һәм үткенлеге белән башкалардан, шөбһәсез, аерым урын тота иде. Бердән, бу роман аркылы татарда беренче мәртәбә авыл тормышы, авыл яшьләренең хәрәкәте киң сызыкта матур әдәбиятка мөндәриҗә итеп алынды. Урта хәлле авыл тормышы күренешләре бирелде. Ничек булганда да, бу роман матур әдәбиятны – авылга, авылны да матур әдәбиятка китереп кертте. Икенчедән, монда вакыйга һәм нәрсәләр турындагы фәлсәфи карашлар, эчке рухи дулкыннар (бигрәк тә романтизм дулкыннары) яхшы ук киң бер алым белән бик оста тасвир ителде. Романда күренгән бу хосусият тә татар матур әдәбиятында үзенең тулылыгы белән беренче мәртәбә күренгән бер хәл иде. Әдип бу романы белән үзен чыннан да эчке дулкыннарны тасвирда да көчле әдип икәнен күрсәтте. «Ибраһимовның бу әсәре эчендәге тасвирлар эчендә иң муәффәккыятьле чыкканы – бәгъзе урыннарда рухның дулкынын, аның буранын яисә ялтыравыклы күл өсте кебек тын булган заманын күрсәтә торганыдыр. Андый тасвирлар бу әсәр эчендә күп» («Аң», 11 нче сан, 1912–[19]13 ел. Г. Газиз тәнкыйте).

«Бу романда татар җәмәгатенең төрле катлавыннан күп типлар бар»[1]. Типлар крестьян яшьләреннән, мирза һәм муллалардан, шуларның тормышыннан алынган.

«Галимҗан әфәнденең яшьләре арасында төрле кешеләр бар. Ләкин анда бер хосусият бардыр ки, ул анларны бигрәк эчке яклары, рухани халәтләре белән күрсәтә. Анлар күбрәк үзләре белән газаплананалар вә үз рухларында яшиләр, дәртләр, моңнар белән көн кичерәләр» («Вакыт», 1674 нче сан, 1914 ел. Җ. Вәлиди).

Романдагы баш типлардан Зыя белән Мәрьям – тәмам идеалист һәм романтик табигатьле яшьләрдер. Болар турында матбугатта: «Ничек тә Зыя тибы бик тормышка муафыйк. Бик татар галәмендә, бигрәк тә фанатизм золымы астында тәрбия кылынган халыкта була торган бер типтыр. Зыя беренче мәртәбә безнең әдәбиятыбызда килеп чыкты, моның белән мөхәррирне тәбрик кылмый булмыйдыр». «Мәрьямнең кызлык дәвере хатынлык дәвереннән әллә ничә кат күп яхшы чыккан. Мин, дөрестен әйткәндә, Мәрьямне аңламыйм: ул сентименталист, ул бик зәгыйфь табигатьле, куркач, әмма Зыя бер картны атып үтергәндә, артык курыкмый да бугай...» («Аң», 11 нче сан, 1912–[19]13 ел. Г. Газиз).

[1] Җ. Вәлиди. Очерки истории образованности и литературы татар. *(Авт. иск.)*

Романда янә яшьләрдән Сабир, Сәлим, дәһри Садыйк, Госманов, «яшерен шагыйрь» Кәрим; яшь муллалардан Җаббар, картлардан Җәләш мулла, Гәрәй мирза типлары бар. Хатыннардан Зыяның анасы – Җәләш мулланың хатыны алынган. Болары – икенче дәрәҗәдәге каһарманнар.

Бәгъзеләрнең тулы эшләнеп җитү-җитмәвенә карамаганда, бу типлар барысы да шул вакытның татар тормышында күренгән типлар иде. Сабир – табигатенең ясалышында, рухи төзелешендә Зыяның бөтенләй киресе булган бер кеше, «акыл, салкын мөхакәмә колы». Ләкин, ахырда бу да уку дигән нәрсәгә, мәдәни тормышка, бигрәк тә шәһәр тормышына дошман булып әверелә. «Тын, караңгы бер авылга китеп югалырга» карар бирә, тагын да кыскасы, Сабир тибы вак буржуалык, мещанлык фикерләре белән төгәлләнә.

Сәлим исә – «бервакыт кызылларга катышып, халык эше белән дә йөргән, зинданда яткан», «берничә еллар атасы белән дә бозылышып йөргән», ләкин соңыннан килешеп, авылда тора башлаган, иң ахырдан ул бик үзгәреп, эчәргә салыну өстенә, хәтта «халык», «милләт», «хезмәт» дигән сүзләрне ишетәсе килмәслек дәрәҗәгә килеп, ахырда үз-үзен атып үтергән бер тип.

«Сәлим татарны, гомумән, төрк халкын бетә һәм бу хәл аңа табигый бер нәрсә итеп карый, аны яшәтергә, яурупалылар катарына[1] китерергә тырышуны балалык һәм «кануны илаһи»га каршы бару дип уйлый һәм гел шулай сөйли торган була. Ул мәсләк өчен җан атып йөреп тә, «теге хәяттә бердәнбер максат итеп, шуның кодсияте алдында даимән табынмакта булган иман вә идеалын югалткан» бер кеше була.

Матбугатта Сәлим тибы болай каршы алынды: «Сәлим – кызык тип. Ул – чын 1905 ел адәме. Ул, мөхәррирнең язуына караганда, шул хәрәкәтнең эчендә йөргән, әмма хәзер әүвәлге иманы беткән, бер пессимист булып калган. Ул нәкъ чабып арыган ат кеби, ул хәзер арыган, талган. Әүвәлдә дә тәкълиди[2] булуы бик ихтимал булган иманы да хәзер беткән. Бу тип – хәятка бик якын тип. Боларны җыйсак, 1908 елларда татар галәмендә бер-ике дистә таба да алыр идек. Болар үзләренең эчләрендәге арыганлык, иманның беткәнен аналогия белән милләтебезгә китереп, аны да үзләре кебек шәлдерәгән, какшаган итеп табалар иде» («Аң», 11 нче сан, 1912–[19]13 ел. Г. Гобәйдуллин).

[1] Катарына – сафына.
[2] Тәкълиди – ата-бабадан күчкән иман.

Садыйк – «яман телле, усал күзле бер егет» булып, шәкертләр арасында «дәһри Садыйк» дип шөһрәт алучы. Дошманнары тарафыннан «тәүфыйксыз» дип тә сөйләнә торган бер тип.

Госман исә – мөгаллим булып, университетка һәм учительлеккә имтихан тотарга йөреп, булдыра алмыйча, ахырда бар нәрсәдән кул селтәп, авылга кайтып өйләнгән, хатыныннан уңган, аның аркасында «чын кеше» булган һәм тәмам аның тәэсиренә бирелгән бер адәм. Кәрим – Зыяның яшьтәше һәм Зыяның киңәшчесе булган бер яшь егет булып, шәкерт ихтилалына катышучы, аннан соң авылга кайтып бераз торгач, Истанбулга китү өчен, Одессага качучы, ул уңышлы чыкмагач, кире кайтып, Идел буе шәһәрләренең берсендә русча укырга тотынган бер тип. Үзе шигырь язып маташа, шагыйрь була. Ләкин яшерен шагыйрь, шагыйрьлеген һәркемнән яшерә. Шуның өстенә татарлык рухы белән бик нык кайнаучы. Бу – шул яктан тәмам Сәлимгә каршы куелган бер тип. Җаббар – яшь бер мулла. Ашыгучанлык, җиңелчә уйлаучылык һәм шаянлык, шулай ук һәрвакыт шәкертләрнең «юрган асты хыялы» белән саташуларыннан көлүчелек – аның табигатенең иң нык күзгә ташланган яклары. Ул – шәкертләрне «җил куып, һавадагы торнаны тотарга йөргәнче», «урынлаша башларга» димләп торучы бер тип.

Зыяның атасы Җәләш хәзрәт – каты табигатьле, кызу, усал, кансыз; халык белән дә, гаилә эчендәге мөгамәләсендә дә үзсүзле, үз кәефен генә караучы, үзен генә кайгыртучы. Үзен үзе бик эре тотарга, һәркемнән өстен булырга тырышучы; һәрвакыт бераз кабарырга, куык очырырга тырыша торган һәм шөһрәт колы булган бер кеше. Үзе халык телендә «җилкуар, мактанчык» дип исем ала. Шулар өстенә ул «ат тилесе» дә. Бөтен тормышында халыкны шаккатырып йөрү, «һәр турыда күренәсе, күрсәтәсе килү», гаилә эчендә каты куллы, үзсүзле булу – аның бигрәк тә аерым бер сыйфаты. Бу тип – романда чынлап та рухи бер тип. Моны татарда шөһрәт, өстенлек сөючеләр тибы итеп алып була.

Зыяның анасы Зөләйха тибы исә – бик динле булып, язмышка да бик нык ышана, искечә, борынгыларча торуны бик сөя, халык теленә төшүдән, халык арасында яманат алудан бик курка торган һәм иргә тәмам буйсынучан, иренең бөтен җәберләренә каршы ләммим эндәшмичә торучан, шулай ук балаларының бәхете өчен бик кайгыручан бер хатын.

Бөтен шушы типлар аркылы татардагы беренче зур романның мөндәриҗәсе ничек, нинди рухта һәм нинди бер киңлектә булуы

ачык аңлашылса кирәк. Типларның кыскача бер характеристикаларын бу урында язып үтүебез дә әнә шуның өчен эшләнә.

Әсәрдә җитешлекләр булган шикелле, кимчелекләр дә юк түгел. Башкаларына бу урында тукталмыйча, тик бәгъзе берләрен генә күрсәтеп үтик: әдип әсәрендә индукция ысулын түгел, дедукция ысулын тота. Хәлбуки, матур әдәбиятта, бигрәк тә хикәя вә романнарда (чөнки лирикада дедукция күбрәк урын ала) индукция ысулы – яхшы нәтиҗәле бер ысул. Әдип, дедукция ысулы буенча барып, әсәрендәге каһарманнарның характеристикаларын үзе сөйләп, тәгъриф кылып[1] бирә. Чын шигъри әсәрләр өчен бу хәл җитешлелек түгел, әлбәттә, каһарманнарның характеристикалары аларның үз эшләре, итенеш-кыланышлары, хәрәкәтләре, башкалар белән мөгамәләләре, сүзләре аркылы үз-үзеннән беленеп торырга; укучы аларның характеристикаларын аларның шушы хәлләреннән үзе чыгарып алырга тиеш. Шулар өстенә, әсәрдә вакыйгаларның үзара тәмам багланып җитмәве, таркаулык һәм кайсы урыннарда тәкрарлар, кирәксез урыннарда тәфсил бирүләр дә юк түгел.

Ләкин шуларга карамастан, һәм шундый кимчелекләре күрсәтелгән хәлдә, бу роман татар тәнкыйть дөньясында вакытында зурлап, яратылып каршы алынды.

«Бу әсәр зур да иде, мөхәррире дә яңарак баш күтәреп, халык күзенә чалынган иде. Ләкин эчендә халык күңелен тибрәтерлек хасияте булгач, укучы аны салкын гына, тавышсыз гына узгара алмады. Әсәр телгә алынырлык булгач, аның хакында тәнкыйть булсын, тәкъриз[2] булсын, байтак кына язылды; күп яхшы гына каләм ияләре мөхәррирнең үткәне, киләчәге хакларында күп фикерләр сөйләделәр һәм Галимҗан әфәнденең киләчәгенә зур гына өметләр багланды». «Дөрестен әйтергә кирәк: якында чыккан мәгълүм дүрт әсәрдән (Тукайның «Җан азыклары», Гаяз Исхакыйның «Мулла бабай»ы, Ф. Әмирханның «Урталыкта»сы һәм Г. Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр»ен әйтә) күбрәк укучыларның дикъкатене үзенә җәлеп иткән, күбрәк тавыш алган һәм мөхәрриренә милләтнең өметен баглатканы «Яшь йөрәкләр» булды» («Аң», 18 нче сан, 1913 ел. Х. Кәримовның «Әдәбиятта үзгәреш көтелә» дигән мәкаләсе).

Бу әсәр турында Риза казыйның «Шура»да сәлби[3] тәнкыйть белән кечкенә бер мәкаләсе чыкканны да бу урында әйтеп үтәргә

[1] Тәгъриф кылып – тасвирлап.
[2] Тәкъриз – язылган әсәр һәм хезмәткә мактап бәя бирү.
[3] Сәлби – тискәре.

кирәк. «Яшь йөрәкләр» романы гаиләви-иҗтимагый бер роман иде. Әдип, моннан соң тагын да күп югары күтәрелеп, «Безнең көннәр» исеме белән икенче бер зур романын иҗат итте. Роман 1912–[19]13 елларда язылып, 1914тә басыла башлаган һәм ике-өч табагы басылып чыккан булса да, цензор кулының инде артык калган табакларын бастыртуга рөхсәт итү өчен түземе җитә алмаган, романны бастырудан туктаткан иде. Шуның өчен роман үзенең төгәл басылып чыгуын 1920 елда гына күрә алды[1]. Татар әдәбиятында аңарчы мондый иҗтимагый-инкыйлаби бер роман юк иде. Бу шуның беренче тарихи зур адымы булды.

Роман – 1905 ел революциясенең җимеше. Романда шул революция дулкыннарының татарларны да үз эченә алып, алар арасында да үзенең көчле тәэсирләрен күрсәтә башлау көннәреннән реакциягә кадәр булган иҗтимагый-сәяси хәрәкәтләр үз каһарманнары аркылы тасвир ителә.

Шәкертләр кузгалышы, мәдрәсә гыйсъяннары, ислах, яңару хәрәкәтләре, рус теле, рус мәктәпләре аркылы гыйлем алуга омтылулар, приказчиклар кузгалышы, гимназист һәм реалистларның мәдрәсә шәкертләре арасына кереп, шунда алар арасын кайнатулары һәм алар белән бергә эш йөртүләре. Милләтчелек – милләтсезлек көрәшләре, исламчылык – татарлык тартышлары. Үзләрен «милләтче» дип атаучы груһ – «Иттифакы мөслимин» партиясе белән татар социалистлары арасындагы тартыш. Татарларда социал-демократлар белән эсерларның бер-берсеннән аерылып эш күрүләре. Контрреволюциянең ерткычларча кысу-җәберләү вакытларында чын революционерлар белән күз буяу, ялган революционерларның төрлечә иләнүләре. «Җимерелгән өметләр, сынган канатлар, иманыннан, идеалыннан ваз кичкән мөртәтләр каберстаны» булып әверелгән тормыш эчендәге хәлләр. «Кемне тотып япкан, кемне сөргән, кемне аскан»лык, «монда калганнарның да кайсы байлар ягын каера башлаган, кайсы эчүгә сабышкан, иң күбе элекке юлны бөтенләй ташлаган» булулары кебек хәлләр. Аумакай мөхәррирләр, байлар, тиречеләр һәм шулар артыннан баручы яшьләрнең җыелышлары – менә романның мөндәриҗәсе шулар.

---

[1] Басылган табаклары белән чагыштырып карау романның әүвәлге хәленнән үзгәртелмичә басылганын күрсәтә. Беренче табагында мин тик беренче басмадагы «ихтилал» сүзенең «революция» сүзенә алыштырылу кебек үзгәрешләрне генә күрдем. Романның беренче басмасы һәм беренче табагы Казанда Әхмәтгәрәй Хәсәни вә шөрәкясе тарафыннан «Мәгариф» матбагасында 1914 елда басылган. *(Авт. иск.)*

Җыйнак кылып әйткәндә, «Безнең көннәр» романында 1905 ел революциясе тәэсире астында татар халкының киң күпчелеге тирән йокыларыннан уянып, зур хәрәкәткә башлаган бер дәвере тасвир ителә. Бу хәрәкәт эчендә самодержавиене яклаучы карагруһ динчеләрдән башлап, аңлы эшче большевик татарларгача һәммә катлаулар үзләренең сыйнфый хәлләренчә аерым партияләргә, организацияләргә бүленәләр. Аерым программалар, аерым лозунглар белән бер-беренә каршы, тарихта беренче мәртәбә, зур сугышка чыгалар. Монда эшче дә бар, солдат та бар, крестьян да бар, приказчик та, байбәтчә дә, либераль буржуа да, халыкчы эсерлар да бар. Революциянең кызу дулкыны чагында кызыл байрак үзенә бик күп кешеләр ияртә. Әмма реакция башлану белән, безгә бу роман аркылы сыйнфый як белән идеологиянең нык багланганлыгы ачык күренә. «Безнең көннәр»нең башында һәм уртасында бик шәп «социалист» булып йөргән бәндәләрнең соңыннан капитал алдында тәүбә иткәнлекләре беленә. Чөнки болар революция тәэсире белән генә пролетариат ягында күренгән вак буржуа элементлары булдылар. Бу роман әнә шушы сыйнфый моментны нык ачып бирә алды.

Иң элек куркыныч бер рәвештә бик каты күкрәп, дөнья туздырып, кинәттән өелеп чыга торган яңгырлар була. Бу яңгырлар шулай чыгалар да, бара торгач, бөтен күккә җәелеп, иңләп алып, бер көйгә генә явып тора башлыйлар. Аларның бик артык иңләп китеп, сыекланып киткән чаклары да булгалый. Романнарында Галимҗан әнә шундый бер яңгырга охшый. Шуның белән бергә роман, шөбһәсез, үзенең алган мәүзугы, мөндәриҗәсе, тасвир рәвешләре, теле-өслүбе белән татар әдәбиятының күп үскәнен, югары күтәрелгәнен күрсәтте. Бу классик әдипнең каләме монда тагын да киң алымнар белән ташланып, реаль бер юл белән чын сәнгатьчә оста хәрәкәт итте. Шуның өчен дә бу роман татар тәнкыйть дөньясында бик зурлап, аңарчы һичбер әдип турында күрелмәгән бер рәвештә каршы алынды[1].

«Безнең көннәр» романы моңа кадәр татар матбугатында күрелгән әдәби әсәрләр арасында кирәк алынган мәүзугы, кирәк тасвир иткән буявының көчлелеге, кирәк тәҗәссем иткән типларның реальный булуы, бөтенлеге ягыннан, шөбһәсез, чагыштырылмаслык дәрәҗәдә аерым урында торырга тиештер».

[1] Романның чыгуы һәм аның хакындагы тәнкыйтьләр революциядән соң булса да, романның язылып, басыла башлавы 1914 елда ук булганга, без бу әсәрне Октябрьгәчә булган ун ел эченә кертүне тиеш күрдек. *(Авт. иск.)*

«Аның моңа кадәр чыккан әсәрләреннән бигрәк тә “Яшь йөрәкләр”дә иң күзгә бәрелгән аермасы – алынган мәузыгысының, сызылган планының бөтенлегендә, романның беренче бабыннан соңына кадәр бер идея тәгъкыйб итүендә[1]; шулай ук бер дәвердәге хәрәкәтне бер йомгакка җыюындадыр. “Яшь йөрәкләр” романында аз гына таркаулык, бер орлыктан үрчеп, киңәеп киткән тармаклы бөтенлекнең сизелмәве беленә. Бу романы, ул кимчелекне бөтенләй тутыру өстенә, шул бөтенлекне аның гына каләменнән килә торган аерым бер осталык белән тасвир итә алуындадыр».

«“Безнең көннәр” романы бер генә вакыйганың яисә берәр генә гаиләнең, булмаса берәр генә ыруның башыннан үткәннәрен тасвир итми, бәлки бер дәвердә, халык дулкынының бер күтәрелеп, бер төшеп торганда, яр читеннән кузгалып киткән һәммә сыйныф, һәммә төрле гаилә, ырулар хакында – кыскасы бөтен бер халыкның хәяттә иң кызу эшләгән моментын тасвир итә. Алар һәммәсе бер-беренә чылбыр кебек бәйләнгәннәр».

«“Безнең көннәр”нең шул мәдәни эшне, бер йомгакка җыеп, әдәби букет рәвешендә тәкъдим итүе инде ул көрәшчеләргә татар мәдәният тарихында хәзердән үк урын хәзерләп куя. “Безнең көннәр” романының иҗтимагый урыны шундый.

Беренче революциядәге хәрәкәтләр, анда ташланган типлар хакында мөзакәрәләр[2], тирән тәхлилләр[3] татар пролетариатының тарихи нигезе булырга тиеш. Шуңар күрә “Безнең көннәр” романы бер түгел, мең мәртәбә бу ноктадан тикшерәләчәгенә ышанганга, мин роман эчендәге типларны тәхлилгә бу мәкаләдә туктамыймын. Мин бары “Безнең көннәр” романының татар мәдәният тарихында тотачак урынын гына искә төшереп китәмен».

«“Безнең көннәр” романының татар матбугатында моңа кадәр күренгән әдәби әсәрләреннән төп аермасы – андагы типларның һәм аларның бер татар халкына гына аңлашылмый, сыйрыф[4] милли – үзебезнеке генә түгел, бәлки руска да, немецка да, французга да аңланырлык типлар һәм эшләр булуында. Бу инде, чынлап та, безнең әдәбиятта иң яңа күренештер».

«Безнең көннәр» романы – тагын тәкрарлыйм, роман булудан бигрәк, бер дәвернең бер-берсенә бәйләнгән сәяси күренешләр,

[1] Тәгъкыйб итүендә – *бире∂ә:* дәвам итүендә.
[2] Мөзакәрәләр – бәхәсләр, фикер алышулар.
[3] Тәхлилләр – анализлар.
[4] Сыйрыф – фәкать.

иҗтимагый хәрәкәтләр бергә бәйләнеп җыелган әсәрдер. Шуна күрә әдипнең алдында романның шигъри буявын тикшерү, матурлату никадәр кирәк, лязем бер әйбер булса да, шул дәвердәге хадисәләрне дөрес тотып ала белү, нигезгә салынган идеягә хыянәт кылмау тагын да мәсьүлиятлерәктер[1]. Әдип әсәрнең беренче яртысын табигый таланты, күнегүе белән тутырган булса, соңгы яртысын да, шөбһәсез, һәркемне канәгатьләндерерлек дәрәҗәдә күрсәтә алган. Дөрес, зур романның бер өлешендә бер мәсьәләгә күбрәк туктап, икенче бер нигезе һәм хәяттагы урынына карап мөһимрәк бер хадисәгә азрак туктау кебек җөзьи кимчелекләр, әсәрнең кайбер урыны нәфасәт, сәнгать ягыннан үзенең йолдызына җитеп («Башкорт кызы Гөлбикә» хикәясе), кайбер урыннары (романның соңгы ягы – Казандагы хәят) бөтенләй сыекланып китү дә әсәргә күләгә төшерерлек түгел. «Башкорт кызы Гөлбикә» хикәясе бөтен романга матурлык йөзеннән асылташлардан тукылган таҗ кебек күренгәнгә, романның сыек урыннары шуның белән берьюлы капланалар».

«Безнең көннәр» укылган саен, тикшерелгән саен, аның тирәсендә бәхәсләр, тәнкыйтьләр арта барачак. Чөнки «Безнең көннәр» – татар мәдәният тарихының нигез ташларының берсе. Моны бүгеннән үк кыю рәвештә хөкем итеп куярга батырчылыгыбыз җитә» («Кызыл Шәрык» журналы, 3–4 нче сан, 1920 ел. Ф. Сәйфи-Казанлы мәкаләсеннән).

«Ибраһимов – XX йөз татар әдәбиятының классикларыннан берсе. Революциягә кадәр башка мөхәррирләр татарның иске тормышын һәм дөньяга урта гасырча карашларын җимерү мәйданында эшләгән, ләкин аннан ары китүдә артта калган, һәм аны алар булдыра алмаганнар иде. Галимҗан Ибраһимов исә, элек тә революциячелек белән рухланган хәлдә, революциядән соң да революция идеалын алга алып, шул юлда хезмәтен дәвам иттереп килә».

«Ул үзенең шушы әсәрендә («Безнең көннәр»ендә) татарның иске тормышыннан һәм 1905 елгы Беренче революция хәрәкәтләреннән иң яхшы картиналарны бирде» («Вестник Татароведения[2]», 1–2 нче сан, 1925 ел. Газиз Гобәйдуллин).

«Безнең көннәр» романы рус тәнкыйть дөньясында да зур игътибар казанды: «Мөхәррир мөселман яшьләре арасында башланган

[1] Мәсьүлиятлерәктер – *биредә:* мөһимрәк.

[2] «Вестник научного общества татароведения» – 1925–1930 елларда Казанда рус телендә чыгып килгән рәсемле фәнни журнал, Татар халкын гыйльми өйрәнү җәмгыяте хәбәрчесе.

хәрәкәтләрне тыныч һәм тәфсилле рәвештә тасвир итә». «Романда революция һәрнәрсә турында һәм һәр урында». «Романның нинди генә кимчелекләре булмасын, романдагы психологик яктан дөреслек һәм бик яхшы үтәлү тонын алып торучы “Башкорт кызы Гөлбикә” дигән кечкенә хикәясе аларның барыннан да коткара». «Үзенең романында мөхәррирнең максаты – шөбһәсез, татарлар арасындагы революция хәрәкәтләрен тасвир итүдер. “Безнең көннәр” романы шул яктан бер кыйммәтле тарихи документ итеп каралырга мөмкин» (игътибарлы мәрхүм тюрколог П. Фалёвның[1] Ташкентта нәшер ителгән «Науки и просвещение»[2] дигән журналның беренче санындагы «Татарский революционный роман»[3] дигән тәнкыйть һәм тәхлиленнән).

«Аның тарафыннан “Безнең көннәр” язылган. Бу зур сәнгать әсәре пролетариатның царизмга каршы гражданлык көрәшен тасвир итә» («Новый Восток»[4] журналы, 12 сан, 1926. М. Павлович[5]).

Гәрчә басылып чыга алуы Октябрь революциясеннән соң булса да, 1909 елда язылганлыгы өчен, әдипнең янә өченче бер бик әһәмиятле зур романы турында да бераз тукталып үтик. «Казакъ кызы» исемендәге бу романы кирәк үз матбугатыбызда, кирәк рус матбугатында, кирәк исә казакъ матбугатында булсын, аның «Безнең көннәр»еннән дә артык бер игътибар казанды. Роман – исеменнән ачык күренеп тора, татар тормышыннан түгел, казакъ тормышыннан, сахра хәятыннан алынып язылган бер иҗат. Бу иҗат татар дөньясының сүз сәнгатендә һәр ягы белән югарылыкның соңгы ноктасына барып җитүнең беренче үрнәге булды. Үз тарафыбыздан моның турында шуннан артык сүз әйтмичә, бу урында башкаларның сүзләрен тыңлау белән канәгатьләнәбез. Казакъ тормышыннан алынып язылган булганлыгы өчен, иң элек казакъ тәнкыйтьчеләренең сүзләрен тыңлап үтик.

«Галимҗан Ибраһимов татардың җаксы җазушыларыннан саналды. Бол романды татар олтын казакъ пән таныстыру өчен җазган булу кәрәк. Казакъ тормысының иче-тысы бир талай күрсәтелгән.

Галимҗан казакъ үмири мән җаксы таныс әкән. Чәт әлдең баска җазучыларындай казакъ тормысының бәтин чырпыб, күдәнең

---

[1] Павел Александрович Фалёв (1888–1922) – рус тюркологы һәм этнографы.

[2] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[3] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[4] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[5] Михаил Павлович (Михаил Лазаревич Вельтман (1871–1927) – публицист, тарихчы-шәркыятчы.

басын чалып кәтбәгән. Казакътың минәзен, салтын әдәт-үрпен, үй иче, әләүмәт үмирен җәтә билип җазган күренәде».

«Қазақтың сүзгә чәчәндиге, бак комарлыгы, морзалыгы, кәңдиги, гәңчилдиги, партия жомысында осчылдыгы – бары анык, бары чын. У җагын җаксы кәлтерген. Әсирәсә Биремҗан дәгән аксакал казакъ минәзинә кәйипкәр (тип) була алады».

«Бол роман казакъчага аударылса җарар әди. Кәрәкте нәрсә әкән»[1] («Ак җул» гәзите, 1925 ел, 23 апрель, 565 нче сан. Җосыпбәкнең «Китап сыны» дигән мәкаләсеннән)[2].

«Казакъ кызы» дигән хикәясе белән Галимҗан иптәш Ибраһимов үзенең ни дәрәҗәдә әтрафлы, киң даирәле әдип икәнен тагын бер кат күрсәтте. «Табигать балалары», «Безнең көннәр», «Кызыл чәчәкләр», «Адәмнәр» шикелле кирәк мәүзуг, кирәк рух вә аһәң ягыннан бер-берсеннән ачык сызыклар белән аерылып тора торган әдәби әсәрләр янына тагын бер матур әйбер өстәлде. «Казакъ кызы»н укырга керешкән кеше беренче битләрдән башлап ук үзенә бертөрле, моңарчы татар әдәбиятында булмаган яңа бер хәят, яңа бер шигърият эченә кереп чума да инде ахыргы биткә кадәр шуның тылсымыннан котыла алмый.

«Кыскасы гына, «Казакъ кызы»н укып чыккан кеше казакъ халкының бөтен матди, мәгънәви тормышы, бөтен психологиясе белән таныштым, дип әйтә ала».

«Дала тормышына һичбер төрле фаразый идеал күзлеге аркылы карамыйча, реаль, битараф рәвештә турыдан-туры, тенденция вә агитациягә бирелмәстән, тыныч эпика тонында тасвир ителә. Әсәрнең төп әдәби кыйммәте дә менә шунда. Чынлап та, бу әсәр күчмәле төрк халыкларының шундый тыныч, мәһабәт агымлы, саф дала исе аңкып тора торган эпосларын, табигый дала шагыйрьләре тарафыннан тудырылган поэмаларын искә төшерә».

[1] Бу мактаулы тәнкыйть бөтенесе белән алынмады. Тагын күп сүзләр калдырылды. *(Авт. иск.)*

[2] Галимҗан Ибраһимов татарның яхшы язучыларыннан санала. Бу роман татар милләтен казакъ [тормышы] белән таныштыру өчен язылган. Казакъ көнкүрешендәге күп нәрсә чагылдырылган. Галимҗан казакъ тормышы белән яхшы таныш. Казакъның холкын, гореф-гадәтләрен, интерьерын, иҗтимагый тормышын яхшы белеп язганы күренә.

Казакъның сүзгә чичәнлеге, оста бакчачылыгы, морзалыгы, киң күңеллелеге, партия эшендә зирәклеге – бары анык, бары чын. Бу якны яхшы күрсәткән. Бигрәк тә Биремҗан исемле аксакал – казакъ характеры (тибы) булырга мөмкин.

Бу роман казакь теленә тәрҗемә ителсә иде. Кирәкле нәрсә.

«Казакъ кызы» – татар әдибе тарафыннан язылып та, татар галәменең рамкасы белән генә чикләнеп калмастай булган сирәк әсәрләрдән берсе» («Безнең юл» журналы, 5 нче сан, 1925 ел. Гали Рәхимнең «Казакъ кызы» дигән мәкаләсеннән)[1].

Галимҗан Ибраһимов каләме аркылы бирелгән әдәби җәүһәрләр турында үз урынында, үз дәверендә сүз төгәлләнсен өчен, аның Октябрьдән соңгы иҗатлары турында берничә сүз әйтеп үтик. Бу әдип бу революциядән соң «Алмачуар», «Адәмнәр» дигән хикәяләр өстенә, «Кызыл чәчәкләр» дигән әдәби чәчәкләрен бирде. «Киң, мул, саф башкорт улы тормышыннан алынып язылган “Алмачуар” хикәясе хакыйкатән матур чыккан. Моны укыганда, бу карт язучыбызның элекке яшьлек дәвере белән язган әсәрләреннән “Табигать балалары”, “Диңгездә”, “Картлык көннәрендә”, “Башкорт кызы Гөлбикә”ләре үзләренең бөтен матурлыклары белән ирексез хәтергә киләләр. Бу хикәя – һәрбер әдәбият сөючеләр тарафыннан, бигрәк тә татар-башкорт яшүсмерләре укып туя алмаслык бер нәрсә»[2].

Фәкать әдипнең «Адәмнәр»е турында гына җәмгыятьтә дә, шулай ук матбугатта да төрле карашлар булып үтте. Бер як авыр ачлык трагедиясен ачык, кыска күренешләрдә чыннан фаҗигалы, ачы бер өслүб белән сурәтләндерүе өчен аны тәкъдир итсә, кайберәүләр дә, әсәрдә агитация моменты җитми дип, каты тәнкыйть кылдылар. Шамил Госманов[3] болай язды: «[19]21 ел ачлыгының иң бөек фаҗигасы – Советлар Русиясен чолгап алган капиталист хөкүмәтләрнең складларындагы миллион потлар икмәкнең, ачтан үлә торган эшче-крестьянга бирелмичә, диңгезгә түгелүе, капиталист мәмләкәтләрнең хәзинәсендә өелеп яткан алтын запасларының йөздән бер өлеше генә бирелгәндә дә, миллионнарның үлемнән котылачагы; Советлар хөкүмәтенең ачлык белән көрәшү юлында иткән фидакярлеге; аның ачлык һәлакәте астында калган авылга, балаларын суеп ашаганнарга җәза бирер өчен генә түгел, шул ачларга чын-чыннан ярдәм кулы сузар өчен барганлыгы вә бу юлда эшче-крестьяннар хөкүмәтенең һичбер капиталистлар мәмләкәтендә күрелмәгән рәвештә зур фидакярлекләр күрсәтүе – болар барысы да ул авыр елларның тарихына яндырылып язылырга тиеш моментлар

[1] «Казакъ кызы» хакында моннан башка тагын «Кызыл Татарстан», 1925 ел, 7 нче санда – Ильясовның, «Эшче» гәзите, 1925 ел, 7 нче санда Кормашның бик иҗаби тәнкыйтьләре бар. *(Авт. иск.)*

[2] «Татарстан», 175 нче сан, 1922 ел. «Матбугат дөньясында» дигән мәкаләдән. С. Җәләл. *(Авт. иск.)*

[3] Шамил Хәйрулла улы Усманов (1898–1937) – хәрби-сәясәт эшлеклесе, язучы.

булып, шуларны карт язучының оста каләме белән җайлы рәвештә китереп бастырып, хәзерге яшь буында ачлыкның сәбәпләренә һәм сәбәпчеләренә ачу кузгатасы урында, «Адәмнәр» укучыны «кеше бармаклары», «бот итләре», яшь хатыннарга өрми торган (!) этләр арасында әйләндереп йөртә» («Безнең юл», 3 (15) нче сан, 1924 ел. Ш. Госманов мәкаләсеннән).

Шуның белән бергә, «Адәмнәр» турында рус матбугаты аркылы түбәндәгечә иҗаби тәнкыйтьләр дә булды: «Аның (Г. Ибраһимовның) күп әсәрләре арасында “Адәмнәр”е аерым бер урын тота. Монда мөхәррир, татарның тар бергәлек тормышыннан чыгып, бөтен кешелек өчен гаять әһәмиятле бер мәсьәләгә тотына. “Адәмнәр”дә ул татар авыл тормышы эчендә гомуми ачлык заманында күренгән адәмчелек рухи халәтенең тәрәккыйсен тасвир итә. Бу хикәядә материалист мөхәррир ачлык картиналарын биреп һәм аның урта крестьянның иң табигый рухи халәтенә ничек дәһшәтле бер рәвештә тәэсир итүен күрсәтеп, җинаятьләрнең икътисадка баглы бер нәрсә булып килеп чыгуын сурәтләндерә» («Вестник Татароведения»[1]. 1–2 нче сан, 1925 ел. Газиз Гобәйдуллин).

Ләкин әдипнең «Кызыл чәчәкләр»е иң уңышлы әсәрләреннән берсе булып чыкты. Әсәрдә тасвир ителгән вакыйгада бер-берсенә капма-каршы булган ике төрле тормыш алына: берсе – авыл ярлылары тормышы; икенчесе – авыл байлары тормышы. Шушы ике тормышның кешеләре арасында һаман сыйнфый каршылыклар сизелә, ачыла, зурая бара.

Әсәрдә баш каһарман барысы бишәү. Шуларның берсе – бай малае Гали, икенчесе – хәзрәт улы Фазыл. Болар – байлар сыйныфының вәкилләре. Гали – нәкъ бай малайлары тибы, ә Фазыл – байлар, буржуа интеллигенты.

Калган өч каһарман Солтан, Гыйлаҗи, Шаһбаз булып, беренчесе – ташчы, икенчесе – балта остасы, өченчесе – көнлекче батрак.

Болар өчесе дә эшче, ярлы крестьян сыйныфының вәкилләре булып алыналар. Болар – шул сыйныфның типлары. Әсәр тәмам сыйнфый идеология нигезендә язылган. Идеология ягыннан бу әсәр – Галимҗан Ибраһимовның 1905 елгы революция белән Октябрь революциясе арасындагы дәвердә язылган «Ялчы карт», «Көтүчеләр» кебек әсәрләренең Октябрь революциясе дәверендәге чын пролетарийләшкән, советлашкан бер юлдашы.

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

Бу әдип, шагыйрь, Октябрьдән күп еллар элек, татарның милли буржуа әдәбияты тәрәккый итү чорларында ук, югарыдагы әсәрләре белән крестьяннар арасында үз-үзеннән яшерен бер рәвештә сыйнфый каршылыклар үсә башлаганын күрсәткән булса, бу әсәре әнә шушы каршылыкларның чыннан гамәли, ачык, тулы бер күренеше булып чыкты.

Шулай да әсәрдә типларның эшләнү ягыннан табигый түгеллек мәгънәсе белән түбәндәге кимчелекләр күренде:

1. Солтан үзенә тиешле дәрәҗәдән артык акыллы, белемле, оста телле. Ул әсәрдәге үзенең сүзләре, эшләре, мөгамәләләре белән урта дәрәҗәдә мәгълүматлы бер егет булып күренә. Шулай итеп, ул бу яктан бер дә ташчы малаена охшамый. Аның сөйләве дә, фикере дә үзенең дәрәҗәсеннән күп өстен күренә. Менә шуның өчен аны фикердә тәрәккый ягыннан идеаллаштырылган бер тип (ягъни бу яктан реаль түгел) дияргә туры килә. Ләкин болай булганда да, аның бу дәрәҗәдә кинәт үсүенең сәбәбе һәм шуның процессы һич күренми.

2. Солтанның соңыннан Фазыл алдында (Фазыл кайтып төшкәч, аны кочаклап күрешү дәрәҗәсендә) ул кадәр йомшап, артык шәфкатьләнеп китүе, аның бу яктан зәгыйфь-йомшак характерлы бер кеше итеп чыгарылуы килешеп чыкмаган.

Әсәр иске әдәби традициядән аерылып җитә алмый алуын, шулай да тел-өслүб бик матур, шома, җиңел, тәмле. Матур әдәби пролетариат теле өчен үрнәк булырлык бер дәрәҗәдә. Әсәрнең теле шулкадәр матур, ул сине үзенә шулкадәр мавыктыра ала, хәтта шуның белән ул әсәрнең башка кимчелекле якларын да синең исеңнән чыгартып куярга мөмкин.

Шуның белән бергә, әсәрдә мөндәриҗә белән форма, өслүб белән фикер бер-берсенә нык бәйләнеп барган. Бу китап турындагы фикерләребезне җыеп, кыскартып әйткәндә, түбәндәгечә:

1. Китапта төп уй бик ачык: сыйнфый каршылык, сыйнфый көрәшне күрсәтү.

2. Китап – татар эшче-крестьян яшьләре арасындагы сыйнфый каршылыкларны, сыйнфый дошманлыкларны Яурупа һәм гражданлык сугышлары аркылы ачып бирүче баш адым, пролетариат әдәбиятының беренче йолдызы.

3. Әсәр тасвирга бай, телгә шәп.

4. Әсәргә математик юл белән процентлап караганда, идеология һәм тел ягыннан йөз процент җитеш. Әмма кайбер типларны эшләп чыгару, сәнгать-художество ягыннан әсәрнең җитешлеге 70–80 процентта тукталып кала.

5. Мәхәббәт, ярату, төрле нәфис әсәрләргә тартылу бабындагы психик моментларны бөтен нечкә катлаулары белән ачып бирүдә «Кызыл чәчәкләр» иясе, башка әсәрләрендәге кебек, бу әсәрендә дә алдына башкаларны чыгармый торган бер көч булып күренә. Шуның белән бергә, аның мәхәббәте матди психик бер характерда[1].

Әдипнең югарыда тикшерелгән әсәрләре тик аның матур әдәбият юлындагы хезмәтләре иде. Боларга башка тагын аның татарның яңа тарихын өйрәнү һәм тел, әдәбиятыбызны тикшерү турында язган күп әсәрләре аркылы зур хезмәтләре булды. Мөхәррирнең моңа кадәр барысы иллегә якын әсәрләре чыкты. Мәүзуг ягыннан боларны түбәндәгечә бүләргә мөмкин:

*Матур әдәбияттан:* «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы», «Яшьләр хәятыннан бер ләүхә», «Татар хатыны ниләр күрми», «Карак мулла», «Сөю-сәгадәт», «Йөз ел элек», «Диңгездә», «Яз башы», «Карт ялчы», «Көтүчеләр», «Яшь йөрәкләр», «Мәрхүмнең дәфтәреннән», Габдрахман Салихов», «Уты сүнгән җәһәннәм», «Табигать балалары», «Безнең көннәр» (1914), «Яңа кешеләр», «Кызыл чәчәкләр», «Алмачуар», «Казакъ кызы».

*Филология һәм лингвистикадан:* «Татар сарыфы» (беренче басмасы 1911 елда чыкты, бишенче басмасы, бөтенләй яңадан эшләнеп, 1919 елда басылды), «Татар нәхүе», «Татар имлясы», «Әдәбият кануннары», «Татар телен ничек укытырга?» (методика), «Тел сабаклары» (ике китап). Болар хосусый дәреслекләр иде. 1909 елдан башлап татарның телен, әдәбиятын, әдәбият тарихын тикшерү, эзләнү, шуңа материаллар хәзерләшү юлында мөхәррирнең гәзит һәм журналларда һәм китапларда бик күп мәкаләләре, тәнкыйтьләре басылып чыга килде. Болар эчендә «Татар шагыйрьләре» белән «Бабич мәҗмугасы» кебекләр дә бар иде. Болар эчендә соңгы замандагылардан аерым рәвештә әһәмиятле булганы «Татарның әдәби, иҗтимагый хәрәкәтләрен өйрәнүдә марксизм ысулы» дигән мәкаләсе булды. Бу мәкаләләрнең бер өлеше «Имля, тел, әдәбият мәсьәләләре» исеме астында басылып чыкты (1911–[19]24 еллардагылар). Шул җөмләдән, «Пролетариат әдәбияты» һәм «Кара маяклар» кебек әсәрләре башта ук аерым китап булып басылдылар.

*Тарихтан:* мөхәррирнең революция соңында ныклап башлаган бер хезмәт тармагы татарның яңа тарихын өйрәнү юлында булды. Түбәндәге нәрсәләр шул юлдагы хезмәтләреннән иде: «Бөек

[1] «Кызыл чәчәкләр» турында Г. Толымбай иптәш белән Г. Нигъмәтинең дә тәнкыйтьләре булып үтте. *(Авт. иск.)*

Октябрь революциясе һәм пролетариат диктатурасы», «Татар студентлары хәрәкәте тарихыннан», Каюм Насыйри һәм Мулланур Вахитов мәҗмугаларындагы мәкаләләре, «Биш ел эчендә» мәҗмугасында татар мәдәнияте турындагы мәкаләсе һәм башкалар[1].

«Аң» журналы заманында шул журналга кушымта итеп «Альманах», соңыннан ачлык вакытында беренче һәм икенче «Ярдәм»нәр (әдәби мәҗмуга) мөхәррирнең якыннан катнашуы һәм редакциясе астында чыктылар. 1905 ел революциясенең егерме еллык бәйрәме уңае белән язылган «Татарлар арасында революция хәрәкәтләре» китабының беренче бүлеге (235 бит) чыгып, рус һәм татар гыйлем дөньясында зур әһәмият белән каршы алынды. Бу әсәрнең русчага тәрҗемәсе дә чыкты.

**Фатих Сәйфи.** Октябрьдән соң бу әдипнең шәһәр вак буржуазиясе һәм вак һөнәрчеләре, завод эшчеләре тормышы драмаларның мәүзугы ителү, аларга мөндәриҗәнең бер ягын завод-фабрик эшчеләре тормышыннан алу кирәклекне күрсәтү юлында «Дошманнар» дигән пьесасы, шулай ук «Крушниклар», «Зимагур»[2], «Двор өендә» дигән хикәяләре чыкканлыгы безгә мәгълүм. Октябрьдән соң шушы әһәмиятле әсәрләрен биргән бу әдипнең бу юлда кечкенә булса да беренче адымы 1907 елда күренгән: кечкенә кулда кырык бит зурлыгында «Мөкаддәс хезмәт» исеме белән пьесага охшаш кечкенә бер әсәре басылып чыккан иде. 1905 ел революциясеннән соң ук үз каләменә эшчеләр тормышыннан мәүзуг, мөндәриҗә эзли башлаган бу әдипнең бу әсәре, беренче тәҗрибәсе булган өчен, сәнгатьчә эшләнүе ягыннан мактарлык булмаса да, алган мәүзугы ягыннан, шул вакытына карап, шөбһәсез, әһәмиятле иде.

Әсәрдә татар байлары, татар буржуазиясенең эшчеләргә җәбере, аларны изүләре күрсәтелә. «Ярлылык, катылык, авырлык, наданлык астларында изелеп картайган», «сасылыкта, начарлыкта изелеп черү»че бер эшче гаиләсе тормышы языла. Монда «майлы бер күлмәк, катып беткән алъяпкыч, әллә ничә урыннан ямалган пальто вә ертык бияләй»дән башка нәрсәсе булмаган һәм төн-көн бүген-

[1] Моннан егерме еллар элек Уфада мәдрәсәи Галиядә шәкерт чагында (1906–[19]07 елларда) мөхәррир тарафыннан «Борынгы ислам мәдәнияте» исемендә борынгы гарәпләрнең гыйлемнәре, мәдәниятләре турында бер нәрсәсе язылып басылган иде. Шул заманнарда моның икенче басмасын чыгару турында наширләр тарафыннан сорау булса да, мөхәррир, үзенең ул әсәрендәге метод һәм идеологиянең кайбер яклары белән килешә алмас булганлыгыннан, яңадан бастырырга ихтыяр бирмәгән. *(Авт. иск.)*

[2] Бу ике хикәясе элек 1922 елда, «Крушниклар» дигәне – «Ярдәм мәҗмугасы»ның беренче кисәгендә, «Зимагур» дигәне икенче кисәгендә басылган иде. *(Авт. иск.)*

ме, иртәгәме бай тарафыннан куылып чыгарылу, урамга ташлану фаҗигасын уйлап, газап эчендә яши торган эшче Шакир – гаилә башлыгы. Әсәрдә бер каһарман шул. Ул һәрвакыт байларның җәберенә, эшчеләрне изүенә каршы чәчен үрә торгызып, ачуланып йөри. Гаиләсенә, балаларына һәрвакыт аларның золымнарын сөйләп тора.

Шушы эшче Шакирның авыр хезмәт белән тапкан акчасына тырышып-тырмашып университетның өченче курсында укый торган Искәндәр исемле уллары була. Бу – әсәрнең икенче каһарманы. Бу – үзенең «авызында эшче кешесе дә, авыл кешесе генә» булып, «һәркайчан да шулар өчен генә кайгырта, авыл кешесенә «җир – ирек» алып бирмәкче була, эшче кешенең эш хакын күбәйтеп, эш вакытын сигез сәгатькә калдырмакчы була» торган бер социалист революционер. Ахырда ул: «Мин бик яхшы беләмен аларның акчалары маңгайларыннан тирләрен агызып эшләгән эшчеләрнең эш хакыннан таланып калганын; һәм дә бик аңлыймын аларның корсакларының зураюы, майларының күбәюе шул ярлы кешеләрнең көчендән булганын. Инде шул таланган, йончылган кешенең рәхәт вә сәгадәте өчен үземнең мөкаддәс гомеремне аямаенча «бүләк» итәчәкмен һәм дә аларның аяк асларында тапталган хакларын алуда үземнең куәт вә көчемне аларның киләчәктәге яхшы тормышлары өчен сарыф итәчәкмен». «Алар өчен хезмәт – «мөкаддәс хезмәт, алар өчен тырышу – бәхетле тырышу идекен белдекемдән дөньяда иң бәхетлелекдән саналган «укуымны» ташлап, аларның хакларын алу өчен үземне корбан кылачакмын», дип үз-үзенә сүз бирүче булып, һәм шул «мөкаддәс хезмәт»е өчен гаиләсен ташлап чыгып китә. Атасы да аңа: «Син теләгән юлның, мәхәббәтең төшкән хезмәтнең ишеген ачамын да, син газиз углымны ипдәшләрем хөрмәтенә бүләк итеп, шул ишектән аерылышу йырлары илә озатып каламын», – дигән сүзләре белән улын көрәшкә озата.

Менә әсәрнең төп рухы кая барганы шушы ике каһарман һәм аларның авызыннан сөйләткән сүзләреннән ачык күренә.

Әдипнең «Көлке бер пәрдәдә» дип язган «Безнең заман» дигән мәнзум бер әсәре бар. 1909 елда кечкенә кулда кырык бит зурлыгында басылган бу әсәр мөндәриҗәсе, теле белән дә уңышлы түгел иде. Вәзене дә тик сүз ахырында бетем (кафия) ясап маташудан гына гыйбарәт иде.

Янә бу әдипнең 1915 елда басылган өч пәрдәлек «Ямьсез тормыш» дигән пьесасы бар. Пьеса вак буржуа груһыннан бер гаиләнең

тынычсыз, ямьсез тормышын тасвир итә. Монда эчкенгә салынган һәм шул вакытта «ысулы җәдит» була торган бер комиссионерның гаиләсе алына.

Үзенең наданлыгы, тәгассебе, каенана булучылыгы белән һәрвакыт киленен әрләп, интектереп, аны һәрвакыт иренә башырып торучы «тәсбихле» каенана. Аның кулы астында изелүче һәм иренең эчүе, көн-төн җәберләве астында чахотка булып әверелүче хатын. Һәр өйгә кайтуында исереп кайтып, хатынына җикеренүче, сүзе, эшләре белән һәрвакыт аны газаплап торучы ир. Аталарының һәм карт аналарының каралыгы, искелеге, кирелеге, кысулары сәбәпле бер җиргә чыга алмый торган бер кыз. Реальныйда укыган шаян табигатьле, милләтче, «милли эшләр»не генә кайгыртып йөрүче ул. Менә – «Ямьсез тормыш»ка алынган гаиләнең әгъзалары һәм шушы тормышның каһарманнары. Шуларга үзләре белән катышып йөрүче бер мөгаллим һәм учитель белән бер бай улы һәм бу гаиләнең кызы белән дус булган, үзе гимназия бетергән икенче бер кыз да кушыла. Әсәрдәге вакыйга әнә шулар арасында, шуларның эш-хәрәкәтләрен тасвирдан гыйбарәт. Әсәр ахырында учитель һәм мөгаллимнең әлеге гаиләнең кызын качырып алып китүе, анасының шуның ачуыннан иреннән тиргәлеп, хәлдән таеп егылуы, улының да атасыннан куылып, гаиләне ташлап чыгып китүе, атасының аның артыннан да һаман карганып, сүгенеп калуы, карт ананың «тәсбихен селки-селки, я сөбханалла, үзең сакла!» дип, Аллага сыгынып торып калуы белән тәмам була.

Әсәрнең бөтен сюжеты менә шушы.

Әсәрдә искеләрдән ата белән каенана; яшьләрдән кызларын качыручы учитель белән угылларының типлары бар. Әүвәлге икесе – инде аннан әүвәлге пьесаларда да була торган иске типлар. Әсәрдә үзләренә игътибарны карата торганнары – соңгы икесе. Уллары Рәшад исемле булып, бу – «милләтне тәрәккый иттерә торганнар» тибы. Үзе – «милли эшләр» кешесе дә. Иптәшләре авызыннан әйткәндә, «урта мәктәптә укучы балалар арасында ялтырап торган милләтче». Үзе бик уенчак, шаян, күтәренке табигатьле. Учитель исә «безнең милләтчеләр кануны буенча йөриячәк түгелләр» тибыннан. Үзе – «мәхәббәт исемле илаһның бөтен дөнья милләтчеләреннән көчле бер куәт икәненә» ышанучы бер адәм. Иптәшләре теленнән әйттергәндә, бу тип – «һәрбер татар эшен сүгүче» һәм «милләтне артка өстери» торган кеше. Бу тип түбәндәгечә уйлый: «Миңа эш сөючән, таза, ирекле татар кирәк. Риясыз, тормышка туп-туры карап, шуның

кануннарын ригая кыла[1] торган татар кирәк. Хакыйкать алдында барысы – берсе өчен, берсе барысы өчен көрәшерлек йөрәкле татар кирәк. Бай, көр күңелле татар кирәк. Менә шундый татар – минем хыялымдагы татар; шундый түгәрәк татарны хәзерге безнең тормышыбыз хәзерли алмый. Андый кешеләр дәрвишләр, коллар арасыннан чыкмый, андый татарны яшел миллияткә әсас ителеп бара торган мәктәпләребез дә тәрбия кыла алмый, мин теләгән татарны безнең хәзерге милли матбугат исемле матбугатыбыз да тудыра алмый; халкыма азмы-күпме файда итим дигән һәрбер татар, милләтебезнең туксан процентын ясый торган ярлы татар арасына керергә кирәк. Ярлылык сәбәпле үрчи алмый торган авыл халкына, эшнең иң авырын эшләп тә, акчаның иң азын ала торган завод-фабрика халкына, көн уздыру кайгысыннан үтми торган шәһәр әһалисенә үзләренең кеше икәнен аңлатырга кирәк. Аларның да бүтән милләт кешеләре белән бертигез гомер итәргә хаклары бар икәнен төшендерергә кирәк. Менә шул вакытта гына бездә чын миллият хисе туар, шул вакытта гына безнең өстебездә сәгадәт кояшы күренер!»

Шуның өстенә, үзе авылга барып, тыныч торырга уйлый. Бу ике тип арасында очраганнары саен «татарлык сугышы», милләт өчен кайгыру-кайгырмау көрәше бара.

Әсәрнең теле табигый, җиңел; каһарманнарның табигатьләре белән яраша торган бер рәвештә.

Октябрьдән соң пролетариат-совет җәмәгатьчелек әдәбиятында әһәмиятле һәм мәсьүлиятле мәкаләләре белән актив бер эшчәнлек күрсәтеп килүче бу әдип Октябрьгәчә булган ун ел эчендәге җәмәгатьчелек әдәбиятында да эшләүчеләрдәндер. «Тормыш», «Йолдыз» гәзитләрендә һәм «Аң»да мәкаләләре булып торды. Ул әдәби тәнкыйтьләр дә язды. Димәк, бу каләм – хәзердәге кебек матур әдәбиятта да, җәмәгатьчелек әдәбиятында да тукталмыйча күптән эшләп килүче карт каләмнәрнең берсе.

Ләкин Октябрьдән соң «Татар дине», «Тарих методикасы», «Русия културасы тарихы», «Русия тарихы» кебек тарихчылык юлындагы хезмәте Октябрьдән элек күренмәгән иде. Октябрьдән соң шушы әһәмиятле хезмәтләре дә өстәлде. Шундый фәнни әсәрләрендә бу әдип аеруча җиңел, ачык язучылыгы белән аерылды.

**Шәриф Камал.** Бу әдипнең 1910 елда беренче әсәре булып мәйданга чыккан «Козгыннар оясында» дигән 42 битлек хикәясеннән

[1] Ригая кыла – *биредә:* үти.

соң, аның күп кенә хикәяләре башта «Вакыт» гәзитендә басылып, ул шулар аркылы үзен укучыларга тиз вакыт эчендә танытып өлгерә алды. «Вакыт»та аның хикәяләре көтелеп алынып, сөелеп укыла иделәр. Соңыннан [19]14 елда башка басылмаган хикәяләре дә өстәлеп, «Хикәяләр төркеме» исеме белән урта кулда 195 бит зурлыгында аерым китап булып чыктылар[1]. Аннан соң балык промыселларында эшләүче эшчеләр тормышыннан аның «Акчарлаклар»ы чыкты.

Беренче әсәре булган «Козгыннар оясында» дигән хикәясенә һәм «Хикәяләр төркеме»ндәге хикәяләрнең язылу елларына караганда, бу әдипнең иҗаты 1909 елдан башланган була.

Ш. Камалның асыл көчле талантлы әдип булып танылуы бигрәк аның «Хикәяләр төркеме»ндәге хикәяләр аркылы булды. Беренче хикәясе булган «Козгыннар оясында» дигән хикәясе әле әдипнең өйрәнчек баскычы булып, бу хикәя үзенең теле, әдәби ягы, сәнгатьчә эшләнүе белән әдипнең көчен зур итеп күрсәтә алмый иде. «Хикәяләр төркеме» исә һәрьяктан бу талантның бердән ачылып үсеп киткәнен күрсәтте.

Аның шушы хикәяләрендә без түбәндәге аерым хосусиятләрне күрәбез: аның һәрбер вак хикәясе бер бөек романның мәтене – тезисы урынын тота. Яисә аның хикәяләре, үзләрен сүтеп, җәеп җибәргәндә, һәрберсеннән бөек бер роман чыгачак җеп очы яшерелгән бер ефәк йомгакка охшыйлар. Өзек хикәяләрдә ул роман яза. Шуның өчен хикәяләрен кеше өстән-өстән генә укып аңлап җитү дә җиңел түгел. Аларны укыганда, укучы зиһеннәрен тәмам бер ноктага, шул укылган хикәясенә генә туплап, бик нык уйлап, төшенеп утырып укырга мәҗбүр. Шул вакытта гына аңа әлеге йомгакларның очы табылырга, әдәби кыйммәте һәм мөндәриҗәсе, төп уе тулы, төгәл аңлашылырга мөмкин. Шуның белән бергә ул – татар тормышындагы вакыйгаларны кисәкләп сурәтләндерүче. Ул – татар тормышын, бигрәк тә аның күз яшьле, кайгылы якларын җилкәсенә кисәкләп алып күтәреп килүче бер әдип. Ләкин, югарыда әйткәнчә, аның һәр кисәге – бер роман яисә бер фаҗига, бер трагедия.

---

[1] «Хикәяләр төркеме»ндәге хикәяләрнең өчесе – 1909 елда, уналтысы – [19]10 елда, өчесе – [19]11 елда, алтысы – [19]12 елда, өчесе [19]13 елда язылган булып, барысы 31 хикәядән гыйбарәт. 1926 елда исә, шушы хикәяләрдән сайланып, барысы 17 хикәяне эченә алган хәлдә, «Хикәяләр» исеме белән тәкрар басылдылар. Бу соңгы басмада [19]10 ел язылганнардан – өч, [19]11 ел язылганнардан – бер, [19]12 ел язылганнардан – өч, [19]13 ел язылганнарның барысы да (өч хикәя) – ундүрт хикәя (китапның ярымына якын) керми калганнар. *(Авт. иск.)*

Бу ягы белән Шәриф Камал хикәяләре татар матур әдәбиятында аңарча булмаган яңа бер рәвеш күрсәтәләр. Шул формада хикәя язуны татарда ул иҗат итте.

Шәриф Камал – каләме сүзгә матур, тәгъбиргә бай, тасвирга оста һәм үткен каләмнең берсе. Әдәби икътисад та тәмамы белән монда бар. Садә, кыска җөмләләр белән җиңел өслүбтә язуда ул – иң ачык үрнәкләрнең берсе. Аның хикәяләре һәр ягы белән укырга бик күңелле, төрлекле дә. Бу турыларда Гаязлар аннан күп артта калалар. Ул яктан, татар әдәби телен эшләүдә бу классик әдип зур хезмәт күрсәтте. Үзендә «Вакыт», «Шура»ларның яисә «төркчеләр»нең аз-маз тәэсире дә юк түгел түгелен. Һалә[1], мәга залик[2], интикам[3], әүмүзин, улдыкчә[4], пәрһизкяр[5], әсәре мөляемәт[6], вә дилкәш[7] манзаралар, инзар хыяллары, сакинләрендән[8], мохатәбе[9], анчак[10], парлак[11], раушан, шөйлә ки, хосулә китерәчәгенә (табышка китерәчәгенә), шөбһә билә, мөбһәм[12], вә мөстәһзиянә[13], дәфга[14], имдад наменә[15], мәшьүм[16], лисан («Козгыннар оясында»), гаддаранә[17], ижра[18], димагым[19], рабыйт[20], җәмгыяте бәшәрия[21], тәвәҗҗеһ[22], тәхмил[23], тәхәйел[24] («Хикәяләр төркеме») кебек сүз-тәгъбирләр – шул тәэсирнең галәмәтләре. Ләкин болар уңган ашлык эчендә үскән, анда-санда сирәк кенә күренеп утырган артык зарарсыз үләннәргә охшыйлар. Алар белән әсәр күп зарарланмый.

[1] Һалә – ай яки кояш тирәсендә була торган нур боҗрасы.
[2] Мәга залик – шуның белән бергә.
[3] Интикам – үч.
[4] Улдыкчә – булганчы.
[5] Пәрһизкяр – саклаучы.
[6] Әсәре мөляемәт – йомшак күңелллелек билгесе.
[7] Дилкәш – күңелне үзенә тартучы.
[8] Сакинләрендән – билгеле бер урында торучылардан.
[9] Мохатәбе – тыңлаучысы.
[10] Анчак – бары тик.
[11] Парлак – йолдыз.
[12] Мөбһәм – аңлаешсыз.
[13] Мөстәһзиянә – көлеп, мыскыллап.
[14] Дәфга – берьюлы.
[15] Имдад наменә – ярдәм хакына.
[16] Мәшьүм – шомлы.
[17] Гаддаранә – хыянәтчел рәвештә.
[18] Ижра – үтәү, эшкә ашыру.
[19] Димагым – баш мием.
[20] Рабыйт – союз.
[21] Җәмгыяте бәшәрия – кешелек җәмгыяте.
[22] Тәвәҗҗеһ – караш, илтифат.
[23] Тәхмил – сылтау.
[24] Тәхәйел – хыяллану.

Янә бу әдип каләмендә бераз кабиләчелек – мишәр шивәсе тәэсире астында калучылык бар. Шул ук сәбәп белән булса кирәк, анда бәгъзе урыннарда рус теле өслүбенең дә тәэсире күренә.

Шәриф Камал – татар әдәбиятында башта ук реалистлык сызыгын алып яза башлаган әдип. Тик шуңа аның татар романтиклык шомлыгыннан котылып җитә алмавын гына кушарга кирәк. «Илаһи»лык, «гүзәллек тәңресе»лек, дини «гает»ләрдә «елатмаучылык», шул гаетләрдә әллә нинди мәгънәви көчләр тәэсире белән күңелләрне йомшартучылык, әллә нинди илаһи шәфкать хисләрен кузгатучылык, шулай ук дөньяны вафасыз һәм бәхетсезлек оясы итеп күрсәтүчелек чиренең йогынтысы бар. 1907–1915 еллар арасында татарда көч алган әдәби чирнең тәэсиреннән, шулай итеп, бу әдип тә тәмам котылып җитә алмаган күренә.

Шәриф Камал кеше тормышын, андагы бәхетлелек, бәхетсезлекләрне (бигрәк тә бәхетсезлекләрне) табигать хадисәләре, аларның күңелсез, куркыныч вакытлары белән бергә бәйләп алып бара. Анда кешеләрнең психологик якларын үзенең килешле сүзләре, тәгъбирләре белән ачып бирә алу хосусияте нык сизелә. Гомумән, бу әдиптә хистән элек акыл-төшенү эш итә. Акылны хис артыннан ияртү монда юк, яисә бу хәл анда аз очрый. Хискә мәгълүб булып киткән чаклары да юк түгел. Ләкин аннан аны акыл тиз аралап ала. Ул күбрәк тыныч, басынкы каләмле. Табигый акыллы иттереп көлү дә бу әдип әсәрләренең иҗаби якларыннан.

Үз вакытында эшчеләр-пролетариат тормышын тәмам реаль юл белән язучы әдипнең дә беренчесе шул иде. Ләкин анда пролетариатның идеология яклары катыштырылмыйча, тик реаль тормышларын тасвир гына алына.

Шәриф Камал хикәяләренең мөндәриҗәләре күбрәк татарның иҗтимагый-гаиләви тормышларының аяныч якларын, гаиләви фаҗигаларны, гаилә тәрбияләрен тасвирдан гыйбарәт. Татарның иҗтимагый-гаиләви тормышының аяныч, шомлы яклары, иҗтимагый фаҗигалары әдипне күбрәк мәшгуль итәләр.

Татар ханнарының дәүләт фаҗигасы, хатын-кызлар турындагы җинаятьләре, татар кызларының ятимлек бәхетсезлекләре, яшь кызларның алтмыш-җитмеш яшәрлек картларга икенче хатынлыкка барып һәлак булулары һәм башка фаҗигалары яисә «үзенең кара язмышы тарафыннан гаддаранә[1] сурәттә изелгән бичара»лар, «кыз-

[1] Гаддаранә – хаиннарча.

ганыч, мескен ятим»нәр, «үксез балалар белән үз көнен ничек үткәрергә белмәүчеләр», «хаклыкны әйткән өчен» таяк җыючы һәм таяк җыйдыручылар, эчкечелеккә мөбтәля булучылар һәм аларның хатыннарын җәберләүләре, шул юлда җинаятьләре, акылдан язучылар; хатын-кызларның төрлечә алдану, мәсхәрә ителүләре, ир өстеннән икенче ирләр белән йөрүчеләр, сукбайлар һәм аларның гаиләви бәхетсезлекләре; аталарның балалар кулында карт гомерләрен кызганыч үткәрүләре, ике-өч хатын алу шомлыклары, бай, мирза балаларының бәхетсезлекләре, хезмәтчеләр, эшчеләр һәм авыр тормышлы эшче гаиләләренең төрле хәлләре – менә аның хикәяләренең төп мөндәриҗәләре шулар. Боларга тагы бәхет эзләүчеләр, татар шәкерте, татар мөгаллимнәренең хәлләре, аларның табигать һәм мөгамәләләре, Гает хиссиятләре, татарның җәмәгать хадимнәренең эшләре кебекләрне көленеч рәвештә тасвирларын кушарга кирәк.

Ш. Камалның татарның иҗтимагый-гаиләви хәлләрен, тормышларын тасвирында һәрвакыт табигать хадисәләре, табигатьтәге нәрсәләр (ай, кояш, йолдызлар; кошлар, мәче башлы ябалак, каргалар) шаһит булып торалар. Анда табигать һәм табигать хадисәләре күп вакыт кеше белән бергә елый. Кеше тормышының күңелсез, кайгылы яклары табигатьнең дә күңелсезлеге, моңлылыгы белән бергә йөртелә. Аның хикәяләре «я моңлы тынлык» белән яисә үкереп торган көчле җилләр, давыллар, тузаннар, мәче башлы ябалак, карга тавышлары – кыскасы, куркынычлы табигать хадисәләре белән бергә дәвам итәләр. Каберләр һәм аларда «кәфеннәре белән торган» үлекләр, мәетләр дә аның хикәяләрендә кайгы моментларын уртаклашалар. «Моң вә зар көйли торган тавышлар» аның хикәяләрен укыганда колак төбендә гел чыңлап торалар. Шулай ук аның хикәяләрендә «үлемнең куркынычлы бармаклары» бар.

Аныңча, адәм хәяты үзе үк «табигатьнең моңлы бер чыңлавы»на охшый да, ул шуның кебек «яңгырый, озая, сүнә...». Анда «мөтәфәккир урманнар» бар. Анда кешедәге «өмет вә хыяллар кара урман арасына яшеренгән убыр карчыклары булып карыйлар» да «элекке алдаулары белән мактанып көлә, бармак яныйлар». Шулай ук «йолдызлар гүя күз яше аркылы карап елмаялар...»

Ш. Камал хикәяләрендәге каһарманнар я төш күрәләр яисә үз эчләренә чумылып әллә нинди хыялларга баталар. Аның хикәяләрендә ата-ана, туганлык мәхәббәтләре нык аңкый. Аның каһарманнарының кайсысы «вәхши хиссият, вәхши шигырь» сөяләр, шуны эзләп маташалар. Ш. Камал хикәяләрендә күплектә – «бәдбинлек»

(дөньяга өметсез, бәхетсез караш), азчылыкта «җәмгыяте бәшәриянең[1] иң бәхетле, иң мәсгуд[2] бер кисәгенең нәмунәсе[3]» бар. Алар гүя матур бакчалардагы шау-шулары, кәеф-сафалары белән күплектәге «бәдбинлеккә каршы» «демонстрация» ясыйлар... Кешелек тормышы анда бик чуар, «чуар манзара»лы.

Аның хикәяләрендә ана мәхәббәте дигән нәрсә дә – аңлап түгел, сизелеп кенә беленә торган «бер илаһи шигырь». Анда үлгәннәр «фикергә калып көлемсерәгән төсле һәм ерактагы яшерен бер куәт тарафыннан тартылган, шуңа тәвәҗҗеһ иткән[4] булалар. Анда кеше үлгәндә, аны «яшен кебек очыртып, әллә кайларга алып бара торган» «дәһшәтле бер куәт» бар.

Ш. Камал хикәяләренең кайберләрендә төп максат, төп уй бер дә ачылмый, тоелмый кала. Ягъни әдипнең ул хикәяне ни өчен язганын ачык аңлый алмый каласың («Чит илдә», «Сәмруг кош» кебек хикәяләре шулар җөмләсеннән).

Шушы югарыдагыларны игътибарга алганда, Ш. Камал, бер яктан, чын реалист бер әдип булса, икенче яктан, ул вакыты белән романтик-идеалист та булып китә. Анда дини, илаһи тойгыларны нык аңкыта торган хикәяләр дә юк түгел.

Ш. Камалның иҗатларында тагы шундый бер кызык хәл күренә: ул, гүя һичбер алдан уйлап-нитеп, план-фәлән сызып тормыйча, каләмен татарның иҗтимагый-гаиләви тормышының нинди дә булса бер ноктасыннан башлап кузгатып алып китә дә, инде моны ничек итеп тәмамлый алыр икән дип аптырап торганда гына, ул шуны матур гына, планлы гына итеп тәмамлый да куя. Кыскасы, плансыз башлап та, планлы булып тәмамлану – менә Ш. Камал иҗатларының төп бер хосусияте шунда.

Әдипнең, югарыда да әйткәнебезчә, башкалардан аерым ягы эшчеләр – шахтёрлар, балык һәм нефть промыселларында эшләүче татар эшчеләренең көндәлек тормышларын яхшы ук тулы иттереп татар әдәбиятында беренче мәртәбә бирүендәдер. Ләкин революциядән соң аның язганнары аз әле. Шулай да Октябрьгәчә эшчеләр-пролетариат идеологиясе белән сугарылмастан, сыйнфый каршылыкларны күрсәтмәстән, тик аларның тормышларын гына тасвир итүче бу әдип Октябрьдән соң шул сыйныфның идеология-

[1] Җәмгыяте бәшәриянең – кешелек җәмгыятенең.
[2] Мәсгуд – игелекле.
[3] Нәмунәсе – үрнәге.
[4] Тәвәҗҗеһ иткән – йөзне юнәлткән.

се белән сугарылып яза башлады. Аның соңыннан «Безнең юл»да (1925 ел, 9–10 нчы сан, [19]26 ел, 4 нче сан) язганнары советлашкан авыл, советчы крестьяннар тормышыннан язылдылар. Боларда советчылык, пролетариат идеологиясе белән сугарылу бар инде.

Шул рәвешчә, Шәриф Камал – Октябрьгәчә җитешеп, аңарча эшчеләр тормышыннан язып килеп тә, соңыннан Октябрь, пролетариат идеологиясе белән сугарылып, әдәби хезмәтен шул сызыкта дәвам иттерүче классик әдипләрнең берседер.

**Мирхәйдәр Фәйзи.** Икенче әдәби дәверебезнең икенче баскычының беренче биш елы эчендә, ягъни 1910 елгача татарда җәдитлек, кадимлек, искелек – яңалык тартышы көч алып, иҗтимагый роль дә татар либераль буржуазиясе кулына күчкәнлектән, татар әдәбиятының киң үлчәүдә алган мөндәриҗәсе шәһәр байлары, шәһәр яшьләре, яисә руханилар: муллалар, мәзиннәр, суфилар, ишаннар, абыстайлар, ниһаять, җәдитче татар зыялылары, татар мөгаллимнәре тормышыннан, шуларның башыннан кичеп-кичерелеп торган вакыйгалардан алына килде. Әмма эшче-крестьян тормышына әле керелми иде. Тик бары 1905 елгы революция һәм шул замандагы иҗтимагый-сәяси хәрәкәтләр кызулыгы белән ул вакыт эчендә Гафур Коләхмәтовның татар пролетариаты хәрәкәтеннән, шуларның идеология көрәшләреннән алынып язылган «Яшь гомер»е белән Ф. Сәйфинең «Мөкатдәс хезмәт»е генә мәйданга чыгып кала алды.

Ләкин бу әдәбият җәдитче байларны, шәһәр халыкларын, татарның җәдит имамнарын, зыялыларын, мөгаллим-мөгаллимәләрен канәгатьләндерсә дә, татар пролетариаты, эшче-крестьян гаммәсенең, бигрәк тә эшче-крестьян яшьләренең һәм алар эченнән чыгып әдәбият укучы, әдәбият белән шөгыльләнә башлаучыларның, бара торгач, аның белән генә канәгатьләнеп җитү ихтималы юк иде. Үз генә бер зәмин һәм үзләрендә үз генә бер психологик хәзерлек күрелү белән, башканы сорый башлаячагы анык иде.

Ахырда бу шулай булып чыкты да. 1910 елларда инде эшче-крестьян гаммәсе өчен әдәбияттан аның үз тормышы, үз вакыйгалары, үз тормышында булган фаҗига яисә көлкеләр, кызыклар һәм дә үз типлары сорала башлады. Эшче-крестьян гаммәсендә шуны укырга теләү, сәхнәдә дә шуларның сурәтләнүен күрәсе килү һәвәсе туды, шуңа психологик бер хәзерлек күрелде. Икенче яктан, шулар өстенә, теге иске мәүзуг, иске мөндәриҗәләр инде аларны ялыктыра да башлады. Татарның иҗтимагый-мәдәни хәрәкәтенә әкренләп шул груһ адәмнәренең катышырга итүе дә сизелде.

Ниһаять, әнә шушы яңа һәвәс, яңа сорауларга җавап бирә торган һәм, шул юл белән булса да, татар буржуазия хәрәкәтенә оппозиция ясап барырга теләүче яңа әдипләр мәйданга чыкты. Әсәрләрендә мәүзуг, мөндәриҗәләрне ярлы, батрак, эшче-крестьяннар тормышыннан, крестьян яшьләре хәрәкәтеннән, шуларның төрлечә омтылыш һәм көрәшләреннән алып яза башлаучы Галимҗан Ибраһимовның хикәя, романнары («Көтүче», «Ялчы карт», «Яшь йөрәкләр»е) белән татар пролетариаты, шахта һәм төрле промыселларда эшләүче татар эшчеләре тормышын сурәтләндерүче Шәриф Камал хикәяләре шул яңа сорауларга беренче җавап булып төштеләр.

Шулай итеп, 1910 еллардан башлап, татар матур әдәбиятының беллетристика бүлеме яңа дөньяга кереп, үзенә яңа мәүзуг, яңа мөндәриҗәләр ала башлады. Ләкин татар театр әдәбияты, бу рәвештә үзенә эшче-крестьян тормышын мәүзуг, мөндәриҗә итеп алып, татар сәхнәсендә аларны сурәтләндерүдән мәхрүм иде әле. Татар сәхнәсендә: авылында да, шәһәрендә дә – һаман шул баягы югарыда әйтелеп үтелгән иске мөндәриҗәләр, аңарчы үз кулында иҗтимагый ролен нык саклап килүче югары сыйныф тормышы сурәтләндерелә, һаман-һаман шулар тәкрарлана бирә иде.

Авыл-крестьян яшьләре белән авыл картлары арасында үз тормышлары эчендә элек-электән иҗтимагый көрәшләр булып килгәне мәгълүм. Бер яктан, авылның олылары, аксакаллары, руханилар үзләре тарафыннан төзелеп, нык сакланып килгән иске тук тормыш кагыйдәләренә, ата-баба йоласы һәм дини тәгассебләргә яшьләрне тәмам буйсындырып, аларны үзләренчә тәүфыйклы, әдәпле итү юлында уллары, кызлары, эне-сеңелләре өчен иң кысынкы бер тәртип сакларга теләсәләр, икенче яктан, авылның яшүсмерләре, яшьлек һәвәсенең теләве буенча, шушы каты, кара кысынкылыкларга каршы төрле төстә, төрле рәвештә көрәш алып баралар; шундый тар рамкаларны ватарга, җимерергә омтылалар иде. Аксакаллар, руханилар тарафыннан авыл-крестьян яшьләренең төрле яшьлек уеннарыннан, егетләр, кызлар җыелып, яшьлек кызыкларын бергәләшеп үткәрергә тырышуларыннан (бергәләшеп төрле күңел ачу утырышлары ясау, скрипка, гармун уйнап, җырлап урамнарда йөрү кебек эшләрдән) каты тыелулары шул җөмләдән иде. Шуларга янә шул ук татар ата-аналары, аксакаллар, руханилар шомлыгыннан егет һәм кызларның үз теләгәннәре, үз сөйгәннәренә өйләнә алмау фаҗигаларын кушарга кирәк.

Менә бу хәлләр, шөбһәсез, эшче-крестьян яшьләренең үзләренчәрәк яшәргә теләүләренә каршы каты бер хәрәкәт һәм аларның

яшьлек ирекләрен картлар, мөтәгассыйблар кулында буып тотудан башка нәрсә түгел иде.

Бик табигый бер эш булып, боларга каршы яшьләрдә ачу кабарды. Аларда шушы иске кагыйдә, иске ганганәләрне җимерергә омтылу хәрәкәтләре, көрәшләре дә моңа бер яктан ярдәм итешә иде. 1910 елларда инде авылларда бу хәл, искелек кысынкылыгына каршы бу ачу хәрәкәте ачык сизелә башлаган иде. Шуның өчен бу юлда яшьләр арасыннан үз каһарманнары, үз типлары да күзгә байтак ташлана иде.

Мирхәйдәр Фәйзи татар театр әдәбиятында әнә шул якларны тасвирчы булып чыкты. 1913 елда язылып уйнала башлаган (басылуы – 1925 тә) «Авыл бәйрәме» дигән пьесасы белән, 1916 елда язылып та, басылмас борын ук авыл һәм шәһәр сәхнәләрен шаулатып, татарда һичбер күрелмәгән рәвештә әллә ничә еллар буенча татар сәхнәләреннән төшми йөрүче (тик бер Казанда гына егерме мәртәбәләр уйналган) «Галиябану» драмасы шул юлдагы беренче адымнар иде. «Авыл бәйрәме»ндә картлык тәгассебе, дин исеменнән булган каты кысынкылык белән яшьлек һәвәсенең тартышы сурәтләндерелә. Яисә картларча яшәү белән яшьләрчә яшәү, тагын да кыскартып әйтсәк, картлык белән яшьлек көрәше күрсәтелә. Монда Йосыф, Касыйм, Шәйхи, Бәхтияр, Заһидлар (бусы шәһәр яшьләреннән) – яшьлек һәвәсенең, яшьлекне яшьләрчә үткәрергә теләүчеләрнең, авылның шук, уйнак табигатьле егетләренең вәкилләре, шуларның типлары.

Болар – «яшьләр яшьнәп яшәргә тиеш; картлар, яшен сукмасын дип, ләхәүләсен укып, почмакта ята бирсен»; «аларның (картларның) тузган миләре яшь заманның үзгәрешләрен сыйдыра алмый»; «иске тормыш какшады, яшь тормыш бәйрәм итә»; «хәзерге заман яшьләрнеке инде, аны пычратырга теләүчеләргә безнең йөрәкләребез яшьнәми кала алмый»; «без – замана баласы, картларның сызып куйган сызыкларына гына сыя алмыйбыз» дип аңлап, карт тормышны яшь тормышның җиңүе өчен күмәкләп җырлап, ду килүчеләр. Болар – заманнарында шулай итеп яшьлек куәте белән картларга каршы гыйсъян күтәрүче авыл яшьләре, авыл батырлары. Йосыф, Касыйм, Шәйхиләр – авылның шул вакытлардагы аеруча шук, батыр яшьләренең типлары. Мәгърүф, Сөбхи кебекләр – шуларның хатын-кызлар арасыннан чыккан иптәшләре. «Яшьләр йөрәге кебек шыгырдап торган йөрәк»ле, шук табигатьле Әхмәдулла агай да – картлардан аларның таянычлары, яклаучылары. Аның хатыны Шәфкыйҗәмал белән Шәгъбән суфи да – иске тәртип сызыгында

торып, дин исеменнән яшьләрнең яшьлек һәвәсләре белән көрәшеп килүче бәндәләр тибы, шуларның вәкилләре.

«Галиябану»да исә ярлы, урта хәлле крестьян яшьләре белән күп җир биләүче бай крестьян яшьләре арасындагы каршылыклар, көрәш һәм интригалар; урта крестьянның ничек бай крестьяннар – авыл кулаклары тәэсире астында булуы; шул сәбәпле, кыз алу, кыз бирү кебек иҗтимагый-гаиләви мәсьәләләрдә дә нинди юлсызлыклар, нинди алданулар, нинди фаҗигалар килеп чыгуы, кызларның үз сөйгәннәренә бирелмәү трагедияләре тасвир ителә. Шул юл белән монда «үткән дәвер крестьянының соң дәрәҗәдә вак милек хирыслыгы, акча өчен кызын сатар дәрәҗәдә комсызлыгы да ачыла» бара.

Шуның белән бергә, «беренче мәртәбә диярлек һичбер буяусыз, саф, булганча, үзләренең уен көйләре, җырлары, музыкалары, гыйшыклары, интригалары, бәетләре, көрәшләре белән крестьян егетләре, крестьян кызлары бу әсәр аркылы безнең театр галәменә килеп керәләр»[1].

Фәйзинең «Авыл бәйрәме»ндә сыйнфый каршылык ачылмастан, тик крестьян яшьләренең яшьлек дулкыннары, яшүсмерлек кызыклары, үзләренчә, яшьләрчә яшәргә омтылулары, кыскача әйткәндә, анда тик яшьлек – картлык көрәше тасвир ителгән иде. «Галиябану»да шулар өстенә сыйнфый каршылыкларны күрсәтү хосусияте дә кушылды. Монда, моның аркылы, «тормышның һәр катлавында, һәр дәверендә төрле төстә, төрле зәминдә була килгән сыйнфый каршылыкларның мәхәббәт, гыйшык турыларында да, гаилә төзелешләрендә дә үзен китереп чыгаруы» крестьян тормышының үз эчендә, үз тормышыннан бик табигый һәм саф реаль бер юл белән күрсәтелә.

М. Фәйзи татар театр әдәбиятында, шулай итеп, чыннан да яңа бер әдәби сукмак салды. Бәлки яңа бер мәктәп тудырды. Авыл-крестьян яшьләренең яшьлек дулкыннары, крестьян яшьләре арасында үсеп килгән иҗтимагый-сыйнфый каршылыклар – менә бу яңа әдәби сукмакның ике баш ноктасы шунда.

Бу әдип аркылы башланган яңа әдәби сукмакның дикъкатьне үзенә нык җәлеп иткән бер ягы театр әдәбиятыбызга җыр, музыка кертүендә күренде. Шуның белән ул татар драма әдәбиятына яңа бер орлык салды. Соңыннан Ф. Бурнашның «Яшь йөрәкләр»е, К. Тинчуринның җырлы, музыкалы театр әсәрләре кебекләрнең һәм

[1] Галимҗан Ибраһимовның «Галиябану»га язылган мөкаддимәсеннән. *(Авт. иск.)*

дә [19]25 елларда «Сания» кебек татарда беренче операларның килеп чыгуына юл ачты, шуңа зәмин хәзерләште.

М. Фәйзинең соңыннан ([19]24 елда) «Асылъяр» исемле биш пәрдәлек янә бер драмасы чыкты. Ләкин монысы идеология ягыннан хәзерге таләпкә җавап бирә алмаслык һәм психологик яктан карагандa яңлышлыкларны (13 яшьтәге Ләлә белән Шәрәфнең бер-берсенә каршы баштагы мөгамәләләре кебек хәлләр) эченә алган булса да, теле-өслүбе ягыннан бу да югарыдагы әсәрләре янына куела ала.

М. Фәйзи каләме аркылы татарның авыллардагы саф, садә, матур гаммә өслүбе татар драма әдәбиятына үзенең әдәби киңлеге белән килеп керә алды. Моның югарыдагы әсәрләрендәге каһарманнар авызыннан сөйләнгән сүзләр, үзләренең сарфи-нәхәви яклары, лөгать байлыгы, әдәби матурлыклары, табигыйлекләре һәм тормышлы булулары белән игътибарны үзләренә аеруча карата алалар.

Гомумән, М. Фәйзи әсәрләрендә шаулап, котырып торган табигый хәят, эшче-крестьян яшьләренең шау-шулы, ирекле тормышы, шул тормышның шуклыклары кебек мутлыклары бар. Татар әдәбиятында менә бу хосусият тә М. Фәйзидә башлап күренде. М. Фәйзи әсәрләрендә әнә шушы югарыда күрсәтелгән хосусиятләр һәммәсе җыелып килеп, бу әдипне, шөбһәсез, татарның классик әдипләре тезмәсенә куйдырталар.

Шуның өчен дә аның әсәрләре, бигрәк тә «Галия»се, татар сәхнә дөньясын башка һәммә әсәрләрдән артык шаулата алды. Бигрәк тә «Тигезсезләр» кебек пьесаларның татар сәхнәсенә килеп керүләре татарның нечкәргән, назикләнгән шәһәр публикасын, «әһле ислам»ын, «кибар[1] гаилә»ләрен, вак буржуа балаларын ничек шатландырган булса, «Галиябану» кебек крестьян драмаларының татар сәхнәсенә аяк басуы да крестьян яшьләрендә, авыл публикасында шулкадәр үк зур шатлык тудырды.

Драма әсәрләрен ничә мәртәбә уйналулары ягыннан, ягъни статистика методы белән дә үлчәүчеләр бар. Драма әсәрләренең халыкның кирәгенә, таләбенә күпме туры җавап биреп, бирә алмавын да алар шул яктан күрсәтергә тырышалар. Сәхнә әсәрләренә бәя биргәндә, менә шушы методның, әлбәттә, кирәге бар. «“Галиябану”га бу метод белән үлчәү куйганда, аның тик бер Казанда гына 20–30 мәртәбә уйналуын игътибарга алу гына да җитә. Шуның белән бергә, марксизм пролетариат тәнкыйть дөньясы да башта

[1] Кибар – аристократ.

ук моны күтәреп алды» («Галиябану»га мөкаддимә итеп язылган тәнкыйть – Галимҗан иптәш Ибраһимов тәнкыйте)[1].

**Шәехзадә Бабич.** Бу шагыйрь татар телендә башкорт йөрәгеннән Урал моңнарын җырлап дөньяга чыкты. Ул башлап әдәбият мәйданына кергәндә, татарның әдәби теле яхшы ук эшләнеп, баеп, матурланып киләдер иде. Бабич, әдәбиятыбызның бу хәзинәсеннән бик нык файдаланып, үзен эшләтте. Ягъни әдәби телебезнең, шигырьнең мәктәбен төрле баскычлары аркылы яхшы үтте. Ул яза башлаганда, бездә бик күп төрле иске һәм яңа вәзеннәр эшләнеп, билгеле бер эзгә төшкәннәр иде. Бабич исә үз алдында торган бу киң әдәби байлыктан файдалана белде. Ләкин аның әдәби байлыгының иң зур бер чишмәсе халык әдәбияты иде. Ул татарныкыннан, казакъныкыннан, аннан да бигрәк бөтен киңлеге белән башкорт халык әдәбияты чишмәсеннән туйганчы эчә алды. Шул ризык, шул әдәби куәт белән татар әдәби мәйданында җырларга тотынды. Аның чишмәләре шундый төрле, бай булганлыктан, аның теле, вәзеннәре бик җиңеллек, бик садәлек белән уйнап, шаярып, рәхәтләнеп, үз-үзеннән агып торалар. Ул гүя башкалар өстенә матур чәчәкләр сибеп шаярып йөрүче бер яшь җилкенчәккә охшый.

Бабич татарда икенче дәвер ахырында җитешкән иң көчле яшь талантларның берсе иде. Ләкин көтелгән күп кыйммәтле җәүһәрләрне биреп бетерә алмыйча, гомере бик яшьләй һәм бик фаҗигалы рәвештә тәмам булды. Шулай да ул, әгәр исән булган булса иде, революция рухында бик күп әдәби җәүһәрләр биргән булыр иде. Бабичны аңлату өчен берәр охшату ясаганда, аның турында болай әйтергә мөмкин: татар тормышындагы өметлелек белән өметсезлек, тормыштан риза булучанлык белән риза булмаучылык, яктылык белән караңгылык, яшәү дәрте белән бетү куркынычы арасында хасил булган иске аралаш яңа, милли туфракта үсеп чыгып, шул туфракка, шул һавага муафыйк рәвештә тиз чәчәк атып өлгергән карарсыз, төрле төсләр күрсәтүче бер гөл – уйласагыз, Ш. Бабич әнә шушы гөлнең үзе булыр. Октябрь белән үзгәргән һава, иҗтимагый революция белән алмашынган туфрак аңа тиз, нык тәэсир итеп, аның чәчәкләрен дә алыштырды. Ниһаять, матур кискен революция гөле төсен алды. Бабичның әүвәлге шигырьләрендә дә дөньяга нәфрәт аралаш нindидер бер көчле ихтилалчылык чаткысы сизелә иде. Февраль-Октябрь революциясе белән шушы чаткы үзенең асыл төсен ачып бирә алды; шул чаткы тизлек белән кызыл төскә әйләнде.

[1] «Театр мәҗмугасы», Г.Сәгъди, 47 бит. *(Авт. иск.)*

Бабич шигырьләрендә үзендә көчле ялкынлы зур көч сизеп, бик зурга, югарыга таба нык омтылган бер шигъри талант гәүдәләнә. Ул талант та – бер яктан, көчле индивидуаль бер чаткы булса, икенче яктан, куәтле иҗтимагый бер ялкын, йөрәгендә революция дулкыны тиз кабынып киткән кискен бер әдәби куәт. Аның шигырьләренең бер тармагы – шәхси моң-зар, икенче бер тармагы да – иҗтимагый хәсрәтләр, иҗтимагый дәртләр чишмәсе. Ул «ярсыну» белән «тарсыну», «эзләнү» белән «сызлану» арасында кайнаучы бер шагыйрь булды. Күз яшен түгә-түгә гайрәтләнү, гайрәтләнә-гайрәтләнә күз яшен түгү хосусиятен дә шуңа кушарга кирәк. Елый-елый көлү, көлә-көлә елауда да ул татар шагыйрьләре арасында аерымлык күрсәтә иде.

Бабич шигырьләрендә бай, киң, үткен мөндәриҗәле охшатулар, табигый тасвирлар бар. Әз гомерендә күп яхшы шигырьләр язган бу талант татар теленә бу яктан күп байлык, киңлек бирде. Болар иң садә, иң җиңел телдә язылганнар. Тасвирны характерландыру өчен алынган бәгъзе гарәпчә сүзләре аның садәлеген бозмыйлар.

Бабич шигырьләренең мөндәриҗәсенә килгәндә, берәүнең бик муафыйк бер тәгъбире белән әйтсәк, «иске савытларга яңа эчемлекләр тутыру»чы иде ул. Аның индивидуаль характердагы шигырьләре дә, иҗтимагый һәм революция рухындагы шигырьләре дә шулай булдылар. Аның «Кем өчен», «Бер тәмсил», «Китабеннас фи хаккылхәвас», «Газазил»ләре моның өчен аеруча ачык мисал була алалар. Икенче дәвер эчендә яшәгән бөтен мәшһүр җәмәгать хадимнәрен, әдип вә шагыйрьләрен (барысы 200дән артык) оста һәм күбесендә бик характерлы үткен тәгъбирләр белән тәнкыйть итеп, камчылап күрсәтүче «Китабеннасы»ы татарда беренче яңа мөндәриҗәле үрнәк булса, «Газазил»е дә дини хорафатны чын, киң һәм бик көленеч бер шигъри сурәткә салып бирүче иң кыйммәтле бер әдәби җәүһәр булып калды. Шунысы үкенеч: аның бу поэмасы тәмам була алмаган хәлдә тора. Я аны шагыйрь үзе тәмам итә алмады яисә тәмам ителгән хәлдә басыла алмастан тәләф булды[1].

Шагыйрь – рухы белән материалист түгел, идеалист иде. Аның шигырьләрендә «илаһилык», «илһамчылык», «ходайчылык», «сәмавилек» шаукымнары да юк түгел («Яшь шагыйрьгә» һәм «Афәрин» дигән шигырьләре).

Шагыйрьдә романтиклык чаткысы да көчле булып, ул:
Уйладыңмы, хөр яшәрмен дип, бәхетсез җирдә дә?!
Ник ябылдың соң алайса «тән» исемле төрмәгә?!

[1] Тәләф булды – югалды.

Чык, җаным, тән зинданыннан, күккә оч, ямьлән янә,
Җиргә төшсен, ал шәфәкътәй алланып, шәүлә генә[1].

һәм:

Вaклыгы белән җиһанның вакланасым килмәде.

һәм:

Дөньяда җанга тынычлык юклыгын белгәч тәмам,
Мин әле яшь дип, үлемнән тартынасым килмәде.

һәм:

Чөнки биздем дөньядан, артык торасым килмәде, –

рәвешле Тукайның зарлануына охшаш зарларны да җырлады[2]. Бабич каршында да җир «каргалган җир» булып, «сөю, вөҗдан, иман, хаклык кебек матур сүзләр сәмави сүз, күктә алар», дөнья да, аның-ча, «ялган».

Бабич, бер яктан, Сәгыйть Рәми шикелле үк, анархи-индивидуалистлык та күрсәтеп ала. «Дөньяда» дигән шигыре – шуның нәтиҗәсе.

Монда ул: «Үз маягымны үземчә кадап, үз сабагымны үземчә аңлап, күкләргә очармын, йолдыз кичәрмен, теләсәм нишләрмен, мин – ирек ханы!» – ди. Шуңа өстәп: «Мин үзем – әдәп», үзем – «нәзакәт», дөнья үземә итсен итагать! Иманым – үзем!.. Коръәндер – сүзем!!!» – дип, тәмам үз башына оча. Үзенең үзлегенә генә табынып, үз башына бөтен дөньяга каршы гыйсъян күтәрергә тели.

Ләкин, ничек булганда да, аның бу сүзләрен үзе турында аның кыска гына әдәби гомере дә, аз гомерендә язып өлгергән шигырьләре дә тәмам распадылар. Ул, югарыда әйтелгәнчә, «үз маягын» үзе һәм «үзенчә» кадады. Татар шигырь дөньясына үзенчә мөндәриҗә ягыннан яңа, матур маяк утыртты. «Үз сабагын» үзенчә аңлап, «ирек» юлында «теләсә нишләргә» теләде. Үзенә үзе нык «иман» итте. Үз сүзләрен дә мөэминнәрнең Коръәннәреннән артык күрде. Әдәби зур батырлык, зур көч, зур талант күрсәтеп үлде.

Шулай, Бабич «ирек» теләп кайнады, иреккә таба омтылды. Тик шунысы бар: ул башта үзенең кайгырткaны һәм җырларында үзе өчен җырлаганы «саф йөрәк», алтын, ярлы-мескен, кызганыч, туган халкы өчен кирәкле булган ирекнең нинди мәгънәдә һәм нинди рәвештәге «ирек» булуын, үзе һәм халкы өчен нинди ирекнең файдалы икәнен белә алмыйча каңгыру, шул юлда төрле якка чайкалу

[1] Ш. Бабичныйң «Җанкаем!» (1917) шигыреннән.
[2] «Көрәшеп үткәр кыска гомереңне» дигән шигыре дә тәмам шул рухта. *(Авт. иск.)*

фаҗигасын үткәрде[1]. Идеалда, иҗтимагый-сәяси якларда «уңга», «сулга» боргаланды, ләкин соңыннан аны тәмам аңлап, чын ирек – большевизм иреге юлына төште. Аның башкорт телендә башкортларга каратып язылган «Без ник кызылларга кушылдык» дигән шигыре шул аңлауның якты чулпаны булып калдылар. «Байларга», «Мөртәт социалистларга», «Афәрин»нәре дә шуңа кушылалар.

Бабич, татар шагыйре булу белән бергә, башкорт шагыйре иде. Ул яңа башкорт әдәбиятының беренче төзүчеләреннән булды. Ул башкорт телендә дә байтак шигырьләр язды, ахыр гомерендә башкортлар азатлыгы юлында корбан булды.

**Фәтхи Бурнаш.** Икенче дәвернең ахырында татар идеологиясенең дингә, дини хиссияткә таба авышуы бик нык көчәя иде. Элекке дәһри С. Рәмиевнең [19]14 елдан соңгы бөтен шигырьләре дингә манчылып чыкты. 1905 елда дингә җиңел, өстән караган Гаяз Исхакый да бу вакытларда инде, исламны идеаллаштырып, үзенең «Зөләйха»сын язды. «Көндезге сәхәр»ләр, «Ташмөхәммәт»нең «Фәтхулла хәзрәт»ләре белән динчеләрдән көлгән Ф. Әмирхан, «Тигезсезләр»не язып, динне, җәмгыятьләрнең тәрәккыйсен дә зур әһәмиятле бер фактор итеп күрсәтте. Боларга башка әдипшагыйрьләрнең дә байтагы, көчәйгән реакция һәм башланган дөнья сугышлары тәэсирендә, дин томанына килеп керә тордылар.

Икенче яктан, шул ук икенче дәвернең ахырларында матур әдәбиятта, кирәк тезмәдә, кирәк чәчмәдә булсын, телнең, өслүбнең эшләнүе дә камилләшеп җитеп барадыр иде. Татарның бик күп шагыйрь-әдипләренең туктаусыз кызу хезмәтләре аркасында безнең әдәби бакчабызның юллары, сукмаклары нык кына салынган иде. Бу вакытларда мәйданга атылучы яңа яшь куәтләр әнә шулар буенча юл алып киттеләр.

Яңа матур татар әдәбияты үзенең беренче адымнарыннан ([18]80 еллардан) ук төп нигезе белән реализм сызыгында булып, икенче дәвернең икенче баскычы башланганда, ягъни 1905 елдан соң бу агым кызу үсү юлын алды. Романтизм исә икенче дәвернең башларында тик аерым-аерым чаткыларны гына күрсәтеп киләдер иде. Реакция татар әдәбиятында моның үсүенә зәмин ачты.

Икенче дәвернең ахырында реакциянең дәвамы, бәйнәлмиләл сугышның бөтен иҗтимагый-икътисади тормышны чыгырыннан

[1] Ләкин болай каңгырулар бер Бабичта гына түгел, күп татар әдипләрендә булып үтте. Бу турыда Галимҗан Ибраһимовның Бабичның «Шигырьләр мәҗмугасы»на язган мөкаддимәсенә каралсын. *(Авт. иск.)*

чыгаруы сәбәпле, романтизм үзенең соңгы куәте белән шигырь дөньясында яңадан нык куерып күтәрелеп чыкты.

Бездә әүвәлдән дә әз-мәз күренгәләгән поэма (дастан)чылык бу соңгы куерган романтизмның үзенә бик муафыйк аерым бер әдәби шәкеле, формасы, калыбы булып чыкты.

Үзенең төп фикере, төп юнәлеше ягыннан, аллалар, диннәр, пәйгамбәрләр, фәрештәләр, җеннәр, оҗмах-тәмуглар белән сугарылган бу агым үзенә төп һәм киң мөндәриҗәне дә һәрвакыт диярлек Көнчыгышның иске әкиятләреннән, хыялларыннан, кыйссаларыннан, хорафатларыннан, мәсәлләреннән ала килде. Мәсәлән, Мәҗит Гафуриның «Гаиб хәзинә»се, Думавиның «Шәрык даһие», Г. Сөнгатинең «Хозыр»ы, Фәрит Ибраһимовның «Төш», «Гармун тавышы»[1], Г. Харисның «Шүрәле»се («Альманах»та), шулай ук Вакыйф Җәлалның, Н. Исәнбәтнең, Кәрим Әмиринең шул рухтагы нәрсәләре шушы поэмачылыкның беренче күренешләре иде.

Ф. Бурнаш иптәш тә әнә шушы поэмачылар һәм шундый бер поэмачылык эченнән килеп чыгып, шуларның иң җимешлесе, иң шома, матур, җиңел теллесе һәм бу турыда күп нәрсәләр бирүчеләрдән булды.

[19]14 елларда ук каләмен тибрәтә башлаган бу шагыйрь беренче мәртәбә үзенең 1916 елда «Аң» журналында язган шигырьләре, поэмалары аркылы танылды, шул елларда татарда көчле романтизм рухында күтәрелгән әлеге «поэмачылык туфаны»ның соңгы яңа көчле бер вәкиле булып әдәби эшкә керešте. Шушы елгы «Аң»да аның «Дулкыннар арасында» («Зиләйлүк» вәзенендә), «Казакъ кызы» (12 иҗекле мәшһүр вәзендә), «Коркыт» (мәшһүр 11 иҗекле вәзендә), «Ятим калды бала гомергә» (1916 елда язылган) дигән поэмалары белән «Авылда» дигән бер балладасы (11 иҗекле вәзендә), шулай ук «Вакытсыз үлгән апама» лирикасы кебек шигырьләре басылды. Болар татар шигырендә көч алган романтизм тамырының үстергән соңгы сабаклары һәм тәңречелек белән сугарылган бер идеалистлык орлыгының җимешләре иде.

Аның беренче поэмасы («Дулкыннар арасында») үзенең сюжеты белән «Таһир-Зөһрә» вакыйгасын яисә шуның бер өлешен искә төшерә. Монда хан кызы, вәзир улы алына. «Казакъ кызы»нда исә бер казакъ егетенең Җаек буенда көтеп утырган бер казакъ кызы алдында дошманнары белән сугышка китеп, ахырда аның кыз яны-

[1] Бу поэмалар барысы да 1915 елгы «Аң»да. *(Авт. иск.)*

на ат өстендә үләксәсе генә кайтып килүе тасвир ителә. «Коркыт» поэмасында бирергә уйланган төп уе «әҗәлдән, үлемнән һичберәүгә котылмак юк» булып кала. Анатоли төркләрендә мәшһүр Дадәм Коркыт дигән бер батыр һәм аның хакында «Китабе Коркыт» дигән бер поэма бар. Ихтимал, аның «Коркыт»ы – шул Коркыттыр. Ихтимал, шагыйрь шул ук Коркытны, көнчыгыштан көнбатышка, аннан көньякка, аннан да төньякка әҗәлдән һәм дә үзенә дип дөньяның дүрт ягында казылган кабердән качырып йөртеп, ахырда көньягындагы кабергә күмдерткәндер. Апасына каратып язган шигырендә юкка туган булудан зарлана. «Авылда» дигән балладасында авылдагы азан тавышы алдында бөтен табигатьнең, бөтен җан ияләренең тынлыкка чумуларын, «бөтен шау-шу киселүен» тасвир белән башлый да, авылның урман кырыендагы бер өйчектә атадан-анадан ятим калган бер матур кыз өчен табигатьтән сәҗдә иттерә. Тирән бер тынлыкта әлеге кызның күзләре «алда күренгән бер зур нокта таба» да, «шушында күзли ул тынлыкта Хак»ны. Шунда ул «сынган, сыгынган яшьле күзләр»е белән «Ходага сөйли көчле серле сүзләр». Монда кыз авызыннан ятимлекләреннән, ашар-киярләренә юклыкларыннан, энесенең хәерчеләве белән тамак туйдыруларыннан зарландыра һәм Ходага исәнлекләреннән шөкер кылдырта, Хода язмышына буйсындырта. Ахырда Хода тарафыннан теләге кабул ителү, алда ак юл күрүе турында күктән тавыш килә. «Ятим калды бала гомергә» дигәне, «Сахра каны» поэмасы шикелле үк, хыялый матурлык белән аерыла. Бу поэмада Казан дәүләтенең җимерелү вакыйгасы, татарларның дине, милләте башка булган рус кул астында изелүе, кайбер татар мирзаларының Мәскәү бәкләренә сатылып, Мәскәү хуҗасына мәңге «садыйк хезмәткә» бирелеп, руска агентлык кылучылыклары, шулай ук үз хезмәтчеләренә дә җәбер кылуы, әхлакый бозыклыклары тасвир ителә.

Шул ук романтизм орлыгының җимеше булып, бу шагыйрь каләменнән иске Шәрык поэмаларыннан мәшһүр «Таһир-Зөһрә» кыйссасыннан алынып, «Таһир-Зөһрә» драмасы язылды. [19]16–[19]17 елларда язылган бу драма шагыйрь йөрәгенә салынган шул орлыкның тәмам үсеп җиткән бер үрнәге иде. Шулай итеп, ахырда татардагы романтизм «иске Шәрык хыялындагы бер вакыйга һәм ханнар сараендагы фаҗигалар арасында үзенә тагын да җылы туфрак табып», татар сәхнәсе өчен хаслап үсә башлады. Бу, шөбһәсез, романтизм агымындагы «сәнгать – сәнгать өчен» нәзариясенең дә соңгы гамәли бер нәтиҗәсе иде.

Октябрь кебек бәйнәлмиләл зур вакыйгалар бөтен дөньяның идеологиясендә дә, әдәбиятында да күп яңалыклар, тирән яңа мәгънәләр һәм яңа әдәби формалар тудырганлыгы һәркемгә мәгълүм. Дөньяның байтак иске зур мөхәррирләре (мәсәлән, Франциядә – Анатоль Франс[1], Англиядә – Бернард Шоу[2], Америкада Синклер[3] кебек), шулай ук татарның да әүвәлге байтак язучылары ачыктан-ачык пролетариат идеологиясенә күчеп, динчелек, милләтчелек, ватанчылык фикерләреннән ваз кичтеләр. Марксизмга, сыйнфый көрәшкә бирелделәр. Шулар белән бергә, Көнбатыш һәм Көнчыгышның һәммә халыкларында диярлек революция рухы, пролетариат идеологиясе белән сугарылган яңа яшь куәтләр мәйданга чыга башладылар.

Бөтен СССРдагы халыкларда, шулай ук татарда бу әдәби-фикри үзгәреш бик куәтле булды. Шагыйрьләрнең күбесе бу вакыйгалар эчендә яңа юлга төштеләр. Ф. Бурнаш исә, форма ягыннан искечә калып, һаман поэмачылыкта барса да, мәгънә, фикер ягыннан анда байтак үзгәрешләр күренде. Ул һаман әкренләп октябрьләшә барды.

«Ф. Бурнаш шигырьләре» исеме белән 1920 елда басылып чыккан мәҗмугадагы поэмалары[4] һәм «Эш иртәсе» кебек лирикалары аның шул юлдагы иҗатлары иде. Болар революция, Октябрь ялкынының тәэсире белән ирек, көрәш рухы белән сугарылып чыктылар. Ягъни аның бу шигырьләре дә романтизмның төп хосусиятләре, төп рухы белән нык сугарылса да, ләкин шуларга сыйнфый көрәш чаткылары, Октябрь дулкыннары аралашкан булды. Боларда инде шагыйрьдә чыннан да самодержавиегә, патша, мирза, түрәләргә, байларга «фәкыйрьләр дошманы», «кара йөрәкләргә», гомумән, ярлы халык дошманнарына каршы нык ачу кабартыла, болар аркылы ул бөтен кызулыгы белән шулар өстенә ташлана; тәхет җимерә, дошманнардан үч алырга омтыла. Монда шагыйрь, кызыл фронт белән ак фронт көрәшләре уртасында калып, «шатланабыз, куркабыз...» сыйфатында җиңү шатлыгы белән җиңелү кайгысы, яисә шундый ике төрле күз яше аралаш ак фронт өстенә кызыл утлар чәчү гайрәтен күрсәтә.

[1] Анатоль Франс (Франсуа Анатоль Тибо) (1844–1924) – француз язучысы һәм тәнкыйтьчесе.

[2] Джордж Бернард Шоу (1856–1950) – ирланд драматургы һәм язучысы, җәмәгать эшлеклесе.

[3] Синклер Льюис (1885–1951 ) – америкалы язучы.

[4] «Чәчәктән һәйкәл», «Сахра каны», «Гөлчәчәк», «Таң алдыннан», «Әҗәл», «Ак каен», «Кичке теләк», «Икеләнмә» поэмалары һәм «Теләк, бүләкләр ул көтә», тагын да «Сәлам хатлар җибәрәм», «Татар пролетариатына», «Кем түзәр?», «Әйдә», «Ярлыга», «Бабичка», «Ташламаска, бәгърем, сүзең бир», «Эш иртәсе», «Түгел» һәм башкалар. *(Авт. иск.)*

Икенче яктан, боларда ул «нәләт» тавышлары чәчеп, «нәләтче» булып, зур шау-шу куптара. Анда «бәхетсез ил» өчен күз яше түгелә. «Төннәр буе бергәләшеп иман ятлаган» туган ил өчен яна.

Шагыйрь – бу шигырьләрендә чыннан да «туган илче», «халыкчы». Шуның белән бергә, монда да аның татар яшьләре эченнән «Таһир-Зөһрә»ләре бар. Ләкин хан сарайлары эчендә түгел, Кызыл фронтларда яшь түгүче, шунда корбан булучы яисә шулар өчен кайгыручы «Таһир-Зөһрә»ләр («Чәчәктән һәйкәл», «Ак каен», «Таң алдында», «Икеләнмә» поэмалары). Шулай ук анда «көчсез инсан, комсыз инсан» дип, Тәңре әмерен китерүче әҗәлләр, «анда каядыр югарыда, ниндидер ялтырый» торган «ут янында» йөрүче «ак сакаллы карт»лар белән «ул түгел уйнаучы илсезләр дә, йортсызлар белән» дип сыйфатланучы Тәңреләр һәм аны шулай дип сыйфатлаучы, ләкин, «солтан Аллалар»га, «Илаһлар»га «каршы сугышучы» кызыл солдатлар белән («Әҗәл» поэмасы), анда тагын фронтта, окопларда сугышып йөрүче улын кайгыртып, шуның өчен «тыныч йоклый» торган «ялкау кышкы төн»дә кечкенә «бер өйчектә» сүнәр-сүнмәс кенә торган бер ут яктысында «түренә намазлыгын җәеп», «кул күтәреп, Тәңрегә елап, Тәңренә дога кыла» торган һәм «тар дөньяга, инсанына, җир-суына нәләт, мең нәләт» укучы, ләкин улының дошманнарын җиңеп кайтуын теләүче «изге карчык»лар бар («Кичке теләк» поэмасы). Шулар белән бергә, анда «шанлы кызыл байрак»ка «Җиңәрбез!» дип язып, «бәйнәлмиләл сафларына» тезелгән һәм дошманнарын җиңгән татар пролетариаты бар. Анда ул «тәхет»ле, төрле төсләргә бизәлгән «чуар тәхет»ле дә, «җәннәт», «гаднән»ле[1] дә, «үзем олуг бер хан» дип, «хан» булучы да («Татар пролетариатына» һәм «Кем түзәр жырламыйча, шатланмыйча да янмыйча»). Шулай ук аның «Эш иртәсе»ндә:

Мамык кебек йомшак язгы җилгә
Яшь үләннәр оеп баш ия;
«Рәхмәт кодрәтеңә!» – дия-дия,
Алар тәсбих әйтә Тәңренә.
Язгы тамчы көен жырлый-жырлый,
Салкын чишмә жырлый моң гына;
Аның көмеш тавышын тыңлый-тыңлый,
Җир-күк тәсбих әйтә тын гына, –

булган табигать тә бар.

[1] Гаднән – җәннәт.

Бурнашның тасвирлары – җанлы, үткен, укучыларны үзенә тартырлык оста тасвирлар («Сахра каны», «Ятим калды бала», «Гөлчәчәк» поэмалары бу турыда аерым урын тоталар). Аның шигырьләрен «бер үк мәүзуг, бер төрле үк мөндәриҗәләрнең тәкрарлануы, тасвир, кинаяләренең бер үк диярлек булуы, вәзен һәм аһәңдә булган бертөрлелек (монотонлык)» белән гаепләүче һәм бу хәлләрнең «шигырьләрнең күпкә киткәч ямьсезләнүенә сәбәп булалар, шигырьләр бер-берсенә яңа мәгънәләр өстәмиләр»[1], дип тәнкыйть итүчеләр дә юк түгел.

Ләкин шунысы бар: бу әдип революциянең 3–4 нче елларында ([19]20–[19]21 елларда) үзенең «Яшь йөрәкләр» дигән театр әсәрләрен язып, реализмга таба борылды. Бу әсәрдә Дөнья сугышы белән башланып, Февраль революциясе вакытлары белән тәмамланган вакыйгалар, крестьян яшьләре тормышы аркылы, аның каләменнән инде чын реаль бер юлда матур тасвир ителде. Шулай итеп, татар драма әдәбиятында «Галиябану»ның революционерланган бер иптәше туган булды. Ул крестьян яшьләренең Яурупа сугышында революционерланып, пролетарийлашып, сыйнфый дошманлык, сыйнфый көрәш дулкыннары белән сугарылып кайтуларын драмаландыру юлында бу әһәмиятле бер адым иде. Әсәрнең ярлы крестьян яшьләре тормышыннан алынуы аның әһәмиятен тагын да арттыра. Бу әсәр – мөндәриҗә ягыннан тулы, табигый һәм кызыклы булган кебек, Бурнашның башка әсәрләре шикелле үк, тел-өслүб ягыннан матур эшләнгән бер әсәрдер. Үзендә хәрәкәтләр дә күп һәм теремек[2] хәрәкәтләр.

Ф. Бурнаш, югарыда да күрсәтелгәнчә, «Зиләйлүк» вәзенендә һәм 11, 12, 15 иҗекле, башка татар шагыйрьләре тарафыннан күп эшләтелгән вәзеннәрдә язды («Таһир-Зөһрә»сендә исә «Зиләйлүк» вәзене белән 15 иҗекле вәзен аралаш эшләтелә). Анда 15 иҗекле вәзеннең бер мисрагын ике юлга бүлеп язу да бар. Ләкин бу аның иҗади бер яңалыгы түгел. Мәсәлән:

Әйдә, ут алсын, кирәксә, яшь гомернең ал таңын,
Мин китәм эзләп туган илнең ирекле юлларын, –

дигән ике мисрагны:

Әйдә, ут алсын, кирәксә,
Яшь гомернең ал таңын.
Мин китәм эзләп туган
Илнең ирекле юлларын, –

---

[1] Галимҗан Нигъмәти – «Әдәбият мәйданында», 33 бит. *(Авт. иск.)*
[2] Теремек – тере, җитез.

рәвешендә дүрт юл итеп яза. Аның «Чәчәктән һәйкәл»е, «Әҗәл»е, «Теләк, бүләкләр ул көтә»се, «Татар пролетариатына»сы, «Кем түзәр...»е, «Ник болай» («Ник болай» әсәре. – *Ред.)* шулай язылганнар (болай итү аннан элек С. Рәмиев, М. Фәйзидә («Аң»дагы шигырьләрендә) күрелеп үткән иде). Бу хәл укучыга авырлык та тудыра. 11 һәм 12 иҗекле вәзенне дә ул шулай итә ([19]25 ел язылган «Шигырьләр, поэмалар җыентыгы»нда «Төнге ләгънәт»е белән «Авыр тынлык»ына («Авыр тынлык» әсәренә. – *Ред.*) кара). Ләкин бу вәзенне алай бүлү килешле чыга. Сөйләшкәнчә кылып, тасвирый уку өчен уңайлык ясый. Бу шагыйрьнең шигырьләрендә башкалардагы (бигрәк тә Дәрдмәнд, Тукай, С. Рәмиләр) кебек тирән, нечкә фикерләр юк. Аерым бер яңа иҗади карашлар, яңа төшенчәләрне дә аннан эзләмәскә кирәк. Аның шигырьләре укучының миеннән бигрәк йөрәгенә чиртәләр. Күп уйлатмыйча, очырту, җилкендерү тәэсирен бирәләр. Уйлаткан вакытларында да башкаларча гадәти, гомуми бер сызыкта җиңел уйлаталар. Кыскасы, ул – бигрәк гомуми фикер, хисләргә шигъри сурәтләрдә популяризация ясаучы, аларны гомумиләштерүче бер шагыйрь. Анда тудырудан бигрәк, тудырылганны оста киендерү бар. Монда да тирән фикер мәхсулатын[1] түгел, бигрәк дулкынлы хисләр мәхсулатын.

**Кәрим Әмири.** Шул ук икенче дәвернең ахырларында романтизм туфрагыннан килеп чыккан шагыйрьнең берсе Кәрим Әмири булды. Моның шигырьләре әүвәл «Шура»да күренде. Башта ул Дәрдмәнд сызыгын алып, шуның рухында, шуның вәзеннәрендә, шуның аһәңендә фәлсәфи шигырьләр язды. Аның:

Очар кош! Оч, канат как, үрлә күккә,
Сәгадәт талларын күктән табарсың...
Үләксә туфрагы җир гөлләрендә…
Бәхет юк анда, тик гөлләр син табарсың.

* * *

Бикар туфракка үскән бер миләүшә
Ботагын Зөһрә кулына охшатамсың?
Бүген таңда авар каны тәхеткә
Кунып сайрап, сазың чалып ятамсың!..

* * *

Асыл кош, мен! Матур кулга кунарсың,
Сиңа тәхеткә ул нурдан яралган;

[1] Фикер мәхсулатын – фикер нәтиҗәсен.

Килеп киткән мосафирлар бәхетне
Фәкать аннан гына тапса таба алган... –

кебек шигырьләре шундый шигырьләреннән иде. Ул вакытларда бу шагыйрь, шулай итеп, Дәрдмәнд артыннан китеп, гүя, «хикмәт күге»ннән кыска бармаклары белән үзенчә матур гына, ләкин йомшаграк бер куәт белән җемелдәүче йолдызлар чүпләргә керешкән иде. Ләкин Октябрь революциясе бу шагыйрьне күктән җиргә иңдерде.

Революциядән соң монда да романтизм тәэсире бәгъзе поэмаларында һәм дә «Йосыф-Зөләйха», «Ләйлә-Мәҗнүн» кебек драмалары аркылы театр әсәрләре язуда да кадим Шәрык сызыгына таба буйлап китә язу кебек хәлләр булып алды. Шулай да Октябрь революциясе тәэсире белән бу шагыйрь күктән җиргә тиз төшеп өлгерде.

Октябрьдән соң инде ул «Эш өстендә» дигән шигырь мәҗмугалары, «Завод мәктәбендә», «Фабрик баласы» дигән хикәяләре, «Печән базары», «Пайтәхет җәлладлары», «Казан кызы» (бу ике соңгы пьесалары басылмаганнар әле) дигән пьесалары белән үзенең коммунизм һәм советчылык сызыгына тәмам төшеп житкәнлеген бик ачык күрсәтте. Ул:

Зөлхәбирә,
Айсылулар
Моң-зарыннан,
Хан сарае,
Таш кальгалар юлларыннан
Ләззәт табып күз яшь түккән күңелләрне
Ычкындырдым мәңгегә мин кулларымнан... –

дип, ул юллардан йөз дүндерү өстенә:

Завод – күкрәк,
Станок – йөрәк,
Ячейкалар – безнең миебез;
Тормыш – хезмәт,
Семья – пролетариат,
Бөтен дөнья безнең урыныбыз, –

дип шаулатып җырлый башлады. Шуның белән бергә бу әдип, бу шагыйрь, «Печән базары» дигән пьесасы аркылы, сәхнә әсәрләре язуда да зур өметле адымнар атлаячагын күрсәтте. Монда ул үзенең «тишек борын»лы Гыймадилары аркылы бу әсәре белән үзендә чын тормыш типлары ясап чыгара алырлык бер куәт барлыгын да сиздертте.

Ләкин бу шагыйрьдә тел-өслүб, вәзен мәсьәләләрендә тәкълидчелек, башкалар юлына тиз кушылып китүчелек хосусияте күренә.

Элек Дәрдмәнд эзеннән юргалаган булса, аның «Эш өстендә»ге шигырьләренә караганда, инде ул Октябрьдән соң, Октябрь белән җитешкән башка яшь шагыйрьләр эзен ала (бу шагыйрьдә казакъ шагыйре Мәгъҗан Җомабайга[1] тәкълид белән, аның вәзеннәрендә язып карау тәҗрибәсе дә ясалды). Шулай да аның шигырьләре, гомумән, мөндәриҗәле, тулы мәгънәле булалар. Теле, тәгъбирләре, тасвирлары да үткен, матур. Бу шагыйрьдә дә, Ф. Бурнаш һәм башкалар шикелле, иске вәзеннәрне яңа техникага кую бар.

Кыскасы, шулай итеп, Октябрь революциясе аркасында бу шагыйрь өчен:

Заманалар, арысландай ялын кагып,
Еллар үткән саен яңа юллар салды... –

була да, шул юлга, ягъни «карт тарих»ның юлыннан яшь, яңа тарихның юлына тизлек белән төшеп китүче шул ук шагыйрь үзе булып күренә.

Ул инде хәзер әүвәлге «күк»челегеннән, романтизмнан бөтенләй кайтып:

Моңлы тургай күккә менсен,
Сандугач каксын канат;
Ни эшем бар,
Җир улы мин, әйдә, йөрсеннәр матур йолдыз санап...
Җирдә җырлый, гөлләрем җирдә минем,
Эзләмим күктән бәхетләр,
Җан-йөрәк – киң җир, димен... –

дип, җир җырын җырлый башлый; тәмам «җир җырчысы» булып әверелә.

**Гыйффәт.** Икенче әдәби дәверебездә татар хатын-кызлары эченнән шигырь язу тәҗрибәсен күреп караучылар берничәләр булса да, күпләре шул тәҗрибә юлында югалып киттеләр. Матур гына шигырьләр язгалаган З. Сәгыйдә кебекләр шулар җөмләсеннән иде.

Ялгыз бу дәвердә татар хатын-кызлары эченнән үзен шаулатып таныттыручы Гыйффәт булды. Ләкин татар хатын-кызларының тормыш шартлары теләвенчә, аның шигырьләре ачы күз яшьләре, аһ-зарлар тезмәсе иде. Аның шигырьләре аркылы татар хатын-кызларының бәхетсез, авыр аһәңле чулпы тавышлары яңгырады. Кыскасы, Гыйффәт ул вакытта татарда тамыр җәйгән романтизмның хатын-кызлар арасыннан чыккан бер вәкиле булып калды. Ул

[1] Мәгъҗан Җомабай (1893–1938) – казакъ шагыйре, публицист, яңа казакъ әдәбиятына нигез салучыларның берсе.

вакытта татар шигырендә көчәйгән романтизм, пессимизм рухыннан, шул юлдагы шагыйрьләрнең шигырьләреннән оеткылар алган бу шагыйрь шәхесе кысынкылык астында, үксеп-үксеп елап, Тәңресенә ялвару, Алла белән сөйләшү көйләрен көйләде[1].

Төн ягымда ал шәфәкъ уттай яна,
Көн ягымда таң туарга уйлана, –

дип җырлаучы бу шагыйрьнең күңеленә дә таң нурлары түгел, гел кичке шәфәкъ нурлары коелып торды. Шуның белән бергә ул, югарыдагы ике юлдан аңлашылганча, көнчыгыштан түгел, көньягыннан «таң туарга уйлану» өмете белән дә юанып алгалады. Шулай да һаман «изге теләге чәчәк ата алмый» интекте. Үзе өчен «алдагы тормыш белемсез» булуы белән сызланып, «миндә бит бик аз хәзерлек, син, диләр ич, кыз бала» дип көйли башлаган бу шагыйрьнең мәгълүмат ягыннан ул вакытта чыннан да хәзерлеге аз булса да, үзенең табигый таланты аркасында байтак кына матур тезелгән моңлы сүзләр сөйли алды. Ләкин Октябрьдән соң рухы-фикере күп үзгәрешләргә очраган, партиянең Шәрык хатын-кызлары арасында мәсьүл эшче булу баскычына килгән, шулай ук әүвәлге күз яшьләре, кайгылары инде шатлыкка әйләнгән бу коммунист иптәшнең Октябрьдән соңгы шигырьләре матбугатта күренмәде. Инде анда, башкалар шикелле үк, романтизм чишмәсе корып, реализм – пролетариат реализмының чишмәсе кузгалдымы? Яисә берәр сәбәп белән ул әле агып китә алмыйча тордымы? Моны якын киләчәк күрсәтер. Һәрхәлдә, бу шагыйрь икенче дәвердә татар хатын-кызлары арасыннан чыккан бердәнбер якты әдәби йолдыз иде.

**Нәкый Исәнбәт.** Икенче дәвернең ахырларында романтизм агымы көчәеп китеп, поэмачылык хәрәкәте кызуланганын, бу агым үзенә шушы форманы яратып сайлап, яшь әдәби куәтләрнең дә күбесе шул юлга кереп киткәнлекләрен аңлап үткән идек. Нәкый Исәнбәт тә әнә шул сызыктан, шул хәрәкәт эченнән килеп чыкты. Романтик-идеалистлык һәм индивидуалистлык моңнарын көйләде.

1916 елгы «Аң»да басылган «Качкын», «Сукбай» дигән поэмалары (7, 11, 12, 14, 19, 20 нче саннарда) һәм «Җәйге таң», «Җәйге кич», «Мәдрәсәдә» дигән тезмәләре шул агымның, шул рухның җимешләре иде.

«Җәйге таң»ында ул:

---

[1] «Телим Тәңремә шушы моңлыкта... Монда серләшәбез – мин һәм Алла»... – «Гыйффәт туташ шигырьләре», II кисәк, 13 бит. *(Авт. иск.)*

Нинди иркен... Нинди дулкын... Нинди илһам... Нинди нур...
Әй күңел!.. Әй мәңгелек гөл!.. Син дә шундый нурлы бул!... –

дип, күңелгә мәңгелек сыйфат бирсә, шулай ук «Мәдрәсә»сендә:

Гөл булып сызсын да күңелем, мин югалмыйм мәңгегә:
Анда гел нур, ямь генә! Аһ, анда гел бәйрәм генә!!. –

дип, «мәңгелек»кә китәргә ашкынды; «гел бәйрәм генә» була торган хыялый нокталарны күзләде. «Җәйге кич»ендә янә:

Бу – көләч нур, язгы гөлләр... гәүдәләнгән ямь генә,
Монда гел бәйрәм генә!.. Тәңрем!! Калыйм мин мәңгегә!! –

дип, Тәңрегә ялварды.

Соңыннан бу лирик шагыйрьнең 1917 елгы «Аң»да шул ук рухта «Теләк» (8–9 нчы сан), «Шәрык кызы», «Табигать почмагында»лары чыкты. Аның шушы югарыда әйтелгән поэма һәм лирикаларында символизм галәмәтләре дә бар иде.

Нәкый Исәнбәтнең поэмаларында:

Нинди карт бу? Монда нишли? Әллә берәр җенме бу?
Я кешеләрдән ераклашкан берәр сөргенме бу?..
Ул җүләрме; ник йөри соң ялгыз айлы төнне ул?
Әллә урманнан килеп чыккан берәр качкынмы ул?
Әллә ул икмәк сорарга илгә килгән ачмы икән?
Әллә ул бер картка әйләнгән Хозыр Ильясмы икән?
Я йөриме буш каберләрдән терелгән бер өрәк?..
Әллә ул бер-бер каракмы? Нишли соң ул, ни кирәк?
Бер пәриме китте юлга, буш тегермәннән чыгып?
Әллә шунда җенме китте, ак сакаллы карт булып?
Әллә бер дәрвишме икән ул? Әллә юл баскын тагын?
Ник алай булса, янында мылтыгы юк соң аның?
Әллә ул бер куркыныч урман убырлы карчыгы?
Ник алайса ул сакаллы? Ник алай юк капчыгы?
Ул юаш бер картка әйләнгән берәр албастымы?
Һәм оясы ул явызның шул тегермән астымы? –

рәвешендә, өслүбтә, тасвир алымнарында (прием[1]) үзеннән әүвәлге романтизм шигырьләре тәэсиренә нык бирелгәнлеге, шуларга тәкълид белән башлаганлыгы ачык сизелде. Анда бу хәл соңыннан да дәвам итте. Ул Тукайларда һәм башкаларда эшләтелгән «Яңа Кисекбаш» вәзенен – 11 иҗекле вәзенне яңа фикерләр, яңа хисләр, революция дулкыннарының калыбы ясап, аны яңа тонда эшләтеп

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

китте. Революциядән соңгы «Коммуна тимерлегендә», «Фән-белем гасыры килә», «Мин дә киттем» дигән шигырьләренең вәзеннәре шул вәзен иде.

Күп шагыйрьләрне күктән җиргә иңдергән Октябрь вакыйгалары астында Нәкый Исәнбәт фикердә, идеологиядә, башкалар шикелле үк, үзгәрү сызыгын алды. Инде ул «Чаң» дигән шигырь мәҗмугасында революцияче бер агитатор шагыйрь сыйфатын күрсәтте. Поэмачылыктан шагыйрь ораторлыкка күчте. Революцияче романтик лирик юлын алды. Вәзен, норма мәсьәләсендә дә Октябрь белән җитешкән соңгы яшь шагыйрьләр сызыгына төште. Шуның белән бергә, символист-индивидуалистлык рухыннан котылып җитә алмады.

Яшь коммунист-марксист тәнкыйтьчеләрдән Г. Нигъмәти[1] бу шагыйрь турында, революциядән соңгы шигырьләренә (бигрәк тә «Чаң» мәҗмугасына) карап, түбәндәге фикерләрне язды: «Нәкый Исәнбәт шигырьләре белән романтик. Романтиклыкның да соңгы замандагысы: ул – декадент. Аның “Эңгер җире” – моңа бик яхшы мисал. Романтизмның иң азаккы чаткылары, шәфәкъ нурлары бу шигырьдә ачык күренеп тора. Ләкин яшь шагыйрьнең яшь йөрәге романтизм идеяләренә ахыр чиккәчә иярә алмый; ул талпына, яңа юлга аяк басарга тели, яңа җырлар җырлый башлый, шулай аның “Коммуна тимерлегендә”се, “Революция” шигырьләре килеп чыга. Тик шагыйрь бөтен вөҗүде белән яңа эзгә бирелә алмый. Элекке романтизм тәэсире – индивидуалистлык аның артыннан өстерәлеп йөри. Шагыйрь масса хәрәкәтләрен, коточкыч көрәш картиналарын күрсәтеп бара-бара да, ахыр килеп, тагы шул “мин”гә төртелә» («Әдәбият мәйданында», 37 бит).

Г. Нигъмәти шуларга тагын шагыйрьнең [19]20 елда язылган «Яралы батыр» шигырендәге үз тәгъбирен үзенә кайтарып: «Шагыйрь һаман әле “кулсыз-аяксыз батыр” хәленнән чыга алганы юк», – дигән фикерне өсти.

Бу шагыйрьдә башта ук тасвирга, тәгъбиргә иркенлек, үткенчелек сизелә иде. Октябрьдән соңгы, революция тәэсире астында туган шигырьләрендә аның бу ягы тагын ачылды. Шигырьләре сәнгатьчә төзеләләр.

[1] Галимҗан Нигъмәти (Галимҗан Әмирҗан улы Нигъмәтуллин, 1897–1941) – әдәбият галиме, тәнкыйтьче һәм педагог. Татар әдәбият белеменең фәлсәфи-эстетик нигезләрен, нәфис иҗатны әдәбият белеме, фәлсәфә, эстетика, тарих, психология, социология фәннәренең үзара йогынтысы нигезендә комплекслы өйрәнү принципларын эшли. Татар әдәбияты дәреслекләре һәм укыту программалары авторы.

**Мөхәммәт Гали.** Хикәяләргә авыл-крестьян тормышын мөндәриҗә итеп алып, реаль бер рәвештә шуларны сурәтләндерү юлында язышучыларның берсе М. Гали булды. Ул шул тормыштагы өзек-өзек, аерым-аерым күренешләрне бирде.

Бу каләмнең беренче хикәяләре 1914 елгы «Аң»да башланды. Аның шул юлда беренче адымы булып, шул елгы «Аң»ның 14 нче санында – «Җиләклектә бер көн», 24 нче санында да «Әни килен чакта» дигән хикәяләре басылды. 1915 елгы «Аң»ның 3 нче санында – «Бер әбинең зары», 9–10 нчы санында «Авыл егетләре» басылды. «Бер әбинең зары»нда Дөнья сугышы вакытларында бер авыл гаиләсе башына килгән авырлыклар тасвир ителә. Шул ук елның «Аң»ында янә бу хикәяченең 1914 елда язылган «Сабан туенда»сы басылды. Соңыннан ул «Яңгырсыз елларда», «Паразитлар» дигән хикәяләрен бирде.

«Әни килен чакта» кебек хикәяләрендә тел-өслүб, тасвир ягыннан әле яңа өйрәнүче сыйфатында күренгән бу каләм соңыннан үсте, шомарды. Авыл тормышындагы вакыйгаларны бик реаль бер юл белән кызыклы бер рәвештә, килешле генә, матур гына тасвирчы бер әдип булып чыкты[1].

**Кәрим Тинчурин.** Икенче дәвернең ахырларына таба, бер яктан, тезмә шигырьдә романтизм көч алган булса, икенче яктан, шуның каршысына, чәчмәдә реализм нык куәт алып киткән иде. Галиәсгар Камаллар, Гаяз Исхакыйлар, Ф. Әмирханнар, Галимҗан Ибраһимов һәм Шәриф Камаллар шул агымны нык тамырландырып, үстереп өлгергәннәр иде инде.

Матур әдәбият мәйданына аяк басарга теләүче, аяк басучы яңа яшь көчләрнең бер өлеше шушы юлны, шул агымны алдылар. М. Галиләр шикелле үк, Кәрим Тинчурин да шуларның берсе булды.

Февраль – Октябрь революцияләреннән соң пьесалар язу эшен кыздырып алып киткән Тинчурин беренче әдәби адымнарын әүвәл беллетристика мәйданында күрсәтте. Аның 1915–[19]16 елгы «Аң»дагы «Ак өрәк», «Ак чирбик», «Биктимер бабай», «Гыйшык», «Юбилей», «Әтәч», «Хәкимҗан агай» дигән хикәяләре шулар җөмләсеннән иде.

«Ак өрәк» хикәясендә шәһәрдә – номерлардагы утырышлар; «Ак чирбик»ында исә шәһәр приказчигы, аның гаилә тормышы, шуларның үз тормышлары белән багланган, шул тормыштан туган мещанлык психологиясе тасвир ителде. Бу хикәядә бигрәк тә аның хатынының кыяфәт һәм табигатен тасвир бар. Монда эче-тышы белән

[1] Аның шул хикәяләренең бер өлеше «Балалык көннәрендә» исеме астында татар әдәбияты көтепханәсеннән 27 нче китап булып басылдылар. *(Авт. иск.)*

ямьсез, тупас, мәдәниятсез, холыксыз, тәрбиясез бер мещан хатыныының чын реаль, хәтта натураль бер картинасы чыннан сәнгатьчә бер осталык белән бирелә. Һәрьяктан мәнфур[1] бер кыяфәт, биздергеч бер табигатьнең дөрес, тулы бер күренешен яхшы эшләп бирә алуында бу хикәя үзенә аерым бер урын тота. Шуның өстенә монда Казанның «тәрәккыйпәрвәр» мещаннарының хатын-кызлар белән булган мәҗлесләре, андагы итенеш-кыланышлары тасвир ителә.

«Биктимер» хикәясе шигъри бер символдан гыйбарәт. Монда «әүвәл-әүвәл заманда, ике күмәч бер тиен, җигүле ат ун тиен булган чакларда», «байлыгы белән илне шаулатып, баһадирлары белән дошманнарын дер селкетеп, гайрәте белән арысланнарны качырып, бик күп авылларның аксакалы хисапланып, ил өстендә баш булып, күз өстендә каш булып, тыныч, рәхәт яши» торган, шулай ук «берсеннән-берсе баһадир унике углы» булып, «кул астындагы мул җирдән һәммәсенә тигез өлеш чыгарып көн күрүләрен үз башларына тапшырган» Биктимер карт – хикәядә алынган мәүзуг һәм сюжетның символ баганасы. Укучы бу символдан нәрсә аңласа да аңлый ала. Моннан Мәскәү патшалыгының төрле катлаулы колонизация хәйләләре астында татарларның каты мәхкүмлеккә төшүләрен аңларга да мөмкин. Символның ишарәсе шуңа якынрак.

Биктимер карт унике арысланы (унике улы) белән, үзенә каршы һәрвакыт дәгъвалар чыгарып, җәнҗаллашып, кычкырышып килүче Мәрьям әби һәм аның егетләре, улларының төрле усал хәйләләре (эченә үткен очлы сөяк төрелгән майны картка хөрмәт күрсәткән булып согындыру шикелле) астында зур бәхетсезлеккә, һәлакәткә очрый. Дәүләт, мөлкәтеннән, илдәшләреннән аерыла. Ахырда «унике почмаклы йортның һәр почмагын бер углына бүлеп биреп, шунда тату гына яшәп гомер уздырырга куша да, үзе, Мәрьям әби кадаган сөяктән хасил булган – бугазындагы җәрәхәтне дәваларга дип, кояш чыгышына таба» юнәлә.

Карт дәваланырга киткән җирендә, кояш чыгышында, «артыграк тәкъваланып китеп, бай, баһадир дөнья кешесеннән куркак, ялкау ахирәт кешесенә» әверелә. «Тау тишегенә кереп, шифа төраблар[2], бөтиләр, догалыклар белән җәрәхәтен дәвалый». Ниһаять, балаларын күрергә дип, иленә кайтып килә. Кайтса, һәлакәт... Унике почмаклы йорт көлгә әйләнгән, балаларының тормыш һәм табигатьләрендә ышанмаслык бер зур үзгәреш. Карт моңа чыдый

[1] Мәнфур – нәфрәт уята торган.
[2] Төраблар – туфраклар.

алмый: «җитен шикелле ак башын калтыратып», «яшел таягына таянып, бөтен вөҗүде белән калтырап», «абына-төбенә кыйбла тарафына» китә... «Биктимер бабай белән бергә туган, озын гомерендә бик күп үлек-үләксә күргән карт карга» да, анда калса, әлеге картның балалары тарафыннан аның оясының да туздырылуыннан куркып, «карлыгып беткән мәкруһ тавышы белән карылдап», Биктимер бабайның артыннан очып китә...

Сәнгатьчә матур язылган бу хикәянең кыска мөндәриҗәсе әнә шуннан гыйбарәт.

Тинчурин хикәяләре, гомумән, картиналы булалар. Аннан кешеләрнең эчке һәм тышкы кыяфәтләрендәге, тормышларындагы тупаслыкларны, килешсезлекләрне тасвирда аерым бер осталык бар. Анда үткен, ачы иттереп көлә белү чаткылары да ачык сизелә.

Дөрес, бу артист-әдип киң татар җәмәгатенә хикәяләре, хикәячелеге белән түгел, бигрәк үзенең пьесалары, драмалары белән танылды. Халык аны, бәлки, беллетрист булудан да драматург иттереп күрәсе килер. Ләкин төбендә аның таланты, һәрхәлдә, беллетристикада, хикәячелектә күренде. Аның югарыдагы хикәяләре әдәбият, сәнгать адәмнәре алдында шуны күрсәтәчәкләр. Болар тасвир ягыннан шулай булган шикелле, тел-өслүб ягыннан да шулайдыр. Монда үткен, оригиналь охшатулар да байтак бар.

Тинчуринның пьеса язучылыгы, драматурглыгы матбугатта хикәячелегеннән соң күренде. 1917 елда ул үзенең «Шомлы адым», «Соңгы сәлам», «Беренче чәчәкләр» шикелле драмаларын язып, бу юлда шулар белән беренче адымнарын башлады. 1918 елда – «Җилкуар» комедиясен, 1919 елда «Сакла, шартламасын», «Назлы кияү», «Йосыф-Зөләйха» (тарихи «Йосыф-Зөләйха» түгел, Казан мещаннары тормышыннан алынган «Йосыф-Зөләйха»)ларын язып, сәхнәгә куйды. Октябрьдән соң артистлык юлында, сәхнә сәнгатендә совет сызыгына төшеп, тагын җитди хезмәткә тотынган бу хикәяче әдип һәм драматургның «Казан сөлгесе» язылды; «Американ»ы, «Сүнгән йолдызлар»ы чыкты. «Нәби абый» пьесасы сәхнәгә керде.

**Күмәк төркемнәр.** Икенче дәверебезнең ахырларында, бигрәк тә соңгы биш елы эчендә һәртөрле бик күп тезмәчеләр (назыймнар), шагыйрьләр, вак хикәячеләр мәйданга чыктылар. Боларның да төрлесе төрле агымда, төрле рухта булып, төрле әдәби мәктәпкә сөялә иделәр. Болар зур елгаларга агып килеп кушылучы үзәннәр, ирмәкләр, вак чишмәләр яисә *күмәк төркемнәр* иде. Болар эченнән су өстендә зур дулкыннар арасында тиз югалып китә торган

күбекләр рәвешендәгеләре булган шикелле, югалмый торганнары һәм әдәби талантлары, шигырь-әдәбиятка азмы-күпме хезмәтләре белән үзләренә игътибарны карата торганнары да бар, бәлки болар байтаклар. Бу соңгыларның бәгъзеләре Октябрь белән тукталып калган булсалар, бәгъзеләре дә Октябрьдән соң да совет сызыгында үз үлчәүләренчә әдәби хезмәтләрендә дәвам иттеләр, дәвам итәләр.

Боларның кайнашкан органнары «Шура» белән «Аң» журналы булды. Тик «Шура»ның үзендә генә шундый назыймнар, шундый шагыйрьләр йөзләп бар.

Китапның күләме сыйдырмаганлыктан, боларга аерым-аерым тукталуга хәзергә имкян[1] юк. Шуның өчен боларга тукталуны китапның икенче басмаларына калдырып, бу юлы бу урында тик аларның исемнәрен генә язып яд итеп[2] үтәбез.

«Аң» һәм «Шура»да түбәндәге имзалар яздылар: М. Хәнәфи, Г. Рәхим[3], Г. Газиз, Г. Гобәйдуллин[4], Н. Хәлфин[5], Г. Авыргазый[6],

[1] Имкян – мөмкинлек.

[2] Яд итеп – искә алып.

[3] Гали Рәхим (Гали Мөхәммәтшакир улы Габдрәхимов) (1892–1943) – язучы, әдәбият галиме. Хәрби-сәяси курсларда (1920–1921) татар әдәбиятын, Шәрык академиясендә (1921–1922), Шәрык педагогия институтында (1922–1930) татар әдәбияты һәм фольклоры тарихын укыта. «Татар әдәбияты тарихы» (1–2 т., 1923–1927) китабы авторларының берсе. 1923–1930 елларда Татар халкын өйрәнү фәнни җәмгыяте эшендә, фольклор экспедицияләрендә катнаша; татар теле һәм әдәбияты белеменә, фольклорына, тарихына, археографиясенә багышланган мәкаләләр авторы.

[4] Газиз Салих улы Гобәйдуллин (Г. Газиз, 1887 – 1937) – тарихчы, тарих фәннәре докторы (1927), профессор (1927), җәмәгать эшлеклесе, публицист. Казанда Шәрык академиясен нигезләүчеләрнең берсе. Хезмәтләре татар халкы тарихына, татар әдәбиятына («Татар әдәбияты тарихы», 1–3 т., 1922–1925, Г. Рәхим белән берлектә), Идел буенда һәм Азәрбайҗанда барган крестьян сугышлары тарихына карый. Г. Гобәйдуллин – сатирик һәм юмористик хикәяләр остасы. «Җомга көн», «Исерек» (икесе дә 1913 елда), «Чалбар» (1915) сатирик новеллалары, Г. Исхакый, С. Рәмиев иҗатлары, XX йөз башы татар әдәбиятында романтизм турындагы (1911–1913 елларда басыла) әдәби тәнкыйть мәкаләләре авторы.

[5] Нәҗип Хәлфин (Мөхәммәтнәҗип Латыйф улы Хәлфин, 1886–1938) – сәясәт эшлеклесе, әдәбият тәнкыйтьчесе, тәрҗемәче, географ. «Аң» журналы белән хезмәттәшлек итә. 1917 елгы Февраль революциясеннән соң Мөселманнар комитетын оештыруда, 1 нче һәм 2 нче Бөтенроссия мөселманнары корылтайлары (1917) эшендә катнаша. 1917 елда Казан губернасы Милли Шурасы башкарма комитеты әгъзасы. Милләт Мәҗлесе депутаты (1917–1918). 1921 елдан Азәрбайҗан университетында (Баку) фәнни һәм педагогик эштә. Г. Исхакый, Й. Акчура һәм XX йөз башындагы татар әдипләре иҗатына, икътисади географиягә караган хезмәтләр авторы. К.Ф. Фуксның хезмәтләрен татар теленә тәрҗемә итә.

[6] Г. Авыргазый (Гыйбадулла Хәбибулла улы Алпаров, 1888–1936) – тәхәллүсләреннән берсе.

Гали Рәфыйк[1], Шәхид Әхмәдиев[2], С. Еникиев[3], Хәлил Әбелхан[4], Х. Кәрим[5], С. Рахманколов[6], Фәхрелислам Агиев, Ш. Ширин, Г. Сөләйман, И. Байбурин, Фазыл Туйкә, Г. Сөнгати, Кыям Юлдаш[7], Ф. Ибраһимов[8], Г. Рамазанов[9], Г. Харис, Чыгтай[10], Ш. Алкин[11],

[1] Гали Лотферахман улы Рәфикый (1890–1944) – журналист, язучы, тәрҗемәче. «Шура», «Аң», «Ак юл», «Белем», «Культура революциясе» журналларында, «Вакыт», «Башкортстан», «Яңа авыл» газеталарында мәкаләләре басыла. «Алатау буйларында» (1913), «Вакытлы никах» (1913), «Артык кеше» (1914) һ. б. очерк һәм хикәяләр җыентыклары авторы. И.С. Тургенев, А.И. Куприн әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә. Урта мәктәпләр өчен рус теле дәреслеге авторы.

[2] Шәһит Гыймадетдин улы Әхмәдиев (1888–1930) – сәясәт эшлеклесе, язучы. Г. Ибраһимов белән бергә «Мәгариф» журналын оештыручыларның берсе.

[3] С. Еники (Сәетгәрәй Арслангәрәй улы Еникиев, 1889–1914) – «Аң» журналында романтик рухтагы өч кенә шигыре чыгып өлгергән шагыйрь. Башка әсәрләре билгесез.

[4] Хәлил Әбелхан (Хәлиулла Габделвәли улы Әбелханов,1887–1919) – язучы, журналист, педагог. 1912 елдан «Шура», «Мәктәп», «Мәгариф» журналларында, «Йолдыз», «Кояш», «Корылтай» газеталарында актив языша. Татар мәктәпләрендә җәдитчә укыту ысулын пропагандалаучы. «Ак юл» журналында балалар өчен хайваннар, җәнлекләр турындагы хикәяләрен бастыра (соңыннан алар класстан тыш уку китабы буларак аерым җыентыкта нәшер ителә).

Җәдитчелек хәрәкәтенең аерым җитешсез якларын тәнкыйтьләгән «Ысулы җәдиткә каршы беренче адым» (1911) исемле китап авторы.

[5] Хөсни Кәрим (Хөснетдин Минһаҗетдин улы Кәримев, 1887–1965) – язучы, педагог һәм җәмәгать эшлеклесе. «Идел» газетасы, «Аң» журналы идарәләре белән хезмәттәшлек итә, бу газета-журнал битләрендә әдәби-публицистик мәкаләләрен, фельетоннарын, хикәяләрен бастыра.

[6] Солтан Рахманколый (Әхмәтсолтан Габделмәннан улы Рахманкулов, 1888–1916) – язучы, тәрҗемәче, тел галиме. 1908 елдан «Йолдыз» газетасы редакциясендә эшли, шунда үзенең беренче хикәяләрен бастыра. XX йөз башында татар матбугатында Рахманколыйның публицистик мәкаләләре һәм тәрҗемәләре актив басыла. Татар теленә А.С. Пушкин, Л.Н. Толстой, И.С. Тургенев, М. Горький, В. Гюго әсәрләрен, фәнни-популяр китаплар һәм брошюралар тәрҗемә итә. Мәктәп һәм мәдрәсәләр өчен «Русча-татарча кесә лөгате» (1915), русча-татарча, татарча-русча сүзлекләр һәм уку ярдәмлекләре авторы.

[7] Кыям (Кыяметдин) Исхак улы Юлдашев (1890–1955) – шагыйрь. Матбугаттагы беренче язмалары 1910 елларда басыла. «Зилзилә хикәясе һәм балалар өчен гыйбрәтле шигырьләр» (1912), «Моңлы тавышлар яки моңлы шигырьләр» (1912) шигырь җыентыклары авторы.

[8] Фәрит Таҗетдин улы Ибраһимов (1893–1943) – шагыйрь, мөгаллим. Шигырь һәм поэмалары 1912–1917 еллардагы татар вакытлы матбугаты («Аң», «Сөембикә», «Ак юл», «Балалар дөньясы», «Кояш», «Себер) битләрендә актив басылган. 1912 елда «Уйларым» һәм «Өмидемнең нурлары» дип аталган ике шигырь җыентыгы дөнья күрә.

[9] Габдерәшит Рамазанов (XIX йөз ахыры – 1919) – шагыйрь. 1910–1914 елларда шигырьләрен «Шура» журналында, «Йолдыз», «Кояш», «Идел» һ. б. газеталарда бастыра. «Габдерәшит Рамазанов шигырьләре» (1910 ел), «Дәртле уку» (1912 ел), «Уку гөле» (1912 ел) җыентыклары авторы.

[10] Язучы, журналист Чыгтай (Галиәсгар Мөгыйн улы Гафуров; 1867–1942) күздә тотыла.

[11] Шәйхулла Сибгатулла улы Алкин (1893–1918 елдан соң) – сәясәт һәм җәмәгать эшлеклесе, язучы.

С. Җәлал[1], Максуди, Б. Мирзанов[2], И. Гобәйди, Р. Ибраһимия[3], К. Гозәй, Г. Терегулов[4], З. Нуркин[5], Н. Гасрый, Имаметдин Шаммаси[6], Г. Кариев, Нәкыя[7], Г. Ильяс[8], Р. Баязид, Тимерләң, Исхак Бахитов, Кәшшаф Патии[9], З. Сәгыйдә[10], Г. Биги, Галә Ходаяров, Гали Раһиб, Зәүкый[11], Ченәкәй, Г. Исәнбирдин[12], Искәндәр Киләүле[13],

[1] Садри Җәлал (Садрислам Хәйретдин улы Вәлидов) (1891–1943) – язучы, тәрҗемәче. Беренче хикәяләре «Ак юл», «Аң» журналларында 1913–1914 елларда басылып чыга. XIX йөз морзалары тормышыннан язылган «Дим буенда» (1914) исемле романтик повесте белән киң катлау укучыга танылa.

[2] Бәхтияр Гомәр улы Мирзанов (1892–1941) – шагыйрь. Инкыйлабка кадәр «Сөембикә» журналында эшләгән, «Аң», «Шура», «Сөембикә», «Балалар дөньясы» журналларында, «Тормыш», «Вакыт», «Кояш» газеталарында шигырь-поэмалары басылган.

[3] Рокыя Ибраһимия – XX йөз башы татар матбугатында берничә шигыре басылган автор.

[4] Гомәр Хәбибрахман улы Терегулов (1883–1938) – җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, язучы.

[5] Заһидулла Садретдин улы Нуркин (1888–1966) – журналист, тәрҗемәче. Башлангыч мәктәпләр өчен уку ярдәмлекләре төзүдә катнаша («Туган тел», 1–4 кисәк, 1916–1918; «Татарча уку», 1920; «Яңалиф», 1929).

[6] Имаметдин Шаммаси – XX йөз башында иҗат иткән татар шагыйре.

[7] Нәкыя (Нәкыя Сәлах кызы Сәйфуллина, 1889 – 1960) – педагог, журналист, тәрҗемәче. Газета-журналларда язына, «Аң» журналында нәсерләре басыла.

[8] Г. Ильяс – нашир, тәрҗемәче, язучы Әхмәтгәрәй Сибгатулла улы Хәсәнинең (1883–1933) тәхәллүсе. Татар телендәге «Аң» журналының нашире һәм мөхәррире (1912–1918); «Денщик Гали» (1907), «Хат болгатты» (1907) комедияләре, халык әкиятләре мотивлары буенча балалар өчен «Батыр тегүче һәм үги ана» хикәяләр җыентыгы (1914) авторы. А. Чеховның «Бәхәс» («Спор»), А. Франсның «Бине Бәшир тарихы» («История бин Башира»), А. Амфитеатровның «Укучы дус» («Ученик-друг»), А. Апинянскийның «Сахра» («Простор») хикәяләрен татар теленә тәрҗемә итә.

1926 елда татар язучылары, галимнәре, журналистлары, әдәбиятчылары, шул исәптән Хәсәни тарафыннан «Яңа китап» кооператив нәшрияты оештырыла, анда Хәсәни нәшрият эше белгече буларак чакырыла.

[9] Кәшшаф Патии (Габделкәшшаф Патиев) – XX йөз башы шагыйре. «Кәшшаф Патии шигырьләре» (1910), «Әшгарь» (1915) дигән шигырь җыентыклары бар.

[10] З. Сәгыйдә (Зәйнәп Хәлиулла кызы Якупова-Бакирова,1897–1994) – шагыйрә һәм язучы. Әсәрләре «Шура» журналында һәм «Вакыт» газетасында басылган.

[11] Зәүкый – Г. Сәгъдинең тәхәллүсе. М. Мәһдиев фикеренчә, Г. Сәгъди ««Шура»да бик еш кына уртакул шигырьләр бастырган. Әдәбият теориясе белән шөгыльләнгән (димәк, башкаларны өйрәткән) галим үзенең уртакул шигырьләренә «Г. Сәгъди» дип имза куярга җөрьәт итмәгән һәм «Рухи», «Зәүкый», «Фикри» кебек псевдонимнар алып, галим Габдрахман Сәгъдинең абруен саклаган» (Кара: Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар. Татар әдәбиятында тәхәллүсләр / төз.: Л.Ш. Гарипова, Г.Н. Зәйниева. – Казан: ТӘһСИ, 2021. – 10 нчы чыг. – Б. 254).

[12] Гыйззетдин Исәнбирдин (1888–1968) – шагыйрь, педагог. Шигырьләре «Шура» журналы битләрендә еш күренгән. 1914 елда Уфада «Гыйззетдин Исәнбирдин шигырьләре» исемле җыентыгы басылып чыга. Шигъри тәрҗемәләре, мәкаләләре дә бар. Совет чорында әсәрләре басылмаган.

[13] Искәндәр Киләүле – XX йөз башында иҗат иткән татар шагыйре. Дистәдән артык шигыре «Шура» журналында басылган.

Сабир Габделмән[1], Гариб, Фиракый, Кылчык, Кәшиф Кормаш[2], Мәхмүд Бөдәйли[3], Мәхмүд Мәрҗани[4], Хәбиб Исхакый[5], Җарулла Виргазин, Габделхәбир Габдуллаев, Хөсәен Абушаев[6], Г. Мөхәммәт, Сәлах Җәләй, Хөсәен Атлаши[7], Ягъкуб Айманов[8], Габдрахман, Шәйхулла Тулбин, Габдесамат углы Габделхак, Фуад Илчурин, Габдулла Габдуллин, Гасаби, Гайнелхәят Илинова, Ширияздан, Фәтхелкадыйр, Әхсән Кормашев[9], Нурлыһода Кормашева, Х. Әлмөхәммәдев, Әхмәдҗан Мостакай, Мостафа Сабит, Камал Максуд, Гали Акбирдин, Сәгыйть Ваккас[10], Мөҗавиров, Мөхәммәдгариф Шәрифи[11], Гыйззетдин Камал Фәхри, Юмаев[12], Карый Мөхәммәдрәхим һәм башкалар.

*Габдрахман Сәгъди. Татар әдәбияты тарихы: дәреслек-кулланма. – Казан: Татар. дәүләт нәшр., 1926.*

---

[1] Сабир Габделмән (1879–1918) – шагыйрь. Шигырь, хикәя, публицистик мәкаләләре «Шура» журналында, «Кояш» газетасында һ. б. басыла. Социаль һәм антиколониаль яңгырашлы «Фөрьядлар» («Аһ-зарлар», 1908) исемле лирик шигырьләр җыентыгы һәм балалар өчен «Нәтиҗәи әхлак. Хикмәтле сүзләр вә хикәяләр» (1909) китабы авторы.

[2] Кәшиф Кормаши – XX йөз башында шигырьләре матбугатта урын алган шагыйрь. Тәрҗемәи хәле билгесез.

[3] Мәхмүт Кәшфелһади улы Бөдәйли (1895–1975) – язучы, журналист, җәмәгать эшлеклесе. Сатирик, юмористик әсәрләр, фәнни-популяр брошюралар авторы.

[4] Мәхмүт Галәветдин улы Мәрҗани (Мәхмүт Галәү) (1886–1938) – язучы, журналист, тәрҗемәче.

[5] Хәбиб Исхакый (1883 – 1913) – XX йөз башында иҗат иткән шагыйрь, лирик һәм сатирик шигырьләр, әкият-поэмалар авторы.

[6] Хөсәен Абушаев-Атлаши (Хөсәен Йосыф улы Абушаев, 1892 – 1961 елдан соң) – шагыйрь. Шигырьләре 1909–1915 елларда «Идел», «Вакыт» газеталарында, «Шура», «Чүкеч» журналларында басыла. Аерым шигырьләре «Яңа әдәбият» хрестоматиясенә (1914, төзүчеләре Г. Ибраһимов, Г. Баттал) кертелә.

[7] Хөсәен Абушаев-Атлаши күздә тотыла булса кирәк.

[8] Ягъкуб Айманов (1891–1937) – укытучы, шагыйрь. Әсәрләре «Кояш» газетасында һәм «Шура» журналында басыла. «Табигать» (1913 исемле шигырь китабы авторы).

[9] Әхсәншәех Кормаши – инкыйлабка кадәр «Шура», «Таң» журналларында язышкан шагыйрь. «Әхсәншәех Кормаши шигырьләре» (1914) җыентыгы авторы.

[10] Сәгыйть Ваккас – шагыйрь Сәгыйть Сүнчәләйнең тәхәллүсләреннән берсе.

[11] Мөхәммәтгариф Ибраһим улы Шәрифи – XIX йөз ахыры – XX йөз башында яшәгән шагыйрь. Чистай шәһәре һәм Яуширмә авылы мәдрәсәләрендә укыта. Шигырьләрендә («Вакыт», «Идел» газеталарында, «Аң», «Шура» һ. б. журналларда басылганнар) татар милләтенең язмышы турында борчулы уйланулары чагыла. Милләтнең үсешен һәм чәчәк атуын илдәге иҗтимагый стройның үзгәрүе белән бәйли. «Идеал, яки күңел теләге» (1912), «Күңел зары» (1913) җыентыклары, педагогика буенча мәкаләләр авторы.

[12] Җамалетдин Хәлиулла улы Юмаев (1892–1940) – шагыйрь, дин эшлеклесе. Беренче шигырьләрен «Шура» журналында, хикәяләрен, сатира язмаларын һәм фельетоннарын татар газета һәм журналларында бастыра. «Җамалетдин Юмаев шигырьләре» (1913), «Әдәби шигырьләр» (1915) җыентыклары авторы. А.С. Пушкин һәм М.Ю. Лермонтов әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә.

# ТЕКСТЛАРНЫ ГАМӘЛДӘГЕ ЯЗУГА КҮЧЕРҮЧЕЛӘР ҺӘМ ШӘРЕХЛӘҮЧЕЛӘР

*Гомәров И.Г.* – филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге мөдире.

*Надыршина Л.Р.* – филология фәннәре докторы, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге өлкән фәнни хезмәткәре.

# ЭЧТӘЛЕК

Кереш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 5
Берничә сүз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7
БЕРЕНЧЕ ДӘВЕР . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 10
I. Кереш. Әдәби дәверләр турында берничә сүз . . . . . . . . . 10
II. Беренче дәвергә кыскача гомуми бер караш. . . . . . . .
(Икенче дәверләргә хәзерлек урынында) . . . . . . . . . . . . 10
ИКЕНЧЕ ДӘВЕР . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 36
**Беренче баскыч** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 36
I. Икенче дәвердә икътисади, иҗтимагый-сәяси як . . . . . 36
II. Реформа тармаклары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 45
1. Әдәби тел. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 45
2. Фәннәр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 74
3. Дин реформасы – дини уяну . . . . . . . . . . . . . . . 83
4. Җәдитчелек хәрәкәте һәм ысулы саутия . . . . . . . . . 87
5. Матур әдәбият . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 96
III. XX йөзгә кергәндә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 120
1. Белем әдәбияты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 122
2. Матур әдәбият . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 126
**Икенче баскыч (1905–1917)** . . . . . . . . . . . . . . . . . 168
1. Иҗтимагый-сәяси хәрәкәтләр һәм җәмәгатьчелек
әдәбияты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 168
2. Әдәби тел. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 205
3. [Октябрьдән элек] ун ел эчендә белем әдәбияты . . . . 230
4. Ун ел эчендә матур әдәбият . . . . . . . . . . . . . . . 239
Текстларны гамәлдәге язуга күчерүчеләр һәм шәрехләүчеләр . 350

**Габдрахман Сагди**

**ИЗБРАННЫЕ СОЧИНЕНИЯ**

**Том 2**

**Духовное наследие: поиски и открытия**

Выпуск 23

(На татарском языке)

Редактор Л. Г. Шарифуллина
Компьютерная верстка Н. Т. Абдуллиной
Дизайн обложки Т. В. Семиной

Подписано в печать: 01.12.2024.
Бумага офсетная. Формат 60×84 1/16. Гарнитура «Таймс».
Усл.-печ. л. 14,9. Уч-изд. л. 13. Тираж 300 экз. Заказ

Оригинал-макет подготовлен
в Институте языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. К. Маркса, 12

Издательство Академии наук Республики Татарстан
420111, Казань, ул. Баумана, 20